Тәлгат НӘҖМИЕВ

# Сабаларда эчәр суым булгач...

*Очерклар*

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2006

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Н98
**Нәҗмиев Т.С.**

Сабаларда эчәр суым булгач...: Очерклар / Тәлгат Нәҗмиев. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 367 б.

ISBN 5–298–04013–6

Бу китапка авторның сәяхәтнамәләре, күренекле шәхесләр һәм Саба җиренең ихтирамлы кешеләре турында очерклары, тарихи язмалары тупланды.

ISBN 5–298–04013–6
© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Нәҗмиев Т.С., 2006

## Каләм көче

...Яңгыр чиләкләп коя.

...Буран котырыпмы-котыра.

...Гадәттә, ел фасыллары алышынган чакларда, гарасат куба.

Яңгыр сибәли. Иркен ишегалдының уртасына басасың да юка күлмәгеңнең иркәләнеп чылануын рәхәтләнеп көтәсең.

Бизәкле һәм уенчыл кар бөртекләре иркәләнеп һәм күзләрне иркәләп очалар.

Сабыйча сулышыбыз табигать миһербанынннан иркәләнеп ала.

Бала чактан ук күңеләңә табигать кочагының нарасыйлык-наныйлык һәм баһадирлык-пәһлеванлык көче сеңә, ягъни туган ягыңны яратуың безнең төбәктә, безнең авылда, безнең урамда, безнең ишегалдында гына җитлегүче шушы дуамал һәм назлы күренешләрдән башлана булыр.

Аннары такыр сукмакларыннан йөгергәндә, болын чәчәкләрен иснәгәндә, тау башларына үрмәләгәндә, уҗымнарны сыйпаганда, искитмәле төшләре-урыннары туган ягыңны яратуны көчәйтә. Әйе, безнең Саба җирләрендә сихри-серле, борынгылыкны искәртүче, хәтта әкиятилеккә тартым атамалар ишле: Алпамша чабатасын какканнан соң өелгән чүмәлә таучык, Аждаһа купканнан соңгы Түгәрәк чишмә, Шүрәле сазлыгы, Төпсез кое, язгы кыр эшләре башлануга бәйле исемдәге Зәрәтау һ.б.

Табигатьне тануың туган ягыңның хезмәтчел кешеләренә һәм дә, әлбәттә, төрле һөнәр ияләренә соклануың белән үрелеп бара. Сәяхәтләрдә дә, күренекле шәхесләр белән очрашканда да, төбәктә хәзер яшәүчеләр белән күрешкәндә дә Саба җире истән чыкмый. Саба ягының кешеләргә ихтирамлы булырга өйрәтүенә сөенәсең, аларга игелек кылырга кирәклеген бурычың санийсың һәм, һөнәреңә тугры калып, каләмеңне эшкә җигәсең.

Гәрчә туган җире хәзерге бүленештәге Саба районы булмаса да, алда сөйләнгәннәр бу китапның авторы Тәлгат Нәҗмиев тормышына һәм иҗатына бик тә хас. Ул күрше Кукмара төбәгенең Байлангарында туган, ә хәзер инде шәҗәрәсенең ике буыны Байлар Сабасына турыдан-туры бәйле. Саба районына Тәлгат Самат улы 1967 елдан бирле хезмәт итә, инде төгәл чирек гасыр — район газетасы мөхәррире. Саба мәзәкләреннән өч китап чыгарды, «Саба шагыйрьләре» исемле җыентык төзеп бастырды, «Керик әле Саба урманнарына» һәм «Яшә, Саба-Йорт!» исемле күләмле китапларының автордашы (беренчесендә Мөнир Абдуллин, икенчесендә минем белән, икесендә дә аның өлеше зуррак икәнен таныйбыз) булды. Олы хезмәтләре өчен сабалылар аны үз итәләр. Әйе, Саба төбәге кешесе ул Тәлгат Нәҗмиев.

һәм ул моның белән хаклы горурлана.

Китапның беренче бүлегенә — сәяхәтнамәләр, икенчесенә күренекле шәхесләр турындагы очерклар тупланган, өченче бүлекне районның хәзерге хәле-торышы һәм кешеләре турындагы язмалар тәшкил итә. Район тарихын нигезле теркәү Тәлгат Нәҗмиев иҗатында эзлекле дәвам итә, өч китаптагы мәзәкләр дә елмаюлы тарих лабаса. Тәлгат Самат улының Саба җирендәге атамаларны — тарих шаһитларын өйрәнеп язган хезмәте дә бар. Анысын да бастырып чыгарырга насыйп кылсын.

Шулай — бер темага күп үк эшләнгән. Бәхәссез бу. Әмма күп иҗат итү турындагы ике мисалны шушы урында теркәүне кирәк саныйм.

Бөек япон рәссамы, гравюра остасы Андо Хиросиге (1797–1858) ун яшендә «Фудзи тавын кар каплаган» исемле картинасын ясый. Аның биш меңнән артык гравюрасы барлыгы мәгълүм. Алар арасында — «Кисокайдоның 69 күренеше» һәм «Эдоның 400 атаклы күренеше».

Японнарның тагын бер күренекле рәссамы Кацусика Хокусай (1760–1849) биш йөз китапка иллюстрацияләр ясый, шулар тупланган унөч томлыгын бастыра. Сәяхәт итәргә яратучы бу шәхеснең пейзажлары да күп икән. Ике ел дәвамында ул «Фудзи тавының 36 күренеше»н ясый, аннары бу тау күренешләре рәсемнәрен йөзгә үк җиткерә — туган җиреңне — иленне ярату, олылау әнә шулай була! Саба җире турындагы китаплар да күбәйсен дә күбәйсен иде. Тәлгат дус, иҗат каләмеңнең көче һаман ныгый барсын!

*Мәгъсум Хуҗин*
*23 май, 2006*

# Бухенвальд кабат сагышта

1990 елда ике Германия берләшкәч, 16 җир (җир — бездәге өлкәләр, крайлар төшенчәсендә) барлыкка килгән. Менә без, Татарстаннан килгән бер төркем журналистлар, Тюрингия җиренә урнашкан Бухенвальд (бу сүз «бук агачы урманы» дигәнне аңлата икән) концлагерена юл тотабыз. Фашизм вәхшилеге символы булган бу тәмугны һәркемнең үз күзләре белән күрәсе килә. Юлыбыз Лейпцигтан ерак булмаган Веймар шәһәре аша үтә. Бу — 975 елда ук төзелеп, XVIII гасыр ахыры — XIX гасыр башында Германиянең мәгърифәт үзәгенә әйләнә. Биредә күренекле фикер ияләре, шагыйрьләр, музыкантлар яшәгән. Немец халкының мәхәббәт һәм гуманизм җырчылары Гете һәм Шиллер торган йорт-музейны караганнан соң, 65 мең кешенең гомере өзелгән урынга бару җиңел түгел, әлбәттә. Патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең 1943 елның декабрендә язылган «Алман илендә» дигән шигырендәге таныш куплетларны Казан дәүләт университетының журналистика факультеты деканы Флорид Әхмәт улы Әгъзәмов күңеленнән искә төшерә:

Синме соң бу — бөек Маркс иле
Һәм давыллы Шиллер ватаны?
Тоткын итеп сиңа китерде дә
«Кол» дип мине немец атады.

Шулай дипме сине белә идем,
Гете белән шашкан чагымда?
Бетховенның кыю симфониясе
Ник яңгырамый мәрмәр залында?..

Менә Веймардан берничә чакрымда гына булган тау башындагы Бухенвальдка күтәреләбез. Лагерь өчен урын алдан уйланылып сайланган. Көзге әче җилләрдә ач-ялангач тоткыннар шушында таш кискәннәр йә дистәләгән сәгать буе басып торганнар, хәлсезләр шунда егылып та үлгәннәр.

— Без бара торган автотрасса «җен юлы» дип аталган, — дип сөйли тәрҗемәчебез Алла Мельничук. — Шушыннан әсирләрне котырган тизлек белән этләр өстереп, таяклар белән кыйный-кыйный куганнар. Тоткыннарның кайберләре шушы канлы юлда ук җан биргән, Бухенвальдның «Едэм дас зайне» — «Каждому свое» — «Һәркемгә үзенеке» дип язылган мыскыллы һәм гыйбрәтле капкасыннан эчкә үтә дә алмаганнар. Эсэсовчылар шушы капка аша һәр көнне меңләгән кешене эшкә куа торган булганнар.

Менә без бер катлы комендатура бинасына керәбез. Ул террорның, җәберләүнең үзәк штабы булган. Биредә комендантлар булып Карл Кох (1937–1941 еллар) һәм Герман Пистер (1942–1945 еллар) утырганнар һәм коточкыч режим саклаганнар. Дөрес, беренчесе сугыш беткәнче үлгән, әмма аның хатыны — табиб Кох — 46 нчы блокта коточкыч медицина сынаулары уздырган. Бик күпләр монда түзә алмаслык газаплар кичергәннәр, аларга төрле вакциналар кертелгән, фосфор белән тәэсир итеп, тәндәге итләре сөяккә кадәр яндырылган. Исән калган әсирләр дә, шаһит калдырмау максатыннан, соңыннан юк ителгән.

Дөрес, тоткыннар асралган бараклар бүген юк инде. Алар нигезенә чуерташ җәелгән, номеры, кайсы ил әсирләренеке икәне күрсәтелгән мемориаль такталар куелган. Бу баракларда яшәү җәһәннәмгә

тиң булган. Мәсәлән, 48 ат сыйдырышлысында 1500 кеше тотылган. Совет әсирләре өчен биредә 6 блок булган. Беренче 2000 тоткынны 1941 елның 18 октябрендә бөтен Германия аркылы куып алып килгәннәр. Сәләмә киемнәрдәге хәлсезләнгән әсирләрне шулай итеп «бөек» халыкка күрсәткәннәр.

Биналар, биналар... Таштан эшләнгәннәре элеккеге хәлендә саклана. Әнә сәяси бүлек. Бирегә китерелгән кеше кире чыкмаган диярлек. Әмма контроль һәм террор никадәр көчле булуга карамастан, әсирләр тик ятмаган. Мәсәлән, ашханә бинасы подвалында яшерен хәрби оешма булган, хәтта үзләре ясаган кул гранатасын сынап караганнар. Лазарет бинасына Интернациональ комитет җыйнала торган булган. Дезинфекция бүлегендә эшләүчеләр лагерьда эпидемия таратмау өчен күп көч куйганнар. Бер кешелек камералары булган һәм 600 ләп әсирнең башына җиткән «бункер»ны карау да җиңел түгел.

Өч катлы кирпеч бинага якынлашабыз. Монда фашистларның складлары урнашкан. Концлагерьга килүчеләр биредән өс киеме алганнар. Шунысы характерлы: биредә фашизмга каршы теләктәшлек белдерүче изге җанлы немецлар өч яшьлек Стефан-Ежи Цвейгны яшереп саклыйлар һәм үлемнән алып калалар. Аның язмышы соңыннан язучы Бруно Апицның «Голый среди волков» дигән китабында сурәтләнә. Гомумән, Бухенвальдка яһүд һәм чегән сабыйлары 1938 елда ук күпләп китерелә һәм 8 нче балалар блогына урнаштырыла. Аларга изге ниятле кешеләр тарафыннан мөмкин кадәр ярдәм күрсәтелә. Бухенвальд азат ителгән вакытта да монда 904 бала һәм яшүсмер була әле...

Мәйдан уртасындагы арба белән баганага күпләр игътибар итә. Алар бүген дә урыннарында тора. Менә шул баганага кулларны артка бәйләп асып кую иң коточкыч җәзалардан саналган. Аяклары җиргә тимәгән килеш озак эленеп торган әсирләр шунда җан биргән. Ә бу арбага башта 50 тонна таш төягәннәр, аннары әсирләрне агач яки резин чукмарлар белән кыйный-кыйный, җырлатып шул йөкне өстерәткәннәр һәм аларны мыскыл итеп «җырлый торган атлар» дип атаганнар.

Әкренләп крематорий бинасына якынлашабыз. Аның озын торбасы әллә кайдан ыржаеп тора. Крематорий, үлүчеләр артык күбәя башлагач, 1940 елда төзелгән була. Тоткыннарны бирегә медицина комиссиясенә дип керткәннәр, башта буйны һәм авырлыкларны үлчәгән рәвеш ясаганнар, соңыннан атканнар, кирәкле әйберләрне — теш, чәч, дару ясау өчен кирәкле бизләр алынганнан соң, тимер арбага төяп, мичкә тутырганнар. Бары тик бер мәртәбә бирелә торган гомернең тән калдыклары шушы торба аша кара төтен булып таралган. Ә инде мичтә калган көл ашлама итеп файдаланылган. Бүген дә крематорий идәнендә чәч толымнары бар.

Әсирләрне биредә генә үтермәгәннәр, әлбәттә. Мәсәлән, читтәрәк урнашкан ат абзарында кешенең баш чүмеченә туп-туры ата торган җайланма көйләгәннәр, шул ысул белән 8483 совет тоткыны юк ителгән. Аннан таш чыгару урынында да байтак кеше һәлак булган. Эсэсовчылар кайбер вакытта әсирләрне чәнечкеле тимерчыбык янында эшләргә мәҗбүр иткәннәр һәм «качарга җыенды» дигән сылтау белән атып үтергәннәр. Оста «мәргән»гә премия биргәннәр...

1944 елның 18 август төнендә Германия Коммунистлар партиясе рәисе Эрнст Тельман шушы концлагерьда үтерелә.

1945 елның 11 апрелендә Бухенвальд тоткыннары азат ителә. Быел аның 50 еллыгы билгеләп үтелде.

Бухенвальд концлагере кырыена мәһабәт мемориаль комплекс эшләнгән. «Милләтләр урамы» дип аталган рәттәге ут кабызыла торган тәлинкәле таш баганаларны унсигез илнең һәркайсы үзе күтәргән. Илле метр биеклектәге Чаң башнясы әллә кайдан күренеп тора. Ул 11 апрель көнне генә суга икән. Күңелгә тагын бала чактагы җыр сүзләре килә: чаң сугалар, чаң, ул тавыш килә Бухенвальдтан...

Тетрәндергеч сәяхәт булды бу. Әлеге җирләрне икенче тапкыр күрәсе килә торган түгел. Хәзер, Германия берләшкәч, экскурсияләр вакытында фашистларның вәхшилеге турында йомшартып сөйли башлаганнар, эш сәгатьләре кыскарган. Бәлки, тора-бара Бухенвальд мемориалы ябылыр да. Кайсы халык үз вәхшилеген үзе күрсәтсен.

1995 елда крематорий бинасын шартлатып юк итәргә дә маташканнар... Кыскасы, Бухенвальд кабат сагышта.

*1995*

## Яуширмәдән Истанбулга

Безнең буынга Гаяз Исхакый әсәрләрен өйрәнеп үсәргә насыйп булмады. Аның исемен авыз тутырып әйтә, әсәрләре белән таныша башлаганга җиде-сигез елдан артык түгел. Казанда нәшер ителә торган «Заман-Татарстан» газетасы мөхәррирләре чакыруы буенча Истанбулга барасым билгеле булгач, мин Гаяз Исхакый иҗаты үрнәкләрен әүвәл «Мирас», «Казан утлары» журналларында укыдым, аннары «Зиндан» китабы дөньяга чыкты. Әлеге сайланма әсәрләр җыентыгы басылу зур, күптән көтелгән вакыйга булды, әлбәттә. Бу уңайдан танылган шагыйрь Рәшит Гәрәй, горурланып:

...Ябырылды халык китапларга.
(Зинданнардан чыккан «Зиндан» томы!)
Ниһаять, без... күпме гомердән соң
Кулга алдык бөек Исхакыйны, —

дип язды үзенең «Гаяз Исхакый китабы чыккач» шигырендә.

Төркиядә булган милләттәшләребезнең татар әдәбияты классигы, атаклы прозаик һәм драматург, ялкынлы публицист һәм тәрҗемәче, күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче Гаяз Исхакый каберенә зиярәт кылмыйча кайтмаганнарын укып белгәнгә күрә, иң элек аның туган авылына сугыласы иттек. Чистайга барып җиткәнче үк икән ул милли азатлык өчен билбирмәс көрәшчене тудырган Яуширмә. Элек-электән мәгълүм: бу авыл халыкка мондый олы затны буш урыннан гына алып үстермәгән. Мөхәммәтгаяз (мулла кушкан исеме) бик укымышлы Гыйлаҗетдин хәзрәт гаиләсендә 1878 елның 22 февралендә дөньяга килә. Әнисе Камәрия абыстай да шул якларның абруйлы дин эшлеклесе Вәли хәзрәт кызы була. Яуширмә гомер-гомергә иң укымышлы, иң тәрбияле, иң әдәпле авыллардан саналган. Менә аның урамнарына аяк басабыз. Моннан бер гасырдан артык элек кечкенә Мөхәммәтгаяз җәен чирәмнән, кышын кар өстеннән аяк эзләре калдырып йөргәндер бу изге туфракта. Гыйлаҗетдин хәзрәтнең балалары яшьли үлә барганга, малайны бик кадерләп үстерәләр. Ул кечкенәдән үзенең үткенлеге белән аерылып торган. Биш яшендә укырга өйрәнеп, тиз арада әтисе мәктәбендәге программаны үзләштереп, гарәп-фарсы китапларын укый башлаган. Унике яше тулар-тулмаста, аны Чистай мәдрәсәсенә бирәләр. Яшьтәшләреннән күпкә алдан киткән Гаяз, өч елдан соң Казанга барып, «Күл буе» мәдрәсәсендә белем алырга керешә. Әмма туган авылын сагынып яши, мөмкин булган саен кайтып йөри.

## МУЗЕЙДАГЫ ТӘЭСИРЛӘР

Менә без Гаяз Исхакый музеен эзләп таптык. Ул хәзергә мәдәният йортының бер бүлмәсенә урнашкан икән. Аның хуҗасы, гомер буе китапханәдә эшләгән энтузиаст Ясирә ханым Вәлиева, якты йөз белән каршы алды безне. Иң беренче күңелдә калган җылы тәэсир шул булды: музей ишегеннән керүгә, якташларыбыз Рөстәм Зарипов белән үзешчән композиторыбыз Рәисә Имамиева Гаяз Исхакыйга багышлап иҗат иткән «Сагыш»ның стенадагы зурайтылган текстына күзебез төште. Ул җыр олуг язучыга багышланган кичәләрдә яратылып башкарыла икән. Безгә аны Ясирә ханым үзе җырлап күрсәтте һәм музей белән таныштырырга кереште.

— Без хәзергә шушы бүлмәгә сыендык, — дип сүзен башлады ул. —Озакламый Гаяз Исхакый музей-утары булыр дип өметләнәбез. Менә аның план-макеты да бар. Музейның төп бинасы итеп Исхакыйларның кияүләре булган Сәйфетдин байның кирпеч йорты реконструкцияләнәчәк. Аларның үз нигезләре хәзерге балалар бакчасы урынында булган. Бу урамга Гаяз Исхакый исеме бирелде. Истанбулга — авылдашыбыз каберенә — туган йортының туфрагын алып барырга планлаштыргансыз икән, шуннан алырсыз. Безгә дә музейны оештырганда әдәбият белгече Лена Гайнанованың ярдәме бик зур булды. Китаплар бүләк итте ул. Кайбер төп нөсхәләрне әдәбият галиме мәрхүм профессор Ибраһим Нуруллин биреп торды. Аларның күчермәләрен алып, китап итеп төпләттек. Бу зур портретны мәшһүр язучының 115 еллыгы уңае белән ясаткан идек, менә бюстын да эшләп бирделәр.

Экспозицияләргә китаплар белән беррәттән фотолар да урнаштырылган. Аларның шактыен Ташкент шәһәрендә яшәүче Сөембикә ханым җибәргән. Билгеле булганча, Гаязның бертуган өч сеңлесе — Фәридәбану, Хәлимәбану һәм Гайнемәрзия була. Сөембикә — Гайнемәрзия кызы. Аңа «халык дошманы»ның туганы булган өчен бик күп кыенлыклар кичерергә туры килә. 1938 елда илле алты яшьлек Гайнемәрзия апаны төрмәгә ябалар. Бу вакытта Сөембикәгә унҗиде яшь була. Чистай медицина техникумын гел бишкә генә тәмамлаган кызга, Г.Исхакый туганы булганы өчен, институт ишекләре ябыла. Әнисен, бертуган укытучы абыйсы Габделхак СССР Югары Совет Президиумы Рәисе Михаил Калининга хат язгач, ундүрт айдан соң төрмәдән чыгаралар. Әмма булган мөлкәтләре белән бергә өйләрен, мал-туарларын тартып алалар. Гомумән, бу гаиләгә бик күпне кичерергә туры килә. Ниһаять, Сөембикә 1942 елда медицина институтына укырга керә. Соңгы курста укыганда, күрше авылы егете Хариска кияүгә чыгып Ташкентка китеп баралар. Егерме алты ел район шифаханәсендә баш табиб булып эшли. Хәзер аңа җитмеш җиде яшь икән. Әле дә баш табиб урынбасары. Сөембикә ханымга озак еллар Г.Исхакый туганы булуы турында сер итеп сакларга туры килә. Ә менә узган ел ул Әнкара шәһәрендәге төрек мәдәнияте институты хезмәткәре Сәйдә Арсланбәктән чакыру ала һәм Истанбул шәһәрендә дә булып, әнисе белән бертуган абыйсы каберен күреп, дога кылып кайта. Сәйдә ханым Сөембикә апага Г.Исхакыйның кызы — профессор Сәгадәт Чагатай кигән күлмәк белән камзулны бүләк итә. Сәгадәт дигәннән, монда шуны искәртергә кирәк: Гаяз яшь вакытта үз авылларының Мәрьям исемле кызына өйләнә. Әмма алар ике ел гына торып калалар. Кызның әти-әниләре: «Гаяз гел төрмәдә, юлда, сиңа яшәве авыр булыр», — дип әйтә торгач, аерылышалар. Сәгадәт уналты яшькәчә әбисе Камәрия абыстай тәрбиясендә үсә. Аннары Исхакыйның дуслары кызны әтисе янына — чит илгә озаталар. Сәгадәт Таһир Шакирга (Чагатай) тормышка чыга. 1940 ел башында ул кияве белән Әнкарага күчеп килә һәм тел белеме, педагогика өлкәсендә күп хезмәтләр куеп профессор дәрәҗәсенә күтәрелгән Сәгадәт Чагатай-Исхакый 1989 елда 83 яшендә вафат була.

Минем Сөембикә ханым турында алгарак китеп язуымның тагын бер сәбәбе бар. 1997 елның июнь аенда Төркиядә Әхмәтвәли Мәңгәр фонды президенты Сафия ханым Имре, Казанга килеп, Г.Исхакыйның архивын, шәхси медальонын һәм сәгатен Татарстан Президентына тантаналы төстә тапшырды. Имре ханым бу олы мирасны Казанга кайтарганчы, иң элек Сөембикә ападан, варис буларак, рөхсәт сорый. Ә ул бик теләп риза була һәм үзе дә, II Бөтендөнья татар конгрессына килгәч, Гаяз Исхакый кызының күлмәге белән камзулын Казан дәүләт музеена тапшыра.

Матбугатта хәбәр ителгәнчә, Әхмәтвәли Мәңгәр фонды президенты Сафия ханым, аның ире Гыйззәт Имре, фондның вице-президенты Мәхмүт Әллүкәй Сабага да килделәр. Сафия ханымның әбисе (әнисенең әнисе) — Бану ханым тумышы белән Сабабаш авылыннан икәне билгеле булган. Алар әбиләренең туган җирендә булып, мәктәп китапханәсенә латин шрифты белән фонд бастырган китаплар бүләк иттеләр һәм, Төркиягә әйләнеп кайтканнан соң, район газетасы редакциясенә Истанбул шәһәре күренешләрен сурәтләгән затлы альбом җибәрделәр.

## Г.ИСХАКЫЙ ГАЗЕТАСЫ

Гаяз Исхакый тарихчы һәм философ, сәясәтче һәм икътисадчы, педагог, әдәбият һәм сәнгать белгече генә дә түгел — ялкынлы публицист һәм коеп куйган мөхәррир дә. Г.Исхакый, Казанга килүгә үк, рус империясендә төрки телдә чыгарылган бердәнбер газета «Тәрҗеман»ны укып бара. Аннары үзе дә 1905 елда чыга башлаган «Казан мөхбире»нә эшкә чакырыла. Әмма Йосыф Акчура мөхәррирлегендәге бу газета юнәлеше аны канәгатьләндерми. «Минем үз гәзитәм булырга тиеш», — дип әйтә торган була ул. Ләкин үз газетасын чыгару аңа җиңел бирелми. Халык арасында патша хөкүмәте тәртипләренә каршы агитация алып баруы билгеле булган Г.Исхакыйга губернатор нәширлек эшен рөхсәт итмәгән. Шуңа күрә рөхсәт мәдәният эше белән һичбер бәйләнеше булмаган Гали Путиляков исеменә алына. Авырлыклар белән булса да, «Таң йолдызы» исеме белән 1906 елның 18 маенда яңа газета дөнья күрә. Кәгазьдә нәшире һәм мөхәррире Г.Путиляков исәпләнсә дә, аның рухи җитәкчесе Г.Исхакый була. Шулай итеп, бу мәшһүр язучы 1906 елның 18 маеннан башлап үзенең язмышын вакытлы матбугат белән бәйли. «Таң йолдызы», «Тавыш», «Ил», «Ил сүзе», «Маяк», «Милли байрак», «Яңа милли юл» мәҗмугалары да аның гомере агышыннан үтә. Әмма «Таң йолдызы» Исхакый газетасы буларак тарихка кереп кала. Үз чоры өчен куркынычлы революцион фикерләр таратучы матбугат озак яши алмый. Гаязның якын дусты — хезмәттәше, танылган шагыйрь, ул вакыттагы «Таң йолдызы» мөхәррире Сәгыйть Рәмиевнең фатирында тентү булып, полициядән качып, аңарда куна калган Г.Исхакый белән С.Рәмиев кулга алына. Гаязны егерме дүрт сәгать эчендә Казаннан чыгып китү шарты белән азат итәләр. Ул туган авылы Яуширмәгә кайтып китә. Анда да тик ятмый.

Сайлаулар кампаниясе башлангач, Дума депутатлыгына кандидат итеп тәкъдим ителгән Исхакыйны ике айга Чистай төрмәсенә ябалар. Шунда ул «Зиндан» әсәрен иҗат итә. Аннан чыккач, Казанга килеп, революцион эшкә чума, яза. 1907 елның 4 июнендә, яңадан кулга алынып, Архангель өлкәсенә сөргенгә җибәрелә. Гомумән, ул бирегә ике тапкыр сөрелә.

## ӘДӘБИ МИРАС

Ясирә ханым сөйли дә сөйли. Гаяз Исхакыйның әдәби мирасын күңел күзеннән үткәрә. Әдәбиятка Гаяз иртә килә. «Тәгаллемдә сәгадәт» исемле беренче чәчмә әсәрен унҗиде яшендә яза. Ул яңа гасыр кергәнче «Кәләпүшче кыз» исемле повестен, «Бай угълы» дигән романын, «Өч хатын берлән тормыш» пьесасын, «Теләнче кыз» романының беренче кисәген язып тәмамлый. 1904 елда басылып чыккан «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повесте Г.Исхакыйның тормыш, көрәш программасы булып тора. Инкыйраз — бетү, юкка чыгу, һәлакәт дигән сүз. Әсәрдә бүгенге проблема — татар халкының җир йөзендә яшәүяшәмәү мәсьәләсе куела, башка милләтләр арасында эреп юкка чыкмас өчен нәрсә эшләргә дигән сорауга җавап бирелә. «Инкыйраз» заманында Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Г.Тукай иҗатына нык йогынты ясый. Гомумән, «XX йөз башы татар әдәбияты Г.Исхакыйның «Инкыйраз»ыннан чыкты дисәк, зур хата җибәрмәгән булырбыз» дип яза әдәбият галиме И.Нуруллин. Рус әдәбияты белән татар әдәбиятын бәйләп карый ул. 1901 елда ук Г.Исхакый тәрҗемәсендә А.С.Пушкинның «Капитан кызы» повесте чыга.

1908 елның җәендә Г.Исхакый сөргеннән Петербургка качып килә һәм шуннан Истанбулга китеп бара. Сөргендә, Истанбулда һәм Петербургта яшәү чорында ул өч роман: «Теләнче кыз»ның икенче кисәген, «Тормышмы бу?», «Мулла бабай», дүрт пьеса һәм дистәдән артык хикәя-повесть иҗат итә. Гомумән, унынчы елларның башына таба Г.Исхакыйның әдип буларак даны үзенең югары ноктасына җитә. Монда «Гасыр» китап нәшриятының олуг язучы әсәрләренең 8 томлык басмасын чыгарырга кере-

шүен әйтү дә җитәдер. Милли чикләрне узып, үзәк матбугатта басыла башлый. Аның турында «Современник» журналы: «Исхаков татар әдәбиятының башлап җибәрүчесе генә түгел, бәлки татар әдәби теленең атасы да», — дип язып чыга.

## СӘЯСИ КӨРӘШЧЕ

Музейдагы экспозицияләр халкыбызның милли азатлыгы өчен көрәшүче шәхес Г.Исхакый икәнен кат-кат раслыйлар. Моны дәлилләү өчен аның нинди рәсми форумнарда катнашканын санап чыгу да җитәдер. 1905 елгы революцияне ул шатланып каршы ала. «Мөселман иттифакы» партиясенең өченче съездында катнаша. 1906 елның 16–21 августында Бөтенроссия мөселманнарының Түбән Новгородта узган беренче съездында делегат була һәм «Тартышуда гына табарсың үз хакыңны!» дигән лозунгны алга куя.

1917 елгы Февраль революциясеннән соң Г.Исхакый Россия мөселманнарының Мәскәүдә узган Беренче съезды эшендә актив катнаша һәм анда төп докладны ясый. Аның докладı нигезендә резолюция кабул ителә һәм Милли Шура төзелүе белдерелә. Әлеге съездның дәвамы рәвешендә шул ук елның июль аенда Казанда үткәрелгән Икенче бөтенроссия мөселман инициативасы белән Идел-Урал милли-мәдәни мөхтәрияте игълан ителә. Ә инде бу съезд карары нигезендә 1917 елның ноябрендә Уфада булган Милли Мәҗлес Идел-Урал Штатын төзү идеясен алга сөргән карар кабул итә. Әмма совет власте елларында, милли азатлык хәрәкәте бастырылу нәтиҗәсендә, әлеге Идел-Урал Штаты идеясе юкка чыгарыла, милли хәрәкәт юлбашчылары кулга алына, котыла алганнары чит илгә китәләр. Гаяз Исхакый да, Уфада узган Милли Мәҗлес тарафыннан сайланган өчлекнең берсе буларак, 1919 елда Ерак Көнчыгыш аркылы Европага, Версаль солых конференциясенә чыгып китә һәм шуннан туган иленә әйләнеп кайтмый. Эмиграциядә дә ул милли азатлык өчен көрәшен дәвам итә, аның кайчан да булса җиңәчәгенә ышана һәм 1930 елларда «Идел-Урал» дигән тарихи-фәнни хезмәт яза. Бу хезмәт биш ел элек, Чаллыдагы бертуган Рәфис һәм Нәфис Кашаповлар, Илфат Гыйльмазов ярдәме белән аерым китап итеп басылып, бөтен җөмһүриятебезгә бушлай таратылды.

...Әйе, кадерле экспонатлар бик күп музейда, Сөембикә апа тапшырган әйберләрне аерым ихтирам белән күрсәтә Ясирә ханым. «Менә болары — бал кашыгы, шикәр савыты, тәлинкә — Гаяз Исхакыйның шәхси әйберләре. Кызыл башлы сөлге, ашъяулык, тастымал-салфеткаларны Исхакыйның әнисе Камәрия абыстай үзе тукыган булган. Бу дисбе әтисе Гыйлаҗетдин хәзрәтнеке икән. Аларны Сөембикә апа алып кайтып бирде. Музеебыз яңа экспонатлар белән тулылана бара. Чөнки Исхакыйлар нәселе бик зур, алар төрле төбәкләргә чәчелгән, шуңа күрә һәркайсы белән элемтә урнаштырырга омтылабыз...» — ди ул.

Исхакыйларның нәсел очлары бераз гына булса да безнең яклар белән дә бәйле. Журналист Фәнил Нигъмәтҗановның «Үткәнгә хатлар бармыйлар...» дигән язмасыннан («Саба таңнары», 29 октябрь, 1996) күренгәнчә, Г.Исхакыйның бердәнбер хатыны Мәрьям ханымның сеңлесенең кызы Рәисә апа башта Сатыш мәктәбендә укыткан. Аннары Олы Нырсыга күчерелгән. Ул хәзер дә шунда гомер кичерә.

## ВАТАННАН ЧИТТӘ

Туган иленнән аерылгач та, Г.Исхакый гаять актив һәм күпкырлы хезмәт күрсәтә. Төрле илләрдә була, конгресс-җыелышларда катнаша, докладлар белән чыга. 1933 елда Ерак Көнчыгышка барып, өч елга шунда кала, Япониядә, Кытайда һәм Маньчжуриядә яшәүче татарларны «Идел-Урал» байрагы астына туплый. 1935 елда Кытайда аның тырышлыгы белән «Милли байрак» газетасы чыга башлый. 1928–1939 елларда Берлинда «Яңа милли юл» дигән журнал чыгара, үзенең типографиясен тота. Берлин, Париж, Варшава кебек шәһәрләрдә яши. Бөек әдипнең әдәби иҗатына кырык ел тулу уңае белән Варшавада үткән юбилей мәҗлесен филология фәннәре докторы Хатыйп Миңнегулов «Милләтебезнең олуг хадиме һәм юлбашчысы» дигән мәкаләсендә болай тасвирлый:

«...1937 елның 5 марты. Варшавадагы Шәрекъ институтының зур залы. Анда алма төшәрлек тә урын юк: берничә йөз тамашачы. Бирегә Польшаның галим-әдипләре, рәсми хакимият кешеләре, җирле татарлар, Украина, Азәрбайҗан, Грузия, Кырым, Төньяк Кавказ, Идел-Урал, Төркестан һәм кайбер башка төбәкләрнең эмиграциядәге милли-азатлык хәрәкәте вәкилләре — «Прометей» әгъзалары, күпсанлы журналистлар җыелган. Арада Финляндиядән, Алманиядән, Кытайдан, Төркиядән, Румыниядән килгән татар әһелләре дә бар. Залның түрендә «Идел-Урал» җөмһүриятенең байрагы һәм аның астында Гаяз Исхакыйның зур рәсеме.

Үзәкләрне өздерерлек итеп, кыллы музыка кораллары уйный. Бөтен залга татар моңы, татар аһәңе тарала. Менә бөек әдипнең иҗатына кырык ел тулу уңае белән оештырылган мәҗлес башланып китә. Аны Шәрекъ институтының зур галиме Стефан Димушовский ачып җибәрә, юбилярны ихлас күңелдән

котлый, аның Идел-Урал бәйсезлеге өчен көрәшүчеләрнең юлбашчысы булуын искәртә. Гомумән, докладта һәм чыгышларда Гаяз Исхакыйның әдәби-иҗтимагый сәяси эшчәнлегенә искиткеч югары бәя бирелә, аның төрки-татарлар өчен генә түгел, ә изелгән, бәйсезлек өчен көрәшүче башка халыклар өчен дә үз һәм якын булуы әйтелә. Чыгыш ясаучыларның берсе үз сүзен: «Яшәсен Гаяз бәк вә яшәсен мөстәкыйль Идел-Урал җөмһүрияте!» — дип төгәлли. Җыелыштан соң зур концерт булуы мәгълүм. Юбилей вакыйгалары матбугатта да яктыртылыш таба.

Гаяз Исхакыйның 40 еллык иҗат бәйрәме Финляндиядә, Алманиядә, Эстониядә, Румыниядә, Кытайда һәм милләттәшләребез яшәгән башка мәмләкәтләрдә дә уздырыла. Чит илләрдә мин татар язучысын бу кадәр зурлаган башка очракларны белмим. Мондый бәхет биниһая зур хезмәтләре өчен бары Г.Исхакыйга гына насыйп була».

Әмма 1939 елның июль аенда Гитлер Германиясе Польшага һөҗүм башлагач, хөкүмәт кушуы буенча, ул, ашыгудан язмаларын, архивларын калдырып, Төркиягә күчеп китә һәм, гомеренең соңгы 15 елын Истанбул, Әнкара шәһәрләрендә яшәп, 76 яшендә ашказаны яман шешеннән вафат була.

## САМОЛЕТТАГЫ ӘҢГӘМӘ

Менә көткән сәгать сукты. Без, Казан аэропортыннан күтәрелеп, Истанбулга юл алдык. Урыным милләт җанлы шәхес, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры, гомер буе Коръән китаплары җыю белән мавыгучы Шамил Зиннур улы Закиров белән янәшә туры килде.

Ул Казандагы татар-төрек лицее чакыруы буенча сәфәр чыккан икән. Әңгәмәбез башта татар театры турында барды. Соңыннан сүз үзеннән-үзе Гаяз Исхакый драматургиясенә барып тоташты. Шулай булмыйча мөмкин дә түгел, Истанбулга — олы драматург яшәгән һәм җирләнгән шәһәргә барабыз бит.

— Гаяз Исхакыйга багышлап буклет эшлибез, — диде Шамил Зиннурович. — Исемен Тукай сүзләре белән «Кайт әле монда Ватанга...» дип куйдык.

Әйе, олуг шагыйребез Г.Тукай 1913 елны Г.Исхакый хөрмәтенә «Мөхәрриргә» дигән шигырен иҗат итә. Анда мондый юллар бар:

> Кайт әле монда Ватанга, кайт әле, саргайтмәле!
> Күз карашыңнан керер җир тапмасынчы, кер, рия».

Гомумән, Гаяз Исхакый белән Г.Тукай — ике олы шәхес — бер-берсен хөрмәт иткәннәр. Г.Исхакый тирәсендә болытлар куера барган чакта, Г.Тукай, Уральскида «Кем ул?» шигырен иҗат итеп, бу сорауга үзе үк җавап бирә: ул — милләтебезне уяткан, күтәргән кеше; ул — безне телле иткән, караңгыдан яктыга чыгарган кеше; ул — инкыйразның, бетүнең нәрсә икәнен аңлаткан кеше; ул — дошманнарыбызның кемнәр икәнен ачып салган кеше; ул — безнең өчен кыенлыклар чиккән, безне бер көлдергән, бер елаткан кеше...

Без Төркиядән әйләнеп кайтканчы, югарыда телгә алынган буклет дөнья күргән иде инде.

Дөрестән дә, XX гасыр татар драматургиясен Гаяз Исхакый иҗатыннан башка күз алдына китереп булмас иде. Әлеге буклетның соңгы битендә аның унбиш сәхнә әсәренең исемлеге бирелгән, кайчан һәм кайда язылуы күрсәтелгән.

Татар сәхнәсендәге бик күп йолдызларның иҗаты Гаяз Исхакый әсәрләре белән бәйле. Мәсәлән, татар театрының атасы дип бәяләнгән Габдулла Кариевнең профессиональ сәхнә эшчәнлеге бөек драматургның «Өч хатын берлән тормыш» спектакленнән башлана. 1907 елда Чистай төрмәсендә языла башлап, 1911 елда Истанбулда тәмамланса да, 1917 елга кадәр (цензура бетерелгәнче) сәхнә күрә алмаган, татарларны көчләп чукындыруга каршы ачы нәфрәт белдергән, халык трагедиясен чагылдырган «Зөләйха» спектакле, Г.Кариев бенефисында куелып, татар дөньясын тетрәндерә. Бу спектакль Мәскәүдә, Беренче Бөтенроссия мөселман съезды делегатлары каршында уйнала. Зөләйханы беренче булып атаклы актриса Гөлсем Болгарская башкара. Бу драмага композитор Солтан Габәши тәүге тапкыр махсус музыка яза. Әмма Г.Исхакыйның сәхнә әсәрләре никадәр көчле булса да, үзе эмиграциягә киткәч, иҗаты кысрыклана башлый. Чәчмә әсәрләре җыеп юк ителгән кебек, комедия-драмаларына да сәхнә юллары ябыла. 1924 елдан совет сәхнәсендә бер генә әсәре дә куелмый. Әмма аны чит илләрдәге татарлар күтәреп ала. Бигрәк тә «Зөләйха», «Җан Баевич» әсәрләре еш уйнала. Алар, асылда, эмигрант үзешчәннәр тарафыннан сәхнәләштерелә, Кытай, Германия, Финляндия кебек илләрдә аеруча күп куела. Ниһаять, илдә, шул исәптән җөмһүриятебездә, милли мәсьәләләргә карата караш үзгәргәч, Г.Исхакыйның сәхнә әсәрләре дә туган илгә әйләнеп кайта башлады.

— Бу изге эшкә безнең Камал театры аеруча зур өлеш кертә. Күренекле артистларыбыз «Зөләйха» (1992), аннары «Алдым-бирдем» (1994) белән «Җан Баевич»ны (1995) сәхнәләштерде. Әлеге үлемсез әсәрләрне татар милләтенә кайтаруда талантлы режиссерыбыз Празат ага Исәнбәт зур тырышлык куйды. Ул тамашачыны «Зөләйха» белән елатса, «Алдым-бирдем» белән сокландырды, ә инде «Җан Баевич» белән ачы итеп көлдерә алды, — дип сүзен йомгаклады Шамил әфәнде Закиров.

ӘДЕРНӘКАПЫ ЗИРАТЫНДА

Санаулы көн тиз үтә дигәндәй, менә Истанбулдан китәр сәгатьләр дә якынлаша. Әмма минем хуҗаларым — «Заман-Татарстан» газетасының элеккеге һәм хәзерге мөхәррирләре Муаммар бәй белән Мостафа Палабыекның зиратка барырга җайлары чыкмый. Мин пошаманга төшә башладым. Гаяз Исхакыйның кайсы зиратка җирләнгәне дә истән чыккан, җитмәсә. Муаммар Муратның өендәге бай шәхси китапханәсенә күз салсам, төрек китаплары арасыннан татарча чыккан «Зиндан»ны күреп алдым да тиз генә зиратның исемен карадым.

...Менә без Әдернәкапыны да эзләп таптык. Ул тирәдә зиратлар байтак икән. Монысы шәһит киткән дәрәҗәлеләрнеке санала. Башта идарә бинасына кереп, Гаяз Исхакыйның кай тирәгә җирләнүен сорадык. Өлкән яшьтәге ага, бинадан чыгып, бик тәфсилләп аңлатты:

— Исхакыйдан ерак түгел генә Йосыф Акчура күмелгән. Аның кабере өстендә кечерәйтелгән Сөембикә манарасы куелган, — диде безне зират эченә озатканда.

Төрекләрнең зираты үзенчәлеклерәк икән. Бернинди чардуган, үсеп утыра торган агачлар юк, фәкать ак төстәге кабер ташлары. Аларның зурлыгы төрлечә. Шулардан чыгып, мәрхүмнең дәрәҗәсен һәм байлыгын чамалап була. Мавзолей, төрбә итеп эшләнгәннәре бар. Зират бик чиста. Бер генә чүп күрмәссең. Шунда себереп-җыештырып йөрүче ике бабай безне кабер янына ук китереп бастырдылар. Мостафа бәй Мөхәммәтгаяз рухына дога кылырга кереште, мин, бисмилламны әйтеп, ватандашымның туган нигезеннән алып килгән туфракны кабер өстенә сиптем.

АТАТӨРЕК КИҢӘШЧЕСЕ

1935 елда ук җирләнгән милләттәшебез Йосыф Акчура кабере янында басып торганда, «Кем соң ул Акчура?» дигән сорау баштан узды. Шуңа күрә кайткач аның тормыш юлы белән җентекләбрәк таныштым. Бик катлаулы шәхес икән ул. Йосыф — атаклы фабрикант. Акчурин морзалар токымыннан булып чыкты. Ул үзе 1876 елда Сембер каласында туа. Башлангыч белемне татар мәктәп-мәдрәсәсендә ала, әнисе белән Төркиягә барып чыккач, Хәрби академиядә укый, яшьтән үк сәяси көрәшкә тартыла. Алтмыш сигез яшьлек төрек белән берлектә Триполи төрмәсенә озатыла. Аннан качып, Франциягә барып чыга. Анда атаклы Сорбонна университетында укый. 1904–1908 елларда Казанда яши. Россиянең аерым шәһәрләрендә дә булып, татарлар һәм төрки халыклар арасында сәясәт, икътисад, мәдәният, мәгърифәт һәм журналистика өлкәсендә эшли.

Й.Акчура Төркиядә зур иҗтимагый-сәяси эшчәнлек алып бара. Озак еллар Төркия президенты Кемал Ататөрекнең киңәшчесе була. Бер үк вакытта бик күп әдәби һәм публицистик хезмәтләр яза. Әнкара, Сорбонна университетларында профессор була. Ул вафат булгач, Әнкараның бер урамына аның исеме бирелә, Төркиянең автомобиль юллары да «Йосыф Акчура юллары» дип йөртелә. Әйткәнебезчә, кабер ташы урынына Сөембикә манарасының кечерәйтелгән варианты куела.

...Заманында Фатих Әмирхан Гаяз Исхакыйны «сүнә белми торган йолдыз» дип бәяләгән. Ул энциклопедик масштаблы әдипләр һәм галимнәр рәтенә керә. Мин аның әсәрләрен анализлауны максат итеп куймадым. Анысы әдәбият белгечләре эше, фәкать Г.Исхакыйның кабатланмас шәхес булуын укучыга җиткерергә тырыштым. Шулай да Г.Исхакый мирасын Ватанга тулысынча кайтару өчен таулар күчерерлек көч түгәсе бар әле. Әмма шунысы ачык: бүген булмаса, иртәгә ул барыбер кайтачак! Бу язманы кабат бөек шагыйребез Г.Тукай сүзләре белән: «Кайт әле монда Ватанга, кайт әле, саргайтмале!» — дип тәмамлыйм.

*1997*

# Саумы, кояшлы Төркия!

БЕЗНЕ ДӘ ИСТАНБУЛГА ЧАКЫРДЫЛАР

Сәяхәтнамәнең кереш өлеше болай дип аталуы юкка түгел. Чөнки соңгы елларда Россия, шул исәптән Татарстан җөмһүрияте белән багланышлар ныгыган чорда, байтак кына милләттәшләребез, күршеләребездә булып, «без дә бардык Төркиягә», «без дә булдык Төркиядә» дип язып чыккаладылар. Менә бишенче елын Казанда чыга торган «Заман-Татарстан» газетасы мине дә, үзенең актив хәбәрчесе һәм бу яңа басмага яздыруда ярдәм итүче буларак, Истанбулга төп редакция эшчәнлеге белән танышырга чакырды. Дөрес, бу сәфәр 1996 елның җәендә үк буласы иде. Әмма Татарстанда халыкара беренче газетаны оештырган баш мөхәррир Муаммар Муратның Төркиягә эшкә чакырылуы сәбәпле, ул беразга кичектерелде. Муаммар үз урынына урынбасарын — 1992 елның язында бер авыз татарча белмәгән ки-

леш килеп, яңа басманы оештырырга булышкан Мостафа Палабыекны калдырды. Менә аны өч айга бер була торган киңәшмәгә чакырдылар. Шулай итеп, икәүдән-икәү генә Истанбулга юл алдык. «ТУ-154» самолеты белән өч сәгать ярым очканнан соң, безне «Заман» газетасына карый торган Төркиядәге «Җиһан» хәбәрләр агентлыгының кадрлар бүлеге башлыгы Муаммар әфәнде каршы алды.

## КЫСКАЧА БЕЛЕШМӘ

Әлеге мөселман дәүләтенең мәйданы — 779, 4 мең кв.км. Чикләре — иңе — 550 чакрым, буе 2600 чакрымга сузыла. Төркия Истанбул бугазы (Босфор), Мәрмәрә диңгезе һәм Данаккала бугазы (Дарданеллы) белән ике (европалы һәм азияле) төп өлешкә бүленгән. Җөмһүрият Азиядәге алты ил — Иран, Гыйрак, Сүрия, Азәрбайҗан, Горҗестан (Грузия), Әрмәнстан һәм Европадагы Болгария, Румыния белән чиктәш.

Төркияне «цивилизация бишеге» дип йөртәләр. Дөнья цивилизациясенең беренче шәһәре бирелә, Чаталһөектә табылган. Бу шәһәр безнең эрага кадәр 6500 ел элек, Неолит чорында төзелгән. Кыскасы, Төркия — бик бай мәдәниятле ил. Аның үткән юлы бик кызыклы һәм мажаралы. Бигрәк тә «төрек гасыры» буларак дөнья тарихына кергән йөзләр еш искә алына. 1453–1769 елларда, ягъни 316 ел буе Госманлы империясе дөньяның иң куәтле дәүләте булган. Ә инде егерменче гасырга кайтсак, Беренче бөтендөнья сугышы ахырында бу империя җимерелә, Төркия әлеге сугышта җиңелүгә дучар була. Шунда хакимияткә төрек армиясе сафларында сугышкан Мостафа Кемал килә. Аның җитәкчелегендә төрек сугышчылары Төркиядән чит ил басып алучыларын куып чыгаралар һәм Ватанны азат итәләр. 1923 елның 23 октябрендә Мостафа Кемал Ататөрек Төркия җөмһүриятен төзи, тынычлык урнаштыра. Шуңа күрә ул бик хөрмәт ителә, аның портретларын, һәйкәлләрен һәм бюстларын һәркайда күрергә була. Мәктәпләрдә һәр бала көнен Ататөреккә, Ватанына, ата-анасына тугры булырга ант итүдән башлый икән.

## ХАЛКЫ, ТЕЛЕ ҺӘМ ДИНЕ

Төркиядә 65 миллион кеше яши. Төрек теле Урал-Алтай телләре гаиләсенә керә һәм фин-угыр телләргә тугандаш. Монда гарәп алфавиты кулланылган, 1928 елдан латин алфавитын керткәннәр. Төрек телендә дөньяның 150 миллион кешесе сөйләшә. Ул иң элек татар теле белән дә бик якын. Байтак сүзләр уртак. Төркия халкының 99 проценты — мөселман. Төп дине — ислам. Демократик дәүләт буларак, монда һәркемгә теләгән динен тоту иреге гарантияләнә.

## ХАЛЫК ХУҖАЛЫГЫ

Төркиянең дүрттән бер өлешен иген басулары тәшкил итә. Игенчелектә бодай беренче урында тора. Ясмык, ногыт, дөге, шикәр чөгендере, бәрәңге, суган, көнбагыш, мамык, чәй, тәмәке игелә. Яшелчәләрдән — помидор, карбыз, кавын, кыяр; җиләк-җимешләрдән әфлисун, алма, груша, лимон, чикләвек, инжир, персик, мандарин мул итеп үстерелә.

Төркиядә зәйтүн агачлары 9 мең гектарга якын игелә икән. Шуңа күрә бер төрек тә зәйтүн җимешеннән башка чәй эчми. Ул кан тамырларындагы холестеринны юкка чыгаруы белән билгеле.

Киң болыннарда, тау араларындагы җәйләүләрдә күпләп ит, сөт, тире, йон житештерелә. Аеруча сарык асрау тармагы алга киткән, сыер, мамык кәҗәсе, Әнкара кәҗәсе, ишәк, ат вә үгез дә үрчетелә.

Төркия сулыкларга бай. Балык күп тотыла. Аның 90 проценты Кара диңгезгә туры килә.

Икътисадта туризм зур урын алып тора. Соңгы елларда Төркия Европа туристлары арасында иң популяр илләрнең берсенә әйләнгән.

Табигый байлыклары: күмер, хром (төп экспорт), тимер, бакыр, боксит һәм күкерт.

## «ЗАМАН» РЕДАКЦИЯСЕНДӘ

Төркиядә меңнәрчә исемдә газета һәм журналлар чыга. Алар барысы да диярлек аерым ширкәтнеке. Дәрәҗәсе һәм тиражы буенча «Заман» («Сабах» һәм «Хөррият»тән кала) өченче урында тора. Газетаны кем нәшер итә соң? Төркиядә «Феза» дигән шәхси ширкәт бар икән. «Заман» да дәүләтнеке түгел (гомумән, хөкүмәт чыгара торган басмалар юк диярлек), шул ширкәтнеке. Газета табышлы. Нәшер ителү, хезмәт хакы түләү, салым һәм башка чыгымнардан соң редакция елына 1–1,5 миллион доллар саф табыш ала. Шуның 60 мең доллары төрле дәүләтләрдә чыга торган «Заман» газеталарын нәшер итү өчен җибәрелә. «Заман» газетасына баш мөдир Хусәйин Гүләрҗә җитәкчелек итә. Халыкара бәйсез «Заман»

газетасының бүлекләре Төркиядән кала, Алманиядә (Германия), АКШта, Румыниядә, Болгариядә, Македониядә, Татарстанда, Башкортстанда, Казакъстанда, Кыргызстанда, Төркмәнстанда, Үзбәкстанда, Азәрбайҗанда чыга иде. Әле күптән түгел аның Канадада чыга башлавы да хәбәр ителде.

Менә «Заман»ның җиде катлы төп бинасы. Әйткәнемчә, шуның каршына ук «Җиһан» хәбәрләр агентлыгы урнашкан. Аның журналистлары дөньяның бөтен почмакларында эшли икән. Башта Муаммар бәйнең эш бүлмәсе белән таныштык. Заманча җиһазланган, компьютерлашкан, яңача итеп әйтсәк, менә дигән офис икән. Хуҗа бер төймәгә басты һәм чәй кертергә кушты. Чәй дигәннән, аны бөтен җирдә дә: офисларда да, урамда да, базарларда да гел бертөрле кечкенә стаканнарда саталар. Төрек чәе хуш исле, утта түгел, пар өстендә генә пешерелгәнгә шулай икән ул.

Чәйдән соң төп бина белән танышу башланды. Башта ашханәгә чакырдылар. «Заман» газетасында бер меңгә якын кеше эшләүгә карамастан, төшке ашны бушлай бирәләр икән. Аш-су әзерләүчеләр — ир-атлар, ризыклары тәмле, бездәге рестораннардагыдан бер дә ким түгел. Соңга калып эшләүчеләр өчен кичке аш та әзерләнә. Эшкә килү һәм китү хаклары да хуҗа тарафыннан кире кайтарыла.

Үзенең җиңел автомашинасы белән йөрүчеләргә бензин өчен акча да бирелә икән. Әгәр син күршең машинасында эшкә йөрсәң, үзеңә тиешле бензинны аңа алып бирә аласың. Гомумән, әлеге җәмгыятьтә бар да алдан исәпләнгән. Бушка бернәрсә дә эшләнми, һәр тиеннең хуҗасы бар. Баш мөдир, безнеңчә генеральный, өйдә юк иде. «Америкада, редакция өчен яңа техника кайтару артыннан йөри», — диделәр. Безне баш мөдир урынбасары, элегрәк Ташкентта чыга торган «Заман» газетасы баш мөхәррире булып эшләгән Мәһмәт әфәнде Арслан кабул итте. Ике метр гәүдәле, мәһабәт кеше. Башта Татарстан турында сорашты. Аннан үз эшләре белән таныштырды.

— Газетабыз унбер ел нәшер ителә, — диде ул. — Ул Төркиянең биш шәһәрендә көн саен егерме дүрт битле булып (бездәге «Ватаным Татарстан» форматында) берничә төс белән берьюлы басыла. Көн саен диюем 365 көн була инде. Безнең рәсми җиде бәйрәмебез бар. Алар: 1 гыйнвар — Яңа ел, 23 апрель — Милли хакимлек һәм балалар бәйрәме, 19 май — Ататөрек истәлегенә яшьлек һәм спорт бәйрәме, 29 октябрь — Җөмһүрият бәйрәме һәм Рамазан белән Корбан (3 һәм 4 әр көн) бәйрәмнәре. Менә бу көннәрдә газетабызны тагын да эчтәлекле итеп чыгарабыз. Безнең фирманың «Саман юлы» («Йолдызлы юл») телевизион каналы һәм үз радиостанциясе бар. Фирма бер үк вакытта «Аксион» исемле атналык иҗтимагый-публицистик һәм хәбәрләр журналы да нәшер итә.

Безнең газетаның максаты — укучыларын Төркия белән таныштыру, аның тарихын, мәдәниятен, фәнен, динен, сәясәтен, икътисадын, халыкара багланышларын яктырту, дөнья вакыйгаларына Төркия күзлегеннән карап бәя бирү, — диде ул, әңгәмәне дәвам итеп. — «Заман»ның бер әһәмиятле бурычы — төрки җөмһүриятләрне, төрки халыкларны, Төркиянең үзен таныту, илләребез арасында үзара файдалы хезмәттәшлекне үстерүгә өлеш кертү, кардәш халыклар арасында дуслык күпере салу. Газета төрки халыклар, мөселман дөньясы вакыйгаларын яктыртуга, аларның казанышларын күрсәтүгә дә зур әһәмият бирә. Төрек халкы бөтен дөньяда танылган күп кенә әдәбият һәм сәнгать әсәрләре иҗат итте.

Әмма аларның күпчелеге бүгенге татар укучысына таныш түгел. Тукайлар, Исхакыйлар, Камаллар сокланып укыган әсәрләрне татар укучысына туган телендә җиткерү «Заман»ның янә бер бурычы дип беләбез. Кыскасы, Татарстанда нәшер ителә торган газетабыз да «Телдә, фикердә, эштә берлек» дигән девиз астында чыга һәм Төркия белән Татарстан арасында дуслык, кардәшлек күпере булып тора. Аның битләрендә төрек теле дәресләре алып барылуны уңай күренеш дип саныйбыз. Безнең телне өйрәнүне гимназияләр, лицейлар, аерым кешеләр аннан бик теләп файдалана.

Чәй янында әңгәмә дәвам итә. Татарстан турында мәгълүматларны Муаммар бәй төгәлрәк бирә. Чөнки ул Казанда дүрт ел буе туплаган материаллардан һәм үз күзләре белән күргән, күңеле белән кичергән тәэсирләрдән 500 бит чамасында китап нәшер итәргә әзерләнә.

Кульъязмаңны тапшыргач, 3–4 айда китапның эшен бетереп бирәләр, ди. Муаммар бәй ике китап чыгарган кеше инде. Беренчесе төрек армиясе турында булса, икенчесендә Мәҗит Гафуриның әсәрләрен тәрҗемәләп нәшер иткән. Китапны таралуына карап басалар икән. Әйбәт сатыла икән, өч тапкыр да дөнья күрергә мөмкин. Бәя һәр басмага үзгә, һаман күтәрелә бара.

Мәһмәт әфәнде белән саубуллашабыз. Бөтенләйгә түгел.

— Шимбә көнне кичке ашка чакырам сезне, — диде ул. — Бу көнгә башка кешегә вәгъдә бирмәгез.

Редакция белән танышу дәвам итә. Халык ахшам намазына әзерләнә. Күпләре тәһарәтен яңарта. Намаз укырга мөмкинлекләр редакциянең үзендә дә тудырылган. Ир-ат халкы тыз-быз килә. Бер хатын-кыз күрмәссең. Төркиядә алар, нигездә, эшләми, бала тәрбияли, гаилә учагын тота икән. Шуңа күрә аш-су әзерләүчеләр дә, идән юучылар да ир-атлар. Дөрес, «Хатын — гаилә» дигән сәхифәне алып баручы берничә хатын-кыз журналист бар, диделәр. Әмма алар күзгә чалынмады.

## МУАММАР БӘЙ ФАТИРЫНДА

Кич якынлашты. Борынгы Истанбулны төрле төстәге утлар каплап алды. Минем атна буе Муаммар

әфәнденең үзендә торасым ачыкланды. Без зур, мәһабәт Истанбул урамнары буйлап машинада үтәбез. Тирә-якка күз салам: адым саен ялтыраган көзгеле, зиннәтле кибетләр. Аларда малның очы-кырые юк, меңләгән төрле әйбер урамга, тротуарга җәелгән. Байтак әйберләр мәйданнарда, җир асты юлларында, күперләрдә сатыла. Сатучылар үзләренә кучмә газ баллоннары белән лампалар көйләгәннәр. Кыскасы, мондагы муллык беренче карашка ук киләчәккә өмет уята.

Җиңел машина күп катлы йорт янына килеп туктады.

— Мин үзем Кония дигән шәһәрнеке, — диде Муаммар бәй. — Әти-әнием, йорт-җирем шунда. Дүрт бүлмәле әлеге фатирымны Казаннан кайткач сатып алдым. Балалар, җәмәгать өйдә түгел. Бабайга операция булды. Шунда киттеләр. Өйдә бар да тәртип булмаса, гаеп итмәссез.

Хуҗам үз ачкычы белән беренче катта тышкы ишекне ачты. Шунда ук хезмәтче егет каршы алды. Ул бөтен подъездга җавап бирә икән: себерә, юа. Өйдән пакетка салып чыгарылган чүпне түгә, йортның тышкы ягын тәртиптә тота. Кирәк булса, кибеттән кирәк-ярак, азык-төлек алып кайта. Хезмәт хакын җыйнаулашып түлиләр.

## ЧАГЫШТЫРЫП КАРАУ

Күзем башка фатирларның ишек төпләрендәге затлы-затлы аяк киемнәренә төште. Без дә туфлиләрне шунда ук салдык. Өченчебез — Мостафа — аяк киемен үзе белән алып кермәкче булган иде, соңыннан башына сукты, ахры, әкрен генә: «Мин үземне Казанда дип торам бит», — диде. Менә бер йозаклы нәфис кенә ишек ачылды. Минем күз алдыма башкалабыздагы тимердән эшләнгән ике-өч катлы йозаклы ишекләр килеп басты...

Эчкә үтәбез. Берсеннән-берсе матур дүрт бүлмә. Затлы җиһазлар. Залдагы стенка изге Коръәннәр, төрек халкының олуг язучылары китаплары белән тулган. Стенада — Казандагы Сөембикә манарасы. Татарстанда эшләгәндә бүләк иткән булганнардыр. Ул аны яхшы рамга куйдырткан. Тагын шуңа игътибар итәм. Беркайда җылылык торбалары күренми. «Бездә аларны хәзер идән астыннан үткәрәләр», — ди хуҗа, гади генә итеп. Кунак-төшем булмаганда, ашау-эчү кухняда. Биредә дә хатын-кыз өчен бөтен уңайлыклар тудырылган. Электр плитәсеннән чыккан көйгән-янган исләрне суыртып алу өчен кондиционер урнаштырылган. Исне безнең авылдагы шикелле ишек ачып чыгармыйлар икән. Кичке аш турында хәзергә язып тормыйм. Анысы — аерым тема.

Озак та үтмәде, фатир коридорында кыңгырау тавышы яңгырады. Тышкы подъезд ишегеннән шалтыраталар икән. Муаммар бәй, өйдән генә төймәгә басып, аскы каттагы ишекне ачтырды һәм кунакларны керергә чакырды. Алар да киңәшмәгә кайткан мөхәррирләр булып чыкты. Кәлим әфәнде Давләр «Заман» газетасын Нью-Йоркта чыгара икән, Нәдим Ялчын — Македониядә. Башта алар сөйләшеп утырдылар. Яшәү-эшләү шартлары белән уртаклаштылар. Хезмәт хаклары турында да сүз булды. Төрле җирләрдә эшләүче мөхәррирләргә айлык акча шул илдә яшәү дәрәҗәсенә карап билгеләнә икән. Мәсәлән, Америкада эшләүче Уәлим әфәнденең айга ике мең биш йөз доллар алуы мәгълүм булды. Бу безнең акчага әйләндергәндә 14 миллион чамасы була. Менә дүрт төрек дус, тезелешеп басып, кычкырып, ястү намазын укыдылар.

Истәлек өчен рәсемгә дә төштек.

Таң алдыннан бөтен дөньяны биләп алган иртәнге азан тавышына уянып киттем. Истанбулда барысы 2500 ләп мәчет бар икән. Микрофон аша шуларның һәркайсыннан моң агыла иде. Муаммар бәй белән бер-беребезгә хәерле иртә теләштек.

— Казанда дүрт ел азан тавышы ишетергә тилмереп яшәдем, — дип куйды ул сүз уңаеннан.

Ә хәзер Аллаһының изге йорты — мәчетләр турында сөйләп китик.

## МӘЧЕТЛӘР — ЗИННӘТЛЕ КОРЫЛМАЛАР

Биредәге дин йортлары турында шактый сөйләп булыр иде, Истанбул мәчетләре күп гасырларның бөек мирасын саклый. Аларның билгеле вакытларда намазга чакыруы үзе бер ансамбль концертын хәтерләтә. Әлбәттә, шәһәрдәге мәчетләрнең барысын да карап бетереп булмый. Без аларның берничәсендә генә булдык.

...Җомга көн иде. Менә сәгать уникеләр тулар-тулмаста халык чабыша башлады. Ул көнне Муаммар әфәнде белән Мостафа бәйнең җайлары булмаганлыктан, мине Уфа егете Исмәгыйль озатып йөрергә тиеш булды. Ул Әнкара университетында укый икән. «Заман» газетасында практика үтә. Әле мыек та чыкмаган үзенә. Татарча авыр сөйләшә. Шәһәрдә үскән егет. Әмма төрекчәне су кебек эчә. Кешеләрнең йөгерешкәнен күргәч, сәгатенә карап алды да: «Тәлгат абый, мин җомга намазын укып чыгыйм инде. Ачуланмыйча, шушында көтеп торыгыз», — дип, мәчет эченә кереп югалды. 1497 елда салынган Гази Атакалы паша мәчете икән бу. Ул шомартылган ташлардан салынган Госманлы төзелеш сәнгатенең үрнәкләреннән берсе икән бу. Мәчеткә сыймаган халык ишегалдына тезелешеп утыра башлады.

Кемдер намазлыгын сумкасыннан чыгарып җәя, кайсылары полиэтилен тарата, якындагы төзелештә эшләүчеләрдер инде, чиста фанера кыстырып килгәннәр. Әмма һәркем башта тәһарәт ала. Мәчет кырыена бик зиннәтле итеп эшләнгән ул урын. Кыйммәт түгел, әмма түләүле. Гомумән, төрек дуслардагы бәдрәфләр — алар эштәме, өйдәме, башка урындамы — тәһарәт алуга җайлаштырылып эшләнгән, ягъни идәннән 15–20 сантиметр биеклектә су килә торган краннар куелган.

Җомга намазы тәгәлләнде. Без Исмәгыйль белән бөтен дөньяга билгеле булган Айя-Суфия мәчетенә киттек. Аны 325 елда Византия императоры Константин чиркәү итеп төзетә. Әмма ул яна. Шуннан соң император Юстинианус Хәзәрти Адәмнән алып бүгенге көнгә кадәр дөньяда күрелмәгән, зиннәтлелегенә тиңе булмаган, янгыннарга, җир тетрәүләргә бирешми торган, киләчәк дәверләрдә барча халыкларга үрнәк итеп куярлык ышанычлы бер сәнгать әсәре иҗат итәргә карар бирә. Төзелеш биш ел дәвам итә. Анда көн саен 5000 оста эшли. Төзү материалларын һәм мәрмәр колонналарны иске храмнардан китергәннәр. Айя-Суфия корылмасы биләгән мәйданның озынлыгы — 77, киңлеге 71,2 метр икән. Бинага 9 биек капкадан керәләр. Айя-Суфия гөмбәзенең диаметры — 33, биеклеге 55,6 метр. Бинаның бөтен биеклеге 81 метрга җитә. Тарихчылар Айя-Суфияне бизәү өчен тотылган алтын, көмеш һәм кыйммәтле ташларның авырлыгы 20 тонна чамасы булганлыгын язалар. Истанбулны басып алган хачлылар (крестоносцы) гаскәрендә булган Роберт Клари үзенең язмаларында Айя-Суфияне менә болай сурәтли:

— Бу гыйбадәтханәнең бөтен капкаларындагы йозак һәм бикләр саф көмештән коелган. Бәясен чамалап булмаслык дәрәҗәдә кыйммәтле миһраб эчендә ундүрт аяк озынлыгында саф алтыннан коелган ай массасы бар иде. Ул айның өсте тагын да кыйммәтлерәк ташлар белән бизәлгән.

Әнә нинди тарихи хәзинә икән ул Айя-Суфия мәчете. Башта 918 ел чиркәү булып тора бу зиннәтле корылма, 1453 елны төрекләр Истанбулны яулап алганнан соң, Фатих Солтан Мәһмәтнең тәүге боерыкларыннан берсе кызганыч хәлдә калган Айя-Суфияне саклау һәм аны аякка бастыру эшен башлап җибәрү хакында бара. Шулай итеп, мәчеткә эверелдерелеп төзелгән бина киләчәк заманнарда ватылу, җимерелү куркынычыннан азат ителгән тарихи йорт булып яңадан торгызыла. 482 ел мәчет хезмәтен башкаручы һәм 60 елдан бирле музей буларак кулланылган дүрт манаралы бу гүзәл йортның бүген дә чиркәү бизәкләре белән берләштереп исән-сау саклауны бары тик төрекләрнең вакытында игътибар күрсәтеп һәм ремонт эшләрен сыйфатлы итеп алып бару нәтиҗәсендә генә мөмкин булганы аңлашыладыр.

— Христиан һәм ислам диннәре сәнгатен иксез-чиксез алтын-көмеш мозаикалар белән чагылдырган дөньядагы бердәнбер корылма бу, — диләр төрек дуслар күпне күргән Айя-Суфия мәчете турында.

Менә без тагын бер тарихи бинага — Солтан Әхмәт мәчетенә үтәбез. Стеналары зәңгәр плитәләр белән тышланганга күрә, «Зәңгәр мәчет» дигән исем белән бөтен дөньяга билгеле бөек сәнгать әсәре санала. Айя-Суфия белән янәшә торганга, аның гүзәллеге күзгә тагын да ныграк ташлана. Дөньядагы 6 манаралы бердәнбер бу мәчетнең эчке бизәге дә күршесеннән матуррак. Ул гыйбадәт кылу өчен ачык. Аяк киемен салып керәсе. Төп намаз залының иңе — 64, буе 72 метр. Көн яктылыгы 260 тәрәзәдән төшә. Миһраб ак мәрмәрдән эшләнгән. Хатын-кызлар өчен гыйбадәт залы аерым. Гомумән, Истанбулдагы мәчетләрнең гүзәллегенә нинди чагыштырулар куллансаң да, аз булыр...

Дин йортлары турында сүзне йомгаклап шуны әйтергә кирәк: Төркиядә мәчетләр салу белән шөгыльләнә торган оешмалар, вакыфлар (фондлар), хәйрия оешмалары бар. Алар Аллаһы Тәгалә йортларын төзү юлында зур көч куеп, тырышып эшлиләр, халыктан рәхмәт сүзе, Аллаһы Тәгаләдән савап алалар. Мәчетләрнең борынгылары да, хәзергеләре дә берсе икенчесен кабатламый, бертөрле ике корылма очрамый, һәрберсе үзенә генә хас манарасы, матурлыгы белән, сәнгать һәйкәле буларак, гасырларга сузылган кадере белән дан тота. Аларның күбесендә солтаннар, дин әһелләре, дәүләт эшлеклеләре җирләнгәнгә, бу урыннар аеруча изге санала.

## СОЛТАННАР САРАЕНДА

Мәчетләрдән соң солтаннар сараен карарга бардык. Алдан ук шуны искәртеп үтү зарури булыр: аны җентекләп карап чыгу өчен үзенә берничә көн яки тулы атна кирәк. «Топкапы» сарае дип атала ул, 1459 елда төзелгән. Бу сарай төрек гражданлык архитектурасының иң зур һәйкәлләреннән санала. Аның исеме «туп капкасы» дигән сүздән алынган. Бу — төрек солтаннары өчен төзелгән беренче сарай. Монда берничә гасыр буена бер-бер артлы патшалык иткән егерме бишләп солтан гомер иткән. Сарай 700.000 квадрат метр мәйдан биләп тора, күпсанлы павильоннарны, мәчетләрне, ишегалларын, фонтаннарны берләштерә. Ул атаклы Византия стеналарына барып тоташа торган калын таш коймалар белән әйләндереп алынган. «Топкапы» сараеның чәчәк аткан вакытларында 4000 чамасы кеше яшәгән. Кухня дигәннәре генә 10 залдан торган. Биредә 300 ел буе көн саен уртача 800 аш-су остасы эшләгән. Елына 30 мең чеби, 23 мең баш сарык, 14 мең чамасы бозау китертелеп эшкәртелгән. Хәзер әлеге залларның кайберләренә кытай һәм япон фарфорыннан 10 меңнән артык коллекция куелган, алтын-көмеш савыт-сабаның нindiләре генә юк! Алтын җепләр белән тегелгән киемнәр, төрледән-төрле сугыш ко-

раллары күргәзмәсе дә игътибарны үзенә җәлеп итә. Мәсәлән, биредә бөтен дөньяга билгеле хәнҗәр куелган икән. Аның сабына өч зур зөбәрҗәт ташы (изумруд) урнаштырылган. Җир йөзендәге иң зур — 3260 граммлы зөбәрҗәт тә монда саклана икән. Биредә үк 86 карат авырлыктагы — күләме буенча дөньяда җиденче урында торучы бриллиант та күз явын алып тора. Ул алтын-көмештән, иң кыйммәтле ташлар белән бизәлеп эшләнгән тәхетләрнең матурлыгын тасвирлап бетерә торган түгел. Кыскасы, һәр солтан үзеннән алдагысын уздырырга тырышкан, 2510 килограммлы «Бәйрәм» дип аталган, истәлекле көннәрдә генә кулланыла торган тәхет үзе генә ни тора! 48 әр килограмм алтыннан 6666 данә зөбәрҗәт ташы белән бизәлеп ясалган бер бүлмәдәге ике люстра да олы хәзинәләрдән исәпләнә.

## БАЗАРЛАР ШӘҺӘРЕ

Истанбул — базарлар шәһәре. Аның мәшһүр «Капалы чаршы» (каплаулы базар) дигәне генә ни тора! Анда 420 ләп кибет бар, диделәр. Түбәсе ябулы урамнар алтын кибетләре, кием-салым, савыт-саба, ризыклар белән тулган. Җаның ни тели, шуны сатулашып алып була. Мөселманнарга ихтирам зур. Мәсәлән, минем түштә Татарстан Дәүләт флагын тасвирлаган значок бар иде. Күн өчен кызгылт-көрән крем сорадым. «Йөз мең» (безнең акча белән 550 сум), — диде сәүдәгәр. Шуннан теге значокка күз сирпеде дә, Россия флагына охшатты бугай, секунд эчендә 50 процентка арттырып: «Йөз илле мең!» — диде. Муаммар бәй Татарстан мосафиры икәнемне аңлаткач кына башта әйткән бәягә бирде.

Лялили дигән районда безнең «капчыклы сәүдәгәрләр» басып алган «рус базары» да бар. Биредә сату-алу рус телендә бара. Безнең ватандашларыбыз да сату итә. Төрекләрнең байтагы русча сөйләшә, үзләре кириллицаны, ягъни безнең алфавитны белмиләр, ә телне өйрәнгәннәр. Биредәге товарлар башка төрек базарларындагыдан аерылалар — күн тире, мех киемнәр, модельле туфлиләр, итекләр, джинсы — ягъни безгә алып кайтып сатыла торган әйберләр. Әлбәттә, аларның бәясе бездәгедән шактый арзан (мәсәлән, крек плащлар бездә өч миллион булса, аларда ике миллион) һәм үз зәвыгыңа туры килгәнен озаклап, сыйфатлысын сайларга мөмкин. Бәяләр кызык итеп куелган. Мәсәлән, ирләр туфлие 2 миллион 200 мең төрек лирасы (аларның 1 миллионы безнең 55 меңгә тора иде) итеп куелган. Сатулаша башлагач, ул 200 меңен тиз генә төшкән була. Рәхмәт әйтеп китәсең инде. Бу базарда товарны күпләп тә саталар, андыйларның бәясе дә шактый түбән. Алыш-биреш итүчеләр рәхәтләнеп русчалатып тозлап-борычлап тарткалашалар, сүгенәләр. Бу районда рус рестораннары да шаулап-гөрләп эшли икән. Әнә шулай итеп рәсәйлеләр Төркиянең икътисадын ныгытуга төрле яклап өлеш кертәләр. Моны рәсми статистика белән дә раслап була. Мәсәлән, 1995 елда «капчыклы сәүдәгәрләр» Рәсәйгә 10,1 миллиард долларлык товар алып кайткан булганнар (бөтен импортның 17,1 проценты). Рәсәй базарын товар белән тәэмин итүдә беренче урынны Төркия алган, ягъни бөтен товарның 45 проценты биредән кертелгән Истанбул аэропортында Рәсәйдән килүчеләр өчен юкка гына аерым бина — таможнясы, көтү заллары — тулы комплекс итеп салынмаган. Алып кергән әйбереңне дә тикшереп караучы юк. 10 долларга виза аласың да Төркия җиренә аяк басасың. Чикне узганда паспортка бер генә күз төшерделәр дә, елмая-елмая, хәерле сәфәр теләделәр.

## КАДЫКӘЙГӘ БАРУ

Билгеле булганча, шәһәрне Истанбул бугазы (Босфор) нәкъ урталай бүлә. Шуның бер як тарафын — Азия, икенчесен Европа дип атыйлар. Шәһәр кешеләренең горурлыгы һәм мактанычы булган бу бугаз Кара диңгезне һәм Мәрмәрә диңгезен тоташтыра. Бугаз аша ике күпер салынган. Аның берсе — Истанбул (озынлыгы — 1150 метр), икенчесе Фатыйх Солтан Мәhмәт күпере (1158 метр) дип атала. Соңгысыннан җәяүләп тә чыгарга туры килде. Бу күперләр машиналар өчен түләүле икән. Алар узган ел 2,5 триллион лира табыш биргәннәр. Босфор бугазы аша сәяхәтчеләр төялгән матур зур теплоходлар бертуктаусыз үтеп тора. Яр буенда рестораннар, чәйханәләр көне-төне эшли.

Без дә бугаз аша ярның икенче ягындагы Кадыкәй дигән җәннәт почмагына барырга булдык. Бу — үзенең тиңдәшсез матурлыгы белән кешеләрне сокландыра һәм гаҗәпләндерә торган диңгез яры икән. Ниләр генә сатмыйлар анда. Бигрәк тә аквариумнар өчен кирәк булган зиннәтле балыклар һәм төрле-төрле йорт кошлары таң калдырды. Босфор ярына басып тору әйтеп бетерә алмый торган үзе бер хозурлык. Шул мизгелләрдә күңелдә тагын бер хатирә яңарды.

...1963 ел. Бишенче классны тәмамлагач, Кара диңгез буендагы Бөтенроссия пионерлар лагере «Бөркеткәй»гә җибәрделәр. Казаннан 15 бала идек. Мине, арада иң яше булгангадыр инде, 13 нче отрядка — кечкенә чик сакчылары отрядына беркеттеләр. Безне бер кичне, «дозорга» дигән булып, чик саклаучы солдат янына алып чыктылар. Ул Кавказ тавы итәгеннән Кара диңгез буендагы сукмак буйлап килә иде. Мәһабәт буйлы сержант, шулай кушылгандыр, безнең белән бераз әңгәмә корды: «Әнә Кара диңгезнең теге ягында Төркия дигән дәүләт бар. Анда безнең дошманнар яши. Шулар чикне бозып кермәсен дип сакта торабыз», — диде.

Ул вакытта ышанылган булган. Анда безнең кан кардәшләребез — бер диндәге төрки халыклар яши икән ләбаса. Без моны ике арадагы «тимер пәрдә» эри башлагач кына белдек. 33 елдан соң мин шул каршы як ярда басып торырмын дип ул чакта башка да килмәгәндер. Дөрестән дә, тарихтан белгәнебезчә, рус дәүләте белән озак еллар дошман булган Төркия сугышлар алып барган. Истанбулга рус патшаларының да күзе төшкән. Мәсәлән, Петр I нең 1725 елгы яшерен «Васыятьнамә»сендә («Казан утлары», 1996, № 10) мондый юллар бар: «Русия мәмләкәтен дөнья мәмләкәтенә әйләндерү өчен, аның башкаласын Азия һәм Европа хәзинәләренең ачкычы булган Истанбулга күчерү шарт... Шөбһәсез ки, Истанбулга ия булган патша дөньяда илаһи патша булачак...»

## АЛ ДА ГӨЛ ГЕНӘ ТҮГЕЛ

Бу сәяхәтнамәне укыган кеше Төркия — йә оҗмах, йә анда «мондагыдан эш кыен» дип уйлый күрмәсен. Яшәү кайда да кыйммәт. Дөнья булгач, хәер сораучы да, салмышы да очрый. Төрмәләр дә бар. «Мафия» дигән сүзне дә ишетәсең. Гомумән, Истанбулның үзендә яшәү җиңел түгел, диләр. Алар эчәр өчен суны да сатып алалар. Кибетләрдә 20–30 литрлы савытларда 5–6 долларга сатыла ул. Ризык әзерләү өчен шуны тоталар, краннан килгән су юыну һәм башка кирәк-яраклар өчен файдаланыла. Сатуга су таулардан китерелә.

Фатир хакы да кыйммәт. Электр, газ өчен саллы түлиләр. Су өчен дә счетчик куелган. Аннан бездәге кебек тәүлек буе исәпсез кайнар су акмый. Газ баллоны белән кирәк кадәр үзең кайнарлыйсың.

Эш хакы төрлечә. Хәрбиләр, хокук саклау органнарында эшләүчеләр, журналистлар, табиблар, гомумән алганда, акыл эшчәнлеге белән шөгыльләнүчеләр күп ала. Алар 20 ел хезмәт стажы булганнан соң пенсиягә чыга.

Мәктәпләрдә уку түләүсез. Шуңа да карамастан, берничә сыйныф кына укыган йә бөтенләй укымаган балалар күп. Алар гаилә өчен акча эшлиләр — вак-төяк саталар, аяк киеме чистарталар, йомышка йөриләр. Әйткәнебезчә, хатын-кызның күбесе эшләми. Акчаны ир-ат тота.

Тулаем алганда, ата-бабасыннан килгән байлыгын дәвам итеп, ныгытып эшләгәннәр яки акыл хезмәте белән шөгыльләнүчеләр яхшы яши. «Уртача хәлле төрекнең өч йорты булырга тиеш, — диде Муаммар бәй. — Шәһәрдә икәү. Берсендә үзе яши. Икенчесендә кеше тотып, акча кертә. Өченчесе — диңгез буенда. Анысы ике катлы, кунаклар кабул итү заллары белән була. Җәйге ялың шунда үтә...»

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙ КАБЕРЕ ЯНЫНДА

Эмиграциягә китү сәбәпле, совет чорында әдәби мираслары халыктан читләштерелгән язучылары арасында Гаяз Исхакыйның (1878–1954) аерым урын алып торуы хәзер күпләргә билгеле. Революциягә кадәр туган илендә татар әдәбиятының классигы, атаклы прозаик, драматург, ялкынлы публицист, зур җәмәгать эшлеклесе булып танылган бу күпкырлы шәхес Октябрьдән соң чит илләрдә, аеруча Төркиядә әдәби-иҗтимагый эшчәнлеген дәвам иттереп, шөһрәт һәм зур ихтирам казанып яши. Ул Истанбулның Әдернәкапы зиратына җирләнгән. Төркиягә барган Татарстан кешеләре Гаяз Исхакый каберенә зиярәт кылмыйча кайтмый. Мостафа әфәнде белән без дә булдык, ул изге һәм кадерле урында.

## КАЙТУ ЮЛЫНДА

Төркиядә соңгы көн. Истанбул урамында күңелгә шигъри юллар килә:

> Истанбулның үзәк урамында
> Басып торам карап берүзем...
> Мин бер төртек монда, бер тузан күк,
> Халык агыла, агыла көнозын.
> Ирексездән мин дә кузгаламын,
> Урам буйлап алга юл алам,
> Мин — бер юлчы, халык арасына,
> Ташкын эченә кереп югалам.

Дөрестән дә, кеше күп биредә. 65 миллион халкы булган илнең 15 миллионга якыны бер шәһәргә туплангач, моны күз алдына китереп тә буладыр. Шәһәр озынлыгын да 100 чакрымнан артык, дидек бит. Бу — Саба белән Казан арасы кадәр җир тоташ шәһәрдән тора булып чыга.

Юкка Истанбулны дөньяның ачык һавадагы иң зур музее димиләр. Шунда туып гомер кичергән кешеләр дә аның бөтен якларын күреп бетерә алмыйлар. Шәһәрнең һәр тыкрыгында, һәр урамында тарихи биналар бар. Алар турында сөйләп тә, язып та бетерә торган түгел. Һич онытылмас истәлекләрне күңелгә сеңдереп, иңнәргә төяп, кайтыр юлга кузгалам. Мине һәр тарафта Төркиянең ай-йолдызлы, кан

төсендәге — һәрбер төркияле өчен изге Кызыл Байрак озата.

Истанбул аэропорты. «Капчыклы сәүдәгәр»ләребез тау-тау байлыкларын тапшыралар. Таможняда капчыкларын рентген аша үткәргәндә үк алар өстәмә долларын чыгара башлыйлар. Чөнки декларация буенча зуррак әйберләрне (дубленка, күн куртка, алтын әйберләр) өчәрне генә алып чыгарга ярый. Самолетка кергәндә, үзең белән кул сумкасы яки дипломат кына алырга рөхсәт ителә. Калганнарын багаж итеп бирәсе. Багажның 20 килограммын буш алырга рөхсәт ителә, калганнары өчен килограммына 2,5 әр доллар түләргә кирәк. Минем олы сумкам алдан үлчәнгән кебек — 18,5 килограмм гына булды.

Багажларны тапшырып, көтү залына үтәбез. Ни күрим, һәрбер алыпсатар 3–4 капчык товарын багажга бирсә дә, әле һәркайсында тагын 4–5 кисәк әйбер бар. Доллар төртеп үтәләр, ахры, шомарган сәүдәгәрләр. Самолетка алдан кереп калмасаң, син бер дипломатыңа да урын таба алмыйсың. Ярар, урнаштык. Һәр тарафта татар, рус сөйләме, җиңелчә генә сүгенүчеләр дә бар. Истанбулга чыгучылар арасында мин 30 ел күрмәгән классташымны очраттым. Икебез дә таңга калдык. «Мин елларымны җыеп, әллә нигә бер генә барам, — диде ул. — Менә бу юлы тешләр куйдырдым». «Заман» газетасы аша төрекчә дә өйрәнгән икән. Мөгаллимә кешегә авырлыгы юк бит аның.

Самолет тәгәрмәчләре Казан җиренә тиде: мин кул чаба башладым. Исән-сау төшкәч, башка самолетларда шулай итәләр иде. Монда ул халәт күренмәде. Киресенчә, «капчыклы кешеләр» миңа сәерсенеп карады: ычкынган бу дип уйладылар, ахры.

3–4 сәгатьтән соң таможняны үттек. Чит илне макта, үз илеңдә тор, дип уйлаганнардыр бабаларыбыз, каланы макта, салада тор, дигән вакытта. Рәхәт булса да торган җир, сагындыра туган ил.

Сау бул, кояшлы Төркия! Исәнме, туган Татарстаным!

*1997*

## Мәртәбәле кунагыбыз

Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезнең игелекле эшләре турында хәбәрләр көндәлек матбугатта еш басылып тора. Әле күптән түгел Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев Төркиядән бик изге теләкләр белән килгән кунакларны — Әхмәтвәли Мәңгәр фонды президенты Сафия ханым Имрены, аның ире Гыйззәт әфәндене һәм фондның вице-президенты Мәхмүт Әлүкәйне кабул итте. Сафия ханым, әтисе эшен дәвам итүче, үзенең дә милләтенә көчтән килгәнчә ярдәм итү теләге белән янучы кеше икәнлеген раслап, Президентыбызга бөек шәхесебез, классик язучы галим Гаяз Исхакыйның архивын, шәхси медальонын һәм сәгатен тапшырды. Очрашуның бик җылы шартларда узуы хәбәр ителде газеталарда.

Икенче көнне Истанбул кунаклары Сабага килде. Алар белән Казан дәүләт университеты профессоры Миркасыйм ага Госманов та бар иде. Кунакларны район чигендә хакимият башлыгы Фәрит Гыйльмиев каршы алып, кыскача гына районның бүгенге сулышы белән таныштырды.

Районыбызның талантлы үзешчәннәре — җырчы Лилия Мансурова «Саба чишмәләре»н (Таһир Исмәгыйлов музыкасы, Рашат Низамиев сүзләре) бүләк итте, Альбина Мөбарәкҗанова татар кызы биюен башкарды.

Аннан сүзне Сафия ханым алды:

— Бу туфракка аяк басуыбызның тирән мәгънәсе бар, — диде ул. — Әтием — Әхмәтвәли Ибраһим Мәңгәр — 1891 елның 8 декабрендә Казакъстанның Петропавловск (Кызылъяр) шәһәрендә туган. Әтинең ата-бабасы Татарстан җөмһүриятенең башкаласы Казан артыннан, төгәлрәге Әтнә районының Мәңгәр авылыннан. Әбинең нәсел очы — сезнең Сабабашныкы. Ул Бану исемле була. 1860–1870 еллар тирәсендә Мәңгәрнең Мөхәммәтҗан Ибраһим дигән укымышлы кешесенә кияүгә чыга. Бабай Казакъстаннан һәм Төрекмәнстаннан җыйган малларын Англия, Италия, Германия кебек Көнбатыш илләренә җибәргән. Тора-бара этиемнәр Истанбулга күчә. Төркиядә Германиянең «Мерседес» компаниясе вәкиллегенә нигез сала һәм соңыннан үз заводларына ия була. Бик милләтпәрвәр була ул. «Казан» журналын чыгарта. Гомумән, китапка гашыйк шәхес иде. Шуңа күрә этием исемендәге вакыф (фонд) оештырдым һәм, үзәгенә татар һәм төрек язучылары вә галимнәренең әсәрләрен халыкара латин алфавитына күчереп, төрки дөньяга таратуны, сирәк китапларны күбәйтеп, төрле китапханәләргә җибәрүне максатым итеп куйдым.

Сөйләшү милләтара багланышлар, гореф-гадәтләр турында дәвам итте. Аннары кунаклар Байлар Сабасына юл тоттылар. Район үзәгендәге төзелешләрне, социаль-мәдәни биналарны карадылар. 1841 елгы борынгы мәчетебездә булдылар. Дин йортының эшчәнлеге белән Зиннур хәзрәт Закиров таныштырды.

Сафия ханымны әбисенең кендек каны тамган Сабабаш җире дә бик җылы каршы алды. Авыл халкы, балалар, укытучылар байтак җыйналган. Урманчылык лесничие Нәгыйм Вәли улы Газизов, мәктәп

директоры Харис Шәрифулла улы Насыйров хезмәт һәм педагогик коллективлары эшчәнлеге турында сөйләделәр. Сафия ханым латин хәрефләре белән әтисе исемендәге фонд чыгарган «Идегәй» һәм «Кыйссаи Йосыф» китапларын мәктәп китапханәсенә кул куеп бүләк итте. Матур итеп, татарча язды ул. Сафия ханым немец, инглиз, француз, рус, татар, төрек телләрен камил белә икән. Академик Миркасыйм Госманов та үзенең ике китабын тапшырды. Заманча итеп төзелгән һәм җиһазланган мәктәп бинасы төрек дусларга бик ошады. Соңыннан эчкерсез сөйләшү Лесхоз бистәсендә дәвам итте. Саба урман хуҗалыгы директоры Рәис Миңнеханов кунакларга үзләрендә эшләнгән милли сувенирлар бүләк итте. Бик җылы тәэсирләр белән, рәхмәт укып киттеләр борынгы Саба җиреннән Төркиядән килгән кунаклар.

*1997*

# Пушкин һәм лицей

Бөек рус шагыйре А.С.Пушкинның тууына 200 ел якынлашу уңаеннан республикада премьер-министр урынбасары И.К.Хәйруллин җитәкчелегендә махсус комиссия төзелүен ишеткәч, кулыма кабат каләм алдым.

Миңа, бу юлларның авторына, соңгы елларда күп кенә музейларда булып, шактый җылы тәэсирләр алырга туры килде. Мәсәлән, Пенза өлкәсендәге Лермонтовның балалык еллары узган элеккеге Тархан авылындагы музей-заповедник, шуннан ерак түгел урнашкан рус әдәби тәнкыйтьчесе, публицист һәм революционер-демократ В.Г.Белинский музей-йорты, Горький шәһәрендәге бөек пролетар рус язучысы Максим Горький, Саратовтагы галим, язучы, әдәби тәнкыйтьче Н.Г.Чернышевский һәм рус совет язучысы, җәмәгать эшлеклесе К.А.Федин музейлары аша аларның тормыш юллары күз алдында якынрак гәүдәләнде. Бер төркем мөхәррирләр белән Германиянең Веймар шәһәрендәге немец халкының мәхәббәт җырчылары Гете һәм Шиллер яшәгән йорт-музейда булу да күңелдә мәңге сакланачак истәлекле вакыйга булып калды. Үзебезнең республиканың Алабуга шәһәре зиратында 1941 елда бирелә җирләнгән танылган рус шагыйрәсе Марина Цветаева каберенә тере чәчәкләр куярга туры килде. Аксубай районында туып үскән күренекле шагыйребез Хәсән Туфан, язучы Газиз Кашапов, шулай ук Чистай районының Яуширмә авылындагы халкыбызның даһи улы Гаяз Исхакый музейлары да язылачак темалар булып тора.

Бөек рус шагыйре А.С.Пушкин белән бәйле урыннар илебездә байтак. Ул Казанда да булган. «Тиңдәшсез шагыйрь булдың, афәрин, Пушкин Александр!» дип язган Тукай аңа сокланып. Бөек шагыйрьнең эзләрен чал Казан һаман кадерләп саклый. Ул тукталган йортка мемориаль такта куелган. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасы янында һәйкәл бар.

А.С.Пушкинның 200 еллыгы якынлашкан көннәрдә, бөек шагыйрьнең иҗатына тирән кермичә, аның балалык еллары үткән һәм шагыйрь булып формалашуында зур роль уйнаган элеккеге Царское Село (1937 елдан Пушкин) шәһәрендәге лицей мемориаль музеенда алган кайбер истәлекләр белән уртаклашасы килә. Билгеле булганча, А.С.Пушкин 1799 елның яңа стиль белән 6 июнендә Мәскәүдә туган. Аның атасы Сергей Львович борынгы дворяннар нәселеннән килгән алпавыт булган, ләкин хуҗалык белән юньләп шөгыльләнмәгән һәм имениеләре аз файда биргән. Сергей Львович күңел ачуларны яраткан. Русча да, французча да шигырьләрне ансат язган. Әдәбият белән кызыксынган, күбрәк французча китаплардан торган бик бай китапханә туплаган. Пушкинның әти-әнисе балаларын тәрбияләү белән әллә ни кызыксынмаганнар, алар француз гувернанткалары кулында үскәннәр. Пушкин укырга хирыс булмаган, бигрәк тә математиканы яратмаган, әмма әдәби китапларны яшьтән үк бик күп укыган. Сигезенче яшендә французча шигырьләр яза башлаган, өйдә гел чит телдә генә аралашканлыктан, Пушкин русчага караганда французча яхшырак сөйләшкән.

1811 елда Пушкинны Царское Селодагы лицейга — дәрәҗәле кешеләр өчен яңа ачылган уку йортына биргәннәр. Менә без Ленинград өлкәсендәге Пушкин шәһәрендә (1918 елга кадәр Царское Село, аннан 1937 елга кадәр Детское Село дип йөртелә). Бу шәһәргә 1708 елда ук нигез салына. Ул рус патшаларының шәһәр яны резиденциясе итеп төзелә. Искиткеч матур итеп эшләнгән Сарай-парк ансамбле 1752 елда салына башлый. Шушы ансамбльнең зур дүрт катлы флигеле бөтен уңайлыклары белән лицейга бирелә. Аның беренче катында — хуҗалык идарәсе, икенчесендә — ашханә, аптека белән шифаханә, өченчесендә — уку заллары, китапханә.

Александр Сергеевичның лицейдагы яшьлеге шушында үтә, биредә шагыйрь Пушкин туа: 130 лап шигырь иҗат ителә, «Руслан һәм Людмила» поэмасы языла башлый, танылган журналларда беренче язмалары басыла. Лицей хәзерге урта яки югары уку йортлары дәрәҗәсендә белем бирергә тиеш була. Бер елдан лицейдагы укытучылар һәм надзирательләр Пушкинга мондый рәсми характеристика биргәннәр: «Төпле булудан бигрәк, өстән генә ялтырый торган илһамлы; тирән акыллы булудан бигрәк,

тиз кабынучан һәм үткен акыллы... Аз көч сорый торган предметларга гына сәләтлелек күрсәтә, шуңа күрә уңышы аз... Тырышып укымый... тапкыр, ләкин буш сүзләргә генә... Җиңел акыллы».

Әмма бу өстән караучы кешеләргә генә шулай тоела. Чынлыкта исә Пушкин лицейда бик күп эшли, укый, фикерләү сәләтен арттыра. Ул «Шәһәрчек» дигән шигырендә үзе яраткан язучыларны санап китә. Менә алар (бу вакытта аңа 15 яшь була): Гомер, Вергилий, Гораций, Тассо, Мольер, Парни; руслардан — Державин, Фонвизин, Карамзин, Дмитриев, Крылов һәм башкалар.

...Лицей залына үтәбез. Ул тантаналы көннәрдәге кебек җиһазланган: кызыл сукно белән капланган өстәл, алтынланган кәнәфиләр, өстәлдә лицей грамоталары. Танылган архитектор В.Растрелли олы сәнгатьчә зәвык белән бизәгән залның стеналарыннан һәм түшәменнән күз карашыңны ала алмыйча, бераз югалып каласың. Нәкъ менә шушы залда 1815 елның 8 гыйнварында лицейда кече бүлектән өлкән бүлеккә күчүчеләргә кешеләр алдында имтихан ясалган. Имтиханда, почетлы кунаклар арасында, русның талантлы шагыйрьләреннән берсе — карт Державин да булган. Пушкинга чират җиткән. Ул, Державиннан ике адым чамасы ераклыкта торып, аның патриотик одалары стилендә язылган «Царское Село истәлекләре» дигән шигырен укый башлаган. Шигырь бик күпләрдә соклану тудырган. Державин, күзләренә яшь тулган хәлдә, Пушкинны кочакларга ташланган. Оялып калган Пушкин йөгереп чыгып киткән, ә Державин аның артыннан:

— Менә Державинны кем алыштырыр! — дип кычкырып калган.

Зал янәшәсендә китапханә. Киштәләргә Пушкин яшәгән чордагы китапларның төп нөсхәләре урнаштырылган. Дәресләрдән соң шөгыль бүлмәләрендә лицейда укучыларның кульязмалары, журналлар, карикатуралар белән танышырга була. Шунда ук Пушкин ясаган рәсемнәр дә куелган. Уку классы да уңайлы итеп эшләнгән: алты ярымтүгәрәк өстәл, берсе икенчесеннән биек итеп урнаштырылган эскәмияләр, язу тактасы, кафедра һәркемнең игътибарын җәлеп итә. Физика кабинеты приборларга байлыгы белән аерылып тора. Күңелдә мәңге җуелып калганы йокы коридоры булды. Биредә 50 номер, ягъни 50 ишек тезелеп киткән. Ишекнең пыялалы өлешенә тышкы яктан пәрдә корылган. Шуларның берсендә «№ 14. Александр Пушкин» дигән язу эленгән. Тар гына бүлмә. Аларның һәрберсендә тимер караватъ-комод, конторка дип аталган язу өстәле, көзге, урындык, юыну өстәле.

Өлкән курсларда укыган чагында, Пушкин Царское Селода торган гусар полкының лейбгвардиясендәге офицерлары белән танышкан. Ул вакытта гвардия офицерлары хөкүмәткә карата бик нык оппозицион рухта булганнар. Пушкин алар аша ул вакыттагы яшерен әдәбият белән танышкан. Офицерларның берсе, соңыннан атаклы булып киткән төпле фикер иясе, язучы һәм философ П.Я.Чаадаев аңа зур сәяси тәэсир ясаган.

Пушкинның замандашларыннан берсенең уенча, Чаадаев Пушкинга белем һәм акыл ягыннан лицейдан күбрәк ярдәм иткән. Шуңа күрә 1818 елда, лицейны тәмамлаганнан соң, Пушкин «Чаадаевка» дип исемләнгән шигырен яза.

Халык «Музейларда — халык хәтере» дип хак әйтә. Лицейда булганнан соң, аның Пушкин мемориаль музейларының иң кызыклыларыннан берсе икәнлегенә инанасың.

*1997*

# Тархан ягында

Һәр регионның үзенә генә хас булган истәлекле һәм тарихи урыннары була. Алар дәүләт тарафыннан күз карасыдай кадерләп саклана. Пенза өлкәсендә шундый урыннарның берсе — Михаил Лермонтовның балалык һәм яшьлек еллары, төгәлрәге — гомеренең яртысы үткән Тархан авылындагы Лермонтов музей-заповеднигы.

Билгеле булганча, булачак бөек рус шагыйре М.Ю.Лермонтов 1814 елның 15 октябрендә Мәскәү шәһәрендә отставкадагы капитан Юрий Петрович гаиләсендә туа. Илебез башкаласында булучылар хәтерли торгандыр: Казан вокзалыннан ерак түгел әлеге йорт урнашкан урында М.Ю.Лермонтовка һәйкәл һәм мемориаль такта куелган. Соңга таба шагыйрь башкалабыз турында болай дип яза: «Мәскәү минем Ватаным һәм ул минем өчен шулай булып калыр. Шунда тудым, шунда ук кайгы кичердем һәм шунда ук ифрат бәхетле булдым».

...Лермонтовлар гаиләсе күп вакыт әбисе — алпавыт Елизавета Алексеевна Арсеньева имениесендә — Тарханда яши. Малайның балачак еллары куанычлы булмый. Ул моңлы итеп җырлый торган әнкәсенең йомшак тавышын һәм иркәләүчән ягымлы кулларын бик томанлы гына хәтерли. Мария Михайловна газиз баласына өч яшь тулар-тулмас вакытта ук, ул чорда киң таралган, халык телендә чахотка дип йөртелгән авырудан үлеп китә. Аның әтисе үз-үзен үтергән була, шуңа күрә Мария әнисенең мирасына ия булырга тиешле бердәнбер кыз исәпләнә. Елизавета Алексеевна малайны шунда ук үзенә ала

һәм атасыннан аны тәрбияләүдән баш тартуны таләп итә. Әгәр дә Юрий Петрович шушы вариантка риза булмаса, ул алпавыт әбисенең мирасыннан колак кагарга тиеш була. Шуннан соң ул, Михаилны Тарханда калдырып, үз имениесенә китә. Лермонтов әтисен сирәк күрә, әбисе Юрий Петровичны яратмый. Михаил, әтисе исән була торып, ата-анасыз үсә, әбисе исә аны бик иркәләп тәрбияли. Ул бала чагында еш авырый, Елизавета Алексеевна аны өч тапкыр Кавказга су эчәргә алып бара. Алар, алпавыт әбисенең үз атларына утырып, бөтен Россия буйлап үтәләр. Кавказ Лермонтовның аңына бала чагыннан ук азатлык, намуслык иле булып керә. Шуңа күрә дә Кавказны үзенең икенче ватаны дип атый.

...Менә без, Тамбов, Пенза өлкәләре аша үтеп, Тарханга — хәзерге Лермонтово авылына якынлашабыз. Булачак шагыйрьнең беренче булып хәтеренә нык кереп урнашкан нәрсә Пенза губернасының тыйнак, ләкин гүзәл пейзажы була: туйралыклар, әкрен генә, тын гына ага торган дала елгаларының текә ярлары, тузанның әсәре дә булмаган авыл юллары, саргаеп, алтынланып килгән иген басулары арасында ара-тирә серләшеп утырган ялгыз каеннар, еракта диңгез дулкыныдай зәңгәрләнеп күренгән калкулыклар — менә болар барысы да яшь Лермонтовның сизгер йөрәгенә ныклап кереп урнашкан тәүге тәэсирләре була.

Ул вакыттагы Тархан авылын әдәбият белгече И.Андроников болай тасвирлый: «Бояр йорты тирәсе борынгы зур бакча аллеялары белән уратылып алынган, якында гына яшел үлән каплаган тымызык күл ята, ә усадьбаның каршысында ике рәт булып тезелешеп утырган кара мужик өйләре һәм ап-ак чиркәү тора — менә шул Тархан авылы үзе була инде». Бу авылда Арсеньеваның крепостнойлары яши. Аларның күбесе әле генә чит ил походыннан кайтканнар, кайберләре Бородино көнен хәтерлиләр, ә управляющийның камчысы элеккечә аларның аркаларын каезлый. Күрше авылларда да шундый ук хәл хөкем сөрә. Лермонтов шушы изү һәм гаделсезлек, кешелексезлек, ачы коллык һәм йөгәнсез башбаштаклык картиналарын бала чагыннан ук күреп үсә. Тарханда мондый тәэсирләр алмаса, «Бородино» да, «Купец Калашников турында җыр...» да, «Ватан» да булмас иде, биредәге материалларга нигезләнеп, «Сәер кеше» драмасы, «Мин Сезгә сөйләргә телим...» повесте, «Вадим» романы һәм бик күп шигырьләре язылa.

1939 елда Лермонтовның алпавыт әбисе усадьбасы музей итеп үзгәртелә. Элеккечә усадьба үзәгендә бояр йорты тора. Хәзер анда «Лермонтов Тарханда» дигән экспозиция урнашкан. Бояр йорты булачак шагыйрь үскән вакыттагы хәлгә китерелгән, беренче каттагы бүлмәләр аның балачак елларын хәтерләтә. «Табигать аңа талантны өеп биргән. Лермонтов әдәбият белән мавыгу белән беррәттән искиткеч музыкаль сәләткә ия булып, скрипкада, рояльдә уйный, үзе яраткан опералардан арияләр җырлый, хәтта музыка яза, рәсем ясый һәм майлы буяу белән картиналар яза, үзен бу эшкә багышлаган булса, һичшиксез күренекле художник була алыр иде», — дип сөйли экскурсия җитәкчесе. Экспозиция Лермонтовны шәхси әйберләре, үзе ясаган картиналары, китаплары аша шагыйрь һәм художник буларак якыннан таныштыра. Икенче каттагы әбисе бүлмәсендәге шагыйрьнең үз портреты аеруча игътибарны җәлеп итә. Әйе, стенада — сөекле оныгының портреты: зур күзле, уйчан карашлы, бер якка шома итеп таралган чәчле, киң маңгайлы малай сурәте.

Бояр йорты белән янәшәдә ампир стиле белән төзелгән чиркәү бинасы урнашкан. Биредә Арсеньевалар гыйбадәт кылган. Ә инде контора хезмәтләрен башкаручы йортында алпавыт крестьяннарының тормышы һәм көнкүреше белән танышырга мөмкин. Элеккеге хезмәтчеләр йортында «Мин Ватанымны яратам...» дигән экспозиция белән таныштырганда, техник средстволар — аудиовизуаль (бер үк вакытта күрү һәм ишетү) система кулланыла.

Лермонтов музей-заповеднигы табигатьнең искиткеч матур урынына урнашкан. Биредәге Түгәрәк бакча, Имәнлек, Ерак бакча, Олы буа, Урта буа, Бояр буасы дип аталган агачлыкларга һәм сулыкларга, аларны тоташтыручы агач күперчекләргә туристлар сокланып туя алмый. Биредә Лермонтов утырткан 166 яшьлек имән дә саклана, ул рәшәткәләп алынган.

Әнә шулай Тарханда Лермонтовның балалык еллары үтеп китә. Ул башкаланың үзендә яши торган балалар дәрәҗәсендә белем ала. Башта әбисе аңа өендә немец телен укыттыра, аннан соң инглиз теле укытучысы чакыртыла.

Хәзер дә башкалада — иске Мәскәү районында Кече Молчановкада — Мәскәү ампиры стиле белән агачтан эшләнгән чардак өйле бер катлы йорт бар. Шәһәрдә шагыйрьне «хәтерләткән» бердәнбер бина ул. 1830 елда бу йортны Лермонтовның әбисе вакытлыча файдалануга ала, һәм оныгы башта — пансионда, ә аннары университетта укыганда, икәүләп шунда тора башлыйлар. Ләкин Лермонтовны университетның икенче курсыннан ук хөр фикерле булганы өчен куып чыгаралар. 1832 елдан ул Петербург университетына керергә омтылып карый, әмма аңа юнкерларның кавалерия мәктәбенә керүдән башка юл калмый. Ул биредә әдәбият белән шөгыльләнүен дәвам итә. Лермонтов иҗат иткән төрле-төрле жанрларның исемнәрен дә санап тормыйча шуны әйтеп китәргә кирәк: 1830 елларның ахырларында ул танылган шагыйрь генә түгел, үз фикере булган зур әдәбият эшлеклесенә әйләнә. 1837 ел Лермонтов өчен аеруча авыр була. Билгеле булганча, бу елны бөек рус шагыйре А.С.Пушкин дуэльдә үтерелә. Бу вакыйга Лермонтовка бик нык тәэсир итә, һәм ул Пушкинны үтерүчеләргә каршы ялкынлы нәфрәт белән сугарылган «Шагыйрьнең үлеме» исемле атаклы шигырен яза.

...Ләкин сезнең өчен дә бар хөкем!
Бар дәһшәтле судья: көтә сезне;
Сатылмый ул алтын-көмешкә,
Алдан сизеп тора һәрбер серне,
Күзе җитә аның һәр эшкә.
Ярдәм итмәс анда сезгә явыз
Гайбәтегез — алмас ул йолып.
Һәм шагыйрьнең изге канын юып
Бетерә алмас кара каныгыз.

Шушы шигыре өчен Лермонтов кулга алына һәм Николай I нең боерыгы буенча сөргенгә, ул вакытта Кавказда сугышлар барган җирдә урнашкан Нижегород драгун полкына җибәрелә. Лермонтов анда бик күп шигырьләр иҗат итә.

1841 елның 27 июлендә Лермонтов Кавказдагы Машук тавы итәгендә патша ялчылары тарафыннан әзерләнгән дуэльдә Мартынов фамилияле отставкадагы майор тарафыннан үтерелә. Әбисе оныгының фаҗигале үлемен бик авыр кичерә. Аның гәүдәсен кургашын табут белән Тарханга кайтарта.

Менә без авыл уртасына урнашкан Михаил Архангель чиркәвенә юнәләбез. Чиркәү белән янәшә зур булмаган часовня, ягъни кечкенә чиркәү сыман иконалы бина тора. Шунда ук кара мәрмәрдән һәйкәл куелган, аңа кыска гына итеп «Михаило Юрьевич Лермонтов» дип язылган. Часовня эченә кергәч, тар гына баскычтан җир астына төшәсең һәм җемелдәп янучы шәм яктысында шагыйрьнең табуты янында басып торасың.

Шулай итеп, Лермонтовның яшь вакыттагы алдан күрүчәнлеге чынга аша: ул Тарханда җирләнә. Биредә үк аның әнисе, әбисе, туганнары мәңгелеккә йокыга талган. Ә соңга таба этисенең гәүдә калдыклары да чиркәү ишегалдына күчерелеп күмелә.

Еллар үтә тора. Тарханга ел саен Лермонтовның поэзиясе, яшьлек еллары белән танышу өчен меңләгән кешеләр килә һәм тирән тәэсирләр алып китә.

...Пенза, Тамбов яклары тагын бер көтелмәгән вакыйга белән истә калды. Вагонга кереп урнашкач, озак та үтмәде, репродуктордан Тамбов — Мәскәү поезды кузгалачагы турында хәбәр ителде, хәерле юл теләнде һәм, бөтен тирә-якны яңгыратып, Салих Сәйдәшевнең Совет Армиясе маршы яңгырады. Мәскәүгә китә торган пассажир поездларын биредә гел шулай озаталар, күрәсең.

*1989*

# Разлив тугайларында

Таллык арасында ике бүкән,
«Кабинет»та башка урын юк.
Язу өчен бигрәк уңай икән —
Берсе өстәл, берсе урындык.

*Д.Блынский, рус шагыйре*

Ленинград. Бу исемне ишетүгә, герой-шәһәрнең үткән һәм бүгенгесе күз алдына килеп баса. Иң кадерлесе — аның В.И.Ленин белән бәйле булган истәлекле урыннары. Ленинградта булучыларның күбесе, тарихи урыннар белән танышканнан соң, Разлив күленә бармыйча калмыйдыр. Чөнки Ильич биредә соңгы подпольеда булган.

Билгеле булганча, 1917 елгы июль көннәреннән соң Вакытлы хөкүмәт Ленинны законнан тыш кеше дип белдерә. Аны тотып биргән кешегә Керенский зур акча вәгъдә итә. Владимир Ильичка Петроградта калу көннән-көн куркынычрак була. Партия Үзәк Комитеты аны ышанычлырак урынга яшерү турында карарга килә.

...9 июль. Кич белән В.И.Ленин хәтәр юлга — Разливка барырга әзерләнә. Сакалын кыра, мыегын кырка. Саргылт төстә пальто, соры кепка кия, бу кыяфәте белән ул фин крестьянына охшый башлый. Кичке сәгать унберләрдә Ленин һәм аны озата баручы И.В.Сталин белән С.Я.Аллилуев вокзалга чыгып китәләр. Алдан билгеләнгән урында Ленинны һәм озатучыларны Сестрорецк эшчесе большевик Николай Александрович Емельянов каршы ала, Партия Үзәк Комитеты юлбашчыны яшерүне аңа тапшырган була. Барысы да алдан планлаштырылганча, төгәллек белән эшләнә. Ленин хәвеф-хәтәрсез генә Разлив станциясенә килеп җитә, ә берничә минуттан инде ул Емельянов өйчегендә була. Аны печәнлеккә әйләндерелгән сарай чардагына урнаштыралар. Алга узып шуны әйтергә кирәк: 1925 елдан бирле бу йортта В.И.Ленинның «Сарай» дип исемләнгән мемориаль музее эшли.

Владимир Ильичны ышанычлырак урынга яшерергә кирәк була. Моның өчен Емельянов Разлив күле артында станциядән 5–6 чакрым ераклыкта сазлыклы, урманлы бер урында арендага печән участогы ала.

«Күл аръягында бөтен нәрсә әзерләнеп беткәч, Ильичны, көймә белән чыгарып, шалашка урнаш-

тырдык, — дип яза соңыннан Н.Емельянов. — Чыбык-чабыклардан корып, печән белән капланган шыксыз гына бу шалаш урынында хәзер Ленинга граниттан куелган «Шалаш-һәйкәл» тора. Художниклар кайчакта Владимир Ильичны шалаш янындагы агач төбенә утыртып төшерәләр. Бу чынлыкка бик үк туры килми. Эшләү өчен Ленинга мин шалаш белән янәшә куе куаклыкта кечерәк кенә бер мәйдан әрчеп бирдем. Ул табигый куаклардан ясалган беседка сыманрак иде, анда агач төбе юк иде. Утыргыч хезмәтен үтәүче түмәр тора иде анда. Шалаш янында «кухня» эшләнгән, казыклар өстенә куелган аркылы агачта котелок эленеп тора иде...»

В.И.Ленин подпольеда булган хәлдә, Партия Үзәк Комитеты белән тыгыз элемтәдә яши. Аны вакыйгалар белән таныштыру һәм директивалар алу өчен, Разливка иптәшләре килә. Биредә Орджоникидзе ике тапкыр, Сталин да ике тапкыр була, Дзержинский белән Свердлов та килә. Тормыш һәм эш шартлары җиңел булмаса да, Ленин бик күп эшли, укый, яза. Шул ук вакытта Разлив күле артындагы сазлыкка дачаларда торучылар гөмбә җыярга кергәли торган булалар, һәм Ильичка берничә тапкыр бик тиз генә чын печән чабучы финга да әйләнергә туры килә.

...Без тарихи Разлив тугайларында. Мемориаль музей зонасына үтәбез. Ул СССРның халык художнигы, Дәүләт премиясе лауреаты В.Б.Пинчукның «Ленин Разливта» дип исемләнгән скульптурасы белән ачыла. Матур итеп эшләнгән павильонда В.И.Ленинның 1917 елның июль-август айларындагы тормышын һәм эшчәнлеген яктырткан экспозиция урнаштырылган. Биредә аның Разливтагы хезмәтләре белән танышырга мөмкин. Алар арасында «Лозунгларга карата» дигән брошюра, башка хезмәтләре, юлбашчының кулъязма күчермәләре бар. Экспозициядә 26 июль — 3 август көннәрендә Петроградта булган РСДРП(б)ның VI съезды материалларына киң урын бирелгән. Партия тарихыннан белгәнебезчә, Ленин бу съездда катнаша алмый. Әмма ул бертавыштан съездның почетлы председателе итеп сайлана. Ленин аңа подпольедан Үзәк Комитет членнары Свердлов һәм Сталин аша җитәкчелек итә. Съезд пролетариатның ярлы крестьяннар белән Союзда торып властьны алуны, кораллы восстание әзерләү лозунгысын алга куя, партияне социалистик революциянең җиңүен яулап алуга юнәлдерә. Витриналарның берсендә VI съезд беркетмәләре беренче басмасының төп нөсхәсе саклана. В.И.Ленинның «Дәүләт һәм революция» исемле гениаль хезмәте бүлегендә 1918–1975 еллар эчендә бик күп төрле телләрдә басылган китапларны күреп таң каласың. Экспозициядәге пролетариат җитәкчесенең көрәштәшләренең фоторәсемнәре, алар турындагы мәгълүматлар, Емельянов гаиләсенә багышланган аерым бүлек зур кызыксыну уята. Биредә үк Н.Емельяновка иҗтимагый-политик эшчәнлегенең 50 еллыгы уңае белән 1954 елда бирелгән Ленин ордены да саклана. Разливта Ильич файдаланган шәхси әйберләрнең копияләре, күлнең аръягына утырып чыккан көймәнең үзе дә җылы тәэсир калдыра.

Иң истәлекле урынга якынлашабыз. Хәзер дә Ленинның шалашы 1917 елда булган төсендә саклана икән. Шалаш янында граниттан һәйкәл торгызылган, аңа түбәндәге сүзләр чокып язылган: «Ботаклардан ясалган шалашта 1917 елның июлендә һәм августында Бөтендөнья Октябрь юлбашчысы буржуазия эзәрлекләвеннән качып яшәгән һәм үзенең «Дәүләт һәм революция» исемле китабын язган урында истәлек итеп граниттан шалаш куйдык. Ленин шәһәре эшчеләре. 1927 ел». Шалаш-һәйкәлгә шул ук елның 3 июлендә нигез салынган була. Ул тантанада большевик Н.А.Емельянов Ленин турында истәлекләр сөйли. Бер үк вакытта көймә туктаган урында пирс эшләнә һәм җәяүлеләр өчен сукмак салына. 1928 елның июлендә «Шалаш» мемориаль музее ачыла. Шалаш-һәйкәл янәшәсенә чын шалаш эшләнә, ул печән кибәненә тоташып тора, «ятак» хезмәтен үтәү өчен кибәндә куыш урын да ясала. Алар ел саен яңартылып тора. Шалаштан һәм кибәннән көнбатыштарак, куаклар эчендә, даһиның «яшел кабинеты» урнашкан. В.И.Ленин шаяртып үзе дә аны: «Минем яшел кабинетым», — дип атый. Һәйкәлдән берничә адым гына учак ясалган.

Тагын шул елларга кайтыйк. «Ленин янына иптәшләре бик еш килә иде. Разлив буендагы гади генә шалаш чын революция штабына әверелде, — дип искә ала Н.Емельянов. — Вакыт бик тиз үтте. Көз якынлашты. Яңгырлар ешайды. Әкренләп салкынайтканнан-салкынайтты. Хатыным өйдәге бөтен җылы киемнәрне ташып бетерде. Әмма бу да салкыннан һәм юештән коткара алмады. Шуның өстенә төрле хәбәрләр тарала башлады: имеш, Ленин, слесарь кыяфәтенә кереп, Сестрорецк заводында яшеренеп яши икән».

Владимир Ильич өчен ышанычлырак һәм куркынычсызрак яңа урын эзләп табарга кирәк була. Үзәк Комитет Ленинны Финляндиягә күчерергә карар бирә. Н.Емельянов Сестрорецк эшчесе Иванов Константин Петрович исеменә таныклык таба. Ленинны парик кидереп һәм гримлап рәсемгә төшерәләр. Фотокарточканы таныклыкка ябыштырып, Сестрорецк хәрби комиссариатының чын печатен басалар. Финляндиягә бару юлларын бик җентекләп эзләгәннән соң, иптәшләре Ленинга кочегар булып паровозда үтеп чыгарга тәкъдим итәләр. 8 августта Ленин кич белән соң гына шалаштан китә...

Хәзер бу тугайлар совет кешеләренең һәм чит ил кунакларының иң яраткан, кадерле урынына әверелгән. «Шалаш» мемориаль музее Бөек Ватан сугышы елларында да эшен туктатмаган. 1941 елның сентябреннән музейдан ерак түгел генә фронт линиясе үткән. Гранит һәйкәл янында шәһәрне саклаучылар Ватанга тугрылык хакында ант иткәннәр, монда Ленинград фронтының иң батыр солдатларын һәм офицерларын бүләкләгәннәр.

Бу тарихи урында ел саен меңнәрчә совет кешеләре һәм йөздән артык чит илдән килгән кунаклар була икән. Алар арасында элеккеге партия ветераннарын, комсомолларны һәм пионерларны, колхозчыларны һәм эшчеләрне, космосны буйсындыручыларны, галимнәрне һәм партия-дәүләт эшлеклеләрен дә очратырга була. Кыскасы, Разлив тугайлары һәркемдә әйтеп бетермәслек тәэсирләр калдыра.

*1986*

# Без — кардәшләр

ИСӘНМЕ, БУДАПЕШТ!

1992 елның 4 ноябрендә Казан Кремлендә Татарстан Республикасы хөкүмәте белән Венгрия Республикасы хөкүмәте арасындагы сәүдә-икътисади һәм фәнни-техник хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куелды. Әлеге килешү нигезендә Татарстан 1992 елда 150 «Икарус» автобусы һәм аларга ике миллион долларлык запас частьлар сатып алачак. Болар пассажирларны ерак рейсларга йөртү өчен эшләнгән. Беренче яруска туалет, багаж бүлеге, ял бүлмәсе, шоферлар кабинасы көйләнгән. Өстә — пассажирлар өчен утыргычлар һәм буфет. Тышкы ягы Татарстанның Дәүләт флагы төсенә буялган. Казанда һәм Чаллыда шушы машиналарны, Чаллыда һәм Чистайда телевизорлар һәм фотоаппаратлар җыю буенча уртак предприятиеләр булдырыла. Республика Венгриядән 3000 баш нәселле тана кайтартты. Бездә елына 3,5 миллион каз үстерүне җайга салу да бурыч итеп куелды. Югарыда телгә алынган рәсми документ буенча, Венгриягә 2000 кешене укырга җибәрү күздә тотыла. Аларның 1100е авыл хезмәтчәннәре — белгечләр, фермерлар, азык-төлекне эшкәртергә өйрәнүчеләр.

...17 гыйнвар көнне Казанда чыга торган барлык газета-журналларның да диярлек баш мөхәррирләре (шул исәптән Түбән Кама, Әлмәт, Буа, Тәтеш һәм Саба мөхәррирләре), радио һәм телевидение журналистлары — барысы утыз ике кеше «Татарстан» авиакомпаниясенең «ТУ-154» самолетында Будапештка юл тоттык. Салонда шулай ук йөзгә якын авыл хуҗалыгы белгече (бездән район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең терлекчелек бүлеге начальнигы Н.Юнысов һәм Киров исемендәге колхозның баш ветеринария врачы А.Гарифуллин), маркетинглар бар иде.

Өч сәгатькә якын очканнан соң, Будапештта Венгриянең эшлекле даирәләре каршы алды. Карның әсәре дә күренмәү, көннең җылы һәм кояшлы булуы бездәге апрель ае ахырын хәтерләтә иде. Татарстан тышкы икътисади элемтәләр министры урынбасары Флёра Зыятдинова һәм Цейс Холдинг Лимитед компаниясе (аның үзәге Канаданың Торонто шәһәренә урнашкан) вәкиле доктор Моротти Ласло реченнән соң безне 100 чакрым ераклыкта булган Балатон күле буендагы курорт зонасына — «Клуб Алига» дип исемләнгән, Венгрия социалистик эшчеләр партиясе Үзәк Комитеты әгъзалары элек ял иткән комплекска алып киттеләр. Балатон Үзәк Европада иң зур күлләрнең берсе икән.

Аның озынлыгы — 78, киңлеге 15 километрга сузылган. Ярлары, курорт һәм туристлык зонасы буларак, халыкара дәрәҗәле урын санала. Кышын да аккошлары белән үзенә җәлеп итеп тора. Беренче очрашуда ук «4 нче корпус» дип исемләнгән аерым йортта Венгрия коммунистлары лидеры Янош Кадарның бик күп мәртәбәләр ял иткәнен дә искәртеп куйдылар. Шулай итеп, Татарстаннан тәҗрибә өйрәнергә килүчеләрнең семинар-укулары башланып китте.

ИКЪТИСАДИ ТОРМЫШ

Венгриядә базар икътисады чаткылары 1960 елларның урталарында ук күренә башлый, индивидуаль кәсепчеләрнең һәм вак һөнәрчеләрнең роле үсә. 1970 еллар ахырында ук хосусый сектор сизелерлек арта. 1981 елда индивидуаль һәм коллектив вак предприятие хуҗалары барлыкка килә, малкуарларга һәм эшкуарларга юл ачыла, нәтиҗәдә шул вакытта ук милли доходның 20 процентын хосусый сектор алып тора. 1980 елдан катнаш типтагы базар мөнәсәбәтләре җәелә башлый. Шуңа күрә хәзер илдә хосусыйлаштыру (приватизация) киң фронтта дәвам итә, бернәрсәгә карамыйча рентабельсез предприятиеләр ябыла, андый банкротлыкка чыгучылар саны 1850 гә җиткән. Авыл хуҗалыгы кооперативларының да 70 проценты хосусыйлаштырылган, дәүләт кибетләре бөтенләй юк, сәүдә хосусый тәртиптә алып барыла, фатирлар һәм йортлар халыкның үзенекенә әйләндерелгән. Әмма квартирага хезмәт күрсәткән өчен (ут, газ һ.б.) түләү бик зур суммаларда исәпләнә.

Ә инде венгр авылларына килгәндә, аларның структурасы 1956 елдан ук нык үзгәрә. Шул вакытта ук 3,5 меңнән артык авыл хуҗалыгы кооперативлары төзелә, халыкны азык-төлек белән тәэмин итүдә дәүләт хуҗалыклары (госхозлар) оеша. 1965–1980 елларда аграр секторның үсеш темпы дөньяда беренче урынга чыга. Бу — кооперативларга һәм дәүләт хуҗалыкларына мөстәкыйльлек бирү белән аңлатыла. Нәтиҗәдә утыз ел эчендә (1960–1990) авыл хуҗалыгы продукциясе житештерү — ике тапкыр, азык

промышленносте әйберләре 6 тапкыр үсә. Бу язманың авторы әлеге чагыштыруны Татарстан хөкүмәтенең һәм белгечләрнең Венгрия икътисадын өйрәнүләре тикмәгә генә түгел икәнен сиздерү максатыннан китерә. Дөрес, соңгы 2–3 елда җитештерүчәнлек һәр тармакта кими башлый, әмма моны, нигездә, башка илләрнең, ягъни тышкы базар мөнәсәбәтләренең үзгәрүе белән аңлаталар.

## МАССАКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫ

Хосусыйлаштыру, базар экономикасы җилләре массакүләм мәгълүмат чараларына турыдан-туры кагылган. Керем китерми торган газета-журналлар ябылган. Балалар басмалары бөтенләй юкка чыккан. Без элек Венгрия социалистик эшчеләр партиясе Үзәк Комитеты органы булган «Непсабадшаг» газетасы редакциясендә булдык. Бер сүз белән әйткәндә, ул вакытта «Правда» кебек зур роль уйнаган баш матбугатның исеме генә калган. Элеккеге бинаны да ташлап чыкканнар, җитәкчелек тә алышынган, журналистлар составы да яртылаш үзгәртелгән. Газета акционерлык җәмгыяте карамагында, мөстәкыйль. Аны хосусыйлаштырганда, чит ил капиталы да (Германия) катнашкан. Әмма ул капитал 50 проценттан артмаска тиеш икән, газета үзен-үзе аклаганлыктан, капитал салган чит ил компанияләре доходтан процентлар алалар. Акционерлык җәмгыяте президенты һәм баш мөхәррир Этвеш Палның әйтүенә караганда, чит ил капиталы газетаның сәяси ягына хәзергә игътибар итми, аларны фәкать акча кызыксындыра. Дөрес, үзәк басма үзенең 47 процент укучысын югалткан. Чөнки бәяләр кыйммәт. Бу газета зур форматта, 32 битле итеп, атнага 6 тапкыр чыгарыла, барлык мәйданның 35 процентын реклама алып тора. Журналистлар уңай эш шартлары һәм җиңел машина белән тәэмин ителгән. Барлык өлкә газеталары диярлек чит ил капиталы катнашында хосусыйлаштырылган.

Ә инде радио мәсьәләсенә килгәндә, компания дәүләт карамагында. Әмма партияләргә бәйле түгел. Соңгы елларда радио җитәкчелеге белән хөкүмәт арасында низаг бара. Шуның нәтиҗәсендә венгр радиосы президенты һәм аның урынбасары отставка игълан иткәннәр. Әмма әле ул Венгрия Республикасы президенты Арпада Генц тарафыннан кабул ителмәгән иде. Радио өч программада эшли, 70 процент тапшыру коммерция эше белән бәйле.

Телевидение тапшыруларына килгәндә, аларның дәүләт карамагында һәм хосусый булганнары да бар. Тапшырулар 7–8 программада алып барыла. Берничә канал немец телендә, шулай ук венгр һәм Мәскәүдән рус телләрендә бирелә.

## ТАБИГАТЬТӘ МОГҖИЗА ЮК

Татарстан журналистлары, берничә төркемгә бүленеп, авыл хуҗалыгы предприятиеләре эше белән дә якыннан таныштылар. Мәсәлән, Кишчери дигән хуторда 2269 баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән Энинг дәүләт хуҗалыгына (госхоз) бардык. Бу Венгриядәге иң эре фермалардан санала. Биредә кайчандыр М.С.Горбачев та булуын телгә алдылар. Шушы хуҗалыктан Татарстанга таналар җибәрелгән. Рентабельле комплекс. Аның начальнигы Симори Янош хезмәтнең ничек оештырылуын аңлатып болай диде: «Табигатьтә могҗиза булмый. Продуктлылыкның 25 проценты — нәселдән, 60 проценты — ашатудан, дөрес итеп савудан һәм асрый белүдән тора, ә калган 15 проценты гына табигатькә бәйле...»

Без барган көнне голштино-фриз токымлы 1700 баш сыердан уртача 21 килограмм сөт савыла иде. Кайберләренең продуктлылыгы 40–50 килограммга җитә. Эш ике сменалы итеп оештырылган.

Комплекста бозаулар читлектә, салкын ысул белән үстерелә. 1200 баш нәселле тана бар. Татарстанга яхшы токымлы яшь терлекнең тере үлчәүдәге бер килограммы 2 доллардан сатылган. Спорт атлары үрчетелә.

Мал-туарны ашату игътибар үзәгендә. Түгәрәк итеп төкләнгән печән алларыннан өзелми. Нигездә, чәкәне белән туратылган кукуруз силосы ашатыла. Концентрат азык төрле культуралар белән аралаштырыла. Азык запасы мул, сыйфаты яхшы. Әле өченче елгы силос файдаланыла иде. Сыер, үзенә кирәкле рационны алганнан соң, торак уртасына төшәлгән саламга ял итү өчен кереп «чума». Атнага бер тапкыр әлеге коридорга салам өстәлеп торыла. Тораклар коры, климат җылы булганлыктан, бер ягы ачык, әмма җил үтәли йөрми.

Госхозның 10000 гектар җире бар. Игенчелек тә рентабельле. Узган ел 2000 гектардан 60 ар центнер бодай, шулкадәр үк мәйданнан бөртеккә игелгән кукуруздан 80 шәр центнер уңыш алганнар. Сыра өчен 1200 гектар арпа көздән чәчелә. Шикәр чөгендере уңышы да гектарга 550 центнер тәшкил итә. Борчак, соя, люцерна, башка культуралар игелә.

Фермада эшләүчеләр уртача 18000 фориент хезмәт хакы ала. Әмма салым зур. 6000 чамасы шуңа китә. Һәр шәхси хуҗалыкның бер гектарга якын җире бар. Эштән соң халык шунда шөгыльләнә. Малтуар асрый. Мәсәлән, баш зоотехникның үз хуҗалыгында 9 баш сыер, 75 баш дуңгыз асравы турында әйттеләр. Гомумән, халык эшчән. Әйбер бәяләре артык кыйммәт булганга, шәһәр халкының күбесе ике урында эшли, җае булганы шәхси хуҗалык тота. Хезмәт урыны кадерле. Чөнки ил буенча эшсезлек ха-

лыкның 10 процентын тәшкил итә. Аның тагын да артуы көтелә. Шул ук көнне без иске торакларны реконструкцияләгән икенче комплекста булдык. Узган ел биредәге 600 сыердан уртача 7004 әр килограмм сөт савылган. Сүзне артыкка сузмыйча, мондагы нәсел эшенә генә тукталыйк. Бер генә мисал. Болар бер-берсен 70000 долларга Америкадан яхшы токымлы дүрт сыер алып кайтканнар. Хәзер шуларның яралгыларын (эмбрион) күчерү белән шөгыльләнәләр. Ягъни, сыер орлыкланганнан соң яралгысын алып, башка яхшы нәселле сыерларга күчерәләр. Шунысы кызык: бу сыерларны донор дип атыйлар. Комплекс хуҗасы шул дүрт сыерның берсенә күрсәтеп болай диде: «Моның үзенең бер тапкыр да бозаулаганы юк, әмма аның оныгы бар инде...»

Гомумән, биредә һәр сыерның биографиясен кешеләрнеке кебек яттан беләләр. Венгрия белгечләре Татарстанга сатылган таналарның да ничек асралуын килгәләп контрольгә алырга вәгъдә бирәләр. Хосусыйлаштыру дәүләт хуҗалыкларында да 20 процент чамасы тәшкил итә. 10 процент акцияне коллектив әгъзалары алган. Әмма хәзергә бу өлкәдә дәүләт милке саклана. Чөнки халыкны туендырасы бар.

### ТАРИХИ УРЫННАР

Будапешт таң калырлык шәһәр икән. Ул үзенең архитектурасы белән җәлеп итә. Биредә игезәк йортлар юк диярлек. Чисталык, югары культуралылык иң беренче чиратта күзгә ташлана. Кече Париж дип аталган сәүдә кварталында йөрү үзе ни тора! 1896 елда венгрлар үз илләрен табуның 1000 еллыгын зурлап билгеләп үткәннәр. Шул уңай белән кыйммәтле сарайлар төзелгән. Без парламент бинасында булдык. Андагы зиннәтне, архитектураны күзең белән күрмәгәндә сөйләп тә, язып та тасвирлый торган түгел. Элеккеге корольләр крепосте хәзер музейлар үзәгенә әверелгән. Дунай аша салынган 12 күпернең һәрберсе үзенчәлекле проект белән эшләнгән. Геллерт таулары, Маргарита утравы, үзәк Рокоти урамы... Һәрберсе үзенчә архитектура ансамбле.

Кибетләр бик бай. Халыкча әйтсәк, атаң белән анаң гына юк. Әмма товар һәм продукция бик кыйммәт.

### ХАЛЫК МӨНӘСӘБӘТЕ

Дөресен әйтергә кирәк, элеккеге СССРга караш әйбәт түгел. Ленин һәм совет солдатлары һәйкәлләрен алып бетергәннәр, проспектларга, урамнарга сугышка кадәр булган исемнәре кайтарылган.

Венгрлар күршеләре Австрия кебек илләрдән артта калуларын совет зонтигы астында озак яшәүләреннән күрәләр. Моңарчы күрсәтелгән ярдәмне сәяси максатка юнәлдерелгән иде дип кире кагалар.

Татарстанга карата мөнәсәбәтләре җылы. Чөнки аларның бабалары безнең эраның беренче меңьеллыкларында Идел, Кама, Агыйдел елгалары буйларында яшәгәннәр. Үз тарихларын яхшы беләләр, безне кардәш халыклар дип исәплиләр.

*1993*

# Казан белән Томск арасы

***Сүз башы***

Казанның халыкара аэропортыннан «Як-42» самолеты күтәрелгәч, 8600 километр биеклектә очуыбызны, температураның 48 градус салкын икәнен, юлда 3,5 сәгать булачагыбызны хәбәр иттеләр.

Без инде үзебез бара торган Томск шәһәре турында берникадәр мәгълүматлы да идек. Патша вакытында губерна үзәге булган ул. Хәзерге Томск өлкәсенең мәйданы 316,9 мең квадрат километр, халкы 1 миллион 72 мең чамасы икән (1999 елгы мәгълүматларга караганда, Татарстан җире 68 мең квадрат километр, 3 миллион мең кеше яши). Ә инде тарихка күз салсак, борынгы Себер ханлыгы XV гасырда Алтын Урда дәүләте таркалгач төзелгән һәм XVI гасырның 80 нче елларында, казак атаманы Ермак Тимофеевич тарафыннан яуланып, рус дәүләтенә кушылган.

Том татарлары этник группасына кергән милләттәшләребез, нигездә, Томь, Обь елгалары буйларына төпләнгәннәр. Хәзер Себер татарлары 500 меңгә якын кеше булып, төп халкы 200 меңләп исәпләнә. Калган 300 меңе — төрле елларда Идел, Урал буйларыннан, башка төбәкләрдән күчеп килгән яисә сөрелгән Казан татарлары, мишәрләр, керәшеннәр һәм башка милләтләр.

Безнең сәфәребезнең максаты — татар гомер кичергән төбәкне барлау, аларның яшәеше, мәдәнияте, мәгарифе белән танышу һәм сабан туенда катнашып, милли азчылык булган кан кардәшләребезнең (өлкәдә 22 мең татар яши) барлыгын, Татарстан дигән җөмһүриятенең онытмавын күңелләренә сеңдерү

иде.

## ШӘҺӘР БЕЛӘН ТАНЫШУ

2004 елда үзенең 400 еллыгын билгеләп үтүче Томск шәһәре аэропортында безне чәкчәк һәм җырбиюләр белән каршыладылар милләттәшләребез. Өлкәнең Татар мәдәнияте үзәге директоры, бөтен гомерен милләтебезне саклап калуга багышлаган шәхес, Бөтендөнья татар конгрессының өчесендә дә делегат булып катнашкан Йосыф әфәнде Әбдрәшитов фестиваль программасы белән таныштыргач, шәһәр үзәгенә юл тоттык. Без авыр техникалар алу-сату белән эш итә торган эшмәкәр Эдуард Заһидуллин машинасына туры килдек. «Мин бирегә 1972 елда Златоуст шәһәреннән килеп урнаштым. Әти-әни татар кызына өйләнергә куштылар, шулай булмаса, бусагадан үткәрмәячәкләре турында кисәттеләр. Мин аларның сүзеннән чыкмадым. Рамилә исемле кәләш табып, тормыш кордык. Ике кыз үстерәбез. Алар да туган телебезне беләләр», — диде ул, безне сөендереп.

Томск — яшьләр шәһәре. Аның Ленин исемен йөрткән урамында гына да 6 университет бар. Башкалада яшәүче һәр бишенче кеше — студент.

Шәһәр белән танышуыбызны дәвам итәбез. Томскиның гербына олау аты рәсеме төшерелгән. Башта без 1900 елда төзелгән Ак мәчеткә юл тоттык. Татарстан кунакларын милләте буенча кыргыз булган имам-хатыйб Нурулла хәзрәт белән бер төркем картлар каршы алды. Түбәтәйләр бүләк иттек, хәерсадака салдык. Бу мәчет тә (русча Белая соборная) күпне күргән. 1930 елларга кадәр татар мөселман җәмгыяте хуҗа була аңарга. Репрессия елларында культура-спорт товарлары артеленә бирелә. Манарасы һәм гөмбәзе сүтелә, төп бина карандаш фабрикасы цехы итеп файдаланыла. 1990 елда мөселманнарга (алар — төрле милләт вәкилләре — шәһәрдәге халыкның 15 процентын тәшкил итә) мәчет кире кайтарыла һәм, тугыз ел буе реставрацияләнеп, үз вазифаларын башкара башлый. 2000 елда биредә СССР-ның беренче һәм соңгы Президенты М.Горбачев та була.

Шәһәрдә тагын бер дин йорты — Кызыл мәчет бар. Аның язмышы тагын да аянычрак булган, бу бинаны совет елларында аракы-шәраб заводы итеп файдаланганнар. Хәзер ул да хуҗаларына кире кайтарылган, әмма ремонтланып бетмәгән. Аның элек мәдрәсә булган өлешен намаз залы итеп файдаланалар икән. Биредә имам-хатыйб вазифасын таҗик милләтеннән булган хәзрәт алып бара. Тагын шунысы кызык: шәһәрдәге бу мәчетләрнең берсе — Уфадагы, икенчесе Азия Диния нәзарәтләренә карый икән.

## КӘРИМ БАЙ ЙОРТЫНДА

Томскидагы Татар урамында һәм Татар тыкрыгындагы барлык агач йортлар үзенә әллә кайдан җәлеп итә. Ике катлы итеп, үз заманының гүзәл архитектурасы белән салынганнар алар. Бүрәнәләр төсләрен югалтсалар да, тәрәзә йөзлекләренең матурлыгына сокланып туя алмыйсың.

Горький урамындагы Кәрим бай Хәмитов (ат белән сәүдә иткән) йортына 1995 елда Россия Президенты Указы белән «Россия Федерациясе халыкларының тарихи һәм мәдәни мирасы һәйкәле» статусы бирелгән. Биредә нәкъ 10 ел «Татар өлкә мәдәни үзәге» (ОЦТК) эшли. Аңа язмабыз башында телгә алынган Йосыф Якуб улы җитәкчелек итә.

Ә инде бу изге һәм кирәкле эшне алтмышынчы елларда Әнвәр Зиннәтов башлап җибәрә. Ул оештырган «Халык моңнары» ансамбле 30 ел буена Томскида һәм күрше-тирә өлкәләрдә бердәнбер иҗат коллективы була. 1990 елда шәһәрдә «Туганлык» — «Братство» мәдәни үзәге төзелә. Тора-бара ул, әйткәнебезчә, өлкә буйсынуындагы һәм финанслануындагы дәүләт учреждениесенә әйләнә.

Аның артыннан бик озак йөриләр, билгеле, күп каршылыкларны үтәләр. Моны, әлбәттә, милләттәшләребезнең зур җиңүе дип бәяләргә кирәк. Биредә дистәләгән коллективлар, түгәрәкләр, барысы 25 белгеч эшли. Үзешчән коллективлар үзләрендә генә түгел, Новосибирск һәм Кемерово өлкәләрендә дә чыгышлар ясыйлар. Рамазан, Нәүрүз, Сабантуй бәйрәмнәрен уздыруда башлап йөриләр. Алга таба милли кафе һәм «Татарстан» сәүдә йорты ачарга ниятлиләр.

Менә шушы йортта безнең рәсми очрашуыбыз булды да инде. Бик күп милләтпәрвәрләр, эшмәкәрләр, әдәбият-сәнгать сөючеләр гаиләләре белән килгәннәр иде. Очрашу үзәк белән танышудан башланып китте. Биредәге китапханә, музей залы, репетиция бүлмәләре милли рухилык белән сугарылган. Милләтпәрвәрләребез делегация составында танылган язучы һәм «Алтын ай» җәмгыяте президенты Мәдинә апа Маликова барын белеп, аның иҗатына багышланган гаҗәеп бай күргәзмә оештырып, бик күп сораулар әзерләп куйганнар иде үзенә. Мәдинә ханым, китапларын, үзенең иҗаты турындагы язмаларны күргәч, чын мәгънәсендә эреп китте. «Безне Себердә дә укыйлар, беләләр икән әле», — дип бик сөенде.

Очрашуны үзәкнең танылган сәнгать остасы Мәрьям ханым Маркелова халкыбызның җәүһәре — «Тәфтиләү» җыры белән башлап җибәрде. Аннары композитор Рөстәм Яхинның «Китмә, китмә, сандугач»ы яңгырады. Сөйләүләр җыр һәм музыка белән үрелеп барылды. Татарстан Республикасының атка-

занган мәдәният хезмәткәре, гармунчыларның Фәйзулла Туишев исемендәге бәйгесе лауреаты Вилорик Вәлиуллинның тальяны «телгә килгәч», бик күпләрнең күзләре яшьләнде, сокланулары йөзләренә бәреп чыкты. Татар-станнан килгән Рисәнә Мостафина башкаруында яңгыраган җырларга алкышлар бик озак яңгырады. Делегациябез җитәкчесе Рәис Миңнеханов кыскача гына Татарстан Республикасы һәм районыбыз белән таныштырды. Китаплар, сувенирлар бүләк итте. Аннары җыр-биюләр Кәрим байның ишегалдына күчте.

## ЕЛЕНА — ИСКЕ ИКШЕРМӘ КЫЗЫ

Ә менә Елена Шәүкәт кызы Сафиуллинаны без биредә очратырбыз дип һич тә уйламаган идек. Ул өлкә радиосыннан татарча тапшырулар алып бара икән. Иске Икшермә дигәннән, элек бер өлеше Томск губернасына кергән Красноярск краенда районыбызның Иске Икшермә, Сатыш, Тимершык, Килдебәк исемнәрен йөрткән торак пунктлары барлыгын белә идек. Столыпин реформасы вакытында моннан киткән якташларыбыз барып төпләнгән яңа җирләренә үз авыллары исемнәрен куйганнар. Бер елны аларның оныклары, Иске Икшермәгә кайтып, нәсел-нәсәбәләрен, шәҗәрәләрен барлап та йөрделәр әле.

Еленабыз бирегә 1978 елда, Икшермә урта мәктәбен тәмамлагач, әнисенең сеңлесенә — Тамара Васильевна янына килеп урнаша. «1974 елда әтиебез — озак еллар «Икшермә» совхозының партком секретаре һәм директоры булып эшләгән Шәүкәт Нәҗип улы вафат булды. Безнең нәселдә авырлык килеп туган вакытта ярдәм итә торган яхшы гадәт бар. Әнием Нина Васильевна да (ул озак еллар Икшермә мәктәбендә укытып, хәзер лаеклы ялда) туганнарында тәрбияләнгән. Менә мин дә Томскига килеп, рейтингы бик югары булган университетның тарих факультетына кердем. Башта Явеш мәктәбендә (татар авылы) укыттым, аннары Абытайга күчтем. Аспирантурага китәргә дә ниятләгән идем, укучыларым җибәрмәде...»

Әйе, бик игелекле эш алып бара Елена. Айга бер мәртәбә генә булса да, ана телебездә бөтен өлкәне шаулата ул. Аның һәр тапшыруын көтеп алалар милләттәшләребез. «Сибир-ский народный собор» дип исемләнгән төбәкара иҗтимагый хәрәкәттә мөселманнарның бердәнбер вәкиле буларак та танылып өлгергән ул. Аның өстенә бик күп җәмәгать эшләре алып бара. Узган ел Бөтендөнья татар конгрессына килгәч, туган авылына да кайта. Бик сагынып яши балачак еллары узган төбәген. «Сабалар килә икән!» дигән хәбәрне ишеткәч, хыялланып-канатланып йөргән. Тимер юл вокзалына барган башта, поездда без булмагач, самолет белән киләсебезне шалтыратып белгән. «Сабалылар — Татарстан вәкилләре — Томск җирендә» дигән радиотапшыру әзерләп калды ул.

Шактый танышлар очраттык Көнбатыш Себер җирендә. Нурислам исемле кеше Килдебәктә яшәүче Дәүләтҗан абыйсы Шакирҗановка сәлам әйтте.

— Без Татарстан халык шагыйре Шәүкәт Галиевнең баҗасы белән балдызы булабыз, — дип таныштырды үзләрен матур гына бер пар.

## АВЫЛ, КОЛХОЗ ТАРИХЫННАН

Абытай Томскига терәлеп торган (арасы 6 чакрым) авыл икән. 1679 елда чат татарлары нигез сала аңа. Башта алар юрталарда, землянкаларда (җир асты һәм киез өйләрдә) яшиләр, аннары агач йортлар сала башлыйлар. 1930 елда Җаббар Әбдерәшитов җитәкчелегендә «1 Май» колхозын төзиләр. Тора-бара ул 5000 гектар җирле «Томский» совхозына әйләнә. Гел алдынгы була татарлар эшли һәм яши торган хуҗалык. 1979 елдан яшелчәчелек белән шөгыльләнергә тотыналар. 220 гектарда бәрәңге игеп, 240 ар центнер уңыш алалар. 5 гектар мәйданда теплицалары бар. Соңгы елларда ябык типтагы акционерлык җәмгыяте итеп үзгәртелгән. Кыскасы, Томск шәһәрен ел тәүлеге яшелчә белән тәэмин итеп тора ул. 5000 тонналык саклау урыннары эшләнгән. Ун ел буе консервланган продукция чыгарыла, I–II сортлы он тартыла, төрле ярмалар ясала, үзләренең пекарнясында ипи пешә, макарон цехлары эшли. 2002 елдан сөт һәм ит җитештерү тармагы ныклап үзләштерелгән. Коллектив бик күп тапкырлар өлкә, Россия күләмендәге конкурсларда лауреат булган. Җәмгыять әгъзаларының (365 төп эшче исәпләнә) уртача хезмәт хакы 4000 сум, ул вакытында — совет чорындагы кебек — айга ике мәртәбә бирелеп барыла. Хуҗалык белән утызынчы елын милли җанлы, өлкә Думасы депутаты Рәшит Әминов җитәкчелек итә. Үз халкы өчен үлеп тора торган искиткеч талантлы кеше, оратор-трибун. «Бездә бик күп милләт вәкилләре — руслар, украинлылар, белоруслар, немецлар яши. Алар әкренләп татарга әйләнеп беттеләр инде», — дигән була. Әйе, Абытайның урта мәктәбе, спорт залы, мәдәният йорты, өч-дүрт бүлмәле музее, ресторан-кафесы, хәтта «Абытай татарлары» дигән махсус җыры да бар...

## АБЫТАЙ АКСАКАЛЫ

Сабан туе ел саен шушы авылда була икән. Бүген биредә бәйрәм өстендә бәйрәм булып чыкты. Халык моннан бер ел элек нигез салынган мәчет бинасы янына җыелды. Бирегә Томск өлкәсе губернаторы, милләте буенча немец булган Виктор Кресс, аның белән шәһәрнең, районның барлык җитәкчеләре килде. Ниятләре изге: Абытайның аксакалы, Бөек Ватан сугышы ветераны, гомер буе имам-хатыйб булып халыкка хезмәт иткән Минневәли ага Мансуровны 100 яше белән тәбрикләү икән.

— Без бүген Минневәли ага йөзендә татарларга булган уңай мөнәсәбәтебезне белдерәбез. Бу — ислам диненең яңарыш символы, халыклар дуслыгының яңа чагылышы, — диде губернатор. — Быелгы сабан туебызда Татарстан делегациясенең беренче тапкыр катнашуы тантана өстенә ямь өсти. Кичә бөтен татар дөньясы Президенты Минтимер Шәрипович Шәймиев белән ике тапкыр телефоннан сөйләшергә туры килде. Ул барыгызга да бәйрәм тәбрикләве җиткерергә кушты.

Аннары В.Кресс «Томь» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Рәшит Әминовка «Томск өлкәсендәге аеруча зур хезмәтләре өчен» билгесе, ә могтәбәр ветеранybыз Минневәли хәзрәткә «Ока» машинасы бүләк итте.

Бүләкләр күп булды аксакалга. Аны татарстанлылар исеменнән район хакимияте башлыгы, Татарстан халык депутаты Рәис Миңнеханов котлап, ветеранның туган ягыннан килгән бүләкләрне тапшырды. Аннары ул, кунакчыллыклары һәм киң күңеллелекләре өчен рәхмәт әйтеп, губернатор М.Кресcның иңенә затлы чапан салды, башына түбәтәй киертте. «Мәчет ачканда, мин тагын шушылай киенеп килермен әле», — дип, Татарстан кунакларын шәһәрнең 400 еллыгына чакырды. Абытай мәчетен юбилейга төзетеп бетерү өчен акча бүләргә вәгъдә итте губернатор.

Минневәли ага «Ока»сына кереп утырганчы, әңгәмә корып алырга да өлгердек әле.

— Без бу якларга 1913 елда күчеп килдек. Башта Тайга дигән җирдә яшәдек. Чыгышыбыз белән Әлмәт районының Елховой авылыннан. Татарстанга соңгы тапкыр 1957 елда кайткан идем. Авылыбыз ике мәхәлләле иде. Менә 1970 елдан бирле Абытайда торабыз, — дип сөйләп китте ул. — Кайда яшәсәм дә, имам-хатыйб вазифасын (1958 елдан) ташламадым. Дин тыелган совет чорында да туктамадык, кеше өенә җыелып укыдык. Бөек Ватан сугышының башыннан ахырына кадәр булдым, Сталинград фронтында идем, Смоленск өлкәсен аркылыга-буйга йөреп чыктык. Казан госпиталендә яраларны дәваларга да туры килде әле. Менә сәламәтлек кенә какшады, аяклар бетте. Бер күз күрми, икенчесе белән эрерәк хәрефләрне күзлексез укыйм әле.

Әйе, хәтере әйбәт, зиһене яхшы әле йөзьяшәр бабайның. Башкомандующий И.Сталинның кайбер приказларыннан өзекләр китерә-китерә сөйли сугыш хатирәләрен. Яшь имам-хатыйб Рәхимҗан гел остазы янәшәсендә булды. Ул Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен 1999 елда тәмамлап кайткан. «Безнең нәсел Саба районыннан. Бабай авылыбызның исемен дә әйтеп калдырган иде. Ниндидер кош исеме белән бәйле иде ул...»

Сабантуй барышында истәлекле мизгелләр күп булды. Мәйданга Россия, Татарстан һәм Томск өлкәсе флаглары урнаштырылган иде. Президентыбыз М.Шәймиевнең котлау сүзләрен ике телдә халыкка җиткереп, байтак милләтпәрвәрләребезгә истәлекле бүләкләр тапшырды Рәис Нургалиевич. Кол Шәриф мәчете рәсеме төшерелгән келәмне Томский районы хакимияте башлыгы Анатолий Каплунов кабул итеп алды. Дүрт сәгатькә якын барган концертыбыз аеруча ошады Себер татарларына.

— Моның кадәр кеше җыелганы юк иде. Сез килгәнгә күрә инде бу галәмәт, — диде алар.

Җырда-биюдә генә түгел, башка бәйгеләрдә дә сынатмадылар сабалылар. Мәсәлән, ярымайлы колга башындагы призны биюче егетебез Раян Садриев менеп алды. Сабантуйның йөзек кашы булган көрәш көтелмәгән куаныч китерде безгә. Мәйданнан читтә — ком өстендә көрәшәләр икән монда. Эзмә урта мәктәбе директоры Азат Галиев (район сабан туе батыры Айдарның энесе) башта 80 килограммлы үлчәүдә чемпион исемен яулады. Аннары грек-рим көрәше буенча Россиянең спорт мастеры, үзеннән озын һәм 30 килограммга авыррак Равил Фатыйховны күтәреп салып, абсолют батыр калды. Аннан соң халыкка мөрәҗәгать итеп: «Мөхтәрәм милләттәшләр! Сезгә Татарстан көрәшчеләреннән кайнар сәлам. Алга таба да милли бәйгебезне югалтмагыз, матур традицияләребезне бетермәгез. Ә менә сабантуйның төп призы булган тәкәне Равилгә һәм аның көрәштәш дусларына бүләк итәм...» — диде.

Себердәге милләттәшләребездә сабан туенда «Иң үрнәк йорт» дигән татар конкурсына йомгак ясалып, бүләк тапшырыла икән.

Менә саубуллашыр минутлар да җитте. Әмма автобус каршына берничә кеше чыгып, бераз туктап торырга мәҗбүр иттеләр. «Сездә айдан артык яңгыр юк икән, үләннәрегез көя башлаган, Татарстаннан шифалы яңгырлар җибәрәбез», — дигәч кенә юл ачылды.

Өч сәгатьтән артык очыштан соң «ЯК-42» самолетыбыз йомшак кына итеп Казан аэропортына төшеп «кунаклады». Көчле кул чабулар яңгырады туган җиребездә.

### *Йомгак*

«Без — бердәм, бүленмәс милләт» дигән гыйбарә узган ел август аенда булып узган Бөтендөнья та-

тар конгрессында кат-кат ассызыкланган иде. Соңгы елларда Россия шәһәрләренең сабан туйларында Татарстан районнары делегациясе катнашуы Казанның тарихи мәркәз икәнен тагын бер кат раслый.

Себердәге кан кардәшләребезнең телләре, диннәре, мәдәниятләре сакланышын, иҗтимагый-сәяси оешмалар эшчәнлеген өйрәндек без дә. Чөнки телсез, динсез милләт милләт түгел ул. Аларның өлкә буйсынуындагы һәм финанслануындагы Татар мәдәнияте үзәге булуы, мәчетләрнең кайтарылуы һәм реставрацияләнүе, «Татарстан — яңа гасыр» (ТЯГ) телевизион программасының күрсәтә башлавы куандырды, билгеле.

Әмма... Себер татарларының киләчәге өметлеме соң? Бу сорау әледән-әле борчып тора. Милли лидер, җанатар Йосыф Әбдрәшитовның «Күбрәк башка милләт өчен эшлиләр. Күңелдә татарлык җитми» дип, җан ачысы белән әйткән сүзләре хәтердән чыкмый.

Россиядә унитар дәүләт ясауга омтылыш зур булган чорда проблемалары күп шул милләттәшләребезнең. Мәсәлән, үзләренең телестудияләре эшләүдән туктаган, рәсми төстә ана телендә бер газета-журнал да чыкмый. Якташыбыз Елена алып бара торган радиотапшыруларның эфир вакыты да 1 сәгатьтән 30–35 минутка кыскартылган. Бу — тәүлеккә бер генә минут дигән сүз бит. Татар теле бер мәктәптә дә укытылмый. Атнага 2–3 тапкыр алып барыла торган факультативлар телне камил белергә ярдәм итми шул, дәреслекләр җитенкерәми. Ә бит заманында Томскидагы Себер төрки-татар педагогия техникумы (1924–1953 еллар) Уралдан башлап Ерак Көнчыгышка кадәр укытучы кадрлар әзерләгән. Шәһәрдә 6 татар мәктәбе булган. Хәзер, 60 елдан соң, 10 нчы мәктәпкә (директоры Надия Исмәгыйлева) татар мәдәниятен кайтару буенча шактый эш алып барганнар, музей булдырганнар. Мондый башлангычларны хупларга кирәк, әлбәттә.

Проблемалар күп, билгеле, әмма максатлары якты, теләкләре изге кан кардәшләребезнең. Бердәм, бүленмәс милләт булсак, аларның планлаштырылган эшләре тормышка ашар әле.

*2003*

# Сабантуй — борынгылык бәйрәме

Айдан артык инде татар халкының хезмәт сөючәнлеген, тыйнаклыгын, түземлелеген, кунакчыллыгын, үз-үзенә тугрылыклы булып калуын, теләсә нинди бәйгеләрдә дә көрәшә һәм җиңә белүен ача торган сыйфатларын чагылдырган сабан туйлары дәвам итә. Ул, Татарстан чикләрен күптән узып, ЮНЕСКОның «Кешелекнең сөйләм, матди булмаган, мәдәни гүзәлләр мирасы» Бөтендөнья исемлегенә кертелү алдында тора. Быелгы милли бәйрәмебез Россиянең илледән артык төбәгендә узды. Безгә, сабалыларга, 2003 елда Томск каласындагы сабантуйга самолет белән очарга насыйп булган иде. 2004 елда исә, автобусларга утырып, Удмуртия башкаласы Ижауга юл тоттык.

Биредә милли бәйрәмебез, татарлар яши торган бистәдә — Ленин районының «Локомотив» стадионында уза икән. Милләттәшләребез күп җыелган иде яшел чирәмле мәйданга. Чигүле сөлгеләр белән бизәлгән ат арбасындагы тальян гармунлы бабайларның «Авыл көе»н сыздыра-сыздыра стадионны әйләнеп чыгулары да күпләрнең күңелен җилкендергәндер. Сирәк кенә булса да, үзе белән бергә картайган яшьлек ядкаре — көмеш чулпыларын таккан әбиләрне дә очраттык.

Бәйрәмнең рәсми өлешенә халкыбызны хөрмәт иткән җитәкчеләр күп килгән иде. Башта сәхнә түренә Ижевск мэры Виктор Балакин, шәһәрнең Ленин районы хакимияте башлыгы Андрей Пиянзин, Удмуртиянең татар иҗтимагый үзәге президенты Фнүн Мирзаянов, Дәүләт Советы һәм шәһәр думасы депутатлары күтәрелде. Аннары олылап һәм хөрмәтләп Татарстан Республикасы кунаклары — районыбыз хакимияте башлыгы Рәис Миңнеханов, «Татреспотребсоюз» идарәсе рәисе Мәхмүт Фәттахов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Шаһинур Мостафин һәм башкалар чакырылды. Рәис Нургалиевич стадионга җыелган халыкка Президентыбыз Минтимер Шәймиев котлавын җиткерде, шәһәр мэры Виктор Балакин белән ТИҮ президенты Фнүн Мирзаяновка затлы чапаннар, калган җитәкчеләребезгә түбәтәйләр кидертте, Ленин районы хакимиятенә Казан Кремле рәсеме тукылган келәм бүләк итте.

Шәһәр һәм өлкә җитәкчеләре бөтен Удмуртия буйлап сибелгән татарны җыя торган олуг бәйрәм — сабантуй белән котлаганнан соң, халык уеннары башланып китте. Аяз күк йөзен бизи-бизи парашютчылар сибелде.

Ниһаять, сабантуй таҗы — татарча көрәш башланды. Иң элек малайлар чыкты. Аннары өлкәннәр көч сынашты. Әмма биредә үлчәнеп бил алышмыйлар икән. Бау белән тотышу да юк. Пәһлевандай ирегетләр җыйнак кына гәүдәле яшүсмерләрне күтәреп салырга мәҗбүр булдылар. Ризасызлыклар, гадел итеп хөкем итмәү күренешләре дә юк түгел иде. Күпме генә тартышмасыннар, көрәшчеләр чиста итеп бер-берсен ала алмадылар. Шактый азапланганнан соң, хөкемдар бабайлар, «Ижауның 2004 елгы Сабантуй батыры» дип, Таһир Хуҗагалиевне игълан иттеләр. Ул быел Әгерҗедә дә көрәш символы — тәкәгә лаек булган икән. Саба батыры Фәргат Фәйзуллин икенче урын белән канәгатьләнде.

Милли бәйрәмдә татар халкының данын гомер бакый еракларга тараткан ат чабышлары булмау да сабантуйның дәрәҗәсен киметә төшкән кебек итте.

Ә менә мәйданның кыл уртасындагы сәхнәдән көн буе җыр-биюләр халыкны дәртләндереп торды.

Читтә яшәүче милләттәшләребезне Саба татар эстрадасы йолдызлары чыгышлары рухландырды. Халык урыныннан кузгалмыйча, бер сулыш белән ике сәгатькә якын концерт карады, һәр номерны көчле алкышларга күмде. «Афәрин!», «Браво!» дигән сүзләр еш яңгырады, биюләргә татарлар гына түгел, удмуртлар, руслар, башка милләт вәкилләре дә кушылды. Сабалылар артыннан сәхнәгә ижаулылар үзләре, удмуртларның фольклор ансамбле, атаклы җырчылары күтәрелде. Биредә якташыбызның — Эзмә авылында туып үскән Ирек Мөхәммәтҗановның җырлавын бик яраталар икән ижаулылар. Аларны Яр Чаллыдан килгән Гөлдания Хәйруллинаның концерт группасы алыштырды. Кыскасы, халык рәхәтләнеп күңел ачты, уйнады, көлде.

Саубуллашыр алдыннан без милләтпәрвәр шәхес, утыз елдан артык шушы шәһәрдә яшәүче Фнүн Мирзаяновтан татар диаспорасы турында сөйләвен үтендек.

— Ижауда 30 меңнән артык татар бар. Дәүләт Советы депутатларының 13 проценты мөселманнар, — дип сүз башлады ул. — Милләттәшләребез бер-берсенә ярдәм итеп, дус һәм тату яшиләр һәм эшлиләр. Алар, татар иҗтимагый үзәге белән берлектә, милли мәгарифне, мәдәниятне һәм динне үстерәләр, шуларга бәйле финанс мәсьәләләрен чишәләр. Уртак тырышлык белән Ижауның педагогия училищесы каршында татар бүлеге, Удмуртия дәүләт университетында татар факультеты ачылды. «Минем Удмуртиям» каналында татарча «Хәерле кич» тапшыруы эфирга чыгып, кан кардәшләребезне сәламли. Үз телебездә «Яңарыш», «Ихлас», «Саф-ислам» газеталары нәшер ителә. Яшьләр белән эшләүгә зур игътибар бирелә. Алар өчен «Иман» дип аталган татар яшьләре бүлеге оештырылды. Күптән түгел Удмуртиянең Можга шәһәрендә яшьләр өчен республика дәрәҗәсендә сабантуй үткәрелде.

Фнүн әфәнде болар хакында илһамланып, горурланып сөйли. Ул Удмуртия президенты Александр Волковның милли мәсьәләләр буенча киңәшчесе буларак та республика хуҗасына һәрдаим ярдәме өчен тирән рәхмәт сүзләре җиткерә. Президент фатихасы белән 1000 кеше сыйдырышлы икенче мәчет төзелә башлаган. Бу изге гамәлгә безнең Президентыбыз Минтимер Шәрип улы бер миллион сум акча күчерткән. Милли мәсьәләләрне уңай хәл итүдә Нәгыйм Каюмов җитәкли торган «Ихлас» хәйрия фондының да йогынтысы зур икән. Гомумән, милләттәшләребез җитәкчелек итә торган зур-зур предприятиеләр үзләреннән саллы өлеш кертәләр изге эшкә. Быелгы сабантуй да бердәмлек, милләтпәрвәрлек нәтиҗәсендә оешкан.

Сүз артыннан сүз чыгып, Казакъстанның беренче очучы-космонавты Тәлгат Мусабаевның әнисе Можга татары икәнен белдек. Ул медицина институтын тәмамлаган, Казакъстанга эшкә җибәрелә һәм шунда кияүгә чыга. Тәлгат быел Можга сабан туена кайтып, татарча белүе белән шаккатырган.

Бу урында хәзер Австралиядә яшәп иҗат итүче, быелгы «Татар җыры» фестивалендә катнашып, тамашачы мәхәббәтен казанган Зөлфия Камалованың да Удмуртиянең Сарапул шәһәре кызы икәнен искәртеп үтү кирәктер.

Әлеге язманы тәмамлар алдыннан, Ижау шәһәренең горурлыгы булган автоматлар һәм пулеметлар конструкторы, ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое, Ленин һәм Сталин премияләре лауреаты генерал Михаил Калашниковка (1921 елда туган) музей төзелә башлавын да хәбәр итик.

Әнә шундый куанычлы тәэсирләр белән кайттык без милләтара бәйрәмебездән. Татар бар җирдә хәтәр түгел, ә тынычлык, бердәмлек, фидакарь хезмәт һәм кешеләрне берләштерә торган сабантуйның барлыгына һәм булачагына инанып кайттык.

*2004*

# Кече авылда олы бәйрәм

Теләче районының Үзәк авыл советы биләмәсендәге Петровский поселогында (ул утыздан артык өйле авыл) ел саен Теләче районының кече сабан туе үткәрелә. Әлеге төнге тамаша турында Мәскәүдә һәм Казанда чыга торган газеталар тәфсилләп яза килә. Без хәзер элегрәк булган бер бәйрәмне искә төшерик.

Сабантуйга әзерлек кенә бара иде. Гадәттәгечә, СССРның һәм союздаш республикаларның флаглары җилферди, удар хезмәткә һәм спорт уеннарына чакырган лозунглар тирбәлә. Кунакка кайтучылар, Петровскийда һәм Алгада яшәүчеләр зираттагы каберләрне тәртипкә китергәннәр, чардуганнарны буяганнар. Татарча көрәш бәйрәме өчен бирнә җыйганнар, кайта алмаганнар акча җибәргәннәр.

...Менә бер-бер артлы автобуслар, җиңел машиналар агыла башлады. Аларның номерларына карасаң, бәйрәмгә кайтучыларның чит өлкәләрдән, хәтта Ерак Көнчыгыштан ук булуларына инанасың.

Урманга тоташа торган алан музыкага чума. Ниһаять, кичке караңгылык төшкәнен сиздереп, утлар кабына. Тамаша гер күтәрүдән башланып китә. Менә мәйданга татарча көрәштә катнашучылар чакы-

рыла. Татар көрәше. Бил алышу. Халкыбызның милли көрәше — Петровский бәйрәменең дә түрендә. Чөнки ул — кече авылдагы бәйрәмнең йөзек кашы.

Мәйдан уртасында — Ленин исемендәге совхозның алдынгы шоферы Иван Аргишев. Быел ул егерменче елын хөкемдарлык итә. Иван Николаевич әйтсә — закон. Чөнки ул гаделлекне ярата. Аңа М.Федоров, С.Артемьев ярдәм итә. И.Аргишев бәйрәмне үткәрү өчен, халыкчан итеп әйтсәк, җан атып йөри. Барлык оештыру чаралары аның аша үтә. Менә төнге караңгылык төшә. Мәйдан тирәсендәге халык көрәшне күзәтә. Башта сиксәннән артык пәһлеван бау тотышкан иде. Алар арасында СССРның спорт мастерлары, РСФСР чемпионнары, районнарның сабантуй батырлары бар. Көрәшчеләр белән С.Федоров таныштырып бара. Биредә үлчәү авырлыкларына бүленеш юк, чиста итеп егарга гына кирәк. 65 килограммлы гәүдәлегә центнердан артык авырлыктагы кеше туры килә икән — бернәрсә дә эшли алмыйсың. Җиңелгәннән соң, көрәштәшеңнең кулын кысып чыгып китәсең. Бу тамаша шунысы белән кызык та. Бертигез көчле парлар туры килеп, берәр сәгать көрәшкәннәр дә булды. Андый вакытта баш судья, көрәшчеләр ризалыгы белән сөлге тотып, янә шобага сала.

Әйткәнебезчә, көрәшчеләр күп. Алар — Казаннан, Яр Чаллыдан, Питрәчтән, Түбән Камадан, Балтачтан, Арчадан... Сабалылар да көчләрен сынап карады. Әмма финишка Арчадан М.Таһиров, Питрәчтән Р.Гыйниятов, Яр Чаллыдан М.Галиевләр чыктылар. Баш приз өчен Марат Галиев белән Рөстәм Гыйниятов аеруча озак тартышты. Бер-берсен чиста сала алмаячакларына алар үзләре дә инандылар. Рөстәмнең гәүдә зур, ә Маратның көрәшү алымнары камил. Шуңа күрә егетләр тотышырга ризалык бирделәр. Бәхет узган елгы Петровский сабан туе батыры Марат Галиевкә елмайды. Батырга дигән тәкә аңа бирелде.

...Бөтенхалык бәйрәменнән халык таралганда, таң сызылып аткан иде инде. Сәүдә хезмәте күрсәтүчеләр дә кайтырга җыена икән.

— Төн буе сәүдә иттек, без генә алты йөз сумнан артык ашау-эчү әйберләре саттык, — ди Теләче коопредприятиесе сатучысы, хезмәт ветераны Сания Әбелкәрәмова.

Таң атты. Халык бәйрәмендә тәртипсезлекләр булмады. Килгән җиңел машиналарны район эчке эшләр бүлеге дәүләт автоинспекциясе хезмәткәрләре урнаштырып торды. Бәйрәм фаҗигасез узсын өчен, халык үзе дә кайгыртучанлык күрсәтте. Шуңа күрә бу төбәк кешеләре дә, кайткан кунаклар да олы тамашадан чын күңелдән риза булып таралыштылар. «Бер елдан соң очрашканга кадәр», — дип кул биреп саубуллаштылар алар. Шулай итеп, Петраудан соң яңа хезмәт иртәсе башланды. Анда катнашучыларның күбесе бәйрәм тәэсире белән эш урынына юнәлде. Аларны мәйдан уртасындагы татарча көрәш бәйрәме символы — чигелгән сөлге — удар эшкә рухландырып озатып калды...

13 июль иртәсендә Иван Аргишев белән иркенләп сөйләшә алмадык. Ул рейска ашыга иде. Аңа Казаннан терлекләр өчен барда ташу йөкләнгән. Без Иван Николаевичны ял көнне совхозның чөгендер плантациясеннән таптык. Алар кайткан кунаклары белән үзләренә бүленгән участокны икенче кат эшкәртәләр иде.

Гаилә башлыгы сүзен болай дип башлады:

— Белгәнегезчә, бу йола алты дистә елдан артык дәвам итә. Авылның туган көне керәшен татарларының дини бәйрәме Петрау белән бәйле. Шуңа күрә элегрәк тыярга да тырышып карадылар. Хәзер андый нәрсә юк. Кем тели, шул катнаша. Без моны илебездә бара торган үзгәртеп кору сәясәтенең, хәбәрдарлыкның бер чагылышы итеп күрәбез. Безнең бәйрәмне көрәш яратучылар зур сабантуй итеп кабул итәләр. Бу традицияне алга таба да дәвам итәчәкбез. Чөнки Петровскийның, Алганың башка кайбер кечкенә авыллар кебек таралып юкка чыкмавы да шушы сабан туе белән бәйле бит.

*1989*

# Җәйге гүзәллекне сагынып

Моңсу булса да, озакламый кыш белән саубуллашырга туры килә, март — язның беренче ае. «Март — шарт» дигән гыйбарә дә бар. Димәк, зыкы суыклы көннәр, әче җилле бураннар кабатланыр әле. Әнә кар бөртекләре әкрен генә кешеләрнең иңнәренә төшә, аяк асларына сибеләләр. Озакламый сыерчык бураннары башланыр, көртләрнең иң биекләре өелер. Аннары җир йөзе кабат яшәрер. Кыскасы, табигать ялгышмый: яздан соң — җәй, җәйдән соң — көз, аннары кыш килә.

...Ә менә табигатьнең бөтен матурлыгы, гүзәллеге, тылсымы аның сихри таңындадыр. Елның һәр фасылында матур ул. Мин, шәхсән үзем, иртә таңда торып, фикерләремне ап-ак кәгазь битләренә төшерергә, күңелем һәм каләмем белән үткәннәргә әйләнеп кайтырга яратам. Бүген дә — март уртасындагы аяз көннең чын кышкы иртәсендә — Кара диңгез шавы язылган кассетаны магнитофонга куйдым да, узган җәйне сагына-сагына, шушы сәяхәтнамәне язарга керештем.

Ямьле май аеның ахырында телефон шалтырады. Татарстан Журналистлар берлеге рәисе урынбасары Юрий Ханжин икән, Сочи янәшәсендәге Дагомыс шәһәрендә узачак «Бөтенроссия — 2004» матбу-

гат фестиваленә катнашырга тәкъдим ясады. Журналистларның мондый форумының 2000 елдагысы Казанда (анысында катнаштым да) Мәскәүдә, Санкт-Петербургта, Екатеринбургта узганын беләидем. Бу бит заманында бөтен СССР өчен ял урыны саналган Сочи! «Бармыйм» дип әйтергә ничек телең әйләнергә кирәк.

Казан — Адлер поезды белән югла кузгалдык. Безнең делегация өчен өстәмә вагон таккан булып чыктылар. Иң арттагысы да иде ул. Төнлә кайсыдыр станциядә тагын бер вагон өстәгәннәр. Анысында Чечняга алты айга хезмәткә баручы милиционерлар икән... Дөнья шулай инде ул: кемгә — фестиваль, диңгез буе, кемгә — таулар, үлем сагалап йөри торган үзәннәр...

...Менә безне Туапсе вокзалы каршы алды. Күпме кешене каршы алып озаткандыр инде бу тарихи бина.

Туапседан башлап тимер юл да, автомобильләр магистрале дә диңгезнең ярына терәлеп үтә. Шулай итеп, пассажирлар алдында аңлатып бетерә алмаслык искиткеч манзара ачыла.

Сочига якынлаша башлагач, ял итү өчен торак урыны — аерым йорт, бүлмә тәкъдим итүчеләр вагон буйлап йөри башладылар. Бер караваt өчен көненә 150 сумнан алып түлисе икән. Кеше өстендә яшисе килмәгәннәр бер бүлмәле фатир өчен тәүлегенә 700–1000 сум чыгарып салырга тиеш була. Бәяләр базардагыча, төрле-төрле, билгеле.

Сочи тимер юл вокзалында безне махсус автобуслар көтеп тора иде. «Кубань встречает Вас с любовью», «Кубань — жемчужина России» дигән яртышар метрлы хәрефләр белән язылган сүзләр күңелне иркәли. Табигатьнең гаҗәеп почмагына урнашкан РФ Президенты хакимияте карамагындагы 25 катлы «Дагомыс» мәдәни-савыктыру комплексына (аны җәмгыять белән партия идарә иткән елларда Югославиядән килеп төзегәннәр, КПСС Үзәк Комитеты кунакханәсе буларак, чит ил кешеләрен генә кабул иткән ул) барып урнаштык.

2004 елның 14 июне кичендә фестивальне ачу тантанасы булды. Анда март аенда гына икенче тапкырын Краснодар краеның губернаторы итеп сайланган А.Ткачев катнашты. Бу фестиваль Кубаньда аның инициативасы белән, әлеге төбәкнең мәдәниятен, яшәешен, чәчәк атуын 89 регионнан килгән ике меңгә якын журналистка күрсәтү йөзеннән оештырылган иде. Тантаналы мизгелләр күп булды, әлбәттә. Россия Журналистлар берлеге рәисе Всеволод Богдановка казакларның чикмәне (бурка) белән папахасын киертте. Ул почетлы казак итеп кабул ителде. Ә губернатор үзе «Көн эшләпәсе»нә («Шляпа дня») лаек булды.

— Мин үземне һәрвакыт журналистлар белән бер каекта итеп сизәм, — диде ул, олы эшләпәне батырып башына кигәч.

Аннары А.Ткачев туган җиренең ашлыкка, балыкка, җиләк-җимешкә, шәрабка, бигрәк тә талантлы кешеләргә гаҗәеп бай икәненә басым ясады. Кубаньның язучылардан Владимир Максимов, Александр Солженицын, Виктор Лиханосов, 46 тел белгән сәясәтче, заманында Л.Брежневның тәрҗемәчесе булган Анатолий Овсянников, рәссам Илья Репин, өч тапкыр Советлар Союзы Герое очучы Александр Покрышкин, композитор Григорий Пономаренко, режиссер Сергей Бондарчук, СССРның халык артисткасы Нонна Мордюкова, 1996 елда Мәскәүдән Краснодарга килеп балет театрын оештырган Юрий Григорович, бокс буенча Европа һәм XXII Олимпия уеннары чемпионы Шамил Сабиров кебек шәхесләр белән горурлануын әйтте.

Сәхнәгә бер-бер артлы дәрәҗәле кунаклар күтәрелде. Бигрәк тә казак хәрәкәте, хәрби мәсьәләләр һәм армиягә кадәрге яшьләрне тәрбияләү буенча край департаменты җитәкчесе, Кубань казакларының атаманы генерал Владимир Громов чыгышы тәэсирле булды. «Кубань — Җирнең кабатланмас почмагы. Таулар, кырлар, урманнар һәм диңгезләр. Кубань — казаклар горурлыгы, минем газиз туган җирем», — диде ул.

Кыскасы, күңелдән мәңге истән чыкмаслык бу тантана Кубань казаклары хоры катнашындагы концерт, заманында Мәскәүнең Зур театрында эшләгән Юрий Григоровичның балет театры чыгышы белән тәмамланды. Аннары «Агат» ресторанында губернатор А.Ткачев кабул итү — банкет уздырды.

Банкет дигәннән, һәр кичне диярлек булды ул. Мәсәлән, икенче көнне кичке сәгать сигездә Кавказ халыклары исеменнән кабул итү пляжда оештырылды. Ә менә «Кубань ярминкәсе» (Кубань өстәле, Кубань шәраблары бәйрәме, казак җырларын тәкъдир итү) кичке дүрттә башланып, төнге уникедә бетте. 2000 журналистка йөз итү станнарга бүлеп бирелгән иде. Андагы казакларның үзләренә генә хас, безнең күзләр күрмәгән ризыкларның, кувшинлы, чирекле шешәле сөйләп бетергесез аракы-шәрабларның төрен татып карау гына түгел, санап чыгып та булмыйдыр. Гомумән, Краснодар краеның кунакчыллыгын Россиянең массакүләм мәгълүмат чаралары әһелләренә мәңге онытылмаслык итеп күрсәтү бурычы куелган икән губернаторның үзе тарафыннан. Журналист халкы рәхәтләнеп ял итте. Җиде йолдызлы коньякка лимон салып эчүчеләр дә күренгәләде. Алай зур корбаннар булмады үзе. Кайбер каләмдәшләр видеокамера, цифрлы фотоаппарат кебек «вак-төяк» кенә югалтканнар иде.

Әлбәттә, гел ашау-эчүдән генә тормады фестиваль. Көндезләрен һәр регионның газета-журналлары күргәзмәсе эшләде. Россиянең танылган шәхесләре, язучылары, журналистлары, Дәүләт Думасы депутатлары белән очрашу-әңгәмәләр, мастер-класслар, «Кайчан? Кайда? Ничек?» дип исемләнгән интел-

лектуаль уеннар, хәтта балык тоту ярышлары, футбол матчлары да оештырылды. Кыскасы, һәркемне канәгатьләндерерлек итеп оештырылган иде секция эшләре. Безгә аның «Район газетасы — бүгенге һәм иртәгегесе көн. Проблемалар һәм перспективалар» дигәне кулай булды. Шулай итеп, бер атнага якын матбугатны ничек алга җибәрергә дип баш ваттык.

Дөрес, гел аудиториядә генә утырмадык инде анысы. Иркен вакыт булуга, диңгез буена ашыктык. Ходай биргән комга — пляжга да чакыру билеты белән лифтта төшәсе икән. Без, колхозчы малайлары, «Ватаным Татарстан» газетасының элеккеге баш редакторы Мөнир ага Әһлиуллин белән беренче тапкыр җәяүләп төшкәнбез дә, күрмәгәндәй, кояшта кызынганбыз. Татарстаннан килгән тиреләребез хәтта кубып төште, «свежие» белән кайттык.

Яшеллек шәһәренә — Сочига булган экскурсия, теплоходта Кара диңгездә йөзү дә кызыклы булды, ә «33 шарлавык»ны карарга барганда күргән тюльпан агачы үзе бер могҗиза. Биеклеге — 30, киңлеге 10 метр икән аның. Ә үзендә безгә таныш тюльпан чәчәкләре...

Хәтәр юллары аша үтеп, тау-ташлар арасындагы тигезлектәге чәй плантацияләрен дә күрдек. Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булган хуҗалык җитәкчесе салдырган «Чәй йорты»нда бу эчемлекнең дистәдән артык төрен тәмләп-татып карадык.

Фестивальнең аккорды, ягъни йомгаклау өлеше дә «Дагомыс» комплексының концерт-театр залында булды. Анда Бөтенроссия конкурсында җиңүче матбугат чараларына бүләкләр тапшырылды. Алты көнгә сузылган фестиваль Россия Журналистлар берлеге рәисе Всеволод Богданов исеменнән оештырылган кабул итү белән төгәлләнде.

Икенче көнне поездыбыз кичкә таба гына китәсе иде. Шуңа күрә тагын 5–6 сәгать суда коендык, кояшта кызындык, диңгез шавын тыңладык. «Көннәре дә бит аның, безнең бәхеттән, комга тыксаң, йомырка пешәрлек эссе булды», — дип, күптән язарга уйлап йөргән сәяхәтнамәмне төгәлләдем дә күземне тәрәзәмә салдым. Җепшек буран туктаган икән.

Тыныч кына язгы таң атып килә. Яз... Табигатьнең татлы йокыдан уянып, дөньяга аваз салган чагы ул.

Җир йөзенә яз, аннары җәй килә. Хәерле, куанычлы җәйләр булсын берүк. Яшәү матур, яшәү ямьле. Моны фәкать күрә генә белергә кирәк...

*2005*

# Тарихи төбәк

Исеме һәм даны еракларга таралган Шөгер якларында булган юк иде. Әмма бу төбәк турында күп ишеткәнем һәм укыганым бар. Төркиягә баргач, Истанбул шәһәрендә бер милләттәшебез белән сөйләшеп утырырга туры килде.

— Төп чыгышыбыз белән без Шөгер якларыннан, — дип сүзен башлады төрекләшеп бара торган якташыбыз. — Төгәлрәге, Иштирәк авылыннан. Хәзер аның янында курорт бар дип беләм. Безнең бабайлар унтугызынчы гасыр ахырларында ук күчеп килгәннәр бирегә. Солтан хөкүмәте Россия мөһаҗирләренә (качакларына) җир дә бүлеп биргән. Хәзерге Лениногорск районына кергән Иштирәк, Куаклы, Шөгер, Әби (Сарабиккол) кешеләре бер авыл булып яшәгәннәр.

Шөгер якларына сәфәр чыгар алдыннан, мин Лениногорск районының тарихы белән кызыксындым, атаклы шәхесләрен күңелдән барладым. Бу төбәк газиз Ватаныбызга унбер Советлар Союзы Герое, ун Социалистик Хезмәт Герое биргән. Шушы районнан җиде язучы, байтак кына журналистлар чыккан. Камил һәм Фазыл Фасиевлар, Индус һәм Энгель Таһировлар, Рамил һәм Рафаил Вәлиевләр, Сәгадәт Ибраһимов, Гали Даутов, Әнвәр Шәрипов, Наил Рәхимов кебек галимнәр һәм җәмәгать-дәүләт эшлеклеләре дә Лениногорск районыннан икән!

Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллинның Сугышлыдан икәнен белә идем. Танылган журналист һәм язучы, Саба ягы кияве Җәүдәт Дәрзаманов бер очрашканда туган авылы турында тәфсилләп сөйләгән иде. Шулай итеп, Сугышлыны да күрергә насыйп булды.

Керкәле авылын үткәндә, күңелдә таныш җыр тибрәлде:

Керкәле авылы кайда —
Биек тау итәгендә.
Тауларын да сагынып кайтам,
Читләргә китәмен дә.

Тимәш авылы. Биредә күп еллар буе күренекле галим, шагыйрь һәм фикер иясе Утыз Имәни яшәгән һәм иҗат иткән. Тимәшлеләр юкка гына зиратларында аның төрбәсен өр-яңадан торгызып куймаганнар. Аның белән бик горурланалар алар. Бу авыл үзенең халык кушкан «Ромашкино» дигән даны белән бөтен дөньяга билгеле. Биредә 3 нче номерлы скважина бораулануга 50 ел тулды. Ул республика күләмендә бик зурлап билгеләп үтелде. Ромашкино дип әйтүгә, күпләр Җир шарындагы уникаль нефть ятмасын күз алдына китерә. Кыскасы, Тимәш — нефть чыгару буенча республикабызны элеккеге СССРда беренчелеккә чыгарган һәм әлеге дәрәҗәле урынны 1974 елга кадәр үз кулында нык тоткан тө-

бәк.

Гомумән алганда, «кара алтын»ның тарихы еракларга барып тоташа икән. Тәүге тапкыр бер яр кырыеннан бәреп чыга ул. «Тау балавызы чишмәсе» турында 1769 елда ук академик И.Лепехин «Ведомости» газетасында язып чыга. Кешеләр җир асты байлыгы белән кызыксынып торганнар. Бөгелмә алпавыты Н.Маланиенконың Шөгер кырыенда кое казытып, 80 чиләк кара май алдыруы да мәгълүм. Бу хәзинәгә күз ялтыратучылар чит илдә дә була. Шуның Шандор дигәне 1870 елда ук Шөгер һәм Сарабиккол тирәсендә ике скважина бораулата башлаган. Әмма ташкүмер катламына туры килеп, ташлап китә. Кыскасы, бу төбәкләрдә нефть чыгару совет власте елларында киң колач ала, һәм Татарстан «Икенче Баку»га әйләнә. Шөгерне юкка гына Татарстан нефтьчеләренең визит карточкасы дип атамыйлар. Монда тагын 1881 елда ук ачылган битум заводы бар. Ерак булуга карамастан, асфальт салу өчен кирәк булган бу чималга безнең Саба районы шоферлары да еш килә. Менә нефть чыккан яклар, аларның каһарманнары турында уйлана-уйлана, «Бәкер» курортына да килеп җиттек. Аның тарихы белән кабул итү бинасында ук таныша аласың. Кечкенә генә музей кебегрәк эшләнгән ул. Буыннан буынга күчеп килгән сөйләүләргә караганда, бу авылны Иске Иштирәктән күчеп утырган Бәкер карт нигезли, исеме шуның белән бәйле. Ул озак еллар бәләкәй генә авыл булып яши. Әмма аның күкертле чишмәләре, аларның сулары җыелган болындагы ләмнең шифалы икәне тирә-як халыкка, җирле түрәләргә элек тә билгеле була. Бу хакта бер риваять тә бар. Имеш, бай хуҗаның аксак аты югала. Әмма бер дә эзләтми ул аны. Чөнки аксак атның кирәге шуның кадәр генә була. Бер атна үткәч, атны Бәкер сазлыгыннан тартып чыгаралар һәм аның аяклары аксамаганын күреп хәйран калалар.

«Бәкер» курорты рәсми рәвештә 1933 елда ачыла. Аңа нигез салучы Иске Куак участок хастаханәсе баш табибы, республикабызда санаторий-курорт эшен оештырып җибәрүчеләрнең берсе — Максим Игнатьев була. Ул махсус мичкәләрдә Бәкердән ләм кайтарта һәм шуның ярдәмендә авыруларны дәвалый башлый. Нәтиҗә әйбәт була. Шуннан әлеге табиб Татарстанның сәламәтлек саклау халык комиссариатына хат яза. Махсус белгечләр килеп, Бәкер ләменең шифалы икәнен раслыйлар. 1932 елның җәендә М.Игнатьев 8 кешене рәсми төстә дәвалап карый һәм уңышка ирешә. «Бәкер» шифаханәсендә сугыш вакытында яралыларны дәвалыйлар. 1960 елда ул РСФСР масштабындагы шифаханәгә әйләнә. «Шанхай» дип аталган йортлар урынына заманча биналар, клуб, ашханә, төрле павильоннар, аэросолярий, ләм белән дәвалау өчен махсус корпус салына. 1967 елдан ук авыруларны ел тәүлеге кабул итә башлый.

Соңгы елларда «Бәкер» курортының данын күтәрү өчен күп көч куела. Шулай эшләмичә мөмкин дә түгел. Әгәр ял итүченең санаторийдан бер кәефен төшереп кайтарсалар, икенче мәртәбә ул бу тарафка борылып та карамый. Монда киресенчә, бер үк кешеләр кат-кат килә. Биредәге алтын куллы, тәмле телле хезмәт күрсәтүчеләр, аларның җитәкчесе — баш табиб Фаяз Ибраһимов. Ул үзе Арча районының Ташкичү авылыннан икән. Казан дәүләт медицина институтын тәмамлагач, 1974 елда Шөгер участок хастаханәсенә җибәрелә. Биредә 20 елга якын баш табиб вазифасын башкара ул. Хастаханә өчен күп төзелешләр алып бара, борынгы авылны мәчетле итә, кадрлар әзерли. Зур оештыру сәләтен искә алып, аңа «Бәкер» курортын җитәкләүне ышанып тапшыралар.

— Фаяз Ибраһимович, санаторий белән курортның аермасы нәрсәдә? — дигән сорауны бирдем аның белән очрашкач.

— Курортның барлык дәвалау мөмкинлекләре — ләме, су чыганаклары үзендә була аның, — дип сүз башлады ул. — Безнең курортны юкка гына Татарстан санаторийларының «энҗе»се дип атамыйлар. Төп дәвалау чарасы — ләмнең шифасы — бәяләп бетергесез. Ул полиартрит, артроз, радикулит, остеохондроз авыруларыннан, гинекология белән бәйле чирләрдән арынырга ярдәм итә. Халык телендә «утлы су» дип йөртелә торган «Мацеста» шифалы суыннан югарыда аталган авырулардан тыш псориаз, экзема, нейродерматит, ихтиоз кебек тире бозылуларына, ашказаны, эчәкләр борчуларына файдасын күрәләр. Элек мөмкинлекләре булган кешеләр «Мацеста» белән дәвалану өчен Сочига йөргәннәр. Аның Татарстанның үзендә булуы чыгымнарны күпкә киметә. Белгечләрнең әйтүенә караганда, составы да Сочиныкыннан бер дә ким түгел.

Әйе, үзгәрешләр гел уңай якка китә Фаяз Ибраһимов эшли башлагач, тиз арада ике катлы административ бина сафка баса. Бирегә кабул итү бүлмәсе, теш кабинеты, китапханә дә урнаша. Аннан яңадан 100 урынлы заманча итеп төзелеп, тору корпусы файдалануга бирелә.

Дәвалау бинасындагы урология һәм гинекология бүлмәләрен киңәйтү өчен янкорма эшләнә.

Бөер, ашказаны һәм эчәк авырулары өчен «Нефтуси» дип аталган минераль су табылу да куанычлы вакыйга була. Дәвалау корпусы дигәннән, биредә ләмдә ятып яки ваннадан чыкканнан соң тирләгәненне бетереп хәл алу өчен ирләр һәм хатын-кызларга ял бүлмәләре булдырылган. Анда сине үлән чәйләре белән Резеда Зыятдинова көтеп тора. Гомумән, «Бәкер»дә тәнгә сихәт бирүче, киң күңелле белгечләр эшли. Алар барысы да диярлек саф татар телендә, җайлап кына сөйләшә. Табиблардан Эльза Шәймәрданова, Наилә Галиева; төрле кабинетлардагы белгечләр Оркыя Сөләйманова, Илсөяр Гаделшина, Нәкыйбә Сәлахиева; массаж ясаучылар Зөлфия Шакирова, Сәүдә Минхәерова, Гөлшат Вәлиәхмәтова; лаборант Фирдәвес Фәйзуллина; «Мацеста» ваннасы белән рәхәтләндерүчеләр Сөембикә Мөхәммәдиева,

Венера Әхмәтҗанова, Мәлифә Гәрәева һәм башкаларга йөзләгән ял итүчеләр рәхмәт сүзләрен кат-кат әйтеп киткәннәр.

«Бәкер»гә күпләр ләмнең файдасына зур өметләр баглап килә. Бу — курортның иң авыр, шул ук вакытта төп сихәтләндерү үзәге. Биредә сезне ачык чырайлы, мөлаем йөзле Дилә Әюпова каршы алыр. Сабыр гына итеп, тәфсилләп аңлатыр. Аннан Хаҗи Гыйләҗев, Резеда Дәүләтова, Зөлфирә Вилданова, Нурвахит Һадиуллин карамагына күчәсең. Алар ләм белән төргәч тә, хәлеңне сорашып, хәтта битеңдәге тир тамчыларына кадәр сөртеп торалар.

Ашау-эчү ягына килгәндә дә тел-теш тидерерлек түгел.

— Яшелчә, җиләк-җимешне Самара каласыннан ташыйбыз, — ди баш табиб Фаяз Ибраһимович. — Анда очсызрак. Юлы да Казанга караганда якын. Иртән китәләр, кич кайталар. Дүрт йөзгә якын кешене биш тапкыр ашатырга кирәк бит.

Әйе, ашаган белми, тураган белә, диләр. Витамин сәгатендә кабыгы белән тәгәрәтеп пешергән бәрәңге бирүне уңай тапканнар. Йөрәккә файдалы икән. Сөт сәгате дә исәпкә алынган, чәй эчәргә бал, сирәк-мирәк балык уылдыгы да биргәч, ризыкны ничек мактамыйсың. Аш-су остасы Миңнур Хамматова җитәкчелегендә бердәм коллектив эшли ашханәдә. Резеда Гыйләҗиева, Рәмзия Гыйльманова, Гөлсия Йосыпова кебек уңганнар ризыкны алдан биргән заказ буенча, кайнар килеш өстәлләргә ташып торалар.

— Мин башка санаторийларның файдасын тапмадым, — ди Аксубай районыннан килгән бот төбеннән үк ике аягы да киселгән сугыш ветераны Закирҗан ага Шәмсетдинов. — Шушыннан сихәтләнеп кайтам, гомерем булса, тагын киләм әле.

Әйе, зур шәһәрләрдән, районнардан, авыллардан төрле-төрле хезмәт кешеләре ял итә биредә. Хакимият башлыкларын, республика күләмендәге җитәкчеләрне дә, ветераннарны да, ел буе эшләгәннән соң хәл алырга килүчеләрне дә очратасың монда. Чөнки табигате чиста, суы шифалы, ләме сихәтле аның. Соңгысын юкка гына тән бәлзәме дип атамыйлар.

*1998*

# Талантларга бай як

Яңавылда Саба районы мәдәният һәм сәнгать көннәре узганнан соң, районыбыз һәм республикабыз газеталарында «Туганлашып кайттык» дип исемләнгән күләмле язма урнаштырылган иде. Яңавылда алган тәэсирләр анда катнашучыларыбыз күңелендә бүгенгедәй сакланадыр, әлеге сәхифәгә күз салгач, ул хисләр тагын бер яңарып алыр.

Яңавыл. Аның җире таулы-ташлы, урман-сулы икән. Иң зур елгалары Бүә дип атала. Русча Буй дип язалар. Бүә һәм башка елга үзәннәрендә — болыннар, уңдырышлы иген басулары. Табигатьнең искиткеч матур булуын бер күз төшерүгә тоемларга була.

Танылган язучы, тарихи романнар остасы Нурихан Фәттахның аңлатуына караганда, Яңавыл яклары кайчандыр Болгар, Болгардан соң Казан җирләре булган. 1755 елда рус колонизаторларына каршы баш күтәргән Батыршаның рус патшасына язган хатында Яңавыл яклары да чагылып китә. Яңавылга якын төбәкләр — Гәйнә иле, Илеш телгә алына.

Яңавыл халкының күпмедер өлеше Казан ягыннан күченгән. Безнең төбәкләрдән китеп яшәүчеләр бик күп. Шуңа күрә сабалылар белән очрашуга нәселләре Арча, Балтач, Кукмара, Мамадыш һәм башка бик күп районнардан булган кан кардәшләр җыйналган иде. Мәсәлән, чыгышы белән Кукмара районының Зур Сәрдек авылыннан булган Сания ханым Вәлиуллина үзенең хисләрен артык яшерә алмады, елап та җибәрде.

Очрашулар һәркайда әнә шундый туганлык шартларында барды.

Яңавыл төбәге безне бигрәк тә эшчән һәм талантлы халкы белән истә калдырды. Монда ике Советлар Союзы Герое — Мәгъсүм Имаметдинов белән Гайнан Хәйдәршин, Социалистик Хезмәт Геройлары Флера Әминова, Әлфизә Гыйниятуллина, Зикаф Даутов туып үскән, Самарада яшәүче Социалистик Хезмәт Герое Шамил Мөхәммәтдинов белән Мурманскидагы «Арктика» атом бозваткычы капитаны Фидүс Әсхәдуллин да Яңавыл кешеләре.

Яңавыллылар дүрт доктор биргән Ганиевлар гаиләсе белән аеруча горурланалар.

Өлкән Ганиев — Әхәт — Чиләбедә яши. Ленин премиясе лауреаты. Бу бүләкне алу бик җиңел түгел иде бит. Наил Казанда, профессор. Аларның сеңелләре Мөзәйнә, энеләре Вил шулай ук фән докторлары.

Тагын бер гаиләгә тукталыйк. Алар — дүрт бертуган Харисовлар. Харисовларның яраткан эше — халык мәгарифе. Татарстанда Яңавыл көннәрен оештыручыларның да берсе өлкән Фираз. Казан дәүләт педагогия институты проректоры булып эшли. Икенче Харисов — Фарис. Ул алдагы елларда безнең районның Үзәк урта мәктәбе директоры иде, хәзер Казанда. Гимназия директоры. Фәнит тә Казандагы 15 нче гимназияне җитәкли. Төпчекләре Фәрит Яңавылда мәктәп директоры урынбасары икән.

Ә инде әдәбият-сәнгать өлкәсендәге талантлар турында сүз башласак, иң элек Нурихан ага Фәттах-

ка тукталыйк. Ул — дөнья күләмендә танылган язучы. Аны Бөекбританиядә Кембридж университеты «1992 ел кешесе» дип атавы шуны раслый.

Танылган язучы һәм драматург Риза Ишморат та күпләребезгә таныш. Казан телевидениесе бер тапшыруында Риза ага Салих Сәйдәшев һәм Кәрим Тинчурин турында пьеса эшләве хакында әйтте.

Филология, журналистика өлкәсендәге эшчәнлеге белән танылган мәрхүм доктор Әнвәр Ахунҗанов та Яңавыл якларыннан иде.

Нил һәм Илдар Юзеевлар. Бу бертуганнар — Татар-стан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары. Мондый мисалны башка китереп булмый. Чөнки шундый олы бүләккә лаек булган абый белән эне бүтән юк. Нил Гафурович — Татарстан Фәннәр академиясе әгъза корреспонденты, филология фәннәре докторы. Илдар Юзеев — татар халкының танылган әдибе, моңлы шагыйрь, үзенчәлекле драматург. Аңа Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык шагыйре дигән мактаулы исемнәр дә бирелде.

Рәссам Эрот Зарипов иҗаты турында да бик иркенләп тасвирларга мөмкин.

Әдәбият сөючеләргә Сәет Кальметов, Саҗидә Сөләйманова, Әдип Маликов исемнәре дә бик таныш. Шагыйрьләр турында сүз барганда, тагын ике шәхесне телгә алмый мөмкин түгел. Алар — Кәүсәрия Шәфыйкова һәм Рәфис Мөхәммәтдинов. Кәүсәрия дә, Рәфис тә йөри алмыйлар. Әмма иҗат итүдән туктамыйлар. Рәфиснең язмышы болайрак: тәпи басып йөри генә башлый сабый, беркөнне ул эссе плитәгә барып тотына һәм куркудан бөтенләйгә хәрәкәтсез кала. Табиблар да: «Күп тормас, үләр», — диләр.

Әмма авырлыклар бераз җиңелә. Рәфиснең кулларында каләм тотарлык көч бар... Менә шундый гыйбрәтле талантлары да бар Яңавылның.

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк: ике районда да күренекле шәхесләр күп. Казан шәһәрендәге очрашулар вакытында алар кул кысыштылар һәм туганлаштылар. Яңавыллылар белән Сабага якташларыбыз — Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге премия лауреатлары — академик Әбрар Кәримуллин (тумышы белән Чәбия-Чүрчидән), танылган музыка белгече, профессор Мәхмүт Нигъмәтҗанов (Олы Арташ), шулай ук Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире, әдәбият белгече, профессор Азат Әхмәдуллин (Саба) кайткан иде. Алар кунакларны Саба җирендә зур горурлык белән кабул иттеләр, эшлекле әңгәмәләр кордылар, иҗат планнары белән уртаклаштылар. Соңыннан үзләре туган төбәкләрдә булып, авылдашларының яшәеше белән кызыксындылар.

## ЙӨРӘКЛӘРНЕ ӘСИР ИТТЕЛӘР

Бу көннәрдә Татарстан радио-телевидениесе, республикабыз һәм районыбыз матбугаты Башкортстанның Яңавыл районы мәдәният һәм сәнгать көннәре турында күләмле тапшырулар бирделәр, матур-матур репортажлар урнаштырдылар.

...Җомга — бөтен мөселман халкы өчен бәйрәм көн, изге көн. Башкортстанның Яңавыл районында яшәүче кан кардәшләребезнең җавап визиты белән Сабага килүләре шушы көнгә туры килде. Табигать тә мәрхәмәтлек күрсәтте: иртәнге якта утырып яңгыр яуды, көннең икенче яртысында ялт итеп кояш чыкты. Җир өстеннән җылы пар күтәрелгән вакытта, 20 гә якын төрле маркадагы җиңел машиналарны, «Икарус» автобусларын берләштергән автоколонна районыбыз чигенә якынлашты.

...Менә Саба җирендә мәдәният һәм сәнгать көннәре дәвам итүен белдергән чыгышлардан соң махсус ясалган сәхнәдә җыр-бию бүләк итешү башланды. Илдар Яхин белән Нәҗип Бәдертдиновның иҗади дуслыгы нәтиҗәсендә туган, халыкчан итеп әйтсәк, табадан яңа гына төшкән «Саба–Яңавыл» дигән җыр кабат-кабат яңгырады.

Автоколонна район үзәгенә юл тотты. Халык депутатларының район Советы бинасы каршына кунакларны каршы алырга бик күп сабалылар җыйналган иде. Планлаштырылмаган митингны Саба районы хакимияте башлыгы Фәрит Гыйльмиев ачып, болай диде:

— Кадерле кунаклар, без бу көннәрдә Яңавылдан алып кайткан тәэсирләр белән яшибез. Безнең делегацияне әйтеп бетерә алмаслык җылы итеп каршы алып, олы хөрмәт күрсәтеп озаткан өчен сезгә бик тә рәхмәтлебез. Менә бүген-иртәгә очрашулар Сабада дәвам итәчәк. Безнең алтындай байлыгыбыз бар: ул — тырыш, эшчән һәм ягымлы халкыбыз. Менә бүген, дөресен әйткәндә, рәсми төстә игълан итмичә дә, сезне якын итеп каршы алырга күпме халык җыйналган.

Җавап сүзе белән Яңавыл районы хакимияте башлыгы, Башкортстан Республикасының халык депутаты Нәзир Зиязов чыкты:

— Хөрмәтле дуслар! Татарстан белән инде күптәннән дус яшәп, ныклы хуҗалык элемтәләрендә торсак та, бүген тугандаш республика белән бәйләнешләрне тирәнәйтүгә барабыз һәм Яңавыл, Саба районнарының җитди инициатива күрсәтүләренә бик куанабыз.

Июньнең беренче ункөнлеге ахырында бездә беренче тапкыр сезнең районның мәдәният һәм сәнгать көннәре үтте. Якташларыгыз ачык, юмарт күңелле булулары, безнең белән дуслашырга чын-чыннан теләк белдерүләре белән яңавыллыларны әсир иттеләр. Кунаклар урыннарда булганда, социаль өл-

кәдәге һәм мәдәнияттәге уңышлар белән кызыксынып таныштылар, кешеләр белән уртак тел таптылар. Районнарыбыз чын мәгънәсендә туганлашты. Безне болай эчкерсезлек белән каршы алганыгыз өчен чын күңелдән рәхмәт, дуслар, милләттәшләр!

Мәйданда зур булмаган түгәрәк барлыкка килде. Җыр, бию, уен-көлке дәвам итте. Ә инде төшке аштан соң хуҗалык һәм промышленность предприятиеләре җитәкчеләре Киров исемендәге колхозга юл тоттылар. Кунаклар арасында 41 ел колхоз рәисе булып эшләүче Мәсгут Кашапов, май-сыр комбинаты директоры Фәрит Минһаҗев, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Әлим Салихов, элеватор директоры Әнис Гыйльмуллин кебек җитәкчеләр булуы очрашуларны эшлекле иттеләр. Аларны хуҗалыкның машина-трактор паркында ипи-тоз, музыкалы сәлам белән үзешчәннәр һәм колхоз, авыл советы җитәкчеләре каршы алды. Хуҗалык рәисе Минислам Зарипов кыскача гына хуҗалыкның икътисади хәле белән таныштырды.

Кичен район мәдәният йортында Яңавыл районында туган талантларның әсәрләреннән күргәзмә оештырылган иде. Сәгать кичке җиде. Сәхнәгә кул чабулар астында ике район вәкилләреннән торган делегацияләр күтәрелә. Район хакимияте башлыгы Ф.Г.Гыйльмиев Яңавыл районы турындагы уңай фикерләрен тамашачыларга җиткергәннән соң, мондый багланышларны ныгытырга мөмкинлек биргән өчен Татар-стан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиевкә, Югары Совет Рәисе Ф.Х.Мөхәммәтшинга, Премьер-министр М.Г.Сабировка рәхмәт әйтте. Ике арада башланган дуслыкның һәр өлкәдә дәвам итәчәгенә ышандырды.

Аннары Яңавыл районы хакимияте башлыгы Н.З.Зиязов һәркайда югары хөрмәт күрсәтелүенә олы канәгатьләнү белдерде.

— Без сабалылар белән чын-чынлап туганлаштык, — диде ул. — Безнең районда унҗиде милләт вәкилләре бердәм, дус гаилә булып яши, аларның күпчелеге — татарлар. Руслар, башкортлар, удмуртлар, марилар бертугандай гомер кичерәләр. Район халкы арасындагы милли бердәмлек социаль һәм икътисади мәсьәләләрне уңай хәл итәргә мөмкинлек бирә. Ә инде Казанда һәм сездә күрсәтелгән ихтирамны сөйләп кенә аңлата торган түгел. Алга таба да сәяси, икътисади һәм мәдәни багланышлар дәвам итәр дип ышандырам. Кыскасы, Яңавылда дүрт сәгать дәвамында куйган концертыгыз, бигрәк тә «Сабада сабантуй» дип исемләнгән тематик күренешегез бүген дә күңелләребездә саклана. Ә хәзер сәхнәне безнең район үзешчәннәренә бирик!

Сәхнәгә бер-бер артлы талантлар күтәрелә. Аларның иҗат җимешләренә хөрмәт йөзеннән чәчәк букетлары агыла. Шагыйрьләр Фәрит Суфияров, Сафуан Әлибаев; җырчылар Маргарита Зарипова, Морат Вәлиев, Фәнәвил Салихов, Халисә Насыйбуллина, Наил Шәймәрданов, ирле-хатынлы Алинә һәм Җәүдәт Хәкимовлар сәхнәгә кат-кат чакырылдылар. Төрле милләтләрнең җыр һәм бию ансамбльләре чыгышы, Хәмит ага Шәймиевнең үзе ясаган гармунда уйнавы, РСФСРның һәм Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәрләре Җамал Исхаковның нәфис сүз сөйләве, Зәйнуллиннарның гаилә ансамбле, яңавыллылар әйтмешли, йөрәкләрне әсир итте.

Шимбә көнне аерылышу минутлары килеп җитте. Иң элек саубуллашу район үзәгендә булды, җырбиюле «күчтәнәчләр» алмашу дәвам итте. Район хакимияте башлыгы Фәрит Гыйльмиев яңавыллыларга очрашу ядкаре итеп мәдәният һәм сәнгать көннәрен эченә алган фотоальбом тапшырды. Аннары район чигендә — «Юлларыгыз уң, Саба җиле юлдаш булсын!» дигән зур панно янында хушлашуның соңгы аккорды булды.

*1993*

# Биш очрашу

Истәлек язу ансат түгел, әлбәттә. Бигрәк тә Хәсән Туфан турында — шигъриятебезнең мәңге сүнмәс йолдызы, аксакалы, алтын баганасы турында — олы шәхес турында. Чөнки бик күп галимнәрнең, әдәбият-сәнгать осталарының аны искә алган язмалары әледән-әле басылып тора һәм алар бу көннәрдә тагын дәвам итәчәк. Чөнки әдипнең 100 еллыгы, бер гасырлык юбилее якынлаша. Әлеге юлларның авторы татар халкының беркайчан да онытылмас шагыйренең олы иҗатына, аның сөйләп бетерә алмаслык фаҗигале тормыш юлына тукталуны максат итеп куймый. Бары тик Хәсән абый белән биш тапкыр очрашу истәлекләрен генә укучыларга җиткерергә тели.

**Беренчесе.** 1960 еллар ахырында Бауман урамындагы Матбугат йортына керергә туры килде. Ул вакытта Татар-стан Язучылар берлеге идарәсе шундагы икенче катка урнашкан иде. Менә ничектер, баскыч ташлары ашалмасын дигән шикелле йомшак кына, сак итеп басып берәү менә. Озынча какча йөзле, ак чәчле бу кеше бик таныш иде. Чөнки аның рәсемен әдәбият китапларында күп күргәнем булды. Хәсән Туфан бит бу дигән уй күңелемнән йөгереп үтте. Туктап, артыннан карап калдым...

**Икенчесе**. 1973 елда, Совет Армиясеннән кайтканнан соң, Казан дәүләт университетында читтән торып укый башладым. Сессияләргә барам. Әдәбият курсыннан Ибраһим Нуруллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Зәет Мәҗитов, Марсель Бакиров, Шәйхелислам Садретдинов, Флера Ганиева кебек фән докторлары

һәм кандидатлары лекцияләр укый. Мөхәммәт Мәһдиевнең бер лекциясен тыңлау үзе ни тора! Аның «Татар поэзиясендә Туфан — беренче багана» дигән сүзләре бүген дә истә. Шулай итеп, без олы шагыйребезнең иҗаты белән тирәнрәк таныша башладык, һәр шигыренең язылу тарихын ишетеп, бөтен аудитория тынып кала иде. Поэзияне аңлый белергә кирәк икән шул. Бер генә мисал. Якташыбыз Нәфисә Василова башкаруындагы Хәсән Туфан сүзләренә язылган «Киек казлар» җырын гына алыйк. Билгеле булганча, Туфан нахак яла белән 10 ел Сталин төрмәләрендә утыра, 6 ел сөргендә була. «Киек казлар»ны ул әйләнеп кайткач яза:

Киек казлар кыйгылдаша,
Җырлашалар микәнни?
— Туган илләр кала бит, — дип
Елашалар микәнни?
Безнең дә бит шулар сыман
Киткән еллар бар иде;
— Кыйгак-кыйгак, илем ерак, —
дигән чорлар бар иде…

Тагын бер мисал. Хәсән Туфанның хатыны — Луиза Салиәсгарова шул чорның танылган артисткасы була. Туфанны кулга алганда дүрт яшьлек кызчыгы Гөлгенә һәм дүрт айлык улы Идегәй кала (Идегәй 1942 ел башында ук авырып үлә). Луиза иң элек Кремль астындагы төрмәгә ризык ташый. Аннары, ерак сөргендә яшәгән ирен ачлыктан саклап калу өчен, посылкалар җибәреп тора. «Халык дошманы» хатыны буларак, эштән куыла, фатирыннан чыгарыла, юньлерәк әйберләре сатылып беткәч, донор була, канын биреп ирен ачлыктан йолып калырга карар итә. Әмма Хәсән ага кайтканчы, үзе дөнья куя. Соңыннан шагыйребез яза:

...Тәрәзәңә «җилләр» бәрелгәннәр,
«Сагынма!» дип янап киткәннәр...
Күнмәгәнсең... Эштән сөрелгәнсең...
Еллар сине донор иткәннәр...
Посылкалар белән ярдәм иттең:
— Без бит илдә... өйдә бит... — дидең.
Ә ул ярдәм
Каныңа алыштырган
Паекларың икән бит синең...
Алдарсың дип уйлый идеммени? —
Ә син мине алдагансың ич:
Өзелер хәлгә җиткән гомеремне син
Җаның белән ялгагансың ич!

Менә шулай итеп без Хәсән Туфан язган һәр шигырьнең мәгънәсен, язылу тарихын белеп укый башладык. Һәркайсыбызда аның үзен күрү теләге уянды. Икенче очрашуны курсташым, запастагы капитан, укырга кергәндә үк дүртенче дистәне ваклаган, офицер вакытта зур фаҗигаләр кичергән Газиз Кашапов оештырды. Алга узып шуны әйтергә кирәк: Газиз, университетны тәмамлаганнан соң, профессиональ язучы булды, шигырьләр, роман-повестьлар язды, күп китаплар чыгарды. Ул Хәсән Туфан турындагы «Киек Каз Юлы» романының беренче кисәген тәмамлап бастырды. Шагыйрьнең «йөргән» эзләре буйлап айлар буе материаллар туплады. Х.Туфан утырган колония-төрмәләрне күрде, «Дело»лары белән танышып, шуның берсенең «кесә»сеннән фотосын да алып кайтты, ул сөргендә булган Новосибирск өлкәсендәге авылларга барып җитеп, хәтта Туфан яшәгән землянка урынында төн кунды... Г.Кашапов та Аксубай районыннан, ул — Яңа Үзидән, Х.Туфан Иске Кармәттән иде. Әмма ни кызганыч, Газизнең 49 яшендә кисәк үлеме әлеге романның икенче — Х.Туфан турындагы төп өлешен язарга, дөресрәге, төгәлләргә ирек бирмәде. Барлык җыйналган материал Газиз Кашапов белән мәңгелеккә китте.

...1979 елның гыйнварында без Хәсән Туфанның Вишневский урамындагы фатирына киттек. Ишекне Мөнҗия апа (Х.Туфанның абыйсының кызы — ул шагыйрьне тәрбияләп тора иде, машинистка хезмәтләрен дә башкарган) ачып кертте һәм Хәсән абыйның эш бүлмәсенә озатты. Х.Туфан безне бик җылы каршы алды. Утырдык. Якташлар әңгәмәгә кереште. Ә мин игътибар белән бүлмәне күзәтә башладым. Кечкенә иде ул (чөнки фатиры да ике бүлмәле генә). Җиһаз да бик гади. Стена кырыенда Хәсән аганың рәссам Рәшит Имашев ясаган кечкенәрәк портреты тора.

Бер портретка, бер Хәсән абыйга карыйм. Аерма байтак иде, әлбәттә. Туфан кечерәеп калган, чәчләре дә гадирәк. Әмма башка кешеләрдән аерылып торган кышкы кыяфәте һәм йомшак мөлаем йөзе белән җәлеп итте ул. Кыскасы, ап-ак чәчле тарих сыман иде. Әкрен тавыш белән генә сөйли, «тегендә» дигән сүзләр дә куллана. Мөнҗия апа өрек җимеше белән ясаган чәй кертеп чыкты. Гомумән, бу бүлмәдә рухың баеп, күңелең тынычлануын тою рәхәт иде. Әңгәмә дәвам итте. Якташларның туган яклары, нәсел шәҗәрәләре турында да сүз байтак булды. Хәсән ага яшел-каралы ручка белән:

«*Кадерле энебез Тәлгат! Әдәбиятыбызның киләчәк дәвамында уңышларга гына ирешүегезне теләп*

*Х.Туфан,*

*28.V.79»,* — дип язып, үзенең китабын бүләк итте.

Аннары без рәхмәт әйтеп, тирән тәэсирләр белән киттек. Газиз Х.Туфанның күп елларда күргән коточкыч хәлләрен кич буе сөйләде...

**Өченчесе**. Монысы да шул ук елның маенда булды. Күптәнге танышлар кебек килеп кердек бу юлы. Хәсән аганың чәчләре тагын да агарган, беренче чиста кар кебек тоелды. Өстәлендә — чәчәкләр. Ул аларга гашыйк кеше. Аның чәчәкләр белән бәйле бик күп җырлары, шигырьләре күпләргә таныш. Ул аларны Аккош күлендәге дачасында тәфсилләп үстергән. Тикмәгә генә «Хәсән Туфан — татар поэзиясенең чәчәге» димиләр бит.

Менә ул елтырап торган тимер кысалы күзлеген киде, кулына яшел-каралы ручкасын (ул фәкать шул төс белән генә язган) тотты. Аннан баш бармак яссуындагы папирос кәгазе алды. Күзлек өстенә лупа куеп, «тегендә» үзе ясаган нindiдер билгеләргә — гарәп хәрефләре белән язган тамгаларга иелде һәм шигырь укый башлады. Соңыннан әкрен генә: «Эшкәртеп бетерә алмам, ахры, шифрын сиңа өйрәтеп калдырырмын әле, яме, Газизҗан», — диде.

Ул лагерьда вакытта папирос кәгазен аерып алып, каты карандашны кыл очы сыман очлап, шигырьләрен шунда теркәп барган. Аннары түгәрәкләп төргән дә сохари эченә тыккан, тишекләрне ике яктан да валчык ябыштырып, мич янында кыздырып киптергән. Тентүләр бик еш булган, әмма сохарига тимәгәннәр. Шулай да Туфан барлык шигырьләрен дә алып кайта алмаган. Бер лагерьдан икенчесенә кисәк кенә күчергәндә, аларның байтагы яшерелгән урыннарда калган...

**Дүртенчесе**. Монысы да университет белән бәйле. Газиз Кашапов «Хәсән Туфан шигырьләренең вариантлары» дигән диплом темасы алды. Миңа шунысы мәгълүм булды: нинди олы шагыйрь булса да, Х.Туфан кайбер шигырьләрен дүрт, биш, хәтта алты тапкыр эшкәрткән, күптөрле вариантлары булган, гел камилләштергән икән. Диплом эше теләп, аңлап, чын күңелдән язылган иде. Менә яклау көне җитте. Хәсән абый белән Мөнҗия апаны Газиз такси белән алып килде. Чөнки ул вакытта Туфан үзе генә өйдән чыкмый иде инде. Менә үтә ябык юка гәүдәсенә бик пөхтә костюм кигән, ак чәчләрен матур итеп тараган Хәсән ага күренде. Без аларны ихтирам йөзеннән аягүрә каршы алдык. Тагын шуңа игътибар иттек: ул костюмына бер медаль таккан иде. Туфанның 1956 елдан соң бирелгән орден-медальләре бар икәнен белә идек. Әмма ул аларны тагып йөрмәгән. Истәлекле урыннарга барганда, монысын — «Чирәм җирләрне үзләштергән өчен» дигәнен калдырмаган. Реабилитацияләгәндә, сөргендә вакытта далада көтү көткән еллары өчен бирелгән булган икән ул. Шагыйрьнең шул чорда нинди хәлдә яшәгәнен сиземләү өчен Зөфәр абыйсына язган хаттан кечкенә генә өзек китерү дә җитәдер:

*«Хәзергә мин — матди ярлы. Әкияттәге бәхет эзләүче егетләр кебек үк ярлы. Тезләр чалбардан дөньяга тәрәзә ача, белье исә иясе белән саубуллашып, үзенә алмаш сорый һәм: «Мин чолгауга ярармын әле», — дип, оекбашларны юата. Ботинка гына ачык авызы кадакланганнан бирле дәшми, дөньяга тел тидерми, болыннарда, кырларда (ферма сыерлары башлыгына, ягъни көтүчегә хас салмак адымнар белән) чәчәкләр арасында гизә бирә...»*

Әмма ул төшенкелеккә бирелми:

> Үткән гомер кире кайтмый, диләр.
> Кайгырма син, Хәсән, кайтмаса.
> Үткән гомер кире кайтмый икән,
> Үтмәгәне аның бар ласа, —

дип үзен юата.

...Диплом яклаучы, аннан оппонент сөйләде, башка чыгышлар да булды. Соңыннан Дәүләт комиссиясе рәисе Нил Юзиев (ул да мәрхүм инде):

— Хәсән ага Сездә сүз юкмы? — дип сорады.

Җавап кыска, тыйнак, йомшак булды.

— Юк, рәхмәт. Олы хезмәт куелган, — диде...

...Бу — Хәсән аганың 80 яшен тутырырга ярты ел вакыт калган көннәр иде. Аның юбилее бик олылап үткәрелде. Аннан соң озак тормады — 1981 елның 10 июнь иртәсендә вафат булды.

Хәсән Туфан сабалылар өчен дә бик якын. Ул бездә очрашуларда катнашкан. «Мишә дулкыннары» берләшмәсе утырышларында чыгыш ясаган. Болар турында редакция архивында фотосурәтләр саклана. Әле шушы көннәрдә генә аның 1960 елда Газиз ага Нәбиуллинга бүләк иткән китабын (1958 елда басылган) карап утырдым. Аңа яшел-кара белән болай дип язылган:

*«Кадерле Газиз! Бу Сезгә Сабада беренче очрашуларыбыз истәлеге булсын. Хөрмәт белән Х.Туфан. 2.Х.60».*

**Бишенче очрашу**. Еллар үтә тора. Озакламый Хәсән аганың Сабага килгәненә — 40, вафатына 20 ел була. Узган җәйләрнең берсендә без газетабызның фотохәбәрчесе Нурхан Дәүләтов белән мәшһүр шагыйрьнең туган ягына — Аксубай районының Иске Кармәт авылына сәфәр кылып, бу юлы инде бөек әдипне дөньяга тудырган җирләр белән очрашып-танышып кайтырга булдык.

— Хәсән абыйны хөрмәт итеп, күрше-тирә район мәктәпләреннән дә, үзебездән дә бик күп укучы-

лар-укытучылар килә. Казаннан әдәбият-сәнгать эшлеклеләре дә булалар, — дип каршы алды шушы тыйнак кына музейны оештыручы-энтузиаст Рушания ханым Миңнеханова. — Аларның нигезләре шушы урында булган. Ул музейны әдипнең 90 еллыгы уңае белән ачкан идек. Бинабыз кечкенә булса да, аның экспонатлары кадерле. Менә монысы — 1957 елда язылган «Тамчылар ни диләр» шигырендәге ридикюль. Ул куплетларны хәтерлисездер:

Сандыгыңда ята
Синнән калган
Белешмәләр салган ридикюль:
Миннән сиңа — гомер юлдашыма —
Иң беренче бүләк иде ул.
Ридикюльдә калган белешмәләр,
Алардагы кайбер билгеләр
Тормышыңның соңгы хәлләрен
Бүген миңа сөйләп бирделәр...

Хәсән абый кулга алынганчы ук, «бу ридикюльне сакларсың» дип әйтеп калдырган була. Безгә аны кызы Гөлгенә апа (ул да фаҗигале төстә үлде бит) бирде. Ридикюль эченнән бик кадерле документлар чыкты. Мәсәлән, Хәсән абый белән Луиза апаның никахлашу турындагы таныклыклары, сугыш вакытында балаларын ялгыз калдырып төнге дежурга чыкмаган өчен әдип хатынына салынган штраф квитанциясе, ире «халык дошманы» булган өчен башта эштән, аннан Чистайга сөрелү турында белешмәләр, Луиза апаның Хәсән абый кайтыр алдыннан вафаты турындагы язу...

Гомумән, биредәге һәр экспонатны күз карасыдай кадерләп саклыйлар. Әнә шкафы белән китаплары, Аккош күлендә утырып язган өстәле белән кәнәфие, документлары салынган шкатулкасы, эш күзлеге, өс киемнәреннән — яшел күлмәкләре, костюмы, бүреге, эшләпәсе, пальтосы. Үзе күп тапкырлар төзәткән стена сәгате дә туктап калган. Музейдагы бөтен әйбер дә кадерле, әлбәттә. Әмма ядкарьләрнең дә ядкаре — Хәсән абыйның әнисеннән калган сөлге — күпләрнең игътибарын җәлеп итә. Аны ул: «Үлгәч, Хизбулланың (әдипнең мулла кушкан исеме) битенә ябарсыз», — дип әйтеп калдырган була. Бу сөлге Мөнҗия апада сакланган иде. Икенче ядкарь — сукно күлмәк. Аның да үз тарихы бар. Хәсән Туфанга сөргеннән кайтырга рөхсәт булгач, ул, кибеткә барып, шушы сукноны сатып ала (өс киеме бик начар була) һәм, үзенең кул машинасында шул күлмәкне тегеп, Казанга кайтып төшә, — дип сүзен тәгәлләде Рушания ханым.

Монда тагын шунысын да искәртеп үтү урынлы булыр: Х.Туфанның 100 еллыгына яңа музее өлгерәчәк икән, моның өчен шагыйрьнең туган нигезендә, нәкъ искесе кебек үк итеп, агач өй салып куелган инде, авылга асфальт юл да кергән.

Әйе, Хәсән Туфанның авылындагы музеенда булып, аның фаҗигале тормышы, иҗат юлы турында тыңлагач, күңел дәрьялары яңадан актарылып, бик күпләргә таныш шигырь куплеты искә төшә:

Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте...
Кайсыгызның кулы җылы? —
Бәйлисе бар йөрәкне.

*2000*

# Ул — Тукай замандашы

Солтан Рахманколый — Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камаллар белән бер чорда иҗат иткән язучы. Ул 1908 елда, ягъни 20 яшендә Тукай белән дуслаша. Күренекле шагыйребез аларның фатирына килеп йөри, Солтанның мандолинада уйнавын, сеңлесе Мәрьямнең (РСФСРның һәм Татарстанның халык артисткасы Мәрьям Рахманкулова турында сүз бара) җырлавын тыңлый. Солтан үзе дә оста җырчы була.

Яшь язучы Солтан Рахманколый революцион хәрәкәтләрдә актив катнашканы өчен ышанычсыз дип табыла һәм Казандагы реальное училищеның 6 нчы сыйныфыннан куыла. Ул башка мәктәпләргә кереп укый алмый, аны «ышанычсыз» булганлыгы өчен кабул итмиләр. Әмма Солтан югалып калмый, бөтен тырышлыгын әдәби хезмәткә юнәлтә, 17 яшендә үк А.С.Пушкинның «Дубровский» әсәрен татарчага тәрҗемә итә. Ул 1907 елда аерым китап булып басылып чыга. 1908 елда исә Солтан И.С.Тургеневның «Төтен», 1909 елда Максим Горькийның «Дуслар», В.Гюгоның «93 нче ел» романыннан өзек, 1912 елда А.С.Пушкинның «Борис Годунов» әсәрен тәрҗемә итә, һәм алар бер-бер артлы аерым китаплар булып дөнья күрәләр.

1909 елда ул «Йолдыз» газетасы редакциясендә Г.Камал белән бергә эшли башлый. Бу газета шул чорда шактый ук популяр була. Әдип, Г.Кәрим белән берлектә, «Русча-татарча сүзлек» төзеп бастыра. Шулай ук «Татарча-русча лөгать» һәм «Русча-татарча кесә лөгате» нәшер иттерә.

1913 елның җәендә ул, сеңлесе Мәрьямне алып, Казанның Яңа бистәсендәге зиратка Тукай каберенә бара.

— Солтан абый Тукай кабере янына баса иде дә, бөтен зиратны шаулатып, көр тавыш белән җырлый иде, — дип сөйләгән замандашларына Мәрьям Рахманкулова.

Солтан 1888 елда хәзерге Саба районы Олы Шыңар авылында дөньяга килә. Әтисе Габделмәннан үз заманының алдынгы карашлы, ачык фикерле мәгърифәтчесе була. Ул Олы Шыңарда 14 ел буе балалар укыта. Әнисе Мәстүрә Арпаяз авылында (Кукмара районы) туып үскән. Солтан нибары 28 ел яши. Аның үлеме турында «Йолдыз» газетасы хәбәр бастырып чыгара.

Солтан Рахманколыйның хикәяләр китабы беренче тапкыр үзенең вафатыннан соң, 1917 елда басылып чыга. Шулай ук шактый күп әсәрләре «Идел буе әдәбияты» сериясендә чыккан 2 нче китапта дөнья күрәләр. Мөхәммәт Мәһдиев, шул китаптан алып, 1979 елда аның «Мәлихә куаклыгы» дигән хикәяләр җыентыгын әзерләп нәшер иттерә.

*1996*

# Күпне күргән, күпне кичергән

Шулай беркөнне эш бүлмәмә Татар Икшермәсе авылында яшәүче хәбәрчебез, ветеран-педагог, шигърият яратучы, үзе дә шигырьләр язучы Нурания ханым Шакирова килеп керде һәм минем өчен яңа хәбәр китерде. Аның әйтүенә караганда, бик күпне күргән һәм кичергән әтисенең 1930 елларда «Сугыш бәете» дигән китабы чыккан икән. Аны бастырыр алдыннан Икшермә якларына язучы һәм тәнкыйтьче Гомәр Толымбай килгән булырга тиеш. Бу китапны өлкәннәр үз куллары белән тотып караганнар, укыганнар... Кыскасы, әлеге бәет язмышы белән кызыксынып, аның берәр нөсхәсен табып бирүдә ярдәм сорады миннән хәбәрчебез.

Мин, үз чиратымда, Татарстан китап палатасына мөрәҗәгать иттем. Андагылар, эзләнә торгач, бу тарихи шигъри әсәрнең 1935 елда Гомәр Толымбай мөхәррирлегендә «Бәетләр» дигән җыентыкка кертелүен, аның фәкать Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсендә саклануы турында әйттеләр.

Менә кулымда моннан алтмыш сигез ел элек латин алфавитында дөнья күргән китап. Аңа кереш сүзне, дөрестән дә, Гомәр Толымбай язган. Китапка Шакир ага Закировның (тулы исем-фамилиясе Мөхәммәтшакир Әхмәтзакиров) «Сугыш бәете» урнаштырылган.

Кем соң ул Мөхәммәтшакир? Бәет нинди шартларда язылган? Ачыклык кертү өчен, хәзер кыскача шуларга тукталыйк.

1893 елда урта хәлле крестьяннар — Әхмәтзакир белән Сәгыйдәбану гаиләсендә көтеп алынган малай дөньяга килә. Аңа авыл мулласы Мөхәммәтшакир дип исем куша. Ул заман өчен бу гаилә укымышлылардан санала. Шуңа күрә Мөхәммәтшакир яшьтән үк Коръәнне яттан белә, математик гамәлләр башкара, исәп-хисапка өйрәнә. Берзаман Байлар Сабасыннан килгән Хуҗахмәт сәүдәгәр ундүрт яшьлек малайны үзе белән алып китеп кибеткә сатучы итеп куя. Бай гадел егетне тиз үз итә. Мөхәммәтшакир 1913 елга, ягъни егерме яшькә кадәр кибеттә сатучылык итә һәм шуннан патша хезмәтенә алына, бераздан Россия армиясе составында Франциягә җибәрелә.

...Тарихтан билгеле булганча, 1914 елның җәендә Беренче бөтендөнья сугышы башлана. Моның төп сәбәбе иң эре империалистик дәүләтләр һәм дәүләт группалары арасындагы каршылыклар көчәю була. Империалистик державалар арасындагы дошманлашу ике группировка китереп чыгара. Ягъни бер яктан — Германия, Австрия-Венгрия һәм Италия хәрби берлеге (союзы), икенче яктан — Россия, Франция һәм Англия составында өчлек килешүе (Антанта) барлыкка килә. Империалистик даирәләр басымы астында 1915 елның октябрь аенда Болгария дә Германия, Австрия-Венгрия ягында сугышка тартыла. Бу сугыш Балкан ярымутравы дәүләтләрен дә чолгап ала. Антанта гаскәрләре, шул исәптән Россия армиясе дә, Грециянең Салоники порты аша үтеп, Австрия-Венгриягә, Болгариягә каршы сугыш хәрәкәтләрен җәелдерәләр. Менә «Сугыш бәете»нең авторы Мөхәммәтшакир солдат, шушы яудагы авырлыкларны үз җилкәсендә күтәреп, Балкан ярымутравындагы хәрәкәтләрне һәм Россиядәге февраль буржуаз-демократик революция чорындагы армиядәге үзгәрешләрне шигъри куплетлар аша чагылдыра. Ул, әлбәттә, әти-әнисе өчен суга төшеп югалгандай була, өйдә аның рухына инде дога кыла башлыйлар. Бераздан нindидер бер газетның читенә «Мамадыш өязендәге Татар Икшермәсенең Әхмәтзакир улы Мөхәммәтшакир исән дип белегез» дип язылган хәбәр килеп төшә.

Шулай итеп, «Сугыш бәете» чит җирләрдә бик авыр шартларда иҗат ителә. «Бу җыентыкка урнаштырыла торган «Сугыш бәете», — дип яза Гомәр Толымбай үзенең кереш сүзендә, — хезмәт ияләре арасыннан чыккан солдатларның империалистик сугышка һәм царизмга ничек карауларын шактый гына күрсәтеп тора:

Балкан тавы башыннан
Орудие таптылар,
Йөзе кара Николайны
Казаматка яптылар.

Сараевтан хәбәр булды,
Афинага барырга,
Әфисәрләр разый булган
Позикада (позициядә. — *Т.Н.*) калырга.
Позикада утырганда,
Күп жалонье алалар,
Солдат атарга барганда,
Блиндажда калалар.
Балкан тавы өстендә
Болгарларның маллары,
Шушы малны алыр өчен
Коела солдат каннары...»

Әлеге җыентыктагы уналты бәетнең һәркайсына китап ахырында искәрмә бирелгән.

«Сугыш бәете» исеме астында басыла торган бу озын бәет империализм сугышы белән бәйләнгән. Аның башында сугыш бәетләренең күбесендә кабатлана торган «Без окоптан аткан чакта, дошманга тар булды» дигән шикелле батырлык белән мактану юллары булса да, нигездә, бу бәет, һичшиксез, империализм сугышына тирән дошманлык, Николай һәм аның офицерларына зур ачу белән язылган. Шуның белән бергә, ул патша офицерлары белән Франция империалистлары арасында бердәмлек булуын да, элекке һәрьяктан көчсез булган Россиянең солдатлары союзниклар кулында бөтенләй кол булып калып, шуның аркасында аларның тагын да ныграк изелүләрен дә чагылдыра.

Тикшерә торгач, без бу бәетне язучыны да таптык. Аны язучы Татарстанның Саба районы Татар Икшермәсе авылыннан Шакир ага Закиров икән (хәзерге көндә актив колхозчы). Ул шушы бәетне һәм аның нинди шартларда язылуына карата менә нәрсәләр яза:

«Безне Николай Франциягә ярдәмгә дип җибәрде. 1916 ел октябрь аенда Франциягә барып җиткәч, безгә ачыктан-ачык:

— Сез ярдәм өчен килмәдегез, ә бәлки без сезне сугыш кораллары биреп сатып алдык, — дип әйтә башладылар.

Без Франциягә барып бераз торганнан соң Германия белән килешү булгач, «без сугышмыйбыз» дип волнование (ризасызлык. — *Т.Н.*) ясый башласак та, үзебез белән бергә барган Николай командирлары ирексезләве аркасында 1918 елга кадәр сугыш алып бардык. Шул дәвердә Николайның калдык чиновниклары, шулай ук Франциянең вәхшиләрчә безне җәберләүләре хакында миңа язарга туры килде».

Димәк, әлеге искәрмәдән күренгәнчә, Г.Толымбай безнең якларга килмәгәнме? Автор белән хат кына алышканнар булып чыгамы? Бәет, бәлки, теге газета кисәге кебек, берәр кеше аша алданрак җибәрелгәндер. Барысын да хәзергә төгәл ачыклап бетереп булмады.

Әмма Гомәр Толымбай егерменче еллар ахырына таба Сабада еш була, хәтта яшәп тә ала түгелме икән. Ул авыл хәбәрчесе Йосыф Закировның үтерелүе турында мәкаләләр яза. Димәк, бәет авторының Г.Толымбай белән очрашуы бик тә мөмкин.

...Утыз яшькә якынлашып килүче Мөхәммәтшакир солдат, күп газаплар кичереп, туган нигезенә кайтып төшә. Бу елларда инде Россиядә революция дулкыннары узып, үзе хезмәт итеп киткән Хуҗахмәт байның мал-мөлкәтен конфискацияләнгән була.

Мөхәммәтшакир тормыш корып җибәрә. 1924 елда беренче балалары туа. Үзе кибетче, хуҗалык эшләре мөдире, кладовойчы, кыскасы, исәп-хисап белән бәйле эшләр башкара. Яшәү максаты — кеше хакына кермәү, бәндәләрне рәнҗетмәү, гаиләсен хәләл ризык белән туендыру була. Умарта тота. Еш кына сугышта күргән ачлыкны, хәерчелекне искә төшерә. «Кешеләр ялангач тәнгә чыпта киделәр, мин андый хәлне күрмәдем. Ялкау булмаска кирәк», — дип әйткәли торган була.

Бөек Ватан сугышы башлангач, карт солдат, дүрт баласын, колхоз амбарларының бер көлтә ачкычын карчыгына калдырып, тагын хезмәт армиясенә китә. Башта Казанда, аннан Мәскәүдәге зур төзелешләрдә эшләп, 1946 елның башында гына гаиләсе янына кайта, яңадан исәп-хисап эшендә була, бәетләр, такмаклар чыгаруын да дәвам итә, хатларны шигъри юллар белән яза. Зарлануны белми. «Әти, нихәлең бар?» — дип килеп керсәм: «Берүзенә ун бәбкә, эш күбәйде үрдәккә дигән шикеллерәк әле, кызым, хәлләр», — дип каршы алуын искә төшерә төпчеге Нурания ханым.

...Еллар шомлы булса да, Мөхәммәтшакир абзый гомеренең соңгы көннәренә кадәр намазын калдырмый, сакланып булса да яшь парларга никах укый, сабыйларга исем куша, өлкәннәрне фани дөньядан озата. Гомумән, кырку ак сакаллы, кечкенә генә гәүдәле, бик күпне күргән шигъри күңелле Мөхәммәтшакир солдат, бихисап изгелекләр кылып, 1986 елда вафат була. Мәрхүмгә «Авыр туфрагың җиңел булсын» дигән теләктә калыйк.

*1996*

# Танылган шәхесләр

*(Хастаханә дәфтәреннән)*

Без, каләм тибрәтүчеләр, кая барсак та — иген басуынамы, фермагамы, тарихи урыннаргамы, чит илгәме, санаторийгамы — язарга тема эзлибез. Кызыклы шәхесләр белән очрашырга тырышабыз.

...Казан шифаханәләренең берсендә дәваланырга туры килде. Анда да күпләр белән әңгәмә кордым. Әнә заманында Татарстан мәгариф министры булган, проблемалы укыту системасын җитәкләгән Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтов кәефсезләнеп йөри. Зур галим ул. Аның гыйльми дәрәҗәләрен генә дә санап бетерә торган түгел. Педагогия фәннәре докторы, профессор, Россия Фәннәр академиясе, мәгариф академиясе академигы, Татарстан Фәннәр академиясе хакыйкый әгъзасы. Әмма еллар үзен сиздерә, сигезенче дистәне ваклаган икән. Сулыгып киткән. Аны күргәч, Эзмә мәктәбенең элеккеге директоры мәрхүм Вәгыйз ага Мөбарәков сөйләгән бер хәл искә төште. Мәктәп директорларының республика киңәшмәсендә катнашып кайтканнан соң, ул: «Карале, министр кадәр министрны бастырып куйды бит Табеев», — дип шаккаткан иде.

Заманында Татарстан Верховный Советы Президиумы Рәисе булган Камил Фатыйх улы Фасеев та «ремонт»ка кергән. Аның язучы Шәйхи Маннур белән Сабага килүе турындагы истәлекләрен газетабызда бастырган идек. Сайланулы урыннан киткәч, ул Казан дәүләт университетының фәнни коммунизм кафедрасын җитәкләде. Философия фәннәре докторы, профессор булды. Бер аягы протез аның. Башка авырулар җиңел аяк киеме белән йөри. Камил әфәнде протезына туфли кидерткән, икенче аягына да шуның сыңарын эләктергән. Шуңа күрә ул атлаганда аерым бер тавыш чыга. Күз тимәсен, әле бик матур йөри.

Элегрәк Сабада авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы булып эшләгән, аннары озак еллар Кукмара районы партия оешмасын җитәкләгән Атлас Минхәер улы Булатов җитмешен тутырырга җыена икән. Аның белән сөйләшеп утыргач, тагын бер истәлекле вакыйга искә төште. Кукмара районы оештырылуга алтмыш биш ел тулуны билгеләп үттеләр. Шул районда туган яки эшләп киткән кешеләр байтак чакырылган иде. Финал якынлашканда, сәхнәгә исән-сау булган райком секретарьлары һәм райбашкарма рәисләре чакырылды. Менә сүз Атлас Минхәеровичка бирелде, залдагы халык аягүрә басып, озаклап кул чапты үзенә. Кукмара халкы аның районны күтәрүгә зур көч куйган шәхес икәнен аңлый белә икән дигән фикер күпләрнең күңеленә уелып калды.

Беляевлар. Бу фамилияне ишетүгә, газета укучыларыбыз күз алдына Кама автомобиль гиганты төзелгән елларда Чаллы шәһәр партия комитетын унбиш ел җитәкләгән Рәис Кыям улы килеп басадыр. Заманында ике Ленин ордены, Октябрь революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почет билгесе» орденнары белән бүләкләнгән шәхеснең йөрәге эш бүлмәсендә — Казан мәдәният һәм сәнгать академиясе ректоры кабинетында тибүдән туктады. Шифаханәгә аларның иң олы абыйлары Геннадий (мулла кушкан исеме — Гайнан) Кыям улы дәваланырга керде. Бик тыйнак карт икән. Күптән түгел җитмеш яшен билгеләп үткәннәр. Башта — укытучы, аннары мәктәп директоры булган, егерме елга якын Әлмәт район Советы башкарма комитеты рәисе итеп сайланган, лаеклы ялга чыккач, ун ел буе район пенсия фондын җитәкләгән. Аксубай районының Шәрбән (ул авылның борынгы исеме Шәһри Бану булып, аңа нигез салынуның 1100 еллыгы билгеләп үтелде) авылында яшәгән Беляевлар гаиләсе ишле балалы булган — Кыям абзыйга карчыгы уналты сабый бүләк иткән. Шуларның унбере үскән. Хәзер дә тугызы исән-сау. Бер сеңелләре вакытсыз вафат булган һәм Рәис Кыямович... Мәрхүмне рәнҗеткән елларны бик үкенечле итеп сөйләде Гайнан ага.

— Ярый әле үзем ул күңелсез вакыйгаларга кадәр пенсиягә китеп барган идем, — дип канәгатьләнү белдереп куйды әңгәмәдәшем. — Алтмышны тутырып, ягъни яшем җитеп китсәм дә, Рәис аркасында чыгардылар дип уйлаучылар булыр иде. Безнең нәселгә килгән хәсрәтләрне ярый әле картлар — әтиәни күрмәде. Картлар дигәннән, әтинең җитмеш яшенә кайткан көн бүгенгедәй истә. Күбебез машина белән идек. Ә Рәис Чаллыдан вертолет белән килеп төште. Бөтен авыл шау итте. Әти мәрхүм әле соңыннан, шаяртып, әнигә болай дип сөйләгән:

— Йөриләр инде шунда, бөтен авылга фаш итеп. Әле минем җитмештә икәнне белгән кеше юк иде. Кибет янына чыгарга оялам. Хәзер урамдагы карчыклар да карт кеше белән исәнләшкәндәй итәләр...

Истәлекләр... истәлекләр. Геннадий Кыямович илленче еллар уртасында Казандагы югары партия мәктәбендә безнең районнан Хөснулла Шәйдуллин дигән кеше белән бергә укыган икән. Әмма сабакташының авылын төгәл хәтерләми.

Мин аны соңыннан сорашып белештем. Пенсиядәге укытучы Хөснулла ага Төбәк авылында исәнсау яши.

## ТАНЫШЛАР БАЙТАК ИКӘН

Шәткедән Сабир Гафур улы Шәйхетдинов та биредә. Ул 1964 елдан бирле «Большевик» колхозында (хәзер Теләче районына керә) иген-икмәк үстерә. Татарстан Республикасының атказанган агрономы.

Алтмыш яшьлек юбилеен бик олылап билгеләп үттеләр. «Нива» машинасы бүләк иттеләр үзенә. Чын крестьян малае ул. Аларның нәсел башы Мәҗит, аның дәвамы Шәйхетдин, аның улы Гафур, Гафурның малае Сабир — бөтен бәгырьләре белән җиргә бирелгән затлар. Алай гына да түгел, Сабир аганың олы малае Азат, иң элек әнисе Гөлсинә ханым эзеннән китеп, укытучы һөнәрен сайлый. Казан педагогика университетында биолог белгечлеге ала, аннары үз мәктәпләрендә укыта башлый. Әмма аны да уңдырышлы җир үзенә тарта. Игенче хезмәте буыннан буынга килгән бит. Менә берничә ел инде җиде кешелек звеноны җитәкләп, Голландия технологиясе белән мөстәкыйль рәвештә бәрәңге игә Азат. Сиксән гектарлы участоктан уртача 300–350 центнер уңыш үстерәләр алар. Боларны ничек игенчеләр династиясе димисең!

Үзебезнең районның Иштуган бистәсендә яшәүче Габделкави ага Гыйматовны да соңгы елда йөрәге «борчый» башлаган. Кырык елга якын Саба урман хуҗалыгында ОРС (эшчеләрне тәэмин итү бүлеге) системасында эшләп алтмышын тутыргач, лаеклы ялга чыккан ул. Бик күпне күрергә туры килә аңа. Габделкави Гыймат улы белән бер дә аралашкан булмаганбыз икән. Бик кызыклы вакыйгалар сөйләде ветеран. Балтач районының Нормабаш авылында туып үсә ул. Әтисе ничек итсә итә, улына урта белем бирә. Габделкави егет булып килгәндә, болар авылында Түбән Кенәдән Майшәрәф Шаһимулла кызы Шәймуллина дигән япь-яшь кыз бала, Арча педагогия училищесын тәмамлап, башлангыч класс балаларын укытырга килә. Шунда Габделкави белән танышалар. Әмма сугыш башлана. Яшь егет фронтка китә. Әлеге яшь йөрәкләр ике елдан соң 1 нче Украина фронтында (Белгород өлкәсендә) кабат очрашалар. Майшәрәфне дә зенитчы итеп сугышка алган булганнар икән. Бу очрашып аерылышуның шатлыклы мизгелләре турында сөйләгәндә, фронтовикның күзләре яшьләнә. Ходайның рәхмәте дигәндәй, болар сугыштан икесе дә исән-сау кайталар. Бер-берсе белән кабат табышып, кырык биш ел да биш ай һәм бер көн бик матур итеп гомер кичерәләр, дүрт кыз, өч малай тәрбияләп үстерәләр. Аларны укыталар, кызларны кияүгә бирәләр, малайларны өйләндерәләр. Кем әйтмешли, малайлар-давайлар инде. Мансурлары — Татарстан Дәүләт автоинспекциясе идарәсе штабы начальнигы, подполковник. Васил — Яңа Савин районы Эчке эшләр бүлеге начальнигы урынбасары, капитан. Рәсим — таможняның Казан бүлеге начальнигы, полковник.

Яшьлегенең иң матур елларын сугыш кырында үткәргән запастагы сержант Майшәрәф апа гына юк. Габделкави абыйның йөрәге туктарга теләгәндәй итә. Шуңа күрә шифаханәдә ул...

Әмма картаймыш көнендә ул ялгыз түгел. Янында яңа җәмәгате, лаеклы ялдагы шәфкать туташы Фәния Кадыйрова бар.

— Гомер иткән Майшәрәфне югалту кайгысын сөйләп бетерә торган булмады. Үзем дә мораль яктан үлгән идем. Фәния ханым йортыбызга нур иңдерде. Кызларым, улларым, оныкларым да бик яраталар үзен. Исән генә була күрсен, — ди Габделкави ага.

...Әнә аерым бүлмәгә берәүне салдылар. Коридорда тән сакчылары да күренгәли. «Татарстан» авиалинияләре компаниясе җитәкчесе Михаил Розенштейн икән ул. Бер атнадан савыгып китеп тә барды. Әле күптән түгел аның унсигез миллиард сум эләктереп, гаиләсе белән АКШка чыгып таюы матбугатта хәбәр ителде...

## КЕМНӘР ГЕНӘ ЮК БИРЕДӘ...

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының иң өлкән артисты Һидият ага Солтанов, урта буын артист Әсгать Хисмәтов, композитор һәм баянчы Ганс Сәйфуллин. Аның белән байтактан таныш идек. Бер елны якташ композиторларыбыз Хөснулла Вәлиуллин, Фасил Әхмәтов, шулай ук җырчылар Миңгол Галиев һәм Люция Хәсәнова белән иҗат кичәләрен уздырырга килгәннәр иде. Ике йөзләп җыр иҗат иткән Ганс Сәйфуллин хәзер үзе дә танылган композитор. «Ак Барс» банкы ярдәме белән җырлар китабын чыгарган. Шуны бүләк итте. Үзенең дә гозере бар икән.

— Безнең бүлектә шәфкать туташлары конкурсы була. Мөдиргә кереш сүз язый әле, — ди.

Аннары, зур сер әйткәндәй итеп кенә, үзләренең катында Гомәр ага Бәширов ятканын әйтте.

Хәер, мин аны ишеткән дә идем инде. Дөресрәге, кызы Лилия апа, ягъни яраткан язучыбыз Мөхәммәт ага Мәһдиевнең җәмәгате очрап, әтисенең шифаханәдә икәнен белгерткән иде.

Менә кичкә таба киттем мин туксан җиде яшьлек аксакал язучыбызның хәлен белергә. Кечкенә банкага салынган үзебезнең «Саба» кумәк предприятиесе балын алдым. Гомәр ага Бәширов белән очрашкан юк иде әле. Шулай да якыннан бер күргәнем бар икән. 1996 елның 29 гыйнварында булды ул. Ел йомгаклары белән киңәшмәгә җыйганнар иде. Шул көнне Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Гомәр агага 95 яшь тулуга багышланган тантаналы кичә буласы көн. Чакыру билетлары тараттылар. Минем урын бишенче рәтнең иң кырыенда булып чыкты. Кичә башлангач, Гомәр ага улы Зөфәр белән шул кырыйдан сәхнәгә күтәрелде. Зал, шул исәптән без дә, аягүрә басып, аксакалны алкышлар белән озаттык. Кичә бик матур булды. Гомәр ага бик эзлекле, саф әдәби телдә эчтәлекле итеп чыгыш ясады. Шаяртып әйткән бер җөмләсе әле дә хәтердә: «Туксан биш яшькә беренче тапкыр

җиткәч, нәрсә сөйләргә дә белеп булмый әле», — дигән булды кереш сүзендә.

...Ярар, җиденчедән дүртенче катка төштем. Гомәр ага холлда телевизордан кичке алтыдагы «Яңалыклар»ны карап утыра. Күзлексез. Кояш төшкәнгә, кулын маңгаена куйган. Янына утырдым. Эндәшү юк. Яңалыклар бетүгә аксакалыбыз җәһәт кенә торды да палатасына таба китте. Таяк шикелле әйбере дә күренми. Артыннан кердем.

— Гомәр абый, сезнең хәлне белергә төшкән идем. Лилия апаны күрдем. Сезне, монда дәвалана, диде. Мин үзем Сабадан булам. Менә күчтәнәч, чәй эчәрсез, — дим.

Банканы әйләндереп карады да:

— Юкә балы икән бу! — диде. — Сез Лилияне кайдан беләсез соң? — дип сорап куйды.

Мин үземнең Мөхәммәт Мәһдиевнең шәкерте икәнлегемне, аларда берничә тапкыр булганым барлыгын сөйләп бирдем. Шуннан ул кияве турында бик җылы сүзләр әйтте. «Талантлы язучы иде, уйланылган бик күп әсәрләрен үзе белән алып китте. Планнары зурдан иде. Нишлисең бит... Без якташлар булабыз инде. Ике яклатып. Минем әни Олы Кибәхуҗаныкы иде. Мөхәммәтнең әнисе — Түбән Симеттән. Әтисе — Гөберчәкнеке. Үзе Керәнле, Яңа Мичән авылларында укытып та йөргән бит әле. Безнең Яңасала да (Арча районы) сезнең район белән чиктәш бит. Урман артында ук Фатих Хөсни авылы. Олы Мәтәскәме әле? Олы Кибәхуҗага барганым да булды.

Мин бу авылларның хәзер Теләче районына керүе турында әйтәм. Аның «Туган ягым — яшел бишек» повесте күз алдына килә. Ул анда Кибәхуҗадан килгән кунак кызы, Кибәхуҗа җыеннары, Кибәхуҗадан Ерак әбисе килүе, апасы Өммикамалны шул авылның Биккенә углы Нәбиуллага димләп кияүгә бирүләре, әтисе җан биргәндә, Кибәхуҗадан Өммикамал апасы килеп җитү күренешләрен бик тәфсилләп яза бит.

— Минем күңелемдә хосусый милекчелек нык саклана әле, — диде ул, әңгәмәне дәвам итеп. — Үзем авырлыкны күп күрдем. Бала вакытта тегүчегә ияреп, өйрәнчек булып йөрдем. Әти 1916 елда вафат булды. Тормыш йөге тулысы белән үз җилкәмә калды. Чәчтем, урдым. Әни иртүк уятып басуга җибәрә иде. Көн эсселәнгәнче эшли идек, аннары үзем дә, ат та ял итеп ала иде. Каты сукага йөргән вакытлар әле дә истә...

Каты сука дигәне көзгә арыш чәчәр өчен җир әзерләү икән. Гомәр ага быелгы игеннәрнең торышы белән дә кызыксына. «...Тәки коммунизм дигәннәрен күреп булмады, — дип офтанып куя. — Башта уртак юрган була икән, дип, колхозга керүчеләрне куркыттылар. Хәзер күмәк хуҗалыкларны яңадан таратырга маташалар бугай...»

Шуннан ул Гражданнар сугышы чорларындагы вакыйгаларны искә төшерә. Ничек итеп үлемнән калу очраклары турында сөйли. Хәтере искиткеч яхшы. Мәсәлән, бу хәл 1921 елның 21 ноябрь көнне булды, дип башлап китә ул җөмләсен.

## ДАНГА КҮМГӘН «НАМУС»

Менә язучыга дан-шөһрәт китергән «Намус» романы турында сүз башланды. Мин аның язылу тарихы белән кызыксынам.

— 1942 ел иде бу. Казан радиосында эшләгән чак, — дип сөйләп китте Гомәр ага. — Авылларда эшләремне тәмамлаганнан соң, кайтыр юлга чыгып, Балык Бистәсе пристанена юнәлдем. Пристаньга ат белән илтеп куюларын үтенергә кыенсындым, чөнки колхозларда атлар иген эшләренә дә җигәргә җитми иде. Кечкенә генә биштәремне аркама астым да җәяүләп кенә китәргә булдым.

Өлкән яшьтәге бер апа белән без иген кырлары буйлап атлыйбыз. Һава яхшы, әйләнә-тирә тын. Юлыбыз бер үргә менә, бер үзәнгә төшә. Әлеге хатын җайга гына авыл хәлләрен сөйләп бара. Ничек яшиләр, ничек эшлиләр, кемнәргә «кара пичәтле» язу килгән... Мин исә, юлдашым сөйләгәннәрне тыңлый-тыңлый, күңелемнән радиога очерк язу белән мәшгуль идем. Сөйли торгач, юлдашыма әллә ни булды: ул кинәт кенә тынып калды да күз яшьләрен сөрткәләргә кереште. Сораша башласам, бу арада алар авылында җан тетрәткеч бер фаҗига булып узган икән бит, ул бөтен тирә-як халкын авыр кайгыга салган. Бер яшь кенә килен иренең сугышта үлеп калуы турында хәбәр алган. Билгеле, кайгырышканнар. Әмма каената белән каенана киленне бик яратканнар икән. Шул сәбәпле, аны йорттан җибәрәселәре килмичә, борынгы гадәт буенча, кече улларына алып калганнар. Шул көннәрдә үк, һич көтмәгәндә, госпитальдән киленнең беренче ире кайтып төшмәсенме! Шушы хурлыкны күтәрә алмыйча, әлеге килен үзен-үзе үтергән... Бу фаҗига мине дә бик дулкынландырды. Мин бу хакта, фашизмны гаепләп, бик усал хикәя язарга ниятләп куйдым.

Казан ягына кайчан пароход булачагын пристаньда беркем дә белми иде. Әллә бүген килә ул, әллә иртәгә, әллә беркайчан да килмәячәк.

Кама яры өстендә арлы-бирле йөренгәләп, баштарак әлеге хикәя белән мавыктым. Ләкин йөри торгач, минем уйларымны бөтен ил күләмендә — фронтта һәм тылда барган аяусыз, тиңсез фидакарь көрәш күренешләре биләп алды. Күз алдыма авылда икмәк өчен көрәшнең төрле кыенлыклары килеп бас-

ты.

Пароходны ике тәүлектән артык көтәргә туры килде. Әмма мин моңа һич тә кыенсынмадым. Дөресен генә әйткәндә, күпме вакыт узганны хәтта сизмичә дә калдым. Үзем эштән чыгып арыган, карыным ач булса да, күңелем күтәренке иде, чөнки мин өйгә яңа әсәр язу дәрте белән канатланып кайттым.

Иртәдән кичкә кадәр көн буе радиода эшләп кайтам да төннәрен, балалар йоклагач, язарга утыра идем. Менә шулай туды ул роман...

Аннан соң Гомәр ага романга Сталин премиясе бирелүе турында әйтте. «Намус»ны премиягә Мәскәүдән тәкъдим иттеләр. «Русчасын Сталин үзе укыган, диделәр», — дип сүзен йомгаклагандай итте.

Дөрестән дә, «Намус» романы 1949 елда ук рус телендә басыла. Юлбашчы үзе укыгандырмы, анысын әйтүе авыр. Әмма 1951 елда Гомәр Бәшировка Сталин премиясе бирелә. Шуннан соң ул союздаш һәм кайбер автономияле республикаларның халыклары телләренә дә тәрҗемә ителә. Шул ук елда инглиз, немец, француз, испан һәм башка телләрдә чыга торган «Совет әдәбияты» альманахында дөнья күрә. Гомумән, «Намус» романы татар телендә дүрт тапкыр, 40 мең данә булып басылса, русчага тәрҗемәсе ун тапкыр дөнья күрә, һәм аның гомуми тиражы 800 мең данә тәшкил итә. Роман китап булып албан, болгар, вьетнам, кытай (өч тапкыр), немец, чех (икешәр тапкыр), поляк, румын, словак, һинд телләрендә басыла.

Сугыштан соңгы елларда Гомәр ага, әдәби иҗатыннан тыш, җәмәгать һәм җитәкче эшләрдә дә активлык күрсәтә. 1953 елда ул Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе итеп сайлана, бу вазифаны биш ел буе алып бара. Аннары 1958 елдан башлап Россия Язучылар берлеге идарәсе рәисенең Федерациядәге милли әдәбиятлар буенча урынбасары буларак берникадәр вакыт Мәскәүдә эшли. Ике тапкыр СССР Верховный Советына (1953–1962 еллар), бер чакырылыш (1951–1954) Татарстан Верховный Советына депутат итеп сайлана. Партиянең XX съездында делегат булып катнаша. Еллар үткән саен, «Туган ягым — яшел бишек», «Җидегән чишмә» кебек романнар, байтак кына повесть һәм очерклар иҗат итә Гомәр ага. Татар халык иҗатын җыюга, аны тикшерүгә дә күп көч куя. Әлбәттә, озак елларга сузылган иҗади хезмәте эзсез калмаган аксакалның. Ул Ленин ордены (1957), ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы (1950, 1962), Октябрь Революциясе (1971), Халыклар Дуслыгы (1981), «Кызыл Йолдыз» ( 1968) орденнары белән бүләкләнә. Аңа, ниһаять, 1996 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.

Аксакал белән әңгәмәбез ахырына якынлаша.

— Гомәр ага, сезнең бер гасырлык юбилеегыз үзегез исән вакытта үткәрелсә, милләтебез, бигрәк тә китап укучылар өчен бәхетле вакыйга булыр иде, — дим.

— Алладан күпме язгандыр инде, — ди Гомәр ага. Аннары тирән оптимизм белән: — Аякларның шыгырдавын исәпкә алмаганда, минем җитди авыруым юк, — дип өстәде.

Мин олы язучының соңгы еллардагы иҗаты белән кызыксынам.

— Алай күп итеп язам дип әйтә алмыйм. «Гыйбрәт» дигән романны тәмамлыйсы бар. Аның өзекләрен «Ватаным Татарстан» газетасына биргән идем, — диде. Аннары фикерен йомгаклагандай итеп: — Ул романның башы да, ахыры да бар. Уртасы буш. Шуны «тутырып» бетерәсе бар, — дип өстәде әкрен генә.

Киң фикерле, тыйнак вә мөлаем язучыдан аерыласы да килми хәтта. Ләкин, әдипне талчыктыру килешмәс дип, саубуллашу ягын карыйм. Күңелдә янә изге теләк уяна: язучының үзе исән вакытта бер гасырлык юбилеенда катнашу да насыйп булса ярар иде.

*1998*

# Гыйлем иясе

Без, сабалылар, газиз якташларыбыз белән һәрдаим горурланып яшибез. Ә менә Әбрар ага Кәримуллин турында Казанда сүз чыкканда, кайберәүләр: «Ул да Сабаданмыни?» — дип гаҗәпләнеп куялар. Әйе, китап белгече булып бөтен дөньяга танылган Әбрар ага 1925 елның 29 маенда районыбызның Чәбия-Чүрчи авылындагы гади крестьян гаиләсендә туган.

Әбрар Кәримуллинга бала һәм үсмер чагыннан ук күп авырлыкларны татырга туры килә. Әнисе коллективлаштыру чорында һәлак була. Сугыш бетеп күп тә үтми, фронтта алган яраларыннан әтисе үлә. Тарих тәгәрмәче әнә шулай, башка бик күпләрне аямаган кебек, ерак бер авылда яшәп яткан гаилә өстеннән дә уза.

Яшүсмер Әбрарның Бөек Ватан сугышына китүе дә үзенчәлекле. Әгәр дә аның фәнни эшләрен эченә алган библиографик белешмәгә күз салсак, ул районыбызда чыга торган «Колхоз байрагы» газетасының 1943 елның 14 гыйнвар санында басылган «Йөрәк кушуы буенча» дигән мәкалә исеме белән ачылып китә. Монда унсигез яшь тулар-тулмас вакытта абыйсының малае К.Кашапов белән үз ихтыярлары буенча фронтка китүләре тасвирланган була.

1941 елда Саба урта мәктәбен тәмамлаган егет тракторчы ярдәмчесе, хисапчы, укытучы булып эшли, гвардия рядовое минометчы Әбрар канлы Курск дугасыннан алып, Румыния, Венгрия җирләрен үтеп, Чехословакия башкаласы Прага шәһәрен азат итүдә катнаша. Җиңү салюты яңгырагач та, Ә.Кәримуллинга тыныч тормышка кайту тиз генә насыйп булмый. Чөнки ул хезмәт иткән частьне Көнчыгышка җибәрәләр. Әбрар Кәримуллин япон самурайларына каршы сугышларда катнаша. Гоби чүлләрендәге коточкыч «үлем үзәне», Хинган тауларындагы каты бәрелешләр аның күңеленнән мәңге китми. Әбрар Гыйбадуллович белән очрашучылар аның костюм капкачының уң ягындагы өч яссы кызыл тасмага игътибар итми калмый. Ул — өч тапкыр яралану, контузия билгесе.

Әбрар Кәримуллин 1947 елда демобилизацияләнгәннән соң да Икшермә МТСында трактор бригадасы учетчигы, аннары ул вакыттагы «Память Ильича» колхозында хисапчы булып эшли. 1948 елны Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Укуын тәмамлагач, 1953–1964 елларда университетның Н.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә калдырыла, башта өлкән китапханәче, бүлек мөдире, аннары директорның гыйльми эшләр буенча урынбасары булып эшли. Аннан соң ул Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына эшкә күчә, институт планы буенча йөкләнгән гыйльми бурычларны үтәүдән тыш татар китабының тарихы өстендә эшли. Әбрар ага Кәримуллин, махсус аспирантурада һәм докторантурада укымаган килеш, 1968 елда — кандидатлык, ә инде 1978 елда докторлык диссертацияләре яклый. Мондый фән биеклекләрен яулау өчен күпме тырышлык, ихтыяр көче, үҗәтлек кирәк икәнен Әбрар ага үзе һәм гаиләсе генә беләдер.

Якташыбыз китап белеме, археография, иҗтимагый-сәяси фикер тарихы проблемалары буенча үткәрелә торган Бөтенсоюз фәнни киңәшмәләрендә актив катнаша. Ул — күп кенә гыйльми советлар әгъзасы, шул ук вакытта Ленин исемендәге дәүләт китапханәсе каршында докторлык диссертациясе яклау буенча махсус совет әгъзасы буларак та аның эшчәнлегенә зур өлеш керткән кеше икәнен яхшы беләбез.

Кыенлыкларга, язмыш кырыслыгына бирешмичә, аларны җиңеп чыгар өчен бик тә түземле, көчле рухлы булырга кирәк була якташыбызга. Үз дигәненнән чигенмичә, куелган максатларына ирешүдә Әбрар Кәримуллинга крестьянлык чыдамлыгы, фронтта чыныгу алуы да ярдәм иткәндер. Сугыштан соң солдат гимнастеркалары киеп югары уку йортлары аудиторияләренә килгән бик күп авыл егетләре кебек, Әбрар Гыйбадуллович та максатына тугрылыклы, тырышлыгы, укуга җитди мөнәсәбәте белән аерылып тора.

Фән юлына аяк басканчы ук, ул бер хакыйкатькә нык төшенә: чын галим беркайчан да ирешелгәннәр белән генә канәгатьләнергә тиеш түгел. Үзеңнең гыйльми эзерлегеңне, белемең даирәсен туктаусыз тирәнәйтү — уңыш яулауның иң катгый шартларыннан берсе.

Яшерен-батырын түгел, Әбрар агага заман җилләре шактый кырыс итеп исте. Аның фәндә шактый кыерсытылган, бәрелгән-сугылган шәхес булуын да ишетеп беләбез, олы-олы хезмәтләре егерме-утыз еллар дөнья күрә алмый ятты. Әмма алтын бәясен югалтмый, диләр. Аның иҗади эзләнүләре, тау-ташларны ярып чыккандай, тарихыбызга турылыклы, китаплары да бер-бер артлы дөнья күрделәр, ялган дөньясына баткан халыкның күзен ачтылар, фаҗигале, әмма бай тарихыбызны яктыртып, башкача уйлый башларга чакырдылар. Теге заманнарда, «Ахыры ни булыр?» дип курка-курка гына басылганга, аларның тиражлары да бик аз куелган иде. Әмма халык, җәмәгатьчелек нәрсәнең нәрсә икәнен бик тиз аңлап алды. Ә инде 1991 елда якташыбызның рус телендә язылган өч китабы — трилогиясе («У истоков татарской книги», «Татарская книга пореформенной России», «Татарская книга начала XX века») олы дәрәҗәгә — Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә, аннары Кол Гали исемендәге халыкара бүләккә лаек булды.

Бүгенге күзлектән караганда, Әбрар ага фәнгә шактый соң килә, әмма эшләгән эшенең күләме ягыннан абруй казанды. Күп гасырлы кульъязма әдәбият һәм басма сүз тарихын тирәнтен өйрәнү нәтиҗәсендә, ул беренче булып татар китабының катлаулы үсеш тарихын торгыза, шул рәвешчә татар филологиясе һәм әдәбиятында яңа юнәлеш ача, татар иҗтимагый фикере һәм мәдәнияте тарихын яңа яктан баета. Ул шулай ук татар мәдәнияте белән башка халыклар мәдәниятләре арасындагы багланышларның яңа сәхифәләрен яктырта, беренче булып филология, сәнгать тарихы буенча милли библиографияне, туган ягыбызның күренекле галимнәре Н.Ливанов, Н.Катанов, мәгърифәтче-галим К.Насыйри, язучы һәм шагыйрьләрдән М.Җәлил, Н.Исәнбәт, Х.Туфан һәм башкаларның персоналияләрен төзи. Бу библиография чит ил белгечләре игътибарын да җәлеп итте. Әбрар ага Кәримуллинның хезмәтләре нигезендә Татарстан һәм Башкортстан югары уку йортларында татар китабы тарихы буенча махсус курслар кертелде. Галимнең басылып чыккан хезмәтләре дүрт йөзләп исәпләнә, шулар арасында татар китабы, әдәбият белеме, сәхнә сәнгате, фольклоры буенча утыз ике монография һәм брошюра булуы белән куандыра.

Әбрар ага Кәримуллин — киң колачлы галим. Аның татарлар этногенезы, чит илләрдә яшәүче татарлар, Америка континентында яшәүче абориген халыклар һәм кабиләләр телләре турындагы хезмәтләре, шулай ук археография, топонимия буенча үткәргән тикшеренүләре җәмәгатьчелек арасында зур кызыксыну уятты. Күпкырлы һәм яссылыклы китап дөньясы белгечлеге буларак, галимнең кызыксыну

даирәләре төрле юнәлешләргә сузыла. Тик шулай да галим архивларда казыну, тарихи эзләнүләр белән чикләнеп калмады, ә республикадагы бүгенге иҗтимагый-сәяси процессларны анализлау белән дә актив шөгыльләнә. Татар халкының милли яңарышына булышуны ул үзенең изге бурычы саный. Аның вакытлы матбугат битләрендә басылып чыккан һәм туган ягыбыз тарихындагы «ак таплар»ны яктырткан мәкаләләре җәмәгатьчелек фикерен кузгатмый калмый.

Әбрар ага Кәримуллинның хезмәтләре безнең илдә генә түгел, чит илләрдә дә киң танылган. «Кем ул кем?» Энциклопедик сериясе басмаларын әзерләү буенча Англиянең Кембридж шәһәрендә урнашкан Халыкара Биографик үзәк фәнни-киңәш советы хакыйкый әгъзасы, Америка биографик институты редакцион советы әгъзасы. Австралиянең Сидней шәһәрендә төпләнгән Гуманизм һәм гаделлек өчен көрәш рыцарьлары конференциясе халыкара парламенты Дәүләт секретаре булып тора. Бу парламент аңа Маркиз оф Туран дигән мактаулы исем бирде.

Әлеге Бөтендөнья парламенты Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Африка, Азия, Океания халыкларының мөстәкыйльлеге өчен барган изге көрәш йогынтысында барлыкка килә. Бу парламентның Югары Советы составын Җир шарының 100 ләп иленнән билгеләнгән, сайлап алынган зыялылар: академиклар, президентлар, профессор һәм илчеләр, Нобель премиясе лауреатлары, галимнәр, дәүләт эшлеклеләре тәшкил итә. Моннан 56 ел элек Бөтендөнья парламенты Югары Советына безнең мөхтәрәм якташыбыз элеккеге СССРдан өченче кеше итеп кабул ителә. Хәзер Әбрар ага тырышлыгы белән әлеге Югары Советка Татарстаннан дистәгә якын зыялы кертелде. Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев Бөтендөнья парламент Президиумына Почетлы әгъза итеп кабул ителде һәм «Хакыйкать һәм гуманизм» ордены белән бүләкләнде. Аны Илбашына Әбрар ага Кәримуллинның тапшыру мизгелләрен күпләр хәтерлидер әле.

Татарстан Президентын һәм аның зыялыларын Бөтендөнья парламенты үзенең Югары Советына һәм Президиумына сайлавы — бу — Татарстанның дөнья дәүләтләре арасында тоткан ролен тану белән беррәттән, аның мөстәкыйльлеген дөнья күләмендә тануның да бер күренеше. Бу безнең бөтендөнья орбитасына чыгу буенча да зур уңышыбыз.

Әбрар ага Кәримуллин татар мәдәниятен өйрәнүдә ике яңа юнәлеш — милли китап тарихын һәм татар фәнни библиографиясен башлап җибәрде. Аның нияте — революциягә кадәрге (1722–1917 еллар) татар китабының күптомлы җыелма каталогын булдыру. Ул шулай ук «китап белеме» буенча фәнни белгечләр әзерләүне киңәйтү, китап фәнни-тикшеренү институты оештыру, «Татар китабы эшлеклеләре» дигән хезмәтләр сериясе чыгару, югары уку йортлары өчен дәреслек төзү планнары белән яши.

Аңа бу изге теләкләрен тормышка ашырырга насыйп булсын!

Без, якташларыгыз, Әбрар ага, Сезне бик хөрмәт итәбез. Шулай булмыйча мөмкин түгел. Чөнки Сез «китап белеме» белгечлеге буенча бөтен дөньяга танылган шәхескә әйләндегез. Шуңа күрә зур тырышлыклар белән филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәре академиясе хакыйкый әгъзасы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе кебек дәрәҗәләргә, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Рыцарьлар Бөтендөнья парламенты тарафыннан Маркиз оф Туран дигән исемгә лаек булган галим-якташыбызга яңа иҗат уңышлары, нык сәламәтлек, планлаштырылган эшләрегезне башкарып чыгарлык озын гомер, тыныч тормыш телибез.

*1985*

* * *

Башкалабыз Казан якташыбыз Әбрар ага Кәримуллин белән мәңгегә саубуллашты. Аны озатырга республикабыз җитәкчеләре, халык депутатлары, галимнәр, язучылар, гомумән, академикны хөрмәт итүчеләр бик күп җыйналган иде. Шулай булмыйча мөмкин дә түгел. Чөнки ул милләтебезнең кабатланмас олуг шәхесе, китап белеме буенча иң беренче профессорыбыз, академигыбыз, «энциклопедия»без иде. Аның исеме Татарстанда һәм Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә киң танылды. Галим соңгы елларда Үзәк Азия тарихына, мәдәниятенә һәм бүгенге көненә багышланган өченче Халыкара конференциядә (АКШ, Висконсен), Төркиянең социаль һәм икътисади тарихы буенча өченче Халыкара фәнни конгресста (Төркия, Истанбул), «Сәнгать һәм Халыкара мәдәни, фәнни элемтәләр» дип исемләнгән Халыкара унсигезенче конгресста (Канада, Торонто), шушы конгрессның унтугызынчысында (Англия, Кембридж), Әхмәт Ясәвинең тууына 900 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни симпозиумда (Төркия, Кайсери) һәм башка бик күп форумнарда катнашты, аларда фәнни докладлар белән чыкты.

Кыскасы, академик вафат булгач, фән агачының олы бер ботагы сынып төшкәндәй булды, милләтебез зур югалту кичерде. Әбрар аганың 35 тән артык китап һәм 6000 фәнни язма авторы булуы да киң колачлы эшчәнлеге турында ачык сөйли. Без аның белән еш очраша идек, шуларның берсендә «Әдәби җыентык һәм альманахлар библиографиясе: 1917–1960» дигән китабының юк ителүе, үзенең эштән чыгарылуы турында тәфсилләп сөйләгән иде. Хәер, бу вакыйгалар «Без тарихта эзлебез» дигән китабында бик ачык тасвирлана.

Әбрар абый туган ягын сагынып, бер үк вакытта горурланып яшәде. Чәбия-Чүрчидә үткән 70 еллык тантаналарын гел искә алды. Хәле бик әйбәт булмаса да, 2000 елда, 75 яшьлек юбилей көннәрендә, сабантуйга чакыргач, җәмәгате Кинтә ханым белән бик теләп һәм шатланып кайтты.

Район хакимияте башлыгы Рәис Миңнеханов аңа, башкарган хезмәтләре, Саба данын еракларга күтәргән өчен рәхмәт әйтеп, мәйдан уртасында башына милли түбәтәй белән затлы бүрек киертте. Әбрар абый шунда районДашлары алдында милләтебезне яклау һәм саклау турында соңгы тапкыр чыгыш ясады, без аны фотосурәткә дә алдык. Монысы да якты дөньяда ахыргы тапкыр рәсемгә төшүе булган икән. Нишлисең, бүреген киеп кыш чыгарга язмаган булып чыкты. Әмма Саба сабан туеннан кайткач: «Кинтә, китер әле теге бүләкне», — дип сорап алган ул һәм җәй көне бүрек кигән килеш йоклап та киткән... Ул үзенең соңгы кайтуы икәнен чамалады, әлбәттә. Туган авылы Чәбия-Чүрчи зиратыннан, әтисе кабере тирәсеннән урын да барлады...

...Хушлашу митингын Олы Нырты җирле үзидарә советы рәисе Мидһәт Хәсәнов ачып, академикның тормыш һәм фәнни юлы белән таныштырганнан соң, сүзне район хакимияте башлыгы Рәис Нургали улы Миңнехановка бирде.

— Без бүген халкыбызның сөекле улын, фән, әдәбият, сәясәт өлкәсендәге йөзек кашы булган Әбрар абыйны соңгы юлга озатабыз, — диде ул. — Аңа без бик рәхмәтлебез. Ул районыбыз данын еракларга күтәрде, аның халкын хөрмәт итте. Без дә, үз чиратыбызда, атаклы якташыбызның исемен мәңгеләштерү чараларын күрербез. Район музеенда аңа багышланган аерым бүлек булдырырбыз, каберенә олы шәхес икәнен белгерткән таш куярбыз, зиратның киртә-коймасын яңартырбыз. Шулай итмичә булмый, чөнки бүгеннән Чәбия-Чүрчи зираты яңа статус алды.

Гомумән, аңа эзне суытмабыз, мәктәп балалары каберен шефка алып, карап-тәрбияләп торырлар... Бүген, халкыбыз авыр югалту кичергән көндә, мәрхүмнең җәмәгатенең, якыннарының авыр кайгыларын уртаклашам. Урының оҗмахта, авыр туфрагың җиңел булсын, Әбрар ага! Сезнең якты истәлегегезне мәңге онытмабыз.

Татарстан халык депутаты, Дәүләт Советының даими комиссиясе рәисе, мәрхүмнең иң якын дусларының берсе Разил Вәлиев, Татарстан Фәннәр академиясенең баш гыйльми сәркатибе Илдус Хәбибуллов, шагыйрь Әхмәт Гадел, язучы Мөсәгыйть Хәбибуллин, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры урынбасары Шәрифҗан Асылгәрәев һәм башка билгеле шәхесләрнең саубуллашу сүзләре дә йөрәкләргә үтәрлек, күңел кылларын тетрәндерерлек булды. Якташыбыз, танылган хикәяче Мәгъсүм ага Хуҗинның: «Тар гына сукмактан чыгып киткән Әбрар ага олы юлдан туган авылына мәңгелеккә кайтты», — дигән җөмләсе мәңге йөрәктән китми торган булды.

Шулай итеп, дөнья күләмендә танылган якташыбыз Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин бу фани дөньядан мәңгелеккә — бакыйлыкка күчте. Тар ләхетең киң, караңгы күгең якты булсын!

*2000*

# Хәтер ташы

Борынгы җирдә яшәвебез дә, тамырларыбызның бик тирәндә булуы тарих белән кызыксынучыларга күптән билгеле, мәгълүматлар байтак иде. Тарихи романнар остасы, танылган әдип һәм галим Нурихан Фәттах «Сөембикә» журналының 1992 елда нәшер ителгән 2–3 нче саннарында Саба тарихы, бу атаманың килеп чыгышы турында тәфсилләп сөйләп, Саба авылының Казан ханлыгы чорында ук булуын, 1184 елгы вакыйгалар (руслар белән болгарлар арасында сугыш) уңае белән Сабаның рус елъязмаларында телгә алынуын искәрткән иде. («Яшә, Саба-Йорт!», 245 бит.) Эзмә авылының иске зиратында 1332 елгы кабер ташының бүгенге көнгә кадәр исән-имин саклануы да тарихыбыз ядкаре.

Соңгы елларда тарих фәннәре кандидаты, танылган археолог Альберт Борһанов әлеге язма чыганакларны археологик ачышлар белән бәйли, баета, тулыландыра. Ул бу изге эшне 1998 елда башлаган иде. Аның җитәкчелегендәге Татарстан Фәннәр академиясенең тарих институты һәм Татар гуманитар институтының берләштерелгән Алтын Урда комплексы тарихи-археологик экспедициясе Калатауда (Өтернәс яки Мишә-Тамак шәһәрлеге дип тә йөртелгән,1998 елда күренекле галим Александр Бахтин чыгарган «XV–XVI гасырлар Марий өлкәләре тарихында» дигән китапта Мишә-Тамакның урнашкан җире картада да күрсәтелгән. Бу шәһәрнең тарихчы-галим Равил Фәхретдинов язмаларында булуы да сабалыларга билгеле.), Сабада, Миңгәрдә, Завод-Ныртыда казу-тикшеренү эшләре алып бара.

Өтернәс (Мишә) шәһәрлегендә, 1552 елда Казанны рус гаскәрләре алгач, бер ел үтүгә баш күтәргән халык тарафыннан салынган, 18 айдан соң, ягъни 1554 елда биредәге халык канга батырылып бастырылгач, тәмам җимерелгән шәһәр изге урынында Хәтер ташы куелды (архитекторы Нурулла Гариф). Әлеге тарихи вакыйганы район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Таһир Шәрәфиев ачып җибәрде. Аннан соң Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары Рафаэль Вәлиев Сабадагы табылдыкларның Казан ханлыгының соңгы елларын өйрәнүдә чагыштырма материал буларак зур

әһәмияткә ия булуына басым ясады. Бу тарихи-мәдәни комплекстагы табылган яңа хәзинәләр белән тынгы белмәс Альберт Әхмәтҗан улы тәфсилләп таныштырды.

Менә көн буе тоташ яуган яңгыр астында Хәтер ташы өстеннән ак япма төшерелә...

Ә табигать «елый да елый». Гүя ул ел ярым гына яшәп, азатлык өчен шәһит китүчеләр рухына әрнеп-сыкрап дога кыла...

*2001*

# Халкыбызның тутыкмас җәүһәрләре

Хөснулла Вәлиуллин иҗатына багышланган тәүге кичә Татарстан Республикасы Композиторлар берлегенең концертлар залында башланып киткән иде. Аның югары дәрәҗәдәге ноктасы Вәлиуллиннарның туган төбәгендә — Байлар Сабасы авылында булды. Олуг шәхеснең юбилеен билгеләп үтәргә Фасил Әхмәтов, Мирсәет Яруллин, Әнвәр Шәрәфиев, Ренат Еникеев кебек танылган композиторлар, Татарстан Республикасы мәдәният министры Марсель Таишев, аның урынбасары Илдус Тарханов (ул Саба урта мәктәбендә укыган), Казан шәһәренең безгә шефлык итә торган Вахитов район хакимияте башлыгы Сабирхан Мөхәрләмов, композиторның тормыш иптәше Әминә ханым, улы Таһир, Вәлиуллиннарның Сабада, Килдебәктә, Шәмәрдәндә, Сатышта яшәүче туганнары җыйналды.

Юбилей тантанасы Вәлиуллиннар яшәгән нигездәге йорт капкасына мемориаль такта кую церемониясе белән башланып китте. Бу турыда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 1993 елда ук махсус карар кабул иткән иде. Шушы нигездә якташыбыз мәшһүр «Самат» операсын оркестрлаштырган. Район хакимияте башлыгы урынбасары Нурислам Насыйбуллин Хөснулла Вәлиуллинның биографиясе һәм иҗат юлы белән таныштырганнан соң, мемориаль такта өстендәге япманы районыбыз хакимияте башлыгы Фәрит Гыйльмиев һәм Татарстан Республикасы мәдәният министры Марсель Таишев шудырып төшерделәр, аннан соң чәчәкләр куйдылар. Тантанага килүчеләр матур итеп эшләнгән тактага язылган «Бу йортта 1914–1934 елларда күренекле татар композиторы Хөснулла Вәлиуллин туган һәм яшәгән» дигән текстны кат-кат укыдылар.

Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Россиянең Глинка исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, күренекле композитор Фасил Әхмәтов чыгышын болай дип башлады: «Миңа бүген икеләтә шатлык. Чөнки без Хөснулла ага белән бик дуслар идек. Кунакка йөрештек, иҗат уңышларыбызны уртаклаштык. Аның белән бергә очрашуларда булдык. Шуларның берсе мәңге онытылмый. 1983 елның кояшлы октябрендә без аның белән Сабага иҗат кичәләре үткәрергә кайттык. Безнең труппада тагын композитор һәм баянчы Ганс Сәйфуллин, җырчылар Миңгол Галиев, Люция Хәсәнова бар иде. Бигрәк тә Лесхоз поселогында булган очрашу истә калган. Ни өчен дисәгез, бөек шагыйребез Габдулла Тукай әйтмешли: «...Гәрчә анда тумасам да, мин бераз торган идем, Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем». Кыскасы, мин Кукмара районында тусам да, балалык һәм яшьлек елларым Саба Лесхозында үтте. Хөснулла ага белән мәңгелек дуслыгыбызның нигезенә бу да тәэсир иткәндер, билгеле...

Аннан соң ул Хөснулла Вәлиуллин турында истәлекләре белән уртаклашты. Аның чыгышы зур игътибар белән тыңланды. Туган нигезенә мемориаль такта куюны композиторның туганнары һәм якыннары чын күңелдән хупладылар, Вәлиуллиннар адресына әйтелгән һәр җөмләне дикъкать белән тыңладылар.

Ул көнне Хөснулла Вәлиуллинның 80 еллык юбилеена багышланган чаралар кичкә кадәр дәвам итте. Сабалылар һәм кунаклар Татарстан Милли музееның туган төбәкне өйрәнү филиалындагы Хөснулла һәм Аллаһияр Вәлиуллиннарга багышланган экспонатларны җентекләп карадылар. Хөснулла һәм Аллаһияр Вәлиуллиннар исемен йөртүче Саба районы балалар сәнгать мәктәбендәге композиторларыбызга багышланган класс-бүлмә аеруча кызыксыну уятты.

Шулай итеп, Хөснулла Вәлиуллинның 80 еллык юбилеена багышланган тантаналар мемориаль такта ачу белән башланып, район мәдәният йортында йомгаклау концерты белән тәмамланды. Анда юбилярның җырлары һәм музыкаль әсәрләре яңгырады. Аларны район үзешчәннәре, балалар сәнгать мәктәбе укучылары һәм укытучылары башкарды. Якташыбыз Хөснулла Вәлиуллинның сәхнәдә яңгыраган һәр әсәре көчле алкышларга күмелде һәм үзешчәннәребезнең иҗаты профессиональ композиторлар тарафыннан югары бәяләнде.

* * *

Татарстан Республикасының Композиторлор берлеге концерт залында якташыбыз — Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, җөмһүриятебезнең Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хөснулла Вәлиуллинның тууына 80 ел тулуга багышланган

иҗат кичәсе алданрак булган иде. Анда олы талант иясен хөрмәт иткән бик күп казанлылар катнашты. Тамашачылар арасында танылган композиторлар, Татарстанның, шәһәр Советының халык депутатлары, җырчылар, музыкантлар, гомумән, татар сәнгатен яраткан зыялылар күп иде. Безнең районнан килгән делегацияне район хакимияте башлыгы Фәрит Гыйльмиев җитәкләде.

Кичәне юбилей комиссиясе рәисе, танылган композитор Фасил Әхмәтов ачып җибәрде. Аннары ул сүзне Ф.Гыйльмиевкә бирде.

— Без сезнең белән бу залда ярты ел эчендә икенче мәртәбә очрашабыз, — диде ул. — Аның беренчесе Хөснулла ага Вәлиуллинны соңгы юлга озатканда — узган елның сентябрь аенда булды. Шул вакытта без мәрхүмнең табуты янында якташыбызның исемен мәңгеләштерү турында сүз алып барган идек. Әйе, районыбыз горурлыгы булган, үзенең «Самат», «Дим буенда» дигән опералары, башка музыкаль әсәрләре белән ил шаулаткан Хөснулла Вәлиуллин исеме сабалыларга бик якын. Шуңа күрә без аның иҗат мирасын барлауга, исемен мәңгеләштерүгә даими игътибар бирәбез. Татарстан Министрлар Кабинеты карары нигезендә, ул туган нигезгә озакламый мемориаль такта куячакбыз һәм район үзәгендә аның юбилеена багышланган иҗат кичәсе уздырачакбыз. Узган ел музыка мәктәбе типовой бинага — балалар үзәгенә күчте. Шуннан соң аңа Хөснулла һәм Аллаһияр Вәлиуллиннар исемендәге сәнгать мәктәбе дигән исем бирелде. Балалар үзәгендә якташ композиторыбыз иҗатын өйрәнү мәсьәләсе алгы планга куелды. Казан дәүләт музееның район филиалында да аларга бәйле материаллар һәм экспонатлар туплана.

Аннары Ф.Гыйльмиев юбилярның Саба белән бәйле хатирәләренә тукталды. Сүзен йомгаклаганнан соң, ул тере чәчәкләр бәйләменең берсен Х.Вәлиуллинның зурайтылган фотосурәте алдына куйды, икенчесен композиторның тормыш иптәше Әминә ханымга тапшырды.

Сәнгать фәннәре кандидаты Клара Таҗиева Хөснулла Вәлиуллинның олы иҗаты турында тәфсилләп сөйләде.

Кичәнең концерт өлешен танылган җырчы Хәдичә Гыйниятова Хөснулла Вәлиуллинның Хәй Вахит сүзләренә язылган «Зөһрә җыры» белән башлап җибәрде. «Кошлар тынды» җырын (Фатих Хөсни сүзләре) Татарстанның халык артисты Рафаэль Ильясов зур осталык белән башкарды. Җыр, музыка, истәлекле хатирәләр белән үрелеп алып барылды. Пианиночы Марс Гомәров һәм виолончель остасы Итәкый Халитов иң якын дуслары Х.Вәлиуллин турында бик җылы фикерләр әйттеләр, аның күргән авырлыклары хакында ачынып сөйләделәр. Сәхнә йолдызлары Вафирә Гыйззәтуллина, Миңгол Галиев, Зилә Сөнгатуллина, Клара Хәйретдинова башкарган җырлардан соң концертлар залы көчле алкышларга күмелде. Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының халык артисты Айрат Арсланов укыган шигырьләр һәм җыр текстлары күңелләрдә җылы тәэсир калдырды. Шамил Монасыйпов, Мөнирә Хәбибуллина, Лариса Маслова кебек талантлар башкарган әсәрләр профессиональ югарылыкта яңгырады. Кыскасы, кичә бик күңелле узды.

*1994*

# Фольклорчы, галим, музыкант

Казан радиосыннан безнең күңелләргә хуш килгән тапшыру яңгырады. Ул танылган музыка белгече, профессор, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, республикабызның Аксакаллар Шурасы рәисе урынбасары Мәхмүт Нигъмәтҗановның балалык елларына багышланган иде. Әйе, сабый вакыты дәһшәтле сугыш чорына туры килгән якташыбызның гомере сигез яшькә кадәр безнең районда уза. Ул 1930 елның 10 маенда Олы Арташ авылында туа. Атасы Нигъмәтҗан Мөхәррәмов күп еллар Донбасс шахталарында эшли, оста гармунчы була. Мәхмүтнең музыкага һәвәслеген күреп, аңа дүрт-биш яшь вакытта ук Казаннан гармун алып кайтып бирәләр. Кечкенә Мәхмүт, башта аның бәләкәендә, аннары атасының тальянында уйнап, авыл кешеләрен шаккатыра.

Мәхмүт аганың хәтерләвенчә, аның әнисе бик дини кеше була, биш вакыт намазын калдырмыйча укып барып, балаларын кечкенәдән үк игелеккә өнди, кичләрен мөнәҗәтләр әйтә, борынгыдан килгән әкиятләр сөйли. Гомумән, аларның нәселләрендә гыйлем, музыкага мөкиббән киткән кешеләр күп була. Шулай ук әнисе ягыннан бабасының күренекле дин әһеле, хаҗи икәнен дә искәртик.

— Мин кайларда гына йөрсәм дә, туган ягымны оныта алмыйм. Юкка гына сигез яшькә кадәрге вакытны бала күңелендәге алтын чор дип әйтмәгәннәрдер, — дип искә ала хәзер Мәхмүт ага. — Олы Арташның күркәм табигате — әрәмәле Мишә буйлары, бер-ике чакрымда гына җәелеп яткан урман, анда баргач үзем ясаган курайлар бүгенгедәй истә...

Шулай итеп, 1938 елда Донбасска күчәләр алар. Дәһшәтле сугыш Мөхәррәмовлар гаиләсен дә читләтеп үтми. 1941 елда Мәхмүтнең әтисе һәм абыйсы фронтка китәләр. Яшүсмер малай авыру әнисе белән фашистлар оккупацияләгән Кадиевкада кала. Кайгы өстенә хәсрәт дигәндәй, күп тә үтми, әнисе

үлеп китә. Шулай итеп, ул тома ятимгә әйләнә.

...Татарстан радиосының тапшырулары дәвам итә. Мәхмүт ага күңелләрне тетрәндерерлек итеп сөйли дә сөйли:

— Елдан артык Герман оккупациясе җирендә — балалар йортында булдым, әле безнекендә түгел — Герман детдомында, Белгородта. Шартлар авыр булуга карамастан, анда рояль бар иде. Тәрбияче миңа гына уйнарга рөхсәт итте. Чөнки мин Донбасста вакытта ук аккордеонда, бандурада, балалайкада да, думбрада уйный беләидем.

Ә инде якташыбызның Белгородтан җәяүләп диярлек туган якларына ничек кайтуын тасвирлау өчен шактый кәгазь битләре кирәк булыр иде.

Кыскасы, исән-сау Татарстан туфрагына аяк баскач, яшүсмер егет бер ел балта остасы һөнәренә укый, аннары Юдинодагы тимер юл училищесына керә. Анда бик яхшы оркестр була. Мәхмүт шуның составында уйный. Аннары аны, укуын дәвам итү өчен, Мәскәү тимер юл техникумына җибәрәләр. Биредә инде үзе үзешчән оркестр оештыра, төрле курсларга йөри. Тиешле белемен алгач, үзе тәмамлаган Юдино тимер юл училищесында мастер һәм педагог булып эшли башлый, бераз соңрак Казан дәүләт университетының физика-математика факультетына читтән торып укырга керә. Анда өч ел укыгач, консерваториягә күчәргә карар кыла. Бу вакытта инде якташыбызның язган әсәрләре дә була. 1958 елда ул «Татар халык көйләрен эшкәртүдә гармония үзенчәлекләре» дигән темага диплом эше яклый, һәм ул 1964 елда, киңәйтелеп, «Татарская народная песня в обработке композиторов» дигән исем белән китап булып чыга. Озакламыйча Мәхмүт аганың фәнни эшчәнлеге башлана, аны Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына чакыралар. Ул, татар халык музыкасы тарихын язу өчен, элеккеге СССР буйлап этнографик экспедицияләр оештыра башлый. Казан, Ленинград, Мәскәү архивларын өйрәнеп, 1966 елда «Татар халык музыкасы» исемле фәнни-этнографик хезмәтен яза. Тора-бара «Татарские народные песни» (1970), «Татарстан музыкасы» (1970), «Татар халык җырлары» (1976), «Народные песни волжских татар» (Мәскәү, 1982), «Татарские народные песни» (1984) дигән китаплары һәм бик күп фәнни мәкаләләре, монографияләре дөнья күрә.

1968 елда КПСС өлкә комитеты аны Г.Тукай исемендәге филармониягә сәнгать җитәкчесе итеп билгели, Татарстанның 50 еллыгы уңаеннан Мәскәүдә декадада катнашу үткәрү бурычын куя. Бу имтиханны да уңышлы уза Мәхмүт Нигъмәтҗан улы.

Аннары озак еллар Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни эшен, Казан педагогика университетында һәм Арча педколледжында укучыларга белем бирүен дәвам итә, тәҗел проблемалар күтәрә, һәр өлкәдә принципиальлек күрсәтә. Галим хәзер дә милли мәктәпләр, училище һәм югары уку йортлары өчен гомум музыка теориясе, милли сәнгать буенча татар телендә дәреслекләр, күргәзмә әсбаплар әзерләү өстендә эшли.

*2000*

# Мәңге яшәр Әлмәндәр

Бу көннәр онытылмас вакыйгалары белән истә калачак. Бай тарихлы Саба җире үзенең талантлы улы — СССРның халык артисты Шәүкәт Хәсән улы Биктимеровны, аның сәхнәдәш дусларын кабул итә. Татарның бөек артисты Шәүкәт аганың ярты гасырлык эшчәнлегенә багышланган тантана-хөрмәтләүнең туган ягында башланып китүе сабалыларга җаваплылык та, горурлык та өсти. Шәүкәт Биктимеровның бенефисы әти-бабасының нигезе булган, үзе уйнап үскән Миңгәрдә һәм район үзәгендә булачак. Без шушы истәлекле очрашулар уңаеннан Россия Федерациясенең Константин Станиславский исемендәге, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге премияләре лауреаты, танылган якташыбыз белән Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында — Шәүкәт аганың грим бүлмәсендә сөйләшеп утырдык. Ул көнне «Сагыш» спектаклендә уйнарга тиеш иде мәшһүр артист. Тыйнак кына бүлмә, кичке спектакльгә кирәкле киемнәр кертеп куелган. Менә шушы бүлмәдән 1986 елдан — үзе яңа бинаның символик ачкычын кабул итеп алганнан бирле сәхнәгә чыга икән ул...

**— Шәүкәт ага, Сезнең актерлык эшчәнлегегез белән якташларыгыз, нигездә, таныш. Чөнки Сез тудырган һәрбер образ белән диярлек театрга килеп яисә радио-телевидение аша танышып баралар. Шуңа күрә сүзне балалык елларыгыздан башлыйк әле.**

— Әйе, минем ундүрт яшькәчә елларым Саба районында үтте. Дөрес, мин 1928 елда Казанда дөньяга килгәнмен. Әнине ул вакытта шәһәргә алып килгән булганнар. Шулай булса да, миндә нииндидер иҗатчы чаткылары бар икән, мин моның өчен авылга бурычлымын. Мин үземне чын авыл баласы дип саныйм. Миңгәрдә — минем әтиемнең кабере, төп йортыбыз шунда. Әти укытучы булгач, аны ике ел саен күчереп йөрттеләр. Шуңа күрә Миңгәр, Татар Икшермәсе, Сабай, Бигәнәй, Чәүкә (Чәбки-Саба), Тимершык авыллары бик якын миңа. Җидееллыкны Тимершыкта тәмамладым.

**— Сезнең сәнгатькә тартылу ничек булды?**

— Дөресен әйтим, мин артист булам дип хыялландым. Җиде класс белем белән кайда да укырга кирәк булган өчен, театр техникумына барып кердем. Әлбәттә, моңа алшартлар булгандыр. Минем әни дә укытучы иде. Бабай (әтинең әтисе), указ белән килеп, Миңгәрдә муллалык иткән. Мәктәптә укыганда, концерт-театрлар куя идек. Авылга килгән артистларны безгә кертәләр иде. Өй иркен булгангадыр инде. Алар белән аралаша идем. Нәселдә дә сәнгатькә тартылган кешеләр бар иде. Татар дәүләт академия театрының күренекле шәхесе, Россиянең халык, Татарстанның атказанган артисткасы Галимә Ибраһимова әти ягыннан якын туган иде. Аның ире дә, минем җизни була инде, Гай Таһиров танылган балетмейстер бит. Казанга баргач, мине алар төрле тамашаларга йөртәләр иде.

Әлбәттә, балалык еллары җиңел булмады, мин өч яшьтә вакытта әни үлде. Әти яңа гаилә корды. Яшь әни үз анам кебек тәрбияләде, мин аңа гомер буе бурычлы һәм рәхмәтле. Сугыш елларында беркемгә дә рәхәт булмады. Әти яраланып кайтты. Кеше күргәнне без дә күрдек инде.

Менә шулай итеп мин 1945 елның язында театр техникумына имтихан тоттым. Буйга кечкенә идем. Әти дә барган иде. Аны авылда Озын Хәсән дип йөрттеләр. Әтигә карадылар да мине дә, үсәр әле, диделәр. Шулай итеп, хәзерге танылган нәфис сүз остасы Айрат Арсланов, аның җәмәгате — диктор Мәрьям Арсланова, радиорежиссер Госман Әхмәтҗанов, баянчы Рәис Сафиуллин кебек шәхесләр белән укып киттем. 1949 елда техникумны тәмамладык. Берничә кешене Г.Камал театрына алдылар. Шунда эшли башладым. Мин инде анда 1946–1947 елларда ук кайбер рольләрне башкара идем. Шул еллар белән минем сәхнә эшчәнлегем илле елга тарта. Иң беренче Сергей Михалковның «Кызыл галстук» дигән спектаклендә уйнадым. Аннары Саба кияве Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт»ендәге Тәлгат роле бик яратып башкарылды. Шуннан китте инде: башта малайлар, аннары ир-ат, хәзер бабайлар рольләре...

**— Шәүкәт ага, театрдан китү турында уйлаганыгыз булмадымы?**

— Булып алды. 1949 елда армия хезмәтенә вакыт җитте. Бронь дә биргәннәр иде. Гел артист булып йөреп булмас, мин әйтәм. Армиядә офицерлыкка укыйм әле. Апамның бер малае да офицер иде. Киемнәре шәп. Кызыктыра, малай. Шуннан армиягә барып, укый-укый сержант дәрәҗәсенә җиткәч, андагы тормыштан гайрәт чикте. Булмыйм офицер, дим. Кайтып яңадан үз театрымда эшли башладым. Дипломым бар бит. Менә шуннан соң бер йөз иллеләп образ тудырылган.

**— Шәүкәт ага, әйткәнемчә, Сез китап укучыларны сәхнәдән тыш тормышыгыз белән күбрәк таныштырсагыз иде. Буш вакытларыгыз ничек үтә? Бармы ул?**

— Юк диярлек. Чөнки гел зур рольләр уйнарга туры килде. Кайбер спектакльләргә кырыгар бит текст ятлыйсы булды. Безнең сәгатьле эш түгел бит, иҗат белән янасың. Көндез — репетиция, кич — сәхнә. Сезонга алтышар спектакль чыгара идек. Аннары, буш вакыт булдымы, телевидениегә, радиога йөгерәсең. Ул елларда яздырып алу дигән нәрсә юк, турыдан-туры телевизор экранына яки радиога чыгасың. Моның җаваплылыгы бик зур иде. Гариф Ахуновның «Хәзинә» романы буенча эшләнгән киногa төштем бит. «Муса», «Ак чәчәкләр» романнары буенча телеспектакльләр чыгардык. Бер тапкыр «Ленфильм»да төштем. Кинодубляжларда да күп тәрҗемә ясадым. Ленин катнашкан фильмнарны миңа эшләргә туры килде. Аннары инде сәхнәдә дә Юлбашчы образын шактый иҗат иттем. Менә әле хәзер дә Булат Мансуровның «Болгарның җылы җилләре» дигән татар халкының тарихына багышланган фильмга көтәләр. Җитешә алмыйм әле. Гел шулай буш вакытым, икенче төрле әйтсәк, хоббием булмады диярлек минем. Репетиция, сәхнә, радио-телевидение — гомер шулай үтеп бара. Әле бакча алганга да күп түгел, хәзер анда да эшли алмыйм. Барып-кайтып йөрибез. Дөрес, җай чыкса, гөмбә җыярга яратам. Миңгәр урманына кайткалаган вакыт та булды. Мин, үзем белән гаилә йә өлкән яшьтәге кеше булмаса, Сабадан җәяүләп, туктый-туктый кайта идем. Сагындыра бит бала вакытта йөргән сукмаклар...

**— Гаилә хәлегезгә тукталсагыз иде.**

— Гомерлек җәмәгатем Рәмзия белән театр техникумын бергә тәмамладык. Ул да актриса иде. Әмма гаиләне саклап калу хакына аңа сәхнәне ташларга туры килде. 1954 елда кызыбыз Гүзәл туды. Ничек икәүләп сәхнәдә, бигрәк тә гастрольләргә йөрисең, баланы кайда калдырасың?.. Шулай итеп, ул, башта Казан университетын, соңрак Мәскәүдә китапханә эше буенча институт тәмамлап, КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында озак еллар китапханә мөдире булып эшләде. Искәндәр исемле улыбыз да бар. Хәзер дүрт оныкүстерәбез.

**— Шәүкәт ага, КПСС өлкә комитеты үткәргән бер зур җыелышта Сезнең, театрның партия оешмасы секретаре буларак, бик тәэсирле чыгышыгызны тыңлаганым бар. Җәмәгать эшләрегез турында берничә сүз әйтсәгез иде.**

— Алар күп инде. Мин унике ел башлангыч партия оешмасын җитәкләдем. Бу — заманында бик җаваплы, күп вакыт сорый торган эш иде. Аннары ике тапкыр шәһәр Советы, берәр тапкыр Татарстан, СССР Верховный Советы депутатлары булып сайландым. Наказлар артыннан да күп йөрергә туры килде. Шунысы гына кызганыч: Сабадан сайланмагач, районыбыз өчен игелекле эш майтара алмадым. Монысы өчен үкенәм, әлбәттә.

**— Иң яратып башкарган ролегез?**

— Әлбәттә, Әлмәндәр инде. Бик популярлашып китте бит ул. Моңа Мәскәү телевидениесе дә тәэ-

сир итте. Егерме елдан артык уйныйм инде мин ул туксан яшьлек картны. Өч йөздән артык мәртәбә куелды. Шуңа күрә Шәүкәт дигән исемем онытылып бара. «Нихәл, Әлмәндәр бабай?» дип исәнләшәләр. Бу спектакльдән өзекләр дә күп уйналды. Илһам Шакиров, Азат Аббасов кебек шәхесләрнең юбилейларына Әлмәндәр булып котлаулар да халык күңеленә хуш килде.

**— Шәүкәт ага, сүзегезне йомгаклап, укучыларга нәрсә әйтер идегез?**

— Мин Саба сәхнәсендә, бигрәк тә элеккеге мәчет бинасында, бик күп спектакльләр уйнадым. Якташларым гел яратып кабул иттеләр. Шуңа күрә гомер буе сәнгатьне үз иткән, театр яраткан сабалыларның үзләренә дә озын гомер, мул тормыш, җан тынычлыгы юллап, безнең соңгы очрашуыбыз булмасын иде әле дигән иң изге теләктә калам.

**— Рәхмәт Сезгә, Шәүкәт ага! Ата-бабалар җирендә очрашканчыга кадәр.**

*1996*

# Профессорлар гаиләсе

Байлар Сабасында туып үсеп, мәркәзебез Казанда яшәүче һәм иҗат итүче якташларыбыз байтак. Гомумән, безнең як туфрагы бик уңдырышлы булып, илебезгә бик күп әдәбият һәм сәнгать әһелләре биргән ул. Бүген сүзем шуларның берсе — олы галим Азат Гыйльмулла улы Әхмәдуллин турында. Ул фәкать үз тырышлыгы, хезмәт яратуы белән Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты профессоры, КДУның һәм КДПУның татар әдәбияты кафедрасы мөдире дәрәҗәләренә күтәрелде. Тәнкыйтьче булып танылды. Бик күп әдәбият дәреслекләре авторы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Озак елларга сузылган драматургия өлкәсендәге фәнни эшчәнлеге гадел бәяләнеп, аңа «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем һәм К.Насыйри исемендәге премия бирелде, «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә дә лаек булды.

Без, сабалылар, Әхмәдуллиннар гаиләсенең галимнәр берлеге икәнен, ягъни Азат аганың җәмәгате Фирая Юнысовнаның профессор, педагогика университетының кафедра мөдире, бик күп фәнни эшләр авторы булуын да яхшы беләбез.

...Хәзерге мәчет ишегалдындагы җәйге театрда, төрле тантаналы кичәләрдә, шулай ук милли бәйрәмебез — сабантуйларда — тынлы оркестр составындагы беренче трубада уйнаучы зәңгәр күзле, түгәрәк кенә малайны тора-бара шулай фән биеклекләренә күтәрелер дип кем уйлаган?!

Әйе, кечкенәдән музыка ярата, сәхнәгә тартыла, курайлар ясый ул. Классташы Рифат Свеигин янына барып, гармунда уйнарга өйрәнә. Соңыннан алар гомер буе әдәбият өлкәсендә бергә эшлиләр. Свеигиннар киң күңелле була, венский гармуннарын өйгә дә биреп торалар. Азатның бу омтылышын күреп, Дилшатбану апа белән Гыйльмулла абый, соңгы акчаларын җыеп, немецлардан трофей булып кайткан кечкенә аккордеонны базардан сатып алып бирәләр.

Әйе, зыялы гаиләдә туа Азат. Шулай булмаса, сигез айлык вакытта төшерелгән фото шушы көнгә кадәр сакланыр идеме? Гыйльмулла аганы, район оешуга, башкарма комитет сәркатибе итеп сайлыйлар да тиздән «Колхоз байрагы» дип исемләнгән яңа газетаның җаваплы секретаре итеп күчерәләр. Ул, Казаннан килгән редактор Зыя Маликов белән бергәләп, район елъязмасының тәүге санын чыгара. Соңыннан Гыйльмулла абый «Кызыл Армия», Кукмара районнары газеталарын җитәкли. «Халык дошманы» дигән яла аңа да тагыла, гаепсезлеге расланып төрмәдән чыгарылгач, Тархан районы газетасы редакторы итеп раслана. Азат беренче сыйныфка шунда керә.

Кешеләрнең уй-гамәлләрен, планлаштырган эшләрен җимереп, дәһшәтле көннәр — канкойгыч сугыш башлана. Гыйльмулла ага, гаиләсенә Сабага кайтырга кушып, үз теләге белән фронтка китә һәм 1945 елның кышында (II группа инвалидлык бирелә) кайта, аннары шактый еллар район газетасында редактор һәм җаваплы сәркатип булып эшли. Ә әниләре Дилшатбану апа — итагатьле, иманлы, кешелекле хуҗабикә — аш-су остасы була. Гомеренең күп өлешен җәмәгать туклануы системасында хезмәт куеп үткәрә. Уллары Азатка, Эдуардка, Рафаэльгә, кызы Рушаниягә ана назы, белем һәм үрнәк тәрбия бирү өчен бөтен көчен куя.

Тормышның авырлыгы олы балага төшүчән. Азат та җәйге каникул вакытларында колхозда атлар көтә, кырдан ашлык ташый, комбайнчы ярдәмчесе була. Җәмәгать эшләрендә актив катнаша. ВЛКСМ райкомы әгъзасы итеп тә сайлана. Кыскасы, гармунда, аккордеонда, баянда, балалайкада, гитарада, үзе ясаган курайда уйнавы белән һәр чараның үзәгендә кайный, спектакльләрдә катнаша. Югары классларда укыганда «Аулак өй»ләр дә аңардан башка узмый. Үзе, шук булса да, бик яхшы укый, кечкенәдән матур әдәбият җене кагыла. Русча китаплар да үзенә тарта. Мәктәпнең ул чордагы завучы Бари ага Ишалин Азатта математикага мәхәббәт уята. Шуңа күрә ул, кулына аттестат алгач, Шекше авылы мәктәбендә математика һәм физика укыта, класс җитәкчесе була. Әдәбиятка һәм сәнгатькә мәхәббәт аны бер елдан Казан университетының татар филологиясе бүлегенә алып килә. 1956 елда ул аны кызыл дипломга тәмамлап, җәен өч ай Татарстан китап нәшриятында эшләп ала да, Төмән өлкәсенең Тубыл шәһәре педагогия институтына китә. Студент елларында да ул яхшы укуы белән беррәттән (Габдулла

Тукай исемендәге дәрәҗәле стипендия ала), тынлы оркестрда уйный, спектакльләрдә аңа төп рольләр бирелә. Соңгы курсларда фән белән шөгыльләнә башлый. Бишенче курста ук аның Ф.Әмирхан иҗатына караган хезмәте студентлар эшләре арасында җиңеп чыга һәм диплом белән бүләкләнә.

Тубылда ул үзеннән алданрак килеп укыта башлаган доцент Фәрит Хатипов, өлкән укытучы Гомәр Саттаров, кафедра мөдире Габделхәй Әхәтов һәм башкалар белән уртак тел тиз таба. Бергәләп К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» музыкаль мелодрамасын сәхнәләштерәләр. Режиссер А.Әхмәдуллин үзе (ул бик матур җырлый да) — Булат ролендә, Ф.Хатипов авыл карты Байгура булып, Г.Саттаров Җиһаншаны уңышлы уйнап, тамашачыны таң калдыралар.

Язмабыз герое, этисеннән күчкән кан белән, «Ленин юлы» дип исемләнгән Себердә беренче татар газетасын оештырып җибәрә, вакытлыча аның җаваплы сәркатибе була.

Әмма Азат Гыйльмулла улы үзенең киләчәген фәннән башка күз алдына китерә алмый. Казанга кайтып, 1958–1961 елларда Тел, әдәбият һәм тарих институтындагы аспирантурада укый. Аны тәмамлагач, ике елга якын Татарстан радиокомитетында сәнгатьле тапшырулар буенча баш мөхәррир, аннары Тел, әдәбият һәм тарих институтында гыйльми секретарь, ә 1972–1981 елларда институт директорының фәнни эшләр буенча урынбасары булып эшли, унтугыз ел буе Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасын җитәкли.

Ул 1964 елда «Фәтхи Бурнаш драматургиясе» дигән темага кандидатлык, 1987 елда Алма-Атага барып, филология фәннәре докторы диссертацияләрен яклый, икенче елны профессор исеме дә бирелә. 2000 елның башыннан А.Әхмәдуллин, төп эш урыныннан — Казан дәүләт университеты профессоры вазифасыннан аерылмый эшләү тәртибендә, Казан дәүләт педагогика университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире вазифаларын да башкара. Хәзер үзе әзерләгән фән докторлары һәм кандидатлары белән кулга-кул тотынып эшли.

Галимнең иҗат биографиясе белән җентекләп танышу өчен шактый вакыт кирәк. Китапларының һәм матбугатта басылган хезмәтләренең исемлеген барлаганда моны ачык күрәсең. Чөнки якташыбыз гел эзләнә. А.Әхмәдуллинның «Фәтхи Бурнаш», «Ничек сурәтләргә сине, замандаш?», «Сәхнә әдәбияты һәм тормыш», рус телендәге «Татарская драматургия» (Мәскәүдә нәшер ителгән), «Горизонты татарской драмы» дигән китаплары әдәбият белеменә аеруча зур өлеш кертте. А.Әхмәдуллин алты томлык «Татар әдәбияты тарихы», «Әдәбият баскычлары», «Татар совет театры» һәм башка шундый китапларны язуның инициаторы, бу басмаларның, татар әдәбияты классиклары күптомлыкларының редакторы булды. Чал тарихлы Казан дәүләт университетының кафедрасын җитәкләгәндә күмәк хезмәтләр әзерләп бастырды, автордаш та, редактор да булды. Шунысын әйтү җитә: матбугатта басылган 370 хезмәтенең 155 ен шул чорда яза, ул редакцияләнгән 75 хезмәтнең 50 гә якыны әлеге елларга карый.

Якташыбызның һәр тармактагы эшчәнлегенә бу язмада гына иркенләп тукталу мөмкин дә түгел. Аның иҗат гомерендә күп көч һәм вакыт сарыф иткән өлкәгә — дәреслекләр һәм уку әсбаплары язу-төзү мәсьәләләрен яктыртмасак, һич дөрес булмас. Аның IX класс өчен М.Хәсәнов һәм И.Нуруллин белән бергә язылган дәреслеге 1970 елда басылып чыга, шуннан соң төрле үзгәрешләр һәм төзәтүләр белән унбиш мәртәбә дөнья күрә. Соңгы басмалар А.Әхмәдуллин редакциясендә эшләнә. Ә күренекле татар галимнәре Х.Госман, Г.Халит, Г.Кашшаф, Х.Хәйри, А.Сайганов, Н.Юзиев белән бергәләп язылган X класс дәреслеге унике мәртәбә басыла. Бер үк вакытта Азат ага урта мәктәпләр өчен татар әдәбияты буенча яңартылган күп программалар төзи.

Татар энциклопедиясендә «Театр сәнгате» бүлеген җитәкли. Халкыбызның рухи мирасы аның өчен һәрвакыт җан азыгы булып тора. Тынгысыз, ихлас күңелле, һәр мәсьәләдә принципиаль булган Азат Гыйльмулла улының башка төрле җәмәгать эшләре дә бихисап. Озак еллар Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комитеты, Язучылар берлеге президиумы әгъзалары, СССР әдәбият фондының Татарстан бүлеге рәисе вазифаларын алып бара. Татарстан Мәдәният министрлыгы янындагы яңа спектакльләр һәм концерт программаларын кабул итү комиссиясендә эшли. Күп журналларның редколлегия әгъзасы була.

Галимнең Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы (1994 елдан) буларак та өстәмә җәмәгать эшләре күп.

Ул — 1981 елдан бирле Тел, әдәбият һәм тарих (хәзер — сәнгать) институты каршындагы баштарак кандидатлык диссертацияләре, соңрак докторлык диссертацияләре яклау советларының, ә 1991 елдан Казан дәүләт университеты каршындагы докторлык диссертациясе яклау советы әгъзасы.

Кыскасы, тарих, фән пьедесталындагы шәхес ул язмабыз герое. «Эш агачы һәрвакыт мул бирер җимеш» дип әйтергә яратабыз икән, монда аның гаиләсенең роленә дә тиешле бәяне бирергә кирәктер. Гомер буе «тылы» нык була Азат Гыйльмулла улының. Үзе кебек зәңгәр күзле, сабыр холыклы, ир һәм балалар җанлы Фирая белән яшьтән үк танышалар һәм язмышларын бергә бәйлиләр алар. Фирая Юныс кызы Ярмөхәммәтованың әти-әниләре чыгышлары белән Апас ягыннан була. Казан дәүләт университетының рус теле һәм әдәбият бүлеген тәмамлагач, шәһәрнең 7нче интернат-мәктәбендә рус теле укытучысы булып эшли башлый яшь белгеч. Тора-бара фәнгә ире Азат тартып кертә аны. Биш ел чамасы Казан авыл хуҗалыгы институтында укытып ала Фирая ханым. 1970 елда Казан педагогия институты рус

теле укытучылары арасында конкурс игълан итә. Шул бәйгедә бәхет елмая Фирая Әхмәдуллинага. Пединститутта укыта башлый ул, кандидатлык диссертациясе дә яклый. Хәзер Фирая ханым Казан педагогика университетының милли мәктәптә рус теле укыту кафедрасын җитәкли, Татарстанның атказанган укытучысы.

«Киләчәгең нинди буласын беләсең килсә, балаларыңа кара» дигән борынгылар. Уллары Айдар һәм кызлары Ләйлә әти-әниләрен оныклар сөю бәхетенә ирештереп, үзләре оя корып яши хәзер. Айдар — хәрби табиб. Майор. Киленнәре Сәгыйдә Кәрим кызы да озак еллар «Казан» санаториенда табибә булып эшли. Кияүләре Шамил Нуретдинов — математика фәннәре кандидаты, Казан дәүләт университеты доценты. Кызлары Ләйлә, тарих-филология факультетын тәмамлап, үз белгечлеге буенча эшли. Өч оныклары бар Әхмәдуллиннарның. Лия берьюлы ике институтта укып сөендерә әби-бабасын, әти-әнисен. Әдилә белән Диләрә әлегә мәктәптә белем алалар.

Әхмәдуллиннар һәм Ярмөхәммәтовлар нәселендә фән кешеләре, педагоглар, хәрбиләр, табиблар байтак. Туган яклары, торган җирләре, эшләгән урыннары белән горурланып яшиләр алар. Гаилә башлыгы Азат Гыйльмулла улын Сабада — гает бәйрәмнәрендә мәчеттә, үзе укыган мәктәптә, үскән нигезендә, ата-бабалары җирләнгән зиратта очратырга була.

— Туган яктан да кадерлерәк җир юк, — дигән иде ул бер сөйләшеп утырганда. — Чөнки монда синең кендек каның тамган, бала чагың, яшьлегең үткән, якыннарың җирләнгән. Шуңа күрә сагынып кайтам. Соңгы еллардагы үзгәрешләрне күреп сөенәм. Дөрестән дә, Байлар Сабасына байлар төсе керде. Район хакимиятенең хәзерге башлыгы Рәис Нургали улына без, якташлары, зур эшләре өчен бик тә рәхмәтлебез. Исән-сау булып, озак еллар эшләргә насыйп булсын аңа...

Туган ягына үз машинасында кайтырга ярата Азат Гыйльмулла улы. «Волга-21»не техниканың иң кадерле заманнарында — алтмышынчы еллар азагында ук ала ул. Тора-бара «Волга-24» тә, «Жигули» дә күргәләргә туры килә. Хәзер «Нива»да йөри. Бер очраганда байтак әдәби китаплар, дәреслекләр, уку ярдәмлекләре төягән иде машинасына. Үзе укыган мәктәпнең китапханәсе өчен мондый изге гамәлне беренче генә кылуы түгел икән инде аның.

...Һәр көнне диярлек мәркәзебез Казанның Николаев урамындагы өйдән (Тукай һәйкәле артында гына ул) ике профессор — Фирая һәм Азат Әхмәдуллиннар эш урыннарына юнәләләр. Галим һәм язучы Нәкый Исәнбәт, композиторлар Хөснулла Вәлиуллин, Мансур Мозаффаров, Заһит Хәбибуллин, атаклы режиссер Шириаздан Сарымсаков, шагыйрь Илгиз Кәримуллин, легендар җырчы Илһам Шакиров кебек шәхесләрне үзенә сыендырган бу йорт менә кырык ел инде безнең якташларыбызны иртән озатып, кичен каршы ала.

Әйе, туган ягын онытмый якташыбыз. Балалар иҗат үзәгендә һәм үзе укыган Саба урта мәктәбендә «Бер очрашу — үзе бер гомер» дип исемләнгән шигъри-музыкалы тамашалар булды. Анда кичә герое Азат аганың классташлары, районның татар теле һәм әдәбияты укытучылары, гомумән, галимне хөрмәт итүчеләр күп җыелган иде. Бик күп хатирәләр яңарды бу көнне.

— Бик зур бәйрәм ясадыгыз минем өчен. Дөрес, үз гомеремдә төрле дәрәҗәдәге тантаналарда катнашканым булды. Әмма туган ягымда, кендек каным тамган авылымда берьюлы ике кичәдә хөрмәтләнү мәңге күңелемнән чыкмас. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте яусын сезгә, сау-сәламәт булыгыз, — диде Азат Гыйльмулла улы үзенең йомгаклау сүзендә.

*2002*

# Фәрештәләр рәхмәт укыр

Бу язманы шагыйрә һәм галимә Рифә Рахман сүзләре белән башлап җибәрсәк, урынлы булыр. Ул болай дип яза: «Үзенең тыйнаклыгы, гадилеге аркасында хезмәтләре тиешенчә бәяләнмәгән, халыкта бик үк билгеле булмаган шәхесләр бар. Алар арасында мин Рифат Хәсән улы Сверигинны да күрәм. Ул Казан дәүләт педагогика университетында әдәбият укыта, үз гомерендә әллә никадәр студентка танылу юлы сызып биргән, кемнәрнедер, җитәкләп, әдәбият дөньясына алып чыккан, талантны вакытында күреп алып, ярдәм кулын сузган кеше...»

Дөрестән дә, Рифат абыйның олы юбилее якынлашканын белгәч, 1992 елгы газета теркәмәләренә күз салдым.

Үзебезнең «Саба таңнары»нда да, республика матбугатында да аның алтмыш яше «онытылган» икән шул. Ә бит мәгариф, әдәбият өлкәсендә гомере буе хезмәт итеп, игелекле эш башкарган кешегә күп тә кирәкмидер. Бер җылы сүз катлаулы тормышны җиңеләйтеп, киеренкелекне йомшартып, кабат яшәртеп җибәргәндәй итәргә мөмкин. Олыгайган саен, күңел нечкәрә бара бит. «Гомер уза аккан сулар кебек» дип җырлаулар да юкка түгел. Үзенең үткән тормыш юлын, авыр чорга туры килгән балалык елларын исенә төшерергә ярата Рифат ага. Аның әти-әнисе тумышы белән Кукмара районының Түбән Өскебаш авылыннан була. Узган гасыр яшьтәше Хәсән ага Лубян урман техникумын тәмамлаганнан

соң, Мамадыш, Норлат (хәзер Яшел Үзән районына керә), Кызыл юл (Яңа Кенәр) районнарында партия-совет органнарында эшли. Гражданнар сугышында да катнаша. Партия мәктәбендә белемен арттыра. Әниләре Латыйфа бик тә мәрхәмәтле, иманлы, чиста-пөхтә татар хатыны була. Балаларына кешелеклелек, рухи ныклык, югары әхлак, игелек кебек сыйфатларны яшьтән сеңдерә. Бу гаиләгә ике тапкыр килергә туры килә Байлар Сабасына. Беренчесендә — утызынчы еллар башында — Хәсән Свериginны район эчке эшләр бүлеге башлыгы итеп җибәрәләр. Шул вакытта биредә 1932 елда аларның өченче балалары Рифат туа. Җаны-тәне белән эшкә бирелгән партия солдатын бер районнан икенчесенә күчереп йөртүне дәвам итәләр. 1946 елда КПСС райкомының икенче секретаре итеп кабат Байлар Сабасына кайтаралар аны. Шактый еллар районның төп идеологы вазифасын алып барганнан соң, ул социаль тәэминат бүлеге мөдире итеп күчерелә. Кыскасы, ирле-хатынлы Свериginнар шушы килүдән борынгы Саба җирендә мәңгелеккә калалар. VI класстан башлап Рифат авыл мәктәбендә белем ала. Шулай итеп, аның гөнаһсыз сабый чагы, риясыз яшьлеге шушында уза. Алар — уналты егет һәм кыз — 1950 елда кулларына өлгергәнлек аттестаты алалар. Алга узып шуны әйтергә кирәк: моннан берничә ел элек шуларның җидесе — Флера Мәҗитова, Мөнәвәрә Мостафина, Мансур Галиев, Госман Гарипов, Нәкыя Галимҗанова, Марсилә Хәлиуллина, Азат Әхмәдуллин һәм язмабыз герое Рифат Свериgin ярты гасырдан соң очрашып, яшьлек хатирәләрен уртаклаштылар, сөйләшеп сүзләре бетмәде. Алар фән биеклекләрен бергә яуладылар, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыдылар. Диплом алгач кына тормыш юллары аерылып тора. Рифатны Аксубай районының данлыклы Иске Ибрай урта мәктәбенә катгый бүленеш буенча эшкә җибәрәләр.

Юлсызлыктан тәмам җәфа чиккән Аксубай якларына барып җитүгә, КПСС райкомына — Волков фамилияле беренче секретарьга алып керәләр Рифат Хәсәновичны ...Һәм мәктәпкә директор булып барырга тәкъдим итәләр. Теше-тырнагы белән каршы тора яшь белгеч. Үзенең, кем әйтмешли, практика вакытында гына дәрес укыткан килеш директор кәнәфиенә лаек түгеллеген җаны-тәне белән аңлата, бәхәскә керә.

— Бар, чык! — дип әйтергә мәҗбүр була иптәш Волков туры сүзле, үҗәт егетне «сындыра» алмагач.

Иске Ибрайда алай канат җәеп каршы алмыйлар үзен. Директор татар теле һәм әдәбият укытучысына әллә ялгышып заявка биргән була... Бу фәннәрдән атнага уникe сәгать кенә дәрес җыйнала, калганын немец теле белән тутыралар. Уку елы башланып озак та үтми, мәгариф бүлегеннән инспекторлар килеп төшә. Шуларның берсе немец теле дәресен сайлый. Кереп утыра өлкән яшьтәге инспектор абый, дикъкать белән тыңлый. Соңыннан бик яхшы итеп анализ ясый дәрескә.

— Произношениегез, ягъни сүзләрне әйтүегез камил түгел, — ди бу.

Каян килеп дөрес булсын инде ул! Мәктәптә һәм университетта имтихан бирерлек кенә укылган фән бит. Сугыш вакытында тәрҗемәче ролен башкарган зыялы белгеч өметле яшь егеткә киңәшләрен бирә, Германиядә чыга торган «Дойчланд» газетасына язылырга куша, үзендә булган немецча пластинка тәлинкәләре бирергә вәгъдә итә. Чын «нимес» ясарга уйлый бу Рифаттан.

Шулай итеп, Рифат Хәсән улы укыту-тәрбия эшләренә кереп чума. Немец телен үзе дә өйрәнә, балаларны да укыта. Аның өстенә җәмәгать эшләре дә өяләр яшь белгечкә. Командалар туплап, малайларны футбол уйнарга өйрәтә. Менә шулай ихлас күңелдән эшкә алынып, берара әти-әнисенә хат язарга да онытып җибәрә ул.

Әтисе борчылып беренче секретарь Волковның үзенә шалтырата.

— Малаегыз миндә булды. Югала торган түгел. Бик тере күренә ул! — дип, сүзне кыска тота район хуҗасы.

Белемле, таләпчән, ыспай, тәртипле-әдәпле, тырыш булуы белән педагогик коллективка тиз кереп китә Рифат. Директор белән дә уртак телне тиз таба. Үзе кебек яшь белгечләр җитенкерәми Иске Ибрайга. Шуннан мәктәпне мактап «Советская Татария» газетасына мәкалә яза Свериgin (русчасы да камил була аның). Янәсе, менә дигән мәктәп! Эшләү һәм яшәү өчен шартлар җитәрлек. Килегез...

Шул хәбәрне укый бит Римма исемле кыз һәм физика-математика белгечлеге дипломы белән Иске Ибрайга килеп төшә. Тиз арада танышып та ала болар. Үзенең тотышы, тәртип-әдәпләре, чибәрлеге белән гашыйк иттерә яшь мөгаллимә. Рифат өчен якты бер җисемгә әйләнеп, күктән нур сипкәндәй итә ул. Дуслык чын мәхәббәткә әйләнә. Шулай булмыйча мөмкин дә түгел бит: газета аша чакырып китергәч!

Өлешеңә тигән көмешең дигәндәй, озакламый никахлашып, бер җан булып яши башлыйлар алар.

Намуслы хезмәт белән өретелгән гомер сукмаклары бормалы була Свериginнарның. Рәхәт булса да торган җир, сагындыра туган җир дигәндәй, үз якларына кайтасы килә боларның. Кукмараның тәҗрибәле мәгариф бүлеге мөдире Павел Башаев бишкуллап каршы ала белгечләрне һәм тимер юлдан шактый эчкәре булган Оштorma-Юмья урта мәктәбенә юнәлдерә боларны. Каенсар станциясеннән шушы авылга тәпили башлыйлар Свериginнар. Рифат удмурт балаларын рус теленә өйрәтергә тиеш була. Һай, афәрин, тырышсаң, мөмкин икән бит! Тегендә — немец теле, монда — рус. Ә диплом татар филологыныкы... Риммасына да үз фәне өстенә астрономияне дә өстиләр. Тормышлары да бераз тернәкләнә

башлый аларның. Велосипед алып җибәрәләр. Шуның белән урман кырыйлатып атна саен диярлек Сабага — әти-әнисе, туганнары янына элдертә Рифат. Кышын чаңгыга баса. Өлкәннәрнең хәлләрен белә, берочтан иң хәләл ризык — ипи дә ала килә пекарнясыз авылга. Шунда эшләгәндә, бик көтеп алынган уртак шатлык булып, олы уллары Рәшит дөньяга килә.

Булачак галимнең оештыру сәләтен тиз күреп алалар Кукмара җитәкчеләре. Танылган директор Рафак Якуповтан Ядегәр сигезьеллык мәктәбен кабул итеп алырга әмер бирелә Рифат Хәсәновичка. Яңа урынга ияләнеп кенә килгән вакытта, «Социалистик Татарстан» газетасындагы аспирантурага чакыру турындагы игъланга күзе төшә бер генә ел эшләгән директорның. Язмышын сынап карарга була ул. Бер урынга җиде кеше җыйнала конкурентлар. Еллар үткәч, аларның байтагы танылган язучылар, галимнәр була. Әмма хәзергә бәхет Рифат Сверигинга елмая. Немец теленнән бишле ала да конкурсантларын ике балга узып китә бит Иске Ибрай мәктәбендә бу телне су кебек эчәргә өйрәнгән педагог. И рәхмәт укый Аксубайдагы теге тылмач абыйга яшь аспирант. Рифат Хәсән улының тормыш мизгелләре шаулы мәктәптән Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына күчә. Шулай итеп, әдәбиятыбызның тарихын, телебезнең нечкәлекләрен, байлыгын, әдипләрнең язу үзенчәлекләрен өйрәнү чоры башлана. Бу 1961 ел була. Гали Халит, Хәсән Хәйри, Хатыйп Госман кебек таләпчән, яхшы ук усал галимнәр кул астында укый һәм эшли ул, соңга таба институтның турыдан-туры өлкә комитетка буйсына торган башлангыч оешмасын җитәкли партиянең дәрәҗәле һәм «каты куллы» заманында.

Ял көннәрендә, кич-иртәләрендә буш вакытларын сарыф итә-итә, якташыбыз Фатих Хөсни иҗатын өйрәнүгә багышлаган кандидатлык дессертациясен дә әзерләп, уңышлы гына яклый. Кырык яшьлек галимне шул ук 1972 елда Казан дәүләт педагогия институты ректоры, күренекле тел галиме Мирфатыйх ага Зәкиев эшкә чакыра. Шунда профессор дәрәҗәсенә күтәрелә.

Бу язмада әдәбият галименең фәнни эшчәнлегенә дә кыскача гына тукталып китмәсәк, бик үк дөрес булмастыр. Хәер, моның өчен аның фәнни һәм методик хезмәтләренә күз салу да җитә. Зур күләмлеләре генә дә утыздан артып китә аларның. Газеталарда басылган төрле характердагы рецензияләре ике дистәгә җыела. Бигрәк тә соңгы елларда дөнья күргән әдәби тәнкыйть мәкаләләре, киң җәмәгатьчелек алдында ясаган чыгышлары, докладлары игътибарга лаек. Аның хезмәтләре Төркиядә нәшер ителүче «Төрки халыклар әдәбиятлары» исемле күптомлыкта, «Татар энциклопедиясе»ндә дөнья күрәчәк әле. Рифат Сверигинның әдәбиятыбызга кагылышлы кайбер хезмәтләре 1974 елда ук Мәскәүдә нәшер ителгән «Күпмилләтле совет әдәбияты тарихы»ның алтынчы томына кертелгән була. Ул — берничә китап авторы. Язучыларның әдәби ел йомгакларына багышланган олы җыелышларында ике ел рәттән — 1999 ел һәм 2000 ел татар прозасы турында үзенчәлекле докладларын бу юлларның авторына да тыңларга насыйп булды. Заманында — моннан чирек гасыр элек үк — Габдрахман Әпсәләмов, Гариф Ахунов, Фатих Хөсни кебек өлкән язучылар аның «1977–1978 еллар татар прозасы» дигән докладына тиешле бәя биреп, әдәбиятчы-галимгә һәм тәнкыйтьчегә яңа иҗат уңышлары телиләр.

Рифат Сверигинның «Яңа герой һәм яңа алымнар» дип исемләнгән китабы да татар әдәби тәнкыйтендә җитди хезмәт булып кабул ителә. Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Фатих Хөсни, Рафаэль Төхфәтуллин, Атилла Расих кебек олпат әдипләребезнең заман герое сыйфатларын эзләү юнәлешендәге зур эшчәнлекләрен реаль чагылдыруга ирешә ул.

«Фатих Хөсни» исемле тәнкыйть-биографик очеркы (Татарстан китап нәшрияты, 1968) өчен дә якташ язучыбыз, чын каләм иясе, атаклы хикәяче Фатих ага үзенең гаять катлаулы һәм каршылыклы иҗат юлын, оригиналь язу стилен дөрес дәлилләгән өчен үзе исән вакытта ук кат-кат рәхмәт әйтә.

Рифат ага әдипләрнең язу осталыгы турында тагын бер китап чыгарырга ниятли. Аны бигрәк тә Мөхәммәт Мәһдиев, Айдар Хәлим, Миргазиян Юныс, Аяз Гыйләҗев, Рафаэль Сибат, авылдашы Мәгъсум Хуҗин кебек матур итеп яза белә торган әдипләрнең стиле уйландыра. Әдәбият галименең үз иҗаты белән кызыксынучылар да байтак. Мәсәлән, Харис Әшрәфҗанов «Тарихка әдәби сәяхәт» дигән китабында Рифат Сверигин хезмәтләрен еш искә ала.

Рифат Хәсән улының тормыш юлы, әдәби эшчәнлеге белән танышкан саен күңел байый, аңа карата ихтирам хисе арта. Әдәбият белән бергә, кино сәнгате, театр белән дә якыннан кызыксына икән ул. Радиотехника өлкәсенә дә «кереп чыккалый». Һади Такташ урамындагы тыйнак кына фатирында үзе җыйган-җайлаган радиоалгычлардан файдалана. Аның яшьтән үк иң яраткан шөгыле, икенче төрле әйтсәк, хоббие — йөгерү икән.

Студент елларыннан ук мавыга ул җиңел атлетика белән. Башта курсташы Рөстәм Галиев белән (ул озак еллар Кукмара мәгариф бүлегендә инспектор булып эшләде) тизлеккә, аннан чыдамлыкка (выносливость) йөгерә. Фәннәр академиясе филиалында эшләгән вакытта, 5–10 чакрымлы дистанцияләрдә беренче разрядлы чаңгычы Рифат ут уйната. 1969 елда Австралия тренеры Артур Лидьярдның «Яшәү хакына йөгерү» дигән китабын укыгач, яшәешне йөгерүдән, гомумән, спорттан башка күз алдына китерә алмый.

1989 елда ашказаны җәрәхәте белән чирләп китә язмабыз герое. Башта хастаханәдә дәвалана. Аннары шул хәрәкәт, йөгерү белән кан йөрешен тизләтеп, ул авырудан да котыла. Шул елда Мәскәүдә уздырылган 42 километрлы Халыкара марафонда катнаша.

— Тфү, тфү, күз тимәсен, — ди Рифат ага Сверигин, — хәрәкәттә булырга тырышам. Эшкә гел җәяү йөрим. Гомумән, гаилә белән яраттык без спортны. Улым Рәшит биеклеккә сикерү буенча ундүрт яшендә Татарстан чемпионы булды. Чиләбедәге хәрби улым Фәрит тә спортсмен иде. Бер елны үзем, җәмәгатем Римма, улым Рәшит, килен һәм онык — бишәү — бәйгедә катнашып, «Спорт сөюче иң яхшы гаилә» исеменә лаек булдык.

Әйе, күпләрне сокландыра торган гармоник гаилә була алар. Әмма... караңгы көзге көннәрнең берсендә тиз генә әйләнеп кайтам дип чыгып киткән җиреннән кире әйләнеп керергә насыйп булмый гаҗәеп дәрәҗәдәге киң күңелле, гаилә җанлы, педагог булып туган һәм ирен хөрмәт итеп гомер кичергән Римма ханымга. Юл чатында автомашина фаҗигасенә эләгә ул...

Бу мизгелләрдә әңгәмәне икенчегә борырга тырышам. Чөнки Рифат аганың керфекләрен күтәрә алмаслык хәсрәтле көннәр ачысы кабат баскандай булды...

Бераздан соң гына:

— Берничә ел үткәч, Риммага охшаган шәфкать туташы белән кавыштык. Характерыма хуш килде. Роза исемле ул. Әни урынына калган Сабадагы олы апам да Рауза бит. Аның да хәле әйбәт түгел. Урын өстендә, — дип өстәде.

Берәүнең дә тормыш казаны буш түгел шул. Сиксәнгә якынлашып килүче Рауза Хәсәновна да гомер буе башлангыч класста укытып, күпме балаларны тәүге тапкыр белем юлына бастырган, серле дөньяның ишеген ачып керткән, хәреф танырга, мисал чишәргә өйрәткән олы җанлы зат бит. Хәзер хәлен белергә кайткан саен, Рифат аганы: «Энем, сине күргәч, умырткаларымның авыртуы басылган кебек була», — дип каршыларга ярата. Дөрес, Рауза апаның тагын ике энесе бар. Алар да укымышлы затлар, офицерлар. Воткинск шәһәреннән Ринатлары кайтып китә, ә менә Равилләре еракта — Ташкентта ук калды шул...

Әңгәмәбез ахырында: «Рифат абый, сезнең берәр төрле бүләгегез бармы соң?» — дип, гадәти соравымны биргәнемне сизмичә дә калганмын.

— Хезмәт ветераны мин, — дип җавап бирде ул. — Иң олы бүләк шул...

Әйе, галим-укытучының дәрәҗәсен мактаулы исемнәр, дипломнар, орден-медальләр түгел, тормышта үз юлын тапкан студентлары билгели. Ә алар — бихисап.

Шул минутларда «Фәрештәләр — күктә, кырмыскалар — ояларында, балыклар суда мәрхәмәтле укытучыларга рәхмәт укып торыр» дигән мәгълүм хәдис үзеннән-үзе күңелгә килде. Шул рәхмәтләр иҗади теләкләрен тормышка ашырырга мөмкинлекләр тудырсын, бәхетле картлык китерсен якташыбыз Рифат ага Сверигинга.

*2002*

# Иҗат чишмәләре тынмый

Саба редакциясе коллективында истәлекле даталарны билгеләп үтү күптәннән традициягә кергән. Әмма ул бишле санына беткән туган көннәргә (хатын-кызларның 55 яшеннән кала) кагылмый. Шулай да без, күңел сизгәндәй, Газиз ага Нәбиуллинның 1985 елның 15 февралендә 65 яшь тулган датасын бөтен коллектив белән билгеләп үттек. Шуннан соң бер елдан аз гына артык вакыт узуга, ул вафат булды. Аңа җитмеш еллык юбилеен каршыларга насыйп булмады.

...Кеше үзе яшәгән вакытта аның кылган эшен һәм иҗатын олылап бәяләү ничектер гадәткә кермәгән.

Балалар язучысы Газиз ага Нәбиуллинның да бай иҗатына үзе вафат булгач кына киңрәк туктала башладык.

Шагыйрьләрнең барысы да диярлек авылда туалар, шәһәрдә үләләр, диләр. Г.Нәбиуллин — бөтен гомерен туган як туфрагында иҗат итеп үткәргән язучы һәм журналист. Аның биографиясенә күз салыйк. Ул Керәнне авылында туган һәм, шул ук авыл мәктәбен тәмамлагач, Арча педагогия училищесында укыган. Бераз авыл советы башкарма комитеты секретаре була, аннары 1940 елдан 1980 елга кадәр, ягъни пенсиягә киткәнче, берөзлексез үзебезнең район газетасы «Колхоз байрагы» (соңыннан «Җиңү байрагы») редакциясендә эшли. Башта хисапчы, җаваплы секретарь, ә инде 1944–1954 елларда — нәкъ ун ел редактор була, яңадан җаваплы секретарь вазифасын дәвам итә.

Газиз Нәбиуллин педагогия училищесында укыган елларда иҗат эше белән ныклап шөгыльләнә башлый. Беренче шигырьләре район газетасында, «Яшь ленинчы»да, «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналында басыла. Сугыштан соң, 1948 елда, «Безнең авыл балалары» дип исемләнгән беренче җыентыгы дөнья күрә. Бу җыентыктагы һәм аннан соң чыккан «Энем турында шигырьләр» (1957) китабындагы әсәрләр Татарстан Мәгариф министрлыгы оештырган балалар әдәбияты конкурсында икенче дәрәҗә бүләккә лаек булалар. Еллар үтә тора. Аннан соң Газиз ага Нәбиуллинның «Батырмы икән Батыр», «Урманда», «Җәй айлары», «Беренче баскыч», «Пьесалар», «Икмәк исе», «Яшел эстафета»,

«Үрләрем» дигән китаплары дөнья күрә, соңыннан «Тын елга буенда» исемле күләмле китабы басылып чыкты. Аның әсәрләренең төп темасы — балаларны хезмәт сөяргә, табигатьне ярата һәм саклый белергә, үзара дус булырга өндәү, гаделлеккә рухландыру.

Газиз ага Нәбиуллин 1961 елда СССР Язучылар союзы әгъзасы итеп кабул ителә. Аның бик күпләр сагынып, рәхмәт әйтеп искә ала торган, бәяләп бетергесез тагын бер олы хезмәте бар. Ул 1957 елдан бирле, ягъни 30 елга якын, район газетасы каршындагы «Мишә дулкыннары» дигән әдәби берләшмәгә җитәкчелек итте. Әлеге берләшмәдән танылган бик күп язучылар үсеп чыкты. Г.Нәбиуллин оештырган әдәбият түгәрәге әдәби-музыкаль берләшмәгә әверелеп, үзенең җимешләре белән районыбыз хезмәтчәннәрен шатландырып тора, иҗат чишмәсе саекмый.

Газиз ага Нәбиуллин һәрвакыт районның җәмәгать тормышында актив катнашты, «Җиңү байрагы» газетасының эчтәлеген баету, полиграфик эшләнешен яхшырту өчен зур көч куйды. Кешеләрнең фидакарь хезмәте турында мавыктыргыч язмалары, публицистик мәкаләләре укучы күңеленә рухи байлык өстәде.

*1990*

## «Кеше китә — җыры кала»

1978 елда тәмамлаган бер повестен ул әнә шулай дип атаган иде. Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев бу фани дөньядан китте. Аның калын-калын роман-повестьлары, гади, җиңел укыла торган хикәя-мәкаләләре мәңгелек һәйкәл булып калды...

Мөхәммәт Мәһдиевнең исеме татар халкына яхшы таныш. Ул — «Без — кырык беренче ел балалары», «Фронтовиклар», «Кеше китә — җыры кала», «Исәнме, Кәшфи абзый», «Торналар төшкән җирдә», «Ут чәчәге», «Мәңгелек яз», «Каз канатлары», «Ачы тәҗрибә», «Бәхилләшү» кебек повесть-романнары белән әдәбият сөючеләрнең ихтирамын казанган күренекле язучы, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Ул — илебезнең төбәкләренә бик күп укытучылар, язучылар, фән һәм әдәбият белгечләре тәрбияләп үстерүдә үзеннән зур өлеш керткән танылган галим, 35 фәнни хезмәтнең авторы. Ул — җанлы, тормышчан, кызыклы лекцияләр укучы, студентларның иң яраткан укытучыларыннан берсе. Ул — әдәбиятның бөтен нечкәлекләрен белеп эш итүче, сизгер, кыю тәнкыйтьче, шушы өлкәгә караган хезмәтләр авторы. Ул — «Казан утлары», «Сөембикә», «Идел» журналлары, «Ватаным Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Мәгърифәт» газеталарына укучыны уйланырга, борчылырга мәҗбүр итә, үткәннәргә борылып карарга, тарихтан гыйбрәт, сабак алырга чакырып мәкаләләр язган автор, заман рухын оста сиземләүче тәвәккәл журналист. Менә шушы берничә җөмләдән соң «иде» дип куярга күңел тартмый, кул бармый. Әмма...

Халкыбызның күренекле язучысы Мөхәммәт ага 1989 елда ук инде «Бәхилләшү» дигән повестен тәмамлап, шул исемдә китап чыгаргач, мондый эчтәлектә интервью биргән иде:

— Бу китап — минем гомер йомгагым. Исән булсам, алга таба да нәрсәдер язармын, бәлки. Бөек Толстой үзенең иртәгә, берсекөнгә һәм гомумән, киләчәктә язылачак әсәрләре, планлаштырган эшләре турында фикер йөртеп көндәлек дәфтәренә язганда, гел өч хәреф куйган «е.б.ж.» — если буду жив, ягъни әгәр исән булсам.

Шулай итеп, укучы алдына мин «йомгак китабы» белән чыгам. Шуннан инде авторның хәлен аңлагыз: йә шатлык китерәчәк бу китап аңа, йә газап, үкенү...

Әйе, аннан соң да күп иҗат итте әле Мөхәммәт абый. «Ачы тәҗрибә»се, «Сайланма әсәрләр»енең 1 нче томы һәм бик күп хикәя-мәкаләләре дөнья күрде. 1 нче томны нәшрият директоры Харис әфәнде Әшрәфҗанов үзе китереп тапшырган. Гонорарына, җәмәгате Лилия ханымга соңгы бүләгем, дип, яхшы тун алдырган. «Үзеңнән соң кызым Гәүһәриягә калдырырсың», — дип тә әйтеп куйган. Барысы уйланылган. Васыятьләр алдан язылган: гаиләгә дә, Язучылар берлегенә дә... Мөхәммәт Мәһдиев безнең төбәкне бик ярата иде. 1990 елда газетабызның 60 еллыгына багышланган санга ул «Саба ягы — туган як» дип исемләнгән мәкалә җибәрде. Анда: «Бала чагым, яшьлегем Саба ягы белән бәйле. Бу турыда мин «Торналар төшкән җирдә» дигән повестемда язган идем. Әнием — Түбән Симет авылыннан, нәселе бик тирәнгә китә, алар нәселендә галим-муллалар, мәгърифәтче Таиб Яхиннар, исемнәре кулъязмаларда сакланган шагыйрьләр бар. Әтинең дә нәселе шунда — Саба ягы авылларында укытучы булып эшлиләр иде, арадан берсе, ихтимал, соңгысыдыр инде, Яңа Мичән мәктәбендә әле дә эшли (сүз Гатауллин Рим Габдуллович турында бара. — *Т.Н.*).

Яңа Мичән, Караңгы Шыңар (Түлешкә), Түбән Симет, Сабай, Кызыл Мишә, Сатыш һәм башка авыллар минем әти-әниемнең биографиясенә бәйле булса, Керәнле, Өчиле, Курсабаш, Бакшанды авыллары — минем яшьлегем... Мәһабәт Керәнле авылында 1948–1950 елларда мин тарих укытучысы булып эшләдем...»

Мөхәммәт аганың «Саба таңнары»ның юбилеена килүе үзе бер истәлекле вакыйга булды. Моны

күпләр хәтерлидер әле.

...Бу юлларның авторын язмыш җилләре аның белән кабат-кабат очраштырды. Казан дәүләт университеты аудиторияләрендә лекцияләрен мөкиббән китеп тыңлаган остазың белән күзгә-күз карап сөйләшү үзе бер тарихи хатирә була иде. 1980 еллар башында без, райкомның ул вакыттагы пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Госман Гарипов, район мәдәният бүлеге мөдире Ризван Шакирҗанов белән аны көн буе Мичән, Керәнне, Бакшанды төбәкләрендә озатып йөрдек, очрашулар оештырдык, кичен туган авылы Гөберчәккә кайтарып куйдык. Тәэсирле минутлар күп булды. Әмма шуның берсе истән чыкмый. Керәннедә ул фатирда торган өй янына килдек. Хуҗалар күптән вафат. Йортның ишек-тәрәзәләре аркылы кадакланган. Мөхәммәт абый тәрәзәдән эчке якны күзәтә башлады һәм үзе йоклаган тимер караватны күрде. Түзмәде. Ирләрчә үксеп елады... Яшьлегенә кайткандай булды. Аныңниләр уйлаганын белеп булмады, билгеле.

Соңгы елларда без, район мәгариф бүлеге мөдире Шамил Зиннурович белән, Мөхәммәт абыйларда еш булдык.

...Чехов базары янында төзелгән күренекле шәхесләргә бүленгән йорттан фатир алган көннәре иде. Өч бүлмәле, һәркайсына олы коридордан ишек. Иркен кухня. Бик сөенгән иде Мөхәммәт абый. Өр-яңадан яши, иҗат итә башлыйсы иде бит...

7 февраль. Мөхәммәт абыйның яман шеше авырулары хастаханәсеннән катлаулы операциядән чыккан вакыты. Алдан шалтыратып белештек. Кабул итә аламы? «Саба егетләренә ишек һәрвакыт ачык», — дигән. Безне коридорда Лилия апа каршы алды. Менә кухнядан әкрен генә Мөхәммәт абый чыга.

— Егетләр, курыкмагыз! Шәүлә килә, — дип шаярта ул. Унсигез килога кимегән икән...

Сөйли дә сөйли Мөхәммәт ага. Аудиториягә сусаган. Тавыш көр. Ничек итеп диагноз куя алмый азаплаганнар. Операцияне ничек ясаганнар... Ничек итеп наркоздан соң рәхәт минутлар кичергән...

Ул сөйли. Без ашыгабыз. Чөнки тышта буран: юллар ябыла дигән сүзләр көндезен үк йөри иде. Саубуллашабыз. Ул көнне барыбер кайта алмадык. Озаклап сөйләшмәгәнебез үкенечле булды...

Озата чыккан Лилия апа әйтте: «Хирург өметсез икәнен яшермәде, елыйбыз. Бик сузганда 3–4 ай — сабан туйларына кадәр гомере бар...»

8 июнь. Без тагын Мөхәммәт абыйларда. Диктофон да алдык. Саба турында истәлекләрен яздырабыз, янәсе. Әмма соңарганбыз. Әдип кеше танымый. Телдән калган. Язучы-галим үзе дә танырлык дәрәҗәдә түгел. Бик якыннарына гына күрсәтәләр. Ишек аркылы икенче мәртәбә күз салган вакытта күңелгә «Мөхәммәт абый, сине эчендә җаның бар вакытта соңгы тапкыр күрәбез» дигән уй килде. Шулай булды да. Чәршәмбе көнне көндез радиодан әдипнең вафаты һәм васыяте буенча шул ук көнне Гөберчәктә җирләнәчәге турында хәбәр иттеләр.

Без, район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Таһир Габдерахманович һәм югарыда телгә алынган Шамил Зиннурович белән килеп җиткәндә, Мөхәммәт Мәһдиев дигән олы шәхес җир куенына салынган иде инде. Каберенә район хакимияте исеменнән чәчәкләр куйдык.

Аннан төп йортка — заманында Сатыш мәдрәсәсендә белем алган Сөнгатулла абзый нигезенә юл тоттык. Безне Симет, Мичән якларында балалар укыткан Мөхәммәт абыйның бертуган апасы каршы алды. 1916 елда ук төзелгән 5 тәрәзәле, күпне күргән, олы язучы туган йорт бакчаның түренә үк салынган. Нинди генә үлән, чәчәк юк бирелдә. Агачны да һәр төреннән утырткан Мөхәммәт абый. Аның заказы буенча Арчаның мәгариф хезмәткәрләре эшләп биргән беседкада әңгәмә корып утырабыз. Алар еллар үткән саен кәгазь битләренә төшәр әле, әгәр исән булсак. Мөхәммәт абый шушы беседкага иң якын дусларын җыярга хыялланган иде. Үзе дә узган ел августта соңгы кайтуында улы Искәндәр белән бер генә кич утырып, чәй эчеп калган.

...Равия апа безне озата чыкты. «Беләсезме, — диде ул, — гомер булмаганны быел сиреньнәребез чәчәк атмады. Мөхәммәт үләсенә чәчәк атмыйсыз, дип чыктым да кочаклап еладым...»

...Хуш иттек, Мөхәммәт абый, мәңгелек йортыңда тыныч йокла, үтә җиңел гәүдәң сыенган гүр туфрагың авыр булмасын!

2000 елның 5 июлендә мәркәзебез Казанның Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында мәшһүр язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең 70 еллыгына багышланган юбилей кичәсе булды. Икенче көнне туган авылы Гөберчәктә аның музее да ачылды. Күптән көтелгән бу бәйрәмгә Казаннан, күрше-тирә районнардан кунаклар бик күп килгән иде. Истәлекле вакыйганы Арча районы хакимияте башлыгы Илһам Сабиров кереш сүз белән ачып җибәрде. Аннан соң Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, Татарстан мәдәният министры урынбасары Рафаэль Вәлиев, Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев, ирле-хатынлы милләт җанлы шәхесләр — Гөлчәчәк һәм Әхмәт Галиевлар, шагыйрә Лена Шагыйрьҗан, профессор Тәлгат Галиуллин, җырчылар Фән Вәлиәхмәтов, Әлфис Кыямов, язучының дуслары, авылдашлары, якыннары, әсәрләрендәге геройларның прототиплары ихлас күңелдән чыгышлар ясап, Кесмәс елгасы буйларына, гомумән, авыл тормышына дан җырлаган, гап-гади кешеләрне зур биеклекләргә күтәргән Мөхәммәт Мәһдиев турында истәлек-хатирәләр белән уртаклаштылар, аның иҗатына тагын бер мәртәбә олы бәя бирделәр. Тантана барышында сабалылар исеменнән дә җылы сүз әйтелеп, район хакимияте исеменнән бүләк белән әдипнең этисе Сөнгатулла сабак алган дан-

лыклы Сатыш мәдрәсәсенең төсле рәсеме урнаштырылган «Яшә, Саба-Йорт!» дигән китап тапшырылды. Шулай булмыйча мөмкин дә түгел. Мәһдиевләрнең нәсел-нәсәбе безнең район белән тыгыз бәйләнгән. Беренчедән, әнисе — Түбән Симет авылыннан. Икенчедән, булачак әдип яшьлек елларында үзе дә, якын туганнары да безнең район мәктәпләрендә балалар укытканнар һәм хәзер дә бу изге эшне дәвам итүче якыннары бар. Музей өчен мәһабәт бинаны якташыбыз — Эзмә авылында туып үскән Алмаз Нәзиров җитәкләгән Арча урман хуҗалыгы коллективы җиренә җиткереп эшләгән. Лесхоз директоры символик ачкыч тапшырганнан соң, тасма киселеп, халык эчкә үтте, һәм зәвыклы, тирән эчтәлекле экспозицияләр белән танышу башланды, бер үк вакытта урамда сәнгать осталарының концерты дәвам итте. Кыскасы, ул көнне Гөберчәк шаулап-гөрләп торды, яңа статус алган (коймалары яхшылап тотылган, буялган) авыл зиратында әдип каберенә бик күп чәчәкләр куелды. Шулай итеп, зур булмаган Гөберчәкнең тарих сәхифәләренә яңа бизәкләр өстәлде. Ул моның белән газиз улы Мөхәммәт Мәһдиевкә бик рәхмәтле, әлбәттә!

*2000*

# Хикәяче

Районыбыз һәм Татарстаныбыз җирлегендә зур иҗади мирас туплаган Мәгъсум Хәмидулла улы Хуҗин әсәрләрендә Саба төбәге белән бәйле вакыйгаларга киң урын бирә. Ул — Тенеки авылында туып, бик озак еллар колхоз рәисе булган этисе белән күченеп йөри-йөри төрле мәктәпләрдә төпле белем алганнан соң, хезмәт юлын укытучы, комсомол райкомының икенче секретаре вазифаларыннан башлап, Казан университетын тәмамлап, «Татарстан яшьләре», «Комсомолец Караганды», «Колхоз байрагы» (Саба), «Коммунизмга» (Арча), «Хезмәт» (Балтач) газеталарында, аннары унсигез елдан артык «Чаян» журналында эшли-эшли хикәяләр язган, китаплар чыгарган әдип. Мәгъсум ага аеруча «Юл өзеге» һәм бу юлларның авторы белән бергәләп язган «Яшә, Саба-Йорт!» дигән китаплары белән район тарихына зур бәяле шәхси өлешен салды. Аның «Казан утлары» журналында «Татар хикәяләре хәзинәсеннән» бүлеген алып баруын, «Татар хикәясе антологиясе»н төзүен дә искәртик. Татарстан Язучылар берлегенең Фатих Хөсни исемендәге премиясе иң беренче итеп атаклы хикәяче якташыбызга бирелде. Тыйнак, ярдәмчел, кешелекле, туры сүзле ул Мәгъсум абый!..

— Ун ел саен бер буын алышынып тора, — дип язды шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов. — ...Әнә шул буыннарны тоташтыру өчен күпер хезмәтен үтәүче кешеләр була. Татар әдәбияты җирлегендә шуларның берсе — Мәгъсум Хуҗин. Ул — Ибраһим Гази, Фатих Хөсни, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким кебек өлкән әдипләр белән яшьтән үк аралашкан кеше.

«Азат хатын» («Сөембикә») журналын даими укып баручылар игътибар иткәндер, анда Мәгъсум Хуҗинның Хәсән Туфан турындагы «Көрендедә чәчәк үсә» дигән кыйссасы урнаштырылган, шунда ук егерменче гасырның алтмышынчы еллары башында төшерелгән фоторәсем дә бирелгән иде. Беренче рәттә Хәсән Туфан, Нурислам Зиннуров, Газиз Нәбиуллин, Нәби Дәүли, Сибгат Хәким, Хәбибрахман Кәримов утырган. Икенче рәттәгеләр арасында Габделбәр Мәннанов, Нурулла Шәрифуллин, Рафаэль Фәсхиев, Рәфыйк Шәрифуллин, Мәгъсум Хуҗин, Фәрит Яхин, Кыям Кашапов бар. Әлеге фотоны журналга тәкъдим итеп, әдип район газетасы редакциясе каршындагы «Мишә дулкыннары» әдәби берләшмәсенең өлкән буын язучылары һәм шагыйрьләре белән күптәнге элемтәсен тагын бер кат раслады.

Мәгъсум Хуҗинның беренче хикәяләре илленче еллар башында күренә, «Ерганак юл ала» исемле тәүге китабы 1961 елда чыга. Аннары «Курагай атлары», «Авылым урамнары», «Урманлы үр», «Өч каен ышыгы», «Бәхет җыры», «Ерактагы кыялар», «Мәхәббәт — һәлакәт...», «Айның уты сүнгән...» исемле һәм башка китаплары басыла.

Якташыбызның «Кулаклар колхозы» дигән хикәясен укыганда, һәр авылда диярлек булган вакыйгаларга игътибар итәсең. Кулыннан эш килгән хезмәт кешеләренең, булсын дип бил бөккән, тир түккән чын җир хуҗаларының маңгайларына «кулак» мөһере сугып, аларны җирдән аерган еллар хакында яза Мәгъсум ага. Гыйбрәтле хикәя бу.

Язучының авыл тормышын, аның эшчән кешеләрен, табигатен тасвирлаган хикәяләре яратып укыла. Мәгъсум ага Саба якларына кайткалап тора. Әүвәл зиратка сугыла ул. Биредә җир куенына этисе һәм әнисе, җәмәгате Мәгефрүз апа, бертуган кече энесе Илгиз мәңгегә иңдерелгән. Аларның каберләре янында чал чәчле башын иеп, озак уйланып тора. Аннары туганнарына сугыла, бераздан Тенекигә юл тота. Тенеки дигәч, аның «Кеше күңеле — үзе бер кояш» дигән хикәясе искә төшә. Автор монда фантазиясен бик оста җигә. Тенеки көмешчесе Нигъмәтҗанны Габдулла Тукай белән гәпләштерә, язучы аларны Казанның Печән базарында очраштыра. Көмешче Ак карт Тукайны Тенекигә чакыра. Шагыйрь көмешчеләр авылына кайта, аңа автор үзе дә ияргә... Якташыбызның Габдулла Тукай турындагы «Иңә дә иңә карлар» һәм «Һомай кошлары» исемле хикәяләре дә игътибарга лаек. Беренче хикәядә Тукай янына шигырьләргә сусаган Туфаил исемле малай керә. Бу хикәяләрне укыганда, Габдулла Тукай ши-

гырьләре күңел аша кабат уза.

Тенекидән соң Мәгъсум ага әкрен генә Тимершыкка таба атлый. Биредә язучыны балачак дусты, комбайнчы булып эшләгән Наил ага көтә. Алар озаклап әңгәмә коралар, авыл тормышы турында, аның мәшәкатьләре һәм шатлыклары турында иркенләп сөйләшәләр. Аннары Мәгъсум ага Язлы Арташ якларына юл тота. Бу төбәк тә бик якын аңа. Чөнки тормыш иптәше, үзенчә әйтсәк, җәмәгате, шушы авылдан. Саба якларын әнә шулай урап йөри ул.

— Мин гомерем буена үземне туган җирем алдында бурычлы саныйм. Аның туфрагына һәрвакыт баш иям, — ди ул. — Мәңге яшә, үзеңчә яшә, ипи-тозлы Саба җирем!

Якташыбыз белән күп тапкырлар гәпләшеп утырганыбыз бар. Аның сөйләшүе дә, үзен тотуы да гади. Һәр сүзен уйлап әйтер, тыйнаклыгы белән сокландырыр. СССР Язучылар берлеге әгъзасы Мәгъсум Хуҗинның орден-медальләре бардырмы, монысын тәгаен генә әйтә алмыйм. Юбилейлары уңаеннан бирелгән язмаларда чагылмады кебек болар. Булмаска да мөмкин, чөнки артык тыйнак кешеләр дан-шөһрәт артыннан кумыйлар бит...

*2005*

# Омтылышлы талант иде

Республикабыз матбугатында язучы һәм журналист Газиз Кашапов-Үзиленең 50 еллыгы уңае белән зур күләмле, тирән эчтәлекле байтак материаллар дөнья күрде. Татарстан радиосыннан аңа багышланган махсус тапшыру яңгырады. Газизҗанның ахирәт дусты буларак, минем дә «Казан утлары» журналында, «КамАЗ» акционерлык җәмгыяте газетасы «Нур»да, Аксубай районында чыга торган «Авыл таңнары» елъязмасында истәлекләрем басылып чыкты. Әлбәттә, вакытсыз вафат булган якын кешең турында хатирәләр язу җиңел дә, куанычлы да түгел. Әмма «Татарстан хәбәрләре» газетасында эшләүче күренекле язучы һәм публицист Барлас ага Камаловның бер-бер артлы килгән ике хаты яңадан каләм алырга мәҗбүр итте. Хатлар озын түгел, шуңа күрә тулысынча, үзгәртмичә бирәм.

*«Казан, 31.VIII.1992. Кичке 9 сәгать 15 минут.*

*Тәлгат энем!*

*Газиз Кашапов турында радиотапшыру тәмамланыр-тәмамланмаста язам бу юлларны. Язучы Нәбирә Гыйматдинова чыгышында да, син сөйләгәннәрне дә бик әсәрләнеп тыңладым. Ихластан булгангадыр, синең чыгышың аерата дулкынландырды. Бик рәхмәт.*

*Дуслык ул берең фани дөньядан киткәч тә дәвам итсә генә олы дуслык санала аладыр да. Әлеге җәһәттән син күпләргә матур үрнәк бирәсең. Монысы өчен дә рәхмәт.*

*Газиз хакында хатирәләр язарга бурычлысың син. Бүген радиодан сөйләгәннәреңне киңәйтеп, детальләп һәм тирәнәйтебрәк тә язу хәерле булыр. Әдипнең 60 еллыгы да җитәр. Ул чагында синең хатирәләрең үтә тансыкка әйләнер. Эшең күп, вакытың тар, мәгәр җан дустың Газизҗан хакына моны эшләргә җай табарсың дип ышанасы килә.*

*Сәлам, ихтирам, гозер вә өмет белән Барлас».*

*«Тәлгат энекәш!*

*Моннан байтак көннәр элек язган хатны, мөгаен, алгансыңдыр дип уйлап, сиңа бер гозер: риза-бәхил булсаң, Газиз хакындагы хатирәләреңнең бер нөсхәсен безгә — «Татарстан хәбәрләре»нә җибәрсәнә. Ике зыялының дуслыгы хакында сүз буларак, бездә чыгып килә торган «Икәүдән-икәү» сәхифәсенә бик теләп бирер идек.*

*Сәлам, гозер, ихтирам белән Барлас».*

Дөрес, радиодан ясаган чыгышым, баргач кына кулдан язылганлыктан, үземдә калмаган иде. Шуңа күрә монысын бераз үзгәртеп эшләдем.

Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, татар халкының танылган язучысы һәм әдәбият галиме Мөхәммәт Мәһдиев язганча («Татарстан яшьләре», 11 август, 1992. — *Т.Н.*), безне Казанның чал университеты дуслаштырды. 1973 елда татар теле һәм әдәбияты бүлегенә читтән торып укырга керү өчен имтиханнар тапшырдык. Бу көннәрдә булачак курсташлар белән артык аралашмадык, чөнки һәркем үзенчә сынауга әзерләнде. Шулай да безнең арада өлкәнрәк яшьтәге бер ир-атның бар икәне күзгә ташлана иде.

Менә студентлар булдык. Тәүге сессиягә килдек. Аны русча «установочная» диләр. Янәсе, бу иң җиңел сессия: зачетлар, имтиханнар тапшырасы юк. Әмма рус теле укытучысы Луиза Кәрәмовна беренче көнне үк «өй эше» бирде. Лекциядән соң Газиз белән (туу турында таныклыкта Газизҗан Салихҗан улы) сөйләшеп киттек, ул минем кая урнашуымны сорады. Үзе туганнары Риза абыйларда икән. Мин «Совет» кунакханәсенә урнашкан идем. Икенче көнне килеп тә керде. Бирелгән заданиене эшләдек. Сөйләшеп киттек. Җитмәсә, тагын бер деталь ачылды. Ул мин армиядә хезмәт иткән Амур өлкәсенең Благовещенск шәһәрендә хәрби училище тәмамлаган икән. Без шушы сессиядән соң аерылмас дус-

ларга әйләндек. Алты ел буе төрле кунакханәләрдә бер бүлмәдә яшәдек. Кышкы сессияләр гадәттә 1 гыйнвардан башлана иде. Урыннар дефицит булганлыктан, без чиратлап, Яңа ел каршыламыйча, 31 декабрьдә урнашып кала идек. Ул көнне бар да диярлек кайтып бетә, «күчтәнәч»ең булса, әлбәттә, номер эләктереп була иде. Газизҗанның гаиләсе ул елларда Чиләбедә яшәде, алар башта Әлмәткә кайттылар, аннан Чаллыга күчтеләр. Безнең җәмәгатьләребез дә уртак тел тапты, гаиләләребез белән бик еш аралаша башладык. Алар — безгә, без аларга бардык. Кашаповларның көмеш туйларында да катнашырга насыйп булды әле. Кыскасы, туганлаштык.

Соңгы тапкыр Газизҗан төпчек улы Дамир белән Сабага 1991 елның июлендә — вафатына 43 көн кала килде. Редакция коллективы белән очрашу үткәрдек. Ике кич кундылар. Мунча бик ярата иде, һәр көнне чабындык. Аннан соң «Жигули»енда Казанга бардык. Ул шуннан Чаллыга китәргә тиеш иде. Эшләр беткәч: «Газизҗан, — дидем, — әйдә кире кайтыйк Сабага, тагын бер мунча чабынырбыз».

Ул бик теләп риза булды. Кире кайтып тагын бер кич кундылар. Күңеле сизде микән, аның Сабага соңгы килүе, капка төбендә минем ахыргы мәртәбә озатуым булган икән...

Әйе, аңа 21 августта 50 яшь тулган булыр иде. Бу бәйрәмен бик көткән иде ул. Алтын юбилее якынлашып килгәндә, ягъни 49 яше тулуга, дөньяны, гаиләсен, туганнарын, дусларын, чәчәккә бөреләнгән иҗатын калдырып китеп барды Газизҗан. Язмыштан узмыш юк, диләр. Шулай булса да үлем үкенечсез булмый: ир уртасы кешенең, талант иясенең йөрәге тибүдән мәңгегә туктавына ышанасы килми. Аның оптимистик рухта язылган, яшәүгә, тормышка мәдхия җырлаган шигырьләре, хикәя, повесть һәм романнары укучылар күңелендә дәвам итә. Әмма үлем — котылгысыз, табигый. Аның шулай икәнен Газизҗан да аңлый иде. Шулай да тәкъдир сәгатен кайчан сугасын белмәде, болары инде, өлкәннәр әйтмешли, бер Алланың үзенә генә мәгълүм булгандыр. Бу көннең киләчәген Газизҗан бөтенләй сизмәде түгел. Чөнки 1969 елда хәрби хезмәт вазифасын үтәгән чакта, авыр җәрәхәтләнеп, төрле госпитальләрдә бик озак дәваланулар әҗәлне искәртеп торгандыр. Баш авыртуы белән бик җәфалана иде (үзе 20 елдан артык зәмзәм суын бөтенләй капмады, тәмәке тартмады). «Баш түбәсенә шулкадәр каты басалар, авыртуына чыдый алмыйча, җирне тишеп керердәй булам» дигән сүзләре хәтердә калган.

Шуңадыр моннан алты ел элек бер хатында мондый юллар язган булган: *«...Хәтерлисеңме, дустым, М.Җәлил Гази Кашшафка васыять иткән иҗатын. Авыр эш бу. Булган барлык әйберләрне чыгару, кабатлап чыгару. Минем иҗатны кайгырту синең өстә булыр. Моның өчен сиңа күп вакыт әрәм итәргә туры килер. Дуслык хакына тырышсаң иде, алай-болай булсам. 1987 гә — «Язмышыңа ышан», 1989 га — «Вөҗдан хәтере» дигән китап әзер диярлек, иң соңгы «Аваз» — 1987 гә — «Казан утлары»на Ренат Харис вәгъдәсе. (Бу әсәрләр Г.Кашапов үзе исән вакытта дөнья күрде. — Т.Н.) Аннарыга: 1992 дә 50 яшькә зуррак китап, аннары 60 камы бөтенесен җыеп — 2, бәлки, хатлар, рецензияләр, очерклар белән 3 том булыр дип уйлыйм. Бу эшләр белән шөгыльләнүне дә сиңа ышандырам. Андый-мондый сүз чыкса... Әлбәттә, болар барысы да минем теләгем генә. Син теләмәгән очракта моның кадәр эшне йөкләве кыен.*

*Сау-сәламәт йөреп кайтсам, барып чыгармын, шаять. Хөрмәт белән тугрылыклы дус булганың өчен рәхмәт хисләре җыеп Газизҗан.*

*20 июнь, 1986 ел, Чаллыяр.*

*P.S. Бу хатны сакларга туры килер инде».*

Әйе, хат сакланган. Әмма юбилейга китабын чыгарып җитештерү мөмкин булмады. Чөнки базар икътисады нәшрият тирәсенә дә китереп сукты. Ярый әле үзе исән вакытта «Сәмум җиле» дип исемләнгән автобиографик повесть, «Солдат иртә ир була», «Җир җылысы», «Убырут», «Гомернең утлы өлеше», «Лачын кошка күкләр кадерле», «Язмышыңа ышан», «Гыйфрит» кебек әсәрләр иҗат итеп, биш китап чыгарырга өлгергән иде. Ә менә басылмаган күп кенә шигырьләре, хикәяләре һәм поэмалары калуы йөрәкне әрнетә. 1991 ел башында ул Ташкент якларында булып, элек үзләренең туган төбәкләрендә яшәгән Сираҗетдин мулланың көндәлеген табып алып кайткач, тагын бер романлык материал бар, дип шатланып сөйләгән иде. Газизҗан туган якларын, балалык елларын бик сагынып искә ала иде. Сабый ятимлектә үсә. Әтисенең сугышта һәлак булуы турында хәбәр килгәч, әнисе аны әбисенә калдырып китеп бара. Алар башка очрашмыйлар...

Газиз Кашапов язучы, шагыйрь генә түгел, көчле публицист та иде. Ул Әлмәт шәһәрендә чыга торган «Хезмәт байрагы» газетасы һәм КамАЗ радиотапшырулар редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, «Социалистик Татарстан» газетасының Түбән Кама, Алабуга, Мамадыш, Тукай районнарындагы үз хәбәрчесе булды. Аннары язучыларның Яр Чаллы оешмасын җитәкләде. Гомумән, Газиз журналистиканы чын күңелдән яратты. Моннан берничә ел элек ул Татарстан Язучылар съездында татар публицистикасы турында ялкынлы чыгыш ясады һәм, менбәрдән төшүгә, аңа көчле инфаркт булды. Шуннан соң да ул бер роман, ике повесть бастырып чыгарды, иҗат эшчәнлеген дәвам итте. Бигрәк тә якташы, танылган шагыйребез Хәсән Туфанга багышланган «Киек Каз Юлы» дигән романы өчен бик күп фактик материал туплады. Г.Кашапов Туфан эзләре буйлап күп йөрде, олы шагыйрь эшләгән Пермь өлкәсендәге Лысьва шәһәрендә мемориаль такта куюны һәм аны тантаналы төстә ачтыруны оештырды. Туфан утырган төрмәгә барып, аның «шәхси дело»сын тапты, шуның кесәсеннән «халык дошманы»ның сирәк

рәсемен алып кайтты. Хәсән ага сөргендә булган Новосибирск өлкәсендәге авылны эзләп табып, аны белгән кешеләр белән очрашты, шагыйрь яшәгән землянка урынында төн кунды... Әмма Г.Кашапов бу романның беренче кисәген генә тәмамлый алды. «Киек Каз Юлы» дип исемләнгән әлеге китап хәзер нәшриятта дөнья күрергә әзерләнеп ята. Хәсән Туфан иҗатына кагылышлы бик күп материал туплаган иде Газизҗан. Менә тагын бер хатыннан өзек: *«Тәлгат дус! Әле синең белән сөйләшеп киткәннән соң, Казанга барып кайттым. «Язмышыңа ышан» акрынлап эшләнә башлаган. Булыр инде. Ренат Харис белән бүлмәсендә бер сәгать сөйләшеп утырдык. 1.07 очам, 12 дә Свердловскига, аннан 21 сәг. Улан-Удэга. 5–6 көннән Новосебергә кайтам, аннан Покровка, Чыпчык авылы — Прометей атлы үгез белән, татарның бөек шагыйре яшәгән җирләргә сәфәр кылмакчымын... Исән булсам».*

Мин, бу юлларның авторы буларак, Газиз Кашаповка исән вакытта Хәсән ага Туфан белән очраштырган өчен мең-мең рәхмәтлемен. Татар поэзиясе аксакалының фатирына ике тапкыр бергә бардык. Бу очрашулар миңа, периферийда яшәүче журналистка, Хәсән Туфан һәм Газизҗан истәлегенә (урыннары оҗмахта булсын) күләмле материал язарга җирлек тудырды.

Үз-үзенә бик таләпчән, нык характерлы, куелган максатына ирешә торган үҗәт кеше иде Газиз Кашапов. Бөек Ватан сугышында һәлак булган, үзе бер тапкыр да күрмәгән офицер әтисенең каберен «Кызыл Хач» җәмгыяте аша Польша җирләреннән тапты. Икенче атадан туган Үзбәкстандагы энеләрен эзләп (әнисе, улын әбисенә калдырып киткәннән соң тәүге тапкыр очрашырга берничә көн калгач, Газиз хәрби хезмәттә вакытта, гүр иясе була), аны якын туган итте. Яннарына барып кайтты, үзләре килделәр.

1990 елның 15 сентябрендә Мәскәү астындагы Переделкино иҗат йортыннан язылган Газизнең үзенә карата үтә таләпчәнлеген раслый торган тагын бер хатыннан өзек китерәм. *«Сәламәтлекне ныгытуны онытмыйм. Иртәнге биштә торам, 1 сәгать гимнастика, чәй эчәм... 2,5 сәг. эшләп утырам. Тугызда — иртәнге аш, 10 да йөрергә китәм, 15 км. ны әйләнеп кайтам. Көн дә. Газеталар укыйм. Аннары тагын бераз эшлим. 14 тә төшке аш. Тозсыз, майсыз пешертәм бит тәки... 16 да — 1,25 минут — гимнастика, урында йөгерү иртән 8 мин., йөргәндә 4 мин., 19 да кичке аш. 1,5 сәгать язу. 21 дә — «Вакыт». 10 сәг. 30 минутта йокларга яту. Железный порядок. Ходайга шөкер. Менә бүген, һәр шимбәдәгечә 42 сәгатьлек ачлык. Тульке су — 5 стакан...»*

Әмма Газизҗанга болар гына ярдәм итә алмады. Ул, 1991 елның 21 февралендә язылган васыяте нигезендә, үзе телгән төбәктә җирләнде. Аның *«Мөмкин булса, туган авылым Яңа Үзигә алып кайтып, Югары як зиратына, әбием, туганнан туган абыем Афзал янынарак күмәрсез. Теләгем шул...»* дигән сүзләре җиренә җиткереп үтәлде.

Газиз Кашаповны районлашлары, авылдашлары да тирән хөрмәт иткән икән. Мәрхүмне җирләгән вакытта бу бигрәк тә ачык күренде. Яңа Үзи авылы кешеләре матәм митингысы вакытында язучының музеен, колхозда аның исемендә премия булдыру һәм бюст кую турында карар кабул иттеләр. Бу тәкъдимнәр Аксубай районы хакимияте башлыгы М.Халитов тарафыннан хупланды һәм алар барысы да тормышка ашырылды.

Язмамны йомгаклар алдыннан, яңадан 1991 елның 30 августына әйләнеп кайтмый булмый. Өйләдән соң фатирда телефон шалтырады. Линиядә университетта бергә укыган, хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгының бүлек мөдире булып эшләүче Мөҗәһит Шәйхетдинов иде.

— Олы кайгы бар, — диде ул. — Газизебез вафат...

Яр Чаллыга ашыктым. Дүрт бүлмәле фатирының залында дустым, йокымсыраган шикелле итеп кенә, күзләрен бөтенләйгә йомган. Чиста йөзе (ул җан бирер алдыннан гына иртән кырынып-юынган була), пөхтә таралган чәчләр, баш түбәсендә матур түбәтәй...

Миңа бик таныш һәм якын эш бүлмәсенә үттем. Өч стенаны идәннән түшәмгә кадәр каплаган меңләгән кадерле һәм иң дефицит китапларны, папка-папка чыгачак повесть-романнар өчен тупланган материалларны, милләтебезгә кагылышлы сувенирларны туплаган әлеге гыйлем почмагында без озаклап фикерләшә идек. Газизҗанның эш өстәлендәге соңгы кульязмасын күреп алдым. Ул 20 августта, шифаханәгә керер алдыннан, түбәндәге шигырен тәмамлап калдырган. Мин аны хәзер дә кат-кат укыйм. Чөнки әлеге куплетлар артында ниндидер сер бар кебек тоела. Менә ул:

**Туган көнемә — 21 августка**

Алтынлангач агач яфраклары,
Тынып калган урман.
Миләшләргә сары сагыш сауган,
Алма пешеп тулган.
Язлар быел иртә килде, диеп,
Әй шатланган идек.
Августның да егермесе җитте,
Китеп бара киек.
Һәр фасылның үз вакыты вакыт,
Артыгы юк аның.

Кырык тугыз тапкыр дүртәр фасыл
Тумышымнан алып...
Юк,
Туктатып булмыйдыр ул, бәлки,
Гомер агышларын.
Минем әле яңа үрләр яулап
Алга барышларым.
Тормыш үзе катлаулы да болай,
Ачы да соң язмыш.
Тик барыбер каршы алам әле
Тагын илле язны.
Әйтсеннәр соң көнче җирдәшләрем,
Туксан тугызлы, дип.
Әрнүләре, рәнҗүләре белән
Бу дөнья кызык бит...
Миләшләргә сары сагыш сауган,
Алма пешеп тулган.
Алтынланган агач яфраклары,
Тынып калган урман.

*18–20 август, 1991*

Әйе, Газиз Кашапов өчен урман гына түгел, бөтен җиһан тынып калды. Кем уйлаган — дөнья белән бәхилләшү дәвалану гимнастикасы ясаганда булыр дип...

Нишлисең бит, йөрәк өчен бик авыр заманда яшибез шул...

*1991*

## Борчулы җан

Рашат Низамиев 1950 елның 1 мартында районыбызның Олы Мишә авылында (хәзер Теләче районына керә) туа. Туган авылындагы башлангыч, Олы Саурыштагы сигезьеллык һәм Икшермә урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1967–1972 елларда Казан дәүләт университетында белем ала. Аннары Татарстанның Биектау районы Зур Битаман урта мәктәбендә балалар укыта, әдәбият түгәрәген җитәкли.

1974 елдан — Казан заводларының берсендә чыга торган күптиражлы газета хәбәрчесе. 1976–1981 елларда «Татарстан яшьләре» газетасында, аннары «Ялкын» журналы редакциясендә эшли. 1983 елдан «Казан утлары» журналының проза бүлеген җитәкли, баш мөхәррир урынбасары була. Бүгенге көндә ул — яшьләр журналы «Идел»нең баш мөхәррире.

Р.Низамиевның беренче шигырьләре мәктәп елларында ук «Җиңү байрагы» («Саба таңнары»), «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газеталарында һәм «Ялкын» журналында басыла башлый.

Ул хикәя һәм повестьлар жанрында да ачылды, балалар өчен шигырьләр язуы белән дә танылды. Беренче татар балеты «Шүрәле»не иҗат иткән һәм Ватан сугышы кырларында ятып калган композитор Фәрит Яруллин турындагы роман-хроникасы татар халкының күренекле уллары тормышын һәм иҗатын өйрәнүдә, яктыртуда күркәм өлеш булды.

Рашат Низамиев — кызыл төскә гашыйк шәхес. Әле югарыда телгә алган «Атаклы кешеләр тормышы» сериясенә язылган романына «Бу әсәремне, кызыл чәчәкләр итеп, Фәрит Яруллин каберенә сәлам», — дигән җөмләне эпиграф итеп ала. Әлеге фикерне аның 1983 елда дөнья күргән «Кызыл җәй» шигырьләр җыентыгы һәм «Кызыл кар яугач» (1994) дигән повестьлар һәм хикәяләр китабы тагын бер кат ачык раслый. Рашат Низамиев — унлап китап авторы. Аның «Йолдызлар яңгыры» (1980), «Бөек сер» (1986), «Яралы керпе» (1987), «Созвездие Сююмбики» (1988, рус телендә) дип исемләнгән басмаларына быел сигезенче китабы — «Ут һәм җыр» романы өстәләчәк.

Гомумән, аның иҗаты турында байтак язучыларның һәм әдәби тәнкыйтьчеләрнең матур-матур фикерләре бар. Мәсәлән, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, республикабыз халык депутаты Фоат Галимуллин аның турында болай ди: «Дөньяга рәссам булып туган кешеләр була. Алар безгә караганда күбрәк сиземлиләр, тирәнрәк хисләнәләр, дөнья гамьнәрен үз йөрәкләре аша үткәрәләр. Рашат — әнә шундый борчулы җаннарның берсе. Аның шигырьләре һәм проза әсәрләре шулай дияргә нигез бирә...»

Шигърият һәм прозадан тыш Рашат Низамиев публицистика өлкәсендә дә актив эшләп килә.

Ул — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

*2000*

## Мөгаллим дә, журналист та

Сабаның борынгы, уңдырышлы туфрагы әдәбиятка, сәнгатькә, журналистикага һәм башка өлкәләр-

гә бик күп талантлар бирде. Шуларның берсе — «Мәгариф» журналының баш мөхәррире, Татарстанның атказанган укытучысы (1979), Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре (1989), Татар-стан журналистларының Хөсәен Ямашев исемендәге премиясе лауреаты (1989) Фәрит Әхмәтнур улы Шәрифуллин.

Миңа, бу юлларның авторына, аның белән эш бүлмәсендә дә, районда да бик еш очрашырга туры килә. Заманында Горький (хәзер Түбән Новгород) шәһәрендә бер айлык курста да булдык. Үтә дә тыйнак, һәр сүзен, җөмләсен уйлап кына, сеңдереп сөйләүче, югары культуралы шәхес ул. Гомерен педагогикага һәм журналистикага багышлаган Фәрит Әхмәтнур улының хезмәт биографиясе гади дә, сокланырлык та. Ул 1939 елның 19 маенда районыбызның Олы Шыңар авылында туа. Яшьтән үк эш сөеп үсә. Көтүен дә көтә, печәнен дә чаба, урманын да кисә. Аңа кечкенә вакытта ук, өй салганда, эти-энисенең, туганнарының кул астына керергә туры килә. Мәктәптә тырышып укый, ныклы белем алу белән беррәттән балалар һәм яшьләр газеталарына хәбәрләр җибәреп тора. Тәүге мәкаләләр язганда, журналистлык эше аның төп һөнәренә әйләнәчәген күз алдына китермәгәндер дә ул. Олы Шыңар җидееллык мәктәбен тәмамлагач, Фәрит Арча педучилищесына юл тота. Биредә алган төпле белем аңа Казан дәүләт педагогика институтының татар теле, әдәбияты һәм тарих бүлегендә укырга ярдәм итә.

1963 елның җәй ахырында кулында ике дипломы булган бөдрә чәчле, озын буйлы Фәрит Шәрифуллин «Совет мәктәбе» (хәзерге «Мәгариф») журналына эшкә килә. Аны коллективка бик теләп кабул итәләр. Казанда укый башлагач, «Татарстан яшьләре» редакциясендә штаттан тыш студентлар бүлеге мөдире дә була. Менә шулай итеп, Фәрит Әхмәтнур улы укытучылар, тәрбиячеләр өчен чыгарыла торган журналда җиң сызганып иҗат итә башлый. Ул вакытта шушы редакциядә тоташ кырык елга якын эшләрмен дип уйламагандыр да. Тәҗрибә туплаган саен, хезмәт баскычлары үзгәрә тора. 1970–1977 елларда журналның педагогика-методика бүлегенә җитәкчелек итә. Аннары иң авыр участокка, гади итеп әйтсәк, редакциянең штабына, җаваплы секретарь вазифасына күчерәләр. Ун елдан артык тарта Фәрит Әхмәтнурович бу йөкне. Бер ел баш мөхәррир урынбасары булып эшләгәч, ягъни 1989 елда, журналга җитәкчелек итүне тапшыралар.

Баш мөхәррир. Бу басмада әлеге җаваплы вазифаны алып бару өчен журналист булу гына җитми, чын педагог та булырга кирәк. Язучы һәм галим Мәхмүт Әхмәтҗанов ассызыклап болай ди: «Мәгариф» журналы редакциясендә дә, башка басмалардагы кебек, журналистлар эшли. Әмма, бүтәннәрдән аермалы буларак, монда эшләү өчен галим дәрәҗәсендә булырга, мәсәлән, күп кенә фәннәрне — педагогиканы, психологияне, этнопедагогиканы да тирән белергә кирәк. Башкача мөмкин дә түгел. Аның кыенлыгы-авырлыгы тагын шунда: замана, сәясәт үзгәрү белән, әлеге фәннәрдә күп кенә яңалыклар барлыкка килә. Тәрбия эше формалары һәм алымнары да яңара. Димәк, журнал яңача эшләү алымнарын күрсәтергә, тәкъдим итәргә, алдынгы тәҗрибәне тупларга һәм шуны укытучыларга җиткерергә тиеш. Бәхеткә, моны баш мөхәррир җитәкчелегендә журнал коллективы уңышлы хәл итеп килә».

Мин Фәрит Әхмәтнур улының оста тәрҗемәче икәнен дә яхшы беләм. Ул вакытын бушка уздыра торган шәхес түгел. Алда телгә алынган Горький шәһәренә дә «өй эше» алып килеп, ял көннәрендә «Ботаника» китабын тәрҗемә итте ул. Гомумән, V–VI класста укучы татар балалары чирек гасыр буе шушы дәреслектән файдаланалар икән. IX класстагылар игътибар иткән булсалар, «Неорганик химия» дә безнең якташыбыз тәрҗемәсендә дөнья күреп килә бит. 1984 елда IX классларга «Гаилә этикасы һәм психологиясе» дигән фән керә башлагач, дәреслекләр булмау сәбәпле, Ф.Шәрифуллин «Мәгариф» журналында ике ел дәвамында дәрес үрнәкләре биреп килде һәм 1989 елда «Гаилә тормышына әзерлек дәресләре» дигән китап чыгарды. Мондый мисалларны күпләп китерергә була. Мәсәлән, Н.Тужилинның «Кызыклы дөнья», Ю.Дружковның «Карандаш белән оста кул маҗаралары», «Тылсымлы мәктәп», Н.Максимовның «География маҗаралары» дигән китаплары да аның тәрҗемәсендә басылып чыкты.

*1999*

## «Туган җирем дә, туган көнем дә икәү...»

*2006 елда Мәскәү шәһәрендәге татар җәмәгатьчелегенең мәшһүр Әсәдуллаев йортында танылган сынчы Кадим Җәмитовның юбилей кичәсе булып үтте.*

Кем ул Кадим Җәмитов? 1999 елда Лондонда нәшер ителгән «Татар энциклопедик сүзлеге»ндә аның турында: «Җәмитов Кадим Җәлил улы (1946 елда туган), сынчы: «Су анасы» (1990), «Шагыйрь» (Тукай) (1985), («Замандаш») — татар мәдәнияте эшлеклеләренең портретлар сериясе (1992), Казандагы «Хөррият» скульптурасы (1996) авторы, 1973 елдан бирле Мәскәүдә яши», — диелгән. 2001 елда дөнья күргән «Кто есть кто в татарской общине Москвы» белешмә-китабындагы ике йөздән артык милләттәшебез арасында Кадим Җәмитов та бар. Аның иҗатына бу басмада бер бит урын бирелгән, фотосурәте дә урнаштырылган.

Мин аны кырык елга якын беләм, дип, курыкмыйча әйтә алам. Моны раслый торган дәлилем дә бар — шәхси альбомымда 1968 елның 9 Маенда — Җиңү бәйрәмендә — җырчы Эльбрус Сибгатуллин, рәссам-баянчы Вил Гарипов, нәфис сүз остасы Хәйдәр Һадиев (өчесе дә вафат инде, бу язмам аларга

дога булып барып ирешсен) һәм Кадим Җәмитов бергәләп Шәмәрдәндә төшкән фоторәсем саклана.

Дөрестән дә, Кадим гомере буе Вил Зариф улын үзенең остазы итеп саный, аны хөрмәт итә. Моның нигезе дә бар. Бик иртә рәсем сәнгате белән мавыга башлаган Кадим, Иске Икшермәдә чагында ук, Шәмәрдәндә балаларга рәсем дәресе бирүче, шул бистәдәге промкомбинат клубын да җитәкләүче, Саба—Шәмәрдән урамнарын Ленин сурәте һәм урак-чүкеч төшерелгән плакат-өндәмәләр белән бизәүче рәссам турында ишетә һәм ярты юлын җәяү, калганын машина белән аның янына килә. Ижаудагы Удмурт педагогия институтында белем алган киң күңелле Вил абыйсы аны җылы кабул итә һәм бик теләп гамәли дәресләр бирә башлый. Тора-бара Кадим остазы укыган институтның графика сәнгате бүлегенә керә.

Ә инде 1969 елда, яшем җитеп мин хәрби хезмәткә алынгач, безнең юллар аерылды...

1996 ел. Мине, инде унбиш ел район газетасын җитәкләүче мөхәррирне, ул вакыттагы хакимият башлыгыбыз Фәрит Гыйльмиев бүлмәсенә чакырып шалтыратты.

— Мәскәүдән Икшермә мәктәбендә бергә укыган сабакташым кайткан. Киңәшләшәсе мәсьәлә бар иде, — диде ул.

Килдем, башлык бүлмәсенә кердем. Бу мизгелдә район хуҗасы үзе телефоннан сөйләшә иде...

Һәм... Чирек гасырдан соң булса да, Кадим белән бер-беребезне тиз танып алдык. Җылы итеп исәнләштек. Бу минутларда Фәрит Гыйльмиевич та бер мәлгә аптырап калды һәм:

— Сез ничек танышлар әле? — дип сорады.

...Олы сәнгатькә юл ярганчы, Кадимгә шактый сикәлтәләрне узарга, дөньяның ачысын-төчесен татырга туры килә. Ижау педагогия институтында төп белгечлек буенча дәресләрнең тирәнлеге, масштабы аны канәгатьләндерми башлый. Өч курсны бетергәч, ул Мәскәүгә китә һәм Югары сәнгать техникумына укырга керергә ниятли. Аннары армия сафларына алына, анда да рәссам-сынчы була, «айт-два»га йөрми. 1973 елда яңадан Мәскәүгә кайта. Башта СССР Рәссамнар берлеге каршындагы иҗат яшьләре берләшмәсенә йөри. Аннары биш ел буе Владимир Табах остаханәсендә сәнгатьнең нечкәлекләренә төшенә. Якташыбыз шунда профессионал булып китә. Гипс, таш, агач, бронза, шамот (эреп пыялаланганчы яндырылган аерым төр үзле балчык) кебек материаллардан күп сыннар ясый. 1983 елда ул Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы итеп кабул ителә. Иҗади әсәрләре дә күргәзмәләрдә еш күренә башлый. «Курайчы» дип исемләнгән сыны тәүге мәртәбә 1971 елда автономияле республикаларның Бөтенсоюз күргәзмәсендә урын ала. Якташыбызга 1985 елда Германиядә уздырылган «Сын-сурәт һәм мохит» дигән тематик күргәзмә яңа уңышлар китерә. Аның бакырдан чокып эшләнгән «Шатлык» исемле әсәре табигый зурлыгында хатын-кыз сыны була. Аңа бик югары бәя бирелә һәм Мәскәүдәге атаклы Третьяков галереясына сатып алына. Хәзер инде Кадимнең ундүрт әсәре әлеге галереяга мәңгегә урнаштырылган.

Бу язмада К.Җәмитовның барлык иҗат җимешләрен дә санап чыгу мөмкин түгел, әлбәттә. Аның талантының үзенчәлеге шунда: ул милләтебезнең рухына, хис-тойгыларына, әхлакый-эстетик көченә, нечкәлекләренә тирән үтеп керә. Мәсәлән, Санкт-Петербургта үзебезнең сәнгатебезгә багышланган «Татар-91» күргәзмәсендә аның «Мөселман карты» аеруча зур уңыш казана.

Гомумән, мөхтәрәм якташыбыз иҗатындагы татар милләте вәкилләре зур урын алып тора, хосусан үзебезнең милли сынлы сәнгатебезне үстерүне максат итеп куя ул. Ә инде Австриядә булып үткән күргәзмәдән аның «Савыгу» әсәрен Венадагы Милли нәфис музей сатып ала. Хәзер ул бер мәйданны бизи.

Кадим Җәмитов иҗатында Тукай һәм аның замандашлары Галиәсгар Камал, Сәгыйть Сүнчәләй, Камил Мотыйгый, Фатих Әмирхан, Сәгыйть Рәмиев һәм башкалар образлары киң урын алып тора. Аның бигрәк тә Г.Тукай әсәрләренә, татар халык иҗатына ихтирамлы булуы күзгә ташлана. Бу темаларга сынчының 1990 елда Мәскәүдә беренче шәхси күргәзмәсендә булучылар аеруча игътибар итә. Монда аның төрле жанрдагы утыз дүрт әсәре куелган була. Ул 1991 елда Казанда татар сәнгате күргәзмәсендә катнаша. Анда Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа, Алма-Ата кебек зур шәһәрләрнең иҗат осталары хезмәтләре күрсәтелә. «Татар-91» күргәзмәсенә куелган К.Җәмитовның унике әсәре аеруча югары бәяләнә. Ә инде 1994 елда аның шәхси күргәзмәсе «Казан» милли мәдәни үзәгендә ай буе эшләде. Аны ачу тантанасында районыбыз делегациясе дә катнашты.

«Исеме дә, эш-хезмәтләре дә болгар-татар халкының бәгырь үзәгенә җуелмас рәвештә язып калынган Бакый Урманче, аннары Васил Маликов, соңында Кадим Җәмитов иң мәртәбәле бер сынчыбыз сыйфатында хөрмәтләнергә, кадерләнергә лаек булган шәхесләребездән берседер», — дип язды Әхәт Гаффар үзенең «Оста дөньясы» дип аталган бәяләмәсендә.

...Кадим Казанга, Австрия, Чехословакия, Германия, Франция, Бөекбритания, Япония, Америка, Корея, Канада кебек илләрдәге күргәзмәләрдә катнашканнан соң, Мәскәү аркылы кайтып төште. Шулай итеп, сынчының язмышы башта СССР башкаласында сыналды. Ә бит байтак шәхесләр, киресенчә, Казаннан Мәскәүгә китәләр. Хәзер Кадим Җәмитов башкалабызда, районыбызда еш була. Сабалыларга билгеле булганча, ул 1995 елда Татарстан Милли музееның районнагы филиалына бер дистә иҗади эшен бүләк итте. Алар арасында дөнья күләмендәге танылган икенче якташыбыз — академик, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Әбрар Кәримуллин бюсты да бар иде. Әлеге танта-

нада галим Әбрар ага үзе дә катнашты. (Бирегә Кадим Җәмитовның Ә.Кәримуллин кебек танылган утызлап татар шәхесләренең бюст-портретларын эшләвен дәвам итүен дә искәртү кирәктер.) Бу изге гамәле белән Кадим әфәнде үзен талантлы гына түгел, киң һәм юмарт күңелле, туган ягына тугрылыклы изге җан икәнен дә күрсәтте.

2005 елга аяк басканда, ул үскән төбәге булган Икшермә авылындагы «Тургай» балалар приютына Тукай бюстын бүләк итте. Бөек шагыйребезнең тууына 120 ел тулу уңаеннан, аның бюстларын тагын биш-алты мәктәпкә тапшырды.

Еллар үткән саен, Кадим Җәмитов иҗат иткән «җанлы сыннар» саны арта тора. Җәлилнең Оренбург шәһәрендәге һәйкәле дә аныкы. Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәймиев, Россиянең һәм Татарстанның атказанган урманчысы Нургали Миңнеханов бюстларын да Кадим Җәмитов ясады. Нурлатның үзәк мәйданына куелган шәһәр символы Нурлы Атның авторы да безнең якташыбыз. Хәзер ул дөньякүләм танылган шагыйрьләребез Габдулла Тукай белән Муса Җәлилнең бюстларын (120 һәм 100 еллык юбилейлары уңаеннан) эшләү белән мәшгуль.

К.Җәмитовның тормышында иҗат куанычлары да аз булмый, билгеле. Мәсәлән, атаклы артист Владимир Дуров нигез салган «Җәнлекләр театры» бар Мәскәүдә. Шуның 75 еллыгы уңаеннан үзе ясаган җәнлекләр-кошлар күргәзмәсе белән Кадимне дә чакыралар. Бирегә сынчының иҗаты белән юбилейга килгән КПССның Мәскәү шәһәре комитеты беренче секретаре, политбюро әгъзасы Виктор Гришин (1914–1992) таныша һәм соңыннан К.Җәмитов аның әмере белән башкаланың дәрәҗәле районыннан өч бүлмәле фатир ала.

Гаилә хәленә килгәндә, җәмәгате — үзебезнең Иске Икшермә авылы тумасы Нурзия белән матур тормыш корып, бер кыз һәм бер малай тәрбияләп үстерделәр. Хәзер Рәзидә Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында белем ала. Гали (борынгы шагыйребез Кол Гали күздә тотылып кушылган) әле мәктәптә укый. Гаилә башлыгы, танылган сынчы булу өстенә, әдәби иҗат белән дә мавыга. Аның хикәя-эсселары республика газета-журналларында әледән-әле басылып тора. Кадим Җәмит үзенең гыйбрәтле бала чагы, яшүсмер чоры, армия хезмәте еллары, гомумән, шәхси тормышы турындагы күләмле автобиографик повестен төгәлләп килә.

Менә шушы урында бу язманың авторына, бәлки, нокта куярга да кирәк булгандыр...

Әмма... Менә шул «әмма»лар җанны телгәли шул. Әлеге очеркны әзерләгәндә, миңа шактый чыганаклар — энциклопедияләр, китап-белешмәләр актарырга, героемның тәрҗемәи хәле турындагы мәкалә-бәяләмәләр белән танышырга туры килде. Аларның барысында да «Кадим Җәлил улы Җәмитов Саба районының Олы Арташ авылында 1946 елның 15 январенда туган» дип язылган. Юк! К.Җәмитов әби-бабаларының кендек каны тамган газиз җирендә тумаган шул! Дөньяга аваз салган көне дә унбише түгел. Елын әйткән дә юк. Кадим Җәмитовның 60 яшен тутыру форсатыннан файдаланып, хәзер дә чын хакыйкатьне каплап торган кара пәрдәне бераз гына ачып, талант иясенең кайчан да булса дөнья күрәчәк автобиографик повестеннан өзек китерик әле.

«...Әсирлектә булган анам белән ерак Германия җиреннән кайтып төшкәнмен мин. Алты айлык чагымда. Мине яшереп тотарга тиеш булганнар. Барлыгымны белдермәс өчен. Югыйсә «нимес көчеге» дип теткәләп ташларлар иде. Шулай итеп, өч яшькә кадәр якты дөнья, чит кешеләр күрмәдем мин Сталин илендә...»

Әйе, Кадимнең барлыгын башта өч кенә кеше — әбисе, әнисе һәм туган тиешле абыйсы гына белә. Аларга күрше-тирә дә сугылмый. Бик тә ярлы булалар чөнки. Әбисе биләмгә үзе генә чыккалый, эт — баш, сыер — аяк, эшкә чыксаң — бер таяк заманы булса да, әнисе фермадан кайтып керми. Тәпи йөри башлаганнан бирле, сабый өчен коты очканы «кеше...» була. Әбисе аңа һәрдаим: «Тәрәзә янына киләсе булма, кеше алып китәр, өйалды ишеге төбендә аждаһа көтеп утыра, кабып йотар!» — дип тукый.

Мунча кебек кечкенә, эчтән-тыштан терәүле өйдә Кадимнең яши торган җире өч «биләмә»дән тора. Чолан, түбән өй, кыш көне — мич башы. Ул шунда ашый да, йоклый да, уйный да. Уен дигәннән, аның «иптәшләре» дә, уенчыклары да кара таракан, кондыз, олы чебен, күбәләк, өй бакасы... соңрак — тычкан, мәче, эт кебек җан ияләре була. Җитмәсә, имидән иртә аерырга теләптер инде, әнисе сабыена үз телен үзе суырырга өйрәтә. Тора-бара, гел хәрәкәттә булгач, теле зураеп китә, ияге дә алга чыгып, соңыннан, үзе әйтмешли, берничә бүлемтекле «өенендә» яши торган җәнлеккә охшый башлый ул...

Кыскасы, тышкы дөньяның нәрсә икәнен белми шул. Әмма әбисеннән «кояш чыкты», «кояш кыздыра», «кояш сүрелде», «кояш баеган вакыт» дип сөйләгәненнән аның барлыгын, күктә «йөзеп йөргәнен» чамалый бала. Тыштан терәтелгән ишекне ачып чыгып, күктә янып торган түп-түгәрәк нәрсәгә карап торгач, күзләреннән яшь ага башлый... Шуннан соң бәбәкләре шешеп, берни белмичә, озак кына авырып ята.

«Бүгенге көндә Казан калабызның тамгасы булып балкып торучы «Хөррият» һәйкәле «кошын» шул сабый чакта саташып ятканда төшемдә күрдем. Кояш кебек күк йөзендә янып тора иде ул... Кырык җиде елдан соң исемә төште шул. «Һомай кошны» һәйкәл иттереп урынына «менгереп» куйганнан соң ук...» — дип искә ала.

Савыккач тагын ишегалдына тартыла. Башта әтәч, тавыклар, аннары кәҗә белән «таныша». Көннәр-

дән бер көнне боларга әбисенең ерак туганнары — ирле-хатынлы кешеләр бер кичкә килеп китәләр. Шулардан соң авылда «Тегеләр гарип, бөкре балаларын калдырып киткәннәр» дигән сүз тарала. Барлык каршылыкларны җиңеп, Кадим урамга ыргыла. Бу вакытта инде гаепсез сабыйның Германия җиреннән кайтканы да ачыклана. Олылар карап торып балалар көрәшә торган урында булган вакыйганы Кадим болайрак итеп искә ала.

...Анда беренче мәртәбә килеп чыкканда тышкы дөнья белән таныша башлаган гына чак. Минем барлыгымны, килмешәк булып Германия җиреннән кайтуымны бөтен авыл белә иде инде. Ул көнне башта мине сырып алдылар. Аннары сүзсез генә карап тордылар, araларыннан берсе әйтеп куйды:

— Шушымыни инде ул туганнары калдырып киткән гарип малай?

— Нишләп инде... Җилдән туган үз баласы бит ул аның...

— Беләсез икән пычагымны! Герман җиреннән алып кайткан килмешәк бит ул...

— Маймыл баласыдыр ул, — әнә бит, ияге чыккан, телен асылындырган, үзе бөкре...

Менә шулай дәвам иткән әңгәмәдән соң бер егет:

— Ягез, малайлар, шушы «нимес көчеген» сала аласызмы, көрәшеп карагыз әле, — дип команда бирә.

Шуны гына көтеп торган Кадимнән хәйран гына олы малайлар моны дөмбәсләргә тотыналар.

Канга батып кайта өенә канатсыз кош баласы. «Үзең сугышкансыңдыр әле», — дип каршы ала аны әбисе һәм чоланына бикләп куя.

Тере була Кадим. Әмма «токмачлар» гел куерып тора. Кызамык авыруыннан, колхоз фермасыннан качкан үгезнең мөгезенә эләгә-эләгә, котыра-котыра «туп итеп» уйнавыннан да исән кала...

Үзен-үзе белә башлаганнан бирле, күңеле сурәткә тартыла баланың. Дөрләп янган утынлы учакка карап торырга ярата ул. Аның ялкынында әллә нинди сихри көч, тере сурәтләр күрә.

Баскыч төпләренә (әбисенең бабасы чорыннан ук калган) зур-зур ташлар салынган була аларның. Шуның чәрдәкләнгән бер кисәген алып, баскычка сызгалый Кадим. Тора-бара әллә нинди сурәтләр килеп чыга, баскычны тутыргач, капка белән койманы бизәкләргә тотына.

Мич башында ятканда, түшәмдәге ботакларны, алар тирәсендәге сызык-эзләрне дә могҗизалы «шайтаннар», «җанварлар» итеп күрә булачак сынчы. Аннары әбисе ипи йә көлчә пешергәндә камырдан вак-төяк фигуралар ясап, шуларны кызган кирпечкә тезәп пешереп ашарга ярата...

Рәсем җене бик иртә кагыла шул Кадимгә. Әнисе, мәктәптә җыештыручы булып эшли башлагач, ярдәмгә малаен да алып бара. Бер класста парталар арасыннан карандаш кыйпылчыгы таба ул. Өйләренә кайткач, шуны бармак арасына кыстырып, ак морҗага сызгаларга керешә. Алар рәсем кыяфәте ала. Кадимнең күңелендә уелып калган тагын бер хатирә бар. Төсле карандашлар белән бәйле вакыйга монысы. Ул заманда мунча һәр хуҗалыкта булмый. Беркөнне аның әбисен юынырга дәшәләр. Кадимне дә ияртә ул. Мунчага бара торган кешеләргә юл авылдагы бердәнбер кибет аша уза. Андый чакта бала шунда сугылмый түзәме соң?! Керәләр, әбисе озак тормыйча, куып җитәрсең, дип китеп бара. Ә Кадим пыяла астындагы нәни җыйнак кына, яртылаш ачылган кечкенә генә тартмадан ялтырап күренеп торган алты төрле төстәге түгәрәк таякчыкларны күреп, тораташтай катып кала. Кибетчедән сорап алып, тотып карый, аннары сихерләнгән кебек була, авырлык белән булса да кечкенә тартманы кире кайтарып, әби белән мунчасын берьюлы онытып өенә йөгерә һәм матчага кыстырылган кәгазь төргәктә икегә бөкләнгән өч кәгазь акча (соңыннан бер-өч тәңкәлекләр булуы ачыклана) барлыгын исенә төшерә.

Шуларны эләктереп, кибеткә мышнап килеп керә ул. Сатучы Хурҗиһан апасы сабыйның рәсемгә хирыслыгын белә, шулай да: «Йә, әйт әле, кайдан алдың бу акчаларны?» — дип сорый.

«Әби бирде», — ди бала. Кибетче ышанып бетмәсә дә, кызганыптыр инде, карандашларны балага тоттыра һәм: «Калган акчаны әниеңә бирермен», — ди югалтуыннан куркып.

Үзләре янып торган, исләре үк тәмле булган карандашларны эләктерү белән куанып-шатланып өенә кайтып керә һәм, кеше юклыктан файдаланып, аларны очларга керешә. Шул мизгелдә әбисе кайтып керә дә: «Денсез! Тукта, шайтан малае! Калганнарын очлама — әниең кайтыр да илтеп бирер!» — дип кычкыра. Аннары акча төргәген барлап килә һәм елый башлый.

Сабый бу хәлгә аптырап кала, чөнки аның әбисен елатканы булмый.

— Әби, җаным, мин ул акчаларны эшләп түләрмен, менә күрерсең!

Дөрестән дә, алты елдан соң авылдашларының резина итекләрен ямап-ябыштырып кайтара ул әлеге акчаны.

Әнисе кайткач, давыл янәдән бер «котырып» ала. Һәрбер тиен хисапта була шул ул заманда. Әни белән әби тагын бер тапкыр «дуэт» ясап елашып алалар. Кире илтеп кенә бирерләр иде, очланганнар бит. Шулай итеп, карандашлар үзенә кала гөнаһсыз сабыйның. Ә инде очраклы килеп чыккан кәгазь кисәгенә тәүге төсле сызыклар төшергәндә ниләр кичергәнен бүген дә онытмый Кадим. Чөнки бу аның күптөсле дөньяга беренче адымы, Бөек Матурлык патшалыгына керүе була...

Хөрмәтле укучым! Мин К.Җәмитовның «Истә калганнары»ннан берничә генә мисал китердем. Әнә шундый күңелләрне тетрәндерә, йөрәкләрне телгәли торган эпизодлар бик күп була сынчының тормыш юлында. Алары турында инде чыгачак китабыннан укырсыз. Авторның үз дөньясы гына түгел, авыл

халкының авыр тормышы да сурәтләнә ул хәтер-хатирәләрдә.

— Исемсез кеше булмый, — дип искә ала Кадим. — Ул адәм баласына тугач та бирелә. Дүрт яшьләр тирәсендә генә барлыкка килде ул минем. Ягъни тышкы дөнья белән аралаша башлагач. Таныклык алганда булгандыр инде ул. Җитмеш җиде көнгә соңрак туган итеп теркәгәннәр мине. Шулай итеп, минем туган җирем дә, туган көнем дә икәү... Миңа исемем белән юньле-башлы эндәшүче булмады. Укый башлагач кына яңгырый башлады ул. Таныклыгымда фамилиям Җәмитов булса да, җиденчене бетергәнчегә кадәр әбием фамилиясе белән — Миңнеханов булып йөрдем. Ә «әтием» Җәлил Җәмит улы дип теркәлгән иде. Анамның кыз вакытта Донбасста танышкан егетенең исеме булырга тиеш ул.

...Нәкъ җитмеш җиде көн алдан котладым мин аны 60 яшьлек юбилее белән. Телеграмманы алгач аптырап калган ул. Чираттагы шаярту дип уйлаган. Телефоннан аңлаштык аннары.

— Ул көнне үз гомеремдә бер кешенең дә котлаганы булмагач, башыма да килмәде, — диде.

Ярар, бу язманы табигатемә хас шаярту тонында төгәлләп куйыйк инде.

Икенче туган көне белән дә котладым аны районодашлар исеменнән. Шуннан соң сүзебез иҗат мәсьәләләренә барып тоташты, һәм аның сирәк кешедә була торган сынчылык талантының кан аша бирелүенә ишарә ясадым.

Әмма бу фикер белән җәһәт кенә ризалашасы килмәде.

— Монысын әле расларга кирәктер. Менә син каләм тибрәтүеңне каннан килә дип уйлыйсыңмы?

— Әлбәттә, — дидем мин, катгый итеп. — Минем бабай ягыннан туганнар арасында классик язучылар, шагыйрьләр бар бит...

— Кемнәр алар? — дип сорады Кадим Җәмитов.

— Берсе — Кави Нәҗми, икенчесе — Нажар Нәҗми, — дидем. — Һәм... Тәлгат Нәҗми...

Ул ихлас күңелдән, эчкерсез итеп көлде.

Менә шулай гел елмаеп, озак яшә, Кадим! Арыма, талчыкма, алҗыма, вак-төяк хөсетлекләргә, каршылыкларга бирешмә! Үзебез кайчан да булса барыбер бу фани дөньядан бакыйлыкка күчәрбез, дустым. Әмма иҗатың үлемсез һәм мәңгелек Синең!

*2004–2006*

# Сабыр ире иде Сабаның

Районыбыздан чыккан ике дистәгә якын артист арасында Шамил Бариев аерым бер үзенчәлекле урын алып тора. Үзенең кыска гына — кырык өч ел гомеренең яртысын татар театрына багышлап, иҗатташлары арасында ихтирам да, уңыш та казана. Ул А.Островскийның «Күктән яуган акча» спектаклендә — Крутицкий, Н.Фәттахның «Кол Гали» драмасында — Ярмыш, Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар»ында — Артомонов, М.Байҗиевның «Кияү белән Кәләш»ендә — Кияү, Ч.Айтматовның «Ахырзаман»ында — Ирназар, М.Садыйкованың «Бәхетлеме син?» әсәрендә — Мирвәли, Вардис, Гариф, Н.Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ендә — Вәзир, Р.Батулланың «Өчәү юлга чыктык» пьесасында — Ихлас, Н.Исәнбәтнең «Зифа»сында — Айдар, Аманулланың «Әлепле әртисләре» комедиясендә Режиссер (соңгы эше) образларын аеруча яратып иҗат итә. Шамил уйнаган геройларның күбесе фаҗигале язмышлы булса да, тормышта ул үзе шат, җор күңелле, хисчән, бик матур итеп җырлый торган шәхес була. Кыскасы, Шамил Бариев 1973 елда Ленинград дәүләт театр, музыка һәм кинематография институтын тәмамлап кайткач, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры белән гомерен соңгы сулышына кадәр бәйли.

Театрдан соң Шамилнең тагын төп ике эше була. Ул — укыту һәм телевидение-радио. Артистның күпкырлы эшчәнлеге, саекмас сәләте педагогик эшчәнлегендә дә ачык чагыла. Ш.Бариев 1991 елдан Казан дәүләт мәдәният академиясендә режиссер-педагог вазифасын башкара һәм сокланырлык шәкертләр тәрбияли. Ул бигрәк тә җырчы Хәния Фәрхи, телевидение дикторы Инсаф Абдулла, артистлар Илдус Фәиз, Резидә Төхвәтуллина, Ләйсән Мәхмүтова, Искәндәр Сираҗи белән горурланып яши. Буш вакытларында шахмат белән мавыга, балыкка йөри. Театрның профком рәисе буларак та артистларга бик күп игелекләр эшли.

Әйе, хәзер без Шамил турында үткән заманда язарга мәҗбүрбез. Чөнки, белгәнегезчә, театр сәнгатенең йөзек кашы, Татарстан Республикасының атказанган артисты, Муса Җәлил исемендәге бүләк лауреаты, Татарстан театр әһелләре берлеге әгъзасы Шамил Мәсгут улы Бариев 1994 елның 11 мартында — Рамазан аеның соңгы җомга көнендә — йөрәк өянәгеннән вакытсыз вафат була. Кешеләргә ярдәмчел, киң күңелле изге җанны озатырга бик күп халык җыела Камал театрына. Тамашачылар зыялы артистның табуты янына үз күңелләрендә олы хөрмәт саклангакга килә. Бик күп истәлекләр, шигырьләр басыла матбугатта. Икенче бер якташыбыз, Бариевларның гаилә дусты, Керәннедә туып үскән Өлфәт Хаҗиев язган «Театрда бүген тамаша юк...» дигән шигырьдән өзек китерәбез:

Театрда бүген тамаша юк,
Театрның йөзе кайгылы.

Бар йөрәкләр
Әрнеп-ярсып тибә:
«Югалттык, дип,
Шамил Барины...»

...Театрда бүген тамаша юк,
Театрда матәм моңнары...
Озата халкым
Мәңгелеккә Улын —
Колакларда чыңлый җырлавы...

...Шамил Бариев районыбызның Олы Арташ авылында укытучы гаиләсендә дүртенче бала булып туа. Укымышлы, тыйнак, тәртип яратучан Бариевлар гаиләсе авылда иң хөрмәтлеләрдән санала. Моның өстенә әле алар сәнгатькә гашыйк кешеләр дә. Абыйлары Наил бик матур итеп баянда уйный, Раиф җырлый (алга китеп шуны да искәртү урынлы булыр: алар, Шамил белән парлап, якташыбыз, СССРның халык артисты Шәүкәт ага Биктимеров уйный торган Әлмәндәр картның «Ала карга дигән, әй, асыл кош, тәүбә иттең мәллә очмаска?» дип башланган җырны бик яратып башкарганнар), апалары Наилә исә күпсанлы үзешчән сәнгать түгәрәкләрендә катнаша. Бариевларның киленнәре дә сәнгатькә якын кешеләр булып чыга. Раиф үзләре хорга йөри торган Ленин исемендәге мәдәният сарае биючесе Наҗиягә өйләнә. Шамилгә шушы ук мәдәният сараеның иң чибәр кызы Гөлфия Садыйкова насыйп була. Әмма Шамилдән соң Гөлфия дә күп тормый... Яратышкан ярлар бер-берсеннән башка озак яши алмыйлар икән шул, дип искә ала хәзер Раиф әфәнде. Гөлфия белән Шамилнең уртак җимешләре булып кызлары Айгөл кала. Аның әтисе белән Яңа елга багышланган тапшыруларның берсендә парлап җырлаганнарын тамашачылар хәтерли булыр әле.

Бераз читкәрәк кереп киттем, ахры. Төп фикерем — Раиф Бариевның узган ел «Хәтер» нәшриятында дөнья күргән «Җырга әверелгән гомер-мизгел...» дигән китабы турында иде. Кыскасы, Раиф Бариев бу китабын язып газиз туганы алдындагы изге бурычын үтәгән, артист энесенә сүздән һәйкәл куйган. Автор аны жанр ягыннан «ядкарь» дип билгеләп, тыйнаклык күрсәткән. Бу әсәр, әдәбият белгечләре бәяләвенчә, документаль повестька бик якын тора. Андагы вакыйгалар укучыны үзеннән-үзе тартып ала, китап битләрен бер-бер артлы ачканыңны сизми дә каласың.

Китап «Хәтерлим мин әле бүгенгедәй...» һәм «Аны язлар алып китте...» дип аталган ике бүлектән тора. Беренче бүлек безгә, сабалыларга, аеруча якын. Чөнки анда таныш авыллар, аларның сихри табигате, кешеләре белән кабат очрашасың.

Шамилләрнең әтиләре Мәсгут ага үзе Тарлау (Язлы Арташ) авылында Габделбарый мулла гаиләсендә дөньяга килгән. Яшьтән әтисез калып (әбиләре Мәсрүрә дүрт бала белән 24 яшендә тол кала), мулла малае булганга, кимсетелүләр күреп үссә дә, укытучы, мәктәп директоры була. Башта — Олы Арташта, соңыннан Явлаштауда директорлык итә. Раиф — алтынчы, Шамил өченче классны тәмамлагач, Казанга күчәләр. Мәсгут ага да озын гомерле булмый, илле яшендә кинәт кенә үлеп китә. Әниләре Шәмсенур чыгышы белән Тимершык авылыннан — хәлле крестьян Габделкәбир гаиләсеннән. Аларны колхозга алмыйлар. Шуннан соң ул, Себергә җибәрүләрен сизеп, бөтен мал-мөлкәтләрен калдырып, гаиләсе белән Лесхоз бистәсенә китеп котыла. Кызлары Шәмсенур, укырга календарь битләреннән генә өйрәнсә дә, курсларга барып, аннары Арчада педучилищеда белем алып, мөгаллимә була. Шәмсенур һәм Мәсгут Бариевларның Наил белән Наиләләре Тимершыкта укытканда туа. Алар монда СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеровның әтисе Хәсән абзый белән бер чорда эшлиләр. Шамилне Шәүкәт аганың якташы буларак та хөрмәтләве Мишә елгасы буйларында бергә үсүләреннән килә.

Татар Икшермәсе һәм Үзәк (хәзер Теләче районы) мәктәпләре директоры булып эшләгән, редакциябезгә озак еллар мәкаләләр язып торган, соңыннан газетабызның Закир Йосыпов исемендәге премиясенә лаек булган Хәлим Бари улы (авыр туфрагы җиңел булсын) аша да бик якын ул. Мәсгут ага һәм Хәлим Бариевлар — бертуганнар. Гомумән, «Бариев абыйлар» — нәселләре белән булган, уңган, тырыш, гыйлемле затлар. «Җырга әверелгән гомер-мизгел...» дигән китапны алып укысагыз, Ике басу Арташ, Чәбия-Чүрчи, Мишәбаш авыллары белән дә якыннанрак танышырсыз. Явлаштаудагы физкультура укытучысы Мөхәммәт абый, Шәкүр белән Бәкер, Плюс Әминнәр дә телгә алына анда...

Язманы Рәсих Шәмсетдиновның вакытсыз гүр иясе булган Шамил Бариевның якты истәлегенә багышланган «Ышанмыйм!..» дигән шигырендәге юллар белән тәмамлыйк.

Мишә буйларында туып үскән
Сабыр ире иде Сабаның.
Әйтче, кәккүк, аның сәгатьләрен
Нигә шулай бик аз санадың?

Театрда матәм...
Асыл ирен
Соңгы юлга халкым озата.
Бу хушлашу авыр...
Шуны аңлау

Йөрәкләрне бигрәк сызлата.

*2000*

# Театр — аның яшәеше

Сабаның элеккеге мәдәният йорты. Сәхнәдә — чибәр, озын толымлы, нәфис гәүдәле, ихлас күңелле Әлфия Хәсәнова. Гөр килеп торган зал тып-тын калган. Әлфиянең үзенчәлекле тавышына гашыйк тамашачы күзләрен сәхнәгә төбәгән. Ул, булачак актер, Гадел Кутуйның Бөек Ватан сугышында ил азатлыгы өчен көрәшүче совет солдатының изге хисләрен сәнгатьчә югарылыкта яңгыраткан «Сагыну» нәсерен сөйли...

Әйе, Әлфиянең дулкынландыра торган, күңелне сихри матурлык белән тутыручы кабатланмас тавышын күпләр хәтерлидер әле. Яшьли бу фани дөньядан киткән Газиз Мөхәммәтшинның «Ни уйлыйсың, дөнья?» нәсерен, башкорт шагыйре Рафаэль Сафинның «Кыр казлары»н тамашачыга җиткерә ала Әлфия. Ә зәвыклы һәм сизгер Саба халкы аның иҗатындагы үсешне күзәтеп, барлап тора. Пионерлар йортында методист булып эшләгән елларда, Әлфия район мәдәният бүлеге каршындагы агитбригада составында бөтен авылларны иңләп-буйлап чыкты, кичен сәхнәдә чыгыш ясаса, көндезен аны басудагы механизаторлар янында яки җәйләүләрдә күрергә мөмкин иде. Сабада уйналган бер генә спектакль дә Әлфиядән башка узмады.

Районыбызның иң гүзәл табигать почмагына урнашкан кечкенә генә Чәбки-Саба авылындагы Якуб белән Мәгъфүрә гаиләсендә дөньяга килә ул. Әнисе иң дәрәҗәле һөнәр иясе иде аның. Утыз җиде ел балаларга белем бирде мөгаллимә. Ә этисе Якубны 1931 елда колхоз рәисе итеп сайлаганда, аңа егерме ике яшь кенә була. Тырыш җитәкче эшне оста итеп оештыра белде. 1937 елда арышның һәр гектарыннан егермешәр центнер уңыш үстергән өчен район слетында тана белән бүләкләнә ул. Сугыш башланыр алдыннан район Советы депутаты итеп тә сайлана Якуб ага. Ә инде 1942 елда үзе теләп фронтка китә. Ленинград блокадасын өзү операциясендә, Финляндиянең башкаласы Хельсинки шәһәрен азат итү сугышларында катнашып нык яралана һәм госпитальгә озатыла. Җиңү шатлыгы килеп шактый вакыт узганнан соң гына аякка баса ул. Туган авылына кайтуга, аны яңадан колхоз рәисе итеп сайлыйлар. Хезмәт биографиясенең соңгы елларында да җаваплы урыннарда эшли.

Район тарихына исеме олы хәрефләр белән язылачак Әлфия Хәсәнова бала чагының омтылу-ашкынулы хыялы булган профессиональ сәхнәгә тартыла һәм, чын сәнгать серләрен үзләштерү өчен, Казан мәдәният һәм сәнгать университетының режиссерлар әзерләү бүлегенә укырга керә. Аны уңышлы тәмамлаганнан соң, туган ягына кайтып, Сабадагы халык театрында иҗат итә башлый, спектакль куя.

Талантлы кызны шул еллардагы Кучмә театрның баш режиссеры Равил Тумашев күреп ала һәм яшь актерны олы сәхнәгә чакыра.

Әлфия Хәсәнова белән театр турында фикерләшә башласаң, аның бөтен тормышы, мәхәббәте, бәхете сәхнә икәнен аңлыйсың. Күпме йокысыз төннәр, газаплы эзләнүләр кичергән ул. Спектакль уңышлы үткәндә сөенгән, кимчелекләргә күңеле сыкраган, җаны елаган. Шуңа күрә аңардан шәхси тормышы, гаиләсе, улы турында сорашсаң, сүз башы барыбер шул ук театрга, сәхнәгә, үзе тудырган образларына әйләнеп кайта.

Иҗатта иректе булырга омтылучы Әлфия иң беренче булып Туфан Миңнуллинның «Кырларым-тугайларым» спектаклендә Мөслимә образын тудыра. Бу әсәр Сабада уйналасы көнне Ләлә Миңнуллина авырып китә. Әлфияне ашыгыч рәвештә туган ягына илтеп куялар да кичкә образга керергә кушалар. Шулай итеп, канат куеп очырган тамашачысы белән «Казан артисткасы» буларак очрашып, үзе дә чыныгу ала, коллективын да көтмәгәндә килеп туган хәлдән коткара.

Әлфия Якуб кызы, хәтер йомгагын сүтеп, уйнаган рольләрен күздән кичерә. Саный китсәң, утыз бишкә җыела алар. Ризван Хәмиднең «Кайтыр идем» спектаклендә Зифа образын тудырган өчен республикада үткәрелә торган фестивальдә аңа лауреат исеме бирелә. Дәринә (Илдар Юзеев «Кыр казлары артыннан»), Камилә (Шәриф Камал «Хаҗи әфәнде өйләнә»), Сихерче (Нәбирә Гыйматдинова «Сихерче»), Зәйнәп (Сәет Шәкүров «Сөяркә»), Геро (Уильям Шекспир «Гаугалы мәхәббәт»), Газия (Эсфир Яһудин «Мәхәббәткә мәдхия»), Аида (Ирина Грекова «Тол хатыннар көймәсе») һәм башка рольләр аша җәмгыятьтәге чынбарлыкны дөрес итеп гәүдәләндерә Әлфия. Үзе сызган юлы, кабатланмас иҗаты, бай таланты белән хыялланып яшәвен дәвам итә, алга таба уйныйсы рольләре төшенә кереп йөдәтә...

Ә менә ярты гасырлык юбилее һәм иҗат эшчәнлегенең егерме биш еллыгы уңаеннан үзе эшләгән театр сәхнәсендә бенефис-спектакльдә Хәбирә образын (Рәдиф Сәгъди «Яз галәмәте») тудыра.

Тормыш байтак кына сикәлтәләрдән дә тора. Алардан чыгу юлларын таба белде язмабыз герое. Чирек гасыр буе сәхнәдән матурлык өләшкән Татарстан Республикасының атказанган артисты Әлфия Хәсәнованың алдагы иҗат чоры да бәхетле булыр дип ышанабыз.

# Кан һәм җан тарту

Сиксән яшен түгәрәкләп килүче Гөлчирә Хуҗахмәт кызы Хөрәмшина белән көтмәгәндә очраштык. Дөресрәге, без аны Сабадан машинабызга утыртып алып барып, башкалабызның тимер юл вокзалында калдырырга тиеш идек. Өлкән яшьтәге кунакның әби-бабаларының, ата-аналарының кендек каны тамган газиз җиреннән — Саба-Йортыннан — гомер кичергән Ташкентына китеп барышы икән. Саба белән Казан арасындагы үткән сәгать ярым вакыт эчендә матур гына әңгәмә дә корып алдык. Гөлчирә ханымның уйлап кына әйткән һәр җөмләсеннән, һәр хәрәкәтеннән зыялы асыл затларга хас акыллылык һәм нәзакәтлелек бөркелеп торуын тиз тоемладык. Аның хәтер сандыгының нәсел шәҗәрәсе, туган Ватаны, яшәгән ил-җире, туганнары Госман, Хан абыйлары, Әсма апалары турындагы барлык мәгълүматны сыйдыра алуына гаҗәпләнмәү һич мөмкин түгел иде.

— Язмыш... Язмыш... Берәүләргә рәхимле, икенчеләргә миһербансыз ул. Адәм баласы дөньяга бәхет өчен туса да, язмыш кемгәдер мәрхәмәтлерәк карый, кемгәдер сынау арты сынау куя, диңгезгә ташланган йомычкаларны рәхимсез җил ничек каккалап-суккалап бер ярдан икенчесенә куып йөртсә, тормыш дулкыннары да кеше белән шулай уйный, — дип сүзен башлады Гөлчирә апа. — Үткән еллар — гомер үлчәве, диләр бит. Менә без дә бәхет эзләп йөреп, сигез дистә ел узганын сизмичә дә калдык. Гомумән, миңа тормыш арбасының гел алдыннан йөгерергә туры килде. Шулай да язмышыма үпкәләмим. Тагын шуны әйтә алам: бала чактагы, яшьлектә булган вакыйгалар, мизгелләр хәтердә озак саклана. Минем дә күңелемнән мәңге чыкмый торган бер шомлы хатирә бар. Дәһшәтле сугыш башлану турындагы хәбәрне очраклы рәвештә әти-бабайлар туфрагында — Сабада ишеттем. 1941 елның матур җәе иде. Без, унҗиде-егерме яшьлек хыялый, яшәү дәртебез ташып торган кызлар-егетләр, Казанга туристлар буларак килдек.

«Җай чыкса, Сабага — туганнарга сугыла күр», — дип калган иде әтием. Пароходыбыз Казанда бер-ике көн торырга тиешлеген белгәч, ике иптәш кызым белән Шәмәрдән станциясе аша Сабага сугылдык һәм шунда, һич көтмәгәндә, сугыш башланганын белдек. Хөрәмша бабай, әби, башка агай-энеләр белән күреп сөйләшкәч, яңадан башкалага киттек. Әмма безгә Казан пристанендә бер ай утыргач кына, бик күп җәфалар күрә-күрә, ягъни нәрсә туры килсә, шуның белән Ташкентка әйләнеп кайтырга насыйп булды.

...Матур гына барган әңгәмәбез шушы урынга җиткәч, машинабыз тимер юл вокзалына килеп туктады. Сүзебезне туктатып торырга мәҗбүр булдык һәм икенче тапкыр очрашкач дәвам итәргә килешендек... «Сабага миннән сәлам әйтегез, исән булсам, тагын кайтырмын әле», — диде Гөлчирә апа саубуллашканда.

Тарта тамыр, тарта кан, тарта әби-бабайлар туфрагы, дип юкка гына әйтмиләрдер шул. Насыйп булгач, яңадан биш ел үткәч очраштык Гөлчирә апа белән. Ташкенттан кайтып Сабага төпләнгән табибә кызы Гөлфия, оныгы Ирек, килене Рушан, оныкчыклары яши торган тыйнак кына йортта әңгәмәбезне дәвам иттек. Гөлчирә Хуҗахмәт кызы сөйләгәннәрне магнитофон тасмасына язып та алдык. Сиксән биш яшьлек бәйрәменә, «кул сузымы» вакыты калган милли рухта тәрбияләнгән якташыбызны, хәтерен чуалтмас өчен, бүлдермәскә тырыштык.

— Гомерем көзгә кереп барганда, бик еш уйланам. Безнең нәсел агачыбыз тирән тамырлы, киң ябалдашлы булган. Таралганбыз, сибелгәнбез, чәчелгәнбез... Әмма Татарстан, Саба дигән газиз җир безне һәрвакыт үзенә тартып торды. Ерак бабаларыбыз эш рәтен белүче һөнәрчеләр — балта осталары булганнар, чана табаннары ясаганнар. Кушаматыбызның «Чанатабан» икәне дә мәгълүм. Төп нигезебез Сапирый мәчетеннән ерак түгел урында, иске зират каршында булган. Анда Әсма апабыз озак гомер кичерде, туксанны түгәрәкләгәч кенә бакыйлыкка күчте.

Хәзер гаилә тарихыбызны барлыйк. Мәдрәсәдә укучы әтиемә унбер яшь тулгач, аны, Мөхәммәт исемле саңгырау һәм телсез иптәше белән икесен, Федор Иванович дигән кеше, русча итеп әйтсәк, вербовщик, Әстерханга алып китә. Шунда алар тегүче һәм аяк киеме төзәтүче һөнәрләрен үзләштерәләр. Эш сөючән, намуслы, гадел әтиемне чыгышы белән Сембер губернасыннан булган, Әстерханнан ерак түгел тоз күле янәшәсендәге Баскынчак шәһәрендә гомер итүче Минһаҗ бай күптәнге танышы Андрей Федоровичтан сорап, приказчик итеп ала, ышанып кибетен тапшыра һәм тора-бара Фатыйма исемле кызына, ягъни минем булачак әниемә өйләндереп тә җибәрә. Алар, алга таба бергә утыз сигез ел гомер итеп, якты дөньяга унбер бала тудыралар. Шулай итеп, Ходайдан биргән сәләт-һәвәслеген камилләштерә торгач, әтием ару тормышлы, яхшы киенгән, югары культуралы кешегә әйләнә һәм үзе мөстәкыйль рәвештә Кызыл Орда портына сәүдә белән йөри башлый. Авылдашы Мөхәммәтне дә калдырмый, билгеле. Әмма аны бирелгәге товар әйләнеше һәм керем канәгатьләндерми. Утызынчы елларның ахырында, Саба районы рәсми төстә оешыр алдыннан, туган җиренә мал белән кайта. Өйдәгеләре, улларының ке-

ше булганын күреп, бик куаналар, әлбәттә. Әти агачтан кырылып буялган һәм үз төсендәге бик күп савыт-саба: коштабаклар, кисмәкләр, кашыклар, чүмечләр, башка кирәк-яракларны Сабадан ат белән Казанга китереп, аннары пароходта төяп, Баскынчакка алып кайта. Боларны бик яратып алалар Әстерхан якларындагы казахлар. Алар бу олы кисмәкләргә икешәр куйның итен ваклап, тозлап куялар. Кыскасы, сәүдә тагын да җанланып китә. Әмма... Менә бу рәхәтлекләр озакка бармады шул. Безнең өчен язмыш зур сынаулар әзерләгән булган. Ачлык-ялангачлык, кайгы-хәсрәтле көннәр — Сталин чорындагы репрессия еллары башланды, — дип бераз сүзсез торды Гөлчирә әби. Аннары тамагына утырган «төерен» йотып җибәргәндәй булды һәм сүзен дәвам итте: — Йортыбызны, мөлкәтебезне раскулачивать иттеләр. Безгә идәнгә ятып елаудан башка чара калмады. Ике катлы таш өебезгә шәһәр башкарма комитеты (горисполком) урнашты. Әти кулга алынудан куркып чыгып югалды. Олы абыем Нурәхмәтне Сахалинга җибәрделәр. Безне, әни белән биш баланы, башта Тамбов өлкәсенең Гореловка авылына сөрделәр. Анда көч-хәл белән кышны үткәрдек. Бер телем ипи өчен тилмереп яшәгән авыр көннәр дәвам итте. Язын ничек кирәк алай Балашов шәһәренә килеп, бик начар гына баракка урнаштык. Бу вакытта безне әни ягыннан агай-энеләребез эзләтә башлап, кайда икәнебезне чамалаганнар. Эт чыкмаслык караңгы бер төндә ишегебезне берәү шакыды. Хәерче киемдәге, хәтта аягындагы галошларын да мунчала белән бәйләгән, сакал-мыек баскан бер сукбай — бомж басып тора иде. Ул әти булып чыкты һәм безне Сабага алып кайтып китте. Ул вакытта — 1933 елда — әтинең үзе бай булмавы, ә барлык мөлкәтнең хатынының атасыныкы икәнлеге турында документ юнәткән булалар әни туганнары. Сабада башта Һәдия җиңгиләрдә, әбидә тордык, аннары колхоз-яшьләр мәктәбендә (ШКМ) әти каравылчы булып урнашты. Без монда елдан артык кына яшәдек, сеңлем белән башлангычта укыдык. Шул вакытта самими, эчкерсез һәм гөнаһсыз күңелемдә мәңге онытылмый торган тирән җәрәхәт калды: мине пионерга алмадылар, галстук бирмәделәр. Бай кызы, имеш... (Монда алга узып шуны да әйтергә кирәк: пионерга ярамаган Гөлчирә соңыннан 30 ел партия сафларында тора.)

...Кешенең язмышы тумыштан маңгаена языла, дисәләр дә, аны алдан күреп-белеп булмый шул. Хуҗахмәтнекеләрнең алга таба эчәр сулары, җыяр ризыклары Урта Азия якларында була икән. Башта кире Баскынчакка кайтсалар да, анда яшәрлек булмый. 1934 елда Гөлчирәнең әнисенең бертуган абыйсы боларны Чимкент өлкәсенә алдыра. Сайран дигән кышлакка килеп урнашалар да, алтын куллы Хуҗахмәт белән Фатыйма үзбәкләргә өс һәм аяк киемнәре тегеп, ярыйсы гына көн күрә башлыйлар. Гөлчирә биредә башлангыч мәктәпне тәмамлый. Күпне кичергән, урыс-татар-казах-үзбәк төбәкләрендә шактый йөргән-аралашкан, гомумән, язмыш шактый сынаган унөч яшьлек кыз русчаны шәп белә. Шуңа күрә аны дүрт класс белем белән Чимкенттагы мәктәпкәчә техникумга укырга алалар. Бер үк вакытта ул яшәгән җирендә наданлыкны бетерү хәрәкәтендә катнаша, аны караңгы кышлактагы өлкән яшьтәге үзбәкләр дә, аларның балалары да бик хөрмәт итә, унбиш яшьлек Гөлчирәне депутат итеп тә сайлыйлар.

Ташкент каласында Гөлчирәнең әтисе белән бертуган Хөрәмшаның кызы Зәйнәп апасы (унбиш яшендә Сабадан киткән була) тамыр җәеп яши. Бик зыялы гаилә була алар. Балаларына тиешле белем дә вакытында бирелә. Мәҗит сәнгать училищесын тәмамлый. Габделкадыйр Казанга килеп хәрби училищеда укый, сугыш вакытында Теләчедә хәрби комиссар вазифасын башкара. Зәйнәпнең абыйсы Әбүталип та генерал дәрәҗәсенә күтәрелә...

Бу зыялы нәселгә кереп китүнең сәбәбе бар, әлбәттә, хөрмәтле укучым! Менә әлеге язманың герое Гөлчирәне нәкъ Мәҗит абыйсы Ташкентка китертә дә инде. Әмма тормыш энергиясе, белем алу теләге ташып торган яшь кызны биредә дә сикәлтәле дә, гыйбрәтле дә сынаулар көткән була. Бер кара эчле үзбәк, үзенеке итү теләге белән, әлбәттә, саф күңелле Гөлчирәнең паспортын, башка документларын урлый... Бу вазгыятьтән чыгу өчен күпне кичерергә туры килә аңа, әмма ул югалып калмый. Үзбәк күлмәге, озын балаклы ыштан һәм түбәтәй кия дә ул вакыттагы Югары Совет Рәисе Юлдаш Ахунбабаев янына китә. Өч көн йөргәннән соң эләгә ул Үзбәкстан ССРның дәүләт эшлеклесенә һәм нәтиҗә куанычлы була: Гөлчирә институтка кабул ителә, эшкә урнаштырырга да әмер бирелә. Кыскасы, шатлыклы визит була ул. Үз теләгенә ирешкән кыз өч курстан соң читтән торып укуга күчә һәм балалар бакчасы мөдире булып эшли башлый, яшьлек мәхәббәтен табып, Зыя исемле кешегә тормышка чыга. 1944 елда — хәвефле чорда кызы Гөлфия туа... Ул елларда кабат күпне күрергә, күпне кичерергә туры килә алар гаиләсенә. «Бары тик кайгының ил белән бергә булуы гына түзәргә, барлык авырлыкларны җиңәргә рухи ныклык, көч бирде, шуңа күрә кыенлыклары да, Бөек Җиңү көннәрендәге иң зур шатлык-сөенечләр дә бүгенгедәй хәтердә», — дип куйды әңгәмәдәшем.

Ир хатыны буларак та лаеклы гомер юлы үтә Гөлчирә ханым. Кызы Гөлфияне табиблыкка укыта, улы Искәндәр дә үзенең яраткан һөнәрен сайлый. Шулай итеп, Гөлчирә Хуҗахмәтовна заманның кырыс җилләренә баш имичә, тырыша-тырмаша өскә үрмәли, булган белемен, оештыру талантын яшь буынны тәрбияләүгә бирә, балалар күңелен аңлаудан зур канәгатьләнү, тәм таба. Кыскасы, аның ак һәм пакь күңеле бу дөньяның карасына бирешми, туганнары белән элемтәсен саклый, әтисенең кендек каны тамган Татарстан җирен, газиз телен дә онытмый, саф татарча сөйли.

— Туган якның төтене дә татлы, күңелгә якын, дигәнме әле бер шагыйрь, — дип, безнең әңгәмәне

тыңлап утырган кызы Гөлфия сүзгә кушылды.

— Мин Сабага беренче мәртәбә Тәгъзимә апа белән 1959 елда кайттым. Ул вакытта миңа унбиш яшь иде. Менә олыгайган көнемдә әти-бабайлар җиренә кайтып яшәрмен дип һич уйламаган идем. Улым Ирекнең дә бик кайтасы килде...

Әйе, Ирекнең дә тарихи Ватанына ничек тартылуы турында сөйләгәне күңелдән чыкмый.

— Моннан ун еллар чамасы элек миңа бергә эшли торган дустым белән Казанга командировкага килергә насыйп булды. Без Сабага да сугыласы иттек, — дип сөйли башлады ул туган телендә. — Кышкы кыска көндә соңгы автобус белән килеп төштек. Караңгы иде инде. Телефоннан Сабага кайтып төпләнгән Тәгъзимә апа белән аның улы Шәһрәт яши торган йортны эзләп таптык. Чәй эчтек. Сөйләшеп утырдык. Ятып йокладык та иртәнге автобус белән китеп тә бардык. Әнә шул арада — бер төн эчендә Саба миңа ошады һәм бирегә бөтенләйгә кайтырга карар иттем...

Менә аның Сабаны бер төн эчендә ошатуын ничек инде кан тарту димисең! Гаҗәп бит?! Башта әнисе белән кайтып керә алар бабалары җиренә. Начар гына өйдә торалар, барлык качаклар кебек бик күп кыенлыклар кичерәләр, әлбәттә. Аннары юньлерәк йорт сатып алалар. Тора-бара Ирекнең җәмәгате Рушан белән кызы Диана да кайта һәм инде... еллар үткәч, уллары Руслан — нәселне дәвам итүче ир бала дөньяга килә... Менә шулай итеп, Хөрәмшаныкыларның бишенче буыны борынгы Байлар Сабасына кайтып сыена. Шушы урында, телисеңме-теләмисеңме, үзеннән-үзе шагыйрь Дамир Гыйсметдиновның шигъри юллары күңелгә килә:

Тагын кайттым, сагынып кайттым әле.
Йөрәкләрдә сагыш, давыл бар.
Ярый әле кайтып сыеныр өчен
Җир йөзендә туган авыл бар...

*2005*

# Зенитчы Мәдинәкәй

Урамда кышкы төн. Салкын җил кар бөртекләрен туздырып уйный. Ә авыл тынычлап йоклый. Шул тынлыкны бозган самолет тавышына еш кына сискәнеп уяна Мәдинә апа. Алтмыш елга якын шулай ул. Пассажирлар самолеты түгеллеге икәнен гүләвеннән яралы тәне һәм күңеле белән сизә ул. Шуңа күрә гомере буе сугыш турында кино да карамый.

Бераз черем итеп алырга ниятләсә дә, яңадан йокы алмый шул инде күпне күргән, күпне кичергән ветеранны. Сызылып таң аткан вакытта, башына әллә нинди уйлар килә. Кеше тормышы бертөрле генә булмый шул. Әнә Мәдинә әби кабат үзе туган Олы Арташ якларына, әти-әнисе нигезенә күңеле белән әйләнә дә кайта, әйләнә дә кайта. Аңлы-фикерле, уңган-булган, укымышлы һәм таза тормышлы Мөхәммәтҗан белән Әминәнең алты малае арасында бер бөртек кыз булып үсә ул. Нәфислеге, сөйкемле булуы, бөтен эшкә кулы ябышып торуы, яхшы укуы белән дә аерылып тора. Ул елларда урта белемлеләр дә бармак белән генә санарлык була бит.

1941 елның 22 июнен — гомер-гомергә каргаласы мәкерле афәт китергән көнне — унсигез яшендә каршылый Мәдинә. Әле ул вакытта бу сугышның 1418 көн дәвам итеп, үзе белән миллионлаган корбаннар алып китәсен, күпләрне мәңгелеккә гарип һәм йөрәк яралы итеп калдырасын да беркем дә чамалый алмый.

Мәдинәнең самими, гүзәл хисләрен, ап-ак хыялларын караңгылык пәрдәсе каплый. Ир туганнары Сәгыйть, Динислам, Мәҗит бер-бер артлы сугышка китә. Мәдинә аларны өйдә генә түгел, төп эшләрендә дә алыштыра. Саба МТСының шул зонадагы учетчысы итеп билгеләнә ул. Атын үзе җигеп, районга ук йөри башлый. Биш көннән биш көнгә отчетларын бик төгәл итеп бирә. Шуңа күрә МТС директоры Нурислам абыйсы Ногманов бик хөрмәт итә, сугышка җибәрмәү чараларын да күреп карый. Әмма яшьлек, комсомол романтикасы һәм дошманны җиңү хисе белән янган кыз чакыруны көтеп ала һәм фронтка әзерләнә дә башлый. 1943 елның көзе була бу. Әтисе почмакларына бәрәңге куеп биштәр ясый, әнисе аның төбенә бербөтен ипи сала. Район хәрби комиссариатына юл алучы яшь-яшь кызны бөтен авыл елап озатып кала. Күңелендәге куркуны «Ни язган — шул булыр» дип баса Мәдинә. Бәрәңге төялгән машина белән Сабадан Шәмәрдән станциясенә алып менәләр сигез кызны. Һәркемнең күңелендә бер генә уй: кире кайтулар булырмы? «Юл буендагы ялгыз наратны соңгы күрүебез түгел микән?» — дип тә куя кайсыдыр...

— Юдино бистәсенә өч йөз утыз кыз җыйналдык, — дип ипләп кенә сүзен дәвам итә Мәдинә әби. — Башта әле алты көн буе бәрәңге чүпләттеләр. Аннары комиссия торгыздылар. Зенитчы-пулеметчы булачагыбызны әйттеләр дә поездга утырттылар. Станцияләрдә туктый-туктый бардык. Мәскәүне дә күрдек. Юлда кичергән михнәтләр сөйләп бетерерлек түгел. Тамак туклыгы да чамалы, өстәвенә бет

басты. Фронт сызыгына барып җиткәнче үк югалтулар булды. Бомба кыйпылчыгына эләгеп үлгән иптәш кызларны юл читенә чокыр казып, күмеп калдыра бардык. Минем исән калачагымны алдан ук әйткәннәр иде. Үзебезнең Төбәк авылыннан Хәдичә исемле кыз карта ачып: «Мәдинә, синең барысы да әйбәт булачак, ә үземә гел начар карталар чыга», — дигән иде. Соңыннан ишетеп белдем: ул Одер елгасы буенда минага эләгеп һәлак булган. Язмыштыр инде, күрәчәгеңне күрмичә, кабергә керү юк, диләр бит.

Мәдинә апа сөйли дә сөйли. Күз тимәсен, хәтере бик әйбәт әле аның. Курск шәһәренең Ленин урамындагы 5 нче номерлы мәктәбендә ай ярым чамасы укыталар кызларны. Хәрби киемнәр бирәләр. Бик яраталар иптәшләре кешелекле, игътибарлы, ярдәмчел татар кызын. Матур итеп, күңел кылларын тибрәндерә-тибрәндерә скрипкада да уйнарга өйрәнә ул.

«Маруся — золото» дип йөртәләр үзен русчалатып.

Кызлар өчен алгы сызык Житомир өлкәсендә башлана. Өстән бомба ява, әле монда, әле тегендә снарядлар ярыла, мина кыйпылчыгы, пуля яңгыры астында калган яшүсмерләр, үз-үзләрен аямыйча, зенитчы-пулеметчы вазифасын үти-үти алга баралар. Әмма кызларның сафлары да күзгә күренеп сирәгәя.

Клинцы шәһәре өчен барган сугыш Мәдинә өчен соңгысы була. Күкрәгенә снаряд ярчыгы тигән кызны госпитальгә озаталар. Бераз рәтләнгәч, кайтырга рөхсәт итәләр.

Исәнлегенә күңеле ышанмый аның. Шул ук вакытта яшь килеш гарип булып калам дип борчылган чаклары да күп була.

— Шәмәрдән станциясенә кайтып төштем, — дип искә ала Мәдинә апа. — И ява яңгыр! Үзебезнең авылдан ике хатын очрады. «Мәдинә, син түгелме бу?» — диләр болар миңа. Сабага машина булды. Авылга Мәртен аша җәяү кайттык. Юлдашларым сөенче алырга йөгерделәр. Әти умарталыкта булган, әни өйдә иде. Мине күргәч, шатлыкларыннан бик елаштылар инде...

Туплар гөрелтесе, бомбалар шартлавы, пулемет тавышы эчендә елдан артык газап чиккән Мәдинәне күрергә авыл халкы агыла башлый. «Туып үскән җирендә үләргә кайткан икән бу бала. Булырлык түгелдер...» — диючеләр дә була. Әмма туган якның һавасы, әти-әнинең бисмиллалы дәвасы савыктыра кызны. Бераз сихәтләнгәч, колхоз идарәсенә хисапчы булып урнаша ул. Менә шунда хуҗалык рәисе Мәүлет Гәрәев — булачак ире белән очраштыра аны язмыш. Уртак фикерләре, серләре тора-бара никахка әйләнә. Озакламыйча кызлары Люция дөньяга килә. Педагог Мәүлет үзе дә бик зыялы җитәкче була. Ул инде моңарчы «Беренче Май» колхозы (Югары Шытсу авылы) рәисе булып эшләп кайткан икән. Кыскасы, Мәүлет абый хуҗалык җитәкчесе белән укытучылык эшен гел чиратлаштырып алып бара. Олы Арташтан башта Кече Шыңар авылына килеп нигез коралар, аннары Олы Шыңарга күчәләр. Кайда буш өй бар, шунда яшиләр алар. Икенче кызлары Ләлә Кече Шыңарда туса, Флера, Наил, Наилә, Камил, Марат, Раилә Олы Шыңарда дөньяга киләләр. Менә шулай тормыш дәвам итә.

— Мәүлет балаларны бик яратты. Башта рәттән өч кыз алып кайткач, малай көтәдер инде, дип, күңелемнән уйлап йөргән идем. Ник бер төртмәле сүзе булсын. Киресенчә, кызларны ихлас күңелдән ихтирам итте ул. Аннары малайлар да булды бит, Аллага шөкер, — дип, авыз чите белән генә елмаеп куйды Мәдинә апа. — Әтиләре бик дөрес тәрбия бирде аларга. Берәр сорау килеп чыкса: «Әниең нәрсә диде?» — дияр иде. Мин дә: «Әтиегездән сорадыгызмы?» — дип куя идем. Хезмәт сөеп, ныклап эшләп үстеләр алар. Беркайчан да эшне чиратка салмадылар, бер-берсенә салынмадылар. Һәркайсы кулыннан килгәнне үзе белеп башкарды. Миңа почта таратырга да булыштылар, уенга да, спорт белән шөгыльләнергә дә вакыт таптылар.

Оясында ни күрсә, очканда да шул булыр, ди халык. Әти-әниләренә охшап, балалар да сүз тыңлаучан, эш яратучан булалар. Шулай булмыйча мөмкин дә түгел бит. Мәдинә апа алтмыш ике яшенә кадәр төп эшен ташламый. Ул елларда хат ташучыларның нинди авыр сумка күтәреп йөргәнен күпләр хәтерлидер әле. Ә Мәүлет абыйны сөйләп тә торасы юк. Үндүрт яшендә Олы Мәтәскәдә балалар укыта башлый. Шыңар якларында рәис итеп сайлангач та: «Мин сезгә, күкрәгегезгә терәп, ипи кистереп ашатам», — дип вәгъдә бирә. Ачлы-туклы елларда нинди олы сүз була ул, һәм әйткәнендә тора. Шуңа күрә тирән хөрмәт белән искә ала аны бу як халкы. Ятимлектә үскән, фин сугышыннан ук гарипләнеп кайткан Мәүлет ага, сәламәтлеге буенча рәислектән киткәч тә, балаларга белем бирүен дәвам итә. Гадел, тыйнак, чама белә торган кеше була. Дүртпочмаклы үз йортын да балалары кул арасына керә башлагач, ссуда алып сала... Шуңадыр бакыйлыкка тыныч күңел белән күчә. Соңгы юлга балалары, җәмәгате, туганнары гына түгел, бу төбәкнең олысы-кечесе бик олылап озата.

Ә бүген авылның уртасында Мәүлет мәчете тирә-якка иман нуры чәчеп, балкып утыра. Анда олылар гыйбадәт кылса, балалар дин сабаклары укый. Мәчетне ачу тантанасы бүгенгедәй күз алдында тора әле. Кунаклар бик күп иде. Казаннан гына түгел, Мәскәүдән дә, Уфадан да (Камил шунда эшли) килделәр Гәрәевләрне, аларның изге гамәлләрен ихтирам итүчеләр. Алар арасында челтәрле шәльяулыгын бөркәнеп тыйнак кына итеп басып торучы Ак әбигә — мәчет салдыручы улларының әниләре Мәдинә апага сокланып караучылар да аз булмагандыр.

Һәрвакыт диярлек ак шәлдән Мәдинә әби. Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев мәркәзебезнең Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында «Минем гаиләм — минем дөньям» номинациясен-

дә җиңүе белән тәбрикләгәндә дә шул ак шәлен матур итеп япкан иде ул. «Бөек Ватан сугышында зенитчы-пулеметчы булып катнашкан, фронттан кайтканнан соң сигез бала табып үстергән, уллары бөтен авылга, районга, гомумән, милләткә хезмәт итә. Менә шундый игелекле ана ул Мәдинә апа Гәрәева», — дигән иде Минтимер Шәрипович башына калфак кидергәндә. Бу хөрмәткә Ак әби үзе дә җавапсыз калмады, әлбәттә, олы рәхмәтен әйтеп, кайчандыр пулемет тоткан куллары белән бәйләгән җылы оегын тапшырды Илбашына.

...Менә әлеге вакыйгаларны яңадан бер тапкыр күз уңыннан үткәрергә мәҗбүр итте тыныч йокысыннан бүлдергән самолет тавышы. Мәдинә апаның сугышта хәбәрсез югалган, әсирлек газапларын кичергән, күзсез калып кайткан ир туганнарының һәркайсы турында аерым повесть язарлык...

Хәзер тормышлары мул, йортлары иркен булса да, байтак авырлыкларны кичерә шул ана йөрәге. Иң олы хәсрәте төпчек кызы Раиләне югалту булгандыр. Ике баласы өстенә өч көнлек сабыен калдырып, япь-яшь килеш кара гүргә керә ул. Бу коточкыч вакыйганы җайлап әйтү өчен бик нык әзерләнеп кайталар Мәдинә апаның уллары һәм кызлары. Сиздермәскә тырышалар башта. Хәле бик авыр, диләр. Сизмиме соң ана йөрәге! Сабыр итеп тыңлап утыра да:

— Дөнья хәлен белеп булмый, балалар, алай-болай булса, Казанда калдырмассыз, авылга алып кайтып җирләрбез, — дип куя Мәдинә апа, әниләре өчен борчылып кайтучыларның үзләрен тынычландырып...

Наилнең Әфганстан җирендә контузияләнүен, Ләләсенең яраткан иренең гомере фаҗигале төстә, үкенечле булып өзелүен, Маратының умырткасы имгәнеп, озак вакытлар Мәскәү хастаханәсендә ятуын да бик авырдан кичерә әни кеше. Менә шул вакытта инде Мараты: «Исән-сау терелсәм, авылда мәчет салдырыр идек», — дигән ниятен белдерә һәм, белгәнебезчә, сүзләрендә тордылар алар.

Мәчет тә салынды, авылларына асфальт юл, газ керткәндә дә башлап йөрделәр, үзләре укыган мәктәпкә, алай гына түгел, районыбызга да гел ярдәм итеп торалар.

— Планлаштырган эшләр бар әле. Булышасы да булышасы иде. Районыбызның заманча җитәкчесе Рәис Нургалиевич белән тыгыз элемтәдә без, — ди Наил Мәүлет улы, гади генә итеп.

Һавалылык дигән нәрсә бөтенләй юк Гәрәевләрдә. Үтә тыйнак алар. Шушы яшенә җитеп, әниләре турында район газетасында кыләмлерәк язма бирелмәве дә әлеге сыйфатларының бер мисалыдыр... Бик миһербанлы да алар. Наил һәр язны диярлек, колхоздан берәр тонна ашлык сатып алып, урмандагы ашарларына беткән пошиларга һәм кабан дуңгызларына куеп чыга шуны. Бу гамәлне ничек инде мәрхәмәтлелек димисең!

Әйе, ана кадерен, «җәннәт ишекләре әниләр аяк астында» дигән гыйбарәнең мәгънәсен белеп яшиләр Мәүлет ага белән Мәдинә апаның балалары. Узган җәйдә Мәскәүдә Наиле яшәгән нигезенә алып барды үзен, даны дөньяга таралган санаторийда да ял иттерделәр, кыскасы, аны сакларга, борчымаска тырышалар. Әмма еллар үтә шул. Олы җанлы ана 23 февральдә 80 яшькә җитте. Ватанны саклаучылар, элеккечә әйтсәк, Совет Армиясе һәм Хәрби Диңгез Флоты көненә туры килүе дә символик мәгънәгә ия бит. Нәкъ шул көнне энесе Тәлгатьнең дә юбилее булды: аңа да 70 яшь тулды. Мәдинә апа Казанга барып, матур итеп котлаган үзен.

Дөрестән дә, җыр-моң яраталар алар: «Соңгы елларда үтә торган «Татар җыры» фестивален оештыручыларның берсе — генераль директоры Марат Гәрәев булган «Барс-Медиа» ябык акционерлык җәмгыяте бит.

Шулай итеп, җыр турында да сүз чыккач, сугыш һәм хезмәт ветераны Мәдинә Мөхәммәтҗан кызын олы юбилее һәм Совет Армиясе көне белән чын күңелдән котлыйбыз һәм аңа иман байлыгы, тән сихәтлеге, бәрәкәтле гомер теләп, язмабызны уллары-кызлары, кияүләре, киленнәре, егерме алты оныгы һәм сигез оныкчыгы күңелендә йөри торган таныш җыр юллары белән төгәллик.

Нигә, әни, нигә картаясың, —
Уйлыйсыңмы сугыш афәтен?
Керсен әйдә безнең күңелләргә
Бар уйларың, бөтен хәсрәтең.

Нигә, әни, нигә картаясың,
Дөнья шундый матур чагында?
Бу дөньяның барлык сагышлары
Күзләреңдә нигә чагыла?

Нигә, әни, нигә картаясың,
Моңланасың һаман, әй, нигә?
Әй син, картлык, кермә безнең өйгә,
Әй син, картлык, тимә әнигә!

*2003*

# Җитмеш биш яшьлек «егет»

*Саба районының Шыңар яклары — данлы-шөһрәтле төбәк. Бередә элек тә, хәзер дә эшчән, үз-үзен хөрмәт итә торган кешеләр яши. Мәсәлән, зыялы шәхес Габделмәннан Рахманколый (җырчы Мәрьям Рахманколованың әтисе) Арча районында туса да, бик яшьтән асрамага алынып, Олы Шыңарда үсә. Укып кайткач, озак еллар мөгаллим була, шигырьләр иҗат итә. Аның Олы Шыңарда туган улы Солтан Рахманколый егерме сигез ел гына яши, үзе вафатыннан соң «Хикәяләр җыентыгы» нәшер ителә.*

*СССРның һәм РСФСРның халык артисты, Г.Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты, танылган композитор, Татарстан Дәүләт гимны авторы Рөстәм Мөхәмммәтхаҗи улы Яхин да төп чыгышы белән шушы төбәктән. 1997 елның июнендә, вафатыннан соң, шыңарлылар Рөстәм Яхинны искә алу кичәсен авылларында республиканың бик күп сәнгать әһелләре, шул исәптән Р.Үтәй җитәкчелегендәге оркестр, гомумән, барлык туганнары, дуслары катнашында билгеләп үттеләр.*

*Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган табибы, Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты (1997), Россия медицина-техник фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, Казан дәүләт медицина университеты профессоры Алмаз Әсгать улы Ахунҗанов белән дә бу төбәк кешеләре хаклы рәвештә горурлана. Чөнки аларның күбесенә Алмаз аганың әтисе — Ленин орденлы укытучы Әсгать ага белем биргән.*

*Бу исемлекне журналист һәм мөхәррир Фәрит Шәрифуллин («Мәгариф» журналы), Татарстанның атказанган артисты Илһам Мөхәммәтов (Әлмәт театры), атаклы көрәшче, милли көрәш буенча Россия һәм Татарстан чемпионы Сабирҗан Шакиров, авылларына затлы мәчет салдырган бертуган Наил, Камил, Марат Гәрәевләр һәм башка бик күп ихтирамга лаек кешеләрнең исем-фамилияләре белән дәвам итеп булыр иде.*

*Өлкәннәр арасында да танылган шәхесләр байтак. Мәсәлән, хәзер бу җирле үзидарә Советы биләмәсендә 212 хезмәт, 19 сугыш ветераны яши. Аларның сафлары ел саен кимесә дә, үзләренә хөрмәт районда гына түгел, республика күләмендә дә арта бара.*

*2004 елда Олы Шыңар авылыннан «Ел ир-егете хатын-кыз күзеннән» бәйгесендә имтихан тоткан җитмеш биш яшьлек тракторчы Зариф ага Шәрипов «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә Минтимер Шәрипович кулыннан истәлекле бүләк, бер кочак чәчәк кабул итеп алды.*

— И-и, гомер буе онытылмаслык вакыйга булды ул, — дип сөйләп китте Зариф абый, шуннан кайткач. — Башта теге «Пирамида» дигәннәрен күреп шаккаттым. Ничәмә йөз хатын-кыз арасында берүзем диярлек идем мин анда. Яныма киләләр дә: «Бабай, син нишләп йөрисең монда? Кайда эшлисең?» — дип сорыйлар. Җылы җирдә генә утырам. Кабинетым да әйләнә торган. Ялт итеп кызылга буялган үзе. Шуңа күрә җитмеш биш яшьтә эшләп йөрим инде мин, дигән булам. «Нинди кабинет ул?» — дип әсәрләнәләр ханымнар. Аптырагач, «трактор кабинасы ул» дип, дөресен әйттем. Менә тантана башланды. Башта хатын-кызлар хөрмәтләнде. Алар бәйрәме бит. Аннары сәхнә түренә — Минтимер Шәрипович белән Зилә Рәхимҗановна янына мине, алтын куллы хирург Леонид Миролюбовны һәм «КамАЗ — мастер» командасының автоузышчыларын чакырдылар. Дулкынлана-дулкынлана менеп киттем баскычлардан. Мин үз гомеремдә хөрмәтне күп күрдем. Әмма бу кадәр зурлаганнары юк иде. Чәчәк, диплом, бүләкләр тапшырдылар. Президентыбыз кочаклап та алды. Җир кешесен шундый олылаганнары өчен рәхмәт аларга! Гомерләре рәхәттә үтсен!

Әйе, җир йөзендәге иң хәләл ризык — Галиҗәнап ипи өчен көрәш җиңел түгел, ул зур тырышлык, түземлелек, гомумән, физик һәм рухи көчләр киеренкелеге таләп итә. Шуңа күрә игенчеләр турында җырлар җырлана, шигырьләр, хикәяләр, романнар языла. Алай гына да түгел, икмәк — сәясәт ул, безнең яшәү чыганагыбыз. Шулай булгач, гомеренең илле елдан артыгын чылбырлы тракторда буразналар сызып, гәрәбәдәй алтын бөртекләрне җир куенына тапшыручы Зариф абзый кебек шәхесләрне ничек ихтирам итмисең! «Алтын ай булып ялтыраса, икмәк кояш булыр» диелә бит халык мәкалендә дә.

...2 май көнне — язгы чәчү гөрләп барган сәгатьләрдә барып чыктык без «Шыңар» крестьян (фермер) хуҗалыгына. Иртән салкынча иде. Көннең икенче яртысында кояш елмайды. Дистәдән артык агрегат иңли иген кырларын.

— Зариф абый Кишәр тау башы басуында инде ул, — диделәр хуҗалык җитәкчесе Илшат Равилев белән бригадир Рафис Хаҗиев.

— Әйдәгез, янына барабыз. Беренче чәчкән участоклары тишелеп чыкты аның. Бүген-иртәгә сабан бодае чәчүгә керешә. Аксакалның аяк-кулы һәр елны җиңел була...

Ашлама чыгаручылар да, чәчкечтә йөрүчеләр дә бер урынга җыелган иде. Машина белән кичке аш китергәннәр икән. Язмабыз героен әллә кайдан күреп алып, яннарына килдек. Ветеранызның кулында тәмле булып кабарып пешкән ипи телеме. Аның хуш исе әллә кайдан аңкып тора. Без сөйләшә торган арада, ашы белән ите дә ашалып беткән аның. Машина әрҗәсеннән җәһәт кенә сикереп төште дә яныбызга ашыкты Зариф абый.

— Менә иртән — кыш көне килгән идек. Хәзер җәен кайтасы була инде, — диде ул, бүреген селкиселки. — Мин беренче тапкыр — 1943 елда, җиденче класста укыганда тырмага чыккан язны да шулай

салкынча булды. Бригадир кушуы буенча Гөлҗи һәм Закирҗан кушаматлы пар ат белән эшкә керештек. Шулай итеп, мин нәкъ алтмышынчы язымны басуда каршылыйм икән быел, — дип, шул елларны күз алдыннан үткәргәндәй булды да фикерен дәвам итте ветеран. — Атлар ач, бер-ике әйләнәләр дә яталар. Өлкән конюх Усман абый Кәримов безнең туган тиешле кеше иде. Фураж саклана торган складның үзем сыярлык кына тишегеннән керәм дә бер чиләк солыны эләктереп чыгам. Менә шулай итә торгач, атларым рәтләнеп китте. Усман бабай да күрмәмешкә-белмәмешкә салынды, ахры. Ярар, егетләр, минем сүз бетмәс, әнә чәчүчеләрем көтеп тора. Язның бер көне ел туйдыра. Эш беткәч килегез, иркенләп сөйләшеп утырырбыз. Карале, иптәш Нәҗмиев, управление нәчәлниге Гафур Шәйхулловичка миңа атап яңа кайтарткан чәчкечләре өчен рәхмәт әйт әле. Тегеләре — моннан чирек гасыр элек кайтканнары — нык искергән иде, — дия-дия район слетында хакимият башлыгы Рәис Миңнеханов рәсми төстә исемләп тапшырган кызыл тракторы «кабинет»ына кереп утырды да кара төтеннәр чыгарттырып кузгалып та китте.

Бирәсе килгән сораулар шул килеш күңелдә калды. Ничек инде уттай чәчү вакытында җәелеп әңгәмә корып утырасың...

Бер ай вакыт узгач, Шыңар якларына коеп яңгыр яуганда чыгып киттек.

— Ай-һай, алар урамына болай гына керә алырсыз микән? Әнә теге койма арасыннан сыйсагыз, Зариф абыйның чирәмле сукмагы бар. Үзе шуннан йөри ул, — дип, юл күрсәтте бер ханым.

Шул сукмактан абзар-кура аша, билгеле, ишегалдына үтәм. Зариф абыйның тәрәзәдән башта гәүдәсе күренеп китте, аннары үзе йөгереп чыкты.

— У-у, Нәҗмиев, каян һәм ничек килеп чыктың әле? — дип шатланып каршы алды ул.

Ә мин баскан җиремдә катып калдым. Нәкъ утыз биш ел элек шушы йортта фатирга кереп, әлеге верандада тезелешеп йоклаган идек район агитбригадасы составында концерт куеп йөри торган егетләр белән. Кызларны өйгә алып кереп киткән иде хуҗабикә Зөлхәбирә апа. Бик җитез, телгә беткән, киң күңелле апа иде, мәрхүмәкәй. Без әйтмичә торып, ягъни үзе белеп, иртән торуыбызга мунчасын өлгерткән булып чыкты. Авылдан авылга куна-куна йөреп, каралып-тузанланып беткәннәрдер, дип уйлагандыр инде, рәхмәт яугыры. Өстәле дә сыйдан сыгылып тора.

Агитбригада җитәкчебез, ВЛКСМ райкомының икенче секретаре Мөдәррис Хисмәтов:

— Апа, ирегез күренми, кайда эшли соң? — дип сорап куйды кичкә таба.

Җавап бик төгәл булды:

— Тракторда. Көндез сукалый, төнлә тырмалый, — дип, сүзне кыска тотты җор күңелле, җырга-биюгә оста хуҗабикә.

Мин шуларны искә төшереп торганда, әңгәмә корырга махир тракторчы бабай сүзгә кушылды:

— Әйе, ул мәзәгеңне беренче китабыңнан укыдык. Искә алганың өчен рәхмәт. Менә өченче китабыңны язасың икән. Хәзер сөйләгәнен шунысына кертерсең.

...Бервакыт төнлә авыртып китте бит Зөлхәбирәм. Урысча әйтсәк, приступ булды. Фатирда уракка Белоруссиядән килгән шоферлар тора иде. Иван дигәнен уяттым да, Сабага алып киттек. Өстен алыштырырга да вакыт булмады. «Апа, эчке киемнәрең керләнгән бит», — диләр икән моңа кабул итүчеләр. Зөлхәбирәм бер дә аптырап тормаган: «Каралмыйча, гомер буе тракторист белән йоклыйм бит мин», — дигән... Ә инде фатирга кемнәр генә кермәде безгә. Элек кунакханә, ашханә кебек нәрсәләр юк иде бит. Барысын безгә җибәрделәр. Илһам Шакировка кадәр кунды инде. Берсендә, әле эти исән чакта, Сабаның милиция начальнигын бер кичкә керттеләр. Ул йоклаган карават астында куган нәрсә булган икән. «Исхаков әйбәт саклаган, самогонның бер шешәсе дә югалмаган», — дип шаярткан булды иртәгесен эти...

Зариф абый сөйли дә сөйли. Искиткеч яхшы хәтер, аек акыл аңарда. Кешеләрнең, үзе эшләгән чордагы колхозның унбиш рәисенең исем-фамилияләрен, төрле техниканың маркаларын, хайваннарның кушаматларын, һәр вакыйганың вакытын хәтерли.

Әңгәмә дәвам итә.

— Зариф абый, Совет Армиясендә кайда хезмәт иттең соң? — дип сорыйм.

— Саратов өлкәсендәге Вольск шәһәрендә — авиачастьта механик булдым, — диде ул. — Вольскины нечкәлек билгесе белән яз, яме, — дип өстәп тә куйды әле бераздан.

Менә шулай әкрен генә сөйләшеп утырабыз ветеран белән. Ул төрле вакыйгаларны образлы итеп сурәтләп, сүзләрне нинди хәрефләр белән язасын өйрәтеп тора, мин аның сөйләгәннәрен кәгазь битенә төшерә барам.

Шул арада кесәсеннән портмоне тартып чыгарып, эченнән биш йөзлекне суырып алды да Зәкигә сузды. «Улым, бар, берне алып кайт, иптәш Нәҗмиев үзе килгән бит! Утыз биш елдан соң...»

Армия хезмәтен Байконурда үтәп, байтак космонавтларны күреп белгән, яшьтән үк рәсем ясарга һәвәс булган Зәки, кош токандай, кибеткә чыгып йөгерде. «Кирәк түгел, мин тотмыйм бит», — дип, Зәкинең күңелен төшерәсе килмәде.

Ә Зариф абый сөйли дә сөйли:

— Армиядән зәңгәр погоннар тагып, шундый ук төстәге фуражка киеп, почти летчик булып кайтып

төштем, — дип, яшьлеген сагына-сагына тезеп китте бабай. — Элек егетләр һәм кызлар очраша торган аулак өйләр була иде бит. Менә шунда күрше Сабай авылыннан килгән Зөлхәбирә исемле кыз күземә ташланды бит. Кыскасы, бер күрүдә гашыйк булдым.

Шуннан соң нәсел-нәсәбен белешә Зариф күрше авыл гүзәленең. Ятимә кыз икән ул. Башта әтисе үлгән. Аннан утыз сигез яшендә әнисе сигез нарасыен калдырып Раббыбыз хозурына күчкән. Зөлхәбирә гаиләдә икенче бала була. Фәйрүзә апасы читтә — Кемерово өлкәсендә яшәгәнлектән, берсеннән-берсе кечкенә алты ятим Зөлхәбирә апалары күзенә карап торалар. Шуңа күрә кияүгә чыгарга бик ашыкмый ул. Өч ел йөртә Зарифын.

Булачак җәмәгате артыннан гына йөреп үткәрми егет кадерле вакытын. Башта туган як табигате белән хозурлана. Өч ел буе сагынып, түземсезлек белән «дембель»не күтәп кайткан Зариф башта авылының һавасын сулап туя алмый. Таллы-болынлы, хуш исле чәчәкле һәм үләнле Мишә буенда гомер итәрлек һөнәрле булырга ниятли. Ул вакытта колхозлары «Байкал» исемен йөртә (Чулпыч — «Авангард», Түлешкә — «Салкын Чишмә», Кече Шыңар Карл Маркс исемендә була). Хуҗалык рәисе Мәүлет абыйсы Гәрәев аңа, Азин МТСына барып, тракторчылыкка укырга тәкъдим итә. Биредә аларны Сталинград шәһәрендә чыккан тәгәрмәчле «СТЗ» серләренә өйрәтәләр. Зариф Шәрипов бу техниканы ярты ел урынына өч айда үзләштерә. «Эш сөйгәнне ил сөя» ди халык. Шуннан соң МТС директоры Халит ага Сабитов Арча районындагы «Үрнәк» һөнәр училищесына чылбырлы тракторга укырга юллама бирә. Аннан кайткач, «ДТ-54»не ышанып тапшыралар үзенә. Бик бәхетле итеп сизә үзен башлы-күзле булырга йөргән егет.

— Зөлхәбирә ялындырып та күрсәтте инде, малай, — дип сүзен дәвам итә язмабыз герое. — Шул сабыйлар хакына булгандыр инде дип уйлап ятам хәзер. Менә сиңа — ялган, миңа — чын, Нәҗмиев. Риза гына булмый бит. Сабай сабан туе көнне шундый матур чүәк кигән иде бу. Ризалыгын сорадым-сорадым да, һаман каршы килеп маташкач, шул чүәкнең чиккән бизәген үбеп алдым, яратуымны раслау һәм үзен ычкындырмас өчен. Шуннан соң тәкате бетте, ахры. Никах көнен билгеләдек. Рәсми төстә өйләнешкәч тә, әле бер елга якын — «юанайганчы» — авылында — энеләре-сеңелләре янында торды. Әти-әнием исән булгач, алар да каршы килмәде. Мин, яшьлек дәртем, яратуым көчле булгачтыр инде, кичен басуда эшне бетереп кайткач, эңгер-меңгердә киемнәремне башыма бәйлим дә, Мишә елгасы аша йөзеп чыгам болар авылына. Турыга ике генә чакрым безгә Сабай. Иртән тагын кире үзебезнең якка таба йөзәм. Осталык бар анысына. Армиядә йөзү буенча полкта икенче урын алган идем. Су чиратканчы шулай йөрдем газиз хәләл җефетем янына. Габдулла тугач, үзебезнең өйдә яши башладык. Дүрт малай бүләк итте миңа Зөлхәбирә. Икесе вафат инде. Закирым башка чыгып яши. Ундүрт ел үзем белән алмашка тракторда эшләде. Хатыны Алмазия фермада сыерлар сава. Тик менә әниләре генә юк. Өйнең яме, яшәүнең тәме калмады. Авыр туфрак астында ниләр уйлап ятадыр, риза-бәхил булып китте микән? Гәүдәсе җир куенында булса да, кешенең җаны үлемсез, диләр бит...

Бер-берсен керфек кагышларыннан аңлап, матур итеп яшәгәндә була шул фаҗига. Шат күңелле, тормыш яратучан, гомер иткән ире, уллары өчен генә яши торган Зөлхәбирә апа иртән сыер саварга чыгып китә, бераз вакыт үткәч, Зариф ага җәмәгате кайнарлаган суны трактор радиаторына салырга кузгала. Абзардан ачынып ыңгырашкан хатынының авазын соңгы тапкыр ишетә ул шул минутларда. Башына кан сава җәмәгатенең, сигез сәгатьтән фани дөнья белән мәңгелеккә саубуллашып та куя. Менә шуннан соң инде гомернең чоңгыллы көннәре башланып, киртәләр очраган саен, күзләре яшьләнә, җаны яралана, күңелендәге бер җыр бик еш яңара ветеранның:

Чәчәкләрнең нигә кирәге бар,
Өзеп бирер кешең булмаса.
Нәрсә соң ул күктә янган кояш,
Үз кояшың янып тормаса...

Ә бит нинди шатлыклы мизгелләр белән яшәде ул көннәрдә Шәриповлар гаиләсе. Беренчедән, алтын куллы механизаторның җитмеш яшьлек юбилее якынлашып килә иде. Икенчедән, шул чорда һич көтмәгәндә тагын бер куанычлы вакыйга булды. Югарыда телгә алынган Вольск шәһәрендәге авиачастьта бергә хезмәт иткән дусты — Әтнә егете Шәйхулла Рәхмәтуллин кайтып төшә Шәриповларга. Кырык ике ел күрешмәгән полкташларның өч көн буе сөйләшеп сүзләре бетми.

Әйе, кемнәр белән генә аралашмый Зариф ага. Академик якташыбыз Әбрар ага Кәримуллинны еш искә алырга ярата ул. Булачак галим, фронтта каты яраланып, госпитальгә эләгә. Хәле бик авыр була.

Менә бервакыт «Урман кызы» дигән җыр колагына ишетелә аның. «Өнемме-төшемме бу? Терелүемме? Саташаммы әллә?» дип уйлый Әбрар. Аягына баскач, җырчы егетнең кем икәнен эзләп таба.

— Мин — Татарстаннан. Мәгаз Саттаров булам, — ди моң иясе.

— Районың?

— Саба...

— Кайсы авылдан?

— Олы Шыңардан...

— Ә мин бит Чәбия-Чүрчидән...

Кочаклашалар, елашалар, җырлашалар татарның ике офицеры чит җирдә. Исән-сау кайткач, очрашырга вәгъдәләр бирешәләр. Әмма Зариф аганың туганнан туган Мәгаз абыйсына гына Саба ягын күрергә насыйп булмый (язмабыз героеның бертуганы Зәкәрия Шәрипов та, сугышта өлкән лейтенант дәрәҗәсенә күтәрелеп, Псков шәһәре янында мәңгелеккә ятып кала).

Утыз биш елдан соң Мәгазнең туганын — Зарифны — радио аша эзләп таба Әбрар Гыйбадулла улы һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр элемтәсен өзми: бәйрәм саен открытка җибәрә, чыккан бер китабын култамга белән бандероль итеп сала. «Китаплар дөньясына сәяхәт» дигәнен алып та күрсәтте әле Зариф ага.

Дөрестән дә, З.Шәрипов беркайчан да «мин» дип күкрәк какмас, алга чәчрәп чыкмас, эшләгәне белән масаймас. Тыныч кына тракторында буразналар сыза булыр, сүзендә торыр. Шуңа күрә аны авылдашлары да, җитәкчеләр дә гомер буе хөрмәт итә. Шулай булмаса, озак еллар КПСС райкомы әгъзасы яки кандидат булып сайланган механизаторны район партия комитетының элеккеге беренче секретаре Әләметдин Җамалетдин улы Камалов, киткәненә егерме ел үткәннән соң, ветеранны җитмеш биш яше белән тәбрикләр идеме?!

Тырыш хезмәте эзсез калмады гади тракторчының. 1986 елда «Татарстан Республикасының атказанган механизаторы» дигән мактаулы исем бирелде, Хезмәт Кызыл Байрагы орденына, бик күп медальләргә лаек булды. Аңа бирелгән мактау грамоталарының, дипломнарының, бүләкләренең исәбен дә хәтерләми. Район слетларында ел саен диярлек хөрмәтләнде ул. Милли бәйрәмебез сабан туе, сукачылар ярышы флагларын күтәрү хокукы бирелде остазга. Берәү булса, моңа кадәр эшләгәненә канәгать булып, абзарындагы сыерын, үгезен, унике баш сарык-бәрәннәрен карап, тынычланып ятар иде. Кая ул!.. 2003 елда алты йөз гектарда чәчү үткәреп, яңадан шуның кадәр мәйданда уҗым тукландырган булган. 2004 елда да сынатмады. Ул чәчкән һәм «сыйлаган» җирнең мул уңышын җыйнап та алдылар инде. Тагын өч йөз илле гектар көзге чәчү үткәреп, 2004 ел уңышына да ышанычлы нигез салды җитмеш алтынчы яше белән баручы аксакал.

Соңгы соравымны ишегалдына чыккач бирдем әңгәмәдәшемә:

— Зариф абый, җайсыз бер соравым бар сезгә: вафатыгыздан соң, тракторым каберем янында ягулыгы беткәнче эшләп торсын, дип әйткәнсез бугай. Дөресме бу?

— Әйе, шундыйрак сүз булган иде. Хәзерге тракторларга ике йөз кырык литр ягулык салына. Бик озак эшләр ул. Шуңа күрә горючийны күп салмаслар инде, бераз зират кырыенда хушлашу-аерылышу тавышы биреп торса, әйбәт булыр иде... билгеле...

Трактор дигәннән, пенсиягә чыккач та унбиш ел хезмәтен дәвам итүче ветеранга ялга туктаганда бүләк итү өчен хуҗалык җитәкчесе Илшат Равилевның атап куйганы барлыгын да белдек бу баруыбызда.

— Нинди теләгең бар? — дип тә сорадым Зариф Шәриф улыннан.

— Шагыйрь Сибгат Хәким әйткәнчә инде, — диде ул, матур итеп елмаеп. — Аерма мине туган җиремнән, кара икмәгем, сөтле чәемнән, — дип өстәде һәм:

Бу җирләрдән, сука башы тотып,
Туры килде күпме узарга!
Бәхет булып өелеп калсын иде
Мин күтәргән һәрбер буразна, —

дип фикерен йомгаклап куйды.

*2004*

# Гармун иясенә иреште

Бөек Җиңүнең 51 еллыгына багышланган бәйрәм вакытында Сатыш авылында яшәүче I группа сугыш инвалиды Зөфәр ага Искәндәровка район хакимият башлыгы Фәрит Гыйльмиев тальян гармун тапшырды. Күңелләргә тия торган бу мизгелләрне тантанада катнашучылар үзләре күрделәр. Зөфәр аганың күңеле тулды, дулкынлануыннан рәхмәттән башка сүз әйтә алмады ул. Соңыннан бүләк тальянын сузып-сузып уйнап та җибәрде. Мәйданга моң таралды, күпләрнең, бигрәк тә ветераннарның күзләре яшьләнде.

...Бәйрәм тантаналары үтүгә, Зөфәр ага редакциягә килеп керде. Дулкынлануы йөзенә чыккан:

— Бик зур рәхмәт барыгызга да, — диде. — Хакимият башлыгы Фәрит Гыйльмиевичка, журналист Хәмзә Зариповка, район газетасы редакциясенә, мәдәният бүлегенә. Илле ике елдан соң мин мондый хөрмәтләүне күрермен дип көтмәгән идем...

Дөрестән дә, ярты гасырдан соң тальян гармун ничек Зөфәр агага барып иреште соң әле?

Зөфәр Искәндәр улы Искәндәров, 1939 елда Сатыш җидееллык мәктәбен тәмамлагач, ат җигә. Сугыш башлангач, Апас районына окоп казырга җибәрәләр. Яше җиткәч, ягъни 1942 ел башында сугышка алына. Хезмәт юлын Вязьма станциясендә башлый. Бигрәк тә Ленинград камалышында күпне күрергә туры килә аңа. Ә менә Волхов юнәлешендә барган сугышларда япь-яшь килеш I группа инвалидка әйләнә. Бу 1944 елның 1 марты була. Ленинград, Мәскәү госпитальләрендә газап чиккәннән соң, бер аягы киселгән, икенчесе яраксыз хәлдә Казандагы 4642 нче номерлы госпитальгә кайтаралар. Менә шунда ятканда, егерме яше дә тулмаган егет ул вакыттагы Татарстан АССР Президиумы Председателе иптәш Динмөхәммәтовка үтенеч хаты яза һәм, үзенең яшь күңелен юатыр өчен, бер гармун белән ярдәм итүләрен сорый. Әмма аңа җавап бирүче булмый. Бу хат шуның белән онытыла.

Зөфәр кебек инвалид егетләрне, госпитальгә килеп, хисапчы һөнәренә өйрәтәләр. Ниһаять, ул, туган авылына кайтып, 1945 елдан колхозда хисапчы булып эшли. Оркыя исемле кыз белән тормыш корып җибәрә. Ике ул — Хәйдәр белән Илдарны тәрбияләп үстерәләр. Хәзер алар да инде гаиләле булып, балалары үсеп килә. Шунысы гына кызганыч, иң авыр елларда колхозда һәм МТСта унҗиде ел тракторчы булып эшләгән Оркыя апа гына дөньядан иртәрәк китеп бара. Зөфәр ага илле елга якын хезмәт стажы белән пенсиягә чыга. Шуннан соң да мәчет салдыру, зират коймасын тоттыру кебек изге эшләр артыннан йөри.

Гармунга кабат әйләнеп кайтыйк. Дөрестән дә, япь-яшь инвалидның хаты барып җитә Верховный Советка. Ул еллардагы Эчке эшләр идарәсе башлыгы Х.Шаһиморатов Верховный Совет Председателе Г.Динмөхәммәтовка 1944 елның 19 декабрендәге доклад язмасында бер аягы бөтенләй булмаган, икенчесе тез капкачыннан бөгелми торган булып имгәнгән Зөфәр Искәндәровка гармунны Кызыл Армиягә бүләкләр җыю буенча комиссия керемнәре исәбенә сатып алырга мөмкин булуын белдерә. Әмма ул шуның белән бетә, кон-трольгә алынмый. Зөфәр Искәндәров та өметен өзә...

Җиңүнең 50 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә район газетасында «Халык хаты» дигән рубрика белән материаллар бирелде. Шуның берсенә Татарстан Министрлар Кабинеты каршындагы архив идарәсендә бүлек мөдире булып эшләүче журналист Хәмзә Зарипов кызыклы күчермә җибәрде. Анда Зөфәр аганың гармун сораган хаты һәм Г.Динмөхәммәтовка бирелгән җавап күчермәсе бар иде.

Хәмзә Зарипов, гармун мәсьәләсен уңай хәл итүне сорап, район хакимиятенә мөрәҗәгать итте, һәм бүләк иясенә барып җитте.

...Зөфәр ага белән сөйләшеп утырабыз.

— Тән ярасы да, сүз ярасы да китми икән, — ди ул. — Әле менә текә баскычыгыздан, азапланып булса да, шуны әйтергә кердем: авылда җыйналып утырган җирдә бер мәнсезе, Зөфәр сугышка барып җитмәгән ул, ди икән. Менә шуны ишеткәннән бирле рәнҗим...

Аннары ул каты яралану турындагы таушалып беткән рәсми кәгазьләрен чыгарып салды, бик күп үпкә сүзләрен әйтте.

Әнә шулай итеп, уйланмый әйтелгән бер җөмлә ветеранның гомерлек йөрәк ярасына әйләнгән...

Бу көннәрдә кабат моңлана Зөфәр ага. Үзе белән бергә, шагыйрь әйткәнчә, аның хәлен аңлагандай, бүләккә бирелгән гармуны да сулкылдап куя.

*1996*

# Хатирәләр яши күңелдә

Завод-Нырты авылының читтәге бер урамында 75 яшьлек сугыш һәм хезмәт ветераны Николай Сидорович Егоров яши. Ул гомер буе, чын мәгънәсендә, халык арасында кайнады. Балалар укытты, мәктәпне, «Красный Завод-Нырты» колхозы башлангыч партия оешмасын җитәкләде, дүрт ел район мәгариф бүлегенә мөдирлек итте. Педагог Людмила Абрамовна белән өч бала тәрбияләп үстерделәр. Олы кызлары — табибә, СССР сәламәтлек саклау отличнигы. Любовь — өлкән укытучы, методист. Төпчек уллары үзләре белән яши. Керәшен татарлары әйтмешли, Николай дәдәй бүген йорт тирәсендә кыймылдый. Сугыш турында бик җәелеп сөйләргә яратмый. Фронтташ дусларын искә төшергәндә моңсуланып китә, авыр сулап куя.

— Күпне күрдек. Шулай да бәхетле язмышлы мин. Бөек Җиңүнең илле еллыгын бәйрәм итәргә дә насыйп икән...

...1941 ел. Котлы Бөкәш урта мәктәбен тәмамлаган Мамадыш районының Теплое Болото (Түбән Әрнәш) авылының егерме яшьлек төп кебек егетнең Казан танк училищесында укыган чагы була. Әмма аңа ул вакытта кече офицер погоннары тагарга туры килми. 1942 елның июнендә, кыска сроклы курсларны тәмамлаганнан соң, старшина дәрәҗәсендә фронтка китә. Яз үтеп, җәй башланган чак. Күпергән туфрак, кар сулары исе бөтен җирне тутырган, табигать, тереклек яшәрә, сулавы рәхәт. Әмма күңелдә төшенкелек: язмыш ни күрсәтер? Җайсыз вагоннарда берничә көн селкенеп барганнан соң, аларны Ленинград фронтына җибәрәләр. Николай кабат уйлап куя: нәрсә белән төгәлләнер бу сугыш дигәне? Газиз башлар ни күрер? Дошманны җиңүдә катнашып, исән-имин кайтып булырмы? Ул сугышчан юлын Ленинград фронтында башлый һәм шунда тәмамлый. Тугыз йөзгә якын көнгә сузылган камалыш — блоканың иң авыр көннәре була Николайлар фронтка килеп кергәндә. Старшина Егоров,

гыйлем кеше буларак, биредәге вазгыятьне ишетеп тә, укып та белә. Гитлер Германиясе башкисәрләре Ленинградның Мәскәүгә караганда да алдан алырга планлаштыралар. 1941 елның 4 сентябрендә үк шәһәр урамнарына беренче снаряд төшә. Тиздән көчле һөҗүм һәм бомбага тоту башлана. Шәһәрне алуны билгеләп үтү өчен Ленинградны данлыклы «Астория» кунакханәсе билгеләнә. Әмма... 25 сентябрьдән немец фашистларына оборонага күчәргә һәм башка алга таба бер адым да атламаска туры килә. Шулай да Гитлер Ленин исемен йөрткән каланы җир өстеннән себереп түгәргә әмер бирә.

— Хәзер ул мәхшәр көннәрне искә төшерәм дә тетрәнеп китәм, — ди Николай Сидорович. — Бер якта фин гаскәрләре, төрле юнәлештән немец һөҗүм итә. Көннәр, атналар, айлар, еллар буе фашист батарейлары биш-ун минут саен шәһәргә аталар, өстән бомба яудыралар. Ленинградта үлем белән яшәү өчен көрәш бара. Халыкка бирелә торган икмәк паегы илле граммга кала, анысы да пычкы чүбе белән катнаштырылган. Шәһәрдә мәче-күсе бетә, Ленинград халкына җан саклау өчен продукция һәм башка кирәк-яраклар кертә торган Ладога күле аша салынган атаклы «тормыш юлы»н саклыйбыз. Монда күргәннәрне сөйләп кенә аңлата торган түгел. Менә илле ел инде шулар төшкә кереп йөдәтә... Шуннан соң Николай ага бераз туктап тора. Аннары тагын фикерен дәвам итә: — Күз алдында күпме кешеләр, машиналар, продукцияләр боз астына китте. Соңыннан шоферларга кабина ишеген ачып барырга әмер бирелде. Өлгерә алган кеше сикереп котыла иде. Мөмкин булган кадәр халыкны эвакуацияләдек, шәһәрдә, нигездә, карт-карчык, бала-чага, ягъни ярдәмгә мохтаҗлар калды. Ачтан, салкыннан үлүчеләрнең мәетләрен соңга таба җыя да алмый башладылар. Яз көне, гади итеп әйтсәк, штабельләп күмәләр иде.

Ленинград камалышы 1943 елның 18 гыйнварында өзелә. Халыкның геройлыгы, күпсанлы корбаннар бәрабәренә шәһәр сакланып калына. Аның һәр кешесе сугышчыга әйләнә. Камалыштагы 872 көн эчендә төньяктагы башкаланың һәр квадрат метр җире 16 фугаслы 320 яндыра торган бомба һәм 480 артиллерия снаряды кабул итә. Камалыш чорында 642 меңгә якын кеше үлә. Хәзер мемориалга әйләнгән 26 гектарлы Пискарев зиратында гына да 186 туганнар каберлеге бар.

Бу саннарны күңелдән атый-атый сугыш хатирәләрен исенә төшерә Николай ага. Ленинград шәһәренең (без булганда Санкт-Петербург түгел иде) Пискарев каберлеге, сәнгатьчә эшләнгән мемориаллары минем дә күз алдына килә. Әмма бер музейдагы рәсем (аның янында кыш көне тере чәчәкләр) аеруча күңелгә сеңеп калган.

...Васильевск утравында сигез кешелек Савичевлар гаиләсе яши. Алар камалыш вакытында берәмберәм үлә башлый. Ә кечкенә Таня мондый көндәлек алып бара. Башта апасы Женя үлә. Аннары әбисе, абыйсы, ике туганы, әнисе. Соңыннан мондый язу барлыкка килә: «Савичевы умерли. Умерли все. Осталась одна Таня».

Таняның үзен дә авыр хәлдә Горький өлкәсенә озаталар. Әмма аны коткара алмыйлар. Юлда вафат була.

...Николай Егоров, камалыш өзелгәннән соң, бик күп шәһәрләрне азат итүдә катнаша. Җиңү көнен хәзерге Калининградта каршылый. 1946 елның маенда туган ягына кайтып, Усали урта мәктәбендә тарих укыта башлый. Аннары ике ел педучилищеда укый. Аны тәмамлагач, Пермь якларына җибәрелә. Әмма туган яклар үзенә тарта. 1953 елда үзе Завод-Ныртыга мәктәп директоры, хатыны укытучы итеп билгеләнә, тарих укыта. Сугышчан Дан музее оештыра. Республика балалар экскурсия-туристлык станциясе эшендә актив катнаша. Фидакарь хезмәте өчен мактау грамоталарына лаек була.

Әнә шулай еллар үтә. Сугышта да, тыныч вакытта да файдалы һәм кирәкле хезмәт белән истәлекле бу еллар Николай Сидорович өчен.

*1996*

# Урман юлы — гомер юлы

Урман юлы. Сезнең аңа игътибар иткәнегез бармы? Бормалы-бормалы ул. Урыны белән күлләвекле, чокырлы, сазлы... Кая илтә бу юл? Үткәнгә — яшьлеккәме, хыялга — киләчәккәме, әллә бәхетле картлыккамы?

Урман юлы. Уй һәм күләгә әле артыңнан йөгерә, әле белдекле булып алдыңа чыга, күңелеңне үткәннәргә кайтара, тормыш баскычларыңны яңадан күз алдыннан кичерергә мәҗбүр итә.

Урман юлы. Урман юлы — гомер юлы — Нургали аганы да җитмеш яшьлек юбилеена китереп җиткерде. Элеккеге Тәкәнеш районының Игенче дигән кечкенә генә авылында (хәзер аның урыны гына калган инде) Миңнехан белән Өммеһода гаиләсендә дүртенче бала булып (алар барысы — җидәү) дөньяга килә. Тормышның бик авыр чорына туры килә балачагы. Үзен белә башлауга, энеләре Әхмәт белән Җәүдәтне, сеңлесе Әлфияне тәрбияләргә булыша. Сигез яшьтән көтүгә чыга башлый, аннары тырмага йөри. Мәктәптә белем алу еллары сугышның иң авыр вакытына туры килә. Укуы өзелеп тә тора. 1947 елда гына Әбде җидееллык мәктәбен тәмамлый ала. Шуннан соң Лубян урман техникумында

укый.

Кечкенә генә Игенче авылында туып үскән Миңнехан малае, Тын океан флотында моряк булып хезмәт итеп, дөньяны яшьтән күп гизә. 1954 елның 5 февралендә хәрби хезмәттән кайтып, Кызыл Йолдыз лесхозының Борчаклы Яз авылына урнашкан Теләче урманчылыгына лесник ярдәмчесе итеп билгеләнә. Аннан Яңа Арышка лесник итеп күчерелә, шунда бераз эшләгәч, Теләче урманчылыгына хуҗа булып кайта. Бу урманчылыкларда эшләгән яшьлек елларын бик сагынып искә ала Нургали Миңнеханович.

Гомумән, үзенчәлекле вакыйгаларны хәтерендә еш яңарта. Шуларның берсен тәфсилләбрәк искә төшерүне сорагач, көлә-көлә сөйләп китте: «Мине 1962 елның 26 гыйнварында Саба лесхозына директор итеп күчерделәр. Ул вакытта әле Шәмәрдән леспромхозы үзе аерым иде. Кыш көне юл булмау үзәккә үтте. Шәмәрдәнгә, Иштуганга, Сабага урман эченнән юл ача идек. Безнең «С-80» маркалы бер трактор бар иде. Шул ватылып китте дә, юлны ача алмадык. Мине район авыл хуҗалыгы производство идарәсе начальнигы Хәмзә Хәмидуллович Галимовка чакырттылар. Бик дуамал кеше иде, мәрхүм. Шуннан Шәмәрдән леспромхозы директоры Шәрхи Нәбиулловичка: «Мине Галимов чакыра әле. Шунда барып кайтам», — дим. «Әйдә, мин дә барам», — ди бу. Киттек. Хәмзә Хәмидулловичның исполком председателе урынына (идарә начальнигы беренче урынбасар да бит) калган вакыты булды, ахры. Тиз генә райбашкарма членнары да кереп утырды моның бүлмәсенә. Бу ике кызу кеше — Шәрхи абый белән Галимов — нәрсәгәдер эләгешеп киттеләр бит. Шуннан башланды! Өстәлгә сугыш, кычкырыш, чын мәгънәсендә сүгенеш. Кыскасы, сугышу дәрәҗәсенә килеп җиттеләр болар. Монда минем бар икәнем дә, теге ватык трактор да, юл ачылмаганы да онытылды. Шәрхи абыйга каты шелтә бирделәр дә куып чыгардылар безне.

Ярый, нишлисең бит. Кереп ашадык, бу вакыйганы бераз «отмечать» иттек, келтер-келтер урман юлыннан кайтып барабыз.

— Нургали, — ди Шәрхи Нәбиуллович.

— Әү! — дим.

— Мин чеп-чи дурак бит, әйеме?

— Нишләп алай дисез, Шәрхи абый? — дим.

— Беркем чакырмаганга нәрсәгә дип бардым соң әле мин Сабага — Галимов янына. Шуны уйлап кайтам әле...

Менә шундый хәлләр дә булгалады», — дип фикерен йомгаклап куйды Нургали Миңнеханович.

...Юбилейлар уңаеннан язганда яки тост әйткәндә, гадәттә: «Аны фәлән елдан бирле беләм», — дип башлыйлар сүзне. Нургали Миңнеханович белән минем дә якыннан танышуым әлеге-баягы юл белән бәйле икән бит.

1967 елның кышы. Лесхозда нindiдер зур вакыйга булды. Безне Шәмәрдәннән концерт белән чакырганнар иде. Килеп алдылар. Ул вакытта клуб та, ашханә дә агачтан салынган, йортлар дигәне нигездә бараклар иде. Тантана бетеп чәйләп алгач, юлга чыктык. Күз ачкысыз буран. Ни Сабага, ни Шәмәрдәнгә, ни Иштуганга (аннан поезд белән китеп була) юл юк. Өч көн котырды буран. Ә без... рәхәтләнеп кунак булдык. Шунда Нургали Миңнехановичның искиткеч киң күңелле, гади җитәкче булуын күреп сокландык. Аннары хезмәт юллары гел очраштырып торды безне. Партиянең иң дәрәҗәле вакытында КПСС райкомы бюросы әгъзалары булып сайландык, бюро өстәле кырыендагы урындыклар да янәшәдән иде. Миңа, бу юлларның авторына, Лесхозда төрле елларда бик күп тантаналарның, корылтайларның, семинар-киңәшмәләрнең, слетларның шаһиты булырга туры килде. Коллективка Бөтенсоюз социалистик ярышында җиңеп чыккан өчен КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, КЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының күчмә Кызыл Байрагы тапшырылу турында алты тапкыр репортаж язылды. Нургали Миңнехан улына иң олы бәя 1989 елның 2 августында — лаеклы ялга китәргә бер ел калгач — хуҗалык итүне комплексы алып бару, предприятие һәм урман поселокларын социаль үстерү буенча Саба леспромхозы тәҗрибәсен өйрәнүгә багышланган Бөтенсоюз фәнни-практик конференциясе вакытында бирелгәндер, мөгаен. Хәтта Балтыйк буе, Урта Азия республикаларыннан да килделәр Саба җиренә ул көннәрдә. Производствоны һәм социаль-мәдәни объектларны күреп хәйран калдылар алар. Дөрестән дә, фидакарь хезмәте эзсез калмады аның. Ул — СССР орден-медальләренә лаек булган шәхес, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган урманчысы.

Гомумән, зур булмаган язмада Нургали Миңнехан улы башкарган хезмәтләрне тасвирлап чыгу мөмкин дә түгел. Китап язарлык тормыш юлы үткән кеше ул. Бу турыда сорасаң, үзе, гади генә итеп: «Без югарыдагы җитәкчеләребезнең йөзенә кызыллык китерерлек итеп эшләмәдек», — дип җавап бирә.

Әмма аның сайлап кисү алымы, «Саба методы» яки «Миңнеханов методы» дигән исем белән фәнни һәм икътисади яктан дәлилләнеп, бөтен Россиядә яклау тапты. Нургали Миңнеханович, пенсия яшенә җитүгә, үз урынын төпчек улы Рәискә — ышанычлы кулга калдырып, лаеклы ялга китте. Монда Татарстан урман хуҗалыгы министры Әбүзәр Гаяновның: «Рәис эстафетаны уңышлы дәвам итте. Алай гына түгел, эшне тагын да камилләштерде. Әтисе башлаган сайлап кисү алымының дөрес алып барылуы нәтиҗәсендә бүген барлык мәйданнарның 40 процентын ылыслы агачлар били. Ә менә Кама лесп-

ромхозының элеккеге директоры Иван Захарович пенсиягә киткәч, кадрлар дөрес сайланмау сәбәпле, коллектив элеккеге данын югалтты», — дип, берничә тапкыр кабатлаганы хәтердә калган.

Язмабыз герое лаеклы ялга чыккач кул кушырып утырырга теләмәде. Мишә авыл советын оештыру артыннан йөрде. Югары Совет тиешле карар кабул иткәч, бертавыштан рәис итеп сайланды. Менә ун ел инде халыкның социаль хәлен, торак пунктларның экологиясен яхшырту буенча ныклап эшли ул.

Нургали Миңнехановичның урман һәм тормыш юллары гел шома гына бармаган, билгеле. Сикәлтәле, борчулы чаклары да булган. Хәтта аны моннан алып «Ирек» колхозына рәис итеп куярга да уйлаган шул еллардагы КПСС райкомының беренче секретаре Үзбәк Садыйкович Закиров.

— Бер елны «Октябрь» колхозының отчет-сайлау җыелышына төшәргә кушалар, — дип искә ала аксакал. — Күңел нәрсәгәдер борчыла, сизенә бит. Шоферым Вәгыйзьдән: «Килдебәктә дусларың бармы?» — дип сорыйм. «Бар», — ди бу. Әгәр дә мине председатель итеп сайлыйбыз, дисәләр, әйтеп куй — каршы килсеннәр.

Дөрестән дә, мине президиумга утырталар, инде сайлау өлеше җиткәч, җыелышка килгән КПСС райкомының ул вакыттагы икенче секретаре Хөснулла Гасыймов минем кандидатураны тәкъдим итеп маташа бит. Шуннан калын тавышлы бер ир-ат, күтәрелеп: «Без аны сайламыйбыз. Урман кешесе ул, үз урынында эшләсен. Менә без, Хөснулла Кашапович, сезне — авыл хуҗалыгын һәм районны яхшы белгән кешене сайлыйбыз», — дип ярып сала, аны башкалар хуплап алды...

Соңыннан Хөснулла Кашапович: «Үзең оештыргансыңдыр әле», — дип үпкәләп тә йөрде. Элеккеге председатель үз урынында калды.

...Менә бу көннәрдә аны җәмәгате — үтә дә тыйнак Васига апа, уллары — Рифкате (Татарстан Республикасы юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе начальнигы), Рөстәме (премьер-министрыбыз), Рәисе (хакимият башлыгы), киленнәре Рәйсә, Гөлсинә һәм Гөлсем, оныклары — гел егетләр — Рамил белән Рәсүл, Ирек һәм Азат белән Нияз — чын күңелдән котлап, иң кирәге — тазалык-саулык теләрләр. Котлаулар бик күп булыр әле юбилярга.

*2000*

# Горурлану

Бу сүзләрне татар генералы Дамир Вәкил улы Тимерханов әңгәмә вакытында берничә мәртәбә чын күңеленнән, якын итеп әйтте. Аның балалык, яшүсмер еллары Кукмара белән бәйләнгән. 2 нче номерлы рус мәктәбе коллективы аңа өлгергәнлеккә аттестат биреп, 1957 елда олы тормыш юлына озаткан. Укуга сәләтле Лесхоз егетен әле хәтерләүче ветеран педагоглар да бардыр, мөгаен. Степан Разин урамында фатирда тора Дамир. Ул елларда интернат та булмый...

Елның бик матур фасылына туры килде аның белән икенче очрашуыбыз. Халкыбызның күңеленә якын булып кереп калган милли бәйрәмебез — сабан туйлары үтә торган июнь ае иде ул. Мәскәү шәһәренең Ленин проспектындагы иркен квартирасында күрешү насыйп булды бу юлы Дамир ага белән.

Очрашуның беренчесенә ун елдан артык вакыт узган инде. Монысы районыбызның Лесхоз поселогында булды. Дамир Вәкилевичның яшьлек еллары үткән туган ягына генерал-майор погоннары белән тәүге мәртәбә кайтуы иде. Аннан соң шактый сулар аккан, билгеле. Шулай булса да, бүгенгедәй хәтердә: гади генә алты почмаклы авыл өендә иркенләп сөйләшеп утырдык. Ул вакытта әтисе Вәкил ага исән иде. Шуннан соң «Социалистик Татарстан» газетасында «Генерал кунакка кайтты» дигән язма дөнья күрде. Анда күбрәк генералның әти-әнисе турында сөйләнелде. Шулай булмыйча мөмкин дә түгел иде. Чөнки Вәкил ага яшьтән үк комсомол ячейкалары эшен башлап йөри, аннары Биләр, Сарман районнарында комсомолның район комитетын җитәкли, ул еллардагы җитәкчелек ролен үтәгән партиянең Сарман райкомының беренче секретаре итеп сайлана. Бөек Ватан сугышын ул Ленинградтагы ел ярымлык мәктәптә каршылый. Фронт юлын башыннан ахырына кадәр В.И.Чапаев исемендәге легендар дивизия составында үтә. Сугыштан соң Әгерҗе районы партия комитетының беренче секретаре итеп сайлана. Аннан Казандагы икееллык партия мәктәбенә укырга җибәрелә. 1949 елда Шәмәрдәндәге урман хуҗалыгында сәяси эшләр буенча директор урынбасары вазифалары тапшырыла. Саба леспромхозы белән бәйле тормышы аның шул чорда башлана.

Әнисе Гөлҗамал апа да тормышның эчендә кайный. Ул Арча районыннан. Гөлҗамал апа 1928 елда ук Мәскәүдә авыл советлары рәисләре укуында була, һәм Татарстаннан килгән хатын-кызлар шунда Н.К.Крупская белән очрашалар һәм бергә рәсемгә төшәләр. Бу рәсемне хәзер Дамир Вәкилевич кадерләп саклый. Шунысы аяныч: әни кеше улының генерал булганын күрә алмый — 1979 елда ук вафат була.

Хәзер Дамир Вәкилевичнең тормыш мизгелләренә тукталыйк.

Вәкил ага белән Гөлҗамал апа өч малай үстерәләр, аларга яхшы тәрбия, барысына да югары белем бирәләр. Илдус Казан авиация институтында укыды. Хәзер Киров шәһәрендә яши һәм инженер булып

эшли. Төпчек уллары Роберт, Казан химия-технология институтын тәмамлаганнан соң, эшкә Мәскәүгә урнашты. Дамир — иң олысы. Ул Сарманда дүрт класс татарча укый, Әгерҗедә русчага күчә. Шәмәрдәнгә килгәндә алтынчы класста була. Мондагы урман хуҗалыгы Лесхозга күчкәч, Тимерхановлар аптырап кала: бирherдә әле җиденче класс бөтенләй булмый. Иң олы балалар алтынчы класска киләчәк икән, шуңа күрә Дамирга Кукмарага юл тотарга туры килә.

— Турыга җәяү дә күп йөрелде, Иштуганга поездга чыксаң да, егерме чакрым кала иде, чаңгы белән узган Чокырча, Комар авыллары әле дә күз алдымда, — дип искә ала ул. — Фатирда тордым, вагон да бушаттым. Шуңа күрә укуның кадерен белдек...

Кулда — аттестат. Кыйбла билгеле. Ульяновск шәһәрендәге танк училищесына юл тота ул. Аны уңышлы тәмамлый һәм хәрби хезмәт юлын Германиядәге гаскәрләр группасында башлый, аннан өлкән лейтенант званиесендә кайта. Хезмәтен Төркстан хәрби округында дәвам итә.

1965 ел. Дамир Вәкилевич илебезнең башкаласындагы В.И.Ленин исемендәге Хәрби-сәяси академиягә имтихан тота. Аны «бик яхшы» билгесенә тәмамлагач, полк командиры урынбасары итеп җибәрелә. Дамир Вәкилевич үзенең Төньяк Кавказ һәм Кавказ арты шәһәрләрендә хезмәт иткән елларын сагынып искә ала. Бу елларда төп хезмәте белән бер үк вакытта бик күп җәмәгать эшләре алып бара. Партиянең өлкә, шәһәр комитетлары әгъзасы, Буйнак, Грозный шәһәрләре депутаты, Чечен-Ингуш республикасы депутаты итеп сайлана. Тбилиси шәһәре депутаты буларак та зур тырышлыгын куя, вакытын да, энергиясен дә кызганмый.

1981 ел. Октябрь ае. Гади татар улының тормышында зур борылыш. Д.В.Тимерхановка генерал-майор званиесе бирелә, татар генералларының саны тагын бер кешегә арта. 1982 елда аны Мәскәүгә күчерәләр. Тагын ике елдан ул илебез Гражданнар оборонасы идарәсенең инспекторлар бүлеге башлыгы итеп билгеләнә.

...Әнә шулай тормыш, хәрби хезмәт мизгелләре турында гәпләшеп утырабыз. Сөйләшкәндә йөзеннән елмаю китми, тыйнак кына итеп көлеп тә алгалый Дамир Вәкилевич. Һәм кинәт кенә җитдиләнеп куйды генерал. Аның күз алдына Чернобыль вакыйгалары килде булса кирәк.

Чернобыль. Фаҗига булганчы, бу шәһәрнең исемен күпләр белми дә иде, менә ул кешеләрне кинәт хафага салды. Әлеге зур булмаган шәһәр исеме бөтен Җир шарын тетрәндерде. Үзе белән күпме кешеләрнең гомерләрен алып киткәне һәм китәчәге төгәл билгеле түгел. Чернобыль фаҗигасе 1,5 миллион кешегә төрле дәрәҗәдә зыян салды. Алар арасында калкансыман биз, ак кан авырулары артуы, иммун системасының какшый баруы күзәтелә. Матди зыянны әйтеп тә торасы юк. Чернобыльнең сабакларын һәм нәтиҗәләрен һаман да МАГАТЭ (атом энергиясе буенча халыкара агентлык) кебек дәрәҗәле оешмаларның экспертлары өйрәнә. Әмма аның күпме нәселгә зыян салганын, ничә буынга күчәчәге турында беркем дә әйтә алмый.

Билгеле булганча, коточкыч нәтиҗәләре гаять зур масштабларны алачак шартлау 26 апрельнең (1986) таңында була. Ә инде ике көннән соң генерал Тимерханов, илебез Гражданнар оборонасының оператив группасы бүлеге башлыгы буларак, үзенең службасы белән Чернобыльгә килә һәм, 1987 ел беткәнче, хезмәт вазифаларын шунда башкара, 1988–1989 елларда да күп тапкырлар булырга туры килә аңа биредә. «Ул вакытта әле совет халкына килгән бу авырлыкларның без күләмен дә, сәламәтлеккә зыянын да, аның бөтен дөньяны аякка бастырырлык соңгы фаҗигаләрен дә болай итеп күз алдына китермәдек. Әмма үз алдыбызга куелган бурычны үтәү өчен белемебезне дә, көчебезне дә кызганмадык. Халыкны эвакуацияләүдә, шартлаган реакторны торгызуда, саркофаг төзүдә Гражданнар оборонасы личный составы зур геройлык күрсәтте», — ди ул.

Әйе, Дамир Вәкилевич Чернобыльдә башкарган эшләре турында тыйнак кына итеп, берничә җөмлә белән генә әйтергә тырышты. Әмма ул олы җитәкчеләр һәм галимнәр белән еш очрашып, һәлакәтне туктату турындагы киңәшләшү мизгелләре хакында сөйләгәндә, андагы хәлләрне күпмедер күз алдына китерәсең. Әйе, татар генералы биографиясендә Чернобыль дүрт елга якын вакытны эченә ала. Аның хезмәтләре эзсез калмый, әлбәттә. Ул башта Хезмәт Кызыл Байрагы, соңрак «Почет билгесе» орденнары белән бүләкләнә.

Тарих фәннәре кандидаты Д.В.Тимерханов аннары Мәскәүдәге фәнни-тикшеренү институтларының берсендә өлкән гыйльми хезмәткәр булып эшләде. Аның чиктән тыш шартларда эш стилен камилләштерү проблемалары буенча, шулай ук Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә Гражданнар оборонасы подразделениеләрендә сәяси хәлләрнең кайбер мәсьәләләре буенча фәнни хезмәтләре байтак. Алар аерым брошюралар итеп чыгарылган, күбесе чит илләрдә хәрби журналларда дөнья күргән.

Мин, уңайсызланып булса да, Дамир Вәкилевичтән ни өчен эшкә институтка күчүе, Чернобыльнең зарары сәламәтлегенә ничек тәэсир итүе турында да сорадым. Җавап кыска булды: «Чернобыль авариясендә булган хәрбиләр запаска илле яшьтән китә. Ә мин илле өчтә чыктым. Сәламәтлеккә дә зыяны булды, әлбәттә. Әмма ул турыда сөйләүне хуп күрмим».

Гаиләсе түгәрәк Дамир Вәкилевичнең. Өйдә саф татар телендә сөйләшәләр. Ачык йөзле җәмәгате Илфа ханым да Лесхоз бистәсеннән, кызлары Наилә югары белемле. Лесхоздагы әби-бабайлары — Ис-

хак ага Әмирхановларны сагынып искә төшерә алар.

— Татарстаныма кайтсам, мин Казан урамнары буйлап йөрергә яратам, — ди ул. — Чөнки хәзер Татарстан халкы күп илләрнең игътибар үзәгендә бит. Үзем укыган мәктәпләр, яшәгән төбәкләр төшләргә керә. Барысы да истә. 1955–1958 елларда әти утызмеңчеләр сафында Сарман районында колхоз рәисе дә булып эшләп алды. Ул вакытта да авыл көтүе чират белән иде. Минем хәрби училищеда укыган елларым. Җәйге каникулга кайтуыма миңа хәйран «чират» җыелып куела иде. Авыл кечкенә, көтүе дә рәттән генә йөри. Ашыйсы килсә яисә сусасам, әнигә кул гына болгыйм, хәзер килеп китә иде. Менә шулай, яшьлекнең бер генә мизгеле дә онытылмый.

Дамир Вәкилевич сөйли дә сөйли. Минем күңелдә шигъри юллар:

Дөньялар гына имин булсын,
Иминлектә — бәрәкәт...

Әйе, тынычлык сабыйга да, анага да, ир-атка да, солдатка да, генералга да кирәк.

*1992*

# Районыбызның беренче башлыгы

Бар табигать сихри матурлыкка чумган язгы иртәдә телефоным шалтырады. Районыбызның элеккеге хакимият башлыгы Фәрит Гыйльметдин улы икән. Хәл-әхвәл сорашкач, болай диде: «Йомышым зурдан түгел. Чәүкә зиратындагы әни ягыннан әби белән бабайның кабер ташларын яңадан куярга ниятләдек. Исем-фамилияләрен саф мөселманча һәм дөрес язасы иде», — диде.

Әйе, мин аның ата-анасы, әтисе ягыннан әби-бабасы, җәмәгате Сәнирә ханымның, барлык якын туганнарының мәңгелек йортларына ээ суытмаганын, гомумән, «Исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен бел» дигән гыйбарәнең асылын аңлап эш итүен белә идем. Алай гына да түгел, 2004 елның җәендә, аларның шәҗәрәләрен ачыклау йөзеннән, район үзәгендәге, Чәбки-Сабадагы (Чәүкә авылының рәсми исеме), Күкчәдәге (хәзер Теләче районына керә) туганнарында булып, нәсел-нәсәпләрен барлап чыккан идек. Бу изге гамәлдә Мәскәүдән кайткан туганнан туганы Рифхәт тә катнашты. Шулай итеп, иртәдән кичкә кадәр дәвам иткән эзләнүдән соң, без Батырша, Мөбарәкша, Гыйльметдиннәрнең нәсел агачы тамырының тирәнгә китүенә тагын бер кат инандык, борынгы Саба җирендә бабалары рухы йөрүенә-саклануына, буыннарның дәвам итүенә куандык. Әйе, һәркем үз вакыты белән бу фани дөньядан бакыйлыкка күчә. Чөнки без туфрактан яралган, кире шуңа кайтасы. Чорыбызның бөек әдибе Мөхәммәт Мәһдиевтән соң халкыбызда бер әйтем калды: «Кеше китә — җыры кала». Бу очракта сүз җыр турында гына түгел, әлбәттә, дөресен әйткәндә, киң мәгънәдә, үзеңнән соң якты эз калдыру турында бара.

Ишанлы авыл буларак тарихка кереп калган Казанчы Бигәнәй авылында туып, МТСлы Иске Икшермәдә үскән, шуннан институтка һәм тормышка юл алган Фәрит Гыйльмиевнең исеме районыбызның тарих сәхифәләренә мәңгелеккә теркәлеп калды. Аның хезмәт биографиясе турында гомерен тәрбия эшенә багышлаган Ханзәфәр ага Сәфәргалиев үзенең туган ягына багышлаган китабында түбәндәге юлларны язып калдырды: «Фәрит Гыйльметдин улы халык депутатларының район Советы башкарма комитеты рәисе, район Советы рәисе, хакимият башлыгы булып эшләгән елларда (1986–1997) зур эшләр башкарылды. Газлаштыру, юллар, күперләр салу олы масштабларда алып барылды, бихисап социаль объектлар төзелде. Авыл хуҗалыгында, мәгарифтә, мәдәнияттә, башка тармакларда алга китеш күзәтелде. Фәрит Гыйльмиевнең районыбыздагы эшчәнлеге Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә (1997 ел, 17 июнь) «Почет билгесе» ордены белән бәяләнде. Ул Саба җирендә туып үскән тәүге җитәкче буларак та тарихыбызга кереп калды. Аңа «Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде, Татарстан халык депутаты итеп сайланды. Соңгы елларда ул «Татавтодор», «Татсельэнерго» берләшмәләре кебек республика күләмендәге оешмаларга җитәкчелек итте һәм итә».

Миңа, бу юлларның авторына, Фәрит Гыйльмиевич белән байтак еллар бергә эшләргә насыйп булды. Әмма моңарчы аның турында язарга җай килмәде. Ул ярты гасырлык юбилеен район хуҗасы кәнәфиендә каршылады. Әмма бу уңайдан мәкалә бирүне кирәк санамады. Башлык хаклы да булгандыр. Үз кул астында эшләүче редакторның мактавын халык та бик дөрес аңламас иде.

Ә Фәрит Гыйльмиевич белән тәүге тапкыр якыннан танышуыбыз турында «Тагын... Саба мәзәкләре» дигән китапта сурәтләгән идем мин. Менә нәкъ шушы урында аны искә төшереп китү зыянлы булмастыр...

Районыбыз авыллары ел саен асфальт юллар челтәренә күбрәк тоташа. «Тормыш артерияләре» килеп җитмәгән хуҗалык үзәкләре бер кул бармаклары санынннан да азракка калып бара. Бар иде заманалар.

1976 елның апреле. Адәм әйтеп ышанмаслык хәл: Саба эченнән үзәк шифаханәгә төшәргә юл юк.

Аны, аптырагачтыр инде, Тимершык ягыннан (хәзерге «Урта Саба» ярдәмче хуҗалыгы фермалары тирәсеннән) карны ачып, басудан салдылар. Аннан да вездеход машиналар гына йөри ала иде.

Җитмәсә, яшь ярымлык улым Нияз чирләп китте. «Срочно стационарга!» — диделәр. Киттем вездеход эзләп. 159 нчы ПМКның ул вакыттагы начальник урынбасары Камил Галимҗанов бирде машина. Рәхмәт яугыры. Ярар, иртән төшереп урнаштырдым баланы әнисе белән.

Үзебезне, ягъни бөтен активны, сәгать тугызга райкомга җыйдылар. Көн тәртибендә бер мәсьәлә: хуҗалыкларга чыгып, язгы чәчүдә катнашачак техниканы тәфсилләп тикшереп, акт төзеп кайтасы. Мине, КПСС райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге инструкторын, иң ерак почмакка —«Җәлил» совхозы белән «Большевик» колхозына куйган Әһлетдин Арсланов. Гел шулай итә иде. Авыр туфрагы җиңел булсын. Үз егетләрен (оештыру бүлеге инструкторларын) ун гына чакрым ераклыктагы Сатышка яисә Эзмәгә куя, безне — җәһәннәмгә. Ул вакытта «КамАЗ» юллары салынмаган бит әле! «Өйдә кеше юк, больницада», — дип тә карадым. «Язгы чәчү важныйрак!» — диделәр.

Киттек. Райком кушкач, ничек карышасың инде. Безнең төркемгә төп белгеч итеп «Сельхозтехника»ның Teләчедәге махсус бүлекчәсе баш инженеры Фәрит Гыйльмиевне беркеткәннәр.

Китү планын төзедек. Машина белән Ленин исемендәге совхозның Үзәк бүлекчәсенә кадәр барабыз да, анда «Җәлил» совхозының куәтле «К-700» тракторы көтеп торачак. Безгә тагын терлекчелек буенча җаваплы кеше — район дәүләт ветеринария берләшмәсе начальнигы, Татарстанның атказанган ветеринария табибы Шәүкәт Хафизов кушылды. (Авыр туфрагы җиңел булсын.) Күрмәгәннең күрәсе килә дигәндәй, Ленино-Кокушкинодан килеп эшләүче район газетасы корреспонденты Сәетбатталов фамилияле сәер генә бик хисле журналист та иярде...

Дөрестән дә, «К-700» тракторы, салам җәелгән арбасын тагып, әйтелгән сәгатьтә каршы алды. Мине (райком кешесе бит!) кабинага утырттылар, калганнар арбага үрмәләде. Их! Шунда тора-бара Фәрит Гыйльмиевичнең хакимият башлыгы буласын чамаласам, арбага үзем мүкәйләгән була идем... Аның каравы әлеге «сөргендә» без ныклап танышып калдык, шуңа күрә район хуҗасы булгач та какмады, алай гына түгел, үзгәрешләр-буталышлар вакытында редактор итеп саклап калды. Шул бер калган килеш менә егерме биш ел эшләп торам бит әле...

Ярар, бик әйбәтләп тикшерәбез. Әле кар бетмәгән. «ДТ-75» тракторы белән чанада йөрибез. Көн саен бер авылда булабыз, чөнки техника шулай чәчелгән. Бу ике хуҗалык биләмәсендә ул елларда ничә авыл булганын хәтерләмим. Унбишкә якын иде бугай. Кич белән Олы Нырсы кунакханәсенә кайтып, терлекчелекне «күтәрергә» килүчеләр белән кунабыз. Кыскасы, ашау — байдан, үлем — Ходайдан.

Менә «Большевик»ка килдек. Таза, тотрыклы миллионер колхозның Ленин орденлы рәисе Кыям Җәләлович белән машина-трактор паркында очраштык.

Ул, миңа карап:

— Шәткегә пропаганда бүлеге инструкторының беренче килүе. Болай булгач, безнең колхоз да рәтләнә башлар инде, — дип борыч салды.

Аннары, монысын «бәрдем» дигән мыскыллы кыяфәт белән райком вәкиленә борылып:

— Фәрит Гыйльмиевич, сез бездәге хәлләрне күргәнсездер инде, — диде. — Эшләр харап бит. Быел чәчеп булмас инде ул. Сезне, Фәрит Гыйльмиевич, болай трактор чанасында йөртү килешмәс. Үземнең машина Теләчегә чыгарып куяр. Бер уңайдан дефектлар ведомостен алырсыз да кирәк запчастьларны төятеп җибәрерсез...

— Юк, юк, — диде юлдашыбыз, — без туганлаштык инде. Ничек килсәк, шулай кайтабыз!

Фәрит Гыйльмиевич бик грамотный итеп биш бүлектән торган русча акт төзеде. (Ул тарихи саргайган документның бер нөсхәсе минем шәхси архивымда хәзер дә саклана икән.) Аның соңгы җөмләсе көл һәм кош тизәге планы үтәлеше белән тәмамланган. Актка башта райком вәкилләре, аннары «Җәлил» совхозы директоры Г.Гарипов, баш инженер Б.Мөхәммәтгалимов, баш агроном Х.Әшрәпов, үзара ярышучы «Большевик» колхозының баш белгечләре С.Шәйхетдинов белән С.Әхмәтшин (ул мәрхүм булды инде) кул куйган.

...Ниһаять, Ленин исемендәге совхозның Үзәк бүлекчәсенә «К-700» тракторыбыз кире чыгарып куйды. Фәрит Гыйльмиевич белән Шәүкәт Кыямовичның машиналары көтеп тора иде. Башта «коры» җиргә аяк басуыбызга ышанмыйча тордык, инде исән-сау кайтканыбызга тәмам инангач, бераз «отмечать» итәргә булдык һәм, туп-туры карап, Теләчегә киттек...

...Мин, тиз генә Сания апа кибетенең склад ягына кереп, шифаханәдә ятучы (үзем еракта булсам да, күңелем гел алар янында булды) гаиләмә алып төшәргә күчтәнәчләр, шул исәптән бик тә дефицит бер банка компот алдым.

Сабага кайткач: «Туктале, мәйтәм, бу килеш туп-туры больницага төшеп булмас, хет күлмәкне алыштырыйм», — дип өйгә сугылсам, ни күзем белән күрим: газизләрем-җаннарым савыгып та чыкканнар!

Кызык итеп, шаян телдә тасвирланган «Савыгу» дип аталган әлеге хикәя-миниатюрада тарихыбызның гыйбрәтле мизгелләре чагылганын тойгансыздыр. Дөрестән дә, ул елларда асфальт юллар нефть чыккан районнарда гына иде, ә хәзер... без «Җәлил» совхозына, ягъни Олы Нырсыга, унбиш-егерме

минутта барып җитәбез. Мондый үзгәрешләрне башка тармаклардан да китереп була.

Әнә шул ярышлар турында әңгәмә корып алдык күптән түгел Фәрит Гыйльмиевич белән.

— Мин генә эшләгән кебек итеп язма тагын, һәр чорның үзенчәлекле авырлыклары, проблемалары, аларны хәл итү юллары була. Бер җитәкче дә булмасын дип йөрми, үзенең эзен калдырырга тырыша, — диде ул.

Сөйләшә башлагач, тарихи мизгелләр күп булып чыкты.

— Истә калган вакыйгалар байтак инде ул, — дип фикерен дәвам итте әңгәмәдәшем. — Бигрәк тә яңа бинаны файдалануга тапшыру, авылның тәүге өенә газ кергәч, шунда бер чынаяк чәй эчү, яңа салынган кара тасма кебек асфальтта бала-чаганың велосипедта йөрүен күрү күңелле була иде, — дип, ирен чите белән генә көлемсерәп куйды. — Әгәр дә мин эшләгән елларда нәрсәгә булса да ирешелгән икән, монда башта район халкы хезмәте чагыла, кадрларның оештыру роле аныклана. Ул чорда үзебездә туып үскән җитәкчеләр тупланды. Мәсәлән, хакимият башлыгы урынбасарлары булып эшләгән Исмәгыйль Мөхетдинов хәзер дә «Сабагаз» идарәсен, Илшат Миннебаев — «Машина-технология станциясе», Илһам Кәримов — «Агрохимсервис» җәмгыятьләрен, Илдус Талипов — «Мелиорация» күчмә колоннасын, Фәнис Хурамшин — «Саба агропромснабы»н, Фәргать Нәбиуллин — «159 нчы ПМК» ширкәтен, Тәлгат Шиһапов «Сабагазстрой» филиалын җитәклиләр. Мондый мисалларны тагын китереп булыр иде. Без бит барыбыз да тормышның әчесен-төчесен күргән, яшел чирәмле урамнарда уйнап үскән авыл малайлары...

Әйе, балачагы сугыштан соңгы ачлы-туклы елларга туры килә Фәритнең. Ишле гаилә баласы буларак, тормышның, гомумән, крестьянның авыр хезмәтен күреп үсә. Шуңа күрә яшьтән белемгә омтыла. Ул елларда югары уку йортларына керү өчен русча яхшы белү мәҗбүри була. Шулай итеп, Фәрит ике телне дә камил үзләштерә. Легендар директор, 1966 елда ук Татарстанның атказанган укытучысы исеменә лаек булган, кырык дүрт ел гомерен мәгарифкә багышлаган Кави Сәлим улы Байкиев җитәкләгән данлыклы Икшермә мәктәбен тәмамлаганнан соң, кечкенәдән техника җене кагылган егет фәкать үз тырышлыгы, нигезле белеме белән Казан авыл хуҗалыгы институтының механика бүлегенә укырга керә.

Студент булу бәхетен дә, авырлыкларын да татый-татый аны уңышлы тәмамлый. Инженерлык факультетындагы сызымнарның күплеген, аеруча төгәллек соравын шул бүлектә белем алган кешеләр генә тирәнтен аңлый. Гади итеп әйткәндә, йомырка өстендәге каз кебек, айлар буе утыралар алар ватман кәгазенә төрледән-төрле деталь рәсемнәрен сызып...

Кыскасы, энә белән кое казуның нәтиҗәсе куанычлы була. Дипломлы егетне үз ягына — «Икшермә» совхозына инженер итеп җибәрәләр. Шунда төпле белгеч икәнен күрсәткәч, башта «Сельхозтехника»ның Теләчедәге бүлекчәсенә күчерәләр. Олы булмаган бу предприятие, Фәрит Гыйльмиев җитәкли башлагач, «Т-150» тракторларын ремонтлый торган республикада махсус бүлекчәгә әйләнә, тулысынча хуҗалык исәбе белән, бер үк вакытта сыйфат гарантиясе белән эшли торган коллектив туплана. Бу елларда аны Казанга күчерү мәсьәләсе дә күтәрелә. Китми ул туган ягыннан. Тора-бара «Сельхозтехника»ның район берләшмәсен җитәкли, озакламый халык депутатларының район Советы башкарма комитеты рәисе, аннары район Советы рәисе итеп сайлана, хакимият башлыгы итеп билгеләнә.

Фәрит Гыйльметдин улы район белән җитәкчелек иткән елларда үзен аек фикер йөртүче, таләпчән шәхес итеп танытты. Аерым кешеләрнең, бигрәк тә сугыш һәм хезмәт ветераннарының, күп балалы, шулай ук ялгыз аналарның, яшь буынның, тулысы белән район халкының проблемаларын яхшы белүе белән хөрмәт казанды. Аның тырышлыгы белән районда беренче тапкыр картлар-инвалидлар йорты (филиалы Завод-Ныртыда) ачылды. Гомумән, сугыш, тыл һәм хезмәт ветераннарының батырлыкларын мәңгеләштерү өчен күп чаралар күрелде. Район үзәгендәге Билгесез солдат һәйкәле янәшәсенә якташларыбыз — Советлар Союзы Геройлары Вәлит Хаҗиевкә (Бөек Җиңүнең 50 еллыгы һәм әлеге мемориалны ачу тантанасында ул үзе дә катнашты), Иван Башкировка, Гали Закировка, Зәки Хәбибуллинга бюстлар куелды.

Район хакимиятенең яңа бинасын эшләтеп бетергәч, элеккесе яшь буынга тапшырылды, бирегә Аллаһияр һәм Хөснулла Вәлиуллиннар исемендәге сәнгать мәктәбе, Балалар иҗат үзәге урнашты. 1996 елның мартында монда Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев булды һәм, биш йөзгә якын укучы тартылган егерме өч иҗат берләшмәсе эшчәнлеге белән танышканнан соң:

— Көчле үзәк бу, — диде. — Могҗиза. Район Советы башкарма комитетыннан бушаган бинаны балаларга биреп бик дөрес эшләгәнсез...

КПСС райкомының элеккеге бинасына үзәк китапханәне күчерү, штатлар алып Татарстан Милли музееның филиалын ачу, 1841 елда төзелгән Җәмигъ мәчетен төзекләндереп, манарасын өр-яңадан күтәртеп, мәхәллә кешеләренә кайтару кебек изге гамәлләр халык хәтеренә мәңгегә кереп калды. Әлбәттә, бу авыр елларда, хуҗалык исәбенә күчеш башында, ягъни кыргый базар шартларында төзелгән производство, социаль-көнкүреш объектларының һәрберсен санап чыгу мөмкин дә түгел. Әмма райондагы мөмкинлекләрдән оста файдаланып, хезмәт коллективларының ярдәменә таянып, халыкка газ кертүдә, юллар һәм күперләр төзүдә, су, электр белән тәэмин итүдә тулаем күп эш башкарылды. Теләчегә газ

трассасы сузу мәсьәләсе буенча Мәскәүгә генә дә берничә мәртәбә барганы истә калган Фәрит Гыйльметдин улының.

Әгәр бу фикерне саннар белән ныгытсак, ел саен ул чорда йөз километр трасса салынып, меңгә якын йортка яисә фатирга газ кертелде. Пар казаннары бер-бер артлы табигый ягулыкка тоташтырылды. Эш күләме артуга «Сабагаз» идарәсенең һәм «Татгазстрой»га караган «Сабагазстрой»ның аякка басып, «зәңгәр ягулык» кертүдә тулы куәтләренә эшли башлавы зур йогынты ясый. Ә аларны мөстәкыйль итү өчен күпме көч куелганын район хуҗасы үзе генә белә. 110 вольт көчәнешле подстанция дә шул елларда сафка басты, агач баганалар ташка алыштырылды, түбән көчәнешле линияләр яңартылды. Шәмәрдәндә яңа ретранслятор эшләнеп, телевидение тапшыруларының сыйфаты яхшыртылды. Ел саен 30–35 чакрым юл асфальтланды, күперләр эшләнде. Яңа социаль-көнкүреш биналар саны артты. 1993 елда унбиш урында мәгариф учреждениеләре — мәктәпләр, балалар бакчалары биналары төзелеп, файдалануга бирелде. Белем бирүнең сыйфаты яхшырды. Олимпиадаларда, башка бәйгеләрдә җиңгән фәнсөярләр һәм аларның укытучылары акчалата бүләкләнә башлады. Халык иманга йөзе белән борылгач, яңа салынган мәчетләрнең саны ике дистәдән артты.

Алты меңнән артык кеше яши торган Шәмәрдән эшчеләр бистәсенә аерым игътибар бирелде. Бирелдә өч йөз егерме урынлы балалар бакчасы, кунакханә, спорт комплексы, гомуми мунча файдалануга тапшырылды.

Күмәк хуҗалыкларда җитештерү объектлары, ягъни терлек абзарлары, машина-трактор парклары төзү-ремонтлау күз уңында булды. Эшкәртү предприятиеләре технологик яктан камилләшә барды. Саба катнаш азык заводы базасында карабодай цехы продукция бирә башлады, ак он тегермәне корылды, рапс кабул итү, саклау комплексы монтажланды.

Хезмәтне заман таләпләре нигезендә оештыру, ит-сөт җитештерү күрсәткечләренә дә уңай тәэсир итте. 1993 елда район тарихында беренче тапкыр һәр сыердан уртача дүрт мең килограмм сөт савып алынды, бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культураларның гектар уңышы утыз центнердан артты.

Яңа ысуллар кертелде. Америка технологиясе белән бөртек өчен кукуруз игелеп, аның һәр гектарыннан илле центнер уңыш алынды. Ун мең баштан артык дуңгыз асрала торган «Кибәче» совхозында чәкән туратылып, азыкның «корнаж» дигән туклыклы төре әзерләнде.

Сәяси вакыйгаларга да бай булды әлеге чор. Теләче районы, мөстәкыйльлек алып, аерым яши башлады. Әлеге бүленеш закон нигезендә хәл ителеп, җитәкчеләргә рәсми төстә рәхмәт белдерелеп озатылды, истәлекле бүләкләр дә тапшырылды.

Фәрит Гыйльмиев — җыр-моң ярата, әдәбиятка, сәнгатькә гашыйк кеше. Туксанынчы еллар башында «Авыл көннәре» үткәрелә башлап, торак пунктларның культурасын күтәрү, халык иҗатын, йолаларны, оста кулларны барлау, үзешчәннәрнең башкару дәрәҗәсен үстерүгә юнәлеш алынды. Сәхнәләр заманча итеп бизәлде, артистларга костюмнар тектерелде. Мәсәлән, төрки халыкларының яңартылган Нәүрүз бәйрәме иң беренчеләрдән булып Сабада үткәрелде һәм аның сценарие республика районнарына таратылды. Мондый үрнәк мисалларны тагын китереп булыр иде. Районның сәнгать сөючеләре башкалабыз Казан, Башкортстанның Яңавыл шәһәрләрендә дә җитди имтихан тоттылар. Болар хакында академик якташыбыз Әбрар ага Кәримуллин «Ватаным Татарстан» газетасында «Җан ата кеше хакына» дигән баш белән җылы итеп язып та чыккан иде. Шуннан өзек китерик әле:

«...Район хакимиятенең мәгариф, сәнгать, мәдәният, шулай ук кешеләрнең социаль хәле турында кайгыртуы, бу өлкәдәге зур уңышлары да сөендерә. Саба үзешчәннәре, башкалага килеп, Казан тамашачыларын шаккатырып, сәнгатьнең иң югары таләпләренә туры килә торган зур бәйрәм ясап киткәннәр иде. Бу сәнгать десантын Ф.Гыйльмиевнең үзе алып килүе дә аның күңеленең сәнгатькә, моңга, изгелеккә тугры булуын күрсәтә дип саныйм. Мин аны районыбыз өчен янып эшләүче, аның халкы турында чын кайгыртучы патриоты дип саныйм. Аның Башкортстанның Яңавыл районы белән хезмәт, мәдәни элемтәләр оештыруын да мин яңача эшләү формасы дип саныйм. Читтә яшәүче, чыгышы белән Саба ягы кешеләрен, артист һәм язучыларын, галим һәм композиторларын, күренекле кешеләрен барлау, аларны Сабага, туган якларына чакыруны да әнә шул җирле ватанпәрвәрлек тәрбияләү дип саныйм.

Саба районы кешеләренең шундый кайгыртучан, тирән акыллы башлыклары булуына сөенәм. Шуның өстенә ул бит читтән килгән, өстән куелган кеше түгел, бирелдә туган, бирелдә формалашкан, кендеге белән туган җиргә бәйләнгән.

Минем гомеремдә Ф.Гыйльмиевне нибары ике-өч тапкыр күргәнем, тыңлаганым бар, тик утырып, рәхәтләнеп сөйләшкәнем юк. Мин аны башкарган хезмәтләре аркылы беләм, аның туган телдә матур, эзлекле, дәлилле, кешеләрнең күңеленә керерлек итеп сөйләшә, аңлаша белгәне өчен хөрмәт итәм. Аның кем икәнлеге Саба районының уңышларында чагыла».

Монда яңавыллыларның Сабага килүе турында сүз чыккач, күңелдә тагын бер хатирә яңарды. Кунаклар арасында Татарстанның халык язучысы, күп кенә тарихи романнар авторы Нурихан ага Фәттах, Казанга кайткач, түбәндәге хатны юллаган иде: «Без әледән-әле сабалыларны искә төшерәбез. Сездә үткәргән күңелле көннәр, елмаюлы йөзләр, мул табыннар, яшел басулар һаман күз алдында. Радиодан

Саба турында сүз чыкса, шундук колаклар үрә тора — туган якларны ишеткәндәй булабыз. Сезнең үзегезгә, барлык сабалыларга исәнлек-саулык, илгә иминлек, муллык теләп калучы Нурихан».

Әлеге язманы укыгач, бу чорда ал да гөл булган икән дигән фикер калмасын тагын. Болгавыр, катлаулы еллар булды алар. КПСС җитәкче партия буларак яшәүдән туктады, сайлаулар альтернатив юл белән үткәрелде, фикер төрлелеге, ягъни плюрализм киң җәелде. Кыскасы, еллар нык сынады район җитәкчесен, төрле каршылыклар килеп чыккан мизгелләр дә булды.

Гомумән, тормыш, яшәеш сынаулардан тора бит ул. Нинди генә вазгыять килеп туса да, Фәрит Гыйльметдин улы беренче чиратта гаиләсенә —җәмәгате, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы Сәнирә Гарифулла кызына таянды һәм таяна. Бер акыл иясе: «Берничә айдан уңыш алыйм дисәң, иген ик, ун елдан уңыш алыйм дисәң, агач утырт. Гомер буе хөрмәттә яшим, җир йөзендә якты эз калдырыйм дисәң, бала укыт», — дигән. Уллары Илфат белән Инсафка (кызлары Нурия Казан финанс-икътисад институтында укуын дәвам итә) югары белем бирделәр Гыйльмиевләр. Егетләрнең үз гаиләләре бар инде.

Әйе, кеше гомере аккан чишмә кебек. Адәм баласы дөньяга килә дә нәсел калдыра-калдыра яшәвен дәвам итә. Менә Фәрит Гыйльметдин улы да алтмышынчы туган көненә — олы юбилее тантанасына килеп җитте. Шәхси язмышына, узган тормыш юлына канәгатьләндерү белдерә ул, үзен якты дөньяга иңдергән әти-әнисенә, туган җиренә, газиз халкына рәхмәт укый-укый яши. Аның үзенә дә алга таба бары бәхет-шатлык, болытсыз күк йөзе, якты киләчәк, гаилә иминлеге һәм иман байлыгы телибез!

*2006*

# Урман белән бәйле гомер

Көзге урман өсләреннән
Гомерләр узып бара...

*Х.Әюп*

Әти җиккән атка утырып Саба урманнарына тәүге тапкыр килгән җәйне бүгенгедәй хәтерлим. Мәктәпкә укырга кермәгән идем әле. Безнең Кукмара тирәсендә урманнар булмаганлыктан, шушы Саба ягын таптый идек. Ул чорда колхоз мал-туар асрау өчен печәнне бик аз бирә иде. Басудан җыярга да ярамады. Шуңа күрә сарык-бәрәннәргә юкә миллеген мул итеп әзерләдек. Бер җәйне ундүрт ат йөге алып кайтканны хәтерлим. Әти белән, таң атып килгәндә, Хаммат яки Мөхәммәтдин абый кордонына юл алабыз. Лесник чыгып киткәнче барып җитәргә кирәк. Аннары ул күрсәткән юкәлекне сирәклибез. Әти чабып бирә, мин арба янына ташып торам. Аннары бергәләп төйибез. Икенче көнне өйдә яфрагын миллек итеп бәйлибез, ботагын кышын ягу өчен чабып өябез...

Минем әле «Карурман» җырын да, «Лашман бәете»н дә ишеткәнем юк иде ул вакытта. Эш белән табигатьнең матурлыгын да күрмәгәнмендер. Гомумән, алга таба гомеремнең күп өлеше шушы Саба якларында узачагы, аның урманнары, атаклы Миңнехановлары, Гыйззәтуллиннары, Гарәфетдиновлары, кыскасы, йөзләгән кешеләре турында очерклар, мәкаләләр язачагым ике ятып бер төшемә дә кермәгәндер...

Ә менә бу язмам герое — Васил Нурулла улы — үзенең урманчы булачагын алдан ук чамалаган. Күпмедер хыялланган да икән әле ул. Моны раслау өчен бер вакыйганы искә төшереп үтү урынлы булыр.

«...Васил Гыйззәтуллин бала вакытта әнисе казыган бәрәңгене чүпли икән. Әтисе Нурулла абый, лесник булгач, бик өйдә тора алмаган, күрәсең.

Кояшлы көзге көн була бу. Күктә сирәк-мирәк самолетлар да оча икән. Шуннан кечкенә Васил әйтеп куйган:

— Үсеп җитиең дә йә лесник, йә летчик булыең».

Әйе, көтү көтеп, агач утыртып үскән малайның хыялы тормышка аша. Техник та, лесник та, баш инженер да була ул. Саба урман хуҗалыгы директоры камытын кигәнгә дә алдагы көздә дүрт ел тула. Нинди генә эш башкарса да, кеше булып калырга тырыша ул. Тора-бара «Урманнарга керсәм...» дигән татар халык җырларының бер куплеты аның кыйбласына әйләнә.

Урманнарга керсәң, сызгырып кер,
Уянмаган кошлар калмасын.
Кай җирләрдә йөрсәң, гел яхшы бул,
Сокланмаган кеше калмасын.

Гомумән, аларның нәселе эш сөючәнлекләре белән аерылып тора. Гыйззәтулла абзый яшьлегендә күмер чаба. Аннары Өркеш авылында бригадир, завхоз, авыл советы рәисе вазифаларын башкара. Улы

Нурулла да бик яшьтән трактор сабанына сукачы булып утыра. Аннары, Тәкәнеш МТСында укып, үзе трактор «иярли». Аны яшьлек ашкынулары, язмыш сукмаклары ил-җир гизәргә дә алып китә. Ленинград—Муром тимер юлының икенче линиясен салуда катнаша. Бөек Ватан сугышы башлануын Мәскәү—Беломорканал төзелешендә ишетә. Шуннан соң Карелия урманнарын кисеп, юл сала-сала Архангельск өлкәсен урый. Төньяк Двина елгасы аша чуен юл төзүдә катнашырга да насыйп була аңа. Сигналчы һәм телеграфист-элемтәче буларак, Ленинград, Кронштадт, Таллинн, Сталинград тирәләрен дә урый ул. Шулай итеп, чыгып киткәненә унбер ел тула дигәндә, күкрәгенә орден һәм медальләр тагып, урман сакчысы булган әтисе янына — Явлаштау авылына кайтып төшә Нурулла-солдат. Озак та үтми, уңганлыгы белән авылда дан казанган сыер савучы Рәйсә исемле кыз белән танышып, гаилә дә корып җибәрәләр, һәм Нурулла егерме ел лесник булып мәрхүм әтисе Гыйззәтулланың эшен дәвам итә башлый. (Бу урында, алга узып, Нурулла ага белән Рәйсә ханымның мәңгелеккә шушы авыл зиратында калуын да искәртү кирәк булыр.) Нур өстенә нур дигәндәй, гаиләдә Рәсимә, Васил, Вәсилә, буй җитеп, кул астына керә башлыйлар.

Кыскасы, Гыйззәтуллиннар — урманны, урман аларны үстерә.

Васил Нурулловичтан: «Кайда тудыгыз?» — дип сорагач, бер генә сүз белән җавап бирде:

— Кордонда.

Явлаштауда сигезьеллык мәктәп тәмамлаганнан соң, Лубян урман техникумында белем ала язмабыз герое. Аннары Нургали Миңнеханов аны Мари политехника институтына югары белем алырга җибәрә.

Без Васил Нурулла улы белән беренче тапкыр Курса урманчылыгында очраштык. Лубянда бергә укыган, үзе янында эшләүче Рәсүләсе белән өч кызларын — Энҗене, Илзараны, Илмираны үстереп, матур гына гомер итеп яталар иде алар. Җитәкче буларак шушында тәүге чыныгуны алды да инде Васил. 1988 ел аның күңелендә уелып калды. Икътисад күрсәткечләрен яхшырту белән беррәттән, социаль объектлар төзүгә игътибар ителә. Кибет, пекарня, балалар бакчасы, башлангыч мәктәп салына. Клуб, китапханә, медицина пункты һәм ашханә яңа бинага күчә. Эшчеләр өчен фатирлар төзелә, су торбалары сузыла, электр линияләренә реконструкция ясала.

Курса урманчылары, һәр елны 8000 кубометр агач кисеп, эшкәртеп, тактасын, рәшәткәлеген, өй тышлау материалын, араталыгын, башка төр халык куллану товарларын күпләп җитештерделәр. Саба урман хуҗалыгы директорының махсус заказларын да җиренә җиткереп үтәделәр алар. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының хәзерге бинасы төзелгәндә, яхшы сыйфатлы агачтан борыс әзерләп бирделәр курсалылар.

Лесхоз бистәсеннән шактый читтә — Арча районы биләмәсендәге әлеге урманчылыкта эшләгәндә, үз эшен чын күңелдән яратуын раслады Васил. Бу вазифа урман тормышының барлык сукмакларын узган кешегә иң элек баш инженер, аннары зур коллективның директоры булырга ярдәм иткәндер. Легендар урманчылар — аталы-уллы Миңнехановлар озак еллар җитәкләгән, ил күләмендә дан казанган, күп тапкырлар Бөтенсоюз Кызыл Байракларына лаек булып, Мактау такталарына кертелгән хуҗалыкны җитәкләүнең авыр да, җаваплы да, шул ук вакытта абруйлы икәнен дә үзе генә беләдер яшь директор.

— Мин тормышымда тыйнак кына уңышларга ирешкәнмен икән, болар өчен гомерем буе Миңнехановларга, иң беренче Нургали абыйга, аннары Рәис Нургалиевичкә бурычлы. Алар белән уртак тел таптык, фикерләр бер булды, шуңа күрә уртак максатка омтылып эшләдек һәм эшлибез, — дип фикерен дәвам итте Татарстан Республикасының атказанган урманчысы Васил Гыйззәтуллин. — Мин генә түгел, бөтен Лесхоз халкы аксакалыбызга рәхмәт укый, рухына дога кыла. Шулай булмыйча мөмкин дә түгел. Сазлы урындагы кечкенә генә авылны социаль мәсьәләләргә багышланган Бөтенсоюз фәнни-практик конференциясе уздырырлык (1989) торак пунктка әйләндергән шәхес бит ул. Табигый газ яга башлаганыбызга да егерме ел була. Шуңа күрә мин, ирешелгәннәрдән чигенмичә, һәр тармакны тагын да камилләштерү өчен җаным-тәнем белән тырышам...

Дөрестән дә, мәңге рәхмәтле һәм тугрылыклы ул үзенең остазына. Исән вакытта да бик хөрмәт күрсәтте аңа Васил Нурулловнч. Вафатыннан соң да исемен мәңгеләштерү, һәйкәлен ясатып кую, Нургали ага калдырган хәзинәләрне саклау һәм ишәйтү өчен көчен дә, сәләтен дә, тырышлыгын да кызганмый. Хәзер бистәдә Урман музееи булдыру артыннан йөри, бинасын салдыра.

Фикерне йомгаклау алдыннан районыбызның даны-горурлыгы булган урманчыларның калдыксыз технология белән башкарган эшләре турында бик күп саннар, мисаллар китереп, исем-фамилияләр тезеп, алар яшәгән бистәне матур итеп тасвирлап булыр иде. Болар хакында республика матбугаты да бик еш яза. Әле күптән түгел «Татарстан хәбәрләре» газетасы түбәндәге исем белән «Саба ягында бар җәннәт почмагы — аны Лесхоз диләр...» сәхифәсен үз укучыларына тәкъдим итте.

Саба урман хуҗалыгы җитәкчеләрен күзаллаганда, төз нарат-чыршылары, сылу каеннар, чәчәклеҗиләкле, гөмбәле аланнары, чишмә-күлләре, җәнлекләре, хәтта кырмыска оялары, күз явын алырлык сувенирлары күз алдына килә. Урман — бөтен тузанны йотып торучы фильтр, кислород һәм башка файдалы элементлар эшләп чыгаручы тере орган, яшәү, тереклек чыганагы да бит ул. Менә сигез район биләмәсендәге 57 мең гектарга җәелгән шушы табигать байлыкларын саклаучы, үстерүче, коллективны

оста җитәкләүче Васил Нурулла улы Гыйззәтуллинны илле яшьлек юбилее һәм бу тармакта эшли башлавына утыз ел тулу уңае белән котлап, иман байлыгы, тән сихәтлеге (ул әле шушы көннәрдә генә операция дә кичерде), бәрәкәтле озын гомер, гаилә иминлеге телисе килә.

*2003*

## Яшәү яме — хезмәттә

Ленин исемендәге тәҗрибә-производство хуҗалыгы хезмәт коллективының сыер савучысы Гөлбикә Гали кызы Кәримованың 387 нче Арча территориаль сайлау округыннан СССР халык депутатлыгына кандидат итеп күрсәтелүен ишеткәч, күңелдә канәгатьләнү хисе туды. Чөнки Социалистик Хезмәт Героен күптәннән беләм: аның белән фермада, район партия комитеты пленумнарында, төрле-төрле тантаналарда да еш очрашырга туры килә. Шуңа күрә үзе янына барырга ашыкмадым. Менә утыз ел инде социалистик ярышның алгы сафында атлаучы хезмәт герое ул. Аңа 1959 елда ук «Татарстанның иң яхшы сыер савучысы» дигән мактаулы исем бирелә. Гап-гади һөнәр иясенең тормыш юлын, абруеның ничек формалашуын, хезмәттә күренекле казанышларга нинди алымнар аша ирешүен кабат күзаллау өчен, 1981 елда Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Эшемне яратам» дигән китабын кулыма алдым. Китапның беренче юлларында ук болай диелгән: «Сыер савучы булып эшлим мин. Егерме биш елга якын инде шушы хезмәтемне башкарам. Күңелгә хуш килгән китапларны кат-кат укып, үзең өчен һаман саен яңадан-яңа мәгълүматлар алган кебек, яшьләй сайлаган һөнәрем дә барыр юлымны гел яктыртып тора, тормышымны тулы, үземне бәхетле итә...»

«Яшьләр белән әңгәмә» сериясеннән чыгарылган бик җиңел укыла торган бу китап язылганга да шактый еллар үткән.

...Авыл гомер-гомергә иртә уяна. Алсу таңнары кешеләргә рухи күтәренкелек бирә, аларның күңелендә якты өметләр уята. Үткән тормыш мизгелләрен күңелдән кичерергә мөмкинлек бирә. Гөлбикәнең дә сабыйлык еллары кырыс сугыш елларына туры килә. Бала чактагы авырлыклар аны күп нәрсәгә — иң беренче һәм тормышта иң кирәге — хезмәтне яратырга өйрәтә. Алтынчы классны тәмамлаган җәйне ул вакытлыча сыер сава башлый. Ә инде 1954 елдан чын терлекче булып китә. Башта Ленин исемендәге совхозда, аннары, тормышка чыккач, «Беренче Май» колхозының Мамалай авылында эшли. Алар гаиләсе совхозның Үзәк бүлекчәсенә күчеп килгәч, эш колачы тагын да арта. Биредә терлек карауны фәнни нигездә алып бару мөмкинлеге зуррак. Хуҗалыкта авыл хуҗалыгы белгечләре еш була. Тора-бара совхоз Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты карамагына бирелә. Галимнәрнең, белгечләрнең чыгышларын тыңлау, аларның киңәшләрен тотып эш итү эзсез калмый, билгеле. Ныклы азык базасы булдырыла, нәсел-селекция эше яхшыртыла. Шул елларда сыерларны сөт бирүчәнлекләренә карап ашатуга күчәләр. Болай эшләү, чыннан да, җитештерүдә әле шактый гына файдаланылмаган мөмкинлекләр булуын күрсәтә. Шулай итеп, группадагы терлекләр берничә төркемгә бүленә. Яңача эшләүгә күчүнең беренче елында ук Г.Кәримова һәр сыердан уртача дүрт мең килограмм сөт сава, республикада иң беренче булып потчылар хәрәкәтен башлап җибәрә. 1966 елда ул Ленин орденына лаек була. Олы бүләк белән рухланган Гөлбикә Галиевна 1970 елны һәр сыерның продуктлылыгын 5734 килограммга җиткереп тәмамлый.

1971 елның апрель иртәсе. Бу көн хезмәт каһарманының күңелендә мәңге саклана.

— Беркөнне иртән фермадагы эшләрне бетереп өйгә кайтырга гына дип чыккан идем, ни күзем белән күрим, каршыма әнкәй йөгерә, — дип искә ала шул көнне Г.Кәримова. — Ул яныма килеп җитәргә дә өлгермәде:

— Котлыйм, балакаем, котлыйм, — диде, еш-еш сулап.

Шунда гына мин безнең гаиләгә нинди шатлык килгәнен абайлап алдым.

— Ни белән котлавың, әнкәй?

— Ишетмәдеңмени? Герой иткәннәр бит! Герой!

— Кемне?

— Сине, балакаем, сине! Синең хөрмәткә радиодан җыр да җырлаттылар инде.

Ул арада мине башкалар да чолгап алган иде инде. СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән илебездәге иң югары исем — Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелгән иде.

Әйе, тырышлык һәрвакыт җиңү китерә. Коммунист Гөлбикә Галиевна андый шатлыклы вакыйгаларны шактый күп кичерде. Аның тагын берсе 1976 елда булды, ул партиянең иң олы форумында — КПССның XXV съездында делегат булып катнашты. Аннан зур тәэсирләр белән кайтты. Шуннан соң, хезмәт коллективлары, мәктәп укучылары белән очрашып, съездда алган фикерләре белән уртаклашты һәм яңа көч белән илһамланып эшли башлады. Фидакарьлек беркайчан да эзсез калмый шул. Биш елдан соң — 1982 елда — СССР Дәүләт премияләре бирү турында КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы карары игълан ителде. Бүләкләнүчеләр арасында безнең Гөлбикә Галиевна да бар

иде. Ул СССР Дәүләт премиясенә терлекчелек продуктлары җитештерүне елдан-ел арттыра һәм сыйфатын яхшырта барганы, заманча технологияләр кулланып, хезмәт җитештерүчәнлеген арттырганы өчен лаек булды.

Күренеп тора, Гөлбикә Галиевна беркайчан да «алтын урталыкта» булмады. Ул гел ярышның алгы сафында барды, соңгы биш елда да сыерларның продуктлылыгын уртача 5000 килограммнан киметмәде. Күп мәртәбәләр СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә катнашты һәм җиде медаль яулады, шуларның икесе — алтын.

Г.Кәримованың тагын кайбер сыйфатларына тукталасы килә. Алар — кешелеклелек, тыйнаклык, үз-үзеңә таләпчәнлек, башкаларга ярдәмгә атлыгып тору, яшьләрдә үз профессиясенә мәхәббәт тәрбияләү. «РСФСРның атказанган остазы» дигән мактаулы исемгә лаек булган Гөлбикә Галиевна үзенең эшләү дәверендә унбиш терлекче тәрбияләде. Шуңа күрә Гөлбикә Кәримова югарыда исемләнгән китабын мондый юллар белән тәмамлый: «Һәм, соңгы сүз итеп, киләчәктә сыер савучы булачак яшьләргә мөрәҗәгать итәсем килә: «Терлекчелеккә эшкә килүегезне, авырлыклардан курыкмавыгызны телим. Кешене бары тик хезмәт кенә бизи. Бәхетегезне дә нәкъ менә хезмәттә табарсыз. Хәерле сәгатьтә, яшь иптәш!»

Әнә шулай фикерләр бер ноктага туплана: яшәү яме, кешенең бәхет, шатлыгы, абруе һәм дәрәҗәсе хезмәттә матди байлыклар тудыруда. Гөлбикәләр кебек уңганнарның тырышлыгы белән совхозның төп базасы ныгыды, хезмәт процесслары механикалаштырылды, авылларның социаль йөзе үзгәрде. Узган биш елда хуҗалыкта бер йөз сиксән урынлы ике ясле-бакча, медицина профилакторие, ике кибет, шулай ук ашханәсе, душы, ял бүлмәләре, медпункты булган терлекчеләр йорты салынды, һәр елны ун квартира файдалануга тапшырыла, производство объектлары төзелә, искеләре реконструкцияләнә. Ел саен бер миллион сумлык төзү-монтаж эшләре алып барыла.

Кыскасы, гомер буе гади хезмәтенә сәләт-рухын, йөрәк җылысын биргән, тыйнаклыгы белән аерылып торучы кеше ул Гөлбикә Гали кызы Кәримова.

*1986*

# Кырык дүрт ел мәктәптә

Укытучыларның яңа уку елы алдыннан була торган август киңәшмәсе башланып килә. Традиция буенча, төп докладларга керешкәнче, сәхнә алдына гомер буе балаларга мәгърифәт нуры өләшеп, лаеклы ялга яше җиткән ветеран мөгаллим-мөгаллимәләр чакырыла. Алар адресына җылы, эчкерсез сүзләр әйтелә, истәлек бүләкләре, кочак-кочак чәчәк бәйләмнәре тапшырыла һәм җыр яңгырый: «Сез иң гүзәл кеше икәнсез...»

Бу залда быел мөгаллимнәрнең мөгаллиме, районның хөрмәтле педагогларының берсе, үзенең кырык дүрт ел гомерен балаларга багышлаган, утыз җиде ел бер урында мәктәп директоры булып эшләгән Кави Сәлим улы Байкиев күренмәде. Гадәттә, аның урыны президиумда була торган иде. Ветеранның быелгы олы педсоветта катнашмавының сәбәбе хезмәттәшләренә мәгълүм: чөнки аны җәй уртасында мәктәп директорлары үзләренең чираттагы киңәшмәләреннән соң рәсми төстә лаеклы ялга озаттылар. Тантана искиткеч тәэсирле булды. Ул махсус сценарий буенча алып барылды. Чал чәчле ветеран үзе дә бик дулкынланды, күңеле тулды, шуңа күрә озак сөйли алмады, фәкать җиренә җиткереп рәхмәт кенә әйтә алды.

...Кечкенә Кавида яшьтән үк укытучы булу теләге уяна. Чөнки моның сәбәбе бар. Мамадыш районының Ак Чишмә авылында туган әтисе, чыгышы белән безнең районның Олы Шыңар авылыннан булган әнисе бөтен йөрәкләре, рухлары белән педагогикага мөкиббән киткән кешеләр булалар, мөгаллим булулары белән чиксез горурланалар, үз эшләренең дәрәҗәсен беләләр. Боларны раслау өчен Сәлим ага Байкиевның Ленин орденына лаек булуын әйтү дә җитәдер. Бу олы бүләк хәзер ветеран-педагогның шәхси әйберләре белән Түбән Шытсу авылы музеенда саклана.

Элек бит укытучыларны күчереп йөртү гадәте булган. Бу — кадрлар җитмәгән өчен шулай эшләнгән. Һәр мәктәпкә махсус урта яки югары белемле укытучы булдыру максат итеп куелган. Алар янына тулы булмаган урта белемлеләрне дә туплаганнар. Менә Байкиевлар Питрәч районының Кибәк Иле авылында эшләгән вакытта дөньяга ир бала килә. Аңа Кави дип исем кушалар һәм газиз улларының үз нәселләрендәге изге юлларын дәвам итүен теләп дога кылалар. Булачак мөгаллимнең балалык еллары Питрәч районының Иске Йорт, Теләче районының Олы Мәтәскә авылларында үтә. Авылдан авылга чегәннәр кебек күчеп йөрүче гаиләне һәркайда да менә дигән йорт көтеп тормый. Кайда буш өй бар, шунда урнаштыралар Байкиевларны. Язмыш җилләре аларны безнең районның Түбән Шытсу авылына китерә. Шушында кечкенә Кави беренче класска укырга керә. Тырышып укый. Җәйге айларда сарыкчылык фермасы мөдире булган Гобәйдулла Хуҗин (соңыннан озак еллар колхоз рәисе булып эшләде) җитәкчелегендә көтү көтә. Бөек Ватан сугышы елларында халык күргән бөтен авырлыкны үз җилкәсендә

татый.

Белемгә сусавы аңа киләчәк юлын тәгаен билгеләргә мәҗбүр итә. «Укытучы булачакмын!» дигән үҗәтлеге бер генә минутка да исеннән чыкмый.

Сугыш вакытында Түбән Шытсу мәктәбенең югары класслары ябылып тора. Шуннан соң ул Октябрь борылышына кадәр данлыклы мәдрәсәсе булган Сатыш җидееллык мәктәбендә укый, аны тәмамлагач, 1943 елда Арча педагогия училищесына барып керә. Ул булачак мөгаллимнәр арасында мәһабәт гәүдәсе, ташып торган энергиясе белән аерылып тора. Училищеның комсомол оешмасын җитәкли, һәр оештырылган чараның, алып барыла торган хуҗалык эшләренең башында тора, яшьләр арасында тәртип өчен көрәшнең, гомумән, күп башлангычларның инициаторы була. Үзе өлгер, сүзгә үткер, тынгысыз, хәрәкәтчән яшүсмер бер генә минутын да бушка сарыф итми. Биредә ул Татарстан Республикасының булачак халык язучылары Мөхәммәт Мәһдиев, Гариф Ахунов кебек талантлы яшьләр белән очраша. Менә үзе бер калын китап язарлык вакыйгалары белән училище еллары артта кала.

Бөек Ватан сугышы тәмамлана. Күптән көткән куанычлы бу хәбәрне аңа училище җирен ат белән сукалаганда килеп ирештерәләр.

1946 ел. Махсус урта белем генә канәгатьләндерми булачак педагогны. Гаиләдәге изгелеккә корылган мөгамәлә, һәр сөйләшү аны югары белем алырга омтылдыра. Әти-әниләренең дә уларын җаны-тәне, акылы-фигыле белән мәгариф эшенә бирелгән, югары культуралы, итагатьле мөгаллим булуын күрәселәре килә.

— Училищены «отлично»га тәмамлаган идем, — дип искә ала Кави ага. — Педагогия институтына имтиханнар биреп йөрим. Абитуриентларның күбесе хәрби киемнән — офицерлар. Күкрәкләре тулы орден-медаль. Аларга өстенлек зур. Конкурс та кечкенә түгел, бер урынга ун кеше. Шулай булса да сынатмадык. Бәхеткә каршы, сочинение Арчада язган тема — Максим Горькийның «Ана» романы буенча иде. Педучилище ныклы белем биргән икән. Моны имтиханнар вакытында бөтен тулылыгы белән аңладым. Шулай да бер кызыклы вакыйга истә калган. Географиядән имтихан тапшырам. Дөянең русча исемен оныттым бит. Шуннан нишләргә? Сикереп тордым да, кулыма акбур алып, тактага дөя рәсемен ясап куйдым. «Верблюд», — диде укытучы Коганъ. Минем дә искә төште. Теге көлде дә тагын бер бишле куйды. Шулай итеп, бөтен фәннәрне «отлично»га биреп, көндезге бүлек студенты булдым. Белем диңгезенә башым-аягым белән кереп чумдым...

Кулына диплом алып, туган ягына әверелгән Саба төбәгенә кайта югары белемле яшь белгеч. Дөресен әйтергә кирәк, бу елларда институт яки университет тәмамлаучылар бармак белән санарлык кына була. Аны Советлар Союзы һәм Социалистик Хезмәт Геройлары, бер академик, шулай ук Татарстан Фәннәр академиясе әгъза-корреспондентын, ике мәшһүр композитор, язучылар, артистлар, бик күп фән эшлеклеләре, халык хуҗалыгы җитәкчеләре биргән Саба урта мәктәбенә тарих укытучысы итеп билгелиләр.

Шулай итеп, 1950 елның 15 августыннан педагогик стажы исәпләнә башлый Кави Байкиевның. Өч ел дәрәҗәле коллективта чирканчык алгач, аны Завод-Нырты тулы булмаган урта мәктәбенә директор итеп билгелиләр. Район җитәкчеләре һәм авыл халкы яшь директорның оештыру талантын тиз күреп алалар: 1954 елда район Советы депутатына кандидат итеп күрсәтәләр. Шуннан, гадәттәгечә, сайлаучылар белән очрашулар китә, наказлар бирелә. Урта Нырты авылында чишмә суын таран белән, ягъни суның төшү авырлыгы белән кудыруны механикалаштыруны сорыйлар сайлаучылар. Бу мәсьәлә уңай хәл ителә. Шунысы кызык һәм тарихи: әлеге наказ, чишмәне вакытында карап тору сәбәпле, бүген дә хәрәкәттә. Шулай итеп, халыкка 40 ел буе игелекле хезмәт итә ул.

Ярар, депутат, ягъни халык хезмәтчесе дә булды Кави Сәлимович. Озак та үтми, син коммунист, партия кайда куйса — шунда эшләргә тиеш, дип, аңа хезмәт ияләренең район советы башкарма комитеты секретаре вазифасын тәкъдим итәләр һәм «сайлап» та куялар. Яңа эшкә керешә Байкиев. Чүрилене Саба районына кушу «операция»ләренең уртасында кайный, килгән җитәкчеләрне каршы ала. Ат белән озатып йөри, ашата-эчертә. Аннары кичләрен артта калган кәгазь эшләрен «куа». Дөресен әйтергә кирәк, күңеленә батмый бу эш. Тизрәк котылу ягын карый ул. Аны әти-әни каны белән кергән яраткан эше — мәктәп гел үзенә чакырып тора, балалар төшләренә кереп азаплый.

Һәм, ниһаять, үтенече канәгатьләндерелә: Кави Сәлим улы Югары Симет мәктәбенә директор итеп билгеләнә. Аны монда да җимерек хәлдәге иске бина каршы ала. Шуңа күрә мәктәпнең бинасы чагыштырмача әйбәтрәк булган Түбән Симеткә күчереп торырга мәҗбүр булалар. Бу уку елы уңышлы тәмамлана. Җаен директор кышка утын хәстәрли. Аны Гәрәй дигән егет белән ташып, кисәләр, яралар. Ике укытучы — Гөлсем белән гомерлек тормыш юлдашы булачак Саяра өеп торалар.

— Шулай май аенда йомышлар белән Казанга киттек, — дип искә ала әңгәмәдәшем Кави ага. — Алма апа дигән әнинең сеңелләренә фатирга кердек. Берзаман, әллә күземә күренәме дип торам, ул вакыттагы мәгариф бүлеге мөдире Гасыйм Йосыпович килеп керә. Бу миңа: «Сине эзләп килдем. Тат.Икшермәгә директор кирәк. Башка кандидатура юк. Тыңла. Бергә-бергә эшләрбез. Киттек министрлыкка», — ди. Ул еллардагы урта мәктәп директорларын Мәгариф министрлыгы раслый иде. Киттек. Министрның Айгистов дигән урынбасары кабул итте. Дөресен әйтергә кирәк, үземнең һич кенә яңадан күчеп

йөрисе килми иде. Симеткә килгәнемә дә бер генә ел бит әле. Шактый сораулар биргәннән соң: «Аракы эчәсеңме?» — ди бу. Бәлки, расламаслар, дигән фикер белән: «Эчәм», — дидем. Барыбер растладылар. 17 май көнне приказга кул куелды. Бу 1957 ел иде.

Татар Икшермәсе авылындагы катнаш рус һәм татар класслары булган урта мәктәп бинасы да бик искергән була. Директор Разак ага Вафин инде Шәмәрдән бистәсенә күчеп киткән. Мәктәпне Кави Сәлимовичка ул вакыттагы завуч Хәлим Бариев тапшыра. Бөтен булган байлык чыгымчы бер ат һәм ярты кубометр чамасы утын була. 1988 елда, соңыннан озак еллар үзе Үзәк урта мәктәбе директоры булып эшләп пенсиягә чыккан, район һәм республика газеталарының актив хәбәрчесе булган Х.Бариев «Социалистик Татарстан»да чыккан «Еллар аша» дип исемләнгән Кави Байкиев турындагы күләмле мәкаләсендә бу чорларны болай дип искә ала: *«...Бөтен кайгысы да, шатлыгы да мәктәптә үтә аның. Укыту-тәрбия эшен, мәктәпнең матди базасын заман таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәгә җиткерү өчен зур көч, күп вакыт сарыф итәргә туры килә. Элеккеге директордан мирас итеп алган ярым җимерек мәктәпне совхоз үзәгендәге балкып торган белем сараена әверелдерү өчен күп тырышлык куя. Бу вакытта ул урман кисүче дә, балта остасы да, ташчы да үзе була».*

Әмма урта мәктәпнең яшь директорын тормыш законнары башта төрлечә сыный. Кышын, уку елы барышында, мастерскойның түшәме ишелә, «бегемот» дип аталган бина яраксыз хәлгә килә. Шуннан мәктәпне совхоз үзәгенә — Иске Икшермә авылына күчерү турында катгый карарга киләләр. Һәм иртә яздан эшкә тотыналар. «Менә, нинди бәхеттәндер, ул җәйне безгә КПСС райкомының беренче секретаре В.Минһаҗев белән ул вакыттагы Татарстан Министрлар Советы рәисе С.Шәрәфиев килде, — дип искә ала Кави ага. — Мәктәпне карадык. Өйгә кереп чәйләдек. Беренче улым Илдар туган вакыт иде. Соңыннан су да коендык бугай. Киткән вакытта Шәрәфиев дүшәмбе көнне үзенә килергә кушты. Киттем. Владимир Сотник дигән ярдәмчесе мине чиратсыз гына кертте. Шуннан ул, тиешле кешесен чакырып: «Бу мәктәпкә 100 мең сум акча, 10 мең кубометр агач бирәсез», — диде. Минем сөенечем эчемә сыймыйча, җил-җил кайтып киттем»...

Шуннан башлана «удар» төзелеш. Башта урын мәсьәләсе килеп туа. Хәзерге нигезне бик бирергә риза булмыйлар. Чөнки анда шалкан уңа торган була. Авылдан читкә чыгарып, тау башына — җил оясына салырга тәкъдим итәләр. Соңыннан Кави Байкиев: «Җир бөтен кешегә дә җитә. Балалардан аны кызганмагыз, тора-бара барыбызга да ике метр урын җитәр», — диярgә мәҗбүр була. Шуннан соң гына мәктәп хәзерге урынга салына башлый. Төзелеш кыш буе дәвам итә. Моңа бөтен ир-ат укытучылар тартыла. Аркылы пычкы белән урман киселә. Матчалыкларның озынлыгы унике-ундүрт метрга җитә. Көндез агачны трактор белән Сабадан ярдәмгә килгән Васыйл Галиев (соңыннан озак еллар «Марс» колхозы рәисе булып эшләде) ташый, кичләрен «С-80» маркалы көчле техниканы директор үзе иярли. Бөтен ишегалды төзелеш материалы белән тула. Шиферы, кадагы да шунда була, авыл халкы бернәрсәгә тими, «урлау» дигән төшенчәне белмиләр биредә. Хәзер әйтергә генә ансат: кыш буе өч авылның кырык-илле кешесе эшләп, яңа уку елына озынлыгы — 50, киңлеге 12 метр өч тамбурлы мәктәп сафка баса. Дистәләгән мичкә ягыла, бина бик җылы, күлмәкчән йөри торган була, укучылар ясаган тумбочкалар өстендә кышын да гөлләр үсеп утыра. Класслар да зур итеп бүленә, чөнки ул вакытта балалар саны ишле була.

Яңа мәктәптә укый башлагач, интернат бинасы да салына. Равил Сабитов совхоз директоры булган елларда ПМК кирпечтән ике катлы йортлар төзи башлый. Шуның җитәкчеләре белән сөйләшкәннән соң, фундамент өчен таш бирү бәрабәренә ак кирпеч юллана. Укытучылар көче белән өелеп, менә дигән тагын бер бина сафка баса.

Еллар үткән саен, Кави Сәлимовичның оештыру таланты ачыла бара. Алай гына түгел, ул оста финансистка, армый-талмый чабучы тәэминатчыга, итагатьле дипломатка әйләнә. Мәктәпнең матди-техник базасы ныгый бара. Укытучылар көче белән төзелгән янкормалар өстәлеп тора. 1967 елда ике катлы яңа бина сафка баса. Әмма ихтыяҗны болар гына канәгатьләндерми. Заманча, типовой проект белән мәктәп төзү турында хыяллана башлый директор. Ниһаять, 1984 елда подряд ысулы белән 464 урынлы бина сафка баса. Бу мәһабәт ташпулат өчен күпме энергия киткәнен, ничә йөз чакрым юллар үтелгәнен, нинди дәрәҗәле кабинетларның ишекләре шакылганын, төзүчеләр белән яхшылап та, ачуланышып та сөйләшкәннәрен Кави ага үзе генә белә. Җитмәсә, соңгы елларда аны шикәр диабеты дигән каһәр төшкән авыру борчый башлый. Шуңа күрә портфелен кулыннан төшерми. Анда һәрвакыт кирәк вакытта үз-үзенә ясау өчен уколлар, ашау ризыгы була. Әмма ул, аңа карап, юл йөрүдән туктамый, яңа мәктәпне җиһаз, уку кирәк-яраклары белән тәэмин итү өчен бөтен сәламәтлеген җигә, машина-машина әйбер ташыта.

Гомумән, мәктәпнең базасы гомер-гомергә бай була. 1957 елда, ягъни эшли башлауга, «Беренче Май» колхозы аша йөк машинасы ала Кави Сәлимович. Алтышар трактор һәм машина тоткан еллары күп булды Икшермә мәктәбенең. К.Байкиев төп база хуҗалыгы белән гомер-гомергә тыгыз элемтәдә яши. Ул эшли башлаганда, Икшермәдә МТС була әле. Аның директоры, Татарстан Верховный Советы депутаты Җиһан ага Хәбибрахманов белән дә тиз арада уртак тел таба. Совхоз оештырылганнан соң төрле елларда җитәкчелек иткән Равил Сабитов, Шәүкәт Сафиуллин, Камал Мөхәммәтшин, Чулпан

Шәрәфетдинов, Илдус Имамиев, Зөфәр Мөхәммәтшин кебек җитәкчеләр белән дә эшлекле мөгамәләдә була. Шулай булмыйча мөмкин түгел, чөнки 1966 елда ук «Татарстанның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исемгә лаек булган Кави Сәлимовичның абруе аның белән исәпләшергә мәҗбүр итә. Дөрес, абруй, фәлсәфи категория буларак, субъектив төшенчә. Аны кулга тотып карап булмый, диләр. Әмма ул Байкиев кебекләрдә күзгә күренеп тора.

Бу язмада тагын бер мәсьәләгә — мәктәпнең ярдәмче хуҗалыгына тукталып үтмәсәк, дөрес булмастыр. Әле «Мәгариф» журналының тулысы белән Саба районы укытучылары тәҗрибәсенә багышланган 1993 елгы декабрь ае санын карап утырдым. Анда мондый юллар бар: «Бүгенге көндә район мәктәпләрендә 1765 урынга исәпләнгән егерме ашханә эшли. Бу уңайдан Икшермә урта мәктәбе (директоры — К.Байкиев) тәҗрибәсе зур игътибарга лаек. Мәсәлән, анда балалар 1957 елдан бирле кайнар аш белән бушлай тәэмин ителәләр. Бу — җитәкченең булган мөмкинлекләреннән хуҗаларча файдалануы нәтиҗәсе. Һәр елны мәктәп үзенең ярдәмче хуҗалыгында уку елына җитәрлек яшелчә әзерли. Быел да ашханә складларында укучылар өчен егерме тонна бәрәңге, кыяр, шактый күләмдә кишер, чөгендер, сигез йөз килограмм кайнатма (варенье) саклана. Кече фермада унбиш баш дуңгыз симертелә. Соңыннан исә дуңгыз ите сыер итенә алмаштырыла».

Элек-электән терлекне мул асрыйлар биредә. Бишәр баш ат, унбиш-егерме баш үгез симерткән чорлар була. Берзаман, совхоздан арендага алып, балаларга сөт өчен сигез баш сыер асрыйлар, саву өчен ике электр аппараты кулланалар. Дуңгыз үрчетеп, аның балаларын сату, итен комбинатка тапшырып, урынына сыер ите алу белән дә озак еллар шөгыльләнәләр. Ә инде куян мәсьәләсенә килгәндә, бу тармак бик «модалы» заманнарда икшермәлеләргә беркем дә тиңләшә алмый. Ул еллардагы партия райкомының беренче секретаре Габбас Гыйматдинов, партконференция трибунасыннан мондый чагыштыру китереп: «Икшермә урта мәктәбе укучылары берүзләре районның унтугыз колхоз-совхозы хәзерләгән кадәр куян ите җитештерделәр. Зур рәхмәт аларга!» — ди.

Ничек башлана соң бу эш? Моның да инициаторы мәгариф бүлеге мөдире Г.Йосыпов була. Берзаман ул Кави Сәлимовны Биектау районының «Бөреле» совхозына алып китә. Баралар, танышалар. К.Байкиев шуннан «Ак великан» дигән токымлы ана куян алып кайта. Әнкәсе булгач, атасы да табыла, әлбәттә. Үрчем мул алына, илле-алтмыш читлек барлыкка килә, аларга сыймагач, махсус ярма эшләнә. Укучыларга көн саен ун-унбиш куяннан кайнар аш әзерләнә, артканы иткә тапшырыла, тере килеш тә сатыла, балаларга да бүләк ителә. Ферма мөдире дә, директоры да үзе була, исәп-хисапны төгәл алып бара, һәр ана куянга исем кушыла. Кыскасы, мәктәпнең махсус счетына акча су кебек ага башлый. Куян тиреләрен Кама Аланына кадәр алып барып саталар. Район финанс бүлегендә акча күп керүгә шик белдерәләр, ул вакыттагы бүлек мөдире Галәү ага Минһаҗев үзе килеп, тикшереп тә китә. Бу елларда укучылар, Татарстан Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә күп тапкырлар катнашып, дипломнар, истәлекле бүләкләр алалар...

Куян дигәннән, тагын бер вакыйга искә төште. Миңа, бу юлларның авторына, моннан шактый еллар элек мәрхүм фотокорреспондентыбыз Рузбек Йосыпов белән Казаннан электр поездында кайтырга туры килде. Шунда юлдашым югарыда телгә алынган мәгариф бүлеге мөдире Гасыйм Йосыповичның җәмәгатен — озак еллар районыбыз сәламәтлек бүлеге мөдире, баш табибә булып эшләгән туганнары Кәримә Хөсәеновнаны күреп алды. Район халкы «Кәримә-врач» дигән исем биргән бу мөхтәрәм ханым турында күп тапкырлар җылы сүзләр ишеткәнем бар иде. Сөйләшеп киттек. Рузбек Гасыйм Йосыповичның (ул вакытта исән иде) хәлен сорады. Кәримә апа кыска гына болай диде: «Әйбәт. Өй-бакча тирәсендә. Һаман куян асрый. Башта үстерә, аннан суя, тиресен үзе или, бүрек итеп тегә һәм базарга алып чыгып сата». Шушы сүзләрне ишеткәч, «Кулыннан гөлләр тама» дигән канатлы фраза кабат хәтердә яңарган иде...

Укытучыларны, гадәттә, архитекторларга, ягъни бала күңелен иҗат итүчеләргә тиңлиләр. Матди-техник база, ярдәмче хуҗалык нык булгач, калган бөтен игътибар ныклы белем һәм тәрбия бирүгә юнәлдерелә. Бу мәсьәләләргә утыз елдан артык директор урынбасары булып эшләүче Фәһим ага Җәләев тә аеруча зур игътибар бирә. Гомумән, педагогик коллектив күп нәрсәне яңача фикерләп, яңача күзаллап эш итә. Белем белән бергә механизатор, терлекче, тегүче һөнәрләре дә бирелә. Әмма девиз бер генә була: «Һәр дәрес — ачык дәрес булсын!» Фидакарь хезмәтнең нәтиҗәсе дә куаныч китерә. Кайбер елларны урта мәктәпне тәмамлаучыларның 40–45 проценты югары һәм махсус уку йортына укырга керә. Бу — 38–40 балалы алтышар параллель класслары булган авыл мәктәбе өчен зур күрсәткеч. Шуңа күрә бүген мөгаллимнәр үзләре путевка биргән укучылары белән хаклы рәвештә горурланалар. Алар арасында фән кандидатлары, танылган табиблар, иҗат кешеләре, район җитәкчеләре, колхоз рәисләре, совхоз директорлары, башка җаваплы тармакларда эшләүчеләр бихисап күп. Кави Сәлимович гомер буе шушындый көчле коллектив белән хаклы рәвештә горурлана һәм хезмәттәшләренең исем-фамилияләрен хөрмәт белән бармак бөгә-бөгә саный.

Менә шулай итеп, тынгысыз хезмәт белән гомеренең шактый өлеше узган инде аның. Кави Сәлимович — гаиләдә дә абруйлы ир, кадерле ата. Җәмәгате Саяра Гарифулловна белән өч бала үстереп, барысына да югары белем биргәннәр.

Кави ага кырык дүрт елдан соң яңа уку елын лаеклы ялда каршылады. Мәктәп яныннан әкренләп кенә үтәргә ярата ул. Чөнки аны монда иң беренче булып 1959 елда утырткан каеннары сәламли, аннан олысы-кечесе тирән ихтирам белән баш иеп исәнләшә башлый...

Әлеге материалны йомгаклау алдыннан шуны искәртәсе килә: Кави аганың хезмәт һәм тормыш юлындагы штрихларны кәгазьгә төшергәндә, аның нигездә уңай сыйфатларына басым ясалды. Дөнья булгач, кемнәргә дә ошамаган вакытлары да булгандыр язма героеның. Җитәкче кеше һәркемгә дә ярап бетмәскә дә мөмкин. Бу — табигый хәл. Ә менә 40 елга якын бер урында директорлык итеп, «җылы» җирләргә чакыручыларны гел кире кагып, шушы төбәккә тугрылыклы булып калган Кави Сәлим улы Байкиевка лаеклы ялының игелеген тигезлек белән, кайгы-хәсрәтсез күрергә насыйп булсын!

*1994*

# Милләт җанлы Шамил

Районыбызның Явлаштау авылында урнашкан сәламәтләндерү лагеренда кызыклы очрашулар булып тора. Иң сәләтле сиксәннән артык бала ял итә торган «Кояшкай»га олы шәхесләр — танылган дин белгече, борынгы кульязма китапларны өйрәнүче Әнвәр Хәйри, Татарстан Фәннәр академиясе әгъза-мөхбире, тарих фәннәре докторы, археолог Фаяз Хуҗин һәм «Сәләт» педагогик комплексы җитәкчесе, Казан дәүләт университеты профессоры, шагыйрь Җәүдәт Сөләйманов еш киләләр. Анда мирасыбызны, тарихыбызны барлауга багышланган гаҗәеп матур, эчкерсез сөйләшү булып, һәр чор объектив бәяләнде, фән һәм археология өлкәсендәге яңалыклар яшь буынга җиткерелде, бик күп сорауларга җаваплар бирелде. Алай гына да түгел, фәнсөярләр алдында Әнвәр һәм Фаяз абыйлары халкыбызның «Гөлмәрфуга», «Уел» кебек мәңге тутыкмас борынгы көйләрен җырлап та күрсәттеләр. Балалар Җәүдәт абыйларын шагыйрь буларак та бик яхшы беләләр. Очрашуның рәсми өлеше тәмамлангач, галимнәрдән култамгалы китап алу өчен өч-дүрт урында чират хасил була.

Борынгы Саба төбәгендә мондый очрашулар әледән-әле булып тора дисәк, һич арттыру булмас. Аларның һәркайсы, матурлык дөньясында сәяхәттә булган кебек, йөрәктә уелып кала, андый шәхесләр белән аралашкан саен күңел байый, иман ныгый. Чөнки, организмга икмәк кирәк булган кебек, җан да, хикмәт, — рухи азык сорый бит. Шушы урында әлеге очрашуларны һәрдаим оештыручының милләт җанлы, телебезнең нечкәлекләрен, әдәбиятыбыз тарихын белүче районыбызның мәгариф бүлеге башлыгы Шамил Зиннуров икәнен ассызыклап китмәсәк, ярамас. Ул, тәрбия-белем, әдәп-әхлак мәсьәләләрен фән, әдәбият, сәнгать кануннары нигезендә яшь буынга үтемле итеп сеңдереп булганын ихлас күңеленнән аңлап, әлеге очрашуларны дистә еллар буе максатчан оештырып килә. Бу фикеремне раслау өчен төгәлрәк мисаллар да китерәм. Мәсәлән, 1990 елда ук халкыбызның яраткан язучылары Мөхәммәт Мәһдиев белән якташыбыз Мәгъсум Хуҗин кайтканнар иде. Аннары олуг шагыйрь-шагыйрәләр Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Фәнис Яруллин, Резеда Вәлиева, язучылар Туфан Миңнуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рашат Низамиев, Нәбирә Гыйматдинова, Камил Кәримов, Рәдиф Сәгъди, галимнәр Азат Әхмәдуллин, Васил Гайфуллин, Хатыйп Миңнегулов, Флорид Әгъзамов, Валериан Габделхаков, Васил Гарифуллин һәм башка бик күп шәхесләр укучыларның, мөгаллимнәрнең, китапханәчеләрнең, гомумән, әдәбият-сәнгать яратучыларның көтеп алган кунаклары булдылар. Сабага ике тапкыр килгән Фәнис абый Яруллинны Шамил Зиннур улының машинадан аудиториягә, аннан кире машинага күтәреп йөрткәне бүгенгедәй күз алдымда тора.

Әлеге язмам герое Шамил дус белән без Мөхәммәт абый Мәһдиев янында элек тә, гомеренең иң авыр чакларында да, соңгы сәгатьләрендә дә булдык. Чөнки ул укытучы-остазыбыз гына түгел иде шул. Әтисе Сөнгатулла яшүсмер вакытта (1895–1905) районыбызның Сатыш мәдрәсәсендә укыганлыктан, Сабаны икеләтә хөрмәт итте әдип. Әтисенең шул мәдрәсәдә кулланган каләме белән кара савытын шушы авыл музеена тапшырырга кушты. Халкыбызның бәгырь язучысы вафат булып, бераз вакытлар үткәч, Шамил Зиннурович, Мөхәммәт абыйның улы Искәндәр белән җәмәгате Лилия апаны алып килеп, берсеннән-берсе истәлекле әдәби-музыкаль кичәләр оештырды.

Шундый зыялылыкның һәм кешелеклелекнең, хөр күңеллелекнең, зирәклекнең чишмә башы кайда икән, дип озак кына уйланып утырдым. Ул, мөгаен, Шамилнең туган авылыннан ук киләдер. Әйдәгез, шул якларга сәяхәт итеп алыйк әле.

Исеме «Идегәй» дастанында «Урмандагы Саба» дип телгә алынган төбәкнең гаҗәеп матур тын почмагына урнашкан бер авыл бар. Казанчы Бигәнәй ул. Шунысын да әйтеп үтик, татар халкының танылган әдибе Шәйхи Маннур «Агымсуларга карап» дигән автобиографик повестенда да телгә алган аны. *«Җәй урталарында әнкәйнең хәле тагын да сәерләнебрәк китте: эссе көндә дә арка үзәгем туңа, дип, иңенә шәл салып, камзул киеп йөри башлады. Төнлә озын-озак йөткерүенә кайчак мин дә уянып китәм,* — дип искә ала Шәйхи ага. — *Ә беркөнне әткәй Мөхлисулла абыйларның атын тимерхутларына җигеп кайтты да, әнкәйгә киемнәрен киендереп, кунакка баргандагы шикелле, олы мендәр өстенә утыр-*

*тып, Бигәнәй мулласына алып китте. Безнең тирәдән әллә кайда ераклыктагы Бигәнәй авылында бик зур ишан хәзрәт бар икән. Аңа барып күренгән, ул өшкереп биргән даруларны эчкән кеше савыкмыйча калмый, ди. Безнең әнкәй дә терелер, боерган булса!*

*Аннан кайткач, чынлап та әйбәт кенә күренә башлагандай булды әнкәй. Күңеле дә көррәк шикелле, гәүдәсе дә җиңелрәк йөрешле. Әткәй белән икесе иртүк торып уракка китәләр...»*

Студент елларында ук хәтергә уелып калган шушы хәлләр озак еллар күңел түрендә йөрде. Кем ул Бигәнәй хәзрәт? Нилектән аның исеме, гасырга якын вакыт узуга карамастан, халык күңеленнән китми, нигә аның турында, дәрәҗәле дин әһеле һәм күренекле табиб буларак, күпсанлы риваятьләр таралган.

— Шамил дус, бүген, көннең бушрак булуыннан файдаланып, тарихи авылыгызга төшеп, аның Хәзрәт бакчасы, Хәзрәт күле, Ишаннар каберлеге дип халык телендә йөри торган урыннарын карыйк әле, — дип шалтыраттым район мәгариф бүлеге мөдиренә.

— Бернинди проблема юк. Бер уңайдан әти белән әнинең хәлен дә белеп чыгарбыз, — дип хуплады ул тәкъдимемне.

— Беләсездер инде, сезнең авылның хәзрәтен Тукай да телгә алган бит. «Куркыныч эш» мәкаләсендә. Укып күрсәтимме?

— Әйдә, — диде Шамил. — Хәтердән чыккан, ахры.

— «Алабуга өязе Салагыш волосы Бәзәкә карьясендә өч хатынның эчләренә җылан кермеш... Аллаһы Тәгалә хәзрәте үзе сакласын. Берсе — унике яшәр кыз, берсе — карчык, берсе — бер суфи кешенең килене. Боларны Бигәнәйле хәзрәткә алып киттеләр. Алла хәерле шифалар бирсен!»

...Без Шамил Зиннур улы белән, Вәлиәхмәт хәзрәтнең биләмәсен, йорт, мәчет нигезләрен, күл, кибет, пыяла, чүнник урыннарын карап чыкканнан соң, зиратка юл тоттык.

Ишаннар каберлеге уникегә уналты метр чамасындагы мәйданны били икән. Ундүрт тупыл шаулап утыра, берничә каен да бар. Табигый таш койма белән уратылып, төп зираттан бүленеп алынган. Койманың биеклеге бер метр чамасы. Каберлеккә керү өчен тимердән эшләнгән ишек-капкасы да бар. Андагы ун кабер ташының язуларын укып та була.

— Әмма аянычы шул, — ди Шамил, — зурлыгы һәм үзенчәлекле формасы белән башкалардан аермалы төп кабер ташының — 1919 елда дөнья куйган Бигәнәй ишаны Вәлиәхмәт хәзрәтнең язулары сакланмаган. Нишләмәк кирәк, заманасы шундый иде бит... Әйдә, өйгә сугылыйк әле, туксан яшьлек әти дә байтак хатирәләрне саклый Ишан хәзрәт турында.

...Зират. Аны авылның ачык һавадагы музее диләр.

Әнә туган авылының матурлыгын тоеп, аның тарихы белән горурланып, алай гына түгел, газиз нигезенең кадерен белеп, туып үскән өенә якынлаша әңгәмәдәшем. Аның артыннан мин дә атлыйм.

Безне туксанны узып унынчы дистәсен ваклаган Зиннур бабай Мөхәммәтрәхимов каршылый. Йөзе тирән җыерчыклар белән чәрдәкләнгән, әмма ул мөлаем елмаеп килеп чыкты. Өйгә узып, түр башында чиста, пакь киемнән утырган Шамилнең әнисе белән ике куллап күрештек. Ул вакытта аңа сиксән тугыз яшь иде (хәзер мәрхүмә инде, авыр туфрагы җиңел булсын). Ходай Тәгалә Акъәбине олыгайган көнендә кояш яктысыннан мәхрүм иткән. Сугыш чорында бигрәк күпне күргән шул ул. Ирен фронтка озатып, өч нарасые белән җан саклау, исән калу өчен көрәшкән. Ачлыкны, ялангачлыкны, хәерчелекне үз җилкәсендә татыган. Ире сугышка киткәндә бәби булып калган Тәслимәсе, әтисе 1947 елның мартында кайтып төшкәч: «Теге кеше бездән кайчан китә икән?» — дип сораганын гомер буе онытмый икән Һаҗәр апа.

Сугыштан соңгы еллар да җиңел булмый. Тырмашып булса да көн күрәләр ирле-хатынлы Мөхәммәтрәхимовлар. Заманына күрә матур гына итеп өй дә салып чыгалар. Нәселне дәвам итүче тагын өч бала — Фәһим, Нәсимә, Шамил дөньяга килә.

— Озын гомерле булдым мин, — дип сүзен башлап җибәрде Зиннур абый. — Сез кызыксына торган Ишан хәзрәт үлгәндә, миңа тугыз яшь булган. Өйләре бездән ерак түгел иде. Бакчасыннан алма өзеп биргәнен дә хәтерлим. Башта төрле хәлфәләрдән дин сабагы алдым, җәдит мәктәпләре ачылгач, укырга өйрәндем. Бервакыт язу таный башлагач, сандыктан кәгазь кисәге алып укыганымны хәтерлим әле. Анда «1909 елның 12 үктәбрендә Мөхәммәтзиннур туды» дип язып куйган булган абыем. Озын гомерле булдым, дип әйтүем юкка түгел, 2009 елда, йөз еллыгым да якынлаша бит.

Унбиш яшьтән әтисенә ияреп балта эшенә йөри башлый Мөхәммәтзиннур. 1922 елгы ачлыктан да исән кала, колхозлашу еллары авырлыкларын да күрә. 1941 елның 10 мартында ике айлык сборга алынганда, Зиннур үзе дә, өч бала анасы Һаҗәр дә алты елга аерыласыларын уйлап та карамыйлар. Сугыш башланганда Литва җирендә булалар безнең солдатлар һәм 25 августта әсирлеккә эләгәләр... Шуннан соң инде, исән калсак, шул җиткән, дип үткәргән газаплы көннәре башлана.

Алар каһәрләнгән концлагерьларны, төрмә-крепостьларны, башкарган авыр хезмәтне, төрлечә кимсетүләрне, этләргә талатуларны тасвирлап бетерә торган түгел. Эчәр суы, җыяр ризыгы, газиз балалары туган җирендә калган булгач, Герман җиреннән мең ярым чакрым араны стройга тезелеп, Белоруссиянең Барановичи дигән шәһәренә кадәр җәяүләп кайталар әсирләр. Аннан соң да өйләренә озатмыйлар әле. Рига шәһәрендәге җимерекләрне төзекләндерүдә эшләтәләр.

— Түздек инде, — ди ветеран. — Пленда булгансыз, дип, Сталин үлгәнче допроска чакырып йөдәттеләр. Минә тиздән сугыш беткәнгә алтмыш ел була. Әмма шундагы мәхшәрләр һаман төшкә кереп йөдәтә. Ярый инде балаларымның бәхете булды. Өчесе Казанга урнаштылар, Тәслимәбез авылда тормышка чыгып калды. Нәсимә белән Шамил Сабада гомер итәләр. Без картаймый кем картайсын инде, әйеме? Төпчегебез Шамил дә иллегә якынлаша икән бит...

Сталин үлеп, «җепшек еллар» башлангач туа Шамил. Сабый вакытта ул, «Гармунчы аю белән җырчы маймыл»ны яттан сөйләп, халыкны таң калдыра. «Хәйдәрнең аты булган, колагы каты булган» дигән юллар бик ошаган авылдашларына. Шуңа күрә очраган һәрбер кеше: «Әйдә, Хәйдәрне сөйлә әле, акча түләп киного алып керәм», — дия торган булган.

Авылларындагы башлангычны, Сатыштагы сигезьеллык мәктәпне гел бишкә диярлек тәмамлый. Урта белемне Сабада ала. Кечкенәдән китапны күп укый. Моның өчен ул китапханәче Ольга апасына, укытучылары, Резеда, Райлә апаларына, Рәуф һәм Рифгать абыйларына рәхмәтле. Җәмәгать эшләрендә катнаша, комсомол оешмасын җитәкли. Мәктәп тәмамлаган елны институтка баруны кирәк дип санамый. Өлгереп җитмәгән әле, янәсе. Шуңа күрә бер ел туган авылында эшли. Кечкенәдән ат җигеп үскән малайны бернәрсә дә куркытмый. Мәктәптә бирелгән таныклык белән трактор «иярли». Аннары гына Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына документларын тапшырып, имтиханнарны уңышлы бирә һәм студент булу бәхетенә ирешә. Биш елга сузылган укулар башлана. Тулай торакка да ике елдан соң гына урнаша Шамил. Чөнки бухгалтериядә эшләүче апасының да хезмәт хакын исәпләтеп алган була гаилә кереме турындагы белешмәне. Шуңа күрә «ару тормышлылар» исемлегенә эләгә ул башта.

Университетта да әйдәп баручыларның берсе була Шамил. Татар хорына йөри. Югары стипендия ала. Профессор Хатыйп Госман индивидуаль план белән укыта аны. Дүрт җәй рәттән Коми якларында төзелештә эшләп, өс-башын карый, кышка бераз мая туплый, иң беренче чиратта колхозчы әти-әнисенә булыша.

Студент еллары да артта кала. Кулда — диплом. Эшкә туган ягына җибәрәләр аны. Ул вакыттагы район мәгариф бүлеге мөдире, элегрәк Сатыш мәктәбендә үзләренә белем биргән Татарстанның атказанган укытучысы Хәйдәр абыйсы Хисанов, кем әйтмешли, бишкуллап каршы ала аны һәм районның республикада дан тоткан, Кави Сәлим улы Байкиев, Фәһим Зыятдин улы Җәләев кебек атаклы педагоглар җитәкли торган җиде йөз балалы Икшермә мәктәбенә тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы итеп билгели. Бирегә яшь укытучыларны «җигә», эшләтә беләләр, әлбәттә. Класс җитәкләү, ачык дәресләр, класстан тыш төрле чаралар үткәрү, кичләрен халыкара темаларга күрше-тирә авылларга җәяүләп барып лекцияләр уку көндәлек шөгыльгә әйләнә. Укытучылар белән спектакльләр дә куялар. Әмма иң мөһиме — тарих дәресләрен җанлы һәм кызыклы итеп, сүз белән сурәт ясап алып бара Шамил.

Шундый гадәти мәшәкатьләр белән тагын ике уку елы үтеп китә. Район читендәге Олы Нырсы урта мәктәбенә класстан тыш тәрбия эшләре буенча директор урынбасары итеп билгелиләр байтак тәҗрибә тупларга өлгергән Шамил Зиннур улын. Монда бер ел гына «канат җәяргә» насыйп була яшь мөгаллимгә. Югары Кибәхуҗа мәктәбен кабул итеп ала ул 1980 елда. Хәер, сәләт-талант дигәнең туксан тугыз процент тырышлыктан гыйбарәт, дип хак әйтәләр. Югары Кибәхуҗа мәктәбендә бу юлларның авторына — КПСС райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге инструкторына да берничә мәртәбә булырга туры килде Шамил Зиннурович директорлык иткән чорда. Бирегә килеп керүгә, күңелне ниндидер җылы тойгы биләп ала иде. Бәлки, моңа биредәге чисталык, тәртип, зәвык белән эшләнгән плакатлар, язмалар да тәэсир иткәндер. Шуңа да мәктәп гел алдынгылар рәтендә булды. Тәрбия бирүнең һәм укыту ысулының шундый актив формаларын каян табып бетергәннәрдер, дип уйланып куясың хәзер дә. Өстәвенә күпме хуҗалык эше күтәеп тора әле. Ел саен мәктәпкә ягу, укытучыларга, хезмәткәрләргә бирү өчен өч йөз кубометр утын да әзерләргә кирәк бит...

Югары Кибәхуҗа яшь директорның гаилә корган авылы буларак та күңелендә саклана. Биредә ул гомерлек тормыш юлдашы Зөлфия белән никахлашты, булачак журналист һәм «Татар радиосы»н алып барып, бөтен мөселман дөньясына танылачак Зөлфәт дөньяга килде. Зиннуровлар гаиләсе, гомумән, сәнгатьне дә бик ярата. Кызлары Алиянең, урта мәктәпне тәмамлагач, укырга Казандагы мәдәният һәм сәнгать университетына керүе дә шуны раслый.

1989 елның 1 марты — Шамил Зиннур улының күңел сәхифәсенә мәңгегә теркәлгән көн. КПСС райкомында алты елга якын инструктор һәм бүлек мөдире урынбасары булып эшләгән педагог район мәгариф бүлеге мөдире итеп билгеләнә. Дөрес, бу зур вазифага тотыну, салкын суга керер алдыннан чирканчык алган кебек, бераз куркытып, уйландырып та куя.

Шулай итеп, ел артыннан ел үтә торгач, Шамил Зиннур улының бу вазифага билгеләнгәненә унбиш ел тула икән инде. Шушы чорда ул әдәп-әхлак төшенчәләрен дөрес аңлап, яшь буынны әлеге кануннар нигезендә тәрбияләүне кыйбласы итеп алды, мәгариф тармагының матди-техник базасын ныгыту буенча җан атып йөри.

Татарстан Мәгариф министрлыгы һәм район хакимияте җитәкчеләре белән уртак тел тапты. Гомуми тырышлык белән соңгы елларда гына да өч урта, дүрт башлангыч мәктәп сафка басты. Сабада 104

нче һөнәр училищесы, балалар бакчасы, Шәмәрдәндә 1000 балага исәпләнгән мәктәп бинасы төзелешләре дәвам иттерелә.

Мәктәпләребезнең яңа төр компьютерлар системасына тоташуы дәресләрне бүгенге көн таләпләренә җавап бирерлек итеп үткәрергә ярдәм итә. Гомумән, республикадагы, мәгариф системасындагы һәр яңалык киң яклау таба. Шәмәрдән урта мәктәбендә профессор В.Габделхаков җитәкчелегендә «Коммуникатив-үстерешле технологияләр кулланып, укучыларның сәләтен үстерү» темасына уздырылган эксперимент нәтиҗәсе дә куанычлы булды. Татар дәүләт гуманитар институты, Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институты хезмәткәрләре катнашында уздырылган региональ фәнни-практик конференция дә мөгаллимнәрнең укыту-тәрбия эшендә җирле материаллар куллану, Саба төбәгенең тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү эшенең дәвамы булды. Район мәгариф системасы 2002 елдан республиканың укытучылар белемен камилләштерү институты җитәкчелегендә «Яңа информацион технологияләр нигезендә белем бирү белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү» дигән тема иҗади проектка тартылды.

Ел укытучысы, иң яхшы тарих, татар теле һәм әдәбияты һәм башка кабинетларга конкурслар үткәрү укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә. «Мәгариф» журналының 1993 һәм 2002 елларда тулаем бер саны сабалыларның эш тәҗрибәсен яктыртуга багышланды.

1999–2002 елларда 27 укучы республика олимпиадасында призлы урыннар алган иде. 2003 елда да бу сафка яңадан 13 бала өстәлде. Аларга һәм район олимпиадаларында җиңүчеләргә, шулай ук укытучыларга район хакимияте башлыгы Рәис Миңнехановның тантаналы төстә акчалата бүләкләр тапшыруы матур гадәткә әйләнде. Мәктәпне алтын һәм көмеш медальгә тәмамлаучылар да, югары һәм махсус уку йортларына кереп, белем дәрәҗәләренең дөрес икәнен раслыйлар. 2003 елда медаль алучылар илле тугызга җитте. Моңа барлык укытучыларның һәм тәрбиячеләрнең район буенча 80 проценты югары белемле булуы да этәргеч ясый. Соңгы елларда спортка, физик тәрбия бирүгә караш уңай якка нык үзгәрде. Мондый мисалларны тагын да тәфсилләп, озак дәвам итеп булыр иде әле. Әмма, язмабыз героеның тыйнак, мактаганда чама белә торган шәхес икәнен истә тотып, фикерне йомгакларга да вакыт җиткәндер. Шамил Зиннур улының хезмәт юлы, әйе, гел ал да гөл түгел. Кайчак керфекләре күтәрә алмаслык көннәре дә булды һәм була аның. Әмма каушап-югалып калмый, аларны сабыр гына, түземлек белән үткәреп җибәрә белә. Тырыш хезмәт эзсез калмый, әлбәттә. Тумыштан коеп куйган югары культуралы мөгаллимгә 1994 елда ук «Татарстан Республикасының атказанган укытучысы» дигән исем бирелде. Башка күптөрле бүләкләргә һәм хөрмәтләргә лаек булды ул.

Әйе, кеше яраткан эше булганда гына бәхетле була. Әңгәмәбезнең ахырында Шамил Зиннур улыннан:

— Сез бәхетлеме? — дип сорадым.

Ул, гадәттәгечә, елмаеп куйды. Бераз уйланып торгач, болай диде:

— Гомерне яңадан башларга туры килсә, барыбер шушы юлны сайлар идем мин...

*2004*

# Нарасыйлар арасында

Кайда син, әни?!
Кайда син, әти?!
Кадерлем, диеп
Кемнәргә әйтим?
Сугышлар да юк,
Нигә мин ятим?

Ятимлек һәм зәгыйфьлек. Бу сүзләрнең берсе генә дә күп нәрсә турында сөйли. Икесе бергә кушылгач, әйтеп бетерә алмый торган ямьсез күренеш хасил була. Әнә шундый ятим һәм зәгыйфь балаларны үз куенына сыендырган интернат-йорт бар районыбызның Югары Утар авылы янында. Анда бер булган кеше икенче барырга атлыгып тормый. Мин, шәхсән үзем, моннан утыз ел элек сугылган идем бирегә. Бөтенләй йөри алмаучылар группасына алып керделәр. Нинди генә гарипләр күрмисең анда: 70–80 сантиметр озынлыгындагы дүрт почмаклы борыс сыман баш (аяк-куллар, гәүдә бөтенләй юк диярлек) гомер буе күз алдымда тора. Илгизәр исемле булган икән ул бала. Икенче бүлмәдә стенадан йөрүче малайны күреп исләр китте. Үз-үзен бөтенләй белештерми торганын читлек шикелле җиргә бикләп куярга мәҗбүр булганнар.

Мондый гыйбрәтле язмышлы кешеләрне адым саен очратасың Югары Утарда. Һәм анда эшләүчеләргә күңелеңнән рәхмәт укыйсың. Ә бит төрле кешеләр бар. Шикаятьләр язылган заманнар да булмады түгел. Шундый хатларның берсе партиянең көчле заманында райкомга килә. Балалар хакын ашыйлар, янәсе. Тикшерергә иң принципиаль инструктор Фәрвәз Нурмөхәммәтова китә. Барганчы ук: «Ашаганнарын чыгарам мин аларның», — дип яный ул. Бара бу, аны да йөри алмаучылар бүлмәсенә алып керәләр, билгеле. Кайта.

— Ничек анда хәлләр? — дип сорыйлар хезмәттәшләре.

Җавап кыска була:

— Үзләре генә ашасыннар да, үзләре генә эшләсеннәр...

Тагын бер шикаятьне «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасына юллыйлар. Ул хат газетаның бүлек мөдире, тарих фәннәре кандидаты Сәмигулла Хәйретдиновка тапшырыла һәм бик нәфрәтләнеп юлга чыга танылган журналист. Соңыннан аның «Яла ягу» дигән күләмле мәкаләсе дөнья күрә. *«Кисәтмичә килдем. Башта сәламәт балалар белән үзем генә сөйләштем. Дөресен әйтим, зарланмадылар алар. Яңа ел кичәләре турында, Кыш бабай күчтәнәчләре хакында сөйләделәр. Ашханәләре тулы ризык. Өс-башлары бөтен.*

*Биредә авыр язмышлы балалар тәрбияләнә икән. Кайберәүләрнең әти-әниләре дә билгесез, чөнки аларны имансыз хатын-кызлар урамда ук ташлап калдырган. Тудыру йортыннан алмыйча качканнары да бар. Зәгыйфь, гарип балаларның хәлен килеп белешмәгән ата-аналар күпме! Ә сабыйлар күзләрен мөлдерәтеп әти-әниләрен көтә. Шушы минутларда интернат-йорт директоры Имаметдин Гәрәев кебек изге җаннар аларга җылы сүз әйтә, тәмле-тәмле ризыклар өләшә, бергәләшеп төсле телевизордан мультфильмнар карый. Күңелле әңгәмә кора, әкиятләр сөйли. Өлкән шәфкать туташы Люция Хәбибуллина, өлкән тәрбияче Флүзә Гатауллина, санитарка Фирая Кәримуллина кебек олы җанлы кешеләр бу балаларның шатлыкларын да, кайгыларын да уртаклашалар, игелекле эшкә дә алар тарта сабыйларны, яшүсмерләрне.*

*Инде килеп, балалар йорты директоры Имаметдин Гәрәев турында берничә сүз. Югарыда телгә алынган хат турында ишеткәч, бик тә борчылды ул. Нахак сүз өчен кәефе кырылды. Әмма хаклык агач-ташта да үскән кебек, гаделлек барыбер табыла. Кемдер яла ягып, абруен төшерергә теләгән икән, район халкы, сабыйларның әлегә югалмаган әти-әниләре аңа бик тә рәхмәтле. Республика, район матбугатында бихисап чыккан язма-бәяләр дә моңа шаһит».*

Әйдәгез, шуларның берничәсе белән танышып үтик. Район газетасында Илфир Салаватуллинның (хәзер ул бу фани дөньяда юк инде. — *Т.Н.*) «Шәфкать» дигән мәкаләсе игътибарны җәлеп итте. *«Ятимлек... Аны беркем дә теләп алмый. Ләкин бар ул һәм шактый әле. Балаларын язмыш кочагына ташлап киткән ата-аналар, кызганычка каршы, бүген дә арабызда йөри. Дөрес, дөньяда төрле хәл булуы бар. Кайбер сәбәпләр аркасында баланың гарип булып тууы да мөмкин. Андыйларны зәгыйфь балалар йортларына урнаштыралар. Шундый интернат районыбызның Югары Утар авылында да бар... Зәгыйфь балаларда ата-анага тартылу көчлерәк тә була кебек. Кайберәүләр кинәт кенә моңсуланып кала. Бу, мөгаен, сагыну, туганнарын күрәсе килү билгеседер. Әйтик, абыйлы-сеңелле Римма һәм Илдар Фәтхетдиновларның әти-әниләре бардыр. Әнисенең Түбән Кама шәһәрендә яшәве дә билгеле. Әлмәт шәһәрендә яшәүче Сафинага биредәге улы Сергейны бер күреп, итәгенә алып сөеп китсә, ни була?*

*Бәхетебезгә каршы, дөньяда әле шәфкатьсезләр генә түгел, игелекле җаннар да бар. Ташлап калдырылган шушы сабыйларны кеше итү өчен алар барысын да эшли. Тәкъдимнәр кенәгәсендәге язуларны да дулкынланмый гына укып булмый. Түбән Кама шәһәреннән килгән бер ханым мондый язу калдырган: «Минем кызым Лариса Сурова биредә җиде ел тәрбияләнә. Монда андый балаларга зур игътибар күрсәтелә. Рәхмәт аларга. Директор Имаметдин Гәрәевичның зур тырышлыгы, чын кеше җанлы булуы сизелеп тора». Бөгелмә шәһәрендә яшәүче Лотфуллинаның зәгыйфь улы Айдар да биредә икән. Ана, монда килеп, иң изге хисләрен, олы рәхмәт сүзләрен тәкъдимнәр китабына язып киткән».*

*«Әйе, монда чын мәгънәсендәге шәфкать ияләре эшли. Күңелләрендә шәфкатьлелек хисе булмаса, атасыз-анасыз, язмыш иркенә ташланган шушы авыру, ярдәмчесез балаларны, инвалидларны тәрбияләү эшенә алыныр идемени алар! Интернатта озак еллар эшләгән Фирая Кәримуллина, Александра Кириллова, Мәрзия Хәмидуллина, Нәфыйга Миңлегалиева, Люция Михайлова, Мөршидә Галиева — әнә шундый киң күңелле, олы җанлы кешеләр»,* — дип яза «Шәһри Казан» газетасының бер санында шагыйрь Рафис Корбан. Аннан ул болай дәвам итә: *«Мин булган көннәрдә интернат балаларын җәйге лагерь шартларында тәрбияләүгә күчергәннәр иде. Бу вакытта аларны күбрәк саф һавада йөртергә тырышалар икән. Кояш һәм һава ванналары алырга өйрәтәләр, яшелчә, җиләк-җимеш, витаминлы азыклар белән тукландыралар. Балаларның сәламәтлеге һәрвакыт күз уңында тотыла...»*

— Билгеле булганча, бездә акылга зәгыйфь һәм гарип сабыйлар, яшүсмерләр тәрбияләнә. Хезмәтебез җиңел түгел, — дип сүзен башлады Россия Федерациясенең атказанган социаль-тәэминат хезмәткәре Имаметдин Гәрәевич. — Соңгы елларда финанс хәлебез начарлану сәбәпле, проблемалар берсе артыннан икенчесе туып тора. Дөрес, элегрәк хәлебез алай начар түгел иде. Бюджеттагы киеренкелек җилләре без буйсына торган Татарстан Республикасының Социаль-тәэминат министрлыгына да гел бәрелеп тора. Авыру балалар өчен өс-баш, ашау ризыклары, дарулар табу кыенлашты. Район үзәгеннән һәм тимер юл станциясеннән шактый ерак, яраклаштырылган биналарны тоту елдан-ел авырая бара. Әмма менә шундый кыен вакытларда безгә спонсорларыбыз, шулай ук райондагы башка төрле хезмәт күрсәтү оешмалары турыдан-туры ярдәм итә. Мәсәлән, иске биналарны ремонтлау эше белән ел саен диярлек Сабадагы 1нче номерлы ремонт-төзү участогы (җитәкчесе Ренат Сөнгатов) шөгыльләнә.

Тагын шунысын да искә төшерү урынлы булыр: Шәмәрдән поселогында интернат өчен 300 урынлы бина төзелә башлаган иде. Билгеле сәбәпләр белән ул да тукталып калды. Шуңа күрә безгә хәзер фай-

далана торган биналарны табигый газга тоташтыру бурычы куелды. Менә шушы бик кирәкле эштә безгә Исмәгыйль Мөхетдинов җитәкчелек итә торган «Сабагаз» идарәсе коллективы бик нык ярдәм итте. Хәзер зәңгәр ягулыктан файдаланган саен, аларга үзебез дә, балалар да рәхмәт укый.

Безнең даими спонсорларыбыз да бар. Ул — «Шәмәрдән ит комбинаты» акционерлык җәмгыяте (директоры Илдар Нигъмәтҗанов). Без бу коллективка һәм анның җитәкчесенә рәхмәтлебез. Беркем дә гарип бала тууын теләми. Ә инде дөньяга килгәч, аны гомере беткәнче яшәтергә кирәк. Гомумән, авырлык килеп туганда, шуларга мөрәҗәгать итәбез. Ремонт өчен кирәкле материалларны да, техникасын да алгалап торабыз. «Шәмәрдән мех комбинаты» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Илшат Гариповның да даими ярдәмен тоеп яшибез. Безнең коллектив аеруча Татарстан Республикасының хәзерге һәм элеккеге социаль-тәэминат министры Клавдия Новикова белән Галина Лоцмановага зур рәхмәтле. Әле шушы арада гына район хакимияте башлыгы Рәхимҗан Хөсәеновка кердем. Ике тонна ак он бирде. Атланмай, башка кирәк-яраклар белән булыша. «Проблема булганда кер», — дип тора.

Безнең 10 гектар җиребез дә бар әле. Менә шуларны эшкәрткәндә, «Победа» колхозы җитәкчеләре ярдәменә таянабыз.

Соңгы елларда төрле мәктәпләрдән килеп, балаларга бүләкләр тапшырып, концерт куялар. Аларны хуҗалык җитәкчеләре автобус белән тәэмин итә. Мәсәлән, Югары Симет, Олы Кибәче, Шекше, Курсабаш, шулай ук Теләче районының Үзәк, Максабаш мәктәпләре килеп изгелек эшләп киттеләр. 1 июнь — Балаларны халыкара яклау көнендә Сабадагы иҗат үзәге коллективы оештырган чара да күңелләребездә озак саклана.

Гарип сабыйларга ярдәм итүчеләр арасында нәзер әйтүчеләр дә юк түгел. Мәсәлән, Лесхоз бистәсеннән Д.Хуҗина мондый эчтәлектәге хат җибәргән иде: «Хөрмәтле тәрбиячеләр! Зәгыйфь балаларны караган өчен Аллаһы Тәгалә сезгә дөньяда сәламәтлек, ахирәттә оҗмахтан урын бирсен. Сезгә 2000 сум акча җибәрәм. Үзем барып йөри алмыйм. Шуны балаларга ашау әйберсе алганда кушсагыз, мин бик тә шат булыр идем».

Әйе, мондый акчаларга көне-сәгате белән тәм-том алынып, балаларга өләшенә. Кыскасы, шушындый болгавыр заманда бездә тәрбияләнә торган сабыйларга һәм яшүсмерләргә шәфкатьлелек күрсәткән өчен барлык коллективларга һәм аерым кешеләргә ничек рәхмәт укымыйсың! Проблемаларыбыз күп. Аларның барысын да язып бетереп булмый. Әмма бердәм булсак, бер-беребезне ташламасак, без аларны уңай хәл итәрбез, — дип фикерен тәмамлады ул.

Әйе, Имаметдин Гәрәевичның сүзен куәтләп тагын шуны өстәр идем. Бер елны Яңа ел алдыннан пакетлар тапшырырга «Шәмәрдән ит комбинаты» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Илдар Нигъмәтҗанов белән бергә төштек.

Бу хәбәр яшен тизлеге белән таралды, йөри алган һәр тәрбияләнүче идарә бинасына йөгерде. Аларның сөенгәннәрен күрсәгез иде! Күптән көткәннәр икән алар бу пакетларны. Әнә кайберләре якын туганнарын күргән кебек кочаклаша, каты итеп кулын кыса директорның, аннары кат-кат: «Спасибо!», «Рәхмәт!» — дигән сүзләр өсте-өстенә әйтелә. Роза дигәне кул сәгате дә сорады әле. Анысы да вәгъдә ителде.

Гомумән, Илдар Фәтхерахман улы, үзе ятимлектә үскәч, аларның хәлен аңлый. Әнә шулай итеп, пакетларны берәм-берәм дүрт яшьтән алып уналты яшькә кадәрге йөздән артык бала алды. Аларны яшь һәм авыру рәвешләре буенча өч төркемгә бүләләр икән. Эчүчелек белән шөгыльләнүче, теләсә ничек йөреп, ирсез килеш бала табучы, «энәдә утыручы» (наркоманнар) хатын-кызлардан туган балалар нинди генә авырулар белән җәфаланмыйлар: церебраль паралич, Даун авыруы, эпилепсия белән изаланучылар, чукраклар һәм телсезләр. Ә инде бөтенләй йөрүдән мәхрүм булучыларга күчтәнәчләрне урын өстенә илтеп бирдек. Аларның сөенгәннәрен күрсәгез!

Матди яктан гына түгел, рухи байлык өчен дә кайгырта «Татарстанның социаль хезмәт күрсәтү отличнигы» исемен дә йөртүче Имаметдин Гәрәй улы. Биредә тәрбияләнүчеләр өчен профессиональ сәнгать осталарының да концертлары оештырыла. Татарстан Республикасының халык артистлары — җырчылар Хәмдүнә Тимергалиева, Рафаэль Ильясов, Фердинанд Сәләхов, Зөһрә Шәрифуллина, нәфис сүз остасы Рәшит Сабиров, танылган музыкантлар Рөстәм Вәлиев, Азат Хәлимов, биюче Гүзәл Вәлиева чыгышлары еш кына зур алкышларга күмелә биредә.

Гомумән, әдәбиятка, сәнгатькә чын күңеленнән мөкиббән киткән кеше ул Имаметдин. Аны Казанның концерт залларында еш күрергә була. Сәнгать сөючеләр, бигрәк тә җырчылар арасында дуслары күп. Ул үзе Кукмара районының Ятмас Дусай дип исемләнгән матур табигатьле авылында туган. Бик ярата Имаметдин үзенең туган җирен. Аның үтенече буенча ике җыр — «Сагындым сине, Дусай» (Рафис Корбан шигыре, Луиза Батыр-Болгари көе) һәм «Дусай җыры» (монысының да сүзләре Рафис Корбанныкы, Илгиз Закиров музыкасы) язылып, Казан радиосыннан бик еш яңгырый.

...Кәккүк моңы, кошлар җыры —
Синең җырың, Дусаем.
Дусаем дип бер җырладым,
Мин — синең бер кошкаең.

Чыннан да, кошларны һәм җәнлекләрне дә бик ярата ул. Интернат-йорт ишегалдына кергәч, тавис (павлин) кебек кошлар, фазан, япон, мисыр тавыклары каршы ала сине. Читлекләрдә ак төлке асрала. Балалар пониларны (кечкенә атлар) бик яраталар. Чын зоопарк диярсең! Җәй көннәрендә якындагы елга-күлләрдә 200–250 ләп каз үстерәләр. Ярдәмче хуҗалыкта башка төр мал-туар да тотыла.

Югары Утар балалар йорты борынгы бинага урнашкан. Биредә заманында Симет урманчылыгы да, мәктәп тә, туберкулез диспансеры да булган. Табигате дә матур аның, урманы да ерак түгел, яшел паркында җәен нарат, каен, топольләрнең ягымлы шаулашулары үзе бер мәһабәтлек өсти, чәчәк клумбалары да күңелләрне иркәли. Халык әкиятләре темасына эшләнгән күренешләр ерактан үзенә тарта. Болар барысы да балаларга үзенә күрә бер тынычлык, сафлык китерәләр.

Әмма... Моннан ятимнәрнең моңлы карашыннан туган әрнү тойгысы алып китәсең. Шулай да: «Хушыгыз, балалар! Моңаймагыз. Сез — ышанычлы кулларда. Гомерләрен сезнең яшәешне тәэмин итүгә багышлаган икенче әтиегез — мөхтәрәм Имаметдин абыегыз җитәкләгән коллектив булганда, төшенкелеккә бирелмәссез», — дип әйтәсе килә.

«Гомер уза аккан сулар кебек» дип юкка гына җырламыйлар икән. Бала җанлы, яхшы күңелле, һәркемгә ярдәм итәргә әзер торучы Имаметдин Гәрәй улы Гәрәев кичергән алты дистә ел гомернең утыз бише бер районда, бер коллективта изгелекләр кыла-кыла үтеп тә киткән. Аңа бирелгән елларның алдагылары да хәерле булсын.

*1999*

# Шигырьле гомер

Зөфәр Гәрәй улы Шәйхетдинов, Тукай әйтмешли, коеп куйган шагыйрь генә түгел, җәмәгать эшлеклесе, көрәшче-коммунист, публицист, фольклорчы, «Яратам мин сине, җирем», «Тургаем», «Ана сүзе» дигән шигырь җыентыклары авторы. Башка халык җәүһәрләрен тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнә.

Сәрдә авылыннан булган әтисеннән, Килдебәктә туып үскән әнисеннән аңа барысы да мул күчкән. Таланты да, романтикасы да, төс-кыяфәте дә, рәвеш-килбәте дә. Шагыйрь болар өчен иң беренче чиратта әти-әнисенә бурычлы. Ул юкка гына «Әти-әниләрне сагынып» дигән шигырендә болай дип язмый:

Әти җырчы һәм гармунчы иде,
Шигырьләрен таптык, ул үлгәч.
Шигырьләре минем җанга күчте,
Тик үзе юк, кайтмый күмелгәч.
Озак тормый әни вафат булды.
(Күптер бездә гөнаһ, гаепләр!)
Әнинең дә көндәлеген таптык —
Эче тулы җырлар, бәетләр...

Кыскасы, аның иҗатында туган телгә, туган илгә, туган җиргә, Ватанга, татар халкына, хезмәткә һәм ата-анага, өлкәннәргә, табигатькә мәхәббәт төп тема булып тора. Зөфәр Шәйхетдинов бер генә шигырен дә бармактан суырып язмый. Чөнки ул тормышның үзен, фәлсәфәсен яхшы белә. 1957 елда, Саба урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казанда «Химэнергострой» трестында балта остасы булып эшли. Үзәк колхоз базарын төзүдә катнаша. Әмма аны ак колонналы Казан дәүләт университеты барыбер үзенә тартып китерә. 1962 елда — практика вакытында — Пермь өлкәсенең Барда районының Карман сигезьеллык мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятын укыта. Шул вакытта, булачак тормыш юлдашы Физия Корбан кызын очратып, укытучылар гаиләсенә нигез салына. Хәзер инде аларның кызлары, уллары, киленнәре — барысы да югары белемле педагоглар.

Университетны тәмамлагач, яшь, энергияле, шигырь җанлы Зөфәр Шәйхетдинов, туган районына кайтып, җирле радиотапшырулар алып бара башлый. Армия сафларында хезмәт итеп кайткач, 1965 елда аны район яшьләре ВЛКСМ райкомының беренче секретаре итеп сайлыйлар. Менә шуннан соң 27 ел буе ул сайланулы органнарда — КПСС райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире, идеология буенча өченче һәм икенче секретарь булып эшли. Шул еллардагы хезмәте өчен В.И.Ленинның тууына 100 ел тулу уңаеннан юбилей медале, Татарстан Югары Советы һәм ВЛКСМ Үзәк Комитеты Мактау грамоталары белән бүләкләнә. Комсомолның XVI съездына делегат итеп сайлана.

Зөфәр Гәрәй улы, райком секретаре буларак, җыелыш трибуналарында, телефон аппаратлары куелган өстәл артында утыручы булып кына калмый, иҗатын дәвам итә. Хәтта аның шигырь язуын өнәмәүчеләр дә була. Мәсәлән, аңа «Ага болыт» дигән шигыре өчен рәсми төстә бәхәскә керергә дә туры килә.

Ага болыт, ага болыт,
Ага болыт тоташтан.
Яңгыр чылбырлары аша
Җир белән күк тоташкан.

Каенда кайгы күлмәге —
Көзләрнең җитүедер.
Үрсәләнеп сыктый йөрәк,
Яшьлекнең үтүедер.
Яшьлектәге олы хыял,
Кая таралып беттең?
Агартам дип бу гавамны
Үзем каралып беттем.
Ява яңгыр, ява яңгыр,
Ява яңгыр тоташтан.
Тагын ниләр үтәр икән
Безнең бу газиз баштан?

Әмма шагыйрь рухын мондый аяк чалулар гына сындыра алмый. Аның меңнән артык шигыре дөнья күрә, ә инде басарга әзерләнгәннәренә килсәк, алары — биш тапкыр артык. Зөфәр Шәйхетдинов җыр өлкәсендә дә актив эшли. Аның сүзләренә Рөстәм Яхин, Сафуан Ибраһимов, Евгения Степанова, Рәисә Имамиева, Сәйдәш Солтанов, Таһир Исмәгыйлев кебек профессиональ һәм үзешчән композиторлар көйләр яздылар. Ул җырларның күбесе халык тарафыннан җылы кабул ителде.

Гомумән, Зөфәр Шәйхетдинов тормышның үзенә, фәлсәфәсенә тирән үтеп кереп яза. Чын каләм иясе буларак, күңелендәге барлык хәлләрне бәян итү белән бергә илдә, дөньяда барган вакыйгаларга битараф кала алмый, аларга үткен итеп мөнәсәбәтен белдерә бара.

*2000*

# Шәхси архивка күчкән хат

*«Азат хатын» журналы редакторы хөрмәтле Л.Ихсановага*

Мин, Саба авылында яшәүче хезмәт ветераны, персональ пенсионер Хәмит Хуҗиәхмәтов, сезгә бер үтенеч белән мөрәҗәгать итәм. Үзем, озак еллар район үзәгендәге Карл Маркс исемендәге колхозда (хәзер «Агрохимсервис» акционерлык җәмгыятенең «Урта Саба» ярдәмче хуҗалыгы. — *Ред.*) рәис булып эшләп, лаеклы ялга киттем. Хәзер 76 яшемдә. Менә шушы дәвер эчендә безнең колхозга һәрьяклап ярдәм итеп килгән хезмәт ияләре депутатлары район Советы башкарма комитетының план комиссиясе рәисе Тәскирә Вәлиевна Ситдикова турында журналыбызда эчтәлекле язма басылып чыгуын телим мин. Ул безнең районга килеп ВЛКСМ райкомы секретаре булып эшли башлаганда, сугыштан соң хуҗалыкны торгызу бурычлары бик авырдан үтәлә иде. Иген уңышы начар, терлекчелек таркау хәлдә. Мин шушы кыен чорда, ярдәм сорап, район комсомол оешмасына мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булдым. Моның нәтиҗәсе озак көттермәде. Тәскирә Вәлиевна, барлык бюро әгъзаларын җыйнап, колхозны шефка алу һәм комсомол-яшьләр фермасы төзү турында карар кабул ителүенә иреште. Бюро әгъзалары Нурзидә Рәхимова, Халисә Шәяхмәтова сыер савучы булып фермага килделәр. Урта мәктәпне тәмамлап авылда калган Нәсимә Ибраһимова, Анфиса Хәкимова... — барысы сигез кыз — коллективның үзәген тәшкил итте. Ә Тәскирә Вәлиевна эшнең барышы белән көн дә кызыксынып торды. Терлек азыгы чәчеләчәк мәйданнарның уңдырышлылыгын күтәрү максатында, комсомол-яшьләр, укучылар өмәләрен секретарь турыдан-туры үзе оештыра иде. Колхозда нәселле куян фермасы булдыру да аның инициативасы белән эшләнде.

Көннәрен төгәл хәтерләмим, бер елны КПСС райкомы карары белән безнең хуҗалык җәйләвендә семинар оештырылды. Анда Казан авыл хуҗалыгы институтының тәҗрибә-житештерү хуҗалыгы белгечләре дә катнашты. Куандырганы шул: эшебезгә уңай бәя бирелде. Соңыннан хезмәт нәтиҗәләренә йомгак ясалгач, комсомол-яшьләр фермабыз районда беренче урынга чыкты. Коллективка районның күчмә Кызыл Байрагы, терлекчеләргә кыйммәтле бүләкләр тапшырылды, ә инде 1959–1960 елларда унике сыер савучыбыз республика күләмендә алдынгылар дәрәҗәсенә күтәрелделәр. Мөнәвәрә Ярмиева Татарстан Югары Советы депутаты, ә Зөһрә Әкбәрова белән Фатыйма Гарипова район советы депутатлары итеп сайланды.

1960 елда фермада сыер саву, су бирү, азык эшкәртү тулысынча механикалаштырылды. Тораклар төзелде, нәсел эше нык яхшырды. Күрше колхозларга 28 баш тана, 10 баш үгез, нәселле яшь үрчем сатып бирелде.

Хуҗалыкның алга китешендә Тәскирә Вәлиевнаның булышлыгы, кайгыртучанлыгы әйтеп бетергесез зур булды.

Т.Ситдикова хезмәт баскычлары буенча югарырак күтәрелгәч тә, тынгысыз, барысына да өлгерүчән житәкче булып калды. Аңа йөкләнгән җәмәгать эшләрен санап бетергесез. Шулар өстенә без, йомышы төшкән ветераннар-пенсионерлар да, Тәскирә Вәлиевнага мөрәҗәгать итәбез. Ул һәр кешене якты йөзе,

тәмле теле белән каршы ала белә. Үтенечеңне канәгатьләндерү өчен мөмкин булганның барысын да үзең барында ук хәл итә, яхшы киңәшләр бирә. Без, сабалылар, Тәскирә Вәлиевнаның киләчәктә дә эшендә һәм тормышында зур уңышларга ирешеп, сау-сәламәт яшәвен телибез.

*Хәмит Хуҗиәхмәтов*
*Саба авылы*
*10 гыйнвар, 1980*

ХАЛЫК ИХТИРАМЫНА ЛАЕК

Әлеге хатның язылганына инде 18 ел үтсә дә, Хәмит аганың кулына каләм алырга мәҗбүр иткән кешенең олы хезмәтен бәяли белүчеләр, аңа тирән ихтирам һәм хөрмәт белән караучылар бүген дә шактый. Аның тормыш юлы өчен «пенсиягә китте дә онытылды» дигән гыйбарә кабул ителә алмый торгандыр. Чын мәгънәсендә халык ихтирамына лаеклы шәхес ул Тәскирә Вәлиевна. *«Аның турында китап язарлык,* — дип башлап киткән редакциягә китергән хатын Сабада яшәүче Хәмит Хуҗин. — *Тәскирә Вәлиевнаның хезмәт урынында ул заманнарда ир-ат та чыдамас иде, мөгаен. Район план комиссиясе рәисе булып эшләгәндә, Министрлар Советының ничә бүлмәсе булса, шул ишекләрне икешәр-өчәр тапкыр ачып керә иде ул. Аның ярты юлда туктап кала торганнардан түгел икәнлеген белеп торалар. Шуңа да министр урынбасарларына «Резервтан фәлән кадәр агач, күмер, он һәм башкаларны бүләргә рөхсәт итәргә» дигән әмер бирелә. Т.Ситдикова, күңелендә җылы тоеп, кайтыр юлга чыга. Иртәгесен аның үзенә хуҗалык-учреждение җитәкчеләре, мең төрле үтенеч белән район кешеләре килә. Көн саен диярлек шулай. Берсен дә кире борып чыгармады. Ятим карчыкларның кулына кәгазь (наряд) тоттырып кына кайтармады ул. «Бар кайт, атна эчендә утын ишегалдында булыр», — дия иде бик авыр тормышлыларга. Аннары үзе телефон трубкасына үрелер. Тормыш бит — кемдә кем кайгысы?! Шуңа күрә Тәскирә Вәлиевнаның характерын күрсәтергә туры килгән вакытлары аз булмады. Әмма дә ләкин сүзендә торды. Атна узамы-юкмы — теге ятимә карчык ягулыклы була, хәер-дога кыла-кыла рәхмәт укый...*

*Хәзер Тәскирә Вәлиевна пенсиядә. Аны күпләр хөрмәт итә, озын гомер, сәламәтлек тели».*

Әйе, ул 1989 елдан лаеклы ялда. Аннан соң да өч ел Шәмәрдән поселок советы рәисе урынбасары булып эшләде ул. 30 елга якын гаять җаваплы һәм четерекле хезмәттә халык депутатлары район советы башкарма комитетының план комиссиясе рәисе итеп сайланды. Бер үк вакытта башкарма комитет рәисе урынбасары вазифаларын да башкарды. Җәмгыяви-мәдәни объектлар төзелеше, матди-техник тәэмин итү, халык куллану товарлары җитештерү, сәүдә, түләүле хезмәт күрсәтү, фондлардан дөрес файдалану мәсьәләләре белән шөгыльләнде, кураторлык итте.

Аңа йөкләнгән җәмәгать эшләрен санап бетермәслек иде. 1962 елдан район хатын-кызлар советы рәисе булып торды, бу юнәлештә зур тәрбия эше алып барды. Бөтенроссия табигатьне саклау җәмгыятенең район советын җитәкләде. Депутат буларак (1958 елдан сайлана башлый) сайлаучылар белән даими элемтә тотты, аларның наказларын үтәүгә зур көч куйды.

Тәскирә Вәлиевнаның совет органнарындагы нәтиҗәле эшчәнлеге «Хезмәттәге батырлык өчен» медале һәм Хөкүмәтнең башка бүләкләре белән бәяләнде. 1986 елда аңа «Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирелде.

Хезмәтен 1948 елда Шәмәрдән урманчылыгында гади эшче булып башлаган Тәскирә Вәлиевна әнә шулай күпләрне сокландырырлык матур тормыш юлы үтте. Пенсиягә киткәч тә, тынгысыз җан булып калды ул: Шәмәрдән бистәсендә җәмәгать эшенә зур активлык белән алынды.

Тәскирә Вәли кызы Ситдикова шушы көннәрдә туган көнен — 65 яшь тулуын билгеләп үтте. Бу датага аның Гафиулла Кадыйр улы белән бергә тормыш корып яши башлауларына 35 ел тулу куанычы да килеп өстәлде. Җәй көне аңа да 65 тула. Гафиулла Кадыйрович та гомер буе диярлек район авыл хуҗалыгы идарәсендә кадрлар буенча өлкән белгеч булып эшләде. Гадел хезмәте өчен «Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исемгә лаек булды. Алар хәзер икесе дә, дәүләт хезмәткәрләре пенсиясен алып, тыныч гомер кичерәләр. Казан шифаханәләрендә эшләүче кызлары — югары белемле табибәләр — Лилия белән Дәлиләнең игелекләрен күрәләр.

Гомумән, эше-хезмәте белән халык ихтирамын яулаган кешенең яшәешендә һәр көн куанычлыдыр ул. Хатын-кызларның язгы бәйрәме уңаеннан Тәскирә Вәли кызына карата әнә шундый теләктә калабыз.

*1998*

# Үзе яккан учакка чакырып

Нурислам Насыйбуллин яшь вакыттан ук гармун телләреннән теләсә нинди җырның көен сайрату тылсымына ия егетләрнең берсе була. Күп кызлар соклана аның бармаклары җитезлегенә. Кичке уеннар, килен төшерүләр дисеңме, туйлармы — гармунчының урыны түрдә. Алай гына да түгел, бер елны алдынгыларның район слеты сәхнәсендә Нурислам Фәтхелисламович тальян гармуны белән күренүгә, зал көчле алкышларга күмелгән иде. Әле күптән түгел сугыш вакытында тракторда эшләгән хатын-кызлар катнашында узган «Шинельсез солдатлар» дип исемләнгән кичәдә үзенең моңлы итеп уйнавы белән ак яулыклы, чал чәчле әбиләрнең нечкә хисләрен тибрәтә-тибрәтә, күпне күргән күзләрен яшьләндереп, күңел дәрьяларын кубарды...

Әйе, бер шагыйрь:

Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул чакта —
Башкаларны чакырганда
Үзе яккан учакка, —

дигән сорау куеп, җавабын үзе биргән.

Нурислам Фәтхелисламович — гомере буе үзе яккан учакка чакыручы олы шәхесләрнең берсе. Сүзебезне газиз татар моңының чишмә башы булган тальян гармуннан башлаганбыз икән, язмабыз героеның бу хактагы фикерен белик әле.

— Моның өчен без, балалар, барыбыз да әтигә рәхмәтле. Үзе гади крестьян булса да, аңлы фикерле кеше иде ул. Авыр туфрагы җиңел булсын. Барыгызны да укытам, кеше итәм, гармунчы итәм, диде ул. Бүгенгедәй хәтердә: мин беренче класста укыганда, якташыбыз Фатих Хөсни әсәрләрендә киң урын алган Теләче базарына барып, 65 сумга бозауны саттык, шуның 28 тәңкәсенә гармун алдык, — дип сөйләп китте ул. — Гомумән, форсаттан файдаланып, мин бүген рәхмәтемне әти-әнием белән бергә укытучым Өммегөлсем апага, Баландыш һәм Олы Нырсы мәктәпләре директорлары Мәхмүт абый Гасыймов белән Григорий Сергеевич Ильинга, математика фәненә мәхәббәт уяткан Николай Емельянович Федоровка, класс җитәкчебез Венера Һадиевна Галиәкбәровага, гомумән, безне тәрбияләгән пионер, комсомол оешмаларына әйтәм...

Нурислам Фәтхелислам улы матур табигатьле Урта Мишә авылында (хәзер Теләче районына керә) апасы Розадан соң, гаиләдә көтеп алынган ир бала буларак, куаныч-шатлыклар белән дөньяга килә. Кечкенәдән үк үткен, тапкыр, шаян булып үсә. Ул башлангычта укыганда, мәктәп мөдире булып әнисенең бертуган энесе Ислам абыйсы (ул соңыннан озак еллар Ленин исемендәге колхозны һәм райондагы зур тәҗрибә-тикшеренү хуҗалыгын җитәкләде) эшли. Беренче класста вакытта ук мәктәптән кайта да әбисенә: «Бүген ронодан инспекторлар килгән, Ислам абый каз пешерергә кушты», — ди. Каз пешә, шәп табын әзерләнә. Соңыннан моның 1 апрель — алдау көне шаяртуы икәне ачыклана.

Нурислам кечкенәдән үк: «Тырышып укырга кирәк миңа! Бернигә дә карамастан, фәкать укырга, тормышның олы юлына чыгарга кирәк», — дигән сүзләрне еш кабатлый һәм яшүсмер чакта эчкән антына тугрылыклы кала. Баландыш җидееллык, Олы Нырсы урта мәктәпләрен гел бишкә тәмамлый. Җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Отряд, дружина советлары рәисе, мәктәпнең комсомол оешмасы секретаре була, Казан дәүләт педагогия институтының физика-математика факультетына кергәч, югары уку йортының комсомол комитеты әгъзасы итеп сайлана. Җиде балалы гаиләнең тормышы җиңел булмый, әлбәттә. Җитмәсә әле, аларга урта мәктәптә укыган өчен елына 150 сум түли торган чор туры килә. Һәм зур бәла — урак өстендә, өйләре, каралты-куралары янып бетеп, урамда калалар...

Җәмәгать эшендә актив катнашкан егетне, урта мәктәпне тәмамлауга, ВЛКСМ райкомының ул вакыттагы беренче секретаре Госман Гарипов аппаратка эшкә чакыра. Бирегә килә ул, әмма соңрак... диплом алып, бераз укытучы, аннары Мәртен җидееллык мәктәбе директоры булып эшләп, тәҗрибә туплагач. Аны Саба колхоз-совхоз производство идарәсенең район комсомол комитеты секретаре урынбасары, аннары беренче секретарь итеп сайлыйлар. Еллар үтә тора. Педагог кешене барыбер мәктәп тарта. Шуннан соң ул, үзе сорап, Теләче мәктәбенә эшкә күчә, башта урынбасар, аннары директор була. 1968–1984 елларда, ягъни уналты ел, райондагы иң зур педагогик коллективны — Саба урта мәктәбен җитәкли. Укыту-тәрбия, хуҗалык эшләре комплекслы алып барыла. Яңа бина төзелә, район үзәгендә табигый газ да иң беренче булып мәктәп котельныена 1981 елда ук кертелә. Н.Насыйбуллинның фидакарь хезмәте эзсез калмый, билгеле. Аңа «Татарстанның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирелә.

Менә 2000 ел — XX гасырны йомгаклау елы бара. Нурислам Фәтхелисламовичның уналты еллык Саба мәктәбе директоры стажына тагын уналты — совет һәм хакимият органнарында эшләү чоры өстәлде. Бу җаваплы тармакларда — халык депутатларының район советы рәисе урынбасары, район хакимияте башлыгының беренче урынбасары булып эшләгәндә, аның киң эрудицияле, оста оештыручы булуы күп тапкырлар расланды.

Нинди генә проблемаларны хәл итәргә туры килмәгәндер бу елларда: мәгариф, мәдәният, медицина учреждениеләре, юллар төзү, газ кертү, мәчетләр салу, халыкның социаль хәлен яхшырту, матбугатка

яздыруны һәм таратуны оештыру, центнерлар һәм килограммнар белән исәпләп булмый торган тәрбия мәсьәләләре...

Торак пунктларның чисталыгын, экологик хәлен яхшырту максатыннан үткәрелгән «Авыл көннәре» уздыру тәҗрибәсе республика күләмендә дә киң яклау тапты.

Без, журналистлар, тормышыгыздагы берничә күңелсез һәм куанычлы вакыйганы искә төшерегез әле, дигән сорауны еш бирәбез. Моңа язмабыз герое болай диде:

— Күп инде алар. Башта күңелсезрәкләреннән башлыйк.

1956 ел. Олы Нырсы урта мәктәбенең тугызынчы классын-да укыйм. Авыллар арасы — егерме километр. Комсомол оешмасы секретаре булгач, иптәшләрем белән шимбә көнне кайта алмадым. Якшәмбе көнне берүзем авылга таба атлыйм. Үрнәктән (хәзер ул авыл юк инде) Баландышка таба борылгач, каршыга бүре чыкты. Күзгә-күз байтак карашып тордык. Тимәде. Шулай да арттан шактый озак барды.

Икенчесе 1979 елда булды. Салкынның котырынган көннәре. Мәктәпнең күмер яга торган алты пар казанының бишесе сафтан чыкты. Берсе белән җылылык системасын саклап калдык.

1985 елның кышы һич истән чыкмый. Яңа ел алдыннан башта көчле буран котырып, машиналар кар астында калды. Ярминкәдән кайтучы Баландыш кибетчесе адашып (өшеп) үлде. 1995 елның 31 декабрендә күп катлы йортларда яшәүчеләргә җылылык бирә торган үзәк котельные сафтан чыкты.

Яңа ел кичен хакимият башлыгы Фәрит Гыйльмиевич, бу тармакка җаваплы башка шактый җитәкчеләр, эшче-хезмәткәрләр белән бергә котельныйда уздырдык.

— Нурислам Фәтхелисламович, болары җитеп торсын. Кызыклырак вакыйгалар бармы соң?

— Кызыклырагымы? — дип сорап куйды ул. — Шул каз вакыйгасы да инде. Институтта укыганда, чаңгы трассасын бераз кисеп, беренчелекне алган идем...

Әйе, матур итеп эшли, яши белгән гаиләдә куанычлы вакыйгалар еш булып тора. Нурислам Фәтхелисламович белән утыз биш ел гомер кичерүче тыйнак, югары культуралы ветеран укытучы Суфия Гыйлемхан кызы да зур хәрефләр белән язарлык КЕШЕ. Болай дигәндә, мин аларның эчке матурлыкларын да, тышкы күркәмлекләрен дә күз алдында тотам.

Кызлары Эльвира белән Элеонора да мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, берсе — табибә, икенчесе икътисадчы булдылар. Кияүләре дә уңган. Олысы Рамазан — Саба үзәк шифаханәсе баш табибы урынбасары, Илнур — Казан финанс институтының баш бухгалтеры. Хәзер законлы әби белән бабай оныклары Дилә белән Искәндәргә һәм Динәгә ата-бабалардан килә торган әйбәт гадәтләрне өйрәтәләр. «Баланыкы балдан татлы» дигән гыйбарә бик дөрес икән, диләр алар, нәселне дәвам итүче бәгырь җимешләренә карап.

Якын туган-тумачалар җыелган табын түрендә сиксән ике яшьлек Мәргубә әбинең утыруына бик күпләр сөенә. Шөкер, Ходай Тәгалә аңа озын гомер биреп, Нурислам улының алтмыш яшьлек тантанасын күрергә насыйп иткән.

Бу көннәрдә юбилярга газиз әнисе белән бергә иң якыннары, хезмәттәшләре, дуслары, укучылары, гомумән, игелеге тигән бик күп кешеләр рәхмәт хисләрен җиткерделәр.

*2000*

# Фирүзә төсендәге шатлык

Миңа, журналист буларак, Шәмәрдәндәге магистраль газүткәргечләрнең линия-производство идарәсендә оешкан көннәреннән бирле бик күп тантанада катнашырга туры килде. 2004 елда биредә ике катлы заманча бинада химия һәм метрология лабораториясе һәм медицина-санитария бүлеге ачылды. Бу 650 кеше эшли торган коллектив өчен бик әһәмиятле объект иде. Аның беренчесендә куәтле турбиналар тикшерелсә, икенчесендә халык сәламәтлеге өчен көрәшәләр. Шул ук көнне 80 фатир файдалануга бирелеп, чират мәсьәләсенә нокта куелды. Салынып беткән тагын ике йортлары булуы турында (берсе — 8, икенчесе 16 фатирлы) әйтеп, халыкны тагын бер мәртәбә куандырдылар төзүчеләр.

2005 елның июль аенда заманча итеп реконструкцияләнгән бинада, русча итеп әйтсәк, «Огонек» дип исемләнгән кафе-бар һәм магазин-кафетерий комплексы файдалануга бирелде. Әлеге тантаналарда җаваплылыгы чикләнгән «Таттрансгаз» җәмгыятенең генераль директоры, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Рәфкать Кантюков, район хакимияте башлыгы Рәис Миңнеханов катнашып, җиде меңгә якын кеше яши торган Шәмәрдәндә юбилейлар, туйлар, башка төрле гаилә бәйрәмнәре үткәрә алырлык комплекс барлыкка килү шатлыгы белән уртаклаштылар...

Ә инде үткән тарихыбызга күз салсак, узган гасырның 70–80 нче елларында СССРдагы газ тармагында иң зур төзелешләрнең берсе алып барылды Саба җирендә. Биредән газүткәргечләренең 8 линиясе салынды. Аларның алтысының торбалары — 1420, икесе 1220 миллиметрлы (диаметры) булуын искәртсәк, әлеге магистральләр аша ел буе миллиардлаган кубометр Себердән килгән табигый ягулыкның

Россия регионнарына, якын һәм ерак чит илләргә куылуын чамалап буладыр.

Бу коллектив өчен тагын бер истәлекле вакыйга булды. Идарәнең «ветеран» корылмасына — 4 нче компрессор станциясенә — утыз ел тулды. Ул, хәзерге линия-производство идарәсенең башлангычы буларак, тарих сәхифәсенә алтын хәрефләр белән язылды. Заманында әлеге предприятиегә Кызыл Байрак тапшырылып, Бөтенсоюз хезмәт даны елъязмасына кертелде, «Газ сәнәгате министрлыгының иң яхшы компрессор станциясе» дигән мактаулы исем бирелде.

Зәңгәр ягулык кудыра торган мондагы 1 нче номерлы агрегатның «НК-12 СТ» авиация двигателе, 500–1000 сәгать урынына 15599 сәгать эшләп, илебездә рекорд куйды.

Аннары белгечләр турбиналарның 30000 сәгатькә кадәр (тора-бара 43000 гә якынлашканнары да була) эшли алу мөмкинлеген расладылар. Тагын шунысы куанычлы: шушы 30 елдан артык вакыт эчендә мәҗбүри рәвештә туктап торуга (простой) юл куелмады. 1995 еллар башыннан цехларны яңарту эше башланып, биш цех тулысынча реконструкцияләнде һәм автоматлаштырылды, яңа буын техникасы куелды. Хәзер тагын бер цехны яңарту һәм Ленинградта эшләнгән өч турбинаны алмаштыру бурычы тора. Эксплуатация вакытында газүткәргечләрнең линия өлешенә дә даими игътибар бирелә. Шул максаттан «Ямбург — Елец-1», «Ямбург — Елец-2» магистральләрендә дефектоскопия үткәрелеп, искерә башлаган торбаларга яңа сулыш бирелде. Гомумән, идарәдә магистраль газүткәргечләрне техник эксплуатацияләү кагыйдәләре төгәл үтәлә.

Коллективның уртак уңышларында «Таттрансгаз»га кергән «Газпром» системасындагы иң эре предприятиене, утыз елдан артык җитәкләүче, Газ сәнәгате отличнигы, Хезмәт ветераны, озак еллар депутат булган Ришат Нурисламовның саллы өлеше бәхәссез, билгеле. Ул табигать зур яңарыш кичерә торган яз аенда — апрельдә дөньяга килгән. Хәзер әңгәмәбезне аның белән дәвам итик.

— Мөгаен, сүзне шул апрельдән башларга кирәктер дә, — диде Ришат Габделиксан улы. — Шул айның унынчы көнендә туганмын, 1974 елның 8 апрелендә Шәмәрдәндәге газ-компрессор станциясе җитәкчесе итеп билгеләндем. Әфганстаннан кайтып (аларның Апрель революцияләреннән соң), биредә кабат начальник булып яңадан шул ук апрель аенда эшли башладым. Идарә итеп үзгәртелүебез дә шул айга туры килде.

Әнә шулай гади итеп, тиз генә санап чыкты ул үзенең ярты гасырдан арткан тормыш юлын. Әмма бер урында озак еллар җитәкче булып эшләгән чорда күңелендә уелып калган мизгелләр күп була, әлбәттә. Шуларга бераз тукталыйк әле.

...Сабый, акыл җыеп, тирә-юньне таный башлагач, үзенең матур табигатьле Югары Манчар авылында (Башкортстанның Илеш районы) укытучы Хәмидә белән нефтьче Габделиксан гаиләсендә туганын чамалап ала. Дөрес, бабасы чыгышы белән урта хәлле крестьян икән. Әтисе, ун баланың икенчесе булып туганлыктан, бик яшьли авырлыкларны үз җилкәсендә күтәрә башлый. Балачакта ук ат башы тотып йөргәндә, сука астында калып, нык гарипләнә. Шуңа күрә сугышка да алмыйлар үзен. Аның каравы дәһшәтле елларда колхоз рәисе «камытын» кияргә туры килә. Әлмәндәр карт әйтмешли, бер-берсе ун мимечкә торырлык тол хатыннар белән җитәкчелек итә.

«Кара алтын» табылгач, «Чакмагышнефть»кә күчә, шунда эшләп, мастер дәрәҗәсендә пенсиягә чыга. Ә инде мәктәптә укыганда ук әтисе эшен дәвам итәргә хыялланган Ришат, шул чордагы иң популяр һөнәрне алу өчен, Уфа нефть институтына бер талпынуда барып керә. Мәктәптә төпле, нигезле белем алуда озак еллар буе балалар укыткан, авыл советы башкарма комитеты рәисе дә булып эшләгән әнисенең йогынтысы зур була, билгеле.

Яшьлекнең иң матур елларында, гыйлем эстәп йөргәндә, үз районнарының Югары Яркәй авылы кызы — медицина институтында укучы Гөлзифаны очратасын белми әле Нурисламов.

Илеш районының төрле институтларда белем алучы студентлары, елга бер мәртәбә җыйналып, фотога төшә торган булалар. Менә җәйге матур бер көндә Гөлзифа исемле кыз белән таныша да инде ул. Һәм шул мизгелдән аларның күңел дәфтәрләренә «Ришат + Гөлзифа» дигән ике исем беркетелә. Ләкин, бер түбә астында ныклап яши башлаганчы, аларга да шактый уңайсызлыклар кичерергә туры килә. Гөлзифаны ординатурада калдыралар, Ришатны юллама буенча Ухта («Севергазпром») шәһәренә җибәрәләр.

Аннары икесе бергәләп җәһәннәмгә — тимер юлдан 70 чакрым читтә булган Вологда өлкәсендәге Нюксеница дигән район үзәгенә китәләр. Шунда ике ел эшләгәннән соң, Гөлзифага хезмәт урыны булмау сәбәпле, Мари Республикасындагы Помары газ-компрессор станциясенә күчерелә болар.

Смена инженеры вазифасын үтәп йөргән Ришат Нурисламовны беркөнне җитәкчелеккә чакырып:

— Син татарча шәп беләсең бит, әйдә, Татарстанның Шәмәрдән дигән җирендә компрессор станцияләре төзелә, шунда начальник булып бар, — диләр.

— Шулай итеп, 1975 елның язында мине «МИ-2» вертолеты белән китереп аттылар, — ди Ришат, чирек гасыр элек булган хәлләрне күз алдына китереп.

Бу вакытта әле станцияләр булачак җирдә язгы пычрак белән тулган тирән-тирән чокырлар гына була, ә поселок урынында урман үсеп утыра. Киеренке хезмәт чоры башлана егерме биш яшьлек начальникның. Тиз арада «Нижняя Тура—Пермь—Горький—Үзәк газүткәргече»нең беренче чираты эш-

ләтелә башлый. 1976 елның 8 гыйнварында станциянең беренче, тагын унике көннән икенче агрегаты хәрәкәткә китерелә. Ә февраль аенда өченчесе җиһазланып бетә.

1974 елда станция булачак урында «Камгэсэнергострой» берләшмәсенең «УС-ТЭС-2» участогы коллективы эш башлап җибәрсә, 1977 елда мәйданда станциянең икенче чиратын һәм социаль объектлар төзергә тиешле «Татнефтестрой»ның 7 нче тресты генподрядчылары пәйда була. Төзүчеләр белән кулга-кул тотынып эшләп, яшь коллектив яңадан-яңа җиңүләр яулый.

1979 елда Гөлзифа һәм Ришат Нурисламовлар Әфганстанга — гаилә башлыгы газ эшкәртү заводына, хуҗабикә табибә буларак эшкә җибәрелә.

Чит илләрдә төрле гыйбрәтләр күреп, булганына шөкер итеп, яңадан Саба якларына әйләнеп кайта алар. КПСС райкомының шул чордагы беренче секретаре Әләметдин Җамалетдин улы Камалов Ришат Габделиксановичны: «Сез югында тәртип бераз чуалды анда. Әйдә, үзең оештырган коллективны кире кабул ит!» — дип каршы ала.

Сиксәненче елларның башы газ промышленностенда эшләүчеләр өчен «Уренгой—Помары—Ужгород экспорт газүткәргече»н салу буенча башланган гасыр төзелеше белән истәлекле булды. 4451 километр озынлыгындагы трансконтиненталь магистральне төзүдә 50 комплекслы технологик агым катнашты, «Миннефтегазстрой»ның 38 трестыннан егерме биш меңләп төзүче эшләде. Иң зур агымга Социалистик Хезмәт Герое Илсур Шәйхетдинов җитәкчелек итте. Бер үк вакытта 40 урында газ кудыру станцияләре төзелешләре алып барылды. Шуларның берсе — ГКС-21 «Арская» дип йөртелгәне Шәмәрдәндә 1984 елда файдалануга бирелде. Төгәлрәк итеп әйткәндә, тәүлегенә 50 миллион кубометр газ кудыруга сәләтле ГТН-25-76 тибындагы өр-яңа өченче буын агрегатның беренчесе сигезенче февральдә, икенчесе алтынчы мартта, өченчесе апрель аенда эшли башлады. Магистраль газүткәргечләрнең Шәмәрдән линия-производство идарәсе итеп үзгәртелүе беренче чиратта шушы станцияләр белән бәйле дә иде. Аның составына дүрт коллектив ГКС-4, ГКС-21 «Арская» станцияләре һәм линиягә хезмәт күрсәтүче элемтәчеләр, техникалар керде. 1982 елдан Шәмәрдәндә оешкан «Казаньхимстрой» трестының 2 нче механикалаштырылган күчмә колоннасы ныклап торып социаль объектлар төзүгә кереште.

Озакламыйча бистә кырыенда «Шәмәрдән-2» дип атала торган яңа микрорайон барлыкка килә. Идарә итү үзгәртелгәч, эшнең колачы киңәя, яңа үрләр яулана. 1993 ел йомгаклары буенча 4 нче газ кудыру станциясенә Газ сәнәгате министрлыгы һәм нефть промышленносте хезмәткәрләре профсоюзы үзәк комитеты карары белән «Иң яхшы служба» дигән исем бирелү дә моны ачык раслый.

Хезмәт коллективының да, аның җитәкчесенең дә башкарган эшләрен яктырткан тарих сәхифәләре байый бара. Соңгы елларда «Таттрансгаз» җәмгыятенә кергән Шәмәрдән линия-производство идарәсе киләчәккә зур өметләр белән яши. Төп база хәзер бер шәһәрчекне хәтерләтә. Һәркайда чисталык күзгә ташлана. Юлларга асфальт түшәлгән, биналар төзек, җәен биләмәдә яшеллек, җимеш агачлары, чәчәкләр... Зур капитал салулар белән беррәттән планлы реконструкция эшләре алып барыла. Социаль мәсьәләләр хәл ителә. Бер-бер артлы күпфатирлы йортлар файдалануга бирелә. Ике котельныйның сафка басуы торак биналарда тиешле температура режимын сакларга ярдәм итә. 1999 елда файдалануга бирелгән административ бина эчтән дә, тыштан да күз явын алырлык. Медсанчасть, химчистка, кибет, ашханә, лаборатория эшләп тора. Кешеләрнең сәламәтлеге кайгыртыла. Эшче хезмәткәрләребез гаиләләре белән Татарстандагы, Россиядәге санаторийларда гына түгел, чит илләрдә дә ял итәләр. Геленджикта, Сочида, Болгариядә, Васильевода балалар сәламәтлеген ныгыталар. Кыскасы, халык эшли дә, ял да итә белә. Бик күпләр спорт белән шөгыльләнә, үзешчән сәнгатьтә катнаша. Фольклор ансамбле Геленджикта узган корпоратив фестивальдә уңышлы чыгыш ясап, идарә музее III дәрәҗәдәге Диплом белән тулыланды.

Гомумән, кеше кадерен беләләр биредә. Мәсәлән, предприятиенең тарихи елъязмасы булдырылып, газ-компрессор станциясенә нигез салынган көннән эшләүчеләрнең исем-фамилияләре шул җыентыкка кертелде. Физика һәм математика фәннәреннән олимпиадаларда җиңүче өч укучыга идарәнең ел да үз «Гран-при»лары бирелүе матур гадәткә әйләнде.

Коллектив шулай ук, үзешчән сәнгатьтә халык традицияләрен саклауга лаеклы өлеш керткән өчен, «Газпром» җәмгыяте тармакара профсоюз оешмасының призына лаек булды. Идарәнең мини-футбол, волейбол, чаңгы спорты командалары районда иң яхшылардан санала.

Әлбәттә, зур коллективның проблемалары да олы.

— Эшләнгәне күп, билгеле. Башкарасы да җитәрлек, — ди Ришат Нурисламов. — Җитәкчелек чылбырының кайбер буыннарында мөмкинлекләрне файдаланып бетермәгән вакытлар да булмады түгел. Болары поселоктагы социаль мәсьәләләргә кагыла. Бик истәлекле вакыйгаларның берсе — Татарстан халык депутаты булып сайланган һәм эшләгән елларым булды. 234 нче Шәмәрдән округы сайлаучылары миңа бик олы ышаныч күрсәтте. Көрәш киеренке, депутат урынына дәгъвачылар күчле иде. Кыскасы, мин сайлаучыларыма гомерем буе рәхмәтлемен. Әйе, 1990–1995 елларда бик күп сәяси вакыйгаларның шаһиты булып, шуның эчендә кайнадык. Алай гына түгел, мин Татарстан Республикасының Конституциясен кабул итүдә катнашуым белән бик бәхетле. Шул ук вакытта сайлаучыларның барлык наказларын, бигрәк тә зур матди чыгымнар таләп иткәннәрен тулысынча үтәп бетерә алмаганнары да бор-

чый...

Әлбәттә инде, без, журналист халкы, әңгәмә ахырына якынлаша башлагач, гаилә хәлен сорамыйча кала алмыйбыз.

— Миннән башка бездә ике Нурисламова эшли. Җәмгатем — Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы отличнигы, 2006 елда үзенең ике бишлегә тәмамланган юбилеен билгеләп үткән Гөлзифа — медсанчастьта. Без Әфганстанга киткән вакытта авылда — әби-бабайлары янында калып торган Гүзәл белән Айгөл дә үсеп җиттеләр инде. Гүзәл үзебездә — кадрлар бүлегендә. Кияүгә чыкты. Айгөл ике ел Төркиядә укып кайткан иде. Аннары, халык депутатларының Казан шәһәр советында эшләп, укуын дәвам итте. Төпчек кызыбыз Гөлнара да югары белем ала. Кыскасы, тормышыбыз матур.

Әйе, студент вакытта кавышкан яшь парларның гомерләре заяга узмый. Киләчәктә дә аларның гаиләсенә һәм, гомумән, бөтен коллективка хәрәкәтле һәм бәрәкәтле тормыш телик. Гомерләр гел шулай матур үтсен, йөрәк пульслары тигез типсен, алай гына да түгел, табигый газ агышлары теләсә нинди һава шартларында да көчле һәм ышанычлы, хәвеф-хәтәрсез булсын. Чөнки без бәяләп бетерә алмый торган зәңгәр ягулык һәр йортка, гаиләгә бәхет, җылылык, кыскасы, дөньялыкта вакытта ук җәннәт рәхәте алып килә. Дөньялар имин, өйләребез гел шулай җылы, ә инде табигать хәзинәсен безгә кудыручылар сау-сәламәт, ихтирамга лаек булсын.

Кыскасы, дөньяда яшәүнең мәгънәсен тасвирлаган бу язмамны Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинның түбәндәге шигъри юллары белән тәгәллисе килә:

Бу дөньяда һәркем
    лаек ихтирамга,
Раслый алса
    яшәвенең олылыгын...

*2006*

# Рәхмәт яусын Исмәгыйльгә!

Район алдынгылары слетында киң күкрәкле, тимер бәдәнле, зифа буйлы кешенең елмаеп, тиз-тиз атлап сәхнәгә менүен күргәч, залда утырган халык гөрләтеп кул чапты. Аның күпләргә игелек кылуын, шуның белән хезмәт кешесенең олы хөрмәтенә лаек булуын белгәнгә күрә, тагын бер кат шулай ихтирам итүләрен белдерделәр. Район хакимияте башлыгы 1997 елда ирешкән уңышлары өчен мактый-мактый аңа кыйммәтле бүләк тапшырды. Район башлыгы үзенең чыгышында бу коллективны тагын бер тапкыр уңай яктан телгә алды. Мактарлык эшләре бар икән: бер елда 110 чакрым газүткәргеч салынган, 1448 йортка табигый ягулык кергән. Газлы булу үзе зур бәхет булса, аның игелеген күреп яшәү, утын-күмер хәстәрләү мәшәкатеннән котылу икенче бер бәхет.

Кем соң ул кешеләргә шулай игелек кылучы Сабаның иң хөрмәтле һәм ихтирамлы кешеләреннән берсе?

Ул, Муса Җәлил сүзләре белән әйткәндә, «Кеше булган иң чын адәм» — Исмәгыйль Мөхетдинов. Шул үзе инде — урманчы Ибраһим малае. Әнисе Нурания гомер-гомергә тегү теккән. Исмәгыйль, Югары Шытсу авылында туса да, әти-әнисе белән авылдан авылга күчеп йөргән. Күчеп йөргән кешенең, билгеле, укыган мәктәбе дә гел алышынып, үзгәреп тора. Ул Сабабаш, Икшермә, Саба мәктәпләрендә белем ала. Әмма бәләкәй чагыннан ук Исмәгыйль техникага бик хирыс була. Әтисе белән әнисе ризалыгын алып, Яниль һөнәр училищесына укырга кереп кайта. Аннан тракторчы таныклыгы алып чыга. Ләкин типсә тимер өзәрдәй егет моңа гына риза булып калмый. Шоферлыкка да укый, таныклык ала. Ә инде армиядән кайткач, тракторга утыра утыруын, тик анда озак эшләргә туры килми. Механикалаштырылган күчмә колоннадан китеп, автотранспорт предприятиесенә урнаша. Эшнең үтә дә җаваплырагын сайлый. Автобуска утырып, «Саба—Казан» маршруты буенча кешеләр йөртә, уникe ел буена шулай. Елның нинди генә вакыты булмагандыр! Әмма үз хезмәтеңне ярату, аны намус белән үтәү авырлыкларны җиңәргә, коллективның таянычы булырга ярдәм иткән.

Автомашинаны энәсеннән җебенә кадәр белгән егеткә тагын да җаваплырак эш йөклиләр. Исмәгыйль Мөхетдинов автотранспорт предприятиесенең инженеры итеп билгеләнә. Элек ике кулга бер эш булса, хәзер инде син тулы бер коллективның күз алдында. Егет монда да үзен тиз күрсәтеп өлгерә.

«Эш күрсәткән ирне ил онытмый» диләр. И.Мөхетдиновка Сабадагы газ хуҗалыгына башлык булып барырга кушалар. Ничә еллар бергә эшләгән коллективны калдырып китәргәме? Шул уй тынгылык бирми. Тегендә хәлләр бик шәптән түгел. Рәтле базалары да юк. Ава-түнә йөргән, тәмам искереп беткән бер-ике машиналары гына бар. Эшчеләр дә бик аз: җәмгысы егермеләп кешесе бар. Менә шулар белән районны газлаштырып кара инде.

Тәвәккәлли Исмәгыйль Ибраһим улы. Нидән башларга? Район ул вакытта газ кертү буенча респуб-

ликада макталмый, халык та зарлана. Ни өчен шушы көнгә кадәр өйләргә газ керми? Кешегә моны ничек аңлатасың? Яңа җитәкче җиң сызганып эшкә тотына. Иң беренче баллонлы газны өйгә китереп урнаштыру оештырыла. Торбалар салына, плитәләр кайтарыла, авыл урамнарында озын, нәзек торбалар күренә башлый. Халыкның эченә җылы керә. Әллә ни күп вакыт та узмый. Сабаның үзендә дә, кайбер авылларда да кешеләр рәхәткә тиенә: зәңгәр ягулык йортларга килә. Район тиз арада алдынгылар сафына чыга. Исмәгыйль Мөхетдиновны халык тиз күреп ала. Аңа рәхмәт укый.

**— Исмәгыйль Ибраһимович, хәзер Саба районында газ кермәгән биш-алты авыл калган, диләр. Газ шул авылларга да кергәч, нишләрсез, эшсез утырмассыз микән? — дигән сорауны бирдек аңа.**

— Безнең эшнең колачын күз алдына китерәсегез килсә, 1991–1997 еллар эчендә барысы 556,5 чакрым үткәргеч сузылды. Шуның 235 чакрымын без салдык. Дөрестән дә, 67 авылдан газ кермәгән 6 авыл гына калды.

**— Шәмәрдән поселогында эшләр ничек бара? Анда әле бик күп йортларга газ кермәгән.**

— Шәмәрдән бистәсендә безнең махсус бригада эшли. Үткән ел анда шактый тырыштык. Тимер юл бүлеп торган ягында да газ кертү буенча хәтсез эш башкарылды. Лесная, Нариман, Пионер урамнарындагы 48 өйгә зәңгәр ягулык тоташты. Поселокта 5 чакрымнан артык газүткәргеч салынды. Без Шәмәрдәндә торак фондының 65 процентын инде газлаштыруга ирештек. Ит комбинаты, урта мәктәп, мех фабрикасы һәм башка кайбер предприятие-оешмаларга да үткәрелде.

**— Районда торбалар буенча килгән табигый газдан тыш баллоннан файдаланучылар да байтак. Болай бик кыенга туры килмиме?**

— Бу өлкәдә дә өзеклек юк. 1997 елда 1009 тоннадан артык сыек газ алып кайтып саттык. Шуның 64,5 тоннасы машиналарга заправка ясау өчен тотылды. 799,8 тоннасы халыкка сатылды.

**— Баллоннардан котылырга җыенмыйсызмы? Болай халыкның үзенә дә уңайсыздыр?**

— Узган ел без авыллар арасында 7,9 чакрым озынлыгында газүткәргечләр суздык. Авыл эчендә 48,3 чакрым торба салынды. Өч пар казаны бинасы, 26 коммуналь-көнкүреш объекты зәңгәр ягулыкка тоташтырылды. Инде яңа елга — 1998 елга кергәч тә, районның 105 йортына табигый ягулык керде. Эш бара. Әлбәттә, берникадәр баллоннар да калыр. Ник дигәндә, торбалар буенча газ кертү өчен ярамый торган биналар, йортлар бар бит әле.

**— Кайбер районнарда торбаларны читтән килеп салалар. Ә сез үзегез бу эшкә тәвәккәлләгәнсез.**

— Ә безнең лицензиябез бар, һәр эшче, үз тармагы буенча укып, имтихан тапшырды. Төтен юлы каналларын да үзебез тикшереп торабыз. Моны элегрәк башка оешма башкарды.

**— Исмәгыйль Ибраһимович, халык, газның бәясе кыйммәт, ди. Үзебезнең җир астыннан чыккан байлыкның хагы нигә очсыз түгел икән, диләр. Бәя үзгәртү сездән тормыйдыр бит?**

— Беренчедән, без күбрәк Төмән газын ягабыз. Икенчедән, аның бәясен без билгеләмибез. Ул Министрлар Кабинеты карары нигезендә тормышка ашырыла. Безгә нинди бәядән җибәрергә кушалар, шуңа сатабыз. Кайвакытта, үзебезгә зыян китереп булса да, арзанракка да сатып җибәрәбез. Мәсәлән, 1997 елда без 47 миллион 99 мең кубометр табигый газ саттык. Шуның 30,6 миллионын халык файдаланды. Ә 11 миллион 697 мең кубометрын ташламалы бәяләрдән җибәрдек. Шуның аркасында ярты миллиардка якын акча югалттык. Табигый газ сатудан миллиард ярым зыян күрдек. 4837 хуҗалык сыек газдан файдалана. Шуларның 1600 енә ташламалы бәядән җибәрдек. Тагын байтак керем алынмый калды.

**— Торбалар салгансыз, күп кенә өйләргә зәңгәр ягулык керткәнсез. Оешма, предприятиеләр, учреждениеләр никадәр, бар да газ яга. Болардан тыш сез ул үткәргечләрне, җиһазларны ничек файдаланылуы өчен дә җаваплы. Тагын акча, тагын чыгымнар.**

— Газүткәргечләргә, җиһазларга ремонт үткәрдек. Моның өчен 1997 елда 723,5 миллион сум акча сарыф ителде. Без төзү-эксплуатация идарәсе дип аталабыз. Әлбәттә, ремонт эшләре дә алып барабыз. Мәсәлән, Саба авылында басым түбән булган урамнарда торбалар яңача тоташтырылды. Югары Симет авылында алар зуррак диаметрлыларына алыштырылды.

Исмәгыйль Ибраһим улы үзенең коллективы, ул башкарган эшләр турында шулай горурланып сөйли.

**— Газ кертү өчен күп акча кирәк. Авыл кешеләренең барысында да акча юктыр, һәркем бер елда ике үгез дә сата алмый. Халык бу эш бик кыйммәткә төшә дип зарланмыймы соң?**

— Юк, зарланмый. Бик мохтаҗларга без үзебез дә ярдәм итәргә тырышабыз. Күптән түгел Килдебәк авылында бер карчыкның өенә газ кертелми калуын килеп әйттеләр. Пенсия акчасына гына яшәгән кешенең хәлен аңлап була. Без аңа ярдәм итәбез. Шәмәрдән бистәсендәге ялгыз карт-карчыкларны да ярдәмебездән ташламыйбыз. Аннары кайбер авылларда күмәк хуҗалыклар булыша.

Шушы авыр заманда торбалар, төрле җиһазлар кайтару алай бик җиңел эш түгел. Бу яктан Исмәгыйль Ибраһим улының күңеле тыныч. Читтән эзләп йөрисе юк. Торбасын да, кранын да, изоляция материалын да кирәк кадәр алып кайтып торалар. Халык та аптырап йөрми. Яңа ел алдыннан үз кибетлә-

рен ачып җибәргәннәр. Газ хуҗалыгы өчен бөтен кирәк-яракны алып була.

«Сабагаз» идарәсе Теләче районы хуҗалыкларына да хезмәт күрсәтә. Дөрес, бу районда газ кертеп бетерү өчен бихисап күп көч куясы бар әле. Әмма «Башланган эш — беткән эш» диләр. Теләче районы алдынгылары слетында да шушы районда газ кертү буенча башкарылган эшләре өчен И.Мөхетдиновка зур рәхмәт белдерделәр.

Бу кадәр зур хуҗалыкны төпкә җигелеп тартып бару өчен әзерлекле, югары квалификацияле кадрлар, белгечләр кирәк. Шул хакта сүз чыгуга, Исмәгыйль Ибраһимович аларның исемнәрен атый башлады:

— Мактаулы кешеләребез күп. Шофер Азат Зарипов, эретеп ябыштыручылар Рамил Салихов, Альберт Кашапов, инженер Илгизәр Вәлиев, баллонлы газ җибәреп торучы Әлфия Галләмова, авария-диспетчерлык хезмәте эшчеләре Миңнәхмәт Нургалиев, Равил Гәрәев, газ кертү бригадасы җитәкчесе Илдар Сафин, баш бухгалтер Гөлсем Имамиева һәм башка кайбер хезмәткәрләребез үз эшләренә чын күңелдән бирелгән кешеләр.

Коллектив газ кертү белән шөгыльләнә торган икенче оешма — «Татгазспецстрой»ның Сабадагы Тәлгат Шиһапов җитәкчелегендәге махсус төзү-ремонт идарәсе белән кулга-кул тотынып эшләгәндә, район 1999 елда тулысынча газлаштырылып бетәр дигән уй белән яши. Моның өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Бүгенге көнгә район буенча инде 8861 йортка газ кергән. Сабалыларның бөтенләе белән рәхәткә тиенәсе көннәренә күп калмаган инде. Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтенең атказанган хезмәткәре Исмәгыйль Мөхетдинов бу бурычларның үтәләчәгенә һич кенә дә шикләнми.

**— Күп урыннарда хезмәт хакын айлар буена ала алмыйлар. Сездә дә шулаймы? —** дип сорыйбыз аннан.

— Без хезмәт хакын вакытында биреп барырга тырышабыз. Ничек шунсыз кешедән эш таләп итәсең? Хезмәт шартларыбыз бик катлаулы бит. Безнең өчен салкын кыш та, яңгырлы-җилле көз дә, эссе җәй дә юк. Елның теләсә нинди вакытында кешеләребез табигый ягулык кертү, газ җиһазларыннан файдалануны төгәл тәэмин итү белән мәшгуль. Үземнең дә производство участокларын көн саен бер карап кайтмыйча, авылларда эшнең барышына күз-колак булмыйча күңел тынычланмый. Торба сузып, өйләрдә плитәләр куеп, аннары зәңгәр факелны кабызып кына эш бетми бит әле. Безнең өчен аның хәвеф-хәтәрсез булуы, кешеләрнең шатлыклы йөзләрен күрү бик мөһим.

Коллектив акчаны үзе эшләп таба. Шуңа күрә монда социаль-көнкүреш мәсьәләләрен дә уңай хәл итәргә тырышалар. Эшчеләргә һәм хезмәткәрләргә уңайлы эш, яшәү шартлары тудыру турында әледәнәле кайгыртып торалар. Яңа начальник килгәч, күп кенә биналар салынган, цехлар ачылган, техника саклау урыннары, кибет һәм башка объектлар төзелгән.

— Исмәгыйль Ибраһимовичны район советына халык депутаты итеп сайлап бик уңдык, — ди «Үзәк» күмәк хуҗалыгы рәисе Марсель Талипов. — Ике авылны бер җәйдә диярлек газлы итте ул. Хәзер аңа бөтен кеше рәхмәт укый. Алай гына да түгел, бер дә мөмкинлеге булмаган кайбер кешеләргә ул газны бушка кертте.

Исмәгыйль Ибраһим улы бик тә гөлләр ярата. Аның эш бүлмәсенә килеп керсәң, «чәчәк кибетедер бу!» диярсең. Алай гына да түгел, ул бүлмәсендә лимон үстерә. Дүрт ел элек Казаннан лимон агачы үсентесе алып кайтып утырткан икән. Тәрбияләгән, караган. Һәм менә лимон агачы җимеш биргән. Инде тәүге уңышын җыеп та алган.

«Сабагаз» идарәсе җитәкчесе Исмәгыйль Мөхетдиновның һәр көне менә шундый эшләр белән уза. Игелекле, шатлыклы мәшәкатьләр белән үткән көннең алды-арты хәерле була, диләр. Шулай була күрсен!

*1998*

# Алтын куллы Ногмановлар

Азрак буш вакытым булса, мин Байлар Сабасының зиратларын әйләнеп чыгам. Ачык һавадагы музей, дип бик хаклы әйтәләр мәңгелек йортыбыз турында. Хәзер авыл эчендә калган иске зират Шиһабетдин Мәрҗанинең «Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр» исемле зур хезмәтендә искә алына.

Каберләр дәшмиләр. Әгәр үлгәннәрнең теле булса: «Безнең тынычлыгыбызны бозмагыз», — диярләр иде. Шуңа күрә каберлекләрдә тыныч кына йөрү табигый хәлдер. Әле күптән түгел Сабаның Тимершык авылы ягы зиратындагы бер кабер ташы игътибарымны җәлеп итте. Ул РСФСР күләмендәге персональ пенсионер Нурислам Ногман улына куелган. Аның утызынчы еллар башында ук тракторчылар курсында укып, 1936–1938 елларда Чиләбе шәһәрендә механиклар мәктәбен тәмамлавын һәм 1941

елдан, ягъни егерме ике ел буе МТС, РТС директорлары, «Сельхозтехника» район берләшмәсе управляющие вазифалары алып барганын да соңрак белдем. Иң мөһиме тагын шунда: Нурислам Ногмановка, 1962 елда «Татарстанның атказанган механизаторы» дигән мактаулы исем бирелеп, республикада беренче номерлы таныклык тапшырылган.

Менә шуннан соң Ногмановлар турында тирәнтенрәк өйрәнү теләге туды. Алар Байлар Сабасына терәлеп торган, көмештән бизәнү әйберләре ясаучылары белән тарихка мәңгелеккә кереп калган Тенеки авылында гомер итеп, тимерчелек эше белән шөгыльләнгән нәселдән икән. Ногман Шәрәфиев алтын куллы булуы белән тирә-юньдә дан тоткан. Аның тимерче алачыгында күмер уты ел тәүлеге сүнеп тормаган.

Урып-җыю эшләре башланыр алдыннан урак тешәтергә (сүз кул уракларын үткенләү, тешле итү турында бара) күрше-тирә авыллардан да киләләр. Уллары Нурислам, Хәмит, Әхмәт, Хәләф ярдәме белән меңләгән урак тешәгән еллары да була.

Тимердән чәчәк коя торган ир-ат җәмәгать эшләрендә дә катнаша. Мәсәлән, 1939 елда хезмәт иялә-ре депутатларының беренче чакырылыш район Советы депутаты итеп сайлана. Аларның гаилә архивында сакланган бер рәсми кәгазь кызыклы гына өстәмә мәгълүмат бирә: «Бу белешмә Саба районы Юлбат авылы Ворошилов исемендәге колхоз идарәсеннән шул ук районның «Яңа юл» колхозы (Тенеки авылы) әгъзасы һәм район советы депутаты Ногман Шәрәфиевка түбәндәге хакта бирелә. Дөрестән дә, иптәш Шәрәфиев, Ворошилов исемендәге колхозга килеп, 1940 елның язгы чәчүенә әзерлекнең торышын карады. Тикшерү вакытында табылган кимчелекләрне бетерергә күрсәтмәләр бирде. Югарыда язылганнарны раслап: колхоз председателе Гайнетдинов, секретарь Галимуллин».

Икенче бер белешмә-килешү ызандаш «Октябрь» колхозы (Туктар авылы) идарәсе белән төзелгән. Анда сугыш вакытында — 1944 елда — 120 данә урак тешәгән өчен Ногман Шәрәфиевка 10 ар сумнан, барысы 1200 сум түләнәчәге әйтелә.

Әйе, саргаеп беткән кәгазьләргә шәмәхә кара белән язылган беркетмәләр, беренчедән, шул чордагы тормышның авырлыгын исбатласалар, икенчедән, сәяси мәсьәләләрнең күз уңында булуын раслыйлар. 1940 елның 6 мартында «Яңа юл» колхозының (Тенеки) идарә утырышы булып, анда 8 Март — Халыкара хатын-кызлар көнен уздыру мәсьәләсе карала һәм түбәндәге карар кабул ителә:

*«1. 8 Мартны уздыру өчен туклану фондындагы җитмеш кило чүпле бодайны, тегермәнгә төшереп, яргычтан өрдерергә.*

*2. Шуннан икмәк пешертеп, һәр хатын-кыз башына өч йөзәр грамм бүлеп бирергә.*

*3. Чәй-шикәрне сельподан акчага сатып алырга.*

*4. Столовойны кызыл почмакка урнаштырырга».*

Һәм әлеге рәсми кәгазьгә президиумның биш әгъзасы кул тамгаларын салганнар.

Менә шундый ачлы-туклы чорда башлана коточкыч Бөек Ватан сугышы. Һәм Ногмановлар гаиләсеннән иң беренче Хәмит фронтка элэгә. Ул яшьтән үк киң эрудицияле булып үсә, русчага өйрәнә, бик яхшы рәсем дә ясый, гармунда да уйный. Шуңа күрә дә 1935 елда ук, Ключище авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлап, башта Татарстан Җир эшләре комиссариатына караган умартачылык конторасында бүлек начальнигы булып эшли. Ә инде 1939 елда бөтен Россиядә бармак белән генә санарлык дәрәҗәдә аз булган совхозларның берсенә — үзебезнең район биләмәсендәге «Нариман» тәҗрибә-житештерү хуҗалыгына җибәрелә һәм шуннан Совет Армиясенә алына. Красноярск краендагы Ачинск полк мәктәбен тәмамлагач, Ленинград өлкәсенә озатыла һәм сугыш вакытында Ленинград камалышына эләгә.

Тугыз йөз көнгә сузылган блокаданың илебезгә, әлеге шәһәрнең герой халкына нинди фаҗигаләр китергәнен күпләр белә. Ногмановларда шушы фаҗигаләрне үз гомерен бирел кичергән Хәмитнең өчпочмаклы хатлары саклана. Аның иң беренчесе 1940 елның март айларында фин сугышыннан соң Россиягә (элеккеге СССР) солых килешүе белән кушылган Ханко ярымутравыннан салынган. Фин култыгыннан Ленинградка килә торган диңгез юлының капкасы булып торган бу утрау һәм андагы крепость, тулы чолганышта булып, немецларга да, финнарга да каршы йөз алтмыш дүрт көн оборонада тора. Шушы вакыт эчендә фашистлар кырык сигез «юнкерс» самолетын, ике миноносец, су асты көймәләрен һәм башка корабльләрен, меңләгән солдат һәм офицерларын югалталар. Утрауда «Җиңү яки үлем» дигән лозунг белән яшиләр, көрәшәләр. Һәр унбиш квадрат сантиметр җиргә бер снаряд туры килә, ярты миллион данә шартлаткыч заряд җибәрәләр немецлар. Шулай да бу аз санлы гарнизон сугышчылары бирешмиләр.

Бик көчле ныгытылган утраудагы 42 нче саперлар батальонында Саба районыннан да ике сугышчы булган. Аның берсе — Йосыф-Алан авылы егете Хатыйп Ситдиков. Икенчесе, әйткәнебезчә, Хәмит Ногманов.

1941 елның ноябрь айларында фин гаскәрләре башкомандующие, ярты рус, ярты швед генералы Маннергейм бу гарнизонга пленга бирелергә кушып хат тапшырттыра. Ләкин гарнизон каршы җавап хаты җибәрә. Менә шул хатның бер данәсе һаман да Саба җирендә саклана. Аны Хәмит җибәргән була.

«1942 елда Ханко гарнизоны Ленинградка кайтарыла, аларның сугышчыларын Тоска-рекада, Колпино поселогында, Пулково биеклегендә дә очрата идек», — дип искә ала элеккеге 42 нче саперлар ба-

тальонының сәяси җитәкчесе (политрук), хәзер отставкадагы полковник В.Ярошеевич үзенең язмаларында.

1942 ел азагында Ленинград фронтында «Искра» операциясенә әзерлек башлана. Бу операция буенча Нева елгасын боз өстеннән үтеп, биек ярыннан менеп, яр өстендәге немец траншеяларын атакалап блокаданы өзү, Волхов фронты сугышчылары белән кушылу бурычы куела.

Менә Хәмит Ногмановның 5 гыйнварда (1943) салган хаты. Ул «Без зур әһәмияткә ия булган операциягә әзерләнәбез. Әгәр исән булмасам, минем хәлне Комаровка кешесе (бу авыл хәзер Теләче районына керә) Белов Григорийдан сорарсыз» дип яза. Ул хат (аның күңеле сизенгән) Хәмит һәлак булган көнне туган йортка килеп җитә. Ә 20 гыйнварда аның үзенең антына тугрылыклы булып Марьино авылы янында һәлак булуы турында хәрби комиссариаттан хәбәр китерәләр. Дөрестән дә, блокаданы өзү өчен куелган чаралар арасында шунысы билгеле: дошманга каршы көрәшкә әзерләнгән гаскәрләрнең һәрбер батальонында ун-унбиш сугышчыдан торган аерым штурмчы саперлар группасы төзелә. 1943 елның 12 гыйнвар иртәсендә алар, баштанаяк коралланган хәлдә, Киров заводыннан килгән карт эшчеләрнең флагларын күтәреп, төп көчләрдән алда беренче юл ачу өчен Нева елгасының карлы бозы аша 600 метр юл үтәләр. Шлиссельбургтан ерак булмаган Марьино авылы янындагы текә ярдан менеп, немецларның окопларына ташлананалар. Кул сугышлары китә, гранаталар шартлый, автоматлар белән кырышалар. Шул сугышларда берничә немецны юк итәргә өлгергән штурмгруппаның командиры Хәмит үзе дә немец автоматыннан һәлак була. «Монда, кырда да, авылларда да, немец солдатлары һәм безнең сугышчыларның үле гәүдәләре чәчелгән иде», — диләр Марьино авылы кешеләре.

Составында 42 нче аерым саперлар батальоны булган 136 нчы Ханко дивизиясе авыр сугышлар белән 6–7 көннән соң Волхов фронты сугышчылары белән очраша. Бу блокаданы өзүнең Марьино-5 эшчеләр бистәсе участогын үтү өлешендә ханкочылардан барлыгы егерме бер сапер һәлак була. 42 нче саперлар батальонының исән калган сугышчылары хәзер дә 18 гыйнвар көнне Ленинградта үз частьларында очрашулар үткәрәләр.

Аларның батырлыгын әлеге бөҗраны өзүдә катнашкан фронт политругы В.Ярошеевич гомере буе сурәтли, газета-журналларга яза, китапларга кертеп калдыра.

Әйе, беркем дә, бернәрсә дә онытылмый. Көмешчеләре, тимерчеләре белән дастаннарга кергән Тенеки авылының Ногмановлар гаиләсендә үскән өченче каһарман — Әхмәт тә — сугыш вакытында камалыштагы Тула шәһәрендә була. Районыбызның Алан-Елга, Йосыф-Алан мәктәпләрендә мөгаллимлек күнекмәләре, Арча педагогия училищесында төпле белем алган егет Мәскәү астындагы Завидово шәһәрендә полк мәктәбен тәмамлый. СССР башкаласын саклауда катнаша. Шунда беренче «катюша»-лар залпын күрә. Мондый ветераннар хәзер ил буенча бик аз калганнар икән. Озакламый Мәскәү шәһәренә очрашуга җыелачак алар. Ашыйсы ризыгы, эчәсе суы бетмәгәч, Тула шәһәре камалышыннан да исән калып, туган ягына кайта Әхмәт ага. Тыныч хезмәттә дә аттай эшли. Фронтта батальонның комсомол оешмасын җитәкләгән Ә.Ногмановны ВЛКСМның Саба район комитеты беренче секретаре итеп тә сайлыйлар. Кыскасы, тормыш юлы бай да, катлаулы да, озын да Әхмәт Ногман улының. Шуңа күрә бу урында танылган журналистыбыз, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Фәнил Мәүлетовның «Әхмәт абыйның дүрт эше» дип исемләнгән күләмле язмасыннан өзек китерсәк, зыян итмәс.

*«...Кечкенәдән тимер-томыр арасында кайнап үскән Әхмәт абыйның техника-механика белән бәйле хезмәттә танылуына гаҗәпләнерлек түгел. Әмма аңа тормышта башта укытучы булырга теләп, педагогик белем алуы да бик ярап куя. Заманаларның үзгәрәчәген, әтисе кайчандыр яхшырак үтсен, кырда иген уручыларга җиңелрәк булсын дип тешәгән кәкре уракның төп эш коралы булудан төшеп калачагын яхшы аңлый ул. Техник алгарыш үсеш ала, әкренләп кул көчен механика алыштыра. Әмма кешелек дөньясы тарихына күз салсаң, бер закончалыкка игътибар итәсең: техника, уйлап табу казанышлары башта, тыныч максатлардан бигрәк, сугыш кырында файдаланылган. Егерменче гасыр урталарына таба танкларны тракторларга караганда күбрәк эшләп чыгаруны алгы планга куйган милитаристик дәүләтләр башкаларга үзенең сәясәтен көчләп тага. Кыскасы, Әхмәт абыйлар буынына сугыш афәтләре аша үтәргә язган булып чыга.*

*Ил тыныч тормышка күчкәч, авыл хуҗалыгы эшләрендә куәтле техника да күренә башлый. Әмма аларның ягулык аппаратларын көйли белүче булмый. Казан авыл хуҗалыгы институты каршындагы курсларда ике ел укып кайткан махсус белемле Әхмәт абыйга шушы җаваплы участокны тапшыралар. Чөнки, аппаратны дөрес көйләп урнаштырмасаң, трактор эшләми, механизаторлар да интегә, гомумән, Әхмәт Ногманов җитәкләгән бу зур булмаган коллектив техник хезмәт тә күрсәтә, диагностика белән дә шөгыльләнә».*

1958 елда Ә.Ногмановны — инде Чистай техникумында көндез укып «кызыл диплом»га тәмамлаган механикны — укытучы белеменә дә ия икәнлеген белеп, район мәгариф бүлеге мөдире Гасыйм Йосыпов үзенә чакырып ала һәм Саба урта мәктәбендә укучыларны производство нигезләрен өйрәтү эшенә алынырга тәкъдим итә. Шушы уңайдан район партия комитетында да җитди сөйләшү була. Һәм Әхмәт абый, ризалыгын биреп, җаваплы эшкә күчә. Мәктәптә производство нигезләрен өйрәтү буенча ур-

нәк кабинет җиһазлый, техник база булдыру артыннан күп чаба. Тырышлык матур нәтиҗәләр бирә, укучыларны хезмәткә әзерләү буенча зур эш башкарыла. Ә.Ногманов яшь буынны производствога өйрәтүгә ун ел гомерен багышлый. Бу Әхмәт абыйның икенче эше.

1971 елда аны кабат район җитәкчеләре чакырып алалар һәм, «Сельхозтехника» район берләшмәсендә терлекчелек фермаларын механикалаштыру цехы оештырылу сәбәпле, Әхмәт Ногман улына управляющий урынбасары вазифасын йөклиләр. Районда (Теләче районын да кертеп) сыерларны машина белән өч хуҗалыкта гына савалар ул вакытта. Сыер савучылар җитешми, кул хезмәте күп булганга, яшьләр фермага килми. Шуңа күрә дә алдагы биш-алты ел эчендә мондый артталыкны бетерү планлаштырыла. Шушы заман таләп иткән колачлы эшне оештыруның башында Әхмәт абый тора. Цехта алга куелган бурычларны тормышка ашырырга сәләтле коллектив туплана, егетләр эретеп ябыштыру серләренә өйрәтелә. Фермалар әкренләп механикалаштырыла. Күздә тотылган вакыт эчендә сыер саву аппаратлары куелмаган бер генә хуҗалык та калмый. Әмма механикалаштыру бер нәрсә, ә сыер савучыларны аппарат белән эш итәргә өйрәтү дә күп вакыт сорый икән. *«Берзаман районда сөт кими башлады, сыерларда мастит авыруы да үзен сиздерә һәм моны бездән күрәләр,* — дип искә ала Әхмәт абый. — *Янәсе, сыер савучыларга өйрәтеп, күрсәтеп бирмисез. Фермаларга чыгабыз — аппаратларны склад урынын үти торган урынга кертеп ташлаган булалар. Сыер савучылар аппарат белән савуның өч этаптан торганлыгын аңлап бетермиләр. Алар: савуга әзерләү, саву һәм савып бетерү. Беренче этап үтәлсә генә сыерда шартлы рефлекс туа, альвеолаларга сөт тула. Монысын да аңлаттык. Шулай ук имчәкләргә кидерелә торган резинкаларны эксплуатацияләү таләпләре дә үтәлми булып чыкты. Нәтиҗәдә алар саву-кысу тактларын дөрес башкармыйлар. Гомумән, сыер савучыларны хуҗалыкларга үзебез чыгып укытуны җайга салдык. Ә ферма мөдирләрен цехка чакырабыз. Махсус укыту-өйрәтү кабинеты җиһазланды. Ягъни бу эштә эзлекле система булдырдык».*

Әхмәт абый әнә шулай, фермаларны механикалаштыруның башында торган кеше буларак, хезмәт юлына матур сәхифәләр яза. Бу — аның өченче эше.

Моннан тыш Әхмәт Ногман улына районда шофер һөнәрен үзләштергән бик күп ир-атлар да бурычлы әле. Бу эшне аңа ДОСААФ линиясе буенча тәкъдим итәләр. «Әхмәт абый, курслар оештырыйк әле», — диләр. «Оештырыгыз соң», — ди Әхмәт абый. «Аның өчен укытучы кирәк бит, ә андый хокук сездә генә». Авылларда балачагы сугыш елларына туры килеп, бернинди һөнәр алмаган ир-егетләр байтак була. Аларны һөнәрле итү кебек изге эштән баш тартып буламы соң! Укытулар мәктәптә, «Сельхозтехника» район берләшмәсендә кичләрен оештырыла. Түләүле курслар була ул. Ел саен утыз кешегә транспорт йөртү таныклыгы бирелә. Әхмәт абый бер елны шоферлыкка укучы егетләрне үзе читтән торып өч курс белем алган Казан авыл хуҗалыгы институтына да алып бара әле. Бирелә укыту-өйрәтү базасын күргән егетләр тел шартлаталар. Их, шушында белем алсаң иде, диләр. Күбесе хыялын тормышка ашыра да. Әйтергә кирәк, аның тәкъдим-фатихасы белән инженер белгечлеген үзләштергән кешеләр районда байтак.

Шоферлыкка өйрәтү — Әхмәт абыйның дүртенче эше. Ул пенсиягә чыккач та, 104 нче һөнәр училищесында укучыларны юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү дәресләрен алып бара әле. Гомуми хезмәт стажы, сугыш вакытында армиядә хезмәт итүне, район партия һәм комсомол комитетларында эшләүләрне кертеп, кырык сигез елга тула...

...Бәхете үзе белән туган тагын бер — дүртенче малай бар бит әле Ногмановлар гаиләсендә. Ул — Хәләф. Яшьтән очучы булырга хыяллана егет. Әмма хезмәт юлын барыбер, абыйлары кебек, плугарьдан, тракторчыдан башлый. Унҗиде яше тулгач, 1944 елда армиягә алына һәм Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәрендә авиация училищесында укый. Япон сугышында очучы-укчы, соңыннан Байконур төзелеше елларында хәрби-төзүчеләр рәтендә булып, бөтен гомерен данлы Кораллы Көчләргә багышлый. Башта экстерн тәртиптә училище, аннары Алма-Атадагы Хәрби академияне тәмамлый. Соңгы елларда Хмельницк шәһәрендә хезмәт итә һәм фәнни эш белән шөгыльләнә.

Бу язманы төгәлләгән мизгелләрдә, Украинада нәшер ителгән бер газета кисемтәсе белән танышырга туры килде. Хәләф Ногман улы эшли торган Богдан Хмельницкий исемендәге Милли академиянең юбилеена багышланган сан булып чыкты ул. Анда безнең якташыбыз, татар улы турында махсус очерк бирелеп, Украинаның ул вакыттагы Президенты Леонид Кучманың Дәүләт бүләге тапшырган мизгел сурәтләнгән. Шулай булгач, мондый кешеләрең белән ничек горурланмыйсың, Саба!

Дөрестән дә, тулы бер нәселнең кылган гамәлләренең, башкарган эшләренең бәясе вә кадере еллар үткәч ачыграк күзаллана кебек. Бәлки, шуңадыр, адәм баласының әледән-әле артка борылып карау, үткәннәргә анализ ясау гадәте бар.

Бөтен гомерен туган авылыннан дүрт-биш чакрым гына урнашкан Байлар Сабасында кичергән Әхмәт ага нигезе озак еллар Ногмановларны туплаучы, көтеп каршы алучы һәм озатучы йорт буларак балкып утыра. Гаилә хәленә килгәндә, Саба кызы Гөлбикә апа белән (ул да озак еллар «Сельхозтехника» системасында эшли), нәкъ алтмыш ел бергә тату яшәп, ике ул һәм ике кыз үстерделәр. Уллары бабалары юлыннан китте. Миңнеислам, хезмәт юлын тракторчыдан башлап, партия-комсомол органнарында эшләде, әтисе кебек, ВЛКСМның беренче секретаре итеп сайланды, озак еллар Саба автотранс-

порт предприятиесен җитәкләде, КПСС райкомының авыл хуҗалыгы мәсьәләләре буенча секретаре булды. Икенче улы Лирик та инженер һөнәрен сайлады. Кызлары Зилә белән Фәридә үзләрен медицинага — халык сәламәтлегенә багышладылар. Кыскасы, һәркайсы тормышта үз урынын тапты. Хәзер инде оныкларының балалары үсеп киләләр. Алар, барысы бергәләп, күптән түгел Әхмәт аганың олы юбилеен — 85 яшьлеген билгеләп үттеләр. Нигез тоткасы булган хезмәт һәм сугыш ветераны туксанга таба барса да, кул кушырып утырмый. Умарта тота, столярлык эше белән шөгыльләнә. Үткәнен барлый, истәлекле вакыйгаларны терки. Мәсәлән, үз нәселләре турында матбугатта басылган язмаларны җыйнап, «китапчык» ясаган ул. Саба урта мәктәбе турындагы (фотосурәтләр белән аралаштырылып) язылган утызынчы еллар башыннан булган чорны эченә алган тарихи альбомны киләчәк буыннар да файдаланыр әле. Кыскасы, Әхмәт Ногман улының күпне күргән, Бөек Ватан сугышы һәм аннан соңгы еллардагы шактый авырлыкларны кичергән йөрәге һәрвакыт үткәннәрне уйлап, киләчәкне кайгыртып тибә. Алга таба да шулай булсын иде ул!

*2006*

# Бирешмәгез, ветераннар!

Ныграк борчый истәлекләр,
Ныграк әрни яралар.
Сирәгәя безнең сафлар,
Ерагая аралар.

Дәһшәтле сугыш кырларында илебез азатлыгын саклаган ветераннар күп түгел инде. Аларның сафы елдан-ел кими бара. Сугышның ачысын-төчесен күргән фронтовикларның байтагы Бөек Җиңүнең 50 еллыгын ничек тә булса бәйрәм итү теләге белән яши. Чөнки олыгайдылар алар. Шулай булмыйча, сугыш беткәндә егермедә булганнарга да җитмеш тула бит. Бу бәйрәм көннәрендә ветераннарның онытылмас истәлекләре тагын бер кат яңарыр әле...

Олы Нырты авыл советы биләмәсендәге авылларда хәзергә егерме дүрт сугыш ветераны яши икән. Алар арасында Хәят Сәйфетдинова, Елена Зайцева, Елизавета Пенкина, Надежда Аришина, Клавдия Поджарева кебек хатын-кызлар да бар. Иван Башкиров кебек Советлар Союзы Герое биргән бу төбәк үзенең дастаннарга тиң лачыннары белән хаклы рәвештә горурлана. Ватан сугышында катнашкан берәр ветеран белән очрашу теләген белдергәч, безгә Габдулла Рәхимовны тәкъдим иттеләр.

— Хөрмәткә лаек кеше. Әле генә үзенең җитмеш яшьлек юбилеен билгеләп үтте, район хакимиятенең Мактау грамотасы тапшырылды, — диде «Саба» күмәк предприятиесе директоры, халык депутатларының Олы Нырты авыл советы башкарма комитеты рәисе Гафур Шәйхулла улы Хәсәншин.

Габдулла агаларның йортын озак эзләргә туры килмәде. Чөнки Бөек Ватан сугышы ветераны яшәгәнен күрсәткән язу капкага ук беркетелгән иде. Менә безне баскыч алдында чәчләренә ак чал төшкән, хәрбиләрчә туры гәүдәле Габдулла ага каршы ала. Шул мизгелдә өй эченнән хуҗабикәнең: «Тәлгат бит бу!» — дигән сүзләре ишетелә.

Бу йортта 1972 елның җәендә булуыбыз келт итеп искә төште. Мәдәният учаклары эшен карарга килгәч, район үзәк китапханәсенең берничә хезмәткәре белән чәйгә кергән идек. Бүгенгедәй хәтердә: хуш исле түгәрәк авыл ипие һәм каты итеп ясалган һинд чәе... Менә егерме ике елдан соң без шушы нигездә кабат әңгәмә корабыз.

1942 ел. Фронтта да, тылда да тәмуг газаплары. Военкомат дигәннәре ир-егетләрне «чүпли» тора. Менә унсигез яшьлек Габдуллага да чират җитә. Ул елларда дәрәҗәле саналган җиде класс белемле Г.Рәхимов әнисен, туганнарын, хисапчы вазифасын калдырып фронтка китә. Башта аларны Горький өлкәсенең Выкса шәһәрендәге артиллерия частенда орудие командирлыгына өч ай чамасы укыталар. Тиз өйрәнә авыл егете гаубица дигән коралны, үзен төз атучы мәргән итеп таныта. Аннары алар Великие Луки, Старая Русса шәһәрләре янындагы сугышларда катнашалар. Габдуллаларның часте Башкомандующийның резервы составында була. Аларны, кайда хәл авыр, шунда җибәрәләр. Шуңа күрә Габдуллага җир өстеннән тимер ташкындай ябырылган фашист аждаһа-танклары, күктән бомбага тоткан карчыга кебек самолетлар белән әледән-әле очрашып торырга туры килә. Иң коточкыч бәрелешләрнең берсе 1943 елның июль аенда Орел шәһәре тирәсендә була. Әйе, сержант Рәхимов монда үлем белән күзгә-күз очраша. Бөек Ватан сугышы тарихында кискен борылыш ясаган Курск операцияләрендә ул турыдан-туры катнаша. Аларны, Башкомандующийның үз резервындагы гаскәрләрне, апрель аенда ук Орел юнәлешенә күчерәләр.

— Кайчакта миннән, сугыштагы берәр истә калган эпизодны сөйлә әле, дип сорыйлар, — ди ветеран. — Әмма утлы елларның хатирәләрен аерып алып булмый. Тоташ кан кою. Минут саен дошман белән күзгә-күз очрашулар. Гомумән, мәрхәмәтсез ул сугыш дигән нәрсә. Шулай да менә Орел шәһәре

янындагы һөҗүм вакыты мәңге истән чыкмый. Илле елдан соң да төнлә төшләргә кереп саташтыра. Без һөҗүмгә таң ата башлагач керештек. Төшкә кадәр күк йөзе яктыра алмады. Ату-шартлау нәтиҗәсендә бөтен дөньяны караңгылык баскан иде. Төн уртасы диярсең. — Ветеран тынып кала. Аннары сүзен болай дип дәвам итә: — Әйе, андый вакытларда күңел каткан була инде. Һәлак буласыңны да беләсең. Әмма шул авыр минутларда да туган ил истән чыкмый. Гомер булса, туган илләргә сагынып, исән-сау кайтып, бергә-бергә тагын тыныч кына, матур гына итеп яшәрбез әле, дип уйлыйсың.

Габдулла Рәхимов әнә шулай, бер яудан икенчесенә күчә-күчә, сугышчан чыныгу ала. Белгород, Харьков, Сумы, Гадяч шәһәрләрен азат итүдә катнаша. Авыр орудиесе белән Днепрны кичә, газап-михнәтле сугыш мәшәкатьләрен үзе генә белә. Украина башкаласы Киевтан соң Бердичев, Белая Церковь шәһәрләре дошманнардан чистартыла.

Ә менә Корсунь-Шевченковск юнәлешендәге бәрелешләр аның йөрәгендә саклана. Чөнки аның яралары бүген дә әрнетә.

1944 елның 4 феврале була бу. Сержант Рәхимов орудиесе фронт линиясенең алгы өлешендә була. Фашистларны дөмбәсли-дөмбәсли алга омтылалар. Әмма алар чолганыштан чыгарга омтыла һәм һөҗүмгә күчә. Безнекеләр чигенергә мәҗбүр була. Корсунь-Шевченковск районының Резино дигән авылында канкойгыч бәрелеш башлана, һәм Габдулла Рәхимов Белая Церковь госпиталендә аңына килә. Ярчык тиеп бил теткәләнгән. Аны Киевтагы госпитальгә күчерәләр, савыккач, тагын фронтка озаталар. Яраланулар була әле. Әмма ул һаман сафта кала. Җиңү көнен Чехословакия чигендә каршылый. 1946 елда Германиядән яраланган сугышчы буларак демобилизацияләнә. Яшисе гомере, ашыйсы ризыгы, эчәсе суы булгангадыр инде, Габдулла Рәхимулла улы туган ягына әйләнеп кайта. Бер телем икмәккә тилмереп яшәгән туганнары, авылдашлары белән очраша. Аларны күргәч, илдәге авырлыклар да, тәндәге җәрәхәтләр дә арткы планга күчә. Алда — матур тормышка ышаныч, тыныч елларга өмет. Ятимлектә үсеп, тылдагы авырлыкның төрлесен күргән Рәйсә исемле кыз белән гаилә корып җибәрәләр. Сугыштан соңгы чорның авырлыгын тасвирлап тору кирәк тә булмас. Гаиләдә татулык, бер-береңне ярты сүздән аңлау алдагы көннәргә өмет уята, нигезгә муллык иңдерә. Габдулла ага олайгач булса да үз белемен күтәрә. Кичке урта мәктәпне тәмамлавы турында аттестатлы була. Аннары, Буа ветеринария техникумында читтән торып укып, үзенә гомерлек белгечлек ала һәм лаеклы ялга чыкканчы терлекчелектә җаваплы хезмәт башкара. Рәхимовлар ике малай тәрбияләп үстерәләр. Робертлары Сабада эшли. Кешеләргә игелекле хезмәт күрсәтә — ясалма тешләр куя. Ә менә «Марсель кайда эшли?» дигән сорау биргәнемә үзем дә уңайсызланып киттем. Болай да күңеле тулып утырган Рәйсә апа түзмәде, үксеп елап җибәрде.

— Марсель юк шул... Яп-яшь килеш гүр иясе булды. Тыныч вакытта армиядән чирләп кайтты. Йөрәк өянәге алып китте улыбызны...

Әйе, Рәйсә апаны аңлап була. Ана кешегә газиз улын югалтудан да олы кайгы юктыр.

— Бөтен таянычыбыз Робертта, — дип сүзләрен дәвам итте ветераннар. — Килиннәребез дә бик әйбәт. Оныкларыбыз хакына яшибез.

Өйдә бераз тынлык урнашты. Сүзгә кабат Бөек Ватан сугышының II группа инвалиды Габдулла ага кушылды. Утлы елларның онытылмас хатирәләре яңадан искә төшә. Пөхтә папкага салынган рәсми кәгазьләре, I дәрәҗә Бөек Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, байтак кына медаль кенәгәләре, тыныч еллардагы хезмәт өчен бирелгән Мактау грамоталары барлана. Рәйсә апа да үзенең истәлекләр папкасын кадерләп саклый.

Ике ветеран әнә шулай көндәлек мәшәкатьләр белән матур гомер кичерәләр. Тыныч тормыш телик аларга. Башка кайгы-хәсрәт күрмәсеннәр. Капкадан чыкканда, шагыйрь Рәфыйкъ Юнысовның шигъри юллары күңелгә килде:

Сокланcын дөнья тагын бер
Безнең ныклык-түземгә.
Бу — приказ: ветераннар,
Бирешмәгез үлемгә!

*1994*

# Җир дә сорый ашарга

Җәлил абзый улының хәрби училищега китүен башта бик өнәп бетермәсә дә, Илһамның шунда укып чыгып, хәрби хезмәттә калачагына артык каршы килеп маташмады. «Бар инде теләгең булгач, өстең бөтен, тамагың тук булыр», — дип, Мөсәвәрә апа белән Җәлил абзый улларын озатып калдылар. Тик менә бөтен гомерен хәрби хезмәткә багышларга хыялланган Илһам үзе эшне «бозып» куйды. Ул училищега керү имтиханнары тапшыргач кына документларын алды да Казан авыл хуҗалыгы институтына (хәзер авыл хуҗалыгы академиясе) укырга керде. «Без бит авыл малайлары, шул авылдан китәсе

килмәгәндер инде, эти-әни дә шунда булгач, авылга кайтып эшләрмен дигән уй кергәндер башка», — дип искә ала ул елларны Илһам Җәлил улы.

Институт тәмамлап, туган Сабасына кайтты егет. Саба җиреннән беркая да китәргә теләмәде. Үзенең һөнәренә турылыклы булып калды. Әүвәл күмәк хуҗалыкта механик, аннары баш инженер булып эшләде. Авылдашлары рәис итеп сайлап куеп та ялгышмадылар. Аннары район хакимияте башлыгы урынбасары итеп билгеләнде. Илһам Кәримов бүген иң җаваплы һәм иң авыр вазифаларның берсен үти: ул — Саба районы «Агрохимсервис» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры. Күптән түгел монда авыл хуҗалыгына агрохимик хезмәт күрсәтү, ярдәмче хуҗалыкны үстерү буенча республика семинар-киңәшмәсе дә үткәрелде. Ә андый киңәшмәләрне үткәрү өчен ныклы җирлек, күрсәтерлек эшең булуы кирәк. Бу яктан Саба районы «Агрохимсервис» коллективының үрнәк итеп куярлык эшләре бар.

Акчасызлык, иртәгә нәрсә буласын белмәгән, исәп-хисап җепләре өзелгән бу заманда агрохимикларга эшләү бер дә ансат түгел. Минераль ашламасын, агулы химикатларны кайчан китереп бирерләр дә шуларның игелеген күреп кенә яшәрбез, дип кул кушырып утырсаң, көймәң комга терәлсен кот тә тор. Инде 1998 елгы уңыш җиренә һәр гектарга файдалы матдәсе 110 килограмм исәбеннән минераль ашлама кайтарганнар, күп өлешен җиргә керткәннәр. Әле һаман ташыйлар.

Аммиак суы да ясыйлар биредә. Шәмәрдәндә үзләренең базалары бар. Ул быелгы уңыш өчен 9000 тоннага якын әзерләнгән.

Саба җире ашламага бик мохтаҗ шул. Әле аның ачы туфраклы басулары да никадәр. Известь чыгару һәм аны җиргә кертү — шактый мәшәкатьле эш. Районда ике карьер эшләп тора. 1997 елны 9409 гектар җиргә 73 мең тонна известь кертелгән.

— Известьламыйча югары уңыш алып булмый, — ди Илһам Җәлил улы. — Шуңа күрә беренче чиратта көчлерәк ачылыктагы басуларга кертергә тырышабыз да. Известь кертү буенча өч звено эшли.

Агрохимикларга тагын бер бик җаваплы эш йөкләнгән. Алар чүп үләннәргә, үсемлек авыруларына, корткыч бөҗәкләргә каршы көрәш алып баралар. Агулы химикатлар сиптерден дә шуннан соң барысы да җайга салынып, дип уйлау зур ялгышлык булыр, һәр агрохимик чара уңай нәтиҗә бирергә тиеш. Чүп үлән баскан кырларда иген уңмый да уңмый. Ә басуларда кара солы шактый киң таралган. Инде хуҗалыклар кырларны эшкәртүгә заявка да биреп куйганнар. Ничек кенә бетерәсе шул зәхмәтне! Менә быел агрохимиклар тагын да нәтиҗәлерәк алымнар кулланып карарга исәпләп торалар.

Әлбәттә, иң яхшысы — комплекслы агрохимик хезмәт күрсәтү. Андый басуларда уңыш та башка шул. Узган 1997 елда 2100 гектарда шундый комплекслы хезмәт уздырылган. Быел ничек булыр? Акча юклыгы бераз кулны бәйли.

— Органик ашлама кертүне дә җайга саласы бар әле, — ди Илһам Җәлил улы.

Крестьян гомер-гомергә бакчасына тирес түккән. Хәзер генә минераль ашламалар сатып алынып кертелә башлады. Ә тирескә караш үзгәрде. Әмма Сабада аның кадерен беләләр. Ферма яннарында тирес өемнәре күп. Хуҗалыкларның аны кырга чыгарырлык чамалары гына юк. Ягулыкның һәр литры исәптә. Шуңа да агрохимиклар ярдәмгә килә. Алар көче белән быелгы уңыш җиренә 121 мең тонна органик ашлама чыгарылган. Шуның 100 мең тоннасы җиргә кертелгән. Эшнең күләмен арттыру мөмкинлеге булса да, хуҗалыклар агрохимиклар хезмәтенә түли алмыйлар. Дөрес, ачы туфраклы җирләрне известьлау тулысы белән хөкүмәт исәбенә алып барыла. Ашламага да 50 процент дотация бирелә. Менә җирнең төп сые булган тиресне басуга чыгаруда да күпмедер дәрәҗәдә үзәкләштерелгән ярдәм булса, ул үзенең уңай нәтиҗәләрен, һичшиксез, бирәчәк. Минераль ашламалар бик кыйммәт. Ярый әле, район хакимияте тырышлыгы белән узган ел да, быел да минераль ашламалар шактый күп кайтарылган, һәр хуҗалыкта саклау өчен складлар булуы да яхшы.

Билгеле, хезмәт күрсәтү күләме арта барган саен техниканың төзек эшләве бик әһәмиятле.

Илһам Җәлил улы Кәримов үзе болай ди:

— Соңгы вакытта без үзебезнең матди-техник базабызны шактый ныгыттык. Бу өлкәдә, тулаем алганда, «Татагрохимсервис» холдинг компаниясе президенты Салихҗан Минсабирович Кәлимуллин бик булыша. Акционерлык җәмгыяте техника белән тулысынча тәэмин ителгән. Быел гына да өч трактор, дүрт агулы химикат сиптергеч сатып алдык.

**— Гомумән, техника белән тәэмин ителеш, аның сакланышы ни хәлдә?** — дип сорыйбыз Илһам Кәримовтан.

— Бездә бит эш ел әйләнәсенә тукталып тормый. Шулай булгач, техника да һаман эштә. Шуңа күрә техник хезмәт күрсәтүне күз уңында тотабыз. Техник хезмәт күрсәтү пунктында иң намуслы, тырыш, үз эшен биш бармагы кебек белә торган Камил Хаҗиәхмәтов эшли. Үзебезнең ремонт бригадасы бар. Әле хуҗалыклардагы агулы химикатлар сиптерү машиналарын да үзебезгә алып килеп ремонтлап бирәбез. Гамәлдән чыгарылган иске техниканың узелларын, детальләрен саклау өчен склад кордык. Хәзер тузган детальләрне бик тиз генә алыштырып кую мөмкинлеге бар.

**— Илһам Җәлилович, техникагыз җитәрлек икән, кешеләрегез дә бик уңган, булган. Менә сез җирне ашлыйсыз. Шуның өчен тиешле әҗерен аласыз. Эшегезнең сыйфатына гарантия биреп**

**буламы?**

— Безнең һәр шоферда, һәр тракторчыда сыйфат кенәгәсе бар. Анда эшнең сыйфаты төгәл язып барыла һәм бәя куела. Шуннан чыгып өстәмә түләү бирелә. Өстәмә түләү төп хезмәт хакының 30 процентына кадәр. Аннан тыш үсемлекләрне саклау хезмәте кешеләренә бушлай биш центнер ашлык, бер йөк печән бирелә. Бозау бирергә дә исәп бар әле. Намус белән эшләгән кешедән кызганырга ярамый.

**— Ә ашлык, печән, бозауны каян аласыз?**

— Безнең ярдәмче хуҗалыгыбыз, 1700 гектар җиребез бар. Быел күрше хуҗалыктан яңадан 500 гектар җир бүлеп бирделәр. Узган ел ярдәмче хуҗалыкта һәр гектардан 46 центнер уңыш үстердек.

**— Мал-туарны күп асрыйсызмы?**

— Үзебезгә җитәрлек, әле дәүләткә дә өлеш чыгарабыз. Тапшырылган терлекнең уртача авырлыгы 420 килограммнан ким булмый. Үткән ел һәр сыердан 3890 килограмм сөт савып алган идек. Быел инде 5000 гә җиткерергә исәп. Шулай дип әйтергә моның нигезе бар. Хәзер үк инде һәр сыердан көн саен берәр пот сөт савып алына. Алдынгы терлекчеләребез Наҗия Әлмөхәммәтова белән Ирина Вәлиева дүрт айда үз группаларындагы сыерлардан 1200–1300 килограмм сөт алдылар. Терлек симертүчеләребезнең дә эшләре көйле бара. Алар һәр мөгезле эре терлекнең авырлыгын көн саен уртача 750 граммга арттыралар. Тана үстерүче Нина Викторова, үгез симертүче Бикбай Ишанов тәүлеклек үсешне бер килограммга җиткерделәр. Бездә бозаулар үзен күптән аклаган салкын ысул белән генә үстерелә. Шуңа күрә үлемгә бөтенләй юл куелмый. Бу тармакта Мәрьям Рәхимова белән Хәмдия Хәйретдинова зур тырышлык күрсәтеп эшлиләр.

**— Ике зур хуҗалыкны алып бару кыендыр ич? Ярдәмче хуҗалык төп эшкә зыян китермиме?**

— Аның үз авырлыклары бар, әлбәттә. Әмма безнең хезмәтебез турыдан-туры күмәк хуҗалыклар белән бәйле булганлыктан, килеп туган проблемаларны хәл итү җиңелләя төшә. Аннан соң ярдәмче хуҗалыкта җитештерелгән продукция төп производствоны, ягъни агрохимия тармагын алып баруда күпмедер дәрәҗәдә ярдәм дә итә. Әмма авыл хуҗалыгы продукциясенең сатып алу бәяләре куелган хезмәтебез, түккән тиребез, шулай ук промышленность товарлары, ягулык-майлау материаллары бәясе белән чагыштырганда бик түбән. Шуңа да карамастан без ит һәм сөт җитештерүне, гомумән, ярдәмче хуҗалыкны үстерүне даими игътибарда тотабыз. Бу турыда бездә узган республика семинар-киңәшмәсендә дә ассызыклап әйтеп үтелде.

Дөрес әйтә Илһам Кәримов. Аз түлиләр шул продукция өчен, бик аз. Ә халык тын да алмый эшли ярдәмче хуҗалыкта, күп кенә каралты-куралар да корып куйганнар. Мәсәлән, Урта Саба авылындагы эш урыны янәшәсенә ашлык, фураж складлары, ябык ындыр табаклары салынган. Типовой проект белән бәрәңге подвалы корыла.

Һәрнәрсәне уйлап, төбенә төшенеп хәл итәргә яратучы, заманча фикерләүче Илһам Кәримов болай дип сөйли:

— Алга таба хуҗалык исәбе нигезендә генә эшләргә туры киләчәк. Бу ни дигән сүз? Һәр тармак табыш бирергә, рентабельле эшләргә тиеш. Димәк, син үз-үзеңне туйдырырга тиеш буласың. Бу инде исәп-хисап эше югары дәрәҗәдә куелачак дигән сүз. Артык кашыклар инде ул вакытта булмаячак.

**— Салым түләтеп бик интектермиләрме соң?**

— Салым түләү — бүгенге көннең иң четерекле проблемаларыннан берсе. Аларның төрләре бик күп. Үзара исәп-хисап ясап була торганнарын җиңелрәк хәл итәбез. Мәсәлән, үзебезнең карьерда таш чыгарып, аны юл төзүчеләргә бирәбез. Алар моның исәбенә юл салымын каплыйлар. Шулай ук булган техникабызны эшләтеп тә кайбер җирле салымнарны киметәбез. Әмма, салымнарның байтагы чиста акча белән бәйле булганлыктан, түләячәк сумнарыбыз күпкә җыйнала...

Менә шулай җаен табып, киләчәкне күреп, кешеләр турында кайгыртып яшәгәнгә күрә «Агрохимсервис»ның эшләре алга бара да. Әллә сез республика семинары бер дә юкка монда үткәрелгән дип беләсезме? «Татагрохимсервис» холдинг компаниясе президенты С.Кәлимуллин, бирегә килгәч, башкаларга Саба агрохимикларын мактап сөйләгән, үрнәк итеп куйган.

Үрнәк итеп куярлык та. «Агрохимсервис»ның иң зур байлыгы — аның хезмәт сөючән, теләсә нинди һава шартларында да авыр йөкне сыкранмыйча тартып баручы кешеләре. Илһам Җәлилович кайберләренең исемнәрен атый. Известь кертүдә Тәлгат Газизҗанов, Илшат Шакиров, Рәхимҗан Исмәгыйлев, үсемлекләрне саклауда Мөдәррис Шәкүров, Илшат Касыймов, Шамил Галимов, органик ашлама чыгаруда Кәримулла Гатауллин, Мәгъфир Латыйпов, Фәрит Хәйретдинов, ремонт эшендә Рифкат Билалов, Мөхәммәтнур Сабиров, Рөстәм Каюмов коллективта үзләренең тырыш хезмәтләре белән ихтирам казанган кешеләр.

Ә «Агрохимсервис» башлыгы Илһам Кәримов үзе дә эшне оста оештыра. 1997 елда Саба игенчеләре мул уңыш үстереп алганнар икән, моңа агрохимиклардан кергән өлеш тә бик саллы. Быел да хуҗалыкларга минераль ашламаларны күп кайтардылар һәм хәзер шуны туфракка кертәләр. Чөнки җир дә, кем әйтмешли, ашарга сорый.

Агрохимикларның «Урта Саба» ярдәмче хуҗалыгында бу көннәрдә кызу эш вакыты. Игенчеләр яңа

уңышка нигез салуда район хуҗалыклары арасында лидерлык иттеләр. Аларның чәчү вакытында агротехник таләпләрен җиренә җиткереп үтәүләренә республикабыз авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры В.Васильев та уңай бәя биреп китте. Терлекчеләр дә җәйләүгә чыгарга әзерләнәләр.

Авыл эшчәннәре әнә шулай үз ярдәмчеләре — агрохимикларның булышлыгын тоеп яшиләр. Кулга-кул тотынып эшләгәндә, мул уңыш җыеп алуга өмет зур.

*1998*

# Төп нигезнең toткасы ул

Районыбызның җитмеш елдан артык тарихы булса да, аның Саба җирлегеннән чыккан төп җитәкчеләре бармак белән генә санарлык. КПСС райкомнарының беренче секретарьлары барысы да читтән китерелеп сайлатылган. Ә менә үзебезнең районнан булган шәхесләрдән Йосыф-Аланда туып үскән Мөхәммәт ага Борһанов озак еллар Кама Тамагы районы партия оешмасын җитәкләде.

Дөрес, 1990 еллардан соң хакимият башлыклары үзебезнең районнан да билгеләнә башлады. Байтак еллар Фәрит Гыйльметдин улы Гыйльмиев эшләде. Хәзер районны Рәис Нургали улы Миңнеханов җитәкли.

Соңгы елларда күрше-тирә районнарга куелган якташларыбыз да бар. Мәсәлән, Рөстәм Нургали улы Миңнеханов һәм Җәүдәт Мидхәт улы Миңнәхмәтов Биектау районында хакимлек иттеләр. Балык Бистәсе район хакимияте башлыгы булып Курсабашта үсеп, шунда белем алган Равил Гарифулла улы Хәйруллин эшли. Әле күптән түгел Арча районы хуҗасы итеп Алмаз Әмин улы Нәзиров билгеләнде. Шул уңай белән игълан ителгән указдан соң урнаштырылган биографик белешмәдә «...А.Нәзиров Арча районының Сеҗе авылында туган» диелгән иде. Бу җөмлә бик күп якташларыбызны гаҗәпләндерде. «Ничек алай? Алмаз Эзмәнеке бит, бергә үстек, бер мәктәптә укыдык», — диделәр авылдашлары.

...Хаклык бар икән бу хәбәрдә. Дөрестән дә, Әмин абый белән Закирә апа чыгышлары белән төп Эзмә авылыныкы. 1940 елда өйләнешеп, тормыш корып җибәрәләр. Олы кызлары Хаҗибә тууга, бөтен хыялларны, планлаштырылган эшләрне җимереп, сугыш башлана. Сабыен кулына тотып, бием-биата белән кала яшь, чибәр Закирә. Заманына күрә белеме дә «югары» була аның. Алар, сигез бала, Югары Утарга өч ел йөреп укып, җидееллык мәктәпне уңышлы тәмамлыйлар. Мондый «диплом»га ия булучылар ул елларда мәктәпләргә укытучы итеп билгеләнәләр. Ә Закирәне югарырак постка — авыл советы рәисе итеп сайлап куялар депутатлар. Чистайга барып, совет работниклары әзерли торган курсларны да тәмамлап кайта ул.

Сугыш чорының законнары кырыс була, билгеле. Хәзерге урта һәм яшь буын якты дөньяда яшәве белән шул дәвер каһарманнарына һәм ул елларның авыр йөген җигелеп тарткан ил кызларына бурычлы. Күп вакытлары хәрби комиссариат белән ике арада уза. Сугышка кешеләр, атлар озату, ФЗӨдән, окоп казулардан, урман чыгарулардан качып кайтканнарны эзләү, «облава» дип, төнлә тәрәзәләрне каплатып, дезертирлар качып ятмыймы дип тентүләр, караклыкларга каршы көрәшүләр, эвакуацияләнеп килүчеләрне урнаштырулар, кырык төрле салымнар, заемнар...

— Сугыш китергән хәсрәт-михнәт дәрьясын соңгы тамчысына хәтле эчтек. Ил өчен барлык авырлыкларга түзеп, сәламәтлегебезне югалттык. Без кичергәнне хәзерге буынга күрергә язмасын, һәркемгә ярап та бетеп булмагандыр. Әмма булдыра алганча авыр тормышлыларга ярдәм кулы сузарга тырыштым. Закирә апа, син булмасаң, без ачка үлгән була идек, дип хәзер дә рәхмәт әйтеп килүчеләр бар. Тормышның рәхәт өлешен Ходай олыгайган көнемә калдырган икән. Балаларның игелеген күреп яшим. Тик картым Әмингә генә озын гомер кичерергә туры килмәде — иртәрәк китте, — ди сиксән өч яшьлек ак яулыклы Закирә әби. Яше өлкән булса да, хәтере, зиһене искиткеч аның. Балаларының-оныкларының укыган елларын, нәрсә тәмамлаганнарын, медальләренең алтынмы-көмешме икәнен — һәммәсен тәфсилләп сөйли. — Хәзер оныкларым диплом күтәреп котлатырга кайталар инде, укыганнарының игелеген күрсеннәр, — дип тә өсти.

Әмин ага да күпне күрә. Сугышка чаклы авыл советы секретаре вазифасын да башкара, фронттан кайткач, хәзерләүче дә (тире җыйнаучы), урманчы да (лесник) була, колхозда да эшли. Берничә ел Саба кордонында яшәп алалар.

— Шул 1955 еллар тирәсендә Арча лесхозына караган Сеҗе тирәсендә урманчы булды Әмин, — ди аның карчыгы. — Торуын Сеҗенең үзендә тордык. Алмазны 1956 елда Чүриле бүлнисендә таптым. «Әнә калын тавыш белән елый, синеке», — диләр иде бүлмәдәш хатыннар, Алмазның тавышы килә башлагач. Кем уйлаган бит: шактый еллар узганнан соң, Саба леспромхозында атаклы урманчы Нургали Миңнеханов кул астында эшкә өйрәнеп, әтисе эшләгән урманнарны малае иңләп йөрер дип...

Әйе, аңа шул Лесхозның хуҗасы булып зур эшләр майтарырга туры килде. Фидакарь хезмәте өчен «Россия Федерациясенең атказанган урманчысы» дигән исемгә лаек булды.

Балалар, балалар... Алар һәркайсы газиз, якын ана кешегә. Сугыштан соң туган Саимәләре гомерен балаларга белем бирүгә багышлый. Биектау районының җырларда җырлана торган Әлдермеш авылын-

да укытып, «Татарстанның атказанган укытучысы» дигән исемгә лаек була. Ике күзләп көтеп алган Атласлары олы тормышка юлны үзе таба. Бала вакытта көтү көтә. Аннары Азнакайга кадәр барып эшли. Соңыннан Казанда техникум, Йошкар-Олада институт тәмамлый. Менә байтак еллар инде «ПМК Поволжская» да начальник урынбасары вазифасын алып бара.

Җитәкчеләре — авылдашы Рафис Вәлиәхмәтов белән районыбыз оешмаларына-хуҗалыкларына кулларыннан килгәнчә ярдәм итәләр. Закирә апаның тагын бер кызы да — техникум белемле Әлфиясе дә — шушы ук коллективта эшли. Әкълимә белән Роза да тормышта үз юлларын таптылар. Гомумән, Закирә әбинең балалары өчен күңеле тыныч. Кияүләре дә, киленнәре Фәрдия белән Диләрә дә эшнең тәмен, тормышның ямен таба беләләр. Һәркайсы икешәр-өчәр бала үстерә. Закирә әби бүген уналты оныгы булуы белән дә бәхетле. Ә инде оныкларыңның балаларын да күрү — һәркемгә дә насыйп булмый! Аны яратып, хөрмәт итеп:

— Әби — өйнең, төп нигезнең тоткасы ул, — диләр.

*2001*

# Районыбыз «министры»

...2004 елның 2 апреле. Җомга кичe. Мәркәзебезнең йөзек кашы булган Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында «Саба җырым — йөрәк моңым» дип исемләнгән иҗат концерты тәмамланып килә. Бәйрәм-тамашаның иң югары ноктасы — финал якынлашты. Чын артистлардан ким булмаган үзешчәннәребез махсус композиция нигезендә олы сәхнәне аллы-гөлле төсләргә күмделәр. Бу минутларда якташларыбыз һәм кунаклар, урыннарында түзеп утыра алмыйча, аягүрә басып алкышлый башладылар. Кемнәр генә юк алар арасында! Татарстанның һәм Россиянең дәүләт премияләре лауреатлары, академиклар, язучылар, рәссамнар, артистлар, гади хезмәт кешеләре, республика күләмендәге җитәкчеләр...

Отчет концерты тәмам. Тамашачылар таралырга ашыкмый. Хакимият башлыгыбыз Рәис Миңнехановка, аның урынбасары Таһир Шәрәфиевкә һәм әлеге язманың герое — мәдәният бүлеге начальнигы, олылабрак әйтсәк, «мәдәният министрыбыз» Мидхәт Хафизовка кат-кат рәхмәт әйтәләр, кулларын кысалар.

Икенче көнне иртүк редакциябезгә факстан хат килеп ирешә. Академик якташыбыз, яшьлегендә Сабадагы тынлы оркестр составында уйнаган Азат ага Әхмәдуллин юллаган аны. Хат болай дип тәмамлана: *«Кичәдән соң фикер алышуда танылган язучыбыз Туфан Миңнуллин: «Чиста эшләнгән, планлы куелган концерт сабалыларның хезмәттә генә түгел, сәнгатьтә дә алдынгы һәм сәләтле булулары турында сөйли торган күренеш; башка халыклар биюләрен дә аларга татарча тыйнаклык, сабырлык, дустанә булу билгеләрендә сеңдереп башкардылар», — диде. Кыскасы, сабалылар шәһәрдәге үз якташларына гына түгел, барлык тамашачыларга да бәйрәм бүләк иттеләр. Бу дүрт сәгатьлек якты тамаша безгә дүрт кенә түгел, берничә елга сузылачак күтәренке рух өстәде. Рәхмәт сезгә!»*

Әйе, 250 гә якын үзешчәннәребез олы сәхнәдә «ут уйнатып» кайттылар ул кичнe. Әмма Казанны «яулау» өчен күпме тырышлык сарыф ителгәнен, өзлексез репетицияләр үткәрелгәнен, зәвыклы итеп сәхнә костюмнары әзерләнгәнен бу тамашаны оештыручылар үзләре генә белә. Әлеге имтиханга аяк алдан киенелде, билгеле. Аның «генеральная репетиция» дигәне дә, Арча һәм Кукмара районнары мәдәният йортларында узып, күршеләребез тарафыннан югары бәяләнгән иде. Мари Республикасының Йошкар-Ола шәһәрендә һәм Бәрәңге районы үзәгендә булган тематик концертлар да татар диаспорасы күңеленә хуш килде.

Үзебездә дә өр-яңа чараларның әледән-әле булып торуы күпләргә мәгълүм. Мәсәлән, хакимият башлыгы призына 2004 елның 30 апрелендә узган «Уйныйбыз да, җырлыйбыз да, гармун кулларыбызда» дип исемләнгән баянга җырлаучылар бәйгесе дә үзенчәлекле тамаша булды. Район үзешчәннәре Томск һәм Ижау калалары сабантуйларында чыгыш ясап та бик күп милләттәшләребезне сөендерделәр.

Гомумән, соңгы елларда районда мәдәни-спорт чараларының яңа күтәрелеш алуын һәр сабалы күреп-белеп торадыр. Ул чараларны санап чыгу һич мөмкин түгел. Әмма күп халык катнашында узган крестьян (фермер) хуҗалыкларының «Яңарыш авазлары», оешма-предприятиеләрнең «Бар яраткан эшем — һөнәрем, мул тормышта яши төбәгем», җирле үзидарәләрнең Бөек Җиңүнең 60 еллыгына багышланган «Батырларга лаек бул!» бәйгеләре, «Шаяннар һәм тапкырлар клубы» ярышлары, җәй буе дәвам итә торган «Саба кичләре» тамашаларын телгә алмасак, дөрес булмас. Әлбәттә, бу һәм башка шушындый йөзләгән чараларның үзәгендә район мәдәният бүлеге җитәкчесе Мидхәт Гата улы Хафизов булуын беркем дә инкарь итә алмас. Әле бит дөнья уйнап-көлеп, җырлап-биеп кенә бармый. Ул — барлык мәдәният йортларының, китапханәләрнең матди-техник базасын ныгыту турында да төп кайгыртучы. Соңгы елларда район хакимияте, Татарстан Мәдәният министрлыгы ярдәме белән 1240 урын-

га исәпләнгән 7 мәдәният йорты файдалануга тапшырылды, 4 клуб ремонтланды, 43 учреждениегә газ кертелде, 15 мәдәният учагына капиталь ремонт (20 миллион сумлык) уздырылды, 9 миллионга сәхнә костюмнары тектерелде, музыкаль инструментлар һәм техник кирәк-яраклар алынды. Кадрларның сыйфат составы яхшырды. Районда һәвәскәрләр иҗатын үстерүдә, матди-техник базаны ныгытуда бүлек начальнигының өлеше, тырышлыгы зур, билгеле. Чөнки, кайда гына эшләсә дә, үз эшенә җанын бирә торган кеше ул. Аның тагын бер шәп сыйфаты бар: кешеләр белән уртак тел таба белә. Әйдәгез, Мидхәт Хафизовның тәрҗемәи хәлен күзаллап үтик әле.

...Заманында перспективасызлар исемлегенә кертелсә дә, матур табигатьле Көек авылындагы гади крестьяннар — Миңкамал белән Гата гаиләсендә туа ул. Урта мәктәпне тәмамлагач, Казан авыл хуҗалыгы институтының механика бүлегенә укырга керә. Әмма студент булып югары белем алырга насыйп булмый (ул бу теләгенә 2004 елда гына ирешә — Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясенең икътисад бүлеген тәмамлый). Бәхетсезлеккә каршы, шул җәйне Чистай совхоз-техникумыннан диплом алып кайтып килүче уртанчы абыйсы Әнвәр Казанда поездга бәрелеп үлә.

Шушы тетрәндергеч вакыйгадан соң барлык туганнар утырып уйлашалар да төпчек малайны туган авылында, ата-ана нигезендә калдырырга карар кылалар. Мидхәт институттан аттестатын кире ала һәм, район хәрби комиссариатына барып, шоферлыкка укытуларын сорый. Монда да колач җәеп тормыйлар аңа. Шоферлыкка сигез класс кына белем кирәк икән... Әмма үҗәт малай, ничек итсә итә, максатына ирешә. Совет Армиясенә шофер булып китә. Аннан кайткач, бик иске «Беларусь» тракторына утырта аны данлыклы колхоз рәисе Нургаян абыйсы Мөхәммәтшин. Аннары егерме ел йөргән «ГАЗ-51» машинасын бирә. Ул вакыттагы сөенүләрен күрсәгез иде сез самими егетнең! Машина кадәр машина белән идарә ит әле син техникага кытлык заманда!

Җай белән, тәртипле йөрүче, техникасын карап тотучы авылдашын шул чордагы зур хуҗалыкның — XXII партсъезд исемендәге колхозның баш белгече, Татарстан Республикасының атказанган зоотехнигы Яхъя Фазлый улы үзенә шофер булырга күндерә көннәрдән бер көнне.

Егетнең өметле икәнен тиз күрәләр идарәдә һәм Кызыл Мишә бригадасын җитәкләргә тәкъдим ясыйлар. Ул вакытта әле Көектә дә 400 баш эре мөгезле яшь терлек була. Кызыл Мишәне әйткән дә юк. Кыскасы, таләпчән, үзе дә тынгылык белми, башкаларны да тик тотмый торган Нургаян Вәлишевич мәктәбен үтә Мидхәт.

Заманында илебезнең иң зур бүләген — КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының күчмә Кызыл Байрагын яулаган колхозның рәисе иртәнге нәрәтне ел тәүлеге сәгать дүрттә (җәй көне генә булса да җиткән бит инде!) өеннән телефон аша бирә... Урта звено җитәкчеләре аны бригада йортына килеп тыңлый. Шулай итеп, Мидхәткә әче таңнан Көектән көн саен Кызыл Мишәгә җәяүләп чыгарга кирәк була.

— Һәр бригадага берәр сәгать эш куша иде Нургаян абый, — дип яңадан искә ала М.Хафизов. — Әгәр дә сиңа беренче булып, ягъни дүрттә нәрәт бирелсә, бик бәхетле булып чыгып китәсең. Алдагы көндә оештырган эшең белән рәис күңеленә хуш килмәсәң, сиңа чират сәгать алтыда гына җитә.

Шулай итеп, өч ел гомер уза. Тимершык авыл советына рәис кирәк була берзаман. Юлдан җәяүләп барган вакытта машинасына утыртып алып китә Мидхәт Гата улын Нургаян ага.

— Депутатлар җыелды. Сине көтәләр, — ди РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре.

— Әти-әни, Әнисә белән киңәшим, — дип карый рәислеккә кандидат.

— Башта сайлыйк әле. Барып чыкса, кайтып киңәшләшерсең, — дип сүзне кыска тота аксакал.

Менә шул сайланудан тоташ унҗиде ел эшли Мидхәт Гатович иң зур авыл советының рәисе булып. Бу чорда эре хуҗалыклар бүленә башлый, һәр авыл бер колхозга әйләнә. Кыскасы, унҗиде рәис белән уртак тел табарга тиеш була җирле власть хуҗасы.

Аның өстенә сөт, ит, йон, йомырка, тире җыю планнары да чәчәк аткан еллар була бу. Бәрәңге сатып алу заданиесе генә дә йөз сиксән биш тонна итеп җиткерелә. Кибетче белән өй саен сетка таратып йөриләр болар. Сөтне, башка авылларга чыгып, тере акчага җыйган вакытлары да була тәҗрибәле рәиснең. Аның өстенә мәгариф, сәүдә, медицина, мәдәният кебек тармакларны да күз уңында тотарга кирәк бит әле. Яңа объектлар төзелү дәвам итә, мәчетләр ачыла башлый. Тимершыкта балалар бакчасы, Кызыл Мишәдә мәктәп салына. Миңгәрдәге стенасы гына өелгән клуб өч айда сафка бастырыла. Бу ашыгычлык якташыбыз, СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеровның иҗат концерты белән бәйле була. Нәкъ шушы урында тарихка кереп калган мәзәк хәлне искә төшерү дә зыян итмәс.

...Бу көннәрдә Мидхәт Хафизов өенә кайтып керми. Шуңа күрә әтисе Гатаулла абзый авыл картлары арасында:

— Малай тәмам икенче Горбачев булды инде, — дип зарланып алган.

— Ник алай дисең? — дип аптырап сораганнар авылдашлары.

— Горбачев СССРны тараткан иде. Малайның да күренгәне юк, өйне таратырга маташа, ахры, — дигән ул.

Шушы вакыйгалардан соң өч ел үткәч, район мәдәният бүлеге мөдире итеп күчерелә Тимершык авыл советы рәисе. Дөресрәге, аңа «Йә монда киләсең, йә авыл советыннан китәсең!» дигән таләп куя

шул вакыттагы район хуҗасы.

Дөресен әйткәндә, тавык чүпләп бетерә торган түгел бу тармактагы эшне. Чөнки бер генә чара да мәдәният хезмәткәрләреннән башка үтми. Ә бәйрәмнәр, төрле кичәләр ел тәүлеге дәвам итә. Бигрәк тә соңгы елларның кышкы айларында күп булды андый тамашалар.

— Атнаның дүрт көне кичке тамашаларда үтте. Шимбә-якшәмбеләрдә дә нииндидер чара узмыйча калмый, — дип фикерен дәвам итте Мидхәт Гата улы. — Төп вазифаңны җиренә җиткереп башкару өчен гаиләңнең тәртиптә, ярдәмчел булуы кирәк, билгеле. Малайлар үсеп җитте. Ришат институттан соң белгечлеге буенча эшли. Альмир — II курста. Фидан урта мәктәп тәмамлый. Җәмәгатем Әнисә белән аңлашып гомер итәбез. Ярдәмчел, кешелекле ул. Башта әнине карап-тәрбияләп соңгы юлга озатты. Әти әнидән соң унөч ел яшәде. Гомумән, кайгыны күп күрдек без. Бертуган өч абыем һәм бер апам бу фани дөньядан бакыйлыкка вакытсыз киттеләр. Авыр туфраклары җиңел булсын...

Әнисә дә ирен бик хөрмәт итеп яши шул. Аның бер сөйләшкәндәге: «Әнкәй Мидхәт кебек бик акыллы иде», — дигән җөмләсе күңелгә сеңеп калган. Мондый сүзләрне бар хатын-кыз да әйтә алмый.

Менә шулай итеп, үзенең яшәешен халык белән эшләүгә багышлаган Мидхәт Гата улы да илленче язын каршылады. Аңа алга таба да эшендә һәм тормышында эшләренең гел уң булуын теләп, әлеге язманы бөек шагыйребез Г.Тукай сүзләре белән тәмамлыйсы килә: «Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!»

*2003*

# Туган як моңнары

Туган илдән киткән сандугачлар
Чит җирләрдә сайрый алмыйлар...

*И.Юзеев*

Әлеге юлларны укыганда, күз алдыма Вилорик Вәлиуллин килеп баса. Ул күптәнге танышым. Моннан 20–25 еллар элек — Шәмәрдән промкомбинаты клубында, аннан район мәдәният йортында эшләгәндә — аны күп мәртәбәләр тамашачыга тәкъдим итәргә туры килгән иде. «Сезнең каршыгызда үзешчәннәрнең Бөтенроссия смотры лауреаты Вилорик Вәлиуллин!» — диюгә (исеме дә үзенә генә хас бит — ул аны «Владимир Ильич Ленин освободил рабочих и крестьян» дигән җөмләдәге сүзләрнең баш хәрефләреннән торганын аңлатып күрсәтергә ярата), зал алкышларга күмелә иде. Менә ничә дистә еллар инде, сәхнә артыннан ук баянда уйный-уйный чыгып, тамашачыларның күңел дәрьяларын тибрәлдерә, йөрәкләрен әсир итә ул.

Аның әтисе Басыйр янгынга каршы көрәш инспекциясендә эшли. Ул заманның тәртибе буенча, аларны бер районнан икенчесенә күчереп йөртәләр. Менә алар элеккеге Кызыл Йолдыз районында (үзәге Котлы Бөкәш авылы). Шуның Тәрберде Чаллысы дигән авылында Басыйр белән Мәрьямбану гаиләсендә өч яшьлек кызлары Гөлинәдән соң орчык кадәр малай туа. Вилорикка дүрт яшь чамасы булгач, әтисе аңа унике телле тальян гармун алып кайта. Дөрес, әти кеше, ватып бетерер дип, башта тальянны «матурлык өчен» өстәлдә генә тота. Вилорикның аңа кулы тиз җитә, капшап кына калмый, төрле яклап тарткалый да башлый. Хикмәтле тавыш чыгара бит! Шуннан соң әтиләре, эшкә киткән вакытта, гармунны яшерә торган булалар. Булачак музыкант мыштым гына тальянның кая куелуын карап тора да аулак вакытта «сайрата» башлый. Өлкәннәр эштән кайтыр вакыт җиткәч, гармунны урынына куя.

...Бу гармунны Вилорик әле дә үзенә мәңгелек профессия сайларга ярдәм итүче ядкарь итеп саклый. Дүртенче класста укыганда, ул инде ике рәтле хромкага күчә. 1956 елда Вәлиуллиннарны Тәкәнеш районына җибәрәләр. Вилорик биредә баянга өйрәнә. «Менә шуннан бирле баянчы мин, — дип искә төшерә ул. — Иллегә җиткәнче уйнадым, тагын күпме уйнарга язгандыр...»

Аулак өйдә дә, сөрәндә дә, сәхнәдә дә, фермаларда да чыгыш ясый баянчы. Кайбер көйләрне үзе эшкәртә, аларның аһәңен эзли, төрле вариацияләр таба. Кыскасы, моң белән халык күңеленә үтеп керә белә. Ул гади тамашачыны да, куанычлы йә хәсрәтле кешене дә, зур-зур җитәкчеләрне дә бирелеп тыңларга мәҗбүр итә. Җитәкчеләр дигәннән, Вилорик озак еллар партия өлкә комитетының беренче секретаре булып эшләгән Фикрәт Әхмәтҗан улы Табеевны еш искә ала:

— Хәзер элеккеге башлыклар турында төрлечә сөйлиләр. Әмма мин Табеевны татар музыкасын яратучы кеше буларак хөрмәт итәм. «Вилорик, сине улымның туена чакырырмын әле», — диде ул берчакны. Һәм сүзендә торды.

Вилорик аерым башкаручы гына түгел, оста аккомпаниатор да. Бу җиңел эш түгел. Чөнки һәр җырчының үз характеры, үз тавышы, җырны үзенчә башкарырга омтылышы бар. Шуны тотып ала белергә кирәк.

Вилорикның иҗат юлында истәлекле вакыйгалар күп. Ә менә 1964 ел аның күңелендә, җырдагыча

әйтсәк, каелып язылган... Үзешчәннәрнең Бөтенроссия смотры бара. Башта талантларны Казанның Киров исемендәге мәдәният йортында «иләк аша» үткәрәләр. Ә инде Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрындагы йомгаклау концертында катнашу бәхете В.Вәлиуллинга гына тия. Ул анда якташыбыз Хөснул Вәлиуллинның «Сау булыгыз, дуслар» вальсын башкара һәм лауреат исемен яулап ала.

...Аннан соң утыз елдан артык вакыт узды инде. Күп смотрлар, конкурслар, «Уйнагыз, гармуннар» фестивальләре үтте. Вилорик аларның барысында да катнашты. Атаклы гармунчы Фәйзулла Туишев исемендәге бүләкне дә алды, бик күп мәртәбәләр лауреат булды.

Вилорикның концерт гармуннары байтак. Ә тальянының тавышын 1978 елда, район үзешчәннәре белән баргач, вьетнамлылар да ошаткан иде. В.Вәлиуллин гармуннарының берсе дә үзе уйнамый, шулар аша чишмә чыңлавын да, кошлар сайравын да, чәчәк һәм үләннәрнең серләшкәнен дә, таң әтәче кычкырганын да халыкка баянчы үзе җиткерә. Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Вилорик Вәлиуллин тамашачылар алкышы астында бик еш елмая. Алга таба да аңа көчле кул чабулар юлдаш булсын иде!

*1992*

# Картаямыни соң йөрәк!..

Рәйсә Имамиева... Аның исем-фамилиясен ишетүгә, күпьяклы, көчле ихтыярлы, максатына омтылышлы, күңел җылысын, вакытын, көчен кызганмый торган талант иясе күзаллана. Балалык еллары коточкыч сугыш елларына туры килә сәнгатькәрнең. Әтисез үсү, хәерчелек, ачлык, балалар йорты... Болар барысы да Рәйсә Билал кызының башыннан үткән. Кыскасы, түбәннән, тормышның төбеннән, җан ачылары белән тырмаша-тырмаша күтәрелгән шәхес ул.

Дәһшәтле сугыш елларын, яшьлеге турында «Булмады балачагым» дип исемләнгән шигырендә бик гыйбрәтле итеп сурәтли Рәйсә.

...Тумышы белән Сауш авылыннан булган Билал абый, Бөек Ватан сугышы башлангач, үзе фронтка китәргә тиеш булу сәбәпле, гаиләсен Украинаның Донецк шәһәреннән туган ягына кайтарып җибәрә. Елый-елый саубуллашкач, өч кызы: Әнисә, Фәния, Рәйсәсе белән әниләре Вәсимәнең авылына — Елышка юл тоталар. Ул вакытта әле сабыйлар әтиләреннән, җәмәгате үзенең сөекле иреннән мәңгелеккә аерылулары икәнен, сугыш бетәсе язны «хәбәрсез югалды» дигән кайгылы кәгазь киләсен белмиләр. Чөнки күңел гел яхшылыкка омтылучан була бит.

Вәсимә ханымның Донбасска киткәнче укытучы булып эшләгәнен белеп, район мәгариф бүлегенә кат-кат чакырталар. Шулай итеп, Сабада, Казанчы Бигәнәй авылларында мөгаллимәлек итәргә туры килә аңа. Район мәгариф бүлеге мөдире Федор Степанов, тамаклары тук булсын дип, сабыйларын Шекшедәге балалар йортына урнаштырырга ярдәм итә. Биредә булуын уфтанып искә алмый Рәйсә. Менә шушында музыка белән кызыксына башлый ул. Сабыйлар йортына бүләк ителгән гармунга күзе төшә аның. Кулларына тотып, телләренә баскалап та карагач, күңелендә сихри моң, әйтеп бетерә алмый торган канәгатьләнү һәм илһамлану хисләре сизә башлый үзендә.

Шекшедән башлангыч мәктәпне тәмамлап кайта ул Елыш авылына. Яшел чирәмле урамнары, киң болыннары, куаклык каплаган биек тау битләре, заманында волость үзәге дә булып торган бай тарихлы авыл кабат каршы ала аны.

Әмма... Әнә шул «әмма»лар азрак булсын иде дә бит. Тормыш үзенекен итә. Үз вакытында белем алырга туры килми талантлы кызга. Дөрестән дә, балачагы хәсрәтсез булмый аның. Сигезенче классны да тәмамламыйча хезмәт юлын башлый. Башта җәйге каникул вакытында колхозның төрле эшенә йөри, төзелешкә дә тартыла. Аннары җиң сызганып сыерлар сава, таналар, бозаулар, тавыклар карый. Кичләрен ихлас күңелле кыз үзешчән сәнгатьтә катнаша.

Яшьлек хыялларына уралып яши, сөю-сөелү дә читләтеп үтми авылның җырга-моңга, биюгә, нәфис сүзгә оста, шигырь язарга хирыс кызын. Әмма күңеле дөреслеккә, фәкать гаделлеккә омтылу, рәнҗетелү-кыерсытуларны кичермәү, принципиальлек мәсьәләләре туган авылын ташлап китәргә мәҗбүр итә. Магнитогорск шәһәренә барып урнашып, төзүче һөнәрен үзләштерә. Аннары матур-матур йортлар салуда катнаша. Эшче яшьләрнең кичке урта мәктәбендә укып, кулына аттестат ала. Аннары, балачак һәм яшьлек хыялларын тормышка ашыру өчен, туган Татарстанына кайтып, Алабуга культура-агарту училищесының көндезге бүлегенә укырга керә. Белемнең кирәген һәм тәмен аңлаган, тормышның ачысын-төчесен күргән Рәйсә югары уку йортының халык уен кораллары оркестры җитәкчеләре әзерләү бүлеген тәмамлый. «Кызыл диплом» ала. Аны ул чордагы бүленеш буенча Әгерҗе районында, халыкчан итеп әйтсәк, биш куллап каршы алалар.

Әмма... Тагын «әмма»... Аның күңеленнән туган ягы, табигатьнең гүзәл кочагы, искиткеч бай,

гыйбрәтле тарихы булган Елыш авылында яшәп ятучы газизе, музыкаль күңелле, мөнәҗәтләр чыгару остасы булган әнисе бер генә минутка да йөрәк түреннән чыкмый. Аңа якынрак җирдә яшәп, терәк буласы килә аның.

Бер кайтуында ул (1972 елның җәе) район мәдәният бүлеге мөдире Госман Гариф улы янына сугыласы итә. Кадрларның кадерен белә һәм хөрмәт итә торган җитәкченең җылы итеп «кодалавы», туган ягы халкына хезмәт итү теләге белән тәңгәл килеп, алдагы язмышын уңай якка хәл итә дә куя...

Шулай итеп, без, бу юлларның авторы, бер җәйдә бер коллективта эшли башладык. Мин, апрель аенда гына армиядән кайтып, шул ук Госман абый Гариповның Байлангар авылыннан (Кукмара районы) эзләтеп, табып-чакыртып китерүе буенча автоклуб мөдире һәм драма түгәрәге җитәкчесе булып эшли генә башлаган идем. Шуңа күрә Рәйсә Имамиеваның утыз биш елга якынлашкан иҗади хезмәте белән турыдан-туры таныш мин. И бу гомер дигәнең, искән җилдәй шундый тиз уза икән ул...

Туган җиренә кайтуның беренче көннәреннән ул, мәдәният йортының сәхнәсе артындагы бүлмәдәге тузанга батып яткан балалайкаларны, думбраларны, мандолиналарны җыйнап, кылларын тарттырырга, ремонтларга, ябыштырырга тотынды. Аннары Саба урта мәктәбеннән утызлап баланы сайлап алып, күнекмәләр дә бирә башлады. Озак та үтмәде, әлеге ансамбль, халык алдында уңышлы чыгыш ясап, тамашачыларны сөендерде һәм озакка сузылган көчле алкышлар белән бүләкләнде. Аларның уйнавына җырчылар да бик теләп кушылдылар.

Әйе, бик күп көчен салды Рәйсә Билал кызы районда үзешчән сәнгатьне күтәрү өчен. Баянында да уйнады, халык хорына дирижерлык та итте, язын-көзен игенчеләр-терлекчеләр янында йөри торган агитбригаданың сәнгать җитәкчесе булды, башта җырчы хатын-кызларның «Лира», тора-бара ветераннарның «Нәүрүз» фольклор ансамбльләрен оештырып җибәрде.

1979 елда ук район мәдәният йорты каршында оештырылган «Ләйсән» агитбригадасы, республика смотр-конкурсында җиңеп чыгып, Вьетнамга туристлык сәяхәтенә бару хокукын яулаган икән, монда да язмабыз героеның олы иҗат фантазиясе, лаеклы өлеше бар.

Район мәдәният йорты методик кабинеты җитәкчесе буларак та ул утыз ел буе авыл клубларына күпьяклы ярдәм күрсәтә. Аларга һәрдаим кулланмалар әзерли, район үзәгендә үткән театраль кичәләр, Яңа ел бал-маскарадлары, слетлар ул язган сценарийлар нигезендә үтә.

Берара район газетасы каршындагы «Мишә дулкыннары» әдәби түгәрәгенә дә җитәкчелек итте Рәйсә ханым. Ул елларда берләшмәнең музыка секциясе төзелде. Шуннан соң үзешчән композиторлар берләшмә әгъзаларының шигырьләренә ешрак мөрәҗәгать итә башладылар. Берләшмә җитәкчесе үзе, Рөстәм Зарипов, Фәннүр Галимов, Таһир Исмәгыйлев, Тәслимә Низамиева, Гөлнур Мохтарова, аталы-уллы Нәкыйп һәм Сәйдәш Солтановлар, Сания Таһирова һәм башкалар бик күп җырлар яздылар. Олы Шыңар авылында яшәп иҗат итүче Фәннүр Галимовның «Хәерле көн телим» дигән җыентыгы да дөнья күрде. Рәйсә Имамиеваның «Язгы сагыш», «Казлар», «Су сип, иркәм, гөлләремә», «Яннарымда син бар ич», «Соң түгел», «Әй, без идек» дигән җырларын үзешчәннәр генә түгел, Римма Ибраһимова, Айдар Фәйзерахманов, Зәйнәп Фәрхетдинова, Хәмдүнә Тимергалиева, Габделфәт Сафин, Фердинант Сәләхов, Рисәнә Мостафина, Лилия Мансурова кебек сәхнә йолдызлары да бик яратып башкаралар.

Яшьтән поэзия җене кагылган авторның поэмалары (мәсәлән, «Айгөл», «Илдәнур»), бәетләре, мөнәҗәтләре, шигырьләре һәм публицистикасы да сокланырлык дәрәҗәдә тирән фәлсәфи фикергә ия. Аның әсәрләре укучы йөрәгенә сеңә, уйландыра, күңеленә гамь сала. Үзенең дөньяга карашын яшьлек, мәхәббәт, туган җир, халкыбыз язмышы һәм Аналарга хөрмәт аша белдерә ул. Татар авылына, аның фаҗигале язмышына әледән-әле әйләнеп кайта.

Шуңа күрә Рәйсә Имамиева, нәрсә язса да, «авыл тыкрыкларына һәм урамнарына» сугылмыйча калмый. Бер үк вакытта йөрәк түреннән, бәгыреннән саркып чыккан хисләрен, уй-хыялларны, борчу-мәшәкатьләрне, кинаяле көлүләрне оста итеп куллана белә. Кыскасы, аның иҗаты белән тормыш юлы тәңгәл килә. Илһамланып яшәгәнгә күрә, йөрәге һаман канатлана, күңеле җырлый Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәренең.

Зур тормыш тәҗрибәсен туплаган автор менә үзенең тәүге китабын чыгарды. Бу тупланманың дөнья күрүе өчен ул иң беренче чиратта иҗат кешеләрен хөрмәт итә торган хакимият башлыгыбыз Рәис Нургали улы Миңнехановка рәхмәтле. Рәйсә Билал кызы киләчәктә дә укучыларын үзенең күңел ялкыны белән ныграк җылытыр, керләнгән җаннарны сафландырырлык матур җырлары, шигъри сәйләннәре белән шатландырыр дип өметләнәбез, аңа иҗади уңышлар, йөрәгенең мәңге картаймавын телибез.

*2003*

# Үзе композитор, үзе шагыйрә

Саба туфрагының талантларга бай икәне бөтен республикабызга мәгълүм.

Буа районында чыга торган «Байрак» газетасы редакциясендә якташыбыз Тәслимә Низами кызы Шәрәфетдинова эшли. Ул — Туктар авылы кызы. Шигърияткә, музыкага гашыйк. Моннан берничә ел элек Тәслимәнең иҗат кичәсен Буаның үзендә олылап үткәрделәр. Әле күптән түгел ул, районыбызга

кайтып, туган авылы Туктарда, шулай ук Килдебәктә һәм Сабада концертлар биреп китте. Һәркайда алкышлар мул булды. Шулай булмыйча мөмкин дә түгел, чөнки Тәслимәнең көйләре, шигырьләре газиз туган якка, аның матур табигатенә, үз төбәгенең алтын куллы кешеләренә багышланган. Тәслимә һәвәскәр композиторлар фестивалендә лауреат булды, аның талантын дәрәҗәле комиссия дөрес бәяләде. «Кара алтын» дип исемләнгән конкурста да җиңеп чыкты. Тәслимәнең концерт программасын караганнан соң, аның талантлы икәненә тагын бер мәртәбә чын күңелең белән инанасың.

...Әнә иҗат кичәсен алып баручы нәфис сүз остасы Кәүсәрия Әхмәтова автор турында сөйләп, туган якка багышланган шигырьләрен матур итеп укый. Моңлы тавышы белән тамашачыларны әсир иткән Айрат Усманов Саба турындагы җырны башкаргач, зал алкышларга күмелде. Тәслимә Шәрәфетдинованың сүзләрен дә, көен дә үзе язган җырлары тамашачы тарафыннан аеруча җылы кабул ителде. Алар рәтенә «Йөрәгемдә — туган авылым», «Яңа ел теләге», «Бишек көе», «Тау кызы», «Ялгызлык», «Бәхет кошы» кебек иҗат җимешләрен кертеп була. Тәслимә шулай ук танылган шагыйрьләр Ренат Харис, Фирая Зыятдинова, Динә Камалетдинова сүзләренә дә байтак көйләр язган.

Ә инде авторның сәхнәгә тугыз яшьлек улы Илшат чыккач, башта залда тынлык урнашты. Сүзен дә, көен дә әнисе иҗат иткән «Минем песи», «Әти, машина ал», «Курчакларым» дигән җырлар ритмына соңыннан бердәм кул чабулар кушылды.

Тәслимә үзе «Хыялымда яшәр кешем син», «Һинд кызы булмасам да», «Ләйсән яңгыр» дигән җырларны яратып башкарды. Соңгысы халыкка аеруча ошады.

Буа сәнгать мәктәбе укытучысы Людмила Кириллова куйган биюләр якташыбызның иҗат программасын тулыландырды.

Тәслимә Шәрәфетдинова концертын карагач, башка төбәкләрдә яшәп иҗат итүче талантларыбыз белән чын күңелдән горурланып куясың. Аңа алга таба да зур уңышлар теләп, туган як турында яңадан-яңа әсәрләр иҗат итүен көтәбез.

*1995*

# Сәламәт һәм бәхетле булыгыз!

Күптән түгел Урта Ныртыда шагыйрь Рәниф Шәриповка багышланган гаҗәеп матур кичә булды. Ул үзе Кукмара районының Чокырча (Аман-Оштырма) авылында туса да, әнисе чыгышы белән шушы җирлектән булган икән. Шуңа күрә Урта Нырты тарихын өйрәнә торган фидакарь җан Ханзөфәр Сәфәргалиев авылдашларын авыр язмышлы шагыйрь белән якыннан таныштырырга ниятләгән һәм Рәниф Шәрипов белән Сабада очрашу оештырган, «Саба дулкыннары» телерадиокомпаниясенә һәм Кукмара районы хакимиятенә мөрәҗәгать иткән. Бу тәкъдимне берсүзсез кабул иткән күршеләребездән биш кешелек делегация килде ул көнне. Авыл клубы халык белән тулган иде.

Кичәгә Завод-Нырты, Урта Нырты мәктәпләре әдәбият сөючеләре дә ныклап әзерләнгәннәр, авторның шигырьләрен өйрәнгәннәр.

Кем соң ул Рәниф Шәрипов? 1950 елда туа ул. Кечкенәдән тома ятим кала һәм Арча районының Субаш-Аты авылындагы балалар йортында тәрбияләнә. Шунда урта белем алганнан соң, сәләтле егет Казан химия-технология институтына укырга керә. Аннары Төньяк диңгез флотына хәрби хезмәткә алына ул. Шунда, корабның сигналчылар отделениесе командиры буларак, аңа тәүлекнең күп өлешен күперчектә, төрле яктан өскә су бәреп торган салкын дулкыннар арасында үткәрергә туры килә.

Тормыш авырлыкларына баш иməскә күнексә дә, егет табигать кырыслыгына каршы тора алмый: бик каты салкын тидереп, гәүдәсе тораташ булыпката, фәкать ике кулы гына хәрәкәтләнүен дәвам итә. Кыскасы, урын өстенә ава Рәниф. Шушындый авыр вакытта аңа әнисе урынына калган табибә Люция апасы ярдәм кулын суза. Аны яшь баланы карагандай тәрбияли башлый. Бер үк вакытта Рәнифнең күңеле әдәбиятка омтыла. Күп укый, ә үзендә туган уй-фикерләрен дөньяга чыгара башлый. Тора-бара язмыш сынауларын җиңә белүче Н.Островский, Ф.Яруллин кебек көчле рухлылар сафына баса һәм берсеннән-берсе матур шигырьләр һәм поэмалар иҗат итә. Хәзерге вакытта ул — биш китап авторы. Аның «Тәрәзәдәге утлар», «Ян, учагым!», «Күк һәм күңел йолдызлары», «Йорт иясе» дип исемләнгән җыентыклары үз укучыларын тиз тапты. Рәнифнең әсәрләрендә туган якка, аның табигатенә, игелекле кешеләренә, анага мәдхия җырлана, тормыш юлында очраган якын кешеләрен сагыну, юксыну хисенә дә, матурлык, кешелеклелек, вөҗдан, намус төшенчәләренә дә төп урын бирелә. Бигрәк тә үзе туган һәм тәрбияләнгән төбәкләргә дан җырлый шагыйрь.

Баскычлардан йөгереп менәр идем...
Вокзал һаман балкып торамы?
Бормалымы, якты елга кебек,
Кукмараның үзәк урамы?! —

дип искә ала Рәниф. Аның «Соңгы сәлам» шигыреннән дә өзек китереп үтик:

Субаш-Аты, Субаш-Аты!
Назлы авыл, ямьле авыл!
Язгы чәчәкләрең белән
Алдың күңелемнең явын.
Туган түгел, үги авыл...
Кимсетмәде Субаш-Аты,
Йөзләп идек, күпсенмәде.
Яраларга кагылмады,
Күп сорашып төпченмәде.
Безнең өчен оекбашлар
Бәйләделәр аналары...
...Юк, кимсетмәс Субаш-Аты,
Йөзләп кайтсак та күпсенмәс.
Онытса да күбебезне,
«Детдум» дисәң, күп төпченмәс...

Җыр-музыка, шигырь һәм сөйләүләр белән үрелеп барды бу кичә. Рәниф Шәриповның остазы, танылган әдип, артист, режиссер Рабит Батулланың чыгышын, Рәнифнең бертуган апасы Люциянең җырлавын, Саба радиосы дикторы Дамир Фәсиевнең шигырьләр укуын һәркем дулкынлану белән тыңлады. Шагыйрь әнисенең ахирәт дусты Мөгаллимә әбинең дә әйтер сүзе бар иде. «Саба дулкыннары» телерадиокомпаниясе генераль директоры Фоат Әхмәтшин, Завод-Ныргы урта мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы Рушания Хафизова, Олы Ныргы җирле үзидарәсе советы рәисе Илфат Шакиров, кичә героеның авылдашлары Ханзөфәр Сәфәргалиев, Рәхимҗан Галимҗанов һәм башкаларның чыгышларыннан соң, очрашуны алып баручы Әлфия Мөбарәкова сүзне Рәниф Шәриповның үзенә бирде. Зал тып-тын булып калды. Башта сәхнәдән шигъри юллар агылды, аннары көчле рухлы шагыйрь сүзен болай дип тәмамлады:

— Миңа тормыш бүләк иткән әниемнең туган авылын бик күрәсем килә иде. Аның «Чиратнай» дип сөйләгәне бүгенгедәй хәтеремдә. Мине газиз анамның кендек каны тамган туфракка алып кайтканыгыз, минем иҗатыма олы бәя биргәнегез өчен һәммәгезгә дә Алланың рәхмәте яусын! Рәхәт яшәгез, сәламәт һәм бәхетле булыгыз!

Икенче көнне шушындый ук җылы очрашу Завод-Ныргы урта мәктәбендә дә оештырылды.

*2002*

# Тәкъдире шундый булгач

«Мин юбилярны фәләненче елдан беләм», — дип сүз башлыйбыз нинди дә булса шәхесне хөрмәтләү кичәсендәге чыгышны. Дөрестән дә, Госман Гариф улы Гарипов белән бер-беребезне якыннан белә башлаганга утыз ел тула икән. «Кеше гомере — агымсу» диләр. Гел кабатлана торгач, ел фасыллары бүгенге язмабыз героен да җитмешенче язына китерде. Госман аганың бөтен гомере җәмәгать эше белән, халык арасында, газиз туган ягында узды. Ул, кайда гына эшләсә дә, үзенең гадилеге, кешелеклеге, ярдәмчел булуы белән күпләрнең хәтерендә уелып калды. Шуны раслый торган бер вакыйганы искә төшерик әле.

...1972 елның апрель ае. Армия сафларыннан кайтып, ял иткән булып йөрим. Каядыр эшкә урнашырга кирәк. Шулай бер кичне туган йортның ишеген шакыдылар. Авыл советында кизү торучы «исполнитель» икән.

— Шәмәрдәннән поссовет председателе Камалов дигән кеше шалтыратты. Иртәгә сине Сабага чакыралар. Кайтканыңны сизгәннәр, элэктерәләр, — дип шаяртты.

Киттем. Башта, разведка ясау өчен, әлбәттә, бергә концерт куеп йөргән күптәнге танышым, танылган баянчы Вилорик Вәлиуллинны эзләп таптым клубтан.

— Күптән түгел мәдәният бүлеге мөдире булып Госман абый эшли башлады. Колхоздан китереп куйдылар. Хәйран кайнаштыра, оешма саен йөреп, хорга кеше җыябыз. Әнә, гомере озын булыр әле, үзе дә килә, — дип фикерен түгәрәкләде һәм, шунда ук каршына чыгып: — Исәнмесез, Госман абый, менә Тәлгат Нәҗмиев дигән тел бистәсе шушы була ул, — дип таныштырып та куйды.

Күн итек белән шул чорның галифе чалбарын кигән кырык яшьләр тирәсендәге булачак хуҗам белән нәзакәтле итеп кенә күрештек. Сүзне озынга сузмады ул.

— Чәчү җитте. Райком иртәгә үк агитбригада белән чыгарга куша. Кил безгә. Шәмәрдәннең промкомбинат клубында эшләп киткәнсең, агитбригадада йөргәнең бар икән. Хәзергә автоклуб мөдире штатына куябыз. Хезмәт хакың алтмыш җиде сум илле тиен булыр.

— Әзрәк бит, — дим.

— Анын каравы эше күп булыр. Тагын ярты штатка драма түгәрәге алып барырсың...

Дөресен әйтергә кирәк, тиз ризалаштым. Чөнки саф татарча гына сөйләшә торган, бер-берсен танымасалар да, урамда үзара исәнләшергә гадәтләнгән мөлаем йөзле кешеләре ничектер күңелгә бик якын иде Сабаның. Эчәсе су, җыясы ризык булгандыр инде...

Ни өчен үзе турында сөйләп китте әле бу, дип уйлый торгансыздыр инде. Мин менә нәкъ шушы урында Госман Гариповичның гадилеген күрсәткән бер вакыйганы тасвирларга телим. Ул бөтен эшен читкә куйды да, мине ияртеп, үзе фатир эзләргә булды. Башта Гали Закиров урамын йөреп чыктык. Аннары елганың теге ягына — Советка күтәрелдек. Һәм Мәрхәбә апа Әхмәтовага тукталдык. Утын сорады хуҗабикә. «Булыр», — диде бүлек мөдире.

Кемгә ничектер, һавалыкның әсәре дә булмаган район күләмендәге җитәкченең яңа армиядән кайткан егеткә Саба буйлап торырга урын эзләп йөрүе бик гаҗәпләндерде, бер үк вакытта үзенә карата ихтирам һәм хөрмәт хисе дә уятты. Әкренләп без фикердәшләргә, чын дусларга әверелдек, алай гына да түгел, тормыш корган вакытта минем яктан шаһит буларак Байлангар авыл советында рәсми документка кул куйган, ягъни өйләндергән кеше дә әле ул Госман Гарипович. Шулай булгач, бу шәхес турында язу (беренче мәртәбә!) хилафлык түгелдер, шәт, иншалла!

...Утызынчы елларда туып, балачаклары һәм яшьлекләре дәһшәтле ачлык һәм сугыш елларына туры килгән буынның биографиясе бертөрлерәктер: хәерчелек, фәкать исән калу, тән саклау өчен көрәш. Әмма тормыш гел югалтулардан, үкенечләрдән генә тормый ул. Болытлар арасында кояш та бар бит!

Табигать яшәрүгә өметләнгән мизгелдә — 1932 елның март ахырында — Беренче бөтендөнья сугышы ветераны Гариф белән Урта Саба авылы кызы Гайниҗамалның дүртенче малае булып дөньяга аваз сала ул. Турысын гына әйтсәк, көтеп алынган, ягъни тансык бала булмый Госман. Ни өчен дисәгез, кешенең ачлыктан һәм сәяси тетрәнүләрдән дә кырыла торган чор бит бу. Җитмәсә, әнисенең бертуган энесе Ташмөхәммәт абыйлары сөргенгә озатылып, йорт-җирләре талана, әби белән бабай тора-бара хәер соранып йөрергә мәҗбүр булалар.

Әле ярый соңрак дүрт гаиләгә бер сыер тота алу мөмкинлеге туа, шул гына үлемнән алып кала Гариф балаларын. Ә 1930 елда туган Гомәр исемле дүрт яшьлек сабыйлары үлеп тә китә.

— Бернигә карамастан тырышып укырга, тормышның олы юлына чыгарга кирәк миңа! — дип үз-үзенә вәгъдә бирә Госман һәм яшь чактагы антына бүгенгәчә тугры кала.

Иң элек туган авылындагы башлангычны, аннары Касыйм абыйсы ярдәме белән түләүле Саба урта мәктәбен тәмамлый. Ул еллардагы аттестат хәзерге дипломга тиңләшә дисәк, һич тә ялгыш булмас. Аларны, хәрби училищега кергән Малик Җаббаров белән Рафаэль Шакировтан калганнарын, ягъни унҗиде егет һәм кызны, район мәктәпләренә укытучы итеп билгелиләр. Шулай итеп, Госман Гарипов Сатыш җидееллык мәктәбендә математика фәненнән белем бирә башлый.

1952 елда Госман запаска кайтарылачак офицерлар әзерли торган частька хәрби хезмәткә алына. Йөз чытмый, сынын горур тотып китә, шулай булмыйча мөмкин дә түгел, илне саклауның ир-егет иңенә төшә торган мактаулы вазифа икәнен яхшы аңлый ул. Балачактан ук күргән кырыс шартлар һәм кыенлыклар да чыныктыра бит аны.

Менә хәзер шул елларда булган бер онытылмаслык хәлгә иркенләбрәк тукталырга ният бар. Чөнки Госман Гариф улының армиядән лейтенант булып кайткач та Икшермә урта мәктәбендә укытуын, аннан соң комсомолның район комитетына инструктор итеп алынуын һәм ВЛКСМ райкомын да җитәкләвен, бераз Сабада география һәм тарих фәннәре укыткач, КПСС райкомының оештыру бүлеге инструкторы вазифасына күчерелүен, аннары 1962 елда, олы кызы Дания белән улы Наилне һәм гомер буе физика-математика укыткан Миңзифасын калдырып, дүрт елга Горький шәһәрендәге югары партия мәктәбенә китүен күпләр белә булыр. Диплом алып кайткач та, аны ак җәймә җәеп каршыламыйлар. Тормышның үз законнары бар бит. КПССның Саба район комитеты Җәлил совхозына партком секретаре итеп җибәрергә омтыла, ә партия өлкә комитетының идеология бүлеге Арчада пропаганда һәм агитация бүлеген җитәкләргә тәкъдим итә. Байтак тарткалашулардан соң үзебезнең районда калдырырга әмер бирелә һәм К.Маркс исемендәге колхоз коммунистлары белән алты ел кулга-кул тотынып эшләргә туры килә аңа. Аннары инде алда әйтелгән мәдәният, шулай ук КПСС райкомының пропаганда һәм агитация бүлекләренә мөдирлек итәргә, 104 нче һөнәри училищеда тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, район кулланучылар җәмгыятенең профсоюз комитеты рәисе, Теләче районы хакимиятенең социаль яклау бүлеге начальнигы вазифаларын алып барырга насыйп була. Илле елга якын булган хезмәт юлында бик күп дәрәҗәләргә ирешә ул. «Почет билгесе» ордены, дүрт медаль белән бүләкләнә. Берничә чакырылыш район Советы депутаты, КПСС райкомы әгъзасы итеп шул ук елларда сайлана. (Гадәттә, йә депутат, йә райком әгъзасы булалар.) Бу — сирәк була торган күренеш. Госман абый мәдәният бүлеген җитәкләгән вакытта, Саба һәвәскәрләре үзешчәннәр фестивалендә җиңеп чыга, Вьетнам Социалистик Республикасына путевка белән бүләкләнәләр. Ул шушы төркемгә җитәкчелек итә. Госман Гариф улына 1982 елда алдынгылардан торган икенче туристлык группасын Болгариягә алып чыгарга туры килә.

Гомумән, балачактан авыр хезмәт белән үсеп, яшьтән аң-белемгә тартылган юбилярыбыз. Соңын-

нан халык мәнфәгатен кайгыртып яшәгән кеше буларак абруй казана һәм 1998 елда ул өченче класслы дәүләт киңәшчесе, ягъни дәүләт хезмәткәре дәрәҗәсендә лаеклы ялга чыга.

Яшерен-батырын түгел, картлык инде Госман Гариповичның гомер ишеген шакыды. Әмма күңеле әле аны бусага төбендә тота. Өенә кертәсе килми. Җирне, яшәүне яраткан бу кешенең үз вакытында үлем белән күзгә-күз очрашкан мизгелләре дә була. Автомобиль фаҗигасенә юлыга ул.

Ә инде алдан искәрткәне хәрби хезмәттәге вакыйга белән бәйле. Армиядә вакытта урта белемле егетләрне Киев шәһәре янындагы Васильково хәрби десант училищесына укырга керү өчен җибәрәләр. Биредә имтиханнарга кадәр төрле физик күнегүләр белән медицина комиссиясе узарга кирәк була. Башта «вертушка»да әйләндерәләр аларны. Шуннан төшкәч, башы шулкадәр каты әйләнә ки Госманның, беренче очраган кешене кочаклаган килеш хәйран селкенеп тора әле ул. Аннары, кап-караңгы туннельгә кертеп, хәрби адымнар белән атларга кушалар. Бераз баргач, бушлыкка төшеп китәчәкләрен дә искәртәләр. (Дөрес, аска ятьмә кебек әйбер куелган була.) Курсант Гарипов шунда чума да аңын җуя...

Аңа башка күнегү-имтиханнарга кереп торасы булмый. Шулай да соңгы әңгәмәгә чакырыла ул.

— Сез карында вакытта әниегез трамвайга яисә башка берәр җиргә кысылмаганмы? — дип сорый грузин милләтеннән булган зур мыеклы полковник.

— Аны каян белергә тиеш мин? — дип, сорауга сорау белән җавап бирә абитуриент.

Хәрби хезмәттән кайткач, Госман әнисенә сөйли бу хәлне.

Гайниҗамал апа башта бик бирелеп тыңлый. Аннары елый башлый.

— Ачуланма, улым. Бик авыр ачлык вакытта дүртенче бала булып дөньяга килергә тиешлегең ачыклангач, әтиең белән киңәшеп, халыкча әйтсәк, бастырырга, ягъни төшерергә булган идек. Әмма син бирешмәдең, үҗәтлек күрсәттең, туасы иттең. Ярабби Ходаем, озын гомер телим! Шуңа күрә мин синең алда үземне гел гаепле кеше сыман сизәм. Кичерә күр, яме, тәкъдирең шундый булгандыр, — дип үксүен дәвам итә.

Менә шунда гына мәрхүм әтисенең: «Артыгым минем», — дип ни өчен сөйгәнен аңлап ала Госман.

Әлеге сөйләшүдән соң әнисенә булган хөрмәте тагын да арта аның. Кулыннан килгән кадәр игътибар-тәрбия күрсәтә. Вакытсыз вафат булган Касыймның җәмәгате Әминә килене тәрбиясендә туксан яшьне тутырып 1979 елда мәңгелеккә күчә әнисе. Төп йортны утыз ике яшьтә тол калган килен нык тота, шунда биш бала үстерә. Килгән-киткән туганнарга табыны мул, күңеле киң, йөзе якты була Әминә апаның (ул озак еллар башта Ленин исемендәге колхозны, аннары совхозны җитәкләгән атаклы директор Ислам Хаҗиевнең бертуган сеңлесе).

Озак еллар Алексеевск районында җитәкче урыннарда эшләп, шул районның «Мактаулы гражданин»ы исеменә лаек булган Касыймның энесе Сөләйман абый да гаиләсе, балалары белән еш кайта туган ягына. Аның да рәхмәте бик зур Әминә апага, шулай ук Госман энесенә, гаиләсенә.

Сүзне йомгаклап шуны әйтергә кирәк: тормышы түгәрәк аның. Ярты гасыр гомерен балаларга белем бирүгә багышлаган Миңзифасы белән дүрт бала үстереп, өчесенә (Дания — табибә, Ләйлә белән Ләйсән — педагоглар) югары белем бирделәр. Хәзер җиде оныклары бар, тәмен белеп кенә шуларны сөяләр.

Менә шундый тормыш һәм хезмәт юлы узды Госман Гариф улы. Һәр кешенең өлешенә мондый көмеш тими, билгеле. Алдагысы да хәерле булсын!

*2002*

# Илленче таң

Оеп утырган җиһанны йокысыннан уятып, үз җаена таң ата. Кемнәргәдер гадәти иртә ул. Ә менә «Агропромснаб»ның район предприятиесе директоры, Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре Фәнис Шәйхеразый улы Хурамшин өчен илленче — юбилее көне ишек шакыды. Көек авылында гомер итүче хөрәмшаныкылар нигезенә бүгенге иртәнге таң нурлары әүвәл сибелеп, изге теләкләр иңдерелде кебек.

...2003 елның башы үзенең бураннары һәм салкыннары белән дә истә калыр. Әйе, дөрестән дә, хәзер авылның, образлы итеп әйтсәк, йокымсыраган чагы. Газ ягу өчен чыгарылган төтен юлларыннан тәүлек буе күтәрелгән «ак баганалар» тормышның дәвам итүен искәртеп тора. Халыкның өе җылы, суы да кергән. Мал-туар өчен азыгы да җитәрлек хәстәрләнгән. Кыскасы, тырыш, тәртипле булганнар, кулыннан эш килгәннәр муллыкта яши.

Казан ханлыгы чорында ук табигатьнең гүзәл почмагында — Мишә елгасы буенда нигез салынган Көек берзаман «перспективасызлар» исемлегенә кертелә, һәм гөрләп торган бу авыл тора-бара бетәргә тиеш була. Хәтта, тимерчелек тә үзәккә күчерелгәч, халык эшсез кала. Күпләр бәхет эзләп төрле шәһәр-

ләргә китү, Шәмәрдән бистәсенә яки Сабага барып урнашу җаен карыйлар. Фәнис үзе дә район үзгендә йорт салу өчен урын ала. Әмма ата-бабасы гомер иткән нигезеннән тиз генә аерыласы килми аның. Уйлана, киңәш-табыш итә. Бервакыт Саба урман хуҗалыгы директоры Рәис Миңнехановка да күрсәтә ул өй урынын.

— Авылыңны ташлама син, Фәнис! Ата-бабаң урынына сал өеңне. Минем дә Лесхоздан китәргә исәп юк, — дип әйтеп куя ул икеләнеп йөргән дустына.

Менә шунда аның туган авылы, кендек каны тамган изге туфрагында җыясы ризыгы, эчәсе суы, калдырасы нәселе күз алдыннан уза. «Юк! Авылдан чыгып китәргә ярамый! Мин дә күченсәм, тәмам таралып бетәчәк бит ул. Авыл болай да картайган, чирле. Аны дәваларга, ашыгыч ярдәм күрсәтергә кирәк!» — дип уйлый Көекнең ватанпәрвәре Фәнис һәм, газиз авылын саклап калу, яшәтү өчен, җаны-тәне белән эшкә тотына...

**— Фәнис Шәйхеразиевич, Сезнең 50 яшегез тулу уңаеннан сүзне биографиягездән башлыйк әле.**

— Безнең, 50 нче еллар башында туган балаларның, тормыш юллары бертөрлерәктер инде ул. Гади колхозчы гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килгәнмен. Булачак әтием, үсеп җиткәч, Кызыл Армиягә алынган. Хезмәт срогын тутырып бетерәм генә дигәндә, коточкыч сугыш башланган бит. Гомерлек инвалид булып кайта ул аннан. Әнием Вадига колхозда гомер буе «таякка» эшләде. Кечкенә генә өйдә алты җан яшәдек. Абыем Вәгыйз, сеңлем Тәслимә белән энем Ясәви дә яшьтән хезмәт сөеп үстеләр, шуңа күрә тормышта һәркайсыбыз үз юлын тапты.

Бик гыйбрәтле еллар кичердек бит. Теләгәнчә мал-туар асрарга, кукуруз, бәрәңге басуыннан алабута-билчән җыярга да ярамады. Утын юнәтү мәшәкатьләрен башыннан кичкән кеше генә белә. Әле Хрущев хакимлек иткән елларда да ашарга ипие, тешләргә шикәр кисәге булмады. Икмәк чиратына Азин МТСына йөрдек, песок урынына повидло саталар иде. Кыскасы, халыкны төрлечә сынадылар. Ул заемнар, кырык төрле салымнар, ит, сөт, йон, йомырка заданиеләре дисеңме! Сыерың булмаса да, кешедән май сатып алып үтисе иде бит аны. Менә безнең балалык еллары шундый авырлыклары белән истә калып, тормышның кадерен белергә өйрәтте. Шуңа күрә мин хәзер гәрәбәдәй алтын бөртекләрне учыма алганда да, күпереп пешкән ипине табын түрендә күргәндә дә, Аллага шөкер, дияргә яратам.

**— Әйе, ризык — дөньядагы иң хәләл икмәк өчен көрәш җиңел хезмәт түгел. Аңа ничек керешеп кителде?**

— Мин Көектә башлангыч белем алдым, сигезенчене Тимершыкта тәмамладым. Аннары Васильеводагы автотранспорт техникумында укыдым, ике ел армиядә булдым. Ә инде хезмәт юлымны Азиндагы 12 нче номерлы механикалаштырылган күчмә колоннада тракторчы-шофер булып башлап, шунда 5 ел эшләдем. 1978 елда «Сельхозтехника»ның район берләшмәсе управляющие Бернард Мөбарәкович (авыр туфрагы җиңел булсын) автомеханик итеп чакырды. Ул вакытта инде Казан авыл хуҗалыгы институтында читтән торып укый идем. Управляющий булып Теләчедән Фәрит Гыйльмиевич килгәч, матди-техник яктан тәэмин итү буенча урынбасары итеп күчерде. 1986 елда Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы безнең районда республиканың иң беренчеләрдән булып «Агропромснаб», ягъни колхоз-совхозларны матди-техник яктан тәэмин итү предприятиесе оештырылды, мин шуның директоры итеп билгеләндем.

**— Эшне нәрсәдән башладыгыз?**

— «Сельхозхимия»нең район берләшмәсеннән бушаган контора бинасын, ташландык хәлдәге гаражларны ремонтладык, складлар булдыра башладык. Без колхоз-совхозларны техника, запас частьлар, төзү материаллары, гомумән, бөтен кирәк-ярак белән тәэмин итәргә тиеш идек. Базаны төзүгә, капка-коймалы итүгә керештек. Риф абый Вәлиев җитәкчелегендә осталар көче белән өч типовой склад (зурысы 96□18 метрлы), ике катлы административ бина, җылы гаражлар төзелде. Риф абый бригадасы «Көек» ярдәмче хуҗалыгында да зур эшләр башкарды. Аның зур хезмәтләрен искә алып, «Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирелде аңа.

**— Фәнис Шәйхеразиевич, Сез, Көекнең яшәешен саклап калган, алай гына түгел, авылны икенче яшьлегенә кайтарган шәхес буларак, биредә башкарган эшләргә киңрәк тукталыгыз әле...**

— Дөрестән дә, авылны яшәүдән туктатмас өчен аның кешесенә эш кирәк. Шуңа күрә Көектәге аксакаллар һәм район җитәкчеләре белән киңәшләштек тә аны «Агропромснаб»ның ярдәмче хуҗалыгы итәргә булдык. Җитәкчесе итеп бай тәҗрибә туплаган Яхъя Фазлый улы Нуриевны билгеләдек. Безнең карамакка 1500 гектар җир беркетелде. 1991 елда уҗым чәчелгән басуга беренче казыкны кагып, сыерлар өчен 100 әр башлык ике торак, он абзарлары төзи башладык. Тора-бара арка тибындагы дүрт склад, ябык ындыр табаклары, автоүлчәгеч, пилорам, нефтебаза, тегермән кордык. Мөгезле эре терлекләр (шуның 90 башы сыерлар) белән беррәттән нәселле атлар санын 120 гә җиткердек. Умарталык, балык күле булдырдык. Еллар үткән саен, һәр гектардан уңыш алу, терлекләрнең продуктлылыгы артты. Хезмәтебез югары бәяләнде. Россия Федерациясе авыл хуҗалыгы министрлыгының күчмә Кызыл Байрагы истәлеккә калдырылды, коллективка бер-бер артлы дипломнар тапшырылды, иң алдынгы кешеләребез-

гә мактаулы исемнәр бирелде. Эш оештыру тәртипләренә бер елны Президентыбыз Минтимер Шәрипович, икенчесендә ул вакыттагы премьер-министрыбыз Фәрит Хәйруллович килеп карап, үзләренең уңай бәяләрен бирделәр. Тәҗрибәбез республика матбугатында киң яктыртылды, китапларга кертелде. Уңышларның башы да, ахыры да кадрларга бәйле. Уңганнар күп коллективыбызда. Алар янәшәсенә Татарстан Республикасының атказанган механизаторы Нурулла Сәйфуллин, тракторчы Басыйр Галиев, баш агроном Бәшир Фәйзетдинов, склад мөдире Рәсимә Хаҗинурова, атчылык тармагын оештырып җибәргән ветераныбыз Данир ага Нурмөхәммәтов, терлек симертүче Гөлфия Низамиева, сыер савучы Маһинур Ахунова, ферма мөдире Фәнүзә Фәйзетдинова һәм башка бик күпләрне кертеп була.

**— Фәнис туган, хәзер Көектәге үзгәрешләрне күз уңыннан үткәрик әле.**

— Авылдагы яңарышларга халык ияләнде һәм күнекте инде. Гел шулай булган, шулай тиеш шикелле ул хәзер. Авырлыклар онытылды. Әгәр дә ун ел эчендә булган үзгәрешләрне күз алдына китерсәк, ышанырлык түгел. Районда беренчеләрдән булып (Лесхоз белән бер елны) газ килде. Теләгән кешегә суын да кертә бардык. Анысын чишмәдән кудырта торган иттек. Чишмәләрнең үзләрен дә карадык. Заманында телетрансляторын да кордык, телефонын да суздык. Юлларны күтәрттек, күпер төзедек. Ә инде социаль объектларга килсәк, башта балалар бакчасы, мәктәп һәм медпункт комплексы эшләп, файдалануга бирдек, аннары бер-бер артлы мәчет, клуб кебек биналар сафка басты, фатирлар салынды. Хәзер кечкенә генә авылда ике кибет, физиотерапия пункты да эшләп тора. Менә шулай яшиләр кайчандыр бетәргә «хөкем ителгән» Көектә.

**— Бу зур эшләрне башлап җибәреп, ахырына кадәр алып барып чыккан өчен халык сезгә мәңге рәхмәтледер. Әңгәмәбезнең ахырында гаиләгез белән дә таныштырып китсәгез иде.**

— Башлаган эшләрнең уң булуында гаиләнең роле зур, билгеле. Өеңдә дә, коллективта да тәртип булганда гына күңел үсә бит ул. Җәмәгатем Рәйсә балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Өч егет үстерәбез. Алар кечкенәдән үк хезмәт яраттылар, бигрәк тә атка хирыс булдылар, шуңа күрә атны шәхси хуҗалыгыбызда асрадык. Фәннүр белән Нияз яшьтән үк үзләре тәрбияләделәр, асларын чистарттылар, атланып чабарга өйрәнделәр. Шулай итеп, ат спорты белән ныклап шөгыльләнә башладылар. Тора-бара район, республика, Россия күләмендәге (бер елны Пятигорск шәһәренә кадәр бардык) ат ярышларында призлы урыннар яуладылар, бик күп бүләкләргә лаек булдылар. IX сыйныфта укучы кече улыбыз Илназ да байтак еллардан бирле ат чабышларында катнаша. Фәннүр, Казан авыл хуҗалыгы академиясенең икътисад факультетын тәмамлап, Казан күмәртәләп сату базары филиалы җитәкчесе булып эшли башлады. Нияз шул ук академиянең өченче курсында укый. Гаиләбездә һәрвакыт аңлашылучанлык, бер-береңә хөрмәт, иминлек хөкем сөрә. Күз генә тимәсен, дибез!

*2003*

# «Халык дошманы» малае

Сәлим Сәйфулла улы Сәйфуллин дигән шәхес белән миңа беренче мәртәбә 1972 елда, ягъни моннан чирек гасыр элек очрашырга туры килде. Район мәдәният бүлегендә эшли башлаган еллар иде. Аның ул вакыттагы мөдире Госман Гарипов Арташ урманында хезмәткәрләр өчен кистерелгән утынны төяшеп торырга кушты. Менә җәйге матур көндә Сәлим ага да китапханәдә эшләүче җәмәгате Сәкинә ханымның утынына килде. Беренче рейсны төяп җибәргәч, сокланып туймаслык гүзәл табигатьле урман эчендә икәү генә калдык һәм сөйләшеп киттек. Мине әңгәмәдәшемнең кем булуы кызыксындырды булса кирәк. Сәлим абый алай ялындырып тормады.

— Хәзер район авыл хуҗалыгы идарәсендә план һәм икътисад бүлеге начальнигы булып эшлим. Зур вазифа, әлбәттә. Эше күп. Үз тырышлыгым белән күтәрелдем. Кыскасы, юктан көрәк булдым мин, — диде ул һәм үзе белән таныштыруны дәвам итте: — 1927 елның 31 мартында үзебезнең районның Юлбат авылында туганмын. Әти-әниемнәр, урта хәлле кешеләр булып, игенчелек белән шөгыльләнгәннәр. Бик дини нәселдән булганнар. Хәер, бу турыда иркенләп сөйләргә дә ярамый. Ярар, урман ишетмәс әле. Репрессия еллары безнең гаиләне дә читтә калдырмады. Миңа ун яшь вакытта бөтен йорт-җирне, каралты-кураны, мал-туарны салым хисабына алып чыгып киткәннән соң, әтиебез Сәйфулла Фәтхуллинны 58 нче маддә белән биш елга төрмәгә ябарга хөкем иттеләр. Без, дүрт малай һәм авыру әниебез, ач-ялангач килеш, ярымҗимерек кечкенә генә йортта торып калдык. Авырлыкларны күп күргәнгәдер инде, энеләрем кырык җиде, кырык биш һәм егерме алты яшьтә вафат булдылар. Әти белән бертуган Нотфулла, Гайфулла һәм Габдерәүф абыйларга да «халык дошманы» дигән кара тамга сугылып, аларның гаиләләре дә каһәрләнделәр. Кыскасы, безнең нәсел балалары гомер буе кимсенеп, үзебезне гаепле санап, кешедән оялып, тартынып үстеләр. Әтиебез дүрт айдан соң Хабаровск төрмәсендә үлә. Аның ике абыйсы — Нотфулла белән Гайфулла да шушындый ук язмышка дучар булалар. Бары тик Габдерәүф абый гына төрмәдән сугышка эләгеп, гарипләнгәннән соң авылга әйләнеп кайта алды. Болар

турында сөйләсәм, күңел тула. Әйдә, икенче темага күчик әле, — диде Сәлим ага, төер утырган тамагын кырып.

Әйе, кая барса да, «халык дошманы» малае» дигән сүзне ишетеп, күзләре яшь белән томалана торган Сәлим бөтен тырышлыгын укуга бирә, ихлас күңелдән белемгә омтыла. Башта Юлбатта дүрт классны яхшы гына тәмамлый, аннан Сатыш җидееллык мәктәбендә белем ала. 1939 елдан туган авылында — ул вакыттагы Ворошилов исемен йөрткән колхозда эшли башлый. Гади йомышчы, табель алып баручы, хисапчы, кырчылык бригадиры була. 1942 ел унбиш яшьлек Сәлимнең тормыш биографиясенә хәбәрчелек эше башлану чоры буларак теркәлеп кала. Аның «Колхоз байрагы» газетасында беренче мәкаләсе басыла. Алга китеп шуны әйтергә кирәк, Сәлим ага Сәйфуллин «газетаның алтын фонды» дигән бу изге эшне илле биш ел буе башкара.

Тормыш дәвам итә. Һәр тапшырылган эшне җиренә җиткереп башкаручы, үрнәк тәртибе белән күпләрдән аерылып торучы егет нигезле белем җитмәгәнен аңлый һәм икееллык авыл хуҗалыгы мәктәбенә укырга керә. Илленче еллар башында мондый махсус белемле белгечләр санаулы гына була әле. Шуңа күрә аны Саба район советы башкарма комитетының авыл хуҗалыгы бүлегенә эшкә алалар. Ә инде 1954 елда район план комиссиясенә икътисадчы итеп күчерәләр.

Менә авыл хуҗалыгын реформалаштыру башлана. 1963 елда колхоз-совхоз производство идарәсе оешкач, ул вакытта инде читтән торып Мәскәү статистик техникумын тәмамлаган Сәлим Сәйфуллинны өлкән икътисадчы итеп күчерәләр, озак та үтми, бүлек начальнигы була. Ул әлеге бүлек белән 20 елдан артык җитәкчелек итә һәм район агропромышленность берләшмәсе рәисе урынбасары дәрәҗәсенә күтәрелә. Еллар үтә тора. Сәлим Сәйфулловичка 60 яшь тулгач, район күләмендә зурлап, лаеклы ялга озаталар. Әмма тәҗрибәле белгечнең булмавы үзен нык сиздерә. Аны кабат эшкә чакыралар һәм ветеран 1993 елның октябренә кадәр үзенә тапшырылган вазифаларны төгәл үти. Әле бүгенгедәй хәтердә, моннан биш ел элек хәбәрчебез турында газетабызда «65 тә дә эштә» дигән мәкалә дөнья күргән иде. Менә Сәлим Сәйфулла улына 70 яшь тула. «Ул бүген дә эштә» дип без авыз тутырып әйтә алабыз. Җәмәгать эшендә, билгеле. Ишекне кем тыйнак кына шакый дисәң, Сәлим абый булыр.

— Менә кичә ветераннар советында мөһим мәсьәлә тикшергән идек, озакка сузмыйча чыгарыйк әле бу язманы. Аннан узган атнада, халык утырышчысы буларак, судта катнаштым. Гыйбрәтле эш каралды. Монысын «Суд залыннан» дигән рубрика белән урнаштырсак, әйбәт булыр иде...

Ярты гасырдан артык тәҗрибәсе булган авторыбызның икътисади темага гомер буе язган анализлы материалларын искә төшереп тору кирәк тә түгелдер. Бу теманы ул бүгенге проблемалар белән бәйләп дәвам итә: уйлана, борчыла. Сәлим абыйның тагын бер язарга ярата торган юнәлеше һәм шөгыле бар. Ул — бакчачылык. *«Минем бакчам язын шау чәчәккә күмелә, җәйләрен анда яшеллек, саф һава, көзләрен җиләк-җимеш, яшелчә муллыгы. Барысы уналты төрле җиләк-җимеш агачы бар. Бу төпләр саны түгел, төрләр исәбе. Бакчада кечкенә генә питомник булуы да уңайлы. Мин шунда һәр елны культуралы алма, чия, слива, карлыган үсентеләрен ялгау юлы белән үстерәм. Япон айвасы, кытай лимоннигы дигән үсентеләр дә җитешеп килә. Грушаны гади миләшкә ялгап үстерә башладым»* дип язган иде ул үзенең табигать дөньясына багышлаган бер мәкаләсендә.

Әйткәнебезчә, хәбәрчебезнең яза торган темалары күпьяклы. Мәсәлән, соңгы елларда «Юлбатның указлы һәм указсыз муллалары», «58 нче маддә — 58 елдан соң» дигән үзенчәлекле мәкаләләре белән газета укучыларыбызны сөендерде ул. Мәскәү, Казан прокуратуралары белән элемтәгә кереп, Дәүләт иминлеге комитетына йөреп, әтисе Сәйфулланың һәм абыйсы Нотфулланың гаделсез хөкем карарын юкка чыгарып, реабилитацияләүгә иреште, азмы-күпме компенсация акчасы юллап ала алды. Бу мәсьәләдә аңа киңәш сорап килүчеләр байтак булды, ул аларның һәркайсына бик теләп ярдәм итте. Сәлим ага Сәйфуллин гомер буе җәмәгать эшләрендә актив катнашты. Озак еллар башлангыч партия оешмасын җитәкләде. Егерме ел партбюро әгъзасы итеп сайланды. Агропромышленность комплексы эшчәннәре профсоюзы район оешмасының ревизия комиссиясе рәисе булды, район газетасының «Экономик анализ бюросы» дип аталган штаттан тыш бүлеген җитәкләде.

Әлбәттә, тырыш, намуслы хезмәт беркайчан да эзсез калмый. Сәлим Сәйфулла улының кадерләп саклана торган шәхси архивы белән танышкач, моңа тагын бер кат инанасың. Башта ул алтмыш яшенә бирелгән КПСС өлкә комитетының һәм ТАССР Министрлар Советының Мактау грамотасын күрсәтә. Аңа республикабыз Президенты Минтимер Шәймиев һәм КПСС Үзәк Комитетының элеккеге секретаре Гомәр Усманов кул куйган. Төрле елларда тапшырылган дистәгә якын медальләр һәм билгеләр, Мактау грамоталары кадерләп саклана. 1985 елда аңа районда беренче булып «Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирелә, ә инде 1988 елда республика күләмендәге персональ пенсия билгеләнә.

«Кеше үткән белән түгел, көткән белән яши» диләр. Гомер буе тырышып-тырмашып, хәләл көче белән өен салып, каралты-курасын, җиләк-җимеш бакчасын булдырып, җәмәгате Сәкинә ханым белән дүрт малай һәм бер кыз үстереп, аларны аерым тормышлы итеп килә ул үзенең 70 еллык юбилеена.

*1997*

# Сез Габдрахман улымы?

1995 елның 14 июне. Казан радиосы авыр хәбәр җиткерде: чын мәгънәсендә халык язучысы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, укытучы-остазыбыз Мөхәммәт Сөнгатулла улы Мәһдиевнең гомере өзелгән...

Сәгате-минуты белән халык бәгыренең тәгәрәп үскән авылы Гөберчәккә — әдип әсәрләренең прототиплары ягына юл алдык. Кесмәс буйларына, торналар төшкән җиргә якынлашкан саен күңелдәге хатирәләр яңарды. Менә Чөмә-Елга авылына кердек. Биредә балалар язучысы, гомеренең күп өлешен районыбызның Эзмә мәктәбендә биология фәнен укытуга багышлаган Заһирә апа Гомәрова туган. Татар әдәбиятына Галиәсгар Камалны биргән Сикертәнне дә узып барабыз. Аннары Гөберчәккә ике чакрым ярым гына кала.

Сикертән дигәннән, Мөхәммәт абыйның әтисе шушында туган. Биредә башлангыч сыйныфларны тәмамлап, 1895–1905 елларда Байлар Сабасыннан ун чакрым ераклыктагы Сатыш мәдрәсәсендә дини белем алганнан соң, Арчада икееллык урыс-татар мәктәбендә укыган. 1907–1909 елларда Вильно шәһәрендә хәрби хезмәт үткән. Аннан кайтып, үзе укыган Сатыш мәдрәсәсендә, бераздан Үзин өязендә мөгаллим булган. 1913–1914 елларда Сөнгатулла үзе туып үскән Сикертәндә мөгаллимлек кыла. Бер елдан Гөберчәккә мулла булып килә. 1929 елда бу вазифаны туктатырга мәҗбүр ителә һәм үз хуҗалыгында җиләк-җимеш, бәрәңге үстерү, умарта үрчетү белән шөгыльләнә. Әмма аны власть вәкилләре еш кына борчырга тотына һәм соңгы тапкыр 1937 елда кулга алына. 1938 елның 5 гыйнварында «халык дошманы» буларак атыла.

...Менә шундый уй-хисләр белән Гөберчәкнең зиратына килеп тә җиткәнбез.

Мөхәммәт абыйның кабере алдында баш иеп, күңелдәге изге теләкләребезне җиткергәннән соң (аны җирләгәннәр иде инде), өйләренә кайттык.

Шушы нигезне кадерләп саклаучы һәр бер-бер артлы туганнарын югалтып барган (1971 елда — әнисен, 1995 елда — Мөхәммәт энесен, 2001 елның гыйнварында Рәшит абыйсын озата) Равия апа башта миңа һәм мәгариф бүлеге башлыгы Шамил Зиннуровка күз сирпеп алды, аннары, хакимият башлыгының беренче урынбасары Таһир Шәрәфиевкә карап:

— Сез Габдрахман улымы? — дип сорады.

...Гөберчәктән кайткан кичне Таһир Габдрахман улы иртәрәк ятты. Әмма тиз генә йоклап китә алмыйча, күңелендәге уйларына ирек бирде. Кабат күз алдына әнисе белән Түбән Симет мәктәбендә укыткан Равия апасы, аның: «Сез Габдрахман улымы?» — дип бастырып соравы исенә төште.

Әйе, әдип әйтмешли, бала, ягъни Таһир да атадан яшь кала. Габдрахман абыйның кызлары Разыя, Марзыя, Гәүһәрдән соң туган төпчеге — тансыгы ул. Әнисенең сөйләвенә караганда, ихлас күңелдән тели ул нәселне дәвам итүче малай тууын. Өченче кызына да Гәүһәрия дип түгел, кыскарттырып, Гәүһәр дип кенә куштыра. Аның чәчен дә малайларныкы кебек итеп үзе ала ул, хәтта алгы өлешен калдыра да. «Малай тугач алып бетерермен калган җирен, ә инде Гәүһәриянең «ия»се үсеп җиткәнче торып торсын, соңыннан ия табылыр», — дип әйтергә ярата.

Бигрәк тә әтисенең соңгы көннәре Таһирның исеннән чыкмый. Бавыры авыртудан җәфалана ул. Тора-бара мәһабәт гәүдәле ир-ат тире белән сөяккә кала. Мәскәүгә яшь төзүчеләр отрядында яхшы эшләгән өчен бирелгән путевка белән киткән студент малаен көтә. «Минем бу хәлне Таһир беләме?» — дип кат-кат сорый. Кайта улы. Табиблар тәкъдим иткән бик дефицит булган лимонны да чиләк сыешлы чемодан белән хастаханәгә китереп җиткерә. Әмма...

Алтын куллы механик була Габдерахман. Басуда эшләгән яисә урамнан узып барган трактор двигателе тавышыннан җитешсезлеген әйтә алган. «Әгәр белемем дә булса, әллә кем булыр идем мин», — дияргә яраткан. Башта үзләрендә учетчы, тракторчы, Керәнне авылында, аннары Түбән Симеттә тракторчылар бригадиры, механик вазифасын утыз ике ел алып барган. Нәселләре белән башлы, ягъни зиһенле, һөнәрле була алар. Габдрахманның әтисен — Шәйхетдин Шәрәфетдин улын — оста тегүчене, әле дә хәтерләүчеләр бар. Толыпка кадәр теккән ул. Аның җәмәгате Миңнисa да «Зингер» машинасы артына еш утырган. Куллары эш белгәч, тормышлары авылда ару саналган.

Шәрәфетдиннәр нәселен дәвам итүче Таһирның күңелендә бер әрнү бар: әтисенә хөрмәт күрсәтә алмый кала, чөнки бик яшьли китә ул. Шуңа күрә Гөберчәктән кайткан көнне күзенә йокы кермәде аның...

...Гөберчәккә кылган бу сагышлы сәфәребез мәңге онытылмаслык булып күңелнең түрендә урын алды. Нәкъ ун ел вакыт узгач, Шәрәфиевләр шәҗәрәсе белән тирәнтенрәк танышу өчен, Түбән Симет авылына кузгалдык. Халык телендә «десятка» дип кергән «Жигули» машинабызның двигатель авазы белән Мөхәммәт абыйның көр тавышы колакка кергән сыман була. Ул кадерле әнисен — Бибирабига Сафина-Мәһдиеваны (1891–1971) ел саен ямьле җәй урталарында шушы авылга — балачагы, яшьлеге узган су буйларына, Түбән Симетнең хәтфә чирәмле аланнарына алып баруы турында сөйләргә ярата иде.

Без башта аларның нигезенә күз салдык. Аннары Шәрәфиевләр капкасын ачып кердек. Ишегалдында безне Таһирның апасы Марзыя каршы алды һәм: «Әни белән Мәдинә апа бакчада иде әле», — диде.

Менә бергәләп өйгә кердек һәм матур гына әңгәмә корып җибәрдек.

— Мин үзем Арча районының Югары Курса авылыннан. Әтием фронтка китте. Әнием һәм башка туганнарым белән сугыш чорының барлык авырлыгын күрдек. Без Арча педучилищесында Мөхәммәт Мәһдиев, соңыннан Түбән Симет, Икшермә мәктәпләре директоры булган, кырык елдан артык гомерен мәгариф эшенә багышлаган Кави Байкиев кебек шәхесләр белән бер чорда укыдык, — дип сүзен башлады ул. — Сугыш вакытында педучилище бинасын госпиталь иткәч, безне Үрнәккә күчерделәр, шундагы куян фермасын агартып, караватлар тезеп яшәдек, белем алдык. Миңа диплом алырга насыйп булмады, укытучылар кирәк, читтән торып бетерерсез, дип, мәктәпләргә тараттылар. Бер ай чамасы гына Өчиледә дәрес бирдем дә Түбән Симеткә күчерделәр. Монда Равия Мәһдиева белән укытырга туры килде. Тора-бара балалар кимү сәбәпле, кыскартылуга эләктем, пенсиягә дә яраткан хезмәтемнән чыга алмадым. Ә бит яшь буынга мәгърифәт нуры сибеп, сабый балаларга ак юл күрсәтеп яшәү, гомереңне тәрбиячелеккә багышлау сөенеч тә, бәхет тә бит ул...

Әйе, яшьлек мәхәббәте Габдрахман белән дә шушында таныша ул. Нараттай төз, сөлек кебек гармунчы егет бер күрүдә ошата аны. Алты ел йөреп, 1950 елда никахларын законлаштыралар алар.

**— Сезнең тормышыгыздагы иң куанычлы мизгелне исегезгә төшерегез әле, —** дим.

— Без Габдрахман белән егерме сигез ел бергә торып калдык. Бик иртә җир куенына кереп ятты шул. Яшьлекнең куанычлы вакытлары күп булды. Таһирның дөньяга килүе безнең йортка зур шатлык иңдерде. Габдрахман эштән һәр көнне бик сагынып, ашыгып кайтты. Кыскасы, сабый йоклаганда өйдә чебен дә очарга тиеш түгел иде. Малае өчен үлеп торды. Игелеген генә күрә алмады...

**— Күңелегездә сакланган берәр күңелсез вакыйга бармы?**

— Бар. Анысы да Таһир белән бәйле, — дип, төшенкелек белән сөйләп китте ул. — Сөйләшә башлаган чагы иде. Мин аралыктан самавыр алып чыккан вакытта, һич уйламаганда каршы йөгереп кереп, кайнар суга йөзе пеште. Капка тавышын ишеткән булган ул. Мин, нишләргә белмичә, үрсәләнә-үрсәләнә: «И балам, синең башың пеште, минем башым бетте», — дип елый башладым. Шуннан Таһир яшь аралаш мөлдерәп карады да: «Әни, мин син пешергәнне этигә дә, апаларга да әйтмәм», — диде. Менә шулай, теш чыкканнан бирле мәрхәмәтле булды ул. Берәр күчтәнәч алып килсәләр, тигезләп бүлә идем. «Әни, кая, үзеңнекен күрсәт әле, синеке белән тигез булса гына ашыйм», — дия иде.

— Без Таһирның үзе пешүе турындагы хәйләңне чамаладык, — дип сүзгә кушылды 89 яшьлек Мәдинә апа (Габдрахман абыйның бертуганы). — Ышанган булып кыландык кына.

— Әйе, Габдрахман да соңыннан: «Ярый әле җаен тапкансың, кызулыгым белән бер-бер нәрсә эшләп ташлаган булыр идем», — дигәне хәтердә калган.

— Таһирның туган җанлы булуы турында мин дә бер мисал китәрсәм ярыймы? — дип сорап куйды Казаннан кайткан бертуган Марзыя апасы. — Аның студент вакыты иде. Таһирга ниндидер кием алу өчен ЦУМга бардык. Ничектер баскыч астындагы бүлектәге хатын-кыз күлмәге игътибарымны җәлеп итте. Соңыннан үзем дә ник караганыма үкендем. Каршы торып карасам да, тәки шул күлмәкне мәҗбүриләп алдыртты Таһир. Шулай итеп, студентка кием алырга дип барып, миңа алып кайттык. Аның бу кешелеклелеге гомер буе мине озата барды. Аннары бик тырыш булды. Гел әйтеп, сорап торып та, бер мәртәбә дә күлмәкләрен юарга китермәде. Бүлмәдәш егетләре белән кайсыдыр Яңа елны каршыларга чакырдылар. Шундый матур итеп табын әзерләгәннәр иде...

Ә хәзер Мәдинә апаның да тәрҗемәи хәленә кыскача гына тукталыйк әле. Унике балалы Шәйхетдиннәр гаиләсенең уңган-булган кызы ул. Ире сугыштан кайтмый. Тол гомерен төп нигезнең иминлеген саклауга, мул ризыклы итүгә багышлый. Алтмыш ел бертуганнар кебек яшиләр апа белән. Тормышка сорап килүчеләр дә булмый түгел. Аларны бик тиз борып җибәрә. Ирләрдән ким эшләми. Сугыш вакытында ферма мөдире, бригадир кебек вазифалар башкара. Ат җигеп, шәхси хуҗалыкның сөтен җыя, майлылыгын билгеләп, Мичән сепараторлык пунктына илтеп тапшыра, исәп-хисабын да гадел итеп үзе башкара. Төштән соң шул ук авылдан егерме елга якын почта алып кайтып, өй саен тарата. Ат үз кулларында булгач, печәнен-утынын да әзерләргә уңай, билгеле. Кечкенә генә ике хатын җир җимертеп тормыш алып баралар, тора-бара кызлары Разыя, Марзыя, Гәүһәр һәм улы Таһир кул арасына керә башлый. Печән-утын өчен урман хуҗасына (лесникка) эшләве дә җиңеләя төшә.

Таһир, диплом алгач, туган мәктәбендә укыта башлый, директоры була, «Үзәк» колхозының башлангыч партия оешмасы секретаре итеп сайлана. Яңа Мичән авылының Ислам белән Даниянең Мәрьям исемле кызлары белән тормыш кора. Ирнең кызулыгы белән хатынның сабырлыгы тәңгәл килеп, берберсенең күз карашыннан аңлап яши башлыйлар. «Мәрьямебез безнең өчен бик тә газиз, — ди, халыкчан итеп әйтсәк, биеме Рауза апа. — Әти-әнисе яхшы кешеләр иде. Авыр туфраклары җиңел булсын. Берсендә яңа Мичәнгә бардым. Кодагый үргә менгәнче озата чыкты. Шунда: «Хәзерге яшьләр җиңелчә. Үз урыныңда тора бел, кодагый!» — дип куйды. Хәзер аның бу җөмләсен кайта-кайта уйлыйм. Кышка безгә килегез, диләр Мәрьям дә, Таһир да. Юк инде. Мәдинә апа белән алтмыш ел саклаган нигезне, үзебезнең гомеребезгә җитәрлек алты почмаклы өебезне ташламыйбыз. Балалар да, оныклар да

үзләре кайтып йөриләр. Таһирга Сабага күчәргә дә ризалыгымны ихлас күңелдән бирдем. Гомергә бәхетле булсыннар!»

Әйе, Таһир Габдрахман улының район үзәгенә алынганына да егерме ел була икән инде. Ул башта район партия комитетының оештыру бүлеге мөдире булды, аннары район советы рәисе урынбасары итеп сайланды, район халык контроле комитеты рәисе итеп расланды, «Октябрь» колхозын җитәкләде.

1995 елдан бирле район хакимияте башлыгының беренче урынбасары вазифасын алып барды, нигездә иң четерекле социаль мәсьәләләр блогына җавап бирде. 2006 елдан ул Саба муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе. Таһир Габдрахман улы, район җитәкчеләре белән уртак тел табып, бер максатка омтылып эшли, булсын дип тырыша. Бүгенге шартларда җитәкчелек итү җиңел түгел, әлбәттә. Моның өчен нык холыклы, халыкны, аның яшәү рәвешен, тормышны тирәнтен аңлаучы зат булырга тиеш. Таһир Габдрахман улы да җитәкче булып тумаган. Моңа аны тормыш үзе өйрәтте. Районда соңгы елларда икътисадта, авыл хуҗалыгында, социаль мәсьәләләрдә, торак йортлар, мәктәпләр, балалар бакчалары, спорт объектлары, медицина учреждениеләре, юллар төзелешендә матур үзгәрешләр бар икән, аларның һәркайсында да хакимият башлыгы Рәис Миңнехановның уң кулы — Таһир Шәрәфиевнең дә лаеклы өлеше булуын беркем дә инкарь итә алмас. Республика, район күләмендә үткәрелә торган семинар-киңәшмәләрнең, җыеннарның, сабантуйларның, фестивальләрнең, әдәбиятка-сәнгатькә, мәгарифкә, спортка бәйләнешле барлык чараларның дирижеры дип әйтер идем мин аны. Кыскасы, олы ышаныч, зур өмет белән эшли һәм яши ул...

Әнә шулай әкрен генә еллар үтә тора. 2007 елда әнисенә 80, Мәдинә апасына 90 яшь тула. Үзенең алтын юбилеена да ерак калмый. Аның истәлекле кичәсендә тостымның караламасын сызгалап та куйдым инде. Ул чама белән түбәндәгечә булачак, Аллаһы боерса:

— Без бүген, хөрмәтле хезмәттәшләр, Саба районы муниципаль башкарма комитеты җитәкчесе Таһир Габдрахман улы Шәрәфиевнең туган көнен билгеләп үтәргә җыелдык. Белгәнегезчә, халык телендә аны Петр I дип тә йөртәләр. Заманында райком машинисткасы Миләүшә Фатыйхова чәпәгән иде бу килешеп тора торган кушаматны. Үзенең бер дә ачуы килми аның моңа. Охшашлык та бар, аннары юкбар кеше булмаган бит инде Петр-патша. Үзегез дә хәтерлисездер әле, СССРның халык артисты Шәүкәт ага Биктимеров бервакыт Саба сәхнәсеннән: «Безнең театрда аны Петр I дип кенә йөртәләр», — дигәч, залдагылар көчле итеп кул чапканнар иде.

Шулай бервакыт РСУның гади генә балта остасы хакимият башлыгының беренче урынбасары бүлмәсенә килеп керә дә үзеннән үк:

— Петр I монда утырамы? Ренат абый җибәргән иде, — дип сорый.

— Мин булам инде Петр I, — дип, тыйнак кына итеп үзе белән таныштыра Таһир Габдрахманович.

Хәзер, мөмкин булса, аны тәүге тапкыр ничек күрүем хакында сөйләп китим әле.

1984 елның җәйге матур көне. Якшәмбе. КПСС райкомының беренче секретаре Илдус Нигъмәтуллович безне җыеп алды да кайсы хуҗалыкларга чыгачагыбыз турында сораша башлады.

— Мин «Үзәк» колхозына барам, — дидем.

— Нәрсә калган анда? — диде беренче.

— Соңгы бишкөнлектә җиңүче комбайнчыга күчмә вымпел тапшырырга кушканнар иде...

— Вымпел тапшырып кына йөрмә анда. Басуларын, ындыр табакларын, фермаларын карап чык, иртәгә доложишь!

— Ярар, — дидем.

Дөресрәге, минем гаилә Сеҗедә — шуннан ерак түгел Арча районындагы авылда — әбиләрдә иде. Бу командировканы хәләл җефет белән яшь баланы алып кайту өчен алдан ук планлаштырган идем.

Бардым. Колхоз рәисе Билал Шаһвәлиевне эзләп таптым. Башта вымпелны тапшырдык. Аннары эскерт салучылар янына киттек. Минем кем икәнне таныштырып тормады бу.

Арттан искән җил белән салам өючеләрнең сөйләшкәне ишетелә:

— Нинди кеше икән бу? — ди эскерт өстендәгесе.

— Ял көне кем эш белән йөрсен? Колхозчыдан башка. Казаннан эчәргә йә иткә-балга кайткан берәр кунагыдыр әле!

...Ярар, төшке аш вакыты якынлашты. Киттек ашханә тирәсенә.

Шунын ишегалдындагы бүкән өстендә, дөрестән дә, Петр I нең яшь вакытына охшаган яшь, чибәр, озын гәүдәле, кара мыеклы бер егет утыра.

— Кем ул? — дип сорыйм.

— Безнең яшь укытучы ул, — диде Билал Баһманович, әллә ни игътибар итмичә.

Ул вакытта кем уйлаган аны: шушы кеше тора-бара озак еллар район хакимияте башлыгының беренче урынбасары, башкарма комитет җитәкчесе — эш кушучың булыр дип. Әгәр дә алдан сизгән булсам, янына йөгереп барып:

— Исәнмесез, Таһир Габдрахманович! Нишләп бүкән өстендә берүзегез моңаеп утырасыз? Әйдәгез, мөмкин булса, безнең белән «чәйләп» чыгыйк, — дия-дия, ике куллап күрешкән булыр идем.

Кыскасы, юбилярның үзенә, җәмәгате Мәрьямгә, кызларына, барлык туганнарына исәнлек-саулык,

озын гомер телим.

*2006*

# Чын тимер тутыкмый

Зәңгәрсу төстәге «уазик» машинасы Байлар Сабасын Килдебәк авылы ягыннан уза торган юлдан килде-килде дә ике катлы заманча итеп төзелгән, хәзергечә итеп әйтсәк, офис алдына туктады. Аннан нык бәдәнле, мәһабәт гәүдәле ир-ат — шушы оешманың директоры Әнәс Хәмзин төшеп, салмак кына адымнар белән территориягә үтте һәм, кабинетына да күтәрелеп тормастан, тау-тау өелеп торган алтын гәрәбәдәй көшелләр янына узды.

Менә 1984 елдан бирле июль-август айларындагы эш көне шулай башлана аның. Ул кабул итеп алганда «Саба хуҗалыкара катнаш азык заводы» дип атала иде бу оешма. Аннан соң заманалар гына түгел, идарә итү алымнары да, заводның исеме дә үзгәрде — «Саба ашлык продуктлары заводы коммуналь унитар предприятиесе» дип йөртелә ул хәзер.

Елларның төрлесе истә калган, әлбәттә. Тоташ яңгырлы җәйләрдә ашлыкны кая куярга белмәгән чорлар да яисә, киресенчә, коллективны яшәтү, саклап калу өчен чимал җитмәгән сезоннар да була.

Әнәс Гаян улы эшли башлагач, заводның матди-техник базасы ныгый. Быел да зур егәрлекле ашлык киптерү, үлән оны ясау агрегатлары, складлар ремонтланган, территория тәртипкә китерелгән. Ак он тегермәне дә яңа уңыштан югары җилемсәле бодай көтә.

Яңа гасырның, яңа меңьеллыкның тәүге 2001 елы Әнәс Гаян улы Хәмзин, гомумән, аларның гаиләсе өчен истәлекле ел буларак хәтерләрендә уелып калыр. Кайсы ягы белән дисәгез, сәбәпләре күп аның... Беренчедән, май аенда гаилә башлыгына илле яшь тулды. Ир-ат өчен гомернең кыл уртасы, диләр бу юбилейны. Ун көн дә үтмәде, җәмәгате Фәридә дә, куып җитеп, биш дистәсен түгәрәкләп куйды. Фәридә дигәннән, матур табигатьле кечкенә генә Түлешкә авылында — Ленин орденлы шофер Мөхәммәт ага белән укытучы Мәсхүдә апа гаиләсендә тәрбияләнеп үсә ул. Гомерен педагогик эшкә багышлый. Хәзер Саба урта мәктәбендә тарих фәне укыта. Хәмзиннәр гаиләсендәге быелгы өченче шатлык — кызлары Айсинә, Саба урта мәктәбен алтын медальгә тәмамлап, югары уку йортына керү имтиханнарының беренчесен үк бишкә биреп, Казан дәүләт медицина академиясе студенты булды, медальне чын-чынлапаклады. Тугызынчы сыйныфны тәмамлаган Гөлия дә яхшы укый. Кызлар икесе дә музыкага гашыйклар. Чөнки әтиләре гармунда да, баянда да өздереп уйный...

**— Әнәс Гаянович, балачагыгыз, әти-әниләрегез, туганнарыгыз турында сөйләгез әле, без, гадәттә, гел эш турында төпченәбез бит, —** дим.

Ул бераз уйланып, карашын ерак офыкка сирпеп алды да:

— Нәрсә дип сөйлим инде, — дип, әңгәмәбезне дәвам итте. — 1951 елда үзебезнең районның Килдебәк авылында гади крестьян гаиләсендә туганмын. Әти сугыш ветераны иде. Колхозда тракторчы да, механик та, ферма мөдире дә булып эшләде. Машина-трактор паркы мөдиреннән пенсиягә чыкты, вафат булды инде, авыр туфрагы җиңел булсын. Әнием Разия гомер буе төрле эшкә йөрде, безне тәрбияләде. Үзем — олы бала, минем өч сеңелкәшем — Әнисә, Фәнүсә, Фирдәүс бар... Тагын шуны өстим инде: 1968 елда унынчыны тәмамладым. Бу — Килдебәк урта мәктәбендәге беренче чыгарылыш иде. Аттестатымны тотып, беркемне белмәгән килеш, Казан авыл хуҗалыгы институтының ул елларда авыр да (чөнки катлаулы сызымнар бик күп), дәрәҗәле дә механика бүлегенә киттем. Конкурсны уңышлы гына узып, көндезге бүлеккә кабул ителдем. 1973 елда диплом алгач, Балтач «Сельхозтехника» берләшмәсенә инженер итеп җибәрелдем. Анда атаклы управляющий Зәки Хәсәнович Заһидуллин кул астында эшкә өйрәндем. Аннан Совет Армиясе — Тын океан флотында моряк булып хезмәт иттем. Хәрби бурычымны үтәгәннән соң, әти-әни үтенече буенча эшкә туган якка кайттым. Башта «Сельхозтехника» район берләшмәсендә инженер-диагнозчы, бераздан мастерской мөдире булдым. Язмыш кушуы буенча туган колхозымда һәм Саба сөт-май комбинатында баш инженер вазифаларын алып барырга туры килде. Аннан... 1984 елда шушы коллективны җитәкләргә тәкъдим иттеләр.

Коллектив дигәннән, аны тулысынча диярлек саклап кала ул. Буш урынга казык кагып, заводны башыннан ук төзегән, соңыннан баш инженер итеп күчерелгән Фәрит Шәймәрданов, башка техник хезмәткәрләр белән утырып киңәшләшәләр дә эшне төп бинаны реконструкцияләүдән башлыйлар. Складлар киңәйтелә, беренче тапкыр саклау өчен 3000 тонна бөртек салына. Югары җитештерүчәнлекле «ДСП-32» ашлык киптерү агрегатын коралар, «КЗС-20» дигәне көйләнеп сафка бастырыла. «АВМ-1,5» үлән оны ясау агрегаты монтажлана, аның 300 тонна витаминлы азык җитештергән еллары була. Яшел масса алу өчен үзләренең 200 гектар чәчеп үстерелә торган печәнлекләре дә бар.

1985 елда завод базасында республика семинары уздырылып, елына 13000 тонна катнаш азык җитештерү бурычы куела. Моңа ирешелә дә, чөнки әлеге максатка меңәр тонна төрле өстәмәләр генә дә

кайтарыла. Дуңгыз балалары өчен азыкның аерым төре җитештерелә башлый. Яшь бозаулар өчен соя сөте ясау да тиз үзләштерелеп, кышлату чорында терлекләрне сау-сәламәт итеп үстерүдә хуҗалыкларга зур ярдәм ителә.

Әлбәттә, күркәм нәтиҗәләргә тырыш хезмәт, яңалыкка омтылучанлык, эзләнүчәнлек аша гына ирешеп була. Карабодай ярмасы ясый башлау да ул чорның зур казанышы иде. Чөнки талон белән шикәр авырулы кешеләргә генә бирелә торган бу файдалы продукт Бөгелмә, Буа кебек ике-өч районда гына чыгарылды. Шуңа күрә цехны төзү, аның җиһазларын урнаштыру тәртипләрен Оренбург өлкәсенә үк барып өйрәнергә туры килде Әнәс Гаян улына. Хыяллары тормышка ашкач, күрше-тирә районнардан да, еракларда да карабодай төялгән машиналар агылды Сабага. 1998 елда 240 тонна ясадылар аны. Базар мөнәсәбәтләренә күчү чорында завод коллективын яшәтүче, саклап калучы төп тармакка әйләнә карабодай. Алтын куллы ветеран Әһлетдин ага Хәйриев җитәкчелегендә цех җиһазлары ишәйтелеп һәм камилләштерелеп, бередә бодай, солы, арпа, тары ярмалары да чыгарыла башлый, хәтта кукуруз да эшкәртелә.

Төрле двигательләр чорнау цехы да ярдәм итеп куя... Ерактан ук балкып торучы тагын бер бина бар завод биләмәсендә. Ул — ак он тегермәне. Чималы, ягъни бодае булса, тәүлегенә 30 тонна тарта ул. Халык өчен көндәлек кирәк булган өч төрле сорттагы онны 4000 тонна чыгарган елларны яхшы хәтерли директор.

Шушы ике дистә ел эчендә башкарылган эшләрне саный китсәң, күп инде алар. Заманында рапс цехы да завод аша төзелде. Гомумән, биредәге складларның гомуми мәйданы 12000 тонна сыйдырышлыга әйләнде.

Туктар авылы — «Татарстан» күмәк предприятиесе заводның ярдәмче хуҗалыгы булып торган өч елда байтак капитал салына. Халыкка табигый газ кертелә, амбарлар, тораклар ремонтлана, терлекләр өчен җәйге лагерь эшләнә, дуңгыз фермасы булдырыла, мөгезле эре терлекләрнең баш саны йөз утызга арта.

Соңгы елларда заводның тирә-ягы да матурлана төште. Моңа кадәр 30 елга якын цех өстендә — тузан эчендә утырган контораның «җиргә төшүе», ягъни ике катлы бина төзелүе (эче Европа стиле белән бизәлгән) зур үзгәреш кертте. Агачлар утыртылу, койма-капкалар буялу, асфальт җәелү дә күп нәрсә турында сөйли.

Тырыш хезмәт эзсез калмый, әлбәттә. Коллектив 1997 һәм 1998 елларда — ике ел рәттән, авыл хуҗалыгы продукциясе эшкәртү предприятиеләре арасында беренче урынны, ә инде узган ел йомгаклары буенча икенче урынны яулады. Завод директоры Әнәс Хәмзиннең үзенә «Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем моннан өч ел элек бирелгән иде. Ул тагын бер олы бүләкне — РСФСР авыл хуҗалыгы министры Л.Флорентьев кул куйган 1981–1982 елларда авыл хуҗалыгы техникасын үрнәк әзерләгән өчен «Октябрь» колхозы баш инженеры булып эшләгәндә бирелгән Мактау грамотасын — шәхси архивында кадерләп саклый.

Әйе, «Чын тимер тутыкмый» ди халык мәкале. Әтисенең һөнәренә тугры калып, коллектив белән уртак тел таба белә Әнәс Гаян улы. Алда тагын никадәр тынгысыз көннәр, борчылулар, йокысыз төннәр икәнлеген ул үзе генә белә...

*2001*

# Тормыш һәм көрәш мәйданында

Җиләк вакыты бер генә булган кебек, печән өсте дә санаулы гына көннәрдән тора. Кояш нурлары уйнаган күктә болытлар да күренмәсә, тырышып, сөенә-сөенә, башын күтәрмичә эшли халык. Бер үк вакытта галиҗәнап икмәк өчен дә киеренке көрәш бер сәгатькә дә туктап тормый бу чорда. Чөнки иген игү электән үк изге, авыр, саваплы эшләрдән саналган.

Авыл кешесенең әнә шулай көнне төнгә ялгап хезмәт куйган иртәдә кузгалдык без ут күршеләребез булган Балык Бистәсе районына. Максатыбыз ачык: районыбыз елъязмасына «Горурланырлык якташларыбыз» дигән циклдан язма бирү өчен хакимият башлыгы Равил Хәйруллин белән әңгәмә кору.

Дөрес, язмабызның герое туган яктан бик еракта дөньяга килгән. Әмма аның балалык һәм яшүсмер еллары Курсабашта узган, белем нигезләрен дә шул авыл мәктәбендә алган. Хезмәт юлы нигездә Арча, Питрәч һәм Балык Бистәсе районнарында үтә аның, ягъни эчәр суы, җыяр ризыгы читтә була. Шуңа күрә газета укучыларыбызны аның белән якыннанрак таныштыру зарурлыгы килеп туды. Ни өчен дисәгез, районыбыздан чыгып, андый «беренче» яки «глава» булган җитәкчеләр күп түгел.

Ә менә без Равил Гарифуллович белән тәүге тапкыр 2000 елның җәендә генә — ул Курсабаш авылында мәдәният йортын ачу тантанасына хакимият башлыгы буларак кайткач танышкан идек. «Тәлгат абый, сезнең республика матбугатындагы мәкаләләрегезне, чыккан китапларыгызны укып барам», — дип, якын итеп күрешкте ул. Һәм менә, ниһаять, җай чыгып, иркенләбрәк сөйләшү өчен юлга кузгалдык.

Әйләнгечрәк булса да, Балык Бистәсе районы биләмәсенә борынгы Чаллы каласы урнашкан яктан — Тәберде Чаллысы, Котлы Бөкәш аша юл тоттык без. Авыллар матур, йортлар төзек, сыланасы сыланган, буйыйсы буялган. Асфальтланган юллар буйлап куе саргылт төс алган иген дулкыннары өстендә «йөзеп» барабыз. Ак каеннар, яшел яулыкларын бөркәнеп, каршыга килә. Күңелдә районның тарихи хатирәләре яңара.

— XVI гасырда бирегә — Чулман елгасы буена — балыкчылар килеп урнашкан. Алар тоткан су хәзинәләрен Чистай, Казан шәһәрләренә илтеп сата торган булганнар, дип сөйләгәннәре истә калган, «Авыл офыклары» газетасы юбилеена баргач. 1747 елда Сембер сәүдәгәре Артемий Маленков Берсут елгасы тирәсендә бакыр заводы төзеткән. Бизәнү әйберләре ясау остаханәләре белән Яриннар җитәкчелек иткән. Челтәр үрү дә алга киткән була. Әмма төп шөгыль булып игенчелек, балыкчылык, терлекчелек кала.

Ә инде әдәбият-сәнгать өлкәсенә килсәк, Балык Бистәсе төбәге бик күп шагыйрьләр, язучылар, атаклы артистлар, галимнәр биргән як буларак билгеле.

Безнең район белән тарихи эзгәлекне күрсәткән тагын бер кызыклы факт бар. Татар халкының олуг ике әдибе — Мөхәммәт Гали 1903 елда ук Лаеш өязенең алтмыш чакрым ераклыктагы Олы Елга (хәзерге Балык Бистәсе районы) авылыннан Сабага терәлеп торган Сатыш мәдрәсәсенә килеп белем алган. Шушы мәдрәсәдә үк Укмас авылыннан танылган шагыйрь Миргазиз Каюм улы Укмаси да (Зәбиров) укыган. Бу хакта күршеләрнең «Туган як» музеенда да тарихи мәгълүматлар бар.

Әнә шундый уйларны күңелдән уздыра-уздыра, җәйге табигатькә хозурланып бара торгач, балыкчылар бистәсенә килеп җиткәнебезне сизмичә дә калганбыз. Шул арада Чулман киңлекләре өстеннән җил исеп, кем әйтмешли, туксан тугыз дулкын йөзеп үтте. Менә хакимият бинасына үтәбез. Кырык биш-илле яшь арасындагы, энергиясе ташып торган урта буйлы, төптән таза чыккан гәүдәле, көләч йөзле, шомырттай кара чәчләренә көмеш йөгергән ир уртасы — якташыбыз каршы алды.

...Хөрмәтле укучым! Бу хәзер башкарылган эшләрне сөйләттерә инде, дип уйлый торгансыңдыр. Юк! Алай түгел әле. Иң элек Равил туганның балалык, үсмер елларына, кыскасы, хакимият башлыгына кадәрге чорга тукталып үтик. Яшьлеккә кайтыйк. Чөнки «җир йөзендә бернәрсә юк яшьлектән кадерлерәк» диләр бит!

Равил үзе 1954 елның 1 февралендә ерак Себер җирендә туа. Аның әнисе Рәсилә, Саба районының унсигез кызы белән бәхет эзләп, русчалатып әйтсәк, вербоваться ителеп килә бирегә. Шул вакытта туган ягыннан мәңгегә аерыласын күз алдына да китермәгәндер алты балалы Шаһинур белән Майсүфә гаиләсендә үскән кыз бала. Бәлки, чыгып киткәндә, бер уч Курсабаш туфрагын да алгандыр.

Кайларда гына йөрми адәм башы, кемнәр белән очраштырмый язмыш дигәннәре. Торган җиреннән беркем дә рәхәтлектән кузгалмый бит. Шунда Гарифулла исемле Себер татары белән очраша Рәсилә. Тәртипле, матур итеп йөреп, сәгате суккач, шәригать законнары кушканча никахлашалар. Тугыз айдан, ир белән хатын арасындагы мәхәббәтнең бер татлы җимеше булып, дөньяга ир бала килә. Тупырдап торган, терекөмеш кебек, кулда шуа торган Равилне күргән саен: «Мин чын ир кеше бит, бракодел түгел бит!» — дип горурлана Гарифулла. Әни кеше дә куанып бетә алмый.

...Адәм баласы җир йөзенә бәхетле булу өчен килә. Тормыш, яшәеш кайгы-сагышлардан, хәсрәт-борчулардан да азат түгел шул. Аларның алма кебек түгәрәк бәхетләре озакка бармый. Равилнең балачагы бик баллы-майлы булмаячагы тиз ачыклана. Булыр-булмас, тулыр-тулмас ике яшьтә атасыз кала ул. «Иртә китте, ашыгып китте», — диләр андый кеше турында. Әнисенә дә Гарифулласы белән бер җан, бер тән булып озак яшәргә язмаган икән. Тәмам сыгылып төшә Рәсилә. Аяк астында җир шуышып киткән кебек була, хәләлен мәңгелеккә озатканда. Ә Равиле берни дә аңламый әле. Фәкать аның уйчан йөзендә сөйкемле нурлар гына уйный. Шушы минуттан башлап яшәү, тормыш өчен көрәш мәйданында үзе генә булачагын, «әти» дип бик өзгәләнәчәген дә чамалый ул.

Бу урында Кукмара районының «Яңа тормыш» арендачылар берлеге рәисе, элеккечә әйтсәк, легендар колхоз председателе, 1941 елда туып, әтисез үскән (сугышта үлгән) Рәфыйк Рәүфов турында язылган «Бәхет бишегем Толлы» дигән документаль повестьтан (авторлары Рафаэль Сибат һәм Мөҗип Хаҗиев) өзек китерү мәгъкуль булыр. *«Ә әтисез кеше тәтисез кеше генә түгел, ятим вә ким кеше. Ләкин шунысы да бар: андыйлар яшьтән үк тормышка берегеп үсә, үз максатларына үҗәтләнеп ирешә. Болар инде кемнеңдер таяныр таза җилкәсен, ярдәмгә дип сузган «йонлач кул»ын эзләп маташмыйлар, ә юлны үзләренә үзләре яралар. Нинди генә авырлыклар килмәсен һәм иң зур каршылыкларга очрасалар да, һаман алга баралар, тауга үрмәлиләр».*

...Сабый, акыл җыеп, тирә-юньне таный башлаганда, «Әти!» дип эндәшер кешесе юклыгына тиз төшенә. Әмма аны газиз әнкәсе янында булу тынычландыра.

Сугыштан соңгы, шулай ук илленче еллар башында ялгыз хатын-кызга тормыш итүләре җиңел булмаганлыктан, әни кеше уңышсыз башланган тормышын яңадан корып карый. Җан бит яшәр, тормыш итү өчен яралган. Гарифулланың авылдашы Алим дигән кешегә кияүгә димлиләр Рәсиләне. Үзенчәлекле холыклы ир була ул. Яшь әти Равилне өнәми башлый. Уртак кызлары Асия тугач, хәл тагын да катлаулана. «Күз карашы ук Гарифулланыкына охшаган», — дип тә кыерсыта сабыйны каты бәгырьле

Алим. Коеп куйган этисе булгач, нишләсен инде ул?!

Түземе төкәнгән бичара ана газиз баласын артык җанга әйләндерергә теләми. Ятимлек ачысын, гөнаһсызга рәнҗетелүләрне һәм кирәкле-кирәксез кагылуларны күрмәсен өчен, Курсабашка — төп нигезгә кайтарырга була. Яшерен-батырын түгел, гаиләнең, аның эчке тормышының бөтен кешегә дә әйтеп булмый торган үз серләре бар бит.

— Поездда бер килеп, бер китеп шактый йөрдек без. Әни, сагынуына түзә алмагач, кайтып ала торган булгандыр, — дип искә ала ул елларны Равил. — Балачакның паровоз тавышлары, аларның «маңгай»ларындагы Ленин, Сталин рәсемнәре әле дә күз алдымда тора...

Дулкын өстендәге кебек, еш кына поезд юлында була алар.

«Игелекле эшнең иртәсе-киче юк» диләр бит. Данлыклы Башаманнар нәселеннән булган, үзләре дә алты бала үстерүче Шаһинур карт белән Майсүфә карчык якты чырай белән каршы алалар оныкларын. Дөрестән дә, хезмәт сөеп, тырышып-тырмашып, гомер-гомергә җитешле тормышта яши Хәйретдиновлар. Аларның эти-әниләре дә һөнәрле була. Равилнең әбисенең этисен — Шакирҗан картны — тегүче буларак та хөрмәт итәләр. Ике сыер, ике ат асрап яшәгәнлектән, 1921 елгы коточкыч ачлыкны да исәнимин үткәрәләр. Кыскасы, холыклары белән сабыр, акыллары белән дөнья солтаны саналырлык әби белән бабасында торып кала Равил. Уйнарга иптәшләр дә бар бит үзенә. Төп нигездәге иң кечкенә кыз Гөлсәрия белән яшь аралары нибары җиде генә ай була. Нурия, Әлфинур апалары, Шамил белән Камил абыйлары да кайтып төшкән сәгатьтән үз энеләрен якын итәләр. Тик, китә башлагач, газиз анасы белән аерылу минутлары гына бик авыр була. Мөлдерәмә яшь белән тулган күзләрен әнисенә төби ул. Аны күреп, ана кешенең дә бер бушанасы, язмышыннан зарланасы, газиз баласын кочаклап үксеп-үксеп елыйсы килә башлый... Бу минутларда ана йөрәге ничек түзгәндер?! Әмма чыдарга, юлга кузгалырга кирәк була. Өстендәге ал төскә зәңгәр чәчәкләр төшкән күлмәге, башындагы ап-ак яулыгы сабый күңелендә мәңгегә кала. Ким-хур булмый Равил күп балалы гаиләдә, туганнарына ияреп, әби белән бабасын «әти», «әни» дип йөри башлый. Моңа нигез дә бар кебек: әле этисе исән вакытта сборга алынгач, әнисе туган авылына кайтып, вакытлыча Мөндеш станциясендә такта яру пунктында эшләп тора. Аннан төшке ашка кайтып йөрү мөмкинлеге булмый. Шуңа күрә, бик елаганда, Майсүфә әбисе Гөлсәрия белән Равилне дә имезә. Шулай булгач, күкрәк сөте ашаткан кешене ничек «әни» димисең дә, ничек үзеңне аңа гомер буе бурычлы санамыйсың?!

Тормыш сәхифәләрен тәфсилләп барлый башласаң, затлы ике гаилә — Хәйретдиновлар һәм Хәйруллиннар турында аерым китап язарга булыр иде. Тормыш шулай инде: адәм баласы, исән-сау кеше, нинди генә авырлыкларга юлыкса да яшәргә омтыла, эшкә өйрәнә, туган-торган җиренә ныграк игътибар итә башлый. Равил дә кечкенәдән үк үзенә «канат чыгарган» Курсабаштагы чишмә-елгаларның, урам-тыкрыкларның, басу-кырларның, урман-аланнарның серле атамалары белән дә кызыксына. Шулай итеп, үскән җиренә ихтирам һәм хөрмәт хисе мәңге онытылмаслык булып бөреләнә. Мәктәптә бик яхшы укый, шул ук вакытта терекөмеш кебек җитез һәм шаян була. Гадәттә, шук бала гел икеләләр җыя бит. Ә Равил, киресенчә, ударник яисә отличник. Математика фәнен аеруча ярата.

Бала күңеленең канатланган, шул ук вакытта кимсенгән чаклары да булмый түгел. Болар турында тәфсилләп сөйләргә яратмый Равил Гарифуллович. Иреннәре арасыннан өр-яңа кызыклы вакыйгалар бер-бер артлы сытылып чыга. «Шәп факт бу!» — дип уйлап та бетермисең, ул: «Монысы язу өчен түгел», — дип кистереп куя.

Шулай да балачак илендәге бик гыйбрәтле хәлне искә төшереп үтик әле. Юрий Гагарин галәмне яулагач, бик күп яшүсмерләр космонавт булу турында хыяллана башлыйлар. Курсабаш малайлары да, клуб янындагы текә Зәрә тавыннан чанага утырып төшкән вакытта, күзләрен чытырдатып йомалар да үзләрен космоста итеп хис итәләр. Беркөнне, бәхетсезлеккә каршы, Равил белән шул тирәдә яшәүче малайның чаналары бәрелешеп, «икенче космонавт»ның борыны каный бит. Шуннан тегенең әбисе каты итеп ачулана Равилне:

— Килмешәк! Җилдән туган!

Бик гарьләнә гөнаһсыз сабый. Елый-елый, ниндидер төссез юл буйлап өйләренә таба атлый ямьсез сүзләр белән миңгерәгән Равил. Матур хыяллары сүнә, кышкы матур табигать күзенә күренмәс була, гүя бөтен күк йөзен кара болыт каплый. Тәкъдиренә шулай язылгач, ни эшләсен бала?!

— Ничек алай булсын! — дип, әбисе сандык төбеннән оныгының туу турындагы таныклыгын яшен тизлеге белән тартып чыгара. — Менә бит, синең этиең — Гарифулла. Фамилияң — Хәйруллин.

Шул мизгелдә генә IV класста укучы бала моңарчы Курсабаш бабайлары фамилиясендә йөргәнен сизеп ала һәм күңелендә ата-бабадан килгән ныклык, үҗәтлек уяна. Мәлҗерәп торуларын бер читкә куеп, таныклыгын кош тоткан кебек эләктерә дә мәктәбенә йөгерә:

— Үзгәртегез минем фамилиямне! Үз этием, үз фамилиям бар икән бит минем!..

Тән ярасы китә, ә сүз, күңел җәрәхәте гел сыкрап, әрнеп тора шул. Бу вакыйга үсеп җиткәч тә исенә төшкәләп тора язма героебызның.

Борын канау белән бәйле тагын бер хатирә бар икән әле. Җиргә сары яфраклар коелып, көннәр көзгә авышкан вакытта, ягъни 1 сентябрьдә, тәүге тапкыр мәктәпкә бара Равил. Сигезенчеләргә кызык бит,

озын тәнәфестә көрәштерә башлыйлар беренчегә кергән малай-шалайларны. Шунда туп шикелле Равилебез, өлешемә тиген көмешем дигәндәй, Харис исемле классташын күтәреп ала да баш аркылы җибәрә, тагын борын җимерелә бит.

Әмма бу мизгелләрдә еллар үтәр дә, шушы малай классик көрәш буенча Россия һәм Татарстан чемпионнары булырын беркем дә башына китерми.

— Кар бетәр-бетмәс вакытта ук без Хәниф абыйлар бакча башына сарык сакларга чыга башлый идек. Менә шунда, чирәмдә, малайлар көн буе көрәштеләр, ә кышын Кече урманны чаңгы белән аркылыга-буйга йөриләр иде, — дип искә ала Равилнең классташы, ике дистә елга якын Курсабаш урта мәктәбен җитәкләүче мәгариф отличнигы Рузалия Сәлахиева. — Равил, шаян булса да, бик яхшы укыды. Контроль эш вакытында, үз вариантын чишкәч, күршесенә булышты. Без аңа бик соклана идек. Үтә туры сүзле, гадел булуы да хәтердә калган. (Монда тагын шуны искәртеп китик әле: Равил Гарифуллович, Балык Бистәсендә эшли башлагач, район газетасы битләрендә яңа ачылган «Синең кыйблаң гаделме?» рубрикасына беренче интервьюны үзе бирә.)

Кыскасы, яшьтән үк малайларның лидеры булды ул. Әмма без Равил үз тырышлыгы белән шушындый биеклекләр яулар дип һич уйламаган идек. Ә бит безнең төбәк гыйлем, батыр кешеләре белән гомер-гомергә дан тоткан. Советлар Союзы Герое Зәки Хәбибуллин, 1922 елда ук М.Фрунзе исемендәге Хәрби академияне тәмамлап, соңыннан генерал булган, тарих фәннәре докторы дәрәҗәсенә күтәрелгән Минзакир Әпсәләмов, авиация генералы Мөхәммәдулла Ибәтуллин, бертуганнар — авиация полковнигы Рафис һәм химия фәннәре докторы, «Теплозащита» фәнни-производство берләшмәсе генераль директоры Рәкыйп Бәйрәмовлар, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең хор җитәкчесе, республикабызның халык артисты Венера Гәрәева, аның әнисе — Татарстанның атказанган артисткасы Мәбрүбә Рәхмәтуллина, алтын куллы хирурглар — бертуган Васил һәм Шәүкәт Галимҗановлар, әйдәп баручы укытучылар Розалия Шәмсетдинова, Мәдинә Исламова, Рәбига Сәлахиева, мәктәпнең яңа бинасын салдырган Татарстанның атказанган төзүчесе Илдар Нигъмәтҗанов — әнә шундыйлар. Үзебезнең классташларыбыздан Вәкил Галимуллин, Сәетша Җиһаншин (Равилләрнең туганы), Рәүф Галәветдинов, Таһир Әхмәтов һәм башкалар, сынауларда сыгылмыйча, тормышта үз урыннарын таптылар.

2001 елның мартында Курсабаш мәктәбе үзенең ярты гасырлык юбилеен зурлап үткәрде. Бик күп хатирәләр яңарды бу көнне. Сөйләшеп сүзләре бетмәде. 1969 елда сигезенчене тәмамлаган Равил дә күптән күрмәгән кайбер классташлары, укытучылары, авылдашлары белән иркенләп аралашты. Бөтен педагогик коллективка, бигрәк тә Мөстәдинә, Әнисә, Зөлфирә апаларына, мәктәп директорлары Халит абыйсына һәм Рәйсә апасына рәхмәт сүзләре чиксез иде аның.

Шушы мәктәптә «канат чыгарган» егет ата-бабасы шөгылен — игенче һәм терлекче эшен дәвам итәргә карар бирә һәм Чистай авыл хуҗалыгы техникумында укый башлый. Аңа бу елларда Казанда һәм Түбән Симет авылында яшәүче Нурия һәм Гөлсәрия апалары кулларыннан килгәнчә ярдәм итәләр, укысын, кеше булсын, диләр. Менә шушында инде Равил классик көрәш белән ныклап шөгыльләнә, яшәешне спорттан башка күз алдына китерә алмый башлый. Тумыштан, нәселдән килгән бу сыйфатны камилләштерә һәм техникумда укыганда ук СССР спорт мастерлыгына кандидат була. Нәселдән килгән дияргә нигез дә бар бит. Курсабаштагы Шаһинур бабасы да авыл сабан туйларында батыр калгалаган була.

Себердәге бабасы да затлы, гыйлемле була Равилнең. Аны дөньяга китергән шушы изге җир ниндидер тылсымлы көче белән үзенә чакыра. Анда бит әле аның бернинди акчага да сатып алып булмый торган, үзенә тормыш бүләк иткән бик тә газиз әнисе дә бар.

...Үз-үзен белә башлагач, әлеге дә баягы Шаһинур бабасы — икенче группа сугыш инвалиды — үзенең бушка бирелә торган поезд билеты белән кышкы каникул вакытында алтынчы класста укучы оныгын Себер җиренә алып бара. Бу вакытта инде туган җир, туган як төшенчәсен күңеле, җаны белән сиземләгән Равил әнисе белән Асия сеңлесе (үги әти инде вафат була) яши торган шәһәрнең тарихына да игътибар итә башлый. Ялуторовск Себер татарлары яши торган бистәдә 1639 елда ук оеша башлаган Төмән өлкәсендәге шәһәр икән. Биредә байтак декабристлар сөргендә булган. Аларның музейлары да бар. Тимер юл станциясендәге бу шәһәргә авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлау заводы урнашкан, азык-төлек, урман, агач эшкәртү промышленносте алга киткән. Декабристлар заманында төзелгән мәктәп белән дә кызыксына Равил, аларның музеенда була. Аннан соң Татарстан кунакларын шушы шәһәрдән утыз чакрым гына ераклыктагы Тубыл елгасы буена утырган әти-бабасы авылына алып китәләр.

Менә шунда инде Равил Себердәге бабасын тәүге тапкыр күрә. Җиргә тирән тамыр җибәргән имән кебек нык, таза-сау Ярулла белән күрешә. Бик мул тормышлы икән Равилләрнең нәселләре. Алты почмаклы, мансардалы, балконлы өй. Мал-туар да ишле. Аты да, сыеры да — икешәр (ул чорда!). Көймәсе белән үзенең балык күле дә бар. Ярулла бабай төбәкнең иң мәртәбәле кешесе — шушы зур авылның мулласы да икән...

Бабай оныгын бик ярата. Кысып-кысып кочаклый, аркасыннан сыйпый, күзләре яшь белән тула. Калырга кыстый башлый. Равилнең җавабы кыска була:

— Рәхмәт, бабай. Кала алмыйм. Иң авыр вакытта үз куенына сыендырган Курсабашыма кайтам. Аннары ...мәктәпне дә тәмамлыйсы бар.

Шушы сәфәрдән соң бер ел үткәч, Шаһинур абзый да бу фани дөньядан бакыйлыкка күчә. Гүрең якты, туфрагың йомшак булсын иде, дип тели Равил.

«Ватан», «ата» сүзе бер тамырдан бит! Чистай техникумында укыганда Равилебез үзенең ата-бабасы ягыннан булган нәселе, токымы, кавеме турында еш уйлана башлый.

Халыкта «Кан тартмаса да, җан тарта» дигән сүз дә бар бит әле. Әлеге мәкаль бик урынлы да түгелдер, бәлки. Ни өчен дисәгез, җаны гына түгел, каны да тарта Равилне үз туфрагына. Техникумның өченче курсын тәмамлагач, Нурия апасы белән кабат китә ул Төмән якларына. Бу юлы инде ул, чын мәгънәсендә нәсел-шәҗәрәсенең асылын, шушы туфрактан яралганын тирәнтен аңлап:

— Бабай җаным, исәнме! — дип, җитмеш өч яшьлек ак сакаллы хәзрәтнең кочагына ташлана.

Ир-егетләр кычкырып еламый, әлбәттә. Әмма бу мизгелләрдә аларның битләрен куанычлы да, сагышлы да кайнар күз яшьләре юып ала.

Әлеге очрашу мәңгегә исендә кала Равилнең.

Бабасы үләр алдыннан — 1975 елда — тагын бер әйләнеп кайта әле ул. Бу юлы да бик озак әңгәмә коралар Хәйруллаларныкылар. Сүз, нигездә, нәселнең, алай гына да түгел, Себер татарларының чишмә башы, тарихы турында барып, бик күп мәгълүматлар ала Казан дәүләт ветеринария институтының беренче курс студенты Равил бабасы белән соңгы очрашуында.

...Безнең татар, элек-электән бил алышып, рухын һәм тән сәламәтлеген ныгыткан. Пәһлеваннарның үз алымы, җиңүгә омтылышы булган. Дөрес, һәр көрәшчене дә баһадир гәүдәле итеп күз алдына китерергә ярамый. Беренче сентябрь көнне тәүге тапкыр мәктәпкә килүчеләр арасында батыр калган Равил кечкенә буйлы, әмма бөтерчек кебек елгыр була. Беренче тапкыр җиңү бәхетен тату да аны спортның көрәш төрен сайларга этәргәндер, бәлки. Шуннан соң һәр елны авыл сабан туенда кулына сөлге ала, аннары Чистай техникумында атнага өч тапкыр махсус шөгыльләнә башлый ул. Кыскасы, ил күләмендәге чын көрәшче булып өлгергәнче, кем әйтмешли, җиде кат тиресен кубарырга, тән сызлануларына түзәргә, имгәнүләрдән курыкмаска туры килә. Җитмәсә, көрәше дә бит аның «грек-рим» дип атала. Равил атаклы тренерлар — СССРның спорт мастерлары Мәгаз Сәхабетдинов белән Әдип Нуруллин кебек остазлары ярдәмендә тиз арада бик күптөрле алымнар үзләштерә. Германиядәге совет гаскәрләре группасында хезмәт иткәндә, яраткан шөгыленнән аерылмый. Ике тапкыр «Армия чемпионы» дигән исемне яулый, соңгы ярты елда спорт ротасында була.

Ватан алдындагы изге бурычын үтәп кайткан егет туп-туры Казан ветеринария академиясенә юл тота. Шушында укыганда, СССР, Россия күләмендәге бәйгеләрдә катнаша.

Зур келәмдә үз авырлыгындагы, ягъни 57 килограммлы күпләр белән очрашырга туры килә якташыбызга. Бигрәк тә казахларның бердәнбер Олимпия чемпионы, халыкара мастер Җаксылык Ушкемперов, грузиннарның ике тапкыр дөнья чемпионы Вахтанг Благидзе, Татарстаннан Нил Мөхәрләмов, Сергей Матвеев, абыйлы-энеле Атамяннар, Анатолий Бозин кебек спорт йолдызлары белән көрәшкәнен хәзер дә горурлык белән искә ала ул.

Әнә шулай хуҗалык рәисе, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы, хакимият башлыгы, халык депутаты булганчы бик үзенчәлекле тормыш юлы узган Равил Гарифулла улы. Хәзер хезмәт биографиясенә дә күз салыйк инде аның.

Институтны бик яхшы билгеләренә генә тәмамлаган егетне Арча районына тәгаенлиләр.

«Заветы Ильича» колхозында биш ел баш зоотехник булып эшли ул. Шул еллардагы КПСС райкомының беренче секретаре Дамир Каюм улы Каюмов Равилнең өметле белгеч икәнен күреп ала да җитәкчеләр әзерли торган курска җибәрә. Аннары ул «Искра» колхозының атаклы рәисе, СССР Верховный Советы депутаты Фәйзи абыйсы Галиев кул астында берничә ай игенчелек серләренә өйрәнә. КПСС райкомының авыл хуҗалыгы бүлеге инструкторы вазифасын да башкарып алгач, якташыбызга Түбән Оры белән Кызыл Яр авылларын берләштергән Азин исемендәге колхозны тапшыралар.

— Сез аның гәүдәсе кечкенә булуына карамагыз, кечкенә булса да, төш кенә ул. Россия чемпионы, — ди орылыларга Равил Хәйруллинны тәкъдим иткәндә шул чордагы район авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы Вәгыйз Минһаҗев.

Дөрестән дә, бик тиз инаналар аның СССРның спорт мастеры икәнлеген санлап бетерергә теләмәүче, хезмәт дисциплинасын бозучы, эчүчелек белән шөгыльләнүче кайберәүләр. Күп булмасалар да, андыйлар да юк түгел бит авыл җирендә. Нәрсәсен яшерәсең инде аның?!

Булсынга дип сигез ел эшли Равил бу хуҗалыкта. Социаль-көнкүреш һәм производство бинналары төзелә. Авыллар яңара. Һәр сыердан уртача сөт саву 4000 килограммнан узып китә. Ашлык мул игелә, бәрәңге уңышы гектарына 300 центнерга җитә. 1989 ел нәтиҗәләре буенча хуҗалык районда беренче урынны яулый. Фидакарь хезмәт эзсез калмый, билгеле. «Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә үзенә. Аның грамотасы белән күкрәк билгесен Арча слетында Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев тапшыра. Рәиснең фотосурәте район Мактау тактасына куела.

**— Равил Гарифуллович, Сезне Питрәчкә идарә начальнигы итеп кем тәкъдим итте? —** дип сорап куйдым телефон шалтырап, әңгәмә өзелеп алган арада.

— Фатих Сәүбәнович Сибагатуллин. Шул чордагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрыбыз. Ул мине яхшы белә иде. Гомумән, миңа абруйлы, танылган җитәкчеләр белән эшләргә насыйп булды, — дип фикерен дәвам итте якташым. — Хезмәт юлымда әйбәт кешеләр күп очрады. Питрәч районының хакимият башлыгы Флүн Хәбибуллинга да бик рәхмәтлемен. Гади колхоз председателеннән алып, ул мине беренче урынбасары — идарә начальнигы итте. Дилбегәне бергә тарттык. Аннары, дүрт ел ярым кулга-кул тотынып эшләгәч, күрше Балык Бистәсе районы хакимият башлыгы итеп тәкъдим итте. Мондый кешеләргә ничек рәхмәтле булмыйсың!

Менә район кадәр районны җитәкли башлаганына да өч елдан артты. Игенчелек культурасын күтәрүдән башлап җибәрә ул эшне. 2001 елда, уртак тырышлык белән, билгеле, районда тәүге тапкыр 118 мең тонна тулай ашлык җыйнап алынган икән, монда бик күп игенчеләрнең, белгечләрнең, җитәкчеләрнең маңгай тире тамганы ачык күренә. Ә менә «Масловка», «Кама» кебек алдынгы хуҗалыклар һәр гектардан алынган уңышны 80–50 центнерга җиткергәннәр. Терлекчелек өлкәсендә дә уңай якка үзгәрешләр бар. Районда барысы егерме меңнән артык мөгезле эре терлек, тугыз мең баш дуңгыз асрала. 2000 елга караганда аларның баш саны арткан.

Районда газ-су кертү, асфальт юллар салу, күперләр төзү, электр линияләре реконструкцияләү эшләре дәвам итә. Хәзерге вакытта газлаштыру 96 процентка үтәлгән. Балык Бистәсенең үзәгендә балалар тудыру, прокуратура, эчке эшләр бүлеге биналары һәм 18 фатирлы йорт төзелеп килә. Мәчетләрнең саны арта бара. Район мәдәният йорты, «Туган як» музее да капиталь ремонттан соң исеме җисеменә туры килә торган булды. Шушы төбәктән чыккан сәнгать-әдәбият әһелләре белән очрашулар, аларга багышланган кичәләр уздыру матур гадәткә керде.

Спорт белән яшьләр дә, өлкәннәр дә шөгыльләнә. Атнага ике тапкыр эштән соң хакимият башлыгы Равил Хәйруллин белән бергә барлык җитәкчеләр һөнәр училищесының спорт залына юнәлә.

Әнә шулай хезмәт белән спортны дөрес итеп чиратлаштырып яшәүгә көч таба ул.

Арча районының Ташкичү авылы кызы — ак белән караны бик тиз аера торган, өстәвенә зур эчке культурага ия Фоадия белән тыйнак, матур тормыш кичерәләр алар. Яшьтән үк бөреләнгән олы мәхәббәткә, бер-берсенә ихтирам хисләренә уралган гаилә бу. Олы уллары Фаил, Казан дәүләт университетының юридик факультетын тәмамлап, белгечлеге буенча эшли. Салават та юрист булырга әзерләнә. Себердәге Рәсилә әниләре белән дә тыгыз элемтәдә торалар. Аның җитмеш еллык юбилеен матур итеп билгеләп үттеләр.

— Балык Бистәсе — гүзәл табигатьле як, — диде Равил Гарифуллович әле күптән түгел булган икенче очрашуыбызда. — Халкыбызның күңеле иркен, йөзе якты, талантлар күп. Хәзер бөтен тырышлыгыбыз, әзләнүчәнлегебез алда торган бурычларны тормышка ашыруга юнәлдерелә.

Саубуллашыр алдыннан мин әңгәмәдәшемә соңгы соравымны бирдем:

**— Равил Гарифуллович, хакимият башлыгы булгач, туган җирегезгә сәфәр кылырга насыйп булдымы?**

Ул, гадәттәгечә, башта тирән уйга калды һәм болай дип җавап бирде:

— Кайттым. Чөнки бабай төшемә керде. Хәер көтеп ята кебек тоелды. Барып корбан чалдырдым. Бабай белән әтинең каберләре янында Коръән укыттым. Ул минутлардагы кичерешләр әле дә күңелемдә тора. Башка әллә нинди уйлар килде. Туфрак астынданиләр уйлап яталар икән алар? Тәннәре җир куенында булса да, аларның җаннары үлемсез кебек бит, — диде Равил Гарифуллович. Аннары әйтергәме-юкмы дигәндәй карап торды да фикерен болай дип йомгаклады: — Менә шунда каберстанда минем күңелемә якташыбыз, якын дустым, Татарстанның халык шагыйре Равил абый Фәйзуллинның түбәндәге шигъри юллары («Зиратта») килде:

Уйласаң, алар — без,
Ә без тиздән — алар...

Әйе, һәркемне уйланырга мәҗбүр итәрлек итеп әйтелгән фәлсәфи фикер бу. Шуңа күрә чоңгыллы гомер агышларын, төрле киртәләрне җиңә-җиңә, чуалган язмышын спорт һәм хезмәт белән бәйләп, алга таба да ирешелгәннәрне ныгыту өчен зур көч куеп яши һәм эшли районыбызның Курсабаш авылында алтынчы класста укыганда ук колхоз терлекләрен көтә башлап үскән Себер егете Равил Гарифулла улы Хәйруллин.

*2002*

# Галиҗәнап игенче

Һәр тармакта эшләүчеләрнең һөнәри бәйрәмнәре бар хәзер. Менә 21 ноябрь телевидение көне булган икән. Шул уңайдан моннан утыз елга якын элек Саба һәм Арча районнары командалары катнашында уздырылган телевизион конкурс искә төште. Һәр районнан берәр хуҗалык рәисе, тракторчы, сыер

савучы, аш-су остасы, рәссам кебек һөнәр осталары белән үзешчәннәр барган иде бәйгегә. Киеренке көрәш студиянең үзендә барды, һәм безнең район командасы җиңде. Бераз яклау да булды шикелле: Ленин орденлы аш-су остасы, якташыбыз Юныс ага Әхмәтҗанов, мәсәлән, безнең токмач кисүче кызга үтә үткен пычак (күршеләргә үтмәсне, билгеле!) биргән иде. Ул кызның бармагын кисүе, токмач өсте ал төскә кереп барганы да телевизордан күренеп китте. Конкурс беткәч, фотосурәткә дә төштек әле. Шуны эзләп таптым. Анда катнашканнарның байтагы юк икән инде: райком секретаре Марсель Васильев, Ленин исемендәге колхоз рәисе Ислам Хаҗиев, редактор Хөснулла Шәфигуллин, рәссам Зиннур ага, балетмейстер Фәрит Зәйнетдинов һәм мәдәният йорты директоры Нәгыйм Нигъмәтҗанов.

Шул конкурста тирән белеме, техника серләрен яхшы белүе белән күпләрне сокландырган «Марс» колхозы тракторчысы Габделбәр Габделәхәтов язмышы кызыксындырды мине.

— Дөрес, элегрәк ашказанына операция ясаткан иде. Хәзер исән-сау. Әле шушы көннәрдә генә үзенең җитмеш еллык юбилеен үткәрде. Район яшьтәше ул, — диделәр авылдашлары.

Туган җиргә бирелеп хезмәт иткән, аның ипекәен булдыру өчен бөтен иҗади көчен салган Галиҗәнап игенче Габделбәр абыйның тыйнак, җитешле өендә сөйләшеп утырабыз. Туксан өч яшьлек әнисе Фазилә әби дә, исән-имин булып, үзләре тәрбиясендә яши. Карчыгы Оркыя апа, шөкрана кылып, чәй әзерләп йөри. Унынчы дистәне ваклаган аның әнисе Рәхимә абыстай да Сабада гомер кичерә икән.

— Безнең балалык еллары авыр чорга туры килде. Беренче класска кереп, латин шрифты белән ярты ел укыган идек, алфавит үзгәрде. Унбер яшь ярым булгач, сугыш башланды. Әтине — икенче группа инвалидны — хезмәт армиясенә алдылар. Олы бала идем. Иң беренче итеп чабата ясарга өйрәндем. Ачлы-туклы килеш, ат җигеп, нәрсә кушсалар — шуны эшләдек, — дип сөйләп китте ветеран.

Армия сафларыннан кайткач, Үрнәккә барып, тракторчы һөнәрен үзләштерә ул. 1956 елда Саба МТСының «У-2» тракторында Мәҗит абыйсы Әхмәтов белән эшли башлый. Урта Сабада җир сөрәләр, лафетлыургычны өстерәтәләр, көзге-кышкы айларда ашлык суырткычны әйләндерәләр. Гомер уза тора. МТСлар да үзгәртелә. 1958 елда Габделбәр Мәҗит абыйсы белән, 500 гектар мәйдандагы игеннәрне теземнәргә салып, районда беренчелекне яулыйлар. Габделбәр, 1958 елда чылбырлы тракторга күчеп, егерме бер ел буе чәчә, җир эшкәртә, алдынгылыкны бирми.

— Бер елны өч тракторчы — Габдулла Шәрифуллин, Миннехан Садыйков һәм үзем — колхозның бөтен басуларын 31 августка ук туңга сөреп бетердек. Чәчүдә дә сынатмадык. Бик күп еллар сабан батыры булдым. Менә комсомол вакытта ук ВЛКСМ өлкә комитеты тарафыннан бирелгән «Чәчү батыры» дигән мандат бүген дә саклана әле, — ди ул.

Әйе, мандатка легендар Рәис Беляев кул куйган. Габделбәр агага тырыш хезмәте өчен бирелгән мактау грамоталарын, дипломнарны, таныклыкларны, медальләрне һәм «Ярышта җиңүче» билгеләрен карап чыгарга да шактый вакыт кирәк. Коммунистик хезмәт ударникларының Казанда үткәрелгән I съезды делегаты да була. Сукачылар ярышында колхозда һәм районда күп тапкырлар призлы урынга чыга, бер елны республикада икенче кыр батыры була. Тәртипле, намуслы, бөтен күңел-йөрәге белән җир яраткан гади хезмәт кешесен авылдашлары берничә чакырылыш авыл советы депутаты, ә коммунистлар КПСС райкомы әгъзасы итеп сайлыйлар.

Габделәхәтовлар, берсеннән-берсе тырыш биш кыз тәрбияләп үстереп, һәркайсына тирән белем бирәләр. Һәдияләре — Норлатта табибә, Рәмзия — Юлбат урта мәктәбендә директор урынбасары, Ризәдә — сәүдә системасында бухгалтер, Чулпан — «Марс» күмәк предприятиесендә икътисадчы, Ләйсән — саклык банкы хезмәткәре. Кияүләрдән дә уңалар Габделбәр абый белән Оркыя апа. Алар да җаваплы хезмәтләрдә — хирург, тарих укытучысы, эчке эшләр майоры, күмәк предприятие рәисе һәм урта мәктәп директоры.

Тыныч күңел белән, унике оныкның әби-бабасы булып, мал-туар, умарта асрап, бәхетле картлык кичерәләр Габделәхәтовлар.

*2000*

# Өчиле егете

Бу язмамда үзебезнең районның Өчиле авылында ятимлектә үсеп, гади тракторчыдан «Шәмәрдән ит комбинаты» акционерлык җәмгыяте генераль директоры дәрәҗәсенә күтәрелгән Илдар Фәтхерахман улы Нигъмәтҗанов турында сөйләргә, аның күңел дәфтәрен актарырга телим. Кайберәүләрнең: «Ит комбинаты директоры булганга язгандыр инде», — дип уйлаулары бар, әлбәттә. Юк, аның өчен генә түгел. Беренчедән, үзен, гаиләсен кырык елга якын белөм. Икенчедән, сәнгатькә гашыйк кеше ул, хезмәтне һәм тормышны җыр белән бәйләп яши. Өченчедән, кешелекле, гади, ярдәмчел җитәкче. Дөрес, аның ярдәм итәргә мөмкинлеге бар, дип караучылар да булыр. Мөмкинлек бер нәрсә, киң күңелле була белү дә кирәк бит әле.

Хәтердә моннан ике-өч ел элек булган вакыйгага уелып калган. Эш бүлмәмә бер ханым килеп керде.

«Мин сезгә бер хат китердем. Почтага салсам, алырлар дидем. Шушыны газетада чыгарыгыз әле, — дип елый-елый сөйләргә тотынды. — Маһиҗамал Галләмова мин. Тумыштан инвалид. Шулай булса да, гомер буе эшләдем. Үземнең хезмәт урынымнан бер дә ярдәм итү мөмкинлеге булмагач, мин Илдар Нигъмәтҗановка, бер поселокта яшәүче кеше һәм депутат буларак, газ кертүдә ярдәм сорап, читенсенә-читенсенә генә мөрәҗәгать иткән идем. Без, табигать тарафыннан кимсетелгәннәр, болай да гомер буе кимсенеп яшибез бит. Гозеремне тыныч кына тыңлады да: «Апа, булышырбыз, булыр», — диде. Сүзендә торды. Өемә газ керде. Оҗмахта яшим мин хәзер. Шулай дип языгыз. Атлаган саен Илдарга рәхмәт укыйм. Бер мин генә түгел, күпләр ихтирам итә аны. Ул, җитәкче буларак, күзеңә карап, нинди уй-хәсрәтең барлыгын йөрәге белән тоя шикелле. Кайберәүләр кебек, кеше кергәч почмакка йә өстәл астына карап утырмый, телефоннан сөйләшергә дә тотынмый.

Шулай бервакыт, Арча районына узышлый, безнең Югары Утар авылы янәшәсенә урнашкан балалар йортына сугыласы иттем. Анда төрле яшьтәге йөздән артык акылга зәгыйфь һәм гарип бала тәрбияләнә. Соңгы биш-алты елда шуларга ел саен Яңа ел пакетлары әзерләтә икән Илдар Фәтхерахманович. Менә шундый игелекле, ярдәмчел кеше инде ул».

«Гомерне еллар гына билгеләми» диләр. Шулай булса да, олыгая башлагач, һәркемнең яшьлегенә кире кайтып, үткәненә йомгак ясый торган гадәте бар. Яшь узган саен, туып үскән җирләр ешрак искә төшә. «Мин бик күп чит илләрдә булдым. Әмма кайда булсам да, туган як истән чыкмый. Көндез искә төшмәсә, төнлә төшкә керә. Шуңа күрә, сәфәрдән кайтуга, Өчилегә ашкынам мин, әти-әни, карап үстергән Дәүләтҗан абый каберләре янында булам, Гөлбәгыйдә җиңгинең, аның балаларының хәлен беләм», — ди Илдар Нигъмәтҗанов.

Дөрестән дә, Өчиле табигатьнең гаҗәеп матур җиренә урнашкан. Ә сандугачлар моңы яшьтән үк Илдар күңеленә күчә. Хромкада уйнап, үзе җырлап, ничәмә-ничә тапкыр әйләнгәндер ул Өчиле урамнарын, тау буйларын. Кечкенә авылның клубы һәрвакыт гөрләп тора ул вакытта. Кечкенә Илдарның җыр-моңга тартылуына оста баянчы Сәлим абыйсы Гарипов, аның сеңлесе Венера Гәрәева да сәбәпче булгандыр. Илдар үзенең тәүге тапкыр авылдашлары алдында җырлаганын яхшы хәтерли әле. Татар халык җыры «Сибелә чәчем»не аеруча ярата ул.

Еллар үтә тора. Газиз туган авылын калдырып читкә китәргә туры килә И.Нигъмәтҗановка. Башта ул Башкортстанда эшли, аннан үзебезнең районга кайта. Әмма туган яктан, газиз авылыннан аерылып торса да, җыр аңа гел юлдаш була. Илдар Фәтхерахманович менә инде утыз елга якын җитәкче эштә. Шактый еллар «Татагропромстрой»ның Шәмәрдәндәге асфальт-бетон заводын, аннан соң хуҗалыкара төзү оешмасын җитәкләде. Бу өлкәдәге хезмәтләре өчен аңа «Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирелде. Шул еллардан бирле поселок һәм район советы халык депутаты итеп сайлана.

Чын-чынлап һәвәслек хас аңа. Үзе генә түгел, гаиләсе белән шундый алар. Хатыны Мәймүнәнең җырлавын шәмәрдәнлеләр дә, Саба, Балтач, Арча, Кукмара районнары тамашачылары да яхшы хәтерлидер әле. Кызлары Айгөл дә, Миләүшә дә җырга гашыйк. Уллары Илһам вокаль инструменталь ансамбльне яратты.

Менә 1990 елдан бирле катлаулы тарихлы чал комбинат белән җитәкчелек итте Илдар Фәтхерахман улы. «Шәмәрдән ит комбинаты»на нигез салынуга 1997 елда җитмеш ел тулды.

— Башта йомырка җыйганнар, тора-бара чебешләр симерткәннәр, аларны суеп шәһәргә җибәрә торган булганнар. Тавык кына түгел, казы, үрдәге килеп торган. Ә терлекләр кабул итү соңрак башлана, — дип искә ала коллективны егерме ике ел җитәкләгән ветеран Әбелгаз ага Дәминов.

Комбинат директоры итеп Илдар Нигъмәтҗанов билгеләнгән коллектив үзенең яңарыш чорын кичерә. Атказанган төзүче исемен йөртүче яңа хуҗа эшне сазлыкка урнашкан комбинат биләмәсен асфальтлаудан башлый. Чөнки резин итексез бер цехка да үтә торган булмый. Тиз арада бу мәсьәлә уңай хәл ителә. Газоннар барлыкка килә. Бер үк вакытта эшчеләрнең киенү-чишенү бүлмәләре, гомумән, көнкүреш биналары менә дигән итеп ремонтлана. Өч йөз тонна сыйдырышлы суыткыч, компрессор цехы сафка баса. Озак еллар хыялда йөргән чистарту корылмасы төзелеп эшли башлый, пар казаны бинасы табигый газга тоташтырыла, коллективның күп әгъзалары яңа фатир ачкычлары алалар.

Илдар Фәтхерахман улы җитәкчелеккә алынган чорда колбаса җитештерү өчен Чехословакиядән кайткан җиһазлар тау өеме булып, күгәреп һәм тузанга батып ятты. Бер ел дигәндә шушы цех эшкә җибәрелде, һәм ул үзенең продукциясе белән халыкка дүрт елга якын хезмәт итте. Әмма җиһазларның искергән булуы колбасаның сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирмәде. Шуңа күрә инициативалы җитәкче, әлеге цехны үзгәртеп кору буенча Алман илендә булып, «Болинт» фирмасы белән уртак фикергә килеп кайтты. Шуннан соң элеккеге цех киңәйтелеп, зур реконструкция эшләре үткәрелде. Эш техниканы көйләү, эшкәртү промышленностеның Мәскәүдәге һәм Казандагы белгечләре контролендә алып барылды. Алманиядән фирма хуҗасы Лукс әфәнде Костер үзе килде һәм тәүге продукцияне үз куллары белән эшләп күрсәтте. Чит ил техникасы бик җыйнак. 45 тәүлек буе бозылмый торган итеп төрү җайланмасы да бик уңайлы. Хәзер бу цехта утызга якын кеше эшли. Бер елда гына өч йөз илле тоннадан артык колбаса ясап чыгардылар инде. Махсус белемле белгеч Тамара Хөббәтуллина җитәкчелегендәге

коллектив аның иллегә якын төрен җитештерә ала. Дөнья стандартына туры китереп эшли торган Шәмәрдән колбасасын һәркайда яратып алалар. Кибет тә ачып җибәрделәр. Зөһрә Кәримуллина җитәкчелегендәге сатучылар гөрләтеп сәүдә итәләр. Кибет өчен йөз илле квадрат метрдан артык мәйдандагы склад төзелеп бетү дә шактый уңайлыклар тудырды.

Үткән еллар турында еш уйлана хәзер Илдар Фәтхерахман улы. Дөрес, эче пошкан, күңеле борчылган көннәре дә була. Андый вакытта ул өендә тезелеп торган өч баянның берсен алып уйный. Аннан якын дусты, танылган җырчы Фән Вәлиәхмәтов алып килгән тальянга күчә. Картиналар, төрле җәнлеккошлар белән бизәлгән өйләренең иркен залы буйлап моң тарала...

*1996*

# Таяну ноктасы

Алтмышынчы елларда игеннәр уңмау үзен нык сиздергәннән соң (бигрәк тә 1963 елда), җирләрне мелиорацияләү илнең авыл хуҗалыгы тармагын интенсивлаштыруның мөһим юнәлешенә әйләнә. Ә мелиорация гидротехник, культура-техник, химия, эрозиягә каршы, агротехник һәм башка чаралар ярдәмендә туфракның уңдырышлылыгын күтәрү дигән сүз. Шушы бурычны тормышка ашыру өчен 1966 елда районыбызның Иләбәр авылында да элекке җитен эшкәртү заводы базасында машина-мелиорация станциясе (ММС) барлыкка килә. Әлеге оешма үзенең эшләү дәверендә басу-кырларның уңдырышлылыгын арттыруга зур өлеш кертте. Сазлыклы мәйданнар киптерелде, эрозиягә каршы чаралар күрелде, ясалма сулыклар өчен буалар төзелде.

Кызганычка каршы, үзгәртеп коруның кырыс җилләре мелиорация системасын да читләтеп үтмәде. Шушы тармак чаралары ярдәмендә чәчү әйләнешенә моңарчы файдаланылмый яткан җирләрне кертү түгел, Россиянең кайбер төбәкләрендә менә дигән авыл хуҗалыгы мәйданнары ташландык хәлгә килде. «Саба «Мелиорация» механикалаштырылган күчмә колоннасы»нда да эшләр түбән тәгәри. Эшчеләр оешмадан киту ягын карый башлыйлар. Калганы да еш кына эчеп онытылу турында уйлый. Белгечлеге буенча инженер-механик булган Илдус Талиповка күчмә колонна «камытын» менә шундый кыен вакытта — 2000 елның язында кидертәләр. Төгәлрәге, 7 май — якшәмбе көнне кабул итеп ала ул оешманы. Спортчылар теле белән әйтсәк, аның кинәт икенче сулышы ачылып киткәндәй була. Ниндидер финиш сызыгына якынлашканын тоеп, җиң сызганып эшкә алына. Бетмәс-төкәнмәс проблемалар эчендә кайный башлагач, ай артыннан ай үткәне сизелми дә икән. Финанс хәле шәптән булмаган оешма йөген тарта башлаганына да 4 елдан артык вакыт узган. Әллә ни күп гомер дә түгел шикелле. Ә шушыннан үтеп-китеп йөргән кешегә «Саба «Мелиорация» механикалаштырылган күчмә колоннасы» җәмгыяте биләмәсендәге үзгәрешләр күз алдында. Таралып яткан техникадан җилләр исте дисәң дә була. Җимерелеп барган биналар да йөзен үзгәртте. Биләмәгә керү капка-коймасы тәртипкә китерелде. Контора янында кукраеп торган иске гаражны яңартып, менә дигән ашханә эшләп куйдылар, тегермәнле дә булдылар. Арка тибындагы складның идәне асфальтланып, түбәсе ябылды. Ремонт остаханәсендә киенүчишенү бүлмәсенә кадәр булдырылды. Гомумән, ташландык булып бетә язган базаны тәртипкә китерүдә шактый эш башкарылды. Күчмә колоннаның «Алга» ярдәмче хуҗалыгы объектлары да игътибардан читтә калмады. Кыскасы, елдан артык вакыт эчендә күчмә колонна республика мелиораторларына үрнәк итеп күрсәтерлек хәлгә китерелгән иде. Башкарылганнарга 2001 елның июлендә үткән зона семинар-киңәшмәсендә «Татмелиорация» траст компаниясе» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Әнвәр Залаков тарафыннан да уңай бәя бирелде.

Иң куанычлысы, билгеле, күчмә колоннада төзекләндерелгән куәтле техникага районда эш фронты булдырылуда. Табигый-климатик факторлар нәтиҗәсендә бездә дә туфракка шактый тискәре йогынты ясалмый калмый. Кар сулары ел саен басуларны «ашый», яңа ерганаклар хасил була. Авыл хуҗалыгы предприятиеләре шушы проблеманы хәл итәргә заказ бирерлек хәлдә түгел. Югыйсә мелиораторлар кулындагы скреперлар, «Т-130»лар таулар күчерергә сәләтле. Күчмә колоннаны Илдус Исламович җитәкли башлагач, гәрчә финанс кыенлыклары аркасында түләү мәсьәләләре авырдан хәл ителсә дә, алар район хакимияте ярдәме белән бу эшкә ешрак алыну бәхетенә ирештеләр. Сабай белән Миңгәр арасында, Чулпыч янында эрозиягә каршы буалар төзелде, булганнары ремонтланды, «Мичән» крестьян (фермер) хуҗалыклары басуларында туфрак ашалуына каршы корылмалар эшләнде, Тимершык авылы янында асфальт юл астына 90 метрлы юан торба салып ерганак барлыкка килүен, шулай ук ташландык хәлдәге ком карьерларының ишелүен туктаттылар. Ә Сабаны урау юл янындагы элекке вак таш карьерында кош-кортлар коенырлык күл барлыкка китерделәр. «Аның суын тагын да күтәртергә план бар», — дип ачыклык кертә Илдус Ислам улы, экологияне яхшырту максатында күрелгән чараларын санауга күчәр алдыннан. Бу урында Сабада 2002 елда сафка баскан каты көнкүреш калдыклары полигонын, Сабинка елгасы буендагы элекке ферма биләмәсендә табигать зонасы булдыру буенча башкарылган эшне

күрсәтү дә җитә. Хәзер Шәмәрдәннең элекке чүп түгү урынын рекультивацияләү өчен проект әзерләткәннәр. Мелиораторларга күп кенә торак пунктларда яшәүчеләр урамнарны тигезләгәннәре өчен дә рәхмәтле.

Инде санап чыгудан туктарга вакыт булса да, күчмә колонна эшчеләренең башка районнарда да алны-ялны белмичә хезмәт куюларын әйтмичә ярамас. Әйтик, И.Сәлахиев, А.Моратов, В.Мөхәммәдиевләр Биектау районындагы ял зонасында спорт мәйданчыгы төзелешендә вагоннарда кунып эшләп яталар икән. Ә Арчага балык күлен чистартырга дүрт техника җибәрелгән. Чәчү, урып-җыю вакытында мелиораторлар Киров өлкәсендә арендага алынган басудан кайтып кермиләр. Үстерелгән бодайны түкми-чәчми җыеп алдылар. Хәзер 500 гектар мәйданда җир эшкәртәләр. «Т-130» кебек трактор башкарасы эш килеп чыкса, юл төзүчеләр дә мелиораторларга мөрәҗәгать итә. Тәҗрибәле механизатор Р.Хәмидуллин, мәсәлән, елның елында сезон чорында юл эшендә була.

«Миңа хезмәт юлымда күп кенә абруйлы һәм бай тормыш тәҗрибәсенә ия кешеләр белән эшләргә туры килде. Аеруча 23 ел Калинин исемендәге хуҗалыкны җитәкләгән Габделнур Мәүлә улын хөрмәт белән искә алам. Аңардан күп нәрсәгә өйрәндем. Аның мәктәбен узу хезмәт эшчәнлегемә уңай йогынты ясады», — дип сүзен дәвам итә Илдус Талипов.

Хәер, үзенең дә таяну ноктасы нык аның. Хөрмәт белән телгә алынган Г.Җәлилов Ош-Юмья урта мәктәбен тәмамлаган егетне хуҗалык стипендиаты итеп Казан авыл хуҗалыгы институтының механика факультетына укырга җибәрә. Тик бер шарт куя: энесе Илгиз (хәзер район электр челтәре начальнигы) таналар көтүе алырга тиеш. Күнә Илгиз. Хезмәт сөючән гаиләдә үскән егеткә нәрсә ул бер җәй мал көтү. Бишенче сыйныфтан комбайнчы ярдәмчесе булган (әтисе алдынгы комбайнчы була) Илдус исә институтта фәннәрне җиңел үзләштерә һәм 1977 елда инде дипломлы белгеч булып туган авылы Мишәбашка кайта. Хуҗалыкта яңа остаханәнең төзелеп беткән чагы. Аны җиһазлау, паркны тәртипкә китерү яшь инженерга тапшырыла. Ул елларда ишәя барган техникадан нәтиҗәле файдалану буенча максатчан эш оештырыла. Тырышлык эзсез калмый. Хуҗалык машина-трактор паркыннан файдалану буенча район конкурсларында беренче урыннарны яулый. И.Талипов баш инженер булып эшләгәндә, үзе таянган остаханә мөдире Х.Галиев, ферма механигы Х.Минкәбиров, ягулык җибәрүче Т.Хуҗин, механизаторлар М.Хәеров, Н.Рәхимуллин, С.Гафиятов, Ш.Имамиев, С.Сәйфуллин, Р.Хаҗиев, А.Әхмәтов, шоферлар М.Мусин, М.Арсланов, Р.Заһидуллин, Т.Шәехов һәм башкаларны хөрмәт белән искә ала. Гомумән, тырыш кешеләрдән бәхете була аның. Калинин исемендәге хуҗалыкны җитәкләүне авылдашлары үзенә ышанып тапшыргач та (җыелыш 1988 елның 30 гыйнварында Явлаштауда була), уңганнарга таяна. Әйтергә кирәк, туган ягына инде Тукай исемендәге колхозда дүрт ел рәислек итеп, тәҗрибә туплаган җитәкче буларак кайта ул. Тукайлылар өчен бигрәк тә 1986 ел нәтиҗәләре уңышлы була. Дәүләткә биш мең урынына ун мең центнер ашлык саталар, хуҗалык өр-яңа «УАЗ»лы, «Беларусь»лы, «ГАЗ-53»ле була. Социаль объектлар да байтак төзелә. Керәнлегә юл күтәртелә, халкы яңа кибетле була, фатирлар салына.

Шулай да Иске Мичәннән Явлаштауга кайткач, Габделнур Җәлилов кебек оста оештыручылар рәислек иткән хуҗалыкны җитәкләү җиңел булмаячагын аңлый Илдус Талипов. Калининлылар сөрү җирләренең һәр йөз гектарына 380 центнер сөт, 120–130 центнер ит җитештерәләр. Әнә шул күрсәткечләрдән чигенмәскә, тормыш тудырган проблемаларны хәл итәргә кирәк. Әйе, хуҗалык алдынгылыгын югалтмый. 1989 елда, игенчелек һәм терлекчелек продуктлары җитештерү буенча ярышта җиңеп, РСФСРның күчмә Кызыл Байрагына лаек була.

Якташлары И.Талиповка социаль проблемаларны хәл иткәне өчен дә рәхмәтле. Авыллар арасында юлларны күтәртү буенча күп хезмәт куела, бу эштә Саба урман хуҗалыгы директоры Нургали Миңнехановның да булышлыгын тоя ул.

Илдус Талиповның район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы кәнәфиенә утыруы да бик катлаулы, ыгы-зыгылы чорга туры килде. Хуҗалыклар бүленә, Теләче районы оеша, һәркем мөстәкыйльлеккә омтыла. Яңа урынга билгеләнүе турында министрлык боерыгы язылгач та, өченче көнне үк эшне «Олыяз» крестьян (фермер) хуҗалыклары берләшмәсенең оештыру җыелышында катнашудан башлый.

Гомумән, Илдус Ислам улы район авыл хуҗалыгына катлаулы чорда алты ел җитәкчелек итте, тырышлыгы өчен «Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

И.Талипов үзенең хезмәт юлында янәдән бер урында — «Саба сөт комбинаты»нда да сыналды. Өч ел эчендә эшкәртү предприятиесенең йөзендә шактый эз калдырырга өлгерә ул. Мини-пекарня төзелү, Шәмәрдәндә иске мунча урынында комбинатның үз кибете ачылу — ул эшләгән чорның хезмәт җимешләре. Язма башында икенче сулышы ачылган Илдус Ислам улының ниндидер финиш сызыгына якынлашуын искәрткән идек. Ул исә аның үз гомерендә мөһим вакыйга булып калачак датага — 50 яшенә якынлашуы иде. Үзенең шушы юбилеена һәркем хезмәттә булсынмы, иҗаттамы — матур эшләр, чордашларына, балаларына үрнәк булыр хезмәт сәхифәләре белән килергә омтыла. И.Талипов та ярты гасырлык гомер бәйрәменә зур хезмәт «багажы» белән, артка тәгәрәгән оешмага яңа сулыш өргән җи-

тәкче буларак килә алды. Илле яшьне үзенә күрә бер финишка тиңләсәк тә, ул һич кенә хезмәттә тынычлану мөмкинлеге биргән финал түгел әле. Алда яңа яулыйсы үрләр көтә, тормыш сынаулары дәвам итә. Килер елларның хезмәт мәшәкатьләре инде үсеп җиткән кызларының тормышта үз урыннарын табу куанычын укытучы җәмәгате, киңәшчесе һәм таянычы Әлфия ханым белән бергә тою да үрелеп барачак. Иң зур бәхет шул түгелмени?!

*2004*

# Икмәк булса, җыр да була

Саба ягыннан килгән вакытта, Мичән тавына җиткәч, гаҗәеп манзарага игътибар иткәнегез бар микән? Берсеннән-берсе әллә ни ерак урнашмаган Яңа Мичән, Иске Мичән, Бакшанды, Керәнне авыллары үзенең матур табигате белән күпләрне таң калдыра. Суы да бар, урманы да ерак түгел. Аннары бит бу төбәк Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең әсәрләрендә дә күп тапкырлар чагыла. «Яңа Мичән, Караңгы Шыңар (Түлешкә), Түбән Симет, Сабай, Кызыл Мишә, Сатыш һәм башка авыллар минем әти- әниемнең биографиясе белән бәйле булса, Керәнле, Яңа Мичән, Өчиле, Курсабаш, Бакшанды авыллары — минем яшьлегем... Мәһабәт Керәнне авылында 1948–1950 елларда мин тарих укытучысы булып эшләдем...» дип язды әдип. Вакытлыча Яңа Мичән мәктәбендә дә укыткан Мөхәммәт ага. Аның биләмәсендәге зифа каеннарның төшенә еш керүе турында да илһамланып сөйләгән иде бер очрашу вакытында.

— Тәүге тапкыр парта алырга баруың, беренче укытучың каршылаган көн ул гомерең буе истән чыкмый. Мәктәп тә, мөгаллимәң дә изге урынга, изге затка әйләнә. Шуңа күрә мин, туган төбәгемдә рәис булып эшли башлагач, яңа мәктәп белән балалар бакчасы биналары салуны намус бурычым итеп куйдым, — диде әңгәмәдәшем Фәрит Хәсәнов.

Әйе, аларны файдалануга тапшырганга да байтак еллар узган инде. Аннан соң ике авылда мәчет, Яңа Мичәндә дүрт эш урынына медицина профилакторие, Керәннедә клуб, мәдәният йорты, болардан тыш бик күп хуҗалык биналары: терлек абзарлары, җәйге лагерьлар, ашлык киптерү җайланмалары, ашлама һәм фураж складлары, җылытылган гаражлар, ремонт мастерскойлары эшләткән, авылларны күпер-буалы, юллы, сулы, газлы иткән җитәкче, әлбәттә, игелекле кеше.

Фәрит Шәрип улының горурланып искә алырлык, бәйнә-бәйнә санап чыгарлык эш-гамәлләре күп булса да, иркенләп сөйләргә яратмый ул. Төзелешләр турында сүз чыккач та:

— Менә, кирәк булса, исемлеге бар аның, ундүрт елга утыз дүрт объект җыелган. Барысы да диярлек хуҗалык ысулы белән, уртак тырышлык нәтиҗәсендә салынды алар, — дип фикерен йомгаклап куярга ашыкты.

«Кеше гомере агымсу» диләр. Сунең да төрле чаклары була: тыныч кына ага-ага да ярсып шаулап ала. Җитәкче тормышы да шулай. Планлаштырган эше тормышка ашса, куана ул, өстеннән тау кадәр бурыч төшкәндәй була. Чатаклыклар килеп чыкса, холыксызланып та куя. Уртак эш өчен бит. Андый чакларын авылдашлары да, урта буын җитәкчеләр дә, дөрес аңлап, тирәнгә җибәрмичә, җиңел генә үткәрергә күнеккәннәр. Озак еллар таянып эшләрдәй кадрлар булганга шат Фәрит. Чөнки иң олы байлык — кешеләр. Мәсәлән, Керәнне дуңгызчылык фермасын җитәкләп, заманында «Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе» дигән мактаулы исем бирелгән Раиф Миңлебаев, шундый ук хөрмәткә лаек дуңгыз үстерүче Рәсимә Бәдриева белән сыер савучылар Миңнур Закирҗанова, Рәкыя Зарипова, тракторчылар Тимерхан Әһлиуллин, Тимерхан Бәдретдинов, терлекчеләр Вәсилә Тимербаева, Рәсимә Хуҗина, Наилә Мөбарәкова, белгечләр Фәргать Кашапов, Фаяз Низамов, ферма мөдире Рафаэль Сафиуллин, бригадирлар Әнәс Мөбарәков, Нәфыйк Заһидуллин, байтак еллар авыл советы рәисе вазифасын алып барып, хәзер Мичән урта мәктәбен җитәкләүче Ринат Сафиуллин кебекләрне мактап телгә ала.

...Бу юлы без Фәрит Шәрип улы белән табигатьнең яшәргән һәм уянган чагында — 2002 елның язгы чәчүе төгәлләнеп килгән көннәрдә — басуда очраштык. Игенче-механизаторларның йөзендә быел да өмет, мул уңышка омтылыш һәм ышаныч балкый. Шулай булмыйча мөмкин дә түгел. 2000 ел җәе бит үзенең рекордлы уңышы белән сөендерде. Дөресен әйткәндә, җиле дә вакытында исеп, яңгыры да кирәгендә явып, көзе дә алтын булып килде. Бөек шагыйребез Тукай исемен йөрткән хуҗалык уңганнары моңарчы күрелмәгән күләмдә — һәр гектардан уртача 52,8 центнер уңыш җыйнап алдылар. Тулай җыем 66 мең центнерга җитте. Ул иң уңышлы җәй дип саналган 1992 елда да 48 мең генә булган. Ә инде хәзерләүләр пунктларына гына да 26 мең центнер гәрәбәдәй бөртекләр озатылды. Әгәр дә яңадан чагыштыру китерсәк, моңарчы саткан ашлыкның 8 мең центнердан артканы булмаган. Хуҗалыкның Рамил Миңнебаев, Фидаил Сәйфетдинов, Әнәс Садыйков, Равил Шәйдуллин кебек уңганнары урак башыннан ук район комбайнчылары ярышының алгы сафында бардылар.

«Икмәктә — хикмәт» ди халык. «Икмәк булса, җыр да була» дип тә өстиләр. Алай гына да түгел,

мул уңыш терлекчелекне тотрыклы итте. Шуңа күрә кышлату чорында азыкка кытлык булмады. Һәр баш шартлы терлеккә 35 центнер азык бирәмлеге тупланган иде. Хуҗалыкта мал-туар ишле: 2600 дуңгыз, 1000 нән артык мөгезле эре терлек асрала. Авыл хуҗалыгы җирләренең 100 гектарына туры килгән шартлы баш саны илледән артып китә. Бик күпләрнең фидакарь хезмәте белән бу тармак озак вакытлар табышлы эшләп килде, терлекчелектә елны 45–50 процент рентабельлелек белән тәмамлаган чаклар еш булды.

— Тормышны шул терлекчелек белән алып барып, без финанс кыенлыклары бик зур елларда да хезмәт хакын вакытында биреп бардык. Хәзер дә шулай, бурычыбыз юк, — ди Фәрит Шәрипович.

Алар аклы-каралы чучкалар асрауга җайлашып та күп оттылар. Чөнки нәселле мондый ферма республикада ике генә иде. Үрчемне дә ишле алдылар. Моның өчен һәр терлекчегә кызыксындыру чарасы кулланылды: планнан тыш алган дуңгыз баласы үзенә булды. Әйтик, бер анадан кимендә җиде үрчем ала икән, калганы премия итеп бирелде. Мондый чаралар сөтчелек тармагында да кулланылды. Тырыш хезмәт эзсез калмый, әлбәттә. Хуҗалык яки аның фермасы озак еллар «Терлекчелектә югары культуралы коллектив» дигән диплом белән бүләкләнеп килә. Дуңгызчылык тармагына Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан бирелгән Мактау грамотасы да тарихи ядкарь итеп саклана. Һәр коллективның хезмәт уңышлары аның җитәкчесеннән тора.

Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, районыбызның Тукай исемендәге күмәк хуҗалыгы рәисе Фәрит Хәсәновның (ул, телефоннан шалтыратканда, үзен «Тукай Фәрит әле бу» дип кенә таныштырырга ярата) тормыш юлы да башкалардан әллә ни аерылмый. Ул унсигез яшендә яу кырында аягын калдырып кайткан, Бөек Ватан сугышының беренче группа инвалиды, бөтен гомерен терлекчелек тармагына багышлаган Шәрип белән гади колхозчы Корбанбикә гаиләсендә апалары Сөембикә белән Сәнирәдән соң бик көтеп алынган малай булып дөньяга килә, аннары сеңлесе Наилә белән энесе Фәргать туа. Үз авылында сигезьеллык белем алганнан соң, Әтнәдәге авыл хуҗалыгы техникумына укырга керә. Аны тәмамлагач, зоотехник булып тормыш юлын башлый да армия сафларына китә. Казакъстан далаларында үти ул гражданлык бурычын. Армиядән кайткач, баш зоотехник була, дүрт ел ызандаш хуҗалык «Үзәк»тә башлангыч партия оешмасын җитәкли, аннары үз колхозы коммунистлары партком секретаре итеп сайлыйлар. Казан дәүләт ветеринария институтын да читтән торып тәмамлый. Әйткәнебезчә, 1988 елдан шушы хуҗалыкны җитәкли.

Адәм баласы җир йөзенә бары бәхетле яшәргә дип килә. Ә менә аның тулы булуы өчен гаиләңнең, ягъни тылның ныклыгы кирәк. Эшкә баргач, өйгә, өйгә кайткач, эшкә барасың килсә генә максатыңа ирешә аласың. Гаилә ягыннан да күңеле тыныч Фәритнең. Тормыш көтәсе кешесен дә әллә кайдан эзләмәгән ул. Менә чирек гасыр ел авылдашы Мәдинә белән ярты сүздән, күз сирпеп караудан аңлашып яшиләр. Кызлары Гөлнара, Казан медицина көллиятен тәмамлап, Тимершык авылы егете, көрәшче, үз үлчәвендә күп тапкырлар җиңүче булган, 1996 елгы район сабантуенда абсолют батыр калган Альберт Хәбибуллинга кияүгә чыгып, матур тормыш коралар. Хәзер, әби-бабаларын куандырып, ике малай үстерәләр. Аларны Фәрит бик тә ярата. Олысы Альмир белән аларны укытучылар сабантуенда да очратып була, рәиснең машина кабинасында да еш күренә ул. Укытучылар сабантуе дигәннән, алар анда нишләп йөри икән, дигән сорау килеп тумасын тагын. Фәритнең җәмәгате Мәдинә Ислам кызы — педагог. Озак еллар үз авылындагы ясле-бакчага мөдирлек итә. Әле күптән түгел «Мәгарифтәге казанышлары өчен» билгесе белән бүләкләнде.

Әйе, язмабыз герое — туган нигезенә, туган авылына, туган җиренә, газиз гаиләсенә чын күңелдән бирелгән шәхес. Шуңа күрә А.Алишның түбәндәге шигъри юлларын еш кабатлый:

Әйтсәләр дә, барып торсын, диеп,
Дөньяның иң рәхәт җиренә.
Әйтер идем, кирәк түгел, диеп,
Кайтам мин, дип, туган илемә.

*2001*

# Вакыт — җил ул

Яшьрәк вакытта, гомернең узуы турында уйлап та бирмичә, кабалана-ашыга дөнья куабыз, тормыш ашыктыра. Саулык, егәр, омтылыш бар яшьлектә. Мәхәббәт, дуслар, җыр бар. Гомер гел шулай дәвам итәр кебек. Әмма, шагыйрь әйтмешли, вакыт — җил ул. Гомер дә, шул җил кебек, әкрен генә үтә тора. Көннәрнең берендә илленңе тутырганыңны сизеп уйга батасың: балаларың да үсеп җиткән икән, гомереңнең күп өлеше узган, кеше буларак үз юлыңны тапкансың, абруең бар, хөрмәт тә итәләр.

Менә чирек гасыр инде елның һәр көнендә диярлек халык белән аралашып, киңәш сорап, үтенеп килүчеләрне кабул итеп, аларның мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәүче Расих Хәсән улы Сабировка да илле яшь тулды. Шул уңай белән язма әзерләргә телләгәнебезне белдергәч, ул башта теше-тырнагы бе-

лән каршы торды. «Кирәк булмас, минем ул мәсьәләләргә үземнең карашым бар. Гомумән, төче итеп язылган мәкаләләрне яратмыйм», — диде ул.

Шуңа күрә без юбиляр белән әңгәмә корырга булдык.

**— Расих Хәсәнович, безнең белүебезчә, сезнең нәсел элек-электән зыялы булган, тамырларыгыз еракка киткән. Башта тәрҗемәи хәлегезне сөйләгез әле.**

— Әйе, сугыштан соңгы дәһшәтле салкын җәйдә туганмын мин. Әтиебез 1913 елгы иде. Авыр туфрагы җиңел булсын. Унбиш яшендә колхозда бригадир булып эшли башлаган. Гомумән, кан-тамыры белән җиргә береккән, үз чорының белемле агрономы саналды. Әтинең бертуганы Гайниҗамал апа безнең белән гомер итте. Әни дә, әби дә тегүче иделәр. Шул уңайдан күңелдә бер истәлекле вакыйга да йөри әле. Егет вакытында бик тә модада булган галифе чалбар киясе килгән әтинең. Башкача мөмкин булмагач, әби аны сатиннан тегеп биргән.

Әниебез чыгышы белән Сатыш авылыннан. Хәзер дә исән-сау әле, Аллага шөкер. Аларның да нәселе бик тырыш, эшчән. Бу фикеремне раслау өчен әниемнең — ягъни Сәлимә Шәймәрдән кызының — бертуганы Галимҗан абый Казан язу машиналары (Пишмаш) заводында гомер буе эшләп «Социалистик Хезмәт Герое» дигән мактаулы исемгә лаек булды. Шәймәрдән бабай заманында сәүдә белән шөгыльләнгән, күп илләр гизгән, сигез төрки тел белгән. Шуңа күрәдер әти-әниебез алга карап фикер йөртә торган кешеләр булганнар. Безнең Кече Кибәче авылында башлангыч мәктәп булса да, дүртебезне дә чакрым ярым ераклыктагы күрше авылга — Ташлыярга — рус мәктәбенә йөрткәннәр. Аннары укуны Әбдедә дәвам иттек, урта мәктәпкә Икшермәгә кайттык. Русча укыганга карап, туган телебезне онытмадык. Әмма югары уку йортларында җиңелрәк булды. Тора-бара дүртебез дә институт тәмамладык.

**— Туганнарыгызга аерым тукталыйк.**

— Илдар абый Казакъстанда яши. Энергетика институтын тәмамлап, Талды-Курган өлкәсендәге югары вольтлы электр энергиясе төзү оешмасында белгечлеге буенча баш инженер булып эшләде. Зөбәрҗәт апа күпләргә билгеле инде. Озак еллар «Саба» совхозында, «Октябрь» колхозында, Саба урман хуҗалыгында исәп-хисап эшендә булды, аңа «Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирелде. Мидхәт абый очучы иде. Транспорт авиациясендә хезмәт итеп, подполковник дәрәҗәсендә отставкага чыкты. Әфганстан һәм Эфиопия күкләрен иңләде. Авиация дивизиясе штабы начальнигы, берләшмә командиры вазифаларын алып барды. Дәүләтебезнең ике бүләгенә — Сугышчан Кызыл Байрак һәм Кызыл Йолдыз орденнарына лаек булды.

Үзем башта Мәскәүдә укып, геодезист булырга хыялланган идем. Аннары Казан дәүләт педагогия институтының физика-математика бүлеген тәмамладым. Төп белгечлегем — физик.

**— Менә минем кулымда югарыда телгә алынган институтның «За педагогические кадры» дигән күптиражлы газетасы. Анда «Уходят выпускники. Среди них очень серьезный, не умеющий размениваться по мелочам отличник учебы Сабиров Р.Х.» дигән юллар бар...**

— Әйе, мин яхшы укыдым. Хәтта философиядән профессор Валерий Васильевич Лузгин ике имтиханга «автомат» куйды. Институттан соң Алан урта мәктәбендә бер ел физика фәнен укыттым. Шуның белән минем педагоглык карьерам төгәлләнде. Павел Андреевич Дадуков җитәкли торган бик көчле, данлыклы коллектив иде.

Предметымны бик яраттым. Атнага егерме сигез сәгать дәрес бирделәр. Әле укучылар өчен физиканың механика бүлегенә караган аңлаешлырак дәреслек чыгарырга хыялланып, караламасын үземчә язган да идем. Һич көтмәгәндә ВЛКСМ райкомының икенче секретаре итеп сайландым да башка проблемалар килеп туды.

**— Комсомол, партия чыныгуын үткән кешегә алга таба эшләргә җиңел була, диләр. Сезнең бу мәсьәләгә карашыгыз нинди?**

— Әлбәттә, яхшы. Дөрес, мин мәктәптә дә, институтта да җәмәгать эше белән шөгыльләнмәгән идем. Оештыру мәсьәләләренә, нигездә, комсомол аппаратында өйрәндем. ВЛКСМ райкомының беренче секретаре Миннеислам Ногманов, мәктәпләр буенча секретарь Зөлфия Фәттахова, аппаратның башка хезмәткәрләре белән уртак тел табып эшләдек.

Ундүрт айдан соң үземне беренче секретарь итеп сайладылар. Ул елларда үзешчән сәнгать фестивальләренә, спорт ярышларына, шулай ук производство мәсьәләләренә, комсомол-яшьләр фермаларына һәм коллективларына игътибарны арттырдык. Саба урман хуҗалыгының сувенир цехына һәм Шәмәрдәндәге 4 нче номерлы газ-компрессор станциясенә ВЛКСМ Үзәк Комитетының һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл Байраклары да тапшырылды әле. Кыскасы, яшьләр комсомол путевкасы белән эшкә калды. Тәртип яхшы, романтика көчле иде. Без үзебезчә мәктәпләрне матди яктан да бераз ныгытырга омтыла идек. Мәсәлән, читтәге мәктәп дип, Субашка пластинка уйната торган проигрыватель алып биргән идек. Андый ярдәмнәр байтакка җыйналып, әлеге статьядан акча артык тотылу сәбәпле, үземне КПСС райкомының башлангыч партия оешмасы җыелышында тикшерделәр әле. Партия райкомының ул вакыттагы беренче секретаре Әләметдин Җамалетдинович: «Телдән шелтә бик җиткән», — диде. Зирәк акыллы кеше бит. Шулай итеп, комсомолда артык тырышкан чор өчен кисәтү шелтәсе дә алдым мин. Алга таба уйлап эшләү өчен зур сабак булды әлеге вакыйга.

Ә инде КПСС райкомының оештыру бүлеге инструкторы вазифаларын алып барган елларга тукталсак, анда һәркемгә унбишләп оешма беркетелгән иде. Аларның секретарьлары, җитәкчеләре белән уртак тел таптым. Шул вакыттагы эшлекле дуслык хәзер дә дәвам итә. Тора-бара КПСС райкомының башлангыч партия оешмасы секретаре булып сайландым. Аерым бүлмәдә утырдым. Хезмәт хакым да башка инструкторларга караганда биш сумга артык иде.

**— Расих Хәсәнович, Саба урман хуҗалыгына җәяү китеп, «Жигули»га утырып кайтканыгыз турында әйтеп үтегез әле.**

— Әйе, булды андый хәл. Бер генә атна партком секретаре булып эшләп алдым әле Саба леспромхозында. Ныгытып эшкә тотынып, «дело»ларны тәртипләгәннән соң, КПСС сафларына яшьләрне кабул гына итә башлаган идем, район партия оешмасының чираттагы отчет-сайлау конференциясе булды да, шунда альтернатив юл белән оештыру бүлеге мөдире итеп сайландым. Ә инде «Жигули»га килгәндә, ул елларда акча булса да, машинасы дефицит иде бит. Үземнең бераз запас бар иде, аннары туганнар да булышып, директор Рәис Нургалиевич, җәяү йөрмәсен диптер инде, машинасын табып бирде. Менә шул аның тарихы.

**— Сез район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең кадрлар бүлегенә җитәкчелек итеп тә алдыгыз бит әле.**

— Әмма анда да озак эшләргә насыйп булмады. Ул вакыттагы район хакимияте башлыгы Фәрит Гыйльмиевич үзенә аппарат җитәкчесе итеп чакырды. Советлар һәм хакимият аерым структуралар булып оешып килә торган чак иде ул. Штатлар буенча, гомумән, бик күп төрле оештыру эшләре белән, шул ук вакытта яңа бинаны (хәзерге) сафка бастыру буенча да шөгыльләнергә туры килде.

**— Төзелеш, коммуналь хуҗалык, транспорт һәм элемтә мәсьәләләре буенча хакимият башлыгының урынбасары итеп күчерү фикере өч катлы мәһабәт бинаны файдалануга тапшыргач тудымы әллә?**

— Анысын әйтә алмыйм. Ел ярым алып бардым бу вазифаны. Районда газ кертү буенча ныклап шөгыльләндек, күпчелек урта мәктәпләр табигый ягулыкка тоташтырылды. Миңгәр, Югары Симет, Иске Икшермә авылларына асфальт юллар җәелде бу чорда. Шәмәрдәндә телевизион ретранслятор да эшләнеп бетте. Аның өчен элемтә министры Ринат Җәләлов рәхмәт белдерде. Бик күп төзүчеләр белән таныштырды дөнья киргә. Мәсәлән, 5 нче трест управляющие Мурманий Пелия Плутарх дигән авторның ике томлы китабын гомер буе эзләгән булган икән. Шуларны шәхси китапханәмнән бүләк иткәч, эшлекле дуслык тагын да ныгыды. Мондый мисалларны тагын дәвам итеп булыр иде әле.

**— Аппарат җитәкчесе булып кире кайтуыгыз ничек булды?**

— Минем урынга калган иптәш үз теләге белән китте. Берничә кешегә тәкъдим ясалса да, алынырга теләүче булмады. Урын өч айлап буш торгач, кире кайтырга туры килде.

Менә шулай итеп, бу вазифадагы стажым да ун елдан артып киткән.

Әйе, аппарат җитәкчесенең кәгазь эше тавык чүпләп бетермәслек. Аңа күпме рәсми хатларны, боерыкларны үзенә әзерләргә, башка бүлекләр керткәнне редакцияләргә, карарлар үтәлешен, хатларга җавап бирү срокларын контрольдә тотарга, гражданнарны кабул итүне оештырырга, хуҗалык эшләрен, ремонтын планлы алып барырга, гомумән, хакимиятнең тулы канлы эшчәнлеген тәэмин итәргә кирәк. Шуңа күрә ел тәүлеге экстремаль шартларда эшли ул. Үзенең генә түгел, башкаларның кылган гамәлләре өчен дә җавап бирә. Төгәллекне ярата, тапшырылган һәр эшне җиренә җиткереп үтәргә, үз фикеренә, принципларына тугры калырга омтыла, үч сакламый, йөзеңә карап, тугры итеп әйтү кебек сыйфатлар хас аңа. Үзенә һәм башкаларга таләпчән. Эшне куша һәм үтәлешен сорый белә. Шуңа күрә кайбер мәзәк хәлләргә дә керде инде ул.

«Расих Хәсәнович үзендәме?» дип шалтырата икән берәү алгы бүлмәгә (приемныйга). «Юк, бик тыныч әле монда», — дигән кизү торучы Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының ул вакыттагы дәүләт инспекторы Зөфәр Насыйбуллин.

Гомумән, юморны аңлый белә ул. Кайберләренең иҗат итәргә ярдәме дә тия әле. Быелгы район сабантуйларын республика матбугаты да киң яктыртты. «Шәһри Казан» газетасы репортажның исемен «Күп ашаучылар да ярышты» дип куйган.

Мин ул язманы башта хакимият башлыгы урынбасарларына күрсәттем. «Әйбәт булган», — диделәр. Юл уңаеннан Расих Хәсәновичка да сугылдым. Карап-карап торды да үзенә кабул итте, ахры: «Мин анда булмадым бит», — дип шаяртты.

Хезмәт вазифаларыңны җиренә җиткереп башкару өчен шәхси тормышыңның, ягъни тылыңның нык булуы кирәк. Апас кызы, үзе кебек педагог Гөлшат Риза кызы белән моннан чирек гасыр элек корган гаилә тормышлары да матур булып дәвам итә. Олы уллары Булат, югары белем алып, «Сабагаз» идарәсендә эшли. Искәндәр дә Казан дәүләт технология университетында — социаль-экономика факультетының дәүләт муниципаль идарәсе (ГМУ) бүлегендә укый. Алар да әтиләре кебек киң эрудицияле, тырыш егетләр.

Фикерне йомгаклап, илледән соң да елларың уң булсын, һаман шулай кешелекле, ачык күңелле, шаян сүзле, олы җанлы булып кал, Расих туган, диясе килә.

# Бәхетле ана

«Саба дулкыннары» радиосының якшәмбе тапшыруы бара. Турыдан-туры эфирда — ишле бала үстереп, барысын да хәрби хезмәткә озаткан һәм каршы алган аналар. Ир хатыны һәм әни кеше буларак шатлыклы да, кайгылы да, борчулы да гомер юлы узган, биш малайның һәркайсын югары белемле иткән Мөкәррәмә Нәҗип кызы Гыйлаҗиевага сүз бирелә. Ул ышанычлы, хәтта бераз гына горур тавыш белән сеңдереп сөйли. Аны тыңлагач, өлкән буын вәкилләренең гыйбрәтле һәм шул ук вакытта сокланырлык тормыш юллары бер-бер артлы тезелешкән кино кадрларыдай, мизгел эчендә күз алдыннан үткән кебек булды һәм бу Ана белән очрашып сөйләшү теләге дә туды.

...Менә без заманында машина-техника станциясе (МТС) белән гөрләп торган, татарлар, руслар, башка милләт халыклары дуслыкта яшәгән, дистәдән артык авылны берләштергән совхозы, урта мәктәбе, участок хастаханәсе, аптекасы, май заводы, сельпосы, хәтта элегрәк чиркәве дә булган Иске Икшермә авылына килеп, үзәк урамда яшәүче Мөкәрәмә апага сугылдык. Балкып торган нурлы йөз белән каршы алды ул һәм болай диде:

— Аткан һәр таңым, Ходай биргән һәр якты көнем өчен куанам мин, рәхмәт укыйм. Безгә хәзер инде күп кирәкмени — ашыйсын ашаган, яшисен яшәгән... Тик менә олыгайган көнемдә күзләремнең бик начар күрүе генә борчый. Укый да, яза да алмыйм. Шулай да әти-әниләрнең үткән тормыш юлын, тыйнак кына итеп булса да, районыбыз тарихына теркәп калдырасы килә, — диде дә гомер «сандыгындагы» олы йомгагын «сүтә» башлады. Шуңа күрә аңа вак-төяк сораулар биреп бүлдермичә, хәтер-хатирәләрен үз авызыннан тоташ сөйләтәсе килде.

— 2005 елда районыбызның олы юбилее билгеләп үтелде бит инде. Җитмеш биш яшь тулды аңа. Шул хактагы радиотапшыруларны тыңлагач, район тормышына үзеннән лаеклы өлеш керткән әтием — Нәҗип Сафиуллин күз алдыма килә, бала чагым искә төшә. 1891 елгы иде ул. Район оешканда, ягъни 1932—1933 елларда Туктарда авыл советы (Мәртен, Тенеки авыллары кергән) рәисе була. Колхоз оештыруга зур көч куя. Әнием Хәерливисал да кумәк эшкә йөри. Төнге икедә көтү чыга иде, шуннан әниләр басуга китәләр дә, кояш баегач кына кайталар. Без, кечкенә балалар, өйдә көн буена ялгыз кала идек.

Елына күрә ашлыгы да әйбәт чыкты ул чакта. Уңыш бәйрәмен зурлап уздырганнары, ударникларның өйләренә кызыл олау белән икмәк китергәннәре дә хәтердә калган.

Арурак тормышлы кешеләрне, кулак дип, нигезләреннән куу башланды. Мулла абзыйны гаиләсе белән Себергә сөргән көн дә онытылмый. Авылның олысы-кечесе озата чыкты. Әти андыйларга уңай белешмә бирергә, гозерләрен үтәргә, ярдәм итәргә тырыша иде. Гомумән, яхшылык кыл да суга сал, халык белмәсә, балык белер, дигән гыйбарәне кыйбласы итеп яшәде. Шуңадыр, мулла абзыйның малае Красноярскидан  кайтып, бүләк тә керткән әле үзенә.

Әтине үтерергә ниятләнүчеләр дә юк түгел иде. Сабага Сабантуйга менгәч, берәү килеп: «Нәҗип абый, чәчең бик кара, бүген агарталар»,— дип кисәтте. Без кайтып киттек. Эчтән ишеккә терәү салып, йокламыйча чыктык. Таң алдыннан гына аяк тавышлары бетте өй тирәсендә. Ә инде икенче бервакыт әтине юк итәргә тиешле кеше, кулым бармый дип әйтеп калдырып, үзе асылынган иде.

Аннары Миңгәргә авыл советы рәисе итеп күчерделәр аны. Анда биш ел эшләде. Хәзер СССРның халык артисты булган Шәүкәт Биктимеровның әтисе Хәсән абыйлар өендә тордык. Ул үзе Бигәнәйдә укыта иде. Әти Миңгәрдә дә булсынга эшләде. Хәтерем ялгышмаса, авыл урамы буйлап суны да ул җибәрттерде кебек. Коточкыч репрессия еллары иде ул. Бу уңайдан тагын бер вакыйга истә калган. Иванов фамилияле укытучы Шомыртбашка (хәзер Балык Бистәсе районына керә) кайтканда, колхоз атының аягын сындырган. Бу хәлне утырышка куйганнар. Авыл советы секретаре Җәмил абый беркетмәгә «Иванов аксатып кайткан атны суярга» дип язасы урынга, ялгышып, әлбәттә, «Ивановны суярга» дип язган. Төнлә әтине килеп алып киттеләр. Кайткач, көлә-көлә сөйләде. «Дөрес язылмаган җөмлә өчен сүктеләр»,— диде.

1938 елда Саба авыл советы рәисе итеп сайланды ул. Дүрт колхоз бар иде район үзәгендә. Сугыш вакытында шуларның берсенә — Каганович исемендәгесенә җитәкчелек итте. Ул чорның авырлыгын сөйләп бетерә торган түгел. Кыш көне кар селкеп, урак урдык. Эвакуацияләнеп килүчеләр дә байтакка җыйналды. Алар арасында латыш, яһүд милләтеннән булганнар да бар иде. Мәсәлән, бер карт белән карчык лабогрейкада эшләделәр. Урак өстендә бөтен бала-чага, яше-олысы басуда, ындыр табагында булды. Без, биш кыз, атлар белән Шәмәрдән заготзерносына ашлык ташыдык. Шушы биш олауга бер бабайны камыт бауларына күз-колак булу өчен башлык итеп беркетәләр иде.

Урып-җыю озакка сузылды ул елны. Үч иткәндәй, октябрь аенда кар яуды. «Ипи басуда калды» дип кайсыдыр шикаять язган. Безнең ишекне дә кара көчләр «шакыды». Әтине кулга алып, ике елга

төрмәгә утырттылар. КПСС райкомының ул чордагы беренче секретаре Сабир абый Шакиров, беренче кар эреп бетүгә, Казаннан комиссия чакыртты. Ашлык басуда калмаганлыгы ачыклангач, этине азат иттеләр. Шул ук Шакиров абый аны рәис итеп «Победа» колхозына — Төбәккә җибәрде.

Анда да хәлләр аяныч булып чыкты. Атларны корчаңгы баскан, еш кына ачтан үләләр иде бахбайлар. Шуларны тунамыйча гына чалалар да ач кешеләргә өләшәләр. Балалар үлән ашады. Арыш башы җыйды. Әти аларны күрмәмешкә салынды. Бәрәңге алыр вакыт җиткәч, немец әсирләрен китерделәр. Өс киемнәре коточкыч иде аларның, аякларында — агач башмаклар. Клуб идәненә салам җәеп йоклаттылар, халык иске-москысын бирде...

Ярар, бер тотынгач, тәрҗемәи хәлебезне сөйләп бетерим инде. Әтине Кибәчегә күчерделәр. Бу колхозга 1952 елга кадәр, ягъни сугыштан соңгы авыр елларда җитәкчелек итеп, пенсиягә чыкты. Кайда буш өй бар, шунда торып тордык. Бер авылдан икенчесенә күчеп йөреп, үз йортыбыз булмады.

Нинди йорт, әйтсәм әйтим инде, әтинең алмашка кияргә чалбары да юк иде. Мунчада юып куйгач, кипкәнен көтеп, өйдә ак кальсоннан йөреп торганы хәтеремдә калды. Аны шулай гадел булуы, нәфселәнмәве репрессия еллары корбаны итмәгәндер, бәлки, дип уйланып утырам хәзер.

Әти, ялга  чыккач та, кул кушырып утырмады. Әнинең төп йортын сатып, Иске Икшермәдән иске генә бер өй алдык. Шуны тәртипләп, үзебезнең «оя»ны кордык. Әти төрле җирдә эшләвен дәвам итте. Әни белән елгада известь яндырдылар. Ремонт мастерское төзелгәч, кладовойчы да булды.

Кыскасы, тормышлар бераз көйләнеп киткәч, бернинди рәхәт күрмичә, 1956 елда җир куены үзенә алды аны. Без алты бала идек. Олы абыебыз Тәлгат туган илебезнең һәр  карышы өчен көрәшеп, сугышта һәлак булды. Энем Шәүкәт 1929 елгы иде, башта укытты, аннары партком секретаре итеп сайланды, «Икшермә» совхозы директоры вакытта яман чирдән үлде.  Беркемнең дә бу фани дөньяда мәңгелек түгеллеген, һәркайсыбызның кайчан да бер бакыйлыкка күчәчәгебезне белсәк тә, Шәүкәтне соңгы юлга озату хәсрәте әле дә йөрәктән китми. Җәүдәт энебез дә бик иртә гүр иясе булды. Хәзер Сабада яшәүче Флера сеңлем һәм төпчегебез Марат белән өчәү генә калдык. Марат, табиб буларак, озак еллар авылыбыз халкына игелекле хезмәт күрсәтә...

Мөкәррәмә апа сөйли дә сөйли, эчәсе чәе дә онытылды. Тирән итеп алган сулышы, калтыранган тавышы тетрәндереп куя.

— Хәзер инде үзем турында бәян итим дә, сүземне йомгаклыйм, — диде ул. — Яшь вакытта колхозда да, хәзерләүләр конторасында да эшләдем. ВЛКСМ райкомын Сөембикә Фәизова җитәкләгәндә учет секторы мөдире итеп алды. Шуннан югары партия мәктәбенә укырга җибәргәннәр иде, ике тапкыр качып кайттым. Яшьлек юләрлеге булгандыр инде. Ул вакытта әти-әниләр Төбәктә иделәр, почта агенты, клуб мөдире вазифаларын алып бардым. 1947 елда Олы Кибәченең Нури исемле егетенә кияүгә чыктым. Ул Икшермә машина-трактор станциясендә баш бухгалтер иде. Нури бик зур таяныч, терәк булды, эшкә бөтен егәрен бирде, урманнан юкә агачы кисеп алып кайтып, мунчала салды, шуны сатып этигә өй алдык. Аннары әкренләп абзар-куралар кордык.

Шатлык өстенә шатлык булып, берсеннән-берсе тупырдап туган малайлар үстердек. Наил, Рифкать, Рәис, Илдус, Әнәс — бишесе дә агроном, ветеринария табибы, укытучы кебек һөнәрләр алдылар, бик тырыш булдылар. Барысы да  армиядә хезмәт итеп кайттылар, өйләнделәр, киленнәрем — Энже, Гөлсинә, Гөлнур, Гүзәлия, Ләйсән — үз кызларымдай әйбәтләр. Чөнки үзем дә эш яраттым. Урта мәктәп Татар Икшермәсендә вакытта укучылар белән йорт куяннары үстердем. Ул елларда Кави Сәлим улы Байкиев җитәкләгән коллективыбыз СССР Халык казанышлары күргәзмәсендә махсус медальләр яулады. Аннары егерме биш ел мәктәп буфетында эшләдем. Азык-төлек тә, уку әсбаплары да, әдәби китаплар да саттым. Ул чорда җиде йөз тирәсе бала укып, 166 егет һәм кыз өлгергәнлек аттестаты алган еллар булды. Балалар бик тәртипле иде. «Сатучысыз өстәл» куя идем. Вак-төяк кирәк-яракны шуннан алдылар. Соңыннан исәпләп карый идем, әмма өч тиен дә зыян күргәнне хәтерләмим. Бик күп әдәби китап саттым. Сәгать кичке уннарда өйдәге эшне бетереп, төнге икеләргә кадәр үзем дә, Нурига ут яктысы төшмәсен өчен лампочкага гәҗит каплап, китап укый идем. «Намус», «Ак чәчәкләр», «Одерда яз», «Ике буйдак», «Юллар, юллар», «Фронтовиклар» кебек әсәрләр әчтәлеген бүген дә хәтерлим.

Шулай итеп, укытучы улым Әнәс, киленем Ләйсән белән унөч ел бергә торабыз. Өебез зур, тормышыбыз матур. Ирем Нури гына озак яши алмады, үземә быел сиксән яшь тула, Аллаһы боерса...

Мөкәррәмә апа сүзен йомгаклагандай итте.

Гадәттәгечә, әңгәмәне тәмамлаганда:

— Сез бәхетле Анамы? — дип сорарга кирәк санамадым. Чөнки мул тормышлы, балалар хәсрәте күрмәгән картлыгыннан канәгать булуы аның йөзендә балкый, хәтта тавышында сизелә иде.

...Озата чыкты Мөкәррәмә Нәҗип кызы. Кешеләрне генә түгел, бал кортларын да җәлеп итә торган чәчәккә күмелгән ишегаллары, йорт тирәсендә җиләк-җимеш өлгергән, кыскасы, табигать муллыкка чумган көннәр иде бу. Җылы гына итеп саубаллашып, юлга кузгалдым. Ә корган әңгәмәбез, гыйбрәтле төш кебек, күңелем түреннән мәңгелеккә урын алды...

*2006*

# Ерак буыннардан килгән серлелек

«Татарстан Яңа гасыр» телеканалының «Кәеф ничек?» хит-парадында Салават Фәтхетдинов башкарган «Юлчы» дигән җырны атна саен тыңласам да, соңыннан һәрвакыт ниндидер тирән хисләр дөньясына чумам. Чөнки өчлек берлеге — шагыйрь, композитор һәм башкаручы тудырган бик тә гыйбрәтле иҗат әсәре бу. Әйдәгез, Эдуард Мостафинның әлеге җыр текстын (көе Рөстәм Зариповныкы) тагын бер сеңдереп укып чыгыйк әле.

Әй, юлчы, кая барасың?
Кереп хәл ал, арысаң.
Бәлкем, кунып та калырсың,
Ходай кушып, яр булсаң.

Тир чыгарып, чәй эчәрбез,
Гәпләшербез туйганчы.
Яшәп карарсың үземдә,
Агач яфрак койганчы.

Алмалар җыярбыз бергә,
Өзәрбез чәчәкләрне.
Сагынып искә алырбыз
Иләс-миләс чакларны.

Юккамыни дәшәм сиңа,
Ялгызыма ямансу,
Күңелдә сагыш уята
Хәтта аннан аккан су.

Әй, юлчы, зинһар, тукта,
Учагым сүнеп бара...
Күңелем дә әкренләп
Бу хәлгә күнеп бара...

Изге җан, сизгер җан булсаң,
Өреп җибәр учакка.
Бәлкем, өметләр терелер,
Ике җан типкән чакта.

Миңа, бу юлларның авторына, Эдуард Мостафин да, Рөстәм Зарипов та бик якыннан таныш.

...Сиксәненче еллар уртасына кайтыйк әле. Бүгенгедәй хәтеремдә, Бауман урамындагы Матбугат йортында дәрәҗәле генә шәхес миңа болай диде:

— Мөмкин булса, Саба редакциясенә эшкә Эдуард Мостафин дигән искиткеч талантлы шагыйрьне ал әле. Яшәү чыганагы юк аның. Әз булса да акчасы булыр. Иткән яхшылыгың җирдә ятмас, үзеңә изгелек булып кайтыр...

Каршы килә алмадым.

— Бер буш штат бар, эшләп карасын,— дидем.

Ярар, килде Эдуард абый. Яши торырга акча, ягъни аванс та бирдек. Бер-ике атна әйбәт кенә йөрде. Аннары Теләче янәшәсендәге Ачы дигән рус авылына үзе сорап иҗат командировкасына китте һәм... юкка чыкты. Ун көн үткәч кайтты бу. Кыска гына бер хәбәр язган. Әмма «командировочное удостоверение»сенә килгән-киткәнгә мөһер суктырып, тамга ясаткан. Район эчендә генә йөргән көннәргә редакциядә беркемгә дә тәүлеклек түләнми иде. Шуңа күрә башкаладан килгән хәбәрчебезгә «югалып торган» ун көне өчен хезмәт хакы бирдек тә, җайлап кына болай дидем:

— Эдуард абый, матур гына килдең, нәкъ шулай итеп кит тә инде син, яме, ачуланма. Тавышка кергәнче, әйбәт кенә аерылышыйк...

— Ярар,— дип, каләме белән куен дәфтәрен (башка әйбере юк иде) кесәсенә тыкты да, тыныч кына юк булды.

Шуннан берничә ел үткәч, сукбайлыкка төшеп фани дөньядан киткәнлеге, җәсәде табылмавы турында авыр хәбәр таралды. Кыскасы, җаны... шигырьләрендә генә калды аның...

Икенче автор — Рөстәм Зарипов үзебезнең район егете. Зыялы шәхес. Әтисе Зәет— табиб булган, ә әнисе ягыннан — муллалар нәселеннән алар. Тарихка тирәнрәк күз салсак, Рөстәмнең Йосыф абзасы Казан губернаторы киңәшчесе вазифасын алып барган. Бу хакта татар классигы Фатих Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» дип исемләнгән фантастик әсәрендә түбәндәге юллар бар: «... Бу, фаразан, закунсыз җир түгел, Алла боерса, Шайтан Елга (Урта Саба авылының шул вакыттагы исеме. — *Т.Н.*) Йосыфны очратмам микән әле, барыгызның, мәсәлән, эшен китерермен, мировойга бирдерермен...»

Йосыф Раков Казанда яшәгән, адвокатлык һөнәренә ия, губернатор киңәшчесе булган. Ул Рөстәмнең бабасы — имам Мирза Мөхәммәтшәрифнең абзасы була.

Икенче бер чыганакта Йосыф абзыйның вазифасы губернатор каршындагы советник дип тәгаенләнгән.

Нәкъ менә шушы урында Рөстәмнең әнисе ягыннан әбисе Гайниҗамал белән Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең әтисе Сөнгатулланың бертуган икәнен дә искәртеп үтик әле.

Ә хәзер шушы затлы нәселне дәвам итүче Рөстәм Зариповның үзенә тукталыйк. Аның әнисе Саҗидә апа Ракова гомер буе укытучы булды. Кызы Лена һәм улы Рөстәм белән Юлбат авылында яшәделәр. Газетабызның даими хәбәрчесе дә иде. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр каләменнән аерылмады. Ни кызганыч, Саҗидә апа бу фани дөньядан бакыйлыкка кинәт кенә, үкенечле итеп күчеп куйды. Урыны җәннәт түрендә булсын.

Рөстәмнең бертуган апасы да, үзе кебек, баянда уйный-уйный җырларга оста иде, кешене авызына каратып тота белде. Казан дәүләт университетын кызыл дипломга тәмамлаган Лenaның гомере дә бик тә аяныч тәмамланды: суга төшкән кебек юкка чыкты ул, гәүдәсе табылмагач, зиярәт кылырга кабере дә калмады. Бәлки, әлеге вакыйгалар белән тетрәнеп, шундый моңлы, гыйбрәтле, үзәкләрне өзгәли, җаннарны телгәли торган җырлар иҗат итәдер Р.Зарипов.

Тулаем алганда, Рөстәм Зәет улы — күпкырлы талант. 1976 елда — «Идел» альманахында «А-у-у-у» дигән тәүге хикәясе дөнья күрә аның. Шулай итеп, ул 30 ел иҗат итә. Аның чәчмә әсәрләре дә, шигырьләре дә, җырлары да фикер сөреше белән үзенчәлекле. Авторның кинаяле, шул ук вакытта сыгылмалы, үткен телле пародияләре, юмористик парчалары, тирән фәлсәфи фикерле эссе-хикәяләре, милләтебез язмышына багышланган мәкаләләре, сәяхәтнамәләре әледән-әле басылып килә. «Татарстан яшьләре» кебек күптиражлы газеталарда дөнья күреп, төрле конкурсларда тиешле бәясен ала. Беркемгә дә охшамаган ике, өч, дүрт юллы «төртмәле» шигырьләрен автор көтелмәгән гомумиләштерү белән очлап куя белә.

Җитәкчене шуннан таныйм:
Басуга кереп китә дә
Үрелә гел башакка.
Өзә, бөртекләрен саный,
Исни, куя ашап та...

Рөстәм узган гасырның җитмешенче елларында ук «Тамчы гөл» дигән җырын (шул исемдә ике китап та чыгарды) үзе уйнап һәм җырлап зур популярлык казанды. Балалык һәм яшүсмер елларын районыбызның Лесхоз бистәсендә үткәргән мәшһүр композитор Фасил Әхмәтов аның аркасыннан сөеп: «Менә бу егет бер җыр язды, шуның белән халык күңеленә керде»,—дигән. Дөрестән дә, бу җөмләдә хаклык зур. Хәтта яңа туган кызларына Тамчыгөл дип исем кушучылар да булды ул елларда. Рөстәм аның белән генә тукталып калмады, әлбәттә. «Мөһаҗҗир» (Гаяз Исхакыйга багышлана), «Алфавит» (Кави Нәҗми шигыренә), «Дуслар җыелган» (сүзләре дә үзенеке), «Беркем сизмәде» (Фәнис Яруллин шигыре), «Бүре» (үз сүзләре) һәм башка байтак җырларын тамашачы бик җылы кабул итте.

Р.Зарипов — төзүче-инженер. Белгечлеге буенча башта Сабада эшләп алды да, Мөслим юл идарәсенә күчте. Аннары алты ел шундагы район эчке эшләр бүлегендә сәяси эшләр буенча начальник урынбасары була. Һәм органнарда эшләгәндә (!) ул Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең Мөслимдәге бүлегенең беренче рәисе итеп сайлана, кыскасы, үзе әйтмешли, «мент» булса да, милли хәрәкәтнең башында йөри, ТИҮ корылтайларында даими катнаша. Ул погон таккан килеш тә әнисе янына бик еш кайткалап торды. Бер елны мәйдан уртасына чыгып, «Саба Сабантуйлары» дигән өр-яңа музыкаль «күчтәнәч»ен якташларына үзе уйнап җырлаганы күңелдә уелып калган. Җыр тәмамлангач, халык мәйданнан чыгармыйча алкышлады Рөстәмне, кабатларга мәҗбүр булды яңа «табадан төшкән» иҗат җимешен:

Сагыш басса, рух сыгылса,
Авырайса уйларым,
Күңелләргә канат куя
Саба Сабантуйлары...

Әйе, сагыш басса кулына баянын, нота кәгазен йә каләмен ала якташыбыз. Мәшһүр җырчыларыбызның репертуарларын «Бүре», «Юлчы» кебек мәгънәле иҗаты белән алга таба да баетыр әле Рөстәм Зарипов.

*2006*

# Зыялы кешеләр зыянлы булмый

Әкрен генә саллы гомер йомгагын сүтә Револь Габдулла улы Раков. Авырлыклар, көтелмәгәндә ки-

леп туган уңайсыз хәлләр алдында җебеп төшми, киресенчә, тырыша-тырмаша торган шәхес. Тормышны, кешеләрне ярата, эшенә намус белән карый. Русларда андыйлар турында әйтелә торган бер матур сүз бар — порядочный человек. Револь Габдуллович турында бу сүзләрне мин икеләнмичә әйтә алам. Нәкъ утыз ел иңгә-иң торып эшләдек аның белән. Җирле радиодан сөйләгәндә, эфирга чыгар алдыннан һәр тапшыруны күзәтеп бирә иде иптәш Раков. Җиде ел минем, инструкторның, турыдан-туры хуҗасы — КПСС райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире урынбасары булды Револь Габдуллович. Ул райком аппаратында барысы, әйтергә генә ансат, егерме ике ел эшләде.

1985 елда тормыш дулкыннары кабат очраштырды безне. Берзаман газета җаваплы сәркатипсез, ягъни редакциянең штабы хуҗасыз калды. Бу шундый урын — газета мөхәррирсез яки бүлек хәбәрчеләреннән башка чыгарга мөмкин, ә җаваплы сәркатипсез укучыга барып җитә алмый. Менә шушы четерекле вазифаны алтмыш тугыз яшенә кадәр алып барды ул. Ничек кенә алып барды әле: редакциягә килмичә калган берәр шимбәсе булды микән аның! Эш көнендә беренче каттагы типографиягә ничә дистә тапкыр төшеп менгәндер. Аңа йомыш кушарга уңайсыз иде. Чөнки син фикереңне әйтеп бетергәнче, ул инде ике этаж арасындагы текә баскычның уртасына җиткән була, «егетләрски» хәрәкәтчән ул.

Башлангыч классларда укучыларга белем бирүче Ленина (В.И.Лениннан алынган) ханым белән башта үз балаларын үстереп, хәзер оныкларын тәрбиялиләр. Ленина Абдулловна да укымышлы нәселдән, әтисе озак еллар башкарма комитет рәисе булып эшли.

Ә инде язмабыз герое Револь Габдулловичка (башта «рево» гына була, «л» хәрефе белән нечкәлек билгесе соңрак өстәлә) кабат тукталсак, ул 1931 елның 7 ноябрендә Килдебәк авылындагы укытучылар гаиләсендә дөньяга килә. Октябрь бәйрәмендә туганга күрә, Револь исеме куялар (аннан соң туган сеңлесенә Люция кушалар). Әнисе Нәсимә апа Мамадыш педагогия училищесын, әтисе Арчаныкын тәмамлаган була. Мәктәпләрдә махсус белемле мөгаллим-мөгаллимәләр җитәрлек булмаганлыктан, аларны гел күчереп йөрткәннәр. Шулай итеп, биш балалы Габдулла белән Нәсимә, районыбызның Яңа Мичән, Кызыл Мишә, Керәнне (әтиләре сугышта вакытта әниләре шушы төбәк балаларына белем бирә), Бакшанды авылларында яшәп, яшь буынны тәрбиялиләр, 1949 елда Иләбәр мәктәбенә күченәләр. Габдулла абзый илле алты яшендә шунда вафат була.

Бик зыялы була бу нәсел. Мәсәлән, революциягә кадәр үк чыккан бер китапта Урта Саба авылы имамының Мирза Мөхәммәтгариф улы Раков булуы теркәлгән. Губернатор киңәшчесе (Казанда) вазифасын алып барган ераграк бабалары бу фамилияне Мөбарәковтан, русча әйтелергә уңайлы итеп, Раков дип кыскарткан булса кирәк.

Сара Ракова, Саҗидә Ракова, Мәрьям Ракова, Зәйтүнә Ракова, Фәрит Раков, Габдрахман Раков, Салих Раков, Әмин Раков... Бу нәселнең исемлеген әнә шулай әле шактый дәвам итеп булыр иде.

Ә инде яңадан хезмәттәшебез Револь Габдулловичка әйләнеп кайтсак, Шекшедә җидееллык мәктәпне тәмамлап, Сабага килеп урта белемле була ул. Аннары читтән торып Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Эзмә, Яңа Мичән мәктәпләрендә укыта. Илле елга якынлашкан хезмәт стажы чорында өч-дүрт кенә төрле вазифа башкара — мәктәп хисапчысы, укытучы, партия хезмәткәре, журналист.

*2001*

# Ике гасырны тоташтыручы

Тимершык авылының Акчишмә урамында гомер кичерүче Галим бабай Вәлиев 2002 елның 25 гыйнварында 100 яшен тутырды. Әйтергә генә ансат: ике гасырны тоташтырып кара әле!

Шулай булса да, Галим абзый хәрәкәттә әле. Без килгән көнне дә кырынган-чистарынган килеш, алай гына түгел, бумази күлмәгенә орден-медальләрен дә тагып куйган иде.

Өйгә кергәч, мөселманнарча дога кылдык. Ә йорт хуҗасы яңгыратып укыды белгәннәрен. Аннары:

— 100 яшькә җитәрмен дип үзем дә уйламаган идем. Күпне күрдек. Килгәнегез өчен рәхмәт инде, — диде.

Дөрестән дә, уйлап карасаң, исең китәрлек бит: Бөек Октябрь инкыйлабын 15 яшьтә каршылаган, армия хезмәтен үткән, 1921 елгы ачлыкны кичергән, Бөек Ватан сугышыннан яраланып кайткан, аннары гомер буе диярлек колхозда эшләгән ул. Хәзер дә кече улы Рамил гаиләсе белән үз нигезендә имин генә яши.

— Мине Рамилгә сорап килгәндә, сиксән яшькә якынлашкан иде инде ул, — дип сөйли килене Фәнүсә. — «Ике-өч ел гомерем калгандыр, тыңла инде, карчыгым да үлеп китте, җитмәсә», — дигән иде ул вакытта. Менә, Аллага шөкер, аннан соң егерме елдан артык вакыт үтеп китте. Улыбыз Рафис, хәрби хезмәттән кайтып, «Көек» ярдәмче хуҗалыгында тракторда эшли. Кызыбызның берсе — Гөлчәчәгебез — Казанда, Фәнзиләбез авылда тугызынчыда укый. Әткәй балаларны үстерергә, хуҗалыкны алып

барырга булышты. Әле туксан биш яшьтә дә печән чаба иде. Тәмәке тартмады, аракы белән мавыкмады. Балык тотты, суны бик яратты. Боз китүгә, елгада коена башлап, көннәр ныгытып суыткач кына туктый иде бу гамәленнән.

Әйе, гасыр кичкәннәр бармак белән генә санарлык районда. Шуларның икесе Тимершыкта. Җәмниха әби Мөхетдинова 2001 елда йөзне түгәрәкләгән иде. Ир-атлар арасында Галим ага — иң өлкән кеше. Аның Көек авылында яшәүче кызы Нәфисҗамал әби дә сиксәнгә якынлашып килә инде. Миннәхмәт белән Хәнифә дә исән-сау. Бирсен Ходай, озын гомерле булыйк. Вәлиевләр нәселен егерме биш онык һәм онықчык дәвам итә.

Бу көннәрдә Галим Вәли улын котлаучылар байтак. Иң беренчеләрдән булып аңа район ветераннар советы рәисе Әрхәметдин Мостафин һәм инвалидлар оешмасын җитәкләүче Сәлим Сәйфуллин, тәбрикләү хаты белән кучтәнәч тапшырып, нык сәламәтлек теләделәр.

*2002*

# Шешәдән стена өя Рәшит

Мин аның хикмәтле кеше икәнен күп еллардан бирле беләм. Алай гына да түгел, Казан дәүләт университетында укыган яшьлек елларыбызда язучы Газиз Кашапов белән Рәшитләрнең Свердлов урамында торучы Ризатдин абыйларына кереп-чыгып йөрдек, кунакханәдә урын булмаганда кунып та кала идек. Шул елларда һич көтмәгән җирдән Рәшит Саба кияве булды да куйды һәм тора-бара иң мөхтәрәм кешеләрнең берсенә әйләнде. Ярты Сабага көтү чиратына әйтә ул. Бу — бик четерекле эш. Күпме халыкка ярарга кирәк бит. Шуның өстенә ике зиратны карап тора. Кабер казу өчен кирәк-яракларны — барлык төр инструментларны ремонтлап, тәртиптә тота. Аның быел җәй, теләсә кайда аунап яткан кадерсез шешәләрне җыеп, гараж стенасы өюен дә ишеткән идем. Әмма үзе белән күрешеп сөйләшергә вакыт җитмәде. Һәм менә бик иркен җай чыкты, «Бәкер» курортында очраштык без аның белән.

Рәшит турында: «Күпне күргән, күпне кичергән», — дип авыз тутырып әйтергә була.

— Алты тапкыр үлемнән генә калдым, — дип искә ала ул. — Бала вакытта ике тапкыр суга баттым, киномеханик вакытта ике тапкыр электр тогы тотты, бер тапкыр юл фаҗигасенә эләктем, комбайнда эшләгәндә, ургычның вариатор пружинасы башыма сукты. Тугыз сәгать аңсыз ятканмын. Үлгән дип сакларга килгән әбиләр, мин торып утыргач, берәм-берәм чыгып шылдылар...

Әйе, Рәшит Минаповның тормыш юлы борылмалы-борылмалы баскычлардан тора. Ул аларның кайсын үрмәләп, кайсыннан йөгереп үткән. Аның әти-әнисе чыгышы белән Аксубай районының татар шигъриятенең аксакалын тудырган Хәсән Туфан авылыннан — Иске Кармәттән була. Рәшитнең әйтүенә караганда, алар ерак туганнар да икән әле.

Минаповлар, тормыш алып барырга җиңел булмасмы дип, Әлмәт районының Новотроицк авылына күчә. Сабый дөньяга килүгә, әтисе аларны ташлап китә. Ә инде балалык еллары тагын икенче җирдә — хәзерге Лениногорск районының Печмән авылында үтә. «Менә торган җирләрне карап килдем әле. Без яшәгән бараклар урынына күп катлы йортлар салынган», — дип искә алды ул үсмер елларын.

Печмәндә беренче классны тәмамлагач, тормыш авырлыгына чыдый алмыйча, әбиләре яши торган (әнисенең анасы) Аксубай районындагы Думага (шагыйрь Нәҗип Думави авылы) кайтып егылалар. Рәшит унике яшенә җиткәч, җәйге каникул вакытында ат җигеп эшли башлый һәм хезмәт көннәре өчен тәүге тапкыр 49 сум 50 тиен акча ала. Минаповларның ишле гаиләсендә (икенче әтидән бу вакытта ике энесе белән бер сеңлесе дә туган була) бик шатлыклы көн була ул. Аннары кырыгар литрлы сөт бидоннарын машинага төяү-бушату вазифасы йөкләнә яшүсмер малайга.

Рәшитне алда тормышның тагын да авыррак баскычлары көтә икән. Алтынчы классны бетерүгә, Куйбышев өлкәсенең (хәзер Самара) җәһәннәм чигендәге Надеждино дигән авылына барып, берьеллык механизаторлар курсына укырга керә. Аны тәмамлап кайткач, иске генә трактор бирәләр, җәен «Коммунар» комбайнына ярдәмче булып утыра. Бик авыр заман: кешенең өеннән кәҗәсен, сарыгын, бозавын җыя торган Хрущев хакимлек иткән чор була. Минаповлар гаиләсенә тагын бер олы шатлык иңә: Рәшиткә ул елны эшләгәне өчен 1 центнер да 14 килограмм ашлык бирәләр!

1964 елда алар, бәхет эзләп, гаиләләре белән Себергә ялланып, русчалатып әйтсәк, вербовать ителеп китеп, Омск өлкәсенең 17 төрле милләт яши торган 27 өйле Коечиләк (исеме казакъчадан алынган булырга тиеш) дигән авылга барып урнашалар. Торырга йортын, асрарга сыерын бирәләр. Рәшит, «ДТ-54» маркалы чылбырлы тракторга утырып, чәчүгә чыга. Язгы кыр эшләре нәтиҗәләре буенча, аңа районда икенче урын бирәләр, костюм-чалбар кебек бүләкләр тапшыралар. Уңган куллы, киң профильле механизатор, өч комбайнны бер итеп, «Сталинец-6»ны җыя һәм шуның белән эшли. Фидакарь, гадел, тырыш хезмәтенең нәтиҗәләре дә куанычлы була: Рәшит Галәветдин улы Минапов комбайнчылар ярышында Омск өлкәсендә беренче урынны ала һәм аны ул вакытта көнкүрешкә әле кереп кенә бара торган иң кадерле, дәрәҗәле бүләк — телевизор белән сөендерәләр, өс-башын карыйлар. Хезмәт көннәре

өчен алты тонна (!) ашлык та тия. Рәшит: «Безнең тамак беренче тапкыр Себердә туйды», — дип искә ала хәзер.

Рәшитнең чираттагы тормыш баскычлары — хәрби хезмәт еллары башлана. Себердән Оренбург өлкәсендәге частька китерәләр аны. Карантиннан соң «Поварлар бармы? Булса — бер адым алга!» дигән команда яңгырый. Рәшитнең өйдә аш-су әзерләгәне булганга, аптырап тормый, Аллага тапшыра. Бәхетенә, часть командиры Победимский фамилияле Сарманнан килгән керәшен татары булып чыга. «Мин сине кеше итәм», — ди ул, тыйнак авыл малае белән танышкач. Командирның җәмәгате Наилә апасы часть ашханәсендә өлкән аш-су остасы икән. Рәшит шуның кул астында эшли, аннары укып, имтиханнар тапшыра, дипломлы пешекче була, киномеханиклыкка да укый. Киносын да куя, хат ташучы, каптенармус, ягъни каптерщик вазифаларын да башкара.

Бу частьның икенче бер шәһәрдә аерым ротасы тора. Киномеханиклары авырып киткәч, Рәшитне шунда җибәрәләр. Кино күрсәтә, азык-төлек склады мөдире дә була. Әмма аның тик торасы килми, буш вакытын кая куярга белми. Ташландык абзарны күреп ала да, командиры белән киңәшләшеп, ике яшь солдат белән шуны өч айда ремонтлап чыга, дуңгызлар алырга тәкъдим итә һәм чучка үрчетә башлый Рәшит. Дуңгызларның баш санын җитмешкә җиткерә ул. Шулар белән мәш килеп ятканда, Победимский абзасы, кабат төп частька чакырып алып, Калининград өлкәсендә хәрби кинооператорлыкка укырга китәргә тәкъдим итә.

Әмма әнисе риза булмый шул Рәшитнең. «Хезмәт срогың бетә, безгә ярдәмең кирәк, калма, кайт!» дип яза Миңзифа апа, елый-елый. Рәшит — яңадан Себердә. Чәчә, ура. Призлы урыннарга чыга, бүләкләр ала. Аны тормышның чираттагы баскычлары көтә: гаилә корырга кирәк! «Фәкать үзебезнең диндәге кеше булсын», — ди әнисе.

Ярар, шундагы Мулланур исемле дустының авылына — Татарстанның бер районына кәләш күзләргә кайталар болар. Таныша ул татар кызы белән. Әмма язган эш булмаган икән. Шул көннәрдә кәләшнең өендә коточкыч фаҗига була: әтисе исерек килеш хатыны белән бер кызын балта белән чабып үтерә. Рәшит белән сөйләшеп йөри торган туташның бер төн эчендә чәче агара, акылын да җуя һәм махсус шифаханәгә озатыла.

Рәшит кире Себергә китмәскә була. Уйлый-уйлый да кунакка кайткан Мулланурның апасы белән Әгерҗе районының Тугызбуе (Девятерня) авылына ияреп китә. Рәшит монда башта колхозда, аннары мелиорация эшләре белән шөгыльләнә торган күчмә колоннада эшли, яңадан Карл Маркс исемендәге колхозга кайта. Төрле-төрле маркалы тракторларда, комбайннарда җиде ел буе чәчә, ура ул. Алдынгылыкны ычкындырмый, көнләшүчеләр дә була, әлбәттә. Кышын кайда кушсалар, шунда хезмәт куя. Эш белән алданыпмы, Ходай насыйп итмәгәнме, өйләнү мәсьәләсе гел арткы планда калып бара. Фатир хуҗасы Мөгаллимә әбисе бик тәрбиядә тота үзен, җае килгән саен тормыш кору мәсьәләсен кузгата.

1977 ел. Урак иртә бетә ул елны. Август ахырларында хуҗалык җитәкчесе, партком, профсоюз әһелләре, Рәшитне чакырып, урып-җыюда яхшы эшләгәне өчен «Берсут» ял йортына путевка бирәләр һәм, хәерле юл теләп, исән-сау кайтырга кушып озатып калалар. Әмма алар ул Рәшитне югалтасын күз алдына да китермиләр әле.

«Берсут»ка килеп урнаша ул. Сентябрьнең җылы җиле Чулман елгасы ягыннан исә. Әледән-әле «Ракета»лар очканы күренеп китә. Игеннәрдән бушап калган басулары искә төшә Рәшитнең. Әмма күңелен өйләнмәү, ялгызлык мәсьәләсе әрнетә аның.

Менә каршысындагы өстәлдә утыручы бер туташка күзе төшә Рәшитнең. Җае чыгып, сөйләшеп тә китәләр болар. Бер-берсенең тормыш баскычлары белән танышалар: икесе дә бер елгы — 1947 дә туганнар, икесе дә ялгызак. Тагын ни кирәк: хат алышырга, очрашырга сүз куешып аерылыша болар.

— Ярар, Тугызбуена кайттым. Эшкә күңел үсми бит, — дип сөйли Рәшит. — Эчкә ниндидер корт керде. Нәрсә булды сиңа, дип сорый фатир хуҗасы Мөгаллимә апа да. Киттем Сабага. Санияләрнең өйләрен эзләп таптым. Кәләш белән күрештек. Әти-әнисе, туганнары белән сөйләштек. Санияне моннан җибәрмибез, Сабада торырлык булсагыз гына өйләнешәсез, диләр болар. Минем киләсе килми. «Йортка керү» дигән сүздән куркам. Уртак сүзгә килә алмыйча, кире кайтып киттем бит.

Рәшиткә Сабадан хатлар килә тора. Бер рәхәт, бер кыен — шул микән әллә чын ярату дигәндәй, күңеле һаман Сания янына ашкына. Октябрь аенда яңадан юлга кузгала ул. Бу юлысына инде сындыралар Рәшитне. Әгерҗегә Саниясе белән кайтып, әйберләрен җыя. Әмма колхоз идарәсе хезмәт кенәгәсен бирми. Бирегә килегез, өй салып бирәбез, диләр.

Уразалар бетеп, никах укыткач кына ир белән хатын буларак яши башлыйлар алар. Менә язмыш кушуы буенча өйләнешкән парлар егерме елдан артык, бер-берсен аңлап, ихтирам итешеп, гөрләшә-гөрләшә яшиләр. Малай һәм кыз үстерәләр, хәзер оныклары да бар. Шулай итеп, алар законлы әби белән бабай булалар.

Рәшит, 1977 елда ук «Сельхозтехника»ның район берләшмәсенә эшкә урнашып, башта «Т-150» тракторында эшли. Авариягә очрап, колаклары ишетми торган булып калгач, техник хезмәт күрсәтү пунктына күчә. Аның бу яңа эштәге турыдан-туры хуҗасы хәзерге премьер-министрыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнеханов була. Уртак тел табып эшләп, зур егәрлекле тракторларга техник карау үткәрү

буенча республика конкурсында катнашу бәхетенә ирешә һәм призлы икенче, өченче урыннарны да яулый.

Бер минутын бушка уздырырга яратмый торган Рәшит үз тырышлыгы белән 65 квадрат метр зурлыкта йорт җиткереп, әби-бабасын, җылы, иркен өйдә яшәтеп, соңгы юлга озата. Йорт җиткерү беркемгә дә җиңел бирелми, әлбәттә. Агачын юнәтеп, бурасын бурата. Әгерҗедән алып килгән мотороллерына прицеп көйли Рәшит. Комын, ташын шуның белән ташып, фундамент салалар.

— Бура авыл кырыенда — комлык чокыры кырыенда иде, — дип искә ала ул. — 6,5 метр озынлыкта 4 әр ниргәне, шул прицеплы мотороллерга салып, төп нигезгә алып кайтып киләм. Карасам, каршыма ул вакыттагы КПСС райкомының беренче секретаре Камалов килеп туктады. Төште төп белгечлеге инженер булган Әләметдин Җамалетдинович. Әйләнә-әйләнә минем йөкне карады һәм: «Менә бит, тырышкан кеше барысын да булдыра. Читтән ат та, машина да сорап йөрми. Молодец!» — дип китеп барды.

Менә шулай дөнья мәшәкатьләре белән тормыштан ямь табып яшәп ятканда, әҗәл дигәне Рәшитне җиденче тапкыр сынап карый: инсульт кичерә. Башына чыдый алмый ул, егылып киткән чаклары да була икән. Менә шул сәламәтлеген ныгыту өчен килгән дә инде «Бәкер»гә.

**— Шешәдән стена өю фикере кайчан килде?** — дип сорыйм.

— Кирпеч кыйммәт бит. Кемдер өй салган дип газетадан да укыдым. Менә абзар-кураны егерме елда өч тапкыр күчереп эшләдем инде. Хәзер мәңгелек итеп салырга исәп бар шешәдән, — дип сүзен дәвам итә ул. — Өч шешә ике кирпечне алыштыра. Чит илнекеләр, шампанскийларныкы фундаментка бата. Теләсә кайда аунап ята ул. Икенче көнне сабантуй урыннарыннан, һөнәри бәйрәмнәр үткән җирләрдән җиде-сигез капчык җыеп алып кайтам. Үземнең атым бар бит. Ком бушлай, цемент кына сатып аласы да стена саласы. Менә шушы 4□10 метрлы ике машина сыярлык гаражга 7000 шешә китте.

Рәшитнең аты гына түгел, «Жигули» машинасы, бәрәңге бакчасын эшкәртә торган мотоблогы да бар. Ремонтлап бетерәсе «ГАЗ-53» йөк машинасы да бакча артында тора. Әйткәнемчә, вакытны бушка уздырырга яратмый ул. II группа хезмәт инвалиды булуга карамастан, ат белән 1 нче номерлы ясле-бакчага азык-төлек ташый. Буш көннәрендә район хуҗалыкларына да килеп алып китәләр, түбән бәядән генә (нигездә бартерга) «К-700» кебек зур егәрлекле тракторның тапшыргыч тартмасын (коробка передач) җыйнап бирә.

— Кирәк булса, өй, мунча мичләре, газ өчен җилләтү каналлары да чыгарам. Зур туйларга аш-су әзерләшергә дә чакыралар: бәлеш, торт, гөбәдия, чәкчәк кебек ризыклар әзерләргә яратам.

**— Рәшит, син бит әле халык ысулы белән кешеләрне дә дәвалыйсың, күрәзәчелек тә итәсең икән,** — дим.

— Кулдан килгәнен эшләргә тырышам, — дип сүзен дәвам итте ул. — Ә инде күрәзәчелек мәсьәләсе безнең нәселдән килә. Әнидә дә бар ул. Ул үзе аерым, четерекле тема. Аңа кермик хәзергә. Минем, сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: тормыш никадәр генә авыр, саулык ничек кенә чамалы булмасын, яшисе килә, яшисе!

*1998*

# Мең рәхмәт сиңа, язмыш!

*Озак еллар «Беренче Май» колхозын җитәкләүче Равил Әмин улы Сөнгатуллин тормышындагы һәм эшчәнлегендәге кайбер мизгелләр.*

...Төн уртасында азрак җил чыга, йомшак ак мамыклар кебек ябалак кар ява башлый, озак та тормыйча буран күтәрелә. Таң алдыннан каты җил бертуктаусыз кар белән уйный, аны туздыра, өйләргә, абзарларга, агачларга, кибәннәргә китереп сылый, уйсу җирләргә ташып өяргә тотына. Шундый гаҗәеп гыйнвар төнендә Югары Шытсу авылында көн күрүче Разыя белән Әминнең уртак җимеше — бишенче ир бала — Равил дөньяга килә. Бу сугыштан соңгы ачлы-туклы яшәгән чор була. Шулай булса да, кешенең бәхете һәм байлыгы балаларда икәнен тирән аңлап яшиләр Сөнгатуллиннар. Алга таба аларның тормышлары тулган ай кебек түгәрәк, ярларына сыймыйча аккан елга суыдай мул булачагына өметләнәләр алар.

Разыя колхоздагы төрле эшләргә йөри. Фин сугышында ук бер аягын калдырып кайткан Әмин башта ат белән сөт җыя. Аннары озак еллар, инвалид булуына карамастан, арбасына мичкәләр төяп, тракторларга ягулык ташый. Бала хәсрәтен дә күрә алар. Әхмәтгасыймны сабый вакытта, Раифны 22 яшендә җирлиләр. Исән-сау калган балаларын укытырга тырышалар: малайлары Рәисне, Наилне, Равилне, Хәмитне, кызлары Равия белән Данияне югары белемле итәләр. Дөрес, язмабыз герое Равил үзе дә яшьтән үк тырыш, үҗәт, максатчан була, җиң сызганып эшләп үсә. «Мин эшләмәгән җир калмады. Яшүсмер вакытта ук ат, сыер, дуңгыз, сарык... барысы алты төрле көтү көттем», — дип искә ала хәзер. Сигез

класс белем алгач, фермага даими эшкә, халыкчан итеп әйтсәк, скотник булып урнаша. Ат җигеп, терлекләргә азык кертә. Туңып-катып кайткач, өч ел буе күрше авылга — Түбән Шытсуга — кичке мәктәпкә йөри һәм 1967 елда Казан дәүләт ветеринария институтына укырга керә. Бу уку йортының бер хикмәтле ягы бар бит. Биредә адәм баласы җан ияләре белән эш итә белгән, монда терлекләргә карата җылы мөнәсәбәте булган кеше генә укый ала. Мал-туарны ярату Равилгә кече яшьтән үк бирелә. Сыер бозаулаганын көтеп алу, аны башак ашатырга һәм бозавын имезергә өйгә алып кергәч, чиләк тотып «пост»та тору, сарык бәрәннәре белән йоклау, ат абзарыннан ак кашкалы бер колынның тууын күреп кайту, әтисе янына утырып йөрү Равил күңелендә гомерлек сөенечләр уята, миһербанлы, кешегә ярдәмчел булырга чакыра.

Югары белемле Равилнең гомер сукмаклары да туган авылындагы фермада зоотехник буларак башлана. Егерме өч яшен тутыргач, күршеләре — өч сугыш ветераны — беренче бөтендөнья, гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнашкан Габделкотдус абзыйның Хәния исемле кызы белән никахлашалар. Баллы айлары озакка бармый Равилләрнең, аны бер елга хәрби хезмәткә алалар. Аннан кайтуга, баш зоотехник итеп билгелиләр. Уртак тормыш ярык кашыктан башлана дигән кебек, Равил белән Хәния Түбән Шытсудагы Гафия әбинең буш тора торган иске өенә күчеп яши башлыйлар. Алар ул вакытта шушы урын гомерлек нигез булачагын уйламыйлар әле.

Бер елдан хуҗалык җитәкчеләре хәзерли торган алты айлык курска җибәрәләр Равилне.

1976 елның феврале. Бу юллар авторының КПСС райкомы инструкторы булып эшләгән вакыты. Карыйм, беренче катта шайтан сөякләрен каплап бетермәгән костюм-чалбар кигән берәү, бик дулкынланган хәлдә, берничә көн рәттән арлы-бирле йөренә, үзе белән үзе сөйләшеп тә куя.

Аның «Беренче Май» колхозы зоотехнигы икәнен чамалыйм. Барып сүз катам. Күңел сизә: «Моны райкомның беренче секретаре Әләметдин Җамалетдинович председатель итәргә кысадыр. Басма салырга кирәк, тора-бара файдасы тияр, бәлки», — дип уйлыйм эчтән генә. Сөйләшеп киттек. Дөрестән дә, нәкъ шулай икән.

— Сезнең кебек кешеләр эшли бит, аптырап торма, — дигән булам.

Икеләнә Равил Әмин улы. Икеләнмәслек тә түгел шул: беренчедән, ул вакытта хуҗалык җитәкчеләре корпусын Социалистик Хезмәт Герое Габделхак Галиев, зур-зур орденнар, мактаулы исем хуҗалары — Кыям Җәләлов, Павел Кощеев, Габделнур Җәлилов, Газиз Йосыпов, Ислам Хаҗиев, Нургаян Мөхәммәтшин, Фәрит Шәйхетдинов, Васыйл Галиев, Афраим Халиков, Хаҗи Габдерахманов, Габделхак Кәримуллин кебек дан-шөһрәт казанган пәһлеваннар тарта. Икенчедән, үзе эшләячәк хуҗалыкның да үзенчәлекле тарихы бар бит. Хәтәр 1937 елда ук республика күләмендә һәр тармак буенча иң югары уңыш алган хуҗалыклар билгеләнә. Орлыклык клевер уңышы буенча Саба районының «Беренче Май» колхозына (Югары Шытсу авылы) тиңнәр табылмый. Председателе Мусин Габдрахман булган әлеге хуҗалык 6 гектар клеверның һәркайсыннан 3,8 центнер уңыш җыя (ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 4580 ф., 850 эш, 1—62 б.). Беренчемайлылар 1947 елда ук бөртеклеләрнең һәр гектарыннан унике центнер уңыш үстереп алалар. Шул уңайдан СССР Югары Советы Президиумы Указы нигезендә Саба районы буенча бүләкләнгән ун колхозчының алтысы «Беренче Май» колхозыннан була. Хезмәт Кызыл Байрагы орденына ия булган Әхтәмҗан Нигъмәтҗанов белән Әхмәдулла Насыйбуллин звеносында һәр гектардан алынган уңыш 18,63—21,4 центнерга җитә. Равил бу казанышларны ишетеп белә бит. Колхоз уңганнары «Илшат» (Түбән Шытсу), «Кызыл яшьләр» (Мамалай), «Мәскәү» (Көек), «Кызыл батыр» (Чәбки-Саба), «Кызыл көч» (Елыш) колхозлары белән берләшкәч тә сынатмыйлар. Мәсәлән, 1968 ел колхозга аеруча зур уңышлар китерә: планнан тыш 5800 центнер ашлык, 5300 центнер сөт, 500 центнер ит, 14 центнер йон сатыла. Әлеге казанышлар өчен «Беренче Май» колхозы СССР Авыл хуҗалыгы министрлыгы, авыл хуҗалыгы һәм хәзерләүләр эшчеләре һәм хезмәткәрләре профсоюзы Үзәк Комитетының күчмә Кызыл Байрагына һәм акчалата беренче премиягә лаек була. Колхозны чабата киеп җитәкли башлап, гомер буе алдынгылар сафында йөртеп, районда Россия күләмендәге персональ пенсияне беренче булып алган Гобәйдулла аганың: «Дөньядагы иң матур агач — ак каен, иң очлы әйбер — сабан, иң авыр нәрсә — башак, иң газиз, иң мөкатдәс ризык — икмәк һәм иң көчле кеше — игенче», — дигән сүзләре күңеленнән уза булачак рәиснең. Туган колхозын җитәкләргә Аланына кайтырга ниятләгән остазы Мансур Хөсәенович та җирне яратуы, үтә таләпчәнлеге һәм максатчанлыгы белән районда хөрмәт казанган кеше бит. Партком секретаре Хәким ага Гарипов та заманында Җәлил совхозы директоры булып эшләгән төпле фикерле кеше. Әйе, җиңел булмаячак әлеге бай тарихлы колхозны җитәкләве. Әмма артка чигенергә урын юк. Тәвәккәлли Равил Әмин улы һәм КПСС өлкә комитетына раслануга китә. Тик бит әле тәвәккәллек ордым-бәрдем дигән сүз түгел, тәвәккәллек акыру-бакыру да түгел. Бу төшенчәгә халыкның икенче бер акыллы фикерен китереп кушарга, үзеңне зур итмәскә, колхозчыларны хур итмәскә кирәк. Халык сизгер ул, акны карадан аера белә. Этлек кылганны да, егетлек эшләгәнне дә тоеп, белеп яши. Шуңа күрә Равил рәислек итә башлаган беренче көннәреннән ук халыкка таяна, һәм моның дөреслеген тормыш үзе раслый. Заманның иң авыр мизгелләрендә дә аны колхозчылары бердәм яклый. Үзенең авылдашларына кирәклеген күп тапкырлар аңлый Равил Әминович. Моннан да зур бәхетнең булмавын бу халәтне үзенең йөрәге аша үткәргән җитәкче генә белә. Бөтен халык абруена ул

фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә иреште. Без, журналистлар, мондый вакытта бик күп саннар тезәргә яратабыз. Мин андый максат куймыйм бүген. Фәкать иң зур үсешкә ирешкән елларны гына телгә алып үтәм.

Утызынчы еллардан ук башланган алдынгылыкны кулдан ычкындырмыйлар беренчемайлылар. 1997 елда бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культуралар уңышын 30 центнердан арттыралар.

Һәр сыердан сөт савып алу күрсәткечен сиксәненче еллардан бирле 3200—3900 килограммнан киметмиләр. 1995 елда 4000 килограмм чиге яулана. Дәүләткә елына 25 мең центнер ашлык, 20 мең центнер сөт, 4 мең центнер ит саткан вакытлар да була. Соңгы киеренке елларда баш санын киметмиләр беренчемайлылар. Продукциясен дә мул җитештерәләр. Әмма эшләгән кешегә вакытында хезмәт хакы бирә алмау нык борчый рәисне.

Җитмешенче еллар уртасыннан башлап терлекчелек корылмаларының һәммәсе дә диярлек яңабаштан төзелә. Һәр бригада ябык ындыр табаклары, ашлама складлары белән тәэмин ителә. Шартлы 50 тракторга исәпләнгән механик мастерской салына. Авылларның йөзе нык үзгәрә: балалар бакчалары, кибетләр саны арта. Спорт заллары, мәдәният учаклары эшләп тора. Бигрәк тә юллар, күперләр төзелешенә игътибар ителә. 1982 елда ук гомер буе язын олы юлдан аерып азаплаган Казкаш елгасы аша тәүге күпер файдалануга бирелә. Гомумән, районда типовой проект белән 17 күпер төзелгән булса, шуның бишесе «Беренче Май» колхозы биләмәсендә. Хуҗалыкның үз көче белән 19 километр юл күтәртелә. Тора-бара һәр авылга табигый газ, өчесенә суы да кертелә.

— Дөрес, бездә заманча төзелгән социаль-мәдәни объектлар күп түгел, — дип, әңгәмәгә ачыклык кертә Равил Әминович. — Югары Шытсудагы мәктәп, балалар бакчасы, медицина пункты комплексын исәпкә алмаганда, без калган барлык биналарны да хуҗалык исәбе белән төзедек. Алай гына түгел, колхоз салып биргән йортларда яшәүчеләр саны да хәзер кырыкка якынлашкан.

Әйе, авыл кешесенә — механизатормы ул, терлекчеме — шартлар тудырырга кирәк. Эш шартлары һәм тормыш шартлары. Шул чагында гына колхозда тулы тәртип була. Аның хәвеф-хәтәре — янгыннары да булып тора бит әле. Мәсәлән, тракторчы Мансур Ибраһимов, сыер савучы Гәмбәр Әдһәмова, инженер Мөхәррәм Заһидуллиннарның өйләре янгач, белгечләр, рәис үзе катнашында өмәләр ясый-ясый тиз генә йортлы итәләр. Белгечләр дигәннән, биредә аларның берсе дә читтән килмәгән. Шушы төбәк кешеләре үз тармакларын биш бармаклары кебек белүчеләр. Баш агроном Әлтәфетдин Сафин белән баш зоотехник Нурислам Гаффаров Татарстан күләмендәге профессия буенча мактаулы исемгә Равил Әминовичның үзенә бирелгәнче үк лаек булдылар. Гомумән, бу колхоздагы мактаулы исемле, орденлы-медальле кешеләрне саный китсәк, исемлек бик озынга сузылыр иде.

Үзенең чирек гасырга якын тәҗрибәсе булса да, ветераннарга таянып эшли Р.Сөнгатуллин. Шуларның берсе 88 яшьлек Гобәйдулла ага Хуҗин булса, икенчесе — озак еллар ферма мөдире, авыл советы башкарма комитеты рәисе, партком секретаре вазифаларын намус белән башкарган Гасыйм ага Хөснуллин. Аларның дуслыгы этиләреннән үк килә. Ять-яшь Әмин белән Хөснулла фин сугышына бергә китәләр. Беренчесе аягын калдырып, икенчесе исән-сау килеш кайта бу яудан. Әмма Хөснулланы алда тагын да авыр язмыш көткән икән: ул, балаларын ятим, хатынын тол калдырып, Бөек Ватан сугышында башын сала.

Әйе, башкалар күңеленә юл табу, хөрмәткә лаек булу, зур абруй казану, колхозчының олысын-кечесен аермыйча, һәркемне тыңлый һәм ярдәм итә белү сәләте, мөлаемлык, киң күңеллелек һәм башка сыйфатлар рәиснең үзенә дә, хуҗалыкка да дан-хөрмәт китерә. Монда колхозның 1984—1985 елларның кышлату чоры нәтиҗәләре буенча КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының Мактау грамотасына лаек булуын, аны Татарстан Республикасының ул вакыттагы Министрлар Советы Рәисе, булачак беренче Президентыбыз М.Ш.Шәймиев тапшырганын да искәртергә кирәктер.

Аннан соң озак та үтмәде, 1989 елдагы социаль үсеш планнарын уңышлы тормышка ашырган өчен РСФСР Министрлар Советының һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл Байрагына лаек булдылар. «Почет билгесе» орденлы Равил Әминович тормышындагы иң зур вакыйгаларның берсе — партиянең XXVIII съездына альтернатив юл белән (көндәше күрше районның беренче секретаре бит әле!) делегат булып сайлануыдыр. Сөйләп бетерә алмаслык канәгатьләнү хисләре кичерә ул КПССның иң олы форумы барган көннәрдә. Ничек итеп горурланмаска кирәк: Югары Шытсуның аксак Әмин малае Съездлар Сараенда утырсын әле. Шул минутларда аның күңеленә, мөгаен, мондый уйлар килгәндер:

Талгын
Тыныч кичтә бар
Җир шары,
Бөтен җиһан сыя авылга.
Дәүләтара эшләр
Хәл иткәндә,
Тиеш түгел читтә калырга,
Тиеш түгел минем
Авыл да!

Коммунист Равил Әминовичны монда тагын бер сынау көтә икән: Татарстан делегациясе аны яшерен тавыш белән өч кандидат арасыннан партия Контроль комиссиясе әгъзасы итеп сайлый. Шулай булгач, Равил Сөнгатуллинның «Кто есть кто» дигән китапның ике басмасына кертелүе юкка түгел.

Язмам герое Равил Сөнгатуллинның һәрвакыт үз фикере булды. СССРның һәм КПССның таркалуын хәзер дә гафу итә алмый. Идарә бинасы өстендә СССР флагы җилфердәве аның бүген дә үз-үзенә тугры калуын раслый. Хуҗалыкларга күмәк предприятие, әйтергә тел әйләнми торган ассоциация кебек исемнәр бирелә башлагач та: «Безнең бабайлар кан түгеп төзегән колхозны таркатмыйбыз да, исемен дә үзгәртмибез, чөнки тапкырланучыларның урынын алмаштырып кына сумма үзгәрми», — диде.

Равил Әминовичка илле яшь. Бу әле картлык, кешене дуга итеп бөгә торган сан түгел. Аның җимертеп эшләр һәм яшәр чагы. Ләкин шунысы куанычлы, узган хезмәт юлы буш түгел. Тормышы да матур. Тыныч холыклы, ачык күңелле, һәр сүзен уйлап бетергәч кенә әйтә торган Ханиясе бар. Уллары Ренат белән Илфат, югары белем алып, матур гына эшләп йөриләр. Төпчек кызлары Айгөл дә җитеп килә. Кыскасы, гомернең узган кадәресе заяга булмаган.

Афәрин! Алга таба да дилбегәне шулай тот, язмышыңа мең рәхмәтле Равил Әминович, дип, әлеге язманы туган җирең, эшчән халкың турындагы шигъри юллар белән тәмамлыйсы килә:

Минем авыл тырыш,
Бераз кырыс, бераз тупас,
Әмма самими.
Ул ягымлы,
Намуслы һәм эшчән —
Кеше җилкәсенә
        салынмый.

*1999*

# Тенекинең соңгы көмешчесе

Тенеки көмешчеләре... Аларның даны еракларга таралган. Көмешчеләр тарихы Болгар дәүләтенең үсеш чорларына барып тоташа. Моны байтак кына фәнни хезмәтләр, татар ювелир сәнгате үрнәкләре һәм тарихи ядкарьләр раслый. «Әйтик, 1987 елда табылган ярымай рәвешендәге кызыл сатинга ялтыравыклы тәңкәләр тагылып ясалган затлы хәситә Саба төбәгендә таралган кәсепнең юл башын тагын да төгәлрәк ачыкларга ярдәм итте, — дип яза Татарстан Сынлы сәнгать музее хезмәткәре Розалина Шаһиева. — Анда үрдәк сурәте чүкеп ясалган бер тәңкә мәҗүсилек авазларын чагылдыра, һәм бу хәситәнең тууы XII–XIII гасырларга туры килүен тәгаенләргә мөмкинлек бирә».

Без Тенекигә — бу авылның соңгы көмешчесе Хәбибрахман ага Ганиев янына юл тоттык. Дөрестән дә, мондагы табигать оста куллы рәссам төшергән гаҗәеп бер рәсемнән сайлап алынган күренешләрдән тора сыман. Таза бүрәнәләрдән салынган җыйнак авыл йортларын бер яктан тау урап алган. Әйтерсең ул авылны кырыс җилләрдән саклар өчен махсус шулай урнашкан. Аз гына астарак бормаланып аккан инеш аша күпер сузылган. Яр буйлап мәһабәт өянкеләр тезелгән.

Пөхтә итеп эшләнгән алты почмаклы өйгә кердек. Безне якты йөз белән Хәбибрахман ага һәм аның карчыгы Мөкәррәмә апа каршы алды. Биредә бар да гади. Чәчәкле чаршаулар да үзенә күрә борынгылыкны хәтерләтә. Менә шушында Хәбибрахман ага халкыбызның сәнгать әсәрләрен иҗат итә. Туксанга якынлашучы ветеранга күз генә тимәсен әле. 1943 елда Воронеж юнәлешендәге фронтта бер аягын калдырып кайткан, аннан соң чирек гасыр тимерчелектә эшләп картайган аксакалның хәтере бик әйбәт. Авылдашларын соңгы юлга озату йолалары да аның өстендә икән әле. Ул агач аягы белән оста хәрәкәт итә. Шулай булмыйча, илле елдан артык агач аяк белән йөр әле! Күнегелгән!

Менә ул кулына Николай-патша сурәте төшкән борынгы акча алды һәм аның көмеш икәненә икеләнеп калды.

— Моны эретеп карамыйча булмый. Хәзер мичне үрләтеп җибәрим әле.

Хәбибрахман аганың мич дигәне эчтән кызыл балчык белән уратылган калай чиләк икән. Ул аны үзе «гурна» дип тә атый. Агач күмере белән ягыла. Ләгәннең аскы өлешендә бер тишек калдырылган. Күмер кызаргач, кечкенә генә калай чүлмәккә салынган көмеш тәңкә су кебек сыеклана да куя. Нәни улакка күчереп, суынгач кына яңадан көмеш хәленә кайта. Аннары ул сандалга куела. Уртача авырлыктагы чүкеч белән чүкелә. Өслеген тигезләү өчен заводтагы прокат станогын хәтерләткән пресска кертелә. Аны тимер кәтүкләрен көч җиткәнчә кысасың да, валны кат-кат әйләндереп, көмешне юкартасың. Чималны ясыйсың. Төсле тимерне, тиешле озынлыкта кисеп, бөгеп, түгәрәк алка хәленә китерәсең. Аннары инде бизәк эшләре башлана. Башта игәү-казыгыч белән рәсем ясала. Дөресрәге, төрле фигурадагы чокырлар «казыла». Ә аннары әлеге уемталарга «кара алтын» — эретелгән җиз, кургашын, күкерт катнаш масса тутырыла. Калган чәчәкләр исә кыргыч-казыгыч белән эшләнә.

Менә шулай итеп, Хәбибрахман ага, бөтен ихтыяр көчен, сабырлыгын җыеп, күңел байлыгын ти-

мергә төшерә, сәнгать җәүһәрләре тудыра, аларга күңел яктысын сала. Бу вакытны бик күп сорый торган хезмәт. Шуңа күрә яшьләрнең олы түземлек сорый торган әлеге «ак эш» белән бик утырасылары килми. Дөрес, үзешчән рәссам Хәлим Габдрахманов һәм көмешченең улы Рафис Хәбибрахман агадан байтак күнекмәләр алганнар. Әмма күңелне шунысы борчый: алар бу эшне алга таба дәвам итәрләрме? Хәбибрахман ага Ганиев Байлар Сабасы дип аталган тарихи төбәкнең соңгы көмешчесе булып калмасмы?

Хәбибрахман ага әтисенең абыйсы Габдулла Габделлатыйповка гомер буе рәхмәтле. Ул, Әстерханда патша армиясендә хезмәт иткәч, остазга ялланып, көмештән челтәр ясарга, аны «кара алтын» белән бизәргә өйрәнгән. Нәселләрен яңа һөнәрле иткән. Дөрес, ул Хәбибрахманның абыйсы Габдрахманны үз янына бик үк якын җибәрмәгән. Әмма тегесе, читтән генә каранып йөрсә дә, үзенә кирәк гыйлемне алган, каралтынлау серләрен Хәбибрахманга өйрәткән.

Шуңа күрә аның бәяләп бетермәслек ядкарьләре бүген дә меңләгән кешеләрнең күз карашын иркәли.

*1996*

# Кулымдагы йөзегемнең исемнәре... Лемара

*(Гаиләбез хәлләре)*

Уемда — яраткан эшем.
Куенда — яшьлек ярым.
Дөньяга, кешеләргә
Рәхмәт әйтер чагым.

*Р.Фәйзуллин*

«Сөембикә» журналы тарафыннан әлеге тема тәкъдим ителгәч, башта бераз аптырап та калган идем. Шушындый олпат басмада катнашырга иртәрәк түгелме икән? Шактый вакытлар уйланып йөри торгач, гаилә корып яши башлавыбызга да утыз ел тулып, энҗе туебыз булып узды, байтак мәзәкләремнең героена әйләнгән оныгыбыз Гадел дә, тәүге тапкыр мәктәп ишеген ачып кереп, парта артына утырды. Үзем дә берничә айдан яшем буенча ике бишлене эләктерергә йөрим. Дөрес, илле биш алтмыш биш тә, җитмеш биш тә түгел әле... Дистәгә якын китапның тышында исем-фамилиям булу да куанычлы хәлдер. Шулай булгач, Аллага тапшырып, ни өчен әле «Кулымдагы йөзегемнең исемнәре... Лемара» дип каләм тибрәндереп карамаска?!

Дөресен әйтергә кирәк, безгә гүзәл табигатьле уртак авылда туып үсеп, ямь-яшел үләннәр өстендә уйный-көлә каз бәбкәләре сакларга, бер мәктәптә укырга насыйп булмады. Чөнки ул — Арча районының гаҗәеп матур исемле Сеҗе авылы кызы. Ә мин Байлангарда (Кукмара) дөньяга килгәнмен. Лемара белән армиядән соң, ягъни балигъ булгач таныштык без.

...1972 елның апрелендә Совет Армиясеннән кайттым. Бер атна вакыт үтте микән, Саба мәдәният йортына эшкә чакырдылар. Ул вакыттагы бүлек мөдире Госман абый Гарипов белән фатир табып, Совет урамындагы Мәрхәбә апаның балчык белән сыланып, акка буялган тыйнак кына йортына урнаштым. Өй эчендә пыяла рамда Габдулла Тукай рәсеме тору да күңелемә хуш килде. Иң беренче эш итеп хуҗабикәнең киселеп, капка төбендә берничә җәй пешеп яткан утынын ярырга керештем. Кичкырын, сәгать дүртләр-бишләр тирәсендә, мөлаем гына бер кыз серле генә итеп исәнләшеп үтә бит. Кыскасы, күз төшәрлек иде ул. Гәүдәсе дә җыйнак, елмаюы да май кояшы кебек. Чиләнгән һәм миләнгән бүкәннәрне яра алмыйча азапланып чәй эчкән арада, Мәрхәбә ападан бу егерме яшьләр чамасындагы туташның кем булуы белән кызыксынам.

— Медсестра ул. Бүлнистә, тештә эшли. Бакча башында — Камәриядә тора. Төпле егете юк бугай...

Күптән түгел шинелен салып, ялгызлыктан башын кая куярга белмичә, «кошлар сайрый тирәктә, ашкынулар бар йөрәктә» дип йөргән солдатка ашыгыч стратегик чара күрергә кирәк иде. Бәхеткә каршы, шул көннәрдә ниндидер концерт килде. Чакыру билеты алдым да менеп киттем мин бакча башына. Бераз каршы килеп карады да ризалашты күрше кызы, рәхмәт яугыры. Саба инеше өстеннән салынган асылмалы басма аша киттек мәдәният йортына. Концерт бик шәп булды. Шул кичтә үк аңа сабый бала анасына тагылган кебек ябыштым мин. Кайтканда, сөйләшә киткәч, әллә кайчангы танышлар булуыбыз ачыкланды. Дөресрәге, ул күптәннән белә икән мине. Хәзер ашыкмыйча гына, иплэп-җайлап кына шул хакта хикәяләп үтим әле, яме, мөхтәрәм укучым!

Әйткәнемчә, бала вакыттан — икенче класста укыганда ук, үзешчән сәнгатьтә нәфис сүз остасы буларак катнашып килдем мин. Сигезенче классны тәмамлагач, авылыбызның Киров өлкәсендә эшләгән баянчысы Илдар Нургалиев Сосновка шәһәрендәге Ю.Гагарин исемендәге Мәдәният сарае исеменнән гастрольләргә алып чыгып китте. Без, дүрт кеше, беренче бүлектә концерт куябыз, тәнәфестән соң Михаил Пармет дигән исем-фамилияле фокусчы сәгать ярым могҗиза күрсәтә, авызыннан утка кадәр чы-

гарып, халыкны шаккатыра...

Бабайның багажы ун-унике кисәк сумка-чемоданнан тора иде. Бүлешеп күтәреп йөрибез. Миңа, метр ярымлы яшүсмергә, гәүдәм бик кечкенә булгач, читлек белән тере күгәрченнәр тоттырдылар. Икенче кулымда — үземнең «чумадан», аркадагы рюкзакта фокусчының чүпрәк-чапраклары...

1 сентябрь килеп терәлгәч, бик яшьли бозылып, аттестатсыз калам, ахры, дип, акыл белән тирәнтен уйлап, авылыбыз мәктәбенең IX классында укуны дәвам итәргә булдым.

«Чир китә, гадәт китми» диләр бит. Байлангарда конферансье малай бар икәнен ишетеп, мине, Шәмәрдән станциясендәге промкомбинат клубы мөдире, рәссам, баянчы, скетчлар язучы һәм уйнаучы Вил Гарипов килеп, шимбә-якшәмбе кичләрендә үзләренең концертларын алып барырга «кодалады». Ризалаштым. Әйбәт кенә түлиләр дә. Колхозчы әти-әнигә анысы да зур матди ярдәм бит.

Вил Зариф улы, рәссам буларак, афишаны мавыктыргыч-матавыклы итеп ясый иде. Башта бик озын итеп мәһабәт тавышлы ике метрлы җырчы Эльбрус абый Сибгатуллинны нәкъ үзенә охшатып ясап куя, янына, урындык өстенә, мине менгереп бастыра... Реклама яхшы булгач, халык өелеп килә иде концертка.

— Хәзер сәхнәгә иң яшь, иң кечкенә җырчыбыз Эльбрус Сибгатуллин чыга, — дип игълан итәм.

Мәһабәт гәүдәле, ягъни гүәрдин кебек кеше күренгәч, тамашачы иләсләнеп кул чаба башлый. Җырның исемен әйтү өчен янына барып басам. Ә теге миңа таба бөгелми. Ә мин аның нәкъ пиджак кесәсе белән тигез. Шуннан соң нишлим? Чарасызлыктан сәхнә артына кереп китәм дә урындык алып чыгып, җырчы янәшәсенә куям. Менеп баскач, тигезләнә язабыз тагын. Аннары ул җырның исемен әйтә, мин тамашачыга җиткерәм һәм, җайлап кына төшеп, урындыгым белән кереп китәм.

Җыр бетәр-бетмәс алкышлар яңгырый башлый. Сәхнә артыннан урындык өстерәгән кечкенә конферансье янә күренә. Өч-дүрт җыр башкарганнан соң, халык ишетерлек итеп:

— Шушысын җырла да кер! Мин сиңа һаман урындык күтәреп йөрмәм, — дип тә җибәрәм.

Тагын алкышлар...

Боларның йөзек темасына ни катнашы бар, нәрсәгә бу үзе турында сөйләргә кирәште әле, дип уйлыйсыңдыр инде, укучым. Хәзер, ашыкма әле, яме, бу кереш сүзнең «аккорды» барыбер булачак...

Без Арча районының Сеҗе авылында чыгыш ясаганда, бергә гомер итәсе җәмәгатем Лемара Фатыйхова, укучы бала буларак (миннән ике яшькә кечерәк), концертыбызны, укытучылардан (ул вакытта курку дигән нәрсә бар иде бит!) кача-поса, мич арасыннан караган булып чыкты. Урындыкта басып торучы шушы «сәхнә йолдызы» белән гомер итәсе, балалар үстерәсе, бер җан, бер тән булып яшисе булыр, дип, ике ятып бер төшенә дә кермәгәндер ул вакытта.

Ярар, яңадан егет һәм кыз вакытка әйләнеп кайтыйк әле. Шулай әйбәт кенә йөреп торабыз. Яшь вакытта күңелгә иләс-миләс фикерләр дә кереп куя бит. Авылында егете бардыр, анда булмаса, армиядәдер кебек тоела. Эчне ниндидер корт кимерә.

1973 елның язгы бер матур көнендә Лемара, минем фатир хуҗама кереп, әнисеннән телеграмма килүе турында әйткән дә юлга кузгалган. Шул хәбәрне ишеткәч, минем йөрәк-бавырым өзелеп төшкәндәй булды. Эчкә тагын җеннәр коткысы керде. Икенче кешегә кияүгә димләмиләр микән, янәсе. Читтә егете булып, шул кайтты микән әллә?

Тиз генә киендем дә чын мәгънәсендә куа киттем. Аның шул мизгелдә Шәмәрдәндәге укытучы Әнисә апасында булуын, Арча ягына поездның кичкә таба гына китәчәген чамалыйм. Саба авылы башына чыгуга, бер йөк машинасы очрады (изге эш уң була бит ул). Әрҗәсенә менеп бастым. Бик җилле көн иде. Шәмәрдәнгә җиткәндә, «Мин сине яратам!» дип кычкырып барганда, башымдагы эшләпәм очты. Шоферны туктатырга яхшысынмадым. Алга китеп, шуны әйтергә кирәк: соңгы 32 ел эчендә бу юлдан мин күпме үткәнмендер, анысын санап булмый. Әмма узган саен машинамның тәрәзәсеннән эшләпә очкан җирне карыйм. Син, хөрмәтле укучым, Тәлгат Нәҗмиев һаман шул баш киемен эзли икән, дип уйлый күрмә тагын. Урыс әйтмешли, «дело не в шляпе». Шашынып-хыялланып, сөю һәм сөелү ләззәтеннән «исереп» йөргән көннәремне искә төшереп, яшьлегемне сагынам мин бу урында. Ниндидер әйтеп булмый торган искиткеч рәхәт мизгел кичерәм.

Дөрестән дә, Әнисә апада булган Лемарам. Язның бик матур көне иде. Зәңгәр күктән елмайган кояш нурлары астында өчәүләп юл буендагы урманга чыктык. Ул кар астыннан яңа гына борын төрткән умырзаяларның, ап-ак, төз каеннарның гүзәллеген тасвирларга сүзләр, чагыштырулар, эпитетлар хәзер дә таба алмыйм.

Әнисә апа умырзая җыйганда, без аңлашып алдык.

— Егетең янына ашкынасыңдыр инде? — дим.

— Ышанмасаң ияреп кайт, — ди бу миңа.

Кайттым да. Дөрес, алай бик эреп каршы алмадылар. Өйләренә кереп чәй эчтек. Кич клубка чыктык. Анда да шикле кешеләр күренмәде үзе. Әмма йокларга өйгә кертмәделәр. Ике-өч йорт аркылы карт әбинең (булачак бабайның төп нигезе) келәтенә урын җәелгән икән миңа. Шунда йокладым. Бик туңдым. Чөнки иртә язда төннәр салкын була бит. Суык җелегемә үтте. Тешләр тешкә тимәде. Хәзер анда бозау кадәр эт — Вулкан яши. Шул келәтнең яныннан үткән саен, яшьлегемнең салкын, ямьсез,

шыксыз хатирәсе яңара.

Икенче көнне кыш буе җыелган тиресне, ат арбасына төяп, бәрәңге җиренә түктек. Шул мизгелдә бакча башыннан гына бер егет килде безнең янга. «Шушы икән!» дип уйлыйм эчтән генә. Исеме Ленар булып чыкты. Бедер-бедер сөйләшәләр болар. Мин лычкылдап беткән тиресне каерам.

— Кияүгә чыкмыйсыңмы соң әле? — дип сорый Ленар.

— Юк әле, — ди Лемара.

— Болай булгач, озак йөрмәссең инде, — ди тегесе, миңа таба ым кагып.

Эчкә җылы керде.

Егет булып башка кайтмадым бугай Сеҗегә.

Ярар, матур гына, тәртипле генә йөреп торабыз. Мине алты айдан соң мәдәният йортыннан җирле радиотапшырулар оештыручысы итеп редакциягә күчерделәр. 1973 елның июнь аенда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә имтиханнарны (читтән торып уку бүлегенә) уңышлы гына тапшырып кайттым. Мәдәният бүлеге мөдире — остазым Госман Гарипович белән бераз әңгәмә корып утырдык.

— Автоклуб өчен микроавтобус тибындагы яңа машина кайтты, — ди бу. — Өйләнсәң, биреп торырмын, яме, — дип тә өстәде...

Кичен Лемарам янына ашыктым. Сагынышканбыз. Әмма күңелсез хәбәр җиткерде бу миңа. Әнисе тагын чакырып телеграмма суккан моның. Башка кабат әллә нинди азгын уйлар килде. Мәңгегә югалтмаммы? Кыскасы, кот очудан тиргә баттым, аркамнан кара тараканнар чабышып үткәндәй булды.

Шуннан ике дә уйлап тормыйча әйтеп салдым:

— Бүген өйләнәм мин сиңа! Яңа машина да кайткан.

Һәм тыкрык буйлатып күтәреп диярлек алып та төштем. Ерак түгел бит. Хәләлемнең бер кулыннан тоткан килеш тәрәзәгә шакылдатам. Мәрхәбә апа (ул — элеккеге Таҗи мулланың карчыгы) чыкты.

— Мондый эш булмый. Икегезнең дә әти-әниләрегез бар. Башта авылларыгызга кайтып рөхсәт сорагыз, — ди бу.

— Минем бүтән тәкатем калмады. Фәрештәләрнең «Амин» дип дога кылган минуты җитте. Бар, көш, шу Лемара фатирына — Камәрия апа янына, — дип бик каты итеп әйттем.

Нишләсен бичара карчык. Таягына таянып, титак-титак килеп (бер аягы кыскарак иде мәрхүмкәйнең) без төшкән тыкрыктан юк булды бу...

Икенче көнгә мәдәният бүлеге мөдиренә шалтыратам.

— Госман абый, берничә көннән машина кирәк булачак бит. Өйләндем мин.

— Кайчан?

— Бүген. Таң алдыннан.

Авылга кайтып киттек. Бабай белән әбидән бик әйбәтләп кызларын сорый башладым. Бабай каршы килеп маташкан була. Икебезгә бер «зәхмәт»не кәктек. Шуннан йомшап китте. «Уйлап бетерербез», — диде һәм йокларга чоланга чыгып китте.

Әби безгә урынны алты почмаклы өйнең түр ягына, буялмаган, сап-сары итеп юылган идәнгә җәеп бирде (бик әйбәт кеше ул). Кызы мәсьәләнең хәл ителгәнен әйткәндер инде.

Иртән бабай, өй ишеген ачып, өч-дүрт җөмләле реплика атты:

— Монда уйлап бетерәсе калмаган икән инде. Аллага тапшырдык!

Без, кем әйтмешли, дәльше — Казанга киттек туп-туры карап. Укырга керү-кермәү ачыкланмаган бит әле. Бигрәк барысы бергә өелде. Чыдаган башка рәхмәт.

«Катык поезды»ннан төшеп, университетка юл алдык. Ак колонналары белән каршы алды безне — нибары бер тәүлек гомер иткән яшь гаиләне. «Монда Ленин, Толстой кебек олы шәхесләр укыган», — дип таныштырам җәмәгатемне.

Беренче катка кереп, игъланнар тактасы янына килдек. Боерыклар чыккан. Әнә безнең группа. Әмма фамилияне таба алмыйм. Күзләрем әлҗе-мөлҗе килә.

Иң беренче Лемара күреп алды (ярый аны алып килгәнмен әле). И сөенештек! «Күрдеңме, юк-бар кеше алмады сине!» дигән булам. Тизрәк кайтып китәргә ниятләдек. Әле үземнең әти-әнидән дә өйләнергә рөхсәт сорыйсы бар бит...

Күз карашым шундагы бер белдерүгә төште. Шул ук көнне сәгать икедә «установочная сессия» башлана диелгән. Егыл да кит. Ярты сәгать вакыт калган. Бер килсә килә бит ул. Бичәмне яшь Ульянов һәйкәле янындагы «таба» кырыена утырттым да лекциягә кереп киттем. КПСС тарихыннан икән беренче дәрес. Эдуард Еникеев дигән укытучы шундый салмак кына, җайлы гына итеп укый инде менә. Үтереп-үтереп йокыга тарта. Кыскасы, шагыйрь әйтмешли, баш мәтәлә алга да, баш мәтәлә артка да.

Ике пар лекциягә генә түземлек җитте. Шылдык әкрен генә вокзалга.

Шулай итеп, студент һәм кияү (ир) булу ләззәтләрен берьюлы кичерә-кичерә, газиз әти-әниемнән өйләнергә фатиха алып, Байлангар авыл советына никахны законлаштырырга гариза калдырдым да, без өйләнгәч, төн кыска булды, дия-дия, уникe көнлек беренче сессиягә китеп бардым.

Ә Лемарам, үзенә кредит рәсмиләштереп, кияү һәм килен бүләкләре хәстәрләргә калды. Балдаклар-

ны соңрак, уртак гаилә бюджетыбыз булгач, сатып алырга булдык. Ярдәм итәрдәй кешеләребез юк. Икебез дә биш-алты балалы колхозчы гаиләләренең олы улы белән кызы икәнбез. Шуңа күрә аларның үзләренә бездән ярдәм кирәк.

Уңайсыз булса да языйм әле. Шулкадәр озак булып тоелды ул тәүге тапкыр аерылулар. Ярый әле группада Лемарага тач охшаган бер кыз бар иде (фамилиясен язмыйм, йә ире көнләшер). Лекция буе а-шардай булып шуңа карап утырам. Охшаса охшар икән. Суйган да каплаган. Бит уртасында мәхәббәт чокырына кадәр туры килә. Утыра торгач, күзләр дә очрашып куя, оялып та куям үзем.

Ниһаять, сессия тәмамланды. Сабага «очам». Ул вакытта юллар начар, автобуслар да өчәр сәгать йөри, җитмәсә.

...Июльнең җидесе мәңгегә истәлекле көн булып калды безнең гаилә тормышында. Башта Сеҗедә кыз озату йоласы булды, аннары Байлангар авыл советы башкарма комитеты сәркатибе Мәүҗидә апа язылыштырды. Тыйнак кына туй мәҗлесе үткәрдек тә икенче көнне Сабабызга тормыш итәргә китеп тә бардык. Башта минем фатирда яшәп тордык. Бергә гомер итә башлау истәлеге итеп тәүге алган әйберебез ун данә әлүмин кашык булды.

Сулар ага торды. Г.Тукай урамындагы Дәминова Гөлсем апаның ишегалдындагы кечкенә өенә башка чыктык. Өч тәрәзәле шушы тыйнак кына йортта үткән көннәребезне хәзер дә сагынып искә алабыз. Утын ягып җылыта идек. Лемарага декрет ялы бирделәр. Өебез кечкенә булса да, нурлы, җылы. Мин, эштән кайткач, укыштыргалаган да булам. Тагын сессиягә барасы, имтиханнар тотасы бар бит. Лемара да булышырга теләк белдерде. Әлеге дә баягы КПСС тарихыннан конспект язарга тотынды бу «беспартийная» башы белән. Берме-икеме общий дәфтәр сырлады. Укып карыйм, каймагын гына сөзеп бара инде, малай.

Кышкы сессия якынлашты. КПСС тарихыннан дүртле куйды Эдуард абый. Читтән торып укучыга моннан да зур билге юк инде ул.

Имтиханнарның барысын да биреп кайттым. Әмма вә ләкин Лемарага конспектлары өчен җиренә җиткереп рәхмәт әйтә белмәгәнмен. Гомумән, студент халкы мәнсезрәк бит ул. Имтиханга керер алдыннан бөтерелә-сырлана Алладан ярдәм сорый, монысын да исән-сау бирсәм, икенче сессиягә яхшылап укып килер идем, дия-дия вәгъдәләр бирә (кайткач барыбер рәтләп укымый, чөнки эшлисе, тормышын алып барасы бар аның). Ә инде зачеткасына билге куйдырып чыккач, әллә кем була: «Укыган тема чыкты, болай да белә идем бу фәнне», — дип сөйләнә башлый. Баш югары күтәрелә, тавыш бөердән чыга. Менә мин дә: «Теге конспект бик кирәк булмады, үзем беләдерием», — дигән кебегрәк сүз ычкындырганмын. Лемарамның хәтере калган булган, миңа сиздермәде үзе. Шуңа күрә, соң булса да уң булсын дигәндәй, хәзер ихлас күңелдән рәхмәт әйтим әле, яме, җаным.

Тормыш матур гына дәвам итә. 19 май — Пионерия көнне улыбыз туды. (Алга таба узып шуны искәртим: кызыбыз Гөлназның дөньяга аваз биргән көне — 29 октябрьдә — Комсомол бәйрәмендә, оныгыбыз Гадел дә Татарстанның мөстәкыйльлек көнен сайлады. Үзебез дә Совет Армиясе һәм 8 Март тирәсен чамалаганбыз.) Шомырт чәчәге өстенә ап-ак кар яуган иде ул иртәдә, күршеләр бакчасыннан бер кочак чәчәк җыйдым да (рөхсәт белән, билгеле) киттем нәселебезне дәвам итүчене күрергә! Әле әнисе аякка басмаган иде. Ниязны алып чыгып күрсәттеләр. Үземнең «курнос» борынны шундук таныдым. Җәмәгатемә исән-сау терелүен теләгән кош теледәй кәгазем белән күчтәнәчләремне керттердем дә малай белән мактанырга редакциягә йөгердем.

Ә минем шомырт чәчәкләремнең исе, палатага гына түгел, бөтен коридорга таралып, дару исләрен хәйран баскан икән. Ул чәчәкләрнең зыкымы озакка барды. Колхозларда, фермаларда булганда, асыл затлар, танып: «Мин синең Лемараң белән бергә бәбәй таптым. Безнең мужиклар еш килә алмадылар, килсәләр дә, букет күтәреп йөрмәделәр, авылда чәчәк кайгысымыни анда! Алып төшкән ризыгыңа, шомырт чәчкәләреңә рәхмәт», — дип әйтүчеләр булгалады әллә ничә еллар үткәч тә.

Ә инде бәбине шифаханәдән алып чыккан көннәр әле дә күңелдә ниндидер бер күтәренке хисләр ташкыны булып саклана.

КПСС райкомының беренче секретарен йөртә торган дәрәҗәле шофер (сугышта да командирларны йөрткән) Мөхип абый белән алып кайттык. Мин сабыйны алып чыкканда, олпат гәүдәсе белән машина ишеген ачып торганы бүгенгедәй күз алдымда.

Менә инде хәзер читтән торып университетта өчәүләп укый башладык. Доцент Флера апа Сафиуллина «Татар теле белеменә кереш»тән керә иде (хәзер ул фәннәр докторы, профессор булды, дистәләгән китаплар, дәреслекләр чыгарды). Таләпчәнлеге истә калган аның. Мәсәлән, Биектау егете Рәшит Туктаровка имтиханда «Кешенең сөйләү органнары» дигән сорау чыкты. Теге өч сүз белән:

— Авыз. Үңәч. Бугаз, — диде.

Укытучыбыз Флера Садриевна:

— Сез кайда эшлисез? — дип сорады Рәшиттән.

— Мясокомбинатта, — диде ул.

— Әйтәм мясник кебек җавап бирәсең. Икеле, — диде Флера апабыз.

Мөхтәрәм мөгаллимәбез безгә «Телләрнең генеалогик классификациясе»н ятларга биргән иде. Шу-

ның күләмен ничек тасвирлыйм икән? Общий дәфтәрдәге өч куш битнең һәр шакмагына ике багана итеп бирәр тел (барысы 200 гә якын) тезелеп төшкән иде. Шуның кайсы телгә, төркемгә, нинди төркемчәгә кергәнен истә калдырырга кушты һәм, җәйге сессиягә килгәч, болай диде Флера апа:

— Әгәр дә телләр классификациясен ятламаган булсагыз, миңа имтиханга кереп тормагыз.

Мин шулай иттем дә. «Койрык» белән кайтып, җәй буе Лемара белән шуны өйрәндек. Тота да имтихан ала бу: «Удмурт теле кая керә?» Мин, карамыйча: «Фин-угыр телләренең Пермь төркемчәсенә», — дим. Аннан сорасам, ул да белә, ятлап бетергән бит, малай. Без шул «каһәр төшкән» телләрне өйрәнә башласак, бишектән Нияз да мес-мес итеп яткан җиреннән: «Ыгы-ыгы», — дип тавыш бирә. Тәмам өйрәнеп беткәч, дүртле куйдырып кайттым. Югары белемне әнә шулай бик тырышып, бөтен гаилә белән, ягъни, заманча әйтсәк, «семья подряды» нигезендә алдык без...

Хәзер инде яшьлекнең бу мизгелен сагынып искә алырга гына калды. Ниязыбыз, үзе югары белем алып, башта «Росгосстрах-Татарстан» акционерлык җәмгыятенең Саба филиалында инспектор, аннары сөт-май комбинатында баш икътисадчы, хәзер шунда ук генеральный директор урынбасары булып эшли. Белгечлеге буенча рус теле һәм әдәбияты укытучысы булган Люба белән өйләнешеп, мөстәкыйль тормыш итәләр.

— Татарча бик тиз өйрәнәчәкмен, — дигән иде Казан кызы, безнең нигезгә аяк басканда, кечкенә сумкасыннан «Русча-татарча сүзлек» чыгарып.

Һәм сүзендә торды. Ана телебезне тиз арада су кебек эчә башлады. Танылган журналист Гөлнара Зиннәтуллина әзерләгән «Иртә түгел, соң түгел» телевизион тапшыруыннан соң «Шәһри Казан» газетасында Әнвәр Сәмигуллин дигән авторның «Кайтаваз» рубрикасында түбәндәге эчтәлектәге мәкаләсе (16 февраль, 2001) дөнья күрде: «Күптән түгел Татарстан каналыннан бер тапшыру карарга туры килде. Анда Саба район газетасында баш мөхәррир булып эшләүче кешенең дә килене безнең милләттән түгел, ягъни катнаш никахта яшиләр, дип сөйләделәр. Казанда туып үскән кыз татарча өйрәнгән. Менә дигән итеп интервью бирде. Кычкырып шигырьләр укый. Чын татар кызыннан бер дә аермасы юк. Бер авыз татарча белмәүче кызның тел өйрәнүе — бик күңелле күренеш...»

Ә инде оныгыбыз Гаделгә килсәк, ике телне дә искитмәле камил белә. Кирәк вакытта «дедуля»сы белән «бабуля»сына «тылмач» ролен үти. Әле менә 2004 елны каршылау табынына җыелгач, килен «урдяк» дип ычкындырды. Бу сүзне Гадел бик тиз эләктереп алды да: «Әни, әни, үрдәкне тагын бер әйт әле?» — дип кабатлатты. Үзе ята-ята көлгән була «урдяк»тан.

Кызыбыз Гөлназ Саба мәктәбенең рус классларында укыса да, хәзер югары белемле татар һәм гарәп телләре укытучысы булырга әзерләнә, киләсе елга диплом алыр дип торабыз.

Ярар, укучым, озынгарак китте бугай «Йөзегемнең исемнәре... Лемара». Хәзер фикерне йомгаклау өлешенә таба юл тотыйк инде.

Гаилә бәхете. Нинди зур мәгънә салынган бу ике сүзгә. Гаилә бәхете ул бер-береңә һәрчак кирәк булып, бер-береңә ышанычлы таяныч булып бер түбә астында мөмкин кадәр килешеп яши алудыр. Менә без 30 ел Сабаның саф һавасын сулап, уртак фикерләр белән хыялланып яшәгәнбез икән, димәк, монда нәрсәдер бар инде... Гомумән, бу язмамның герое — җәмәгатем Лемараның үзе өчен иркенләп, җәелеп китеп яшәгәне юк әле аның. Шуңа күрә 2002 елда булып узган юбилеенда без аны тәбрикләп «Ватаным Татарстан» газетасында («Саба таңнары»нда түгел!) бердәнбер котлавыбызны бастырган идек:

«Байлар Сабасы авылында яшәүче Лемара Миннегали кызы Нәҗмиевага 18 февральдә 50 яшь тула.

Кадерле әниебез, сине ихлас күңелдән олы юбилееӊ белән котлыйбыз. Сине — ныклы терәгебезне, киңәшчебезне — Җир йөзендәге иң яхшы әниләрнең берсе дип саныйбыз. Чөнки син, үзең турында уйламыйча, фәкать безнең һәм эти өчен яшәдең. Шуңа күрә, барысы өчен дә рәхмәт әйтеп, синең алдыңда баш иябез.

Кадерле әниебез! Истәлекле көнең белән котлап, сиңа иң кадерлесе — бик яхшы сәламәтлек һәм эти белән тигезлектә озын гомер, кыскасы, моңа кадәр безнең өчен тырышканнарыңның игелеген күрүне телибез.

Карашларың җылы яңгыр кебек,
Елмаюың айдай сөйкемле.
Гел игелек кылып яшә әле,
Кояш чәчкән нурлар шикелле.

Иң изге теләкләр белән кызың Гөлназ, улың Нияз, киленең Люба, оныгың Гадел. Бу теләкләргә этиебез һәм барлык туганнарың да кушыла».

Дөрестән дә, ул гомер буе хезмәт сөючәнлеге белән аерылып торды. Кыска гына декрет ялы бетәр-бетмәс, балаларны карарга кеше табып, эшкә чыкты. Ул заманнарда өчәр ел өйдә тору мөмкинлеге юк иде. Лемарамның иң теләп башкара торган эше — чәчәкләр үстерү. Аларны һәм гөлләрне бик ярата ул. Җәй көне бакчабызда, алай гына түгел, ишегалдыбызда, аларның берничә дистә төрен очратырга мөмкин. Узган җәйне өстән-өстән генә санаган идек, илле җидегә җитте алар. Мәсәлән, розаның гына берничә төре — алсуы, кызылы, ак белән кызылның бергә кушылганы, хәтта кытайныкы да бар. Өйдәге

гөлләрнең саны кырыкка тулган инде. Ул аларны сабый кебек тәрбияли, сөйләшә, исемнәре белән мөрәҗәгать итә. Читтән шыпырт кына карап торсаң, әллә җиңеләя микән, дип тә уйлап куярга мөмкин. Бер елны «хәсрәтле» дә булдык. Шул көннәрдә ахирәт дусты Нәсфия шалтыратты.

— Хәлләрегез ничек? — ди бу.

— Коточкыч начар, — мин әйтәм.

— Бер-бер төрле нәрсә булдымы әллә?

— Булды шул, булды.

— Нәрсә булды? Сузма, әйт инде!..

— Лемараның сары розасы бетләде...

Боларга чәчәк белән гөл генә кирәк икән, дип уйлый күрмә тагын, укучым. Дөрес, гөл үбеп кенә яшәп булмый. Яшелчә-җимеш тә үстерә ул. Февраль-март айларында ук помидор, борыч кебек әйберләр чәчә башлый.

Моннан биш-алты ел элек булган тагын бер вакыйга искә төште әле. Бик иртә өлгерде ул җәйне помидорларыбызның бер өлеше. Өйдән чыкканда ук чеби йомыркасы кадәр иде алар. Җиргә күчереп утыртуга кызара да башладылар. Башкорстанда яшәүче бертуган энем Зөфәр белән җәмәгате Гөлсәвия кайттылар. Иртәнге чәйгә берничә помидор алып керде дә: «Үзебезнеке», — диде Лемара. Зөфәр ышанмады, үзе чыгып карады.

Авылга кайткач, әни энекәшкә помидор утыртырга кирәклеге турында әйткән.

— И, нәнә (Кукмара ягында әнигә шулай диюче гаиләләр дә бар), син әле утыртырга йөрисең, туган апаныкы кызарган бит инде, — дигән.

Төп хезмәт вазифасын да җиренә җиткереп башкарды. Озак еллар четерекле урында — стоматология кабинетында шәфкать туташы булды. Ул елларда чират коточкыч зур иде тешкә.

Башка төрле эшләргә дә кулы ябышып тора аның. Өченче ел булган бер вакыйганы искә төшереп үтим әле.

«Син барыбер комиссиядә буласың, Гөлназ имтиханга әзерләнә, шуның янында торам», — дип, район сабантуена бармады бу. Икенче көнне Сатыштан хуҗалык рәисе Наил Миннәхмәт улы, шалтыратып: «Тәлгат Саматович, безнең округтан район советы халык депутаты буларак, сабантуйга килүчеләрне һәм кайтучыларны котларсыз әле», — диде. Мин, Лемарага икенче көнне булса да милли бәйрәмебезне күрсәтим әле дип, аны алырга өйгә кайттым.

Башта күзләремә ышанмадым. Йортыбызның тышкы стенасын үзем алып кайткан сап-сары төскә буяп ята хәләлем. Ялт-йолт килеп торган буялган өлешенә хозурланып карап та тора әле. Аннан яңадан баскычка менеп китә... «Әйдә, сабантуйга», — дип әйтергә телем әйләнмәде минем, ихлас күңелдән башлаган шөгыленә булган «әпитетын» бозасым килмәде. Сайлаучыларымны үзем генә котлап кайттым.

Сабантуйга гына түгел, Яңа ел тамашаларына да бик исе китми аның.

...Күптән түгел эшләнгән абзарыбызның (сарай) озынлыгы ошап бетмәде хуҗабикәгә. Шуның печәнлек өлешен кыскартырга кирәклеген берничә тапкыр әйтеп карады ул. Яңа ел алдыннан Казаннан алтын куллы энесе, ягъни минем каениш Лемарик кайтты. Шуның белән, минем өйдә юк көннән файдаланып, печәнлекнең шул өлешен сүтеп ташлаганнар болар. Кыскасы, бер атна карлы буран астында үзгәртеп кору белән шөгыльләнделәр. Төгәлләү өлеше Яңа ел чыршысы ачылган көнгә — 24 декабрьгә туры килде. Кешеләрнең хатыннары кышкы сабантуйда — шул тантанада мәш киләләр. Ә минеке — түбәдә.

Шуннан кайткач:

— Фейерверклар ничек булды соң? — дип сорадым.

— Шәп, — диделәр апалы-энеле бертуганнар, — моннан, түбә өстеннән, әйбәтрәк күренә икән ул.

Гомумән, Лемараның андый гына вак-төяк балта эшләре үзенең кулыннан да килә. Чөнки бабай тимер һәм агач эшен бик булдыра. Каннан киләдер инде. Берсендә кайтып керсәм, осталар ясаган өйгә керә торган баскычны сүтеп җыеп ята бу. Лемарик белән мин ясаган эт оясын да ошатмады хуҗабикә. Аны кечерәйтеп, түбәсен матур итеп калай белән ябып куйган. Кыскасы, күңеленә ошаганчы, канәгать булганчы тырыша ул, максатына ирешмичә туктамый. Тормыш итәргә мин үзем дә җайлы, тыныч кеше инде. Теге вакытта: «Абзарны ник кыскарттыгыз?» — дип тә тавышланмадым, гомумән, минем Лемарага үз гомеремдә бер тапкыр да, балтаны дөрес тотмыйсың яисә кадакны туры какмыйсың, дип кисәтү ясаганым юк. Нервысын бозсаң, кан басымы күтәрелә аның. Болай да җәй җитә башласа борчылып тора. Эссегә чыга алмый. Бакчада кичен, төнге уникеләргә кадәр эшли, чәчәкләре, яшелчәләре арасында кайнаша. Капка төбендәге электр баганасына ишегалдына төшә торган итеп лампочка куйдырттым. Шуның яктысына рәхәтләнә инде. Миңа рәхмәт укый. Үзем иртән торып язарга гадәтләнгән мин. Шуңа күрә кыска җәйге төннәрдә ул ятканда, ә мин торып маташканда очрашкалыйбыз без...

Хөрмәтле асыл затлар, сез инде бу кеше хуҗалыгында бер дә эшләми икән, русча итеп әйткәндә, «работодатель» ролен генә үти икән, дип уйлап куйгансыздыр. Һич алай түгел.

Ир-ат вазифалары тулысынча минем өстә. Табу-кайтарту, эшләтү һәм башкалар. Озын җир казу, ти-

рес һәм ком кертү, түтәл әзерләү кебек чараларны җыйнаулашып башкарабыз. Хәтта оныгыбыз Гадел дә уенчык «КамАЗ»ы белән ком ташый. Тик аның машинасының бензины гына тиз «бетә».

Эштән соң ялын да оештырабыз. Сабадагы концерт-спектакльләрне, ШТМнарны (КВН) калдырмыйбыз диярлек. Казандагы якташларыбызның юбилей кичәләренә дә өлгерәбез әле. Ял дигәннән, ел саен «Бәкер» курортына бергәләп барабыз. Менә анда Лемарам бөтен мәшәкатьләрдән, бигрәк тә аш-су әзерләүдән арынып, иркенләп торып ял итә инде. Ә мин чираттагы китабымны «чүким». Ул сериаллар карый.

Менә шулай, бер караганда, барысы да ал да гөл кебек. Икенче караганда, тормышның язылмаган законнары да бар бит әле аның. Ватылмаса да, табак-савыты да шалтырамый тормый. Ачуланышкан вакытта күңелне кимерә, йөрәкне телгәли торган киеренкелекне озакка сузарга тырышмыйбыз. Икебезнең арада язылмаган бер кагыйдә бар: бу аңлашылмаучанлыкта кем үзен гаепле саный, сүзне шул башлый. Мәсәлән, берсендә мин командировкага китәр алдыннан «эләгештек». Чыгып киткән кешегә дә, озатучыга да әйбәт булмады, билгеле. Шуннан мин кичкә кадәр түзеп йөрдем дә, үземнең хаксыз икәнемне сизеп, телефоннан:

— Мин әйбәт кенә килеп урнаштым, — дидем.

— И Тәлгат җаным, ничек шалтыраттың әле! Шундый борчылып тора идем. Исән-сау йөр, яме... — дип тезеп китте бу.

Икебез дә, җиңел сулап, күрешкәнчегә кадәр, дип саубуллаштык.

Дөресен әйткәндә, шикәр дә, бал да түгел мин. Кәефсез чакларым да була. 25 елга якын мөхәррир булып эшләү чорында нинди генә вазгыятьләргә килеп капмадым. Ярыйсы-көйлисе кешеләр районда гына түгел, Казанда да җитәрлек. Газетаның чыккан һәр саны диярлек борчу китерә, ул йә өстәгеләргә, йә астагыларга, ягъни әбүнәчеләргә ошамый. Кайсыннан гафу үтенәсең, кайберләренә катырак та әйтәсең. Коллективы да четерекле бит аның, анда да катлаулы хәлләр, хата җибәрүләр чыгып тора. Шәхсән үзем, өйдә кунып, редакциядә яшәсәм дә, эштәге кирәк түгел кайбер проблемалар ияреп тә кайткалый. Менә шул ачуны баскан, «пар чыгарган» очраклар да булгалый.

Гомумән, без икебез дә төчелекне, ясалмалылыкны яратмыйбыз. Минем, белгечлегем буенча телче буларак, каты һәм туры итеп әйткәли, «Теш дигән койма артында тел дигән арыслан йөри» дигән гыйбарәне оныткалый торган чакларым да була. «Тәтием, тәтием», — дип кенә торган ир-атларны асыл затлар үзләре дә өнәп бетерми бит ул. Русчалатып «мямля» диләр андыйларны.

Әмма кыска вакытлы үпкәләшүләр истәлекле мизгелләр генә ул. Ә иң мөһиме шул: озын-озак елларны, сикәлтәле-чокырлы тормыш юлларын бергә-бергә, үкенмәслек итеп, бер-береңөчен җаныңны бирергә әзер булып, бер-береңә таянычка әйләнеп, бер-береңә ихтирам-хөрмәтне югалтмыйча картлык көннәрендә, шагыйрьләр әйтмешли, гомер көзләренә тыныч күңел белән керергә язсын иде. Бәхетле ир-атның ахирәткә җәмәгатеннән алда күчүе дә сөенечле фалдыр.

Гомер дигәнең, чабышкы аты кебек, җилләп-давыллап бик тиз узып китә икән ул. Туарга, тормыш корырга да өлгермисең, икеңнең дә ярты гасырлык юбилее үтеп, яшәү кояшың инде баюга таба авышып та өлгергән була. Ә менә шул картлык көнеңдә бер түбә астында күзгә-күз карашып һәм киңәштабыш белән килешенеп яшәүгә ни җитә!

Әмма монда тагын иң мөһим бер нәрсәне ассызыклап үтәргә кирәк: балаларның чәчләренә чал кергәндә дә әни олы йөрәкле Ана булып кала.

Нияз белән Люба да, кызыбыз Гөлназ да, оныгыбыз Гадел дә, үзем дә, әлбәттә, бу язманың хуҗасы Лемарабызны, аннары инде барыбыз бергәләп Сеҗе һәм Байлангар авылларында гомер кичерүче Кафия белән Габидә әниләребезне бик яратабыз һәм хөрмәт итәбез.

Мин шушы язмага ничек нокта куярга икән, дип уйланып утырдым да, мәшһүр «Ана» романының авторы, рус халкының пролетар язучысы М.Горький сүзләрен тагын бер мәртәбә искә төшерергә булдым: «Мәхәббәте һичбер киртәләрне белми торган, күкрәк сөте белән бөтен дөньяга хәят биргән хатын кешене — Ананы олылыйк! Кешедә булган гүзәллек кояш нурыннан һәм ана сөтеннән килә, — менә шулар безнең йөрәкләрне яшәүгә мәхәббәт белән сугаралар!.. Гөлләр кояшсыз чәчәк атмый, мәхәббәтсез бәхет юк, хатын-кызсыз мәхәббәт юк, анасыз — шагыйрь дә, батыр да юк!» — дип, тыйнак кына имзамны куям.

*2004*

# Эчтәлек

**I бүлек**

Каләм көче. *Мәгъсум Хуҗин* .......................
Бухенвальд кабат сагышта ........................
Яуширмәдән Истанбулга .........................
Саумы, кояшлы Төркия! .........................
Мәртәбәле кунагыбыз ..........................

Пушкин һәм лицей ............................
Тархан ягында ...............................
Разлив тугайларында ...........................
Без — кардәшләр .............................
Казан белән Томск арасы .........................
Сабантуй — борынгылык бәйрәме ....................
Кече авылда олы бәйрәм .........................
Җәйге гүзәллекне сагынып ........................
Тарихи төбәк ...............................
Талантларга бай як ............................

## II бүлек

Биш очрашу ................................
Ул — Тукай замандашы .........................
Күпне күргән, күпне кичергән ......................
Танылган шәхесләр ............................
Гыйлем иясе ................................
Хәтер ташы ................................
Халкыбызның тутыкмас җәүһәрләре ..................
Фольклорчы, галим, музыкант ......................
Мәңге яшәр Әлмәндәр ..........................
Профессорлар гаиләсе ..........................
Фәрештәләр рәхмәт укыр ........................
Иҗат чишмәләре тынмый ........................
«Кеше китә — җыры кала» ........................
Хикәяче ..................................
Омтылышлы талант иде .........................
Борчулы җан ...............................
Мөгаллим дә, журналист та ........................
«Туган җирем дә, туган көнем дә икәү...» ................
Сабыр ире иде Сабаның .........................
Театр — аның яшәеше ..........................
Кан һәм җан тарту ............................

## III бүлек

Зенитчы Мәдинәкәй ...........................
Җитмеш биш яшьлек «егет» .......................
Гармун иясенә иреште ..........................
Хатирәләр яши күңелдә .........................
Урман юлы — гомер юлы ........................
Горурлану .................................
Районыбызның беренче башлыгы ....................
Урман белән бәйле гомер ........................
Яшәү яме — хезмәттә ..........................
Кырык дүрт ел мәктәптә .........................
Милләт җанлы Шамил ..........................
Нарасыйлар арасында ..........................
Шигырьле гомер .............................
Шәхси архивка күчкән хат ........................
Үзе яккан учакка чакырып ........................
Фирүзә төсендәге шатлык ........................
Рәхмәт яусын Исмәгыйльгә! .......................
Алтын куллы Ногмановлар .......................
Бирешмәгез, ветераннар! .........................
Җир дә сорый ашарга ...........................
Төп нигезнең тоткасы ул .........................
Районыбыз «министры» .........................
Туган як моңнары .............................
Картаямыни соң йөрәк!.. .........................
Үзе композитор, үзе шагыйрә .......................
Сәламәт һәм бәхетле булыгыз! ......................
Тәкъдире шундый булгач .........................
Илленче таң ................................
«Халык дошманы» малае .........................
Сез Габдрахман улымы? .........................
Чын тимер тутыкмый ...........................
Тормыш һәм көрәш мәйданында .....................
Галиҗәнап игенче .............................
Өчиле егете ................................
Таяну ноктасы ..............................
Икмәк булса, җыр да була ........................
Вакыт — җил ул .............................
Бәхетле ана ................................
Ерак буыннардан килгән серлелек ...................

Зыялы кешеләр зыянлы булмый ....................
Ике гасырны тоташтыручы ........................
Шешәдән стена өя Рәшит ........................
Мең рәхмәт сиңа, язмыш! ........................
Тенекинең соңгы көмешчесе ......................
Кулымдагы йөзегемнең исемнәре... Лемара ..............

Литературно-художественное издание

**Назмиев** Талгат Саматович

# Утоление жажды

Очерки

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Нәҗмиев** Тәлгат Самат улы

# Сабаларда эчәр суым булгач...

Очерклар

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Р.Н.Шакирова, Г.Г.Гарифуллина, С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 14.11.2006.
Форматы 84×108 1/32. Офсет кәгазе. «Kudriashov» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 19,32 + форз. 0,21.
Шартлы буяу-оттиск 20,58. Нәшер-хисап табагы 20,88 + форз. 0,36.
Тиражы 3000 д. Заказ З-943.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.